# АМИРХАН ЕНИКИ

**СОЧИНЕНИЯ**
в пяти томах

# 5

*Публицистические заметки*
*Статьи*

Казань
Татарское книжное издательство
2004

# ӘМИРХАН ЕНИКИ

**ӘСӘРЛӘР**
биш томда

**5**

*Публицистик язмалар*
*Мәкаләләр*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-4
Е56

**Төзүчесе**

*Нажия Ильясова*

**Редколлегия:**
*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Т.А.Миңнуллин, М.Х.Вәлиев, Н.С.Фәттах,*

*Н.Т.Ильясова*

**Еники Әмирхан**

Е56 Әсәрләр: 5 томда.— 5 том: Публицистик язмалар, мәкаләләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. — 479 б., рәсемнәр белән.

Бу томга язучының төрле елларда вакытлы матбугатта дөнья күргән публицистик язмалары, мәкаләләре хронологик тәртиптә тупланды.

ISBN 5-298-01355-4 © Татарстан китап нәшрияты, 2004



## КАСЫЙМГА СӘЯХӘТ

Күптән инде Касыйм якларын барып күрәсем килә иде. Тарихтан билгеле булганча, моннан 3—4 гасырлар элек Ука елгасы буенда әнә шул исемдә татар ханлыгы яшәгән бит әле. Тарихи риваятьләргә караганда, аны рус патшалары Казан ханлыгына каршы файдаланыр өчен оештырган булганнар («Касыйм» дип аталуы да Казан ханы Олуг Мөхәммәтнең руслар ягына качкан малае исеме белән бәйләнгән). Шуңа күрә дә ул, баш-аягы белән Мәскәү патшалары кулында булып, аларның Казан ханлыгына каршы барлык походларында да аты-коралы белән катнаша килгән. Әмма Казан ханлыгы җиңелгәч, Касыйм ханлыгының да кирәге беткән. Күпмедер вакыттан соң аны бөтенләй «ябып» та куйганнар.

Ләкин ханлык бетерелсә дә, халкы калган... «Касыйм татарлары» дип йөртәләр иде аларны. Мине дә, әллә кайчан беткән, юкка чыккан ханлыктан бигрәк, шул ханлык җирендә күптәннән яшәп килгән милләттәш халкыбызның язмышы кызыксындыра иде. Бармы алар, һаман шунда яшиләрме, ничегрәк яшиләр, нәрсәләре сакланган яки югалган — менә шуларны күпме-азмы белер өчен, Касыймның үзенә генә булса да барып кайту кирәк иде. Мондый теләк күптән туса да, мин аны төрле сәбәпләр аркасында үти алмыйча йөрдем. Бары 1985 елның август башында гына мин, кинәт кенә кузгалып, Касыймга табан, ниһаять, чыгып китә алдым.

Касыйм шәһәре, әйткәнебезчә, Ука елгасы буенда. Хәзерге вакытта ул Рязань өлкәсенә керә. Аңа Казаннан туры юл юк. Муром аша, яки Горький аша барырга кирәк. Мин Горький аша су юлы белән барырга булдым. Алтынчы августның төнендә Әстерхан — Горький пароходына, ничектер ансат кына аерым каюта алып, әйбәт кенә утырып киттем. Җәйнең әле хозур чагы, август башында гына коры көннәр дә бик кыздырып җибәрде. Көндезен пароход палубасыннан инде картая башлаган, йокымсырап утырган яшькелт-соры тауларга, кара-куч-

кыл урманнарга, аксыл кырларга карап баруы да күңелле иде.

Бер тәүлекне тутырып, икенче көннең иртәсендә, сәгать алтыда, пароходыбыз Горькийга җитеп туктады. Ярга чыккач та, мин иң әүвәл Касыймга пароходларның кайдан, кайчан китүен белештем. Сәгать җидедә «Ракета» китә, диделәр. Мин аңа өлгергән дә идем, ләкин, кызганычка каршы, билет сатылып беткән, касса инде ябык иде. Ә бу «Ракета» дигән нәрсә тәүлеккә бер генә тапкыр китә, имеш, шулай итеп, миңа икенче көннең иртәсенә кадәр Горькийда калырга туры килде. Хәерле булсын, дидем дә, башта елга вокзалының кунакханәсеннән үземә урын алдым. Бусы көтелмәгәнчә ничектер уңышлы килеп чыкты. Аннары иртәгә китәр өчен билетны да бүгеннән алып куярга булдым. Ләкин монысы шактый ук мәшәкатьле булды. Иң элек зур залдагы алдан билет сатучы кассаның ачылганын бер-ике сәгать көтеп тордым. Инде бәләкәй тәрәзә ачылып, Касыймга билет сорагач, эчтә утыручы ханым коры гына, урын юк, диде. Һәм билет бирмәде. Аптырап калдым — болай булыр дип һич тә көтмәгән идем. Нишләргә?.. Монда тагын бер тәүлек утырыргамы — юк, булмый болай! Вокзалларда администратор дигән кемсә була иде, шуны эзләп киттем. Аны табып, хәлне аңлаткач, ул кассага записка язып бирде. Әлеге «юк» дигән кассиршага барып, берсүзсез билетны алып, кесәгә әйбәт кенә салып куйдым.

Юл йөргәндә, шуның ише хәлләр очрый инде ул. Әмма кайчагында — һич башка сыймый торганнары да. Икенче көнне, причалга барып, «Ракета»га утыргач һәм бераздан кузгалып киткәч, мин чын-чынлап хәйран калдым: монда урыннарның яртысы диярлек буш иде. Моны ничек аңларга? Ни өчен кичә миңа: «Урын юк»,— диделәр? Ә кем өчен соң бу урыннар? Бәлки, алдагы тукталышларда сатыр өчендер? Ләкин «Ракета» Горькийдан ераграк киткән саен, төшүчеләр күбәя, утыручылар азая барды. Кыскасы, мин бу хәлне аңлаудан ерак идем. Бары тик моны электән үк сакланып килгән алама бер гадәтнең дәвамыдыр дип кенә уйладым һәм Горькийда кемнәрнеңдер билет ала алмыйча торып калуларына ирексездән бераз сыкранып куйдым.

«Ракета» Горькийдан Касыймга 9 сәгать бара. Ә буфеты юк, махсус урыны булса да, ябык, эшләми. Хәтта бак белән суы да юк. Моны белмичә утырган кеше көне буе ач барырга тиеш. Мин әнә шундый пассажирларның берсе идем.

Әйтергә кирәк, Ука буйлары бик ямьле икән. Безнең

Агыйделдән зурректыр — менә шуның кара ярларына, киң тугайларына карап бару күңелне хушландырып, ашыйсы-эчәсе килүне дә бераз онытыргандай булды. Сәгать дүртләрдә, ниһаять, Касыймга килеп җиттек. Көн бик эссе иде.

Су буендагы күп шәһәрләр шикелле үк, монда да пристань түбәндә, кала үзе югарыда иде. «Ракета»дан төшкән халык, төеннәрен, яшь балаларын күтәреп, әкрен генә югарыга үрмәлиләр. Кемнәндер: «Шәһәргә менәргә транспорт юкмыни?» — дип сорагач, ул иренеп кенә: «Элек бар иде дә, хәзер юк шул»,— диде. Автобус, түбән төшеп тормыйча, югарыдан гына китә икән — рәхмәт яугыры! Чара юк, башкалар артыннан мин дә, әлсерәп, югарыга үрмәләдем.

Касыймның кунакханәсе биш катлы яңа, зур бина иде. Ничектер ансат кына миңа бер кешелек урын бирделәр. Кереп урнашкач та, ашау-эчүне кайгырта башладым. Ләкин шушы шәп, зур кунакханәнең дә буфеты юк, имеш! Бар иде, эшләүчесе чыгып киткәч, яңа кеше таба алганнары юк әле, диделәр миңа. Нишләмәк кирәк, була андый хәл дә безнең көнкүреш хезмәтендә. Ярый, түбәндә рестораны бар икән, тизрәк шунда төшеп киттем. Тик монда да күңелне теләгәнчә хушландырып булмады. Чәйләре юк икән, ә бу эсседә куе яхшы чәйне мин бик сагынып килгән идем. Шулай да өстәлләргә графиннар белән «морс» дигән су куйганнар — чәйгә караганда, бу кызгылт суның мәшәкате азрактыр, күрәсең. Аннары монда хәмернең һәртөрлесен китертергә була икән. «Анысы — пожалысты! — диделәр миңа елтыр официанткалар.— Конечно, норма белән генә!..»

Касыймда үткәргән дүрт көнемнең берсе якшәмбегә туры килде. Шул көнне төшке ашка төшсәм, ресторан халык белән шыгрым тулы. Ләкин ашап утыручылар бик сирәк күренә. Нишли соң бу халык монда? дисәм, аларның бик күбесе эчеп чыгарга керүчеләр, имеш! Һәр өстәл артында 3—4 кеше үзләренең 100 граммнарын көтәләр (норма шулай гына). Официантка китереп куйгач, бераз сабыр итә төшеп, үтә күренмәле «суны», ашыкмыйча, берьюлы иләп кенә каплыйлар, авызларын сөрткәлиләр, кесәләренә тыгып килгән ипи кисәген яки кыярларын тозлап кабалар да, аннары тәмәке тартып керер өчен тышка чыгып киткән булалар. Ә биш-ун минуттан кире кереп, икенче официантканың өстәленә утыралар да... 100 граммны яңадан кабатлыйлар (кайберләре исә, чыгып та тормыйча, бер өстәлдән икенче өстәлгә күчеп кенә утыра). Болар барысы да, күрәсең, даими йөрүче-

ләр. Официанткаларга да алар Маня, Валя, Галя дип кенә дәшәләр. Дөрес, үзара мөнәсәбәтләрдә бернинди нәзакәтлелек юк, ләкин бер-берләрен яхшы аңлыйлар булса кирәк — «алыш-биреш», гомумән, гаугасыз, тыныч-шома гына бара. Озын сүзнең кыскасы, якшәмбе ялын «отмечать итәр» өчен бирегә килүчеләр әнә шулай, өстәлдән өстәлгә күчә-күчә, үз нормаларын тутырып, тәмам канәгать хасил булып, ахырда үз аяклары белән «тәртипле» генә чыгып китәләр.

Сорау туарга мөмкин: ни өчен әле мин, төп максаттан читкә китеп, боларны язып торам? Эш шунда ки, болар барысы да — «Ракета»да буш урын була торып та, билет сатмау, пассажирларны 9 сәгать буена кайнаган суга да интектереп бару, ә менә мондагы ресторанда аракыны теләгән кадәр эчеп чыга алу — әйе, болар барысы да апрель Пленумыннан соң һәм эчүчелеккә каршы юнәлтелгән карарлар чыккач, күзгә бәрелеп торган тискәре күренешләр. Аларның тормышта тамыры тирән әле, кешеләрдәге иске гадәтләр белән нык бәйләнгән — димәк, аларны корытып бетерер өчен дә әле күпме вакыт һәм көч кирәк булачак. Йә, шулай булгач, кеше андый тискәре күренешләргә очраган чакта тыныч кала аламы? Менә минем дә дәшмичә тыныч каласым килмәде.

* * *

Инде булмаса төп максатка күчик. Төп максат, әйткәнемчә, Касыйм татарларыннан кемне дә булса күрү, сорашу, бүгенге хәлләре белән бераз танышу иде. Билгеле, минем кулымда беркемнең дә исеме дә, адресы да юк иде. Берәрсен очрату бары тик очраклы гына булырга мөмкин. Килгән көнне үк кунакханәдә юынып, ашап, бераз ял итеп алгач, кичкырын якын-тирә урамнардан бер әйләнеп кайттым. Татарлардан берәү дә очрамады, хәер, очраса да, мин аны кайдан таныйм?! Маңгаенда мөһере юк бит аның. Болай каранып йөрү, белмим, нинди генә нәтиҗә бирер икән?

Икенче көнне мин иртә генә торып, шәһәр базарына киттем. Анда инде татар ага-энесе очрамый калмас. Сөйләшеп торуларына колак салып та белеп булачак.

Базарга мин шәһәрнең борынгы үзәк урамы буйлап бардым. Мондагы таштан салынган берничәшәр катлы зур, таза, матур йортларга игътибар иттем. Күренеп тора: бу төз урам кайчандыр Касыймның эш һәм сәүдә үзәге булган булырга тиеш. Хәзерге кибетләрнең дә күбесе шушы урамда иде.

Менә базарына да барып җиттем. Монда да иң элек күзгә ташланган нәрсә — «гостиный рәт» (таштан салынган бер кыек астындагы тоташ кибетләр рәте) белән шактый тузган, төсен югалткан иске чиркәү булды. Ә базар үзе шулардан бер читтә, ачык мәйданда иде. Ләкин ул бик кечкенә дә һәм бик ярлы да икән. Бөтен базарында — бәрәңге дә яшелчә, шуннан башка нәрсә юк та диярлек (мәсәлән, ит, сөт азыклары бөтенләй күренмәде). Хәер, бер нәрсә бик күп иде: ул да булса, алма — алмага бай җир икән.

Минем, билгеле, аласым да, сатасым да юк — миңа монда берәр татарны гына очратырга кирәк. Әкрен генә каранып йөрим, ике-өч кеше сөйләшеп торса, шулар янына тукталып колак та салып торам. Аннары тагын кузгалып китәм; базарны бер әйләнәм, ике әйләнәм, өч тә әйләнәм, әмма очрамый гына бит татар! Мин тәмам аптырап калам — базарда татар булмасын, имеш!.. Бәлки, минем үземә дәшеп карарга кирәктер. Менә базар капкасы төбендә какча, кара тутлы бер кеше җиргә ачып куйган капчыгыннан стаканлап көнбагыш сатып тора. Нәрсәсе беләндер мин бу кешене татарга охшаттым һәм ипләп кенә аңардан, русчалап: «Гафу итегез, сез татар түгелме?» — дип сорадым. Ул борылып, гаҗәпләнеп миңа карады да: «Слава богу, я со дня рождения русский!» — диде. Шәп әйтте көнбагыш сатучы, һичбер төрле шик калдырмаслык итеп — шулай әйтү кирәк ул кем икәнеңне сораучыларга! Мин бик мәмнүн булдым аның бу җавабыннан. Тик шуннан соң базарда татар эзләп йөрүем миңа мәгънәсез бер эш булып тоелды һәм артык буталмыйча моннан тизрәк чыгып китәсем килде.

Ул көнне мин ялгызым гына шәһәрне карап йөрдем. Ханлык заманыннан калган кайбер нәрсәләрнең монда сакланганын белә идем — шуларны да барып күрмәкче булдым. Кунакханәдән ерак та түгел икән. Ука елгасына таба сузылган туры гына урам белән китеп, урта зурлыктагы бер мәйданга барып чыктым. Башта кечкенә, куе гына бакча аша үттем. Бакчаның урта бер җирендә — зур гына ак һәйкәл. Үзенә күрә кызыклы гына эшләнгән ул: яшь солдат белән яшь кенә хатын сыны, кулларын бер-берсенә сузган килеш, кара-каршы басып тора. Сузылган куллар өстенә нәни бала сыны утыртып куелган. Ватан сугышы корбаннарына багышланган бу һәйкәл нәрсәне аңлата? Җиңеп кавышуны, яшәүнең дәвам итүен булса кирәк — шулай аңладым мин.

Бакчаны үтүгә, ике катлы һәм аерым манаралы ак бина янына килеп чыгасың. Бу — татар ханнарыннан

калган мәчет бинасы. Мәчет үзе бер генә катлы булган, тик соңыннан, совет вакытында, икенче катны өстәгәннәр. Менә шунда инде шәһәр музее урнаштырылган. Мин кергәндә, монда беркем дә юк иде. Музей хадимәсе үз урынында утырып тора, ләкин мин аны борчымаска булдым — нигәдер ялгыз гына карап йөрисем килде.

Түбәнге катта ханнардан калган кайбер нәрсәләр куелган. Пыяла шкаф эчендә, мәсәлән, татарның тутыккан кәкре кылычы, тимер боҗралардан эшләнгән сугыш киеме, ханнармы, бәкләрме кигән чапан, бүрек, кайбер хатын-кыз зиннәтләре — җыеп кына әйткәндә, татарларга хас әйберләр монда бик аз. Бу калдык-постыклар «Касыйм ханлыгы»ның чынлап та вакытлыча гына оештырылган гомерсез бер сателлит булуын гүя үзләре үк әйтеп торалар иде.

Аннары монда бу якларның табигатен, хайваннар дөньясын күрсәткән кайбер экспонатлар да бар иде. Ләкин алар да күп түгел. Ике-өч бүлмәдән гыйбарәт түбәнге катны ашыкмыйча гына карап үткәч, мин икенче катка күтәрелдем. Монда бүлмәләр күбрәк тә һәм иркенрәк тә иде. Биредә куелган экспонатларның һәммәсе дә революция елларына, совет чорына һәм Ватан сугышына багышланган. Бу алтмыш-җитмеш еллык дәвер эчендә Касыйм шәһәренең тарихы шактый тулы чагылдырылган дип әйтергә була. Шулай ук монда сугыш каһарманнары һәм корбаннарының фоторәсемнәре дә бик күп — берәмләп карап бетерерлек тә түгел (соңыннан миңа татардан бер Советлар Союзы Герое булуын да әйттеләр, мәгәр музейда аның фотосы нишләптер минем күземә чалынмады).

Музейдан чыккач, мин борынгы мәчетнең манарасына да менеп төшәргә булдым (теләгән кешегә рөхсәт ителә). Манара эре ак таштан салынган, тышкы күренеше белән Болгар хәрабәләрендәге манарага бик охшаган (бер үк осталар салган диярсең), биеклеге бер 18—20 метр чамасы гына булыр. Менә торган баскычы гаять тар, текә, ике кеше очрашса, үтәрлек түгел. Менә шул баскычтан мин, иңнәрем белән ышкыла-ышкыла, кечкенә түгәрәк мәйданчыкка күтәрелдем. Манара калкулык өстенә салынганга күрә, моннан шәһәрнең үзен дә, бөтен әтрафын да бик тулы күзәтеп булырлык иде. Ука елгасының сул яры буйлап сузылган Касыйм зур гына бер шәһәр икән. Тоташы белән диярлек бер катлы җыйнак аерым йортлардан гыйбарәт, электән калган зур йортлар үзәктә генә күренә, безнең заманның дүртәр-бишәр катлы соры йортлары да күп түгел, ә менә иске чиркәүләр байтак

кына икән әле. Уканың аръягы еракларга җәелгән киң, якты тугайлык — шәһәр кешесенә барыр, йөрер урыннар күп монда. Мин үзем дә табигатькә якын шушындый тыныч, аулак шәһәрдә торырга риза булыр идем, әмма ләкин аның нииндидер бик үзенчәлекле авыр шартларына җайлаша алмам дип куркам.

Манарадан төшеп, урамга чыккач, кире кайтыр якка таба атладым. Болай ялгыз гына йөрүнең кызыгы шулай да азрак. Аннары беркемне очрата алмавым һаман эчемне пошыра да тора. Көнем әрәм бит әле, көнем.

Уйланып бара торгач, башыма кылт итеп бер фикер килде: тукта, мин әйтәм, Касыймның мәчете булгач, зираты да булырга тиеш ләбаса! Бәлки әле караучысы да бардыр. Эзләп тапсам, һич югы, шуның белән сөйләшермен.

Ләкин башта кунакханәгә кайтырга булдым. Көннең эсселегенә түзәрлек түгел. Мондый эсседә әллә кайдагы зиратны эзләп йөрү бер газап кына булачак. Янып-пешеп, бүлмәмә кайтып кердем. Эх, менә хәзер чәй булса иде, куе чәй! Бик заманча итеп салынган зур кунакханәдә чәй юк кына бит.

Көн тәмам сүрелгәч, кичке якта мин татар зиратын эзләп киттем. Ул ерак та түгел икән, шәһәр эчендә диярлек, киң, озын урамның очындарак куе бакча шикелле күренеп үк тора. Сузылып киткән калын койма, таза капка, бер катлы кечерәк йорт — болар барысы да кайчандыр чын кызыл кирпечтән гомерлек итеп салынган. Яңадан йөз ел торса да, үзлегеннән җимереләчәк түгел.

Капкадан үтеп, кечкенә йортның ишеген ачтым. Эче караңгы, кеше барлыгы сизелми. Башны тыгып кына: «Кем бар икән монда?» — дип дәшкән булдым. Түрдәге караватта яткан бер ир заты әкрен генә башын калкытты, аннары тавышы ишетелде:

— Кем кирәк?

Мин, читтән килгән бер кеше булуымны әйтеп, аның, мөмкин булса, торып чыгуын үтендем. Шуннан соң ул кузгала башлады. Капка төбендә агач эскәмия күземә чалынган иде — мин шунда чыгып көтәргә булдым.

Бераздан шактый арык, хәлсез агай бөкрәеп кенә минем яныма килде дә, ике кулына таянып, сакланып кына янәшәмә утырды. Исәнләштек. Танышу өчен мин фамилиямне, кайдан килүемне әйттем. Аның да исемен сорадым. Сафа исемле икән. Кайчандыр Нижгардан (Горький өлкәсеннән) килгән, менә шушы зиратны каравыллап ята. Аңа сиксән сигез яшь икән инде.

— Эшләве авыр түгелме соң? — дим.

— Нинди эш, эш юк, мәет бик сирәк килә,— ди агай.
— Касыймда татарлар күпме соң? — дип сорыйм.
— Әллә тагын, кем санаган,— ди сүлпән генә.
— Шулай да?..
— Ну, может, бер утыз-кырык семья булыр...
Билгеле, минем агайга ышанасым килмәде, кайдан белсен ул?!
Мәет килүенә карап кына әйтә торгандыр.
Бу кыска гына сөйләшүдән соң, мин аңардан мондагы берәр татар кешесенең адресын әйтүен сорадым. Касыймның төп үз кешесе булсын иде, дип тә өстәдем. Агай уйлана калды.
Нәкъ шул чакта безнең янга бик чандыр, тере-җитез генә бер карчык килеп туктады.
— Минем катын,— диде агай иренеп кенә, аннары карчыгына русча дәште.— Менә бу иптәш Казаннан килгән, мондагы берәр татаринның адресын сорый. Син, Катя, яхшырак беләсең, кемнәр бар әле касимскилардан?
— Әнә Ишимбаевка барсын! — диде карчык, уйлап та тормыйча.
— Дөрес,— диде агай да.— Әхмәт барсын да белә, сүләргә дә ярата.
— Кем соң ул Ишимбаев?
— Бывший учитель.
Мондый кеше миңа бик ярый иде. «Тетя Катя» адресын да өйрәтте. Мин, рәхмәтемне әйтеп, тизрәк шунда ашыктым. Кояш баеган иде инде, ләкин караңгылык иңмәгән иде әле. Федорова исемендәге аулак урамны озак эзләргә туры килмәде. Менә миңа кирәк йорт та: ике катлы, асты таш, өсте агач йорт. Бакчалы ишегалдына кердем. Өске катның тәрәзәләре киңенчә ачык, ут алынган, яп-якты. Мин шул ачык тәрәзәгә: «Әхмәт абзый!» — дип тавыш бирдем. Шунда ук тәрәзәдән зур гына чал баш күренде:
— Кем анда?
— Сезне эзләп килдем! — дидем мин аңа.
— Хәзер, алайса! — диде «баш» һәм, озак та үтми, түбәнге ишектән өлкән яшьләрдәге таза-базык кына бер абзый килеп чыкты. Күрештек. Мин кем икәнемне әйттем. «Әйдәгез, кереп сүләшик!» — диде ул миңа. Текә генә баскычтан менеп, зур гына өйалдын узып, иркен якты бүлмәгә килеп кердек. Уртада зур өстәл, өстәлдә кайнап торган самавыр — кичке чәйгә утырырга гына торалар икән. Бүлмәдә тагын бер яшь ир белән яшь ханым да бар иде — Әхмәт абзыйның кунакка кайткан

кияве белән кызы икән. Менә уйламаганда гына күңелле табынга туры килдем бит әле.

— Мактап йөрисез! — диделәр миңа, өстәл янына чакырып. «Мактамаган кая инде ул!» — дидем мин эчемнән генә, күтеп торган матур чынаякларга карап.

Хуҗам Әхмәт абзый яшькә миннән күпмегәдер олырак булыр, сирәк чәчләре тәмам агарган инде, әмма тулы йөзе җыерчыксыз-шома, күзләре дә тере, хәрәкәтләре дә әле иркен-җиңел дип әйтерлек. Ул мине бик гади һәм ачык каршылады. Сөйләшүебез дә күптәнге танышлардай табигый, җиңел башланып китте (күрәсең, минем ише «Касыйм ханлыгы»на килеп чыгучылар белән аңа еш очрашырга туры килгәндер). Сүзгә дә ул юмарт иде. Үзе турында да, бер сорау белән, барысын да сөйләде дә бирде. Касыймда туган, Касыймда үскән, бөтен гомерен шушында (һәм якын-тирә авылларда) укытучы булып уздырган. Иң мөһиме — Касыймның үткәнен дә, хәзергесен дә бик яхшы белә икән абзый! Сөйләшә торгач, кинәт исемә төште: бу мөхтәрәм кеше миңа таныш лабаса! Моннан дүрт-биш ел элек булса кирәк, күренекле журналист В.Песков (телевидениедә «Хайваннар дөньясы» дигән тапшыруны да алып баручы) «Комсомольская правда» газетасында Касыймның карт бер укытучысы турында озын гына очерк бастырган иде. Аның да бит фамилиясе, хәтерем алдамаса, Ишимбаев иде бугай. Әхмәт абзыйның үзеннән сорагач, ул бик гади генә: «Әйе, минем турыда иде шул!» — дип раслады. Кара син, нәкъ кирәк кешегә тап булганмын бит әле, бәхеткә каршы!

Шушы беренче кичтә үк Әхмәт абзый миңа шактый күп нәрсә сөйләде. Дөрес, без ерак тарихка — ханнар заманына кереп тормадык. Күптән беткән, онытылган инде ул. Башта ук әйткәнемчә, мине Касыйм татарларының соңгы замандагы (мәсәлән, XX гасыр дәвамындагы) тормышлары кызыксындыра иде. Ә бу заманны Әхмәт абзый үзе күреп тә һәм ишетеп тә бик яхшы белә икән. Кыскасы, сөйләшү бик кызыклы үтте, чәй дә бик тәмле иде — рәхәтләнеп бер эчтем, ичмасам!

Икенче көнне төштән соң Әхмәт абзый үзе мин торган кунакханәгә килде. Номерда бераз сөйләшеп утыргач, ул миңа шәһәрнең татарлар яшәгән өлешен күрсәтергә булды. Ашыкмыйча гына узышлый, мине һаман Касыймның үткәне белән таныштыра барды. Ханнар заманыннан ук татарлар монда үзләренә аерым бер төбәк булып утырганнар. Урнашкан җире калкулык өстендә булганга күрә, электән үк аны «Татар тавы» дип атаганнар. Ока елгасына таба сузылган хәзерге Татарская бе-

лән Нәриман исемендәге иң озын ике урам һәм шуларны аркылы кисеп узган кыскарак урамнар менә шул төбәкне эченә ала икән. Бу урамнардагы йортларның барысы да диярлек кайчандыр татарларныкы булган. Алар Касыймны да борынрак заманда Ханкирмән дип йөрткәннәр.

Әхмәт абзыйның сөйләвенә караганда, халык монда тулаем таза торган. Күбесе сәүдә яки сәүдәгә бәйле хезмәт белән шөгыльләнгән. Араларында хәтта чит илләр белән алыш-биреш итүче байлары да булган. Аннары Мәскәү, Петербург, Киев кебек мәркәз шәһәрләргә китеп эшләүчеләр, шулай ук зур сәүдә алып баручылар да аз булмаган. Мәсәлән, Мәскәүдәге каракүлче миллионер Ирзиннар яки Петербургтан алып Кырымга чаклы барлык зур вокзаллардагы рестораннарны тотучы Киевтагы Максудовлар белән Дивеевлар әнә шундыйлардан (шунысы да мәгълүм булсын: менә шул Максудовлар, гимназист улларын һәм кызларын татарча да укытыр өчен, әдип Галимҗан Ибраһимовны 1912 елны Киевка махсус чакыртып алалар).

Касыймлылар — үзара бик нык аралашып, оешып яшәгән халык. Касыймның үзендә бер-берсен белмәгәне, йөрешмәгәне, сәүдә яки хезмәт белән бәйләнмәгәне булды микән?! Берәрсе читкә китеп эш башласа да, тизрәк моннан йә якын туганын, йә яхшы танышын чакыртып алган. Приказчиклар, официантлар, хезмәтчеләр булып шулар эшләгән. Шулай ук өйләнешү, гаилә кору да күбрәк үз араларында барган.

— Гаиләләр ишле — һәркайсында җидешәр-сигезәр бала була торган иде,— ди Әхмәт абзый.

Бай йортларда балалар өчен гувернанткалар тотканнар, мәгәр аш-суны, гадәттә, бикәләр үзләре карыйлар икән. Тагын бер деталь: бу йортларда дворник һәм кучер булып күбрәк руслар хезмәт иткән. Болар барысы да, билгеле, революциягә чаклы булган хәлләр.

Ул заманда татар дөньясында көчәеп киткән прогрессив тәрәккыяттән касыймлылар да читтә торып калмаган. Хәтта кайбер җәһәттән алгарак та чыкканнар. Мәсәлән, Касыймда беренче югары типтагы мәдрәсә 1833 елда ук ачылган һәм җәдитчә укыту да, башка җирләргә караганда, иң элек шушы мәдрәсәдә башланган. Даны аның шактый еракка таралган. Үз тирәсеннән генә түгел, Идел буеннан, Уралдан, хәтта Себердән дә килеп укыганнар. Безнең язучыбыз Закир Һади дә шушы мәдрәсәдән чыккан кеше.

Халык саны һаман арта баргач, янә бер мәчет салдыр-

ган булганнар. Әхмәт абзый миңа аны да күрсәтте: архитектурасы бик матур, тик манарасы юк — сүтеп ташлаганнар. Шәһәрдә шулай ук бай татар китапханәсе дә булган. Татар телендә басылган барлык китаплар һәм барлык газета-журналлар килеп торган.

Без үзебезнең театр тарихын 1906 елдан башлыйбыз. Ә менә Касыймда халык өчен беренче ачык театр тамашасы 1898 елда ук уйналган. Әхмәт абзыйның әйтүенә караганда, бу хакта Рәшит казый Ибраһимов тарафыннан чыгарылган «Миръат» («Көзге») журналында хәбәр дә басылган булган. Ихтимал, соңрак Касыйм яшьләреннән Петербург һәм Мәскәүдә махсус театраль белем алган Әшраф Синяева, Гомәр Девишев кебек сәхнә осталарының чыгуы да очраклы хәл түгелдер. Әлбәттә, Касыймның рус культурасы үзәкләренә якын торуы, халкының шактый гына өлеше шул үзәкләр белән бәйләнгәнлеге дә аларга уңай йогынты ясаган булырга тиеш. Рус культурасы аша алар Европа культурасына да күпмедер дәрәҗәдә якынайганнар. Франциягә барып, мәшһүр Сорбонна университетын тәмамлап кайткан беренче татар кызы Сара Шакулованың Касыймнан икәнен искә төшерү дә без әйткәнне раслау өчен җитсә кирәк.

Инде Касыймның үткәне белән, өстән генә булса да, танышканнан соң, Әхмәт абзыйдан хәзерге хәлләрне сорашуы ничектер уңайсыз иде. «Татар халкы Касыймнан китеп беткән диярлек. Торып калганы да бер 60—70 гаилә генә»,— шулай диде Әхмәт абзый.

Әмма халык, таралып бетсә дә, юкка чыкмый бит ул. Язмыш кая гына ташламасын, яңа җирдә тамырланып яши бирә. Кая гына барсаң да, аларны очратып була. Еллар узу белән, картлар үлеп бетә, яңа буын үсеп җитә, аның артыннан икенчесе дә өлгерә. Болары инде Касыймны ишетеп кенә белә, бәйләмеш җепләр күптән өзелгән, мәгәр нәсел җепләре өзелмәгән, кайлардадыр, аерым ояларда нәселләре дәвам итә.

Ашыкмыйча гына киң урам буйлап атлыйбыз. Әхмәт абзый миңа татарлардан калган йортларны күрсәтеп бара:

— Менә бу Девишевлар йорты,— ди.

— Әллә Гомәр Девишев туган йортмы? — дип сорыйм.

— Ул кадәресен белмим, әйтә алмыйм,— ди Әхмәт абзый. Тагын Акалаевлар, Байрашевлар, Ширинскийлар йортын күрсәтә. Аннары, туктый биреп, каршы яктагы ике катлы йортны күрсәтеп:

— Әнә ул Әшраф Синяева туган йорт! — диде.

Бу йортлар барысы да бертөслерәк, барысы да ике кат-

лы: асты кып-кызыл кирпечтән, өсте озын-таза бүрәнәләрдән. Кайчандыр гомерлеккә исәпләнеп салынганнар һәм әле дә булса нык торалар. Аларның капка-коймалары да игътибарны җәлеп итмичә калмады. Күп җирдә бит йортлар торса да, капма-каршы череп, авып бетә. Монда исә капкалар бер үк стильдәге дүрткырлы юан баганалар рәвешендә, шул ук борынгы кызыл кирпечтән, гүя йортның үзеннән дә тазарак итеп салынган. Болар инде бервакытта да череп авачак түгел... Әхмәт абзыйның әйтүенә караганда, Мәскәүнең бер өлгер яшь архитекторы килеп күреп киткәч, «Касыйм татарларының капка-коймалары» дигән темага кандидатлык диссертациясе дә яклаган, имеш! (Касыйм татарларының матди культуралары буенча Казан галимнәре тарафыннан да махсус хезмәтләр язылды.— *Ред.*)

Икенче бер урамнан узышлый, юлдашым яшел түбәле җыйнак кына йортны күрсәтеп: «Закир Һади йорты»,— диде. Моннан күп еллар элек язучы яшәгән йортка мин, билгеле, башкачарак, кызыксыныбрак карадым. Закир Һади — тумышы белән касыймлы түгел, ләкин Касыйм белән нык бәйләнгән кеше. Әле үткән гасырның ахырларында ул Касыймның җәдит мәдрәсәсендә укый. Мөгаллим булып, якын авылларда үзе дә балалар укыта, инде бу яклардан китеп торганнан соң да, гомеренең ахырына таба, яңадан Касыймга кайта. Вафат булуы да — шушы туфракта (1933 елны). Болар барысы да аның тәрҗемәи хәленнән билгеле. Ә менә ничек, нәрсәдән үлгәнен ишеткән юк иде. Инде, сүздән сүз чыгып, Әхмәт абзыйдан Закир Һадиның утыз өченче елны Касыйм урамында ачтан егылып үлүен ишеткәч, мин ышанырга да, ышанмаска да белмичә аптырап калдым. Дөресме, чынмы бу? Әмма гомерен шушында уздырган олы кешенең сүзенә ничек ышанмаска мөмкин ди?!

Урамнар буйлап йөрү һәм Әхмәт абзыйны тыңлау борынгы китап укыган шикеллерәк бер тәэсир калдырды миндә. Гыйбрәтләр бар икән бу калада!..

Ә икенче көнне без янә әлеге тарихи урынга — «Касыйм ханлыгы»ның калдыкларына бардык. Бу юлы монда минем өчен иң әһәмиятлесе — Шаһгалидән калган тәкияне күрү булды (үзем генә килгәндә мин аңа нишләптер игътибар итмәгән идем). Хуш, нәрсә соң ул тәкия? Махсус эшләнгән бина эчендәге каберлек. Русчасы — «усыпальница» яки «склеп» була шикелле. Үзебезнең телдә моңа туры килгән «төрбә» сүзен беләм, мәгәр «тәкия»не беренче ишетүем. Касыйм татарларына кайдан килеп кергәндер — ачыклап булмады. Ярый, нindирәк соң ул тә-

кия? Сарай калдыкларыннан түбәнрәк җирдә эре ак таштан озынча дүрткырлы итеп салынган тимер ишекле, тәрәзәсез, тәбәнәк бер бина. Ишек башына татарча «Тәкия», русча «Текия» дип язып та куелган. Салынуы — 1555 елда. Ханнар заманыннан хәзергәчә бөтен килеш сакланып килгән тарихи истәлекле нәрсәнең берсе шушы бина да икенчесе — ак манара.

Әхмәт абзый миңа сөйли:

— Бу тәкия эчендә унбер кабер,— ди.— Барысының да ташлары бар, барсына да кем күмелгәне язылган. Тик бер генә кабернең ташы язусыз, шоп-шома, ягъни кемнеке икәне язылмаган. Ләкин мондагы халык телендә борын-борыннан ук ул кабер — Сөембикәнеке дигән сүз йөри. Һәм шуңа халык ышана да иде. Әмма ни өчен аның ташы ялгызы гына язусыз куелган? Моны Шаһгали, бу кабердә кем ятканын беркем дә, беркайчан да белмәсен өчен, юри шулай эшләткән. Чөнки Сөембикә Шаһгалине хан итеп тә, ире итеп тә танымаган,— үзенчә үч алмакчы булган инде касимский хан!

Бераз риваятьне дә хәтерләтә бу. Әмма моның, һичшиксез, реаль җирлеге дә бар. Казан тәхетендә утырган ханнарның бик күбесе онытылып бетсә дә, Сөембикә әнә онытылмаган, халык хәтерендә һаман сакланган. Исемен дә шушы көнгә кадәр күп кенә хатын-кызлар йөртә, революциягә чаклы чыгып килгән хатын-кыз журналы да «Сөембикә» дип атала иде. Сәбәбе? Бәлки, аның язмышы фаҗигале булганга күрәдер. Тарих ни әйтә соң бу хакта?

1549 елны Сафагәрәй хан үлеп киткәч, Сөембикә ике яшьлек улы Үтәмешгәрәй белән тол кала. Казанның олы голәмәләре бишектәге баланы хан итеп игълан кылалар, ә дәүләт эшләрен башкаруны әнисенә тапшыралар (ягъни регент итеп билгелиләр). Сөембикә акыллы, нык характерлы, гайрәтле хатын булган дип язалар элекке тарихчылар.

Бу вакыйгалардан соң бер ел да үтәргә өлгерми, Иван Грозный зур гаскәр белән Казанны алмакчы булып килә. Бик каты сугышлар башлана, Казан бирешми, Грозный чигенергә мәҗбүр була (шул чакта Сөембикә үзе, крепость өстенә менеп, гаскәр белән «кумандылык» иткән, имеш!). Мәгәр берничә айдан соң Грозный, күп гаскәр туплап, яңадан Казан өстенә килә. Көчләр тигез түгел, Казан никадәр каты торса да, хәле мөшкел, сугышны туктатыр өчен, ул солых сорый. Иван патша Казанны сугышып алуның җиңел булмаячагын күреп, солых төзергә риза була, ләкин бик авыр шартлар куя. Шартларның берсе — Сөембикәне, улы Үтәмешгәрәй белән

бергә, Мәскәү кулына тапшырырга. Казанның олы голәмалары һәм түрәләре бу шартларны кабул итәләр... Һәм 1551 елның августында Сөембикәне, баласы белән бергә зиннәтле кимәгә утыртып, Мәскәүгә алып китәләр. Казан халкы 18 ел ханбикә булып торган бу гаҗәеп хатынны «аглый, аглый» озатып кала (Сөембикә фаҗигасен Фатих Әмирхан да үзенең «Сөембикә» исемле хикәясендә язган иде).

Ә Казанга хан кирәк. Иван Грозный боерыгы белән тәхеткә Шаһгалине китереп утырталар. (Касыйм ханын Мәскәү патшалары гүя пешка урынына әнә шулай күчереп йөртәләр.) Шаһгали Казан тәхетенә инде өченче тапкыр утырып карый, әмма озакка түгел. Бу юлы да ул, үзенең кара эшен эшләгәч, Казан халкының нәфрәтеннән куркып, качып китәргә мәҗбүр була.

Сөембикәне Мәскәүгә китергәч, сабый баласын, аерып алып, чукындыралар, ә үзен бераздан Шаһгалигә хатынлыкка бирәләр. Соңгы гомерен авыр хәсрәт эчендә уздырып, ул 1557 елны шушы Касыйм каласында вафат була.

Әнә шулай язылган иске тарихи китапларда. Билгеле, мин үзем тарихчы булмагач, иске китапларда язылганнарның ни дәрәҗәдә дөреслеген раслап әйтә алмыйм. Ләкин шулай да халык телендә сакланган риваятькә ышанасым килә. Чөнки татар халкы, әйткәнемчә, Казан ханнары арасыннан бердәнбер Сөембикә образын һәм аның ачы язмышын онытмыйча хәтерендә саклап тоткан. Югыйсә кайдан туар иде әлеге риваять? Димәк, тәкия эчендәге язусыз таш астында яткан мәетнең Сөембикә булуы бик тә мөмкин. Әйе, фаҗигале һәм гыйбрәтле язмыш!

Бераздан без борынгы калдыклардан һәм хатирәләрдән аерылып, әкрен генә кузгалып киттек. Сүз күп булмады. Кайтышлый Әхмәт абзый шул ук мәйдандагы моннан 150 ел элек ачылган мәдрәсәнең бинасын күрсәтте. Касыйм «стилендәге» таза капканың ике ягында кызыл кирпечтән салынган берсе зуррак, берсе кечерәк ике гади генә йорт — ничектер шушы көнгә чаклы искермичә-тузмыйча матур гына торалар әле.

Әйтергә кирәк, Әхмәт абзый үзе дә Касыймның үткәне турында материаллар җыя икән. Мәйданнан кайтып, өенә кергәч, ул миңа катыргыдан эшләнгән карталар күрсәтте. Дәфтәр битеннән зуррак бу карталарда Касыйм татарларының көнкүрешләрен (әйтик, йорт-җирләрен, кием-салымнарын, аш-суларын) чагылдырган фотолар һәм шуларга кыска гына аңлатма текстлар урнаштырылган. Кызыклы һәм кирәкле эш. Тик югалмасын гына иде алар!

* * *

...Касыймда дүрт кич кунып, мин бишенче көнне кайтырга чыктым. Әхмәт абзый кияве белән үз машиналарында мине автовокзалга илтеп куйдылар. Юлым Касыймнан — Рязаньга, Рязаньнан — Мәскәүгә, Мәскәүдән Казанга иде. Әнә шулай тәмам булды минем безгә бик аз билгеле Касыймга кыска гына сәяхәтем. Үткәне нинди генә булмасын, Россия үзәгендәге ул кала да — безнең тарихыбызның бер сәхифәсе. Ә тарихның бер генә сәхифәсен дә ертып ташларга ярамый. Һәм мөмкин дә түгел, минемчә!..

*«Казан утлары», 1986, 11 сан*

## МӘГЪНӘЛЕ ЯШӘҮ

Туксан яшь!.. Бөтен бер гасырга җитә язган бу озын гомер үзе генә дә ирексездән бездә чын гаҗәпләнү һәм соклану тудыра. Моңарчы бит безнең халыктан чыккан акыл ияләреннән бу яшькә бары Сәйфи ага Кудаш кына җитте һәм узып китте. Мәдәният тарихыбызда менә икенче кеше — Бакый ага Урманче! Һәм иң мөһиме, иң куанычлысы — Бакый ага шушы яшенә иҗади егәрлеген, дәртен, өмет-хыялларын саклаган хәлдә килеп җитте. Ходай бирмеш һәр көн ул үзенең остаханәсендә — алъяпкычын буган, җиңен сызганган... Мәгънәле яшәү һәм армый-талмый эшләү дәвам итә!..

Мин бу кыска гына сүземдә Бакый ага Урманченың гаять бай, гаять төрле, чын мәгънәсендә гуманистик милли сәнгатенә профессиональ күзлектән бәя бирүне өстемә алмыйм — ул кадәресен белгечләр хөкеменә калдырыйк. Минем Бакый аганың мәдәният тарихында тоткан урынын беркадәр билгеләп үтәсем килә. Чөнки җае, вакыты шуны таләп итә.

...Безнең мәдәният — яшь мәдәният. Тамыры бик ерактан башланса да, мәдәниятебезнең аеруча үсеп, көчәеп, ачылып китүе шушы гасырның башларына туры килә. Мәгърифәттән кала, мәдәниятнең асылын тәшкил иткән яңа әдәбият, сәнгатьнең яңа төрләре бездә, календарь буенча, Бакый агадан да соңрак туды. Һәм һәркайсының тарих тарафыннан танылган, халык күңелендә онытылмыйча яшәгән «тудыручысы» бар. Мәсәлән, демократик рухтагы яңа әдәбиятның тууын без Тукай исеме белән бәйлибез, Тукайдан башланды, дибез. Аз гына соңрак туган театр сәнгатен инде без Габдулла Кариев исеме белән бәйлибез — аны, ягъни Кариевны, татар сәх-

нәсенең атасы, дибез... Шулай ук профессиональ музыканың тууын без бик хаклы рәвештә Салих Сәйдәштән башлыйбыз.

Бүгенге мәгънәдәге сынлы сәнгать исә бездә барысыннан да соңрак туды. Әмма «тудыручысы» кем соң?.. Бер дә икеләнмичә мин: «Бакый ага Урманче!» — дияр идем. Чөнки аңа хәтле бездә татарның милли сынлы сәнгате юк иде (сүз биредә рәсем һәм скульптура сәнгате турында бара). Менә шуны тудыручы, үстерүче, чын сәнгать итеп танытучы буларак, Бакый ага Урманченың мәдәният тарихында тоткан урыны билгеләнер дә инде... Аның озын гомере дәвамында өч буын рәссамнар туып җитеште, моннан соң да яңа буыннар киләчәк, алмашынып торачак, әмма алар дәвам иттерәчәк сынлы сәнгатьнең танылган атасы булып, һичшиксез, Бакый Урманче калыр.

Тукай, Кари, Сәйдәшләр шикелле!..

*«Казан утлары», 1987, 2 сан*

## БЕР СОРАУГА БЕР ҖАВАП

Сорау:

— *Татар әдәбияты үсешендә Г.Ибраһимовның роле нинди?*

Әмирхан Еники:

— Сорау җитди, Галимҗан Ибраһимов — зур шәхес: әдип, галим, җәмәгать эшлеклесе. Шуңа күрә сорауны конкретлаштырып, үземнең бурычны ныграк ачыклыйсым килә. Сүз билгеле, матур әдәбият һәм аның да проза дигән жанры турында барырга тиештер инде: безнең проза үсешендә Галимҗан Ибраһимовның әдип-художник буларак роле нинди?

Бу сорауда игътибарны иң элек үзенә җәлеп иткәне — «үсешендә» дигән сүз... Димәк, проза әдәбиятыбызның Галимҗан Ибраһимовка чаклы хәленә дә күз салырга кирәк була... Һәм күз салу белән ике нәрсәгә хәйран калырга туры килә: бер яктан бик нык артка калу, икенче яктан гаҗәп тиз алга китү... Уйлап кына карагыз: без диңгездәй галәмәт зур Россия уртасында яшибез, бөтен әйләнәбездә рус мохите, русның культурасы, сәнгате, әдәбияты... Бу әдәбиятның Гоголь, Достоевский, Тургенев, Толстой, Чехов кебек бөек әдипләре бар, аларның даһи әсәрләре бер-бер артлы чыгып тора, тарала, укыла, ә бездә әле бернәрсә дә юк. Ягъни, бик борыннан килгән шигъри әдәбиятыбыз булса да, проза дигән яңа реалистик әдәбиятның һаман да әле туа алганы юк. Бу ни эш?.. Әллә

безнең халык шуны күрмиме, әллә ул томана сукырмы, уку-язудан бөтенләй мәхрүмме?.. Юк, күрә, ишетә. В.И.Ленин искәртеп үткәнчә, Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк ана телендә укый-яза белү җәһәтеннән Россия халыклары арасында алда тора (Ленин В.И. Әсәрләр: 4 нче басмадан тәрҗемә.— 39 т.— 549 б.). Әмма шуңа карамастан бездә беренче реалистик проза әсәре бары 1886 елда гына дөньяга килеп чыга.

...Әйе, без бик озак, бик авыр уянабыз. Мәгәр бер уянгач, аякка тиз басабыз. Башта Муса Акъегетнең «Хисаметдин мелла»сы, аның артыннан ук Заһир Бигиевның «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә» романы (1887 елда) дөньяга чыкса, алардан соң тиз арада Риза Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Закир Һади, Мәҗит Гафури һәм башка язучыларыбызның яңа проза әсәрләре бер-бер артлы чыга башлыйлар. Боларга ялганып ук диярлек иҗатларын барысыннан элек прозага багышлаган Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Садри Җәләл, Ярулла Вәли, Шаһит Әхмәдиевләр әдәбиятка килеп керәләр. Исемнәр күп... Бигрәк тә Рәсәй өстеннән күкрәп узган бишенче ел давылының татар дөньясына бәрәкәтле йогынтысы гаять зур булды. Кыска гына вакыт эчендә әдәбият, матбугат, нәшрият эшләре искиткеч бер җанлану һәм күтәрелү кичерде. Әмма хикмәт гомуми җанлану, язучылар саны күбәеп китүдә генә түгел иде. Иң мөһиме — сыйфат ягыннан тиз үсү-үзгәрүдә иде.

Телебезнең саф татарчага әйләнә баруы, сүз сәнгате буларак аның нәфисләшүе, образлашуы, бизәкләргә баюы Фатихлар, Галимҗаннар заманына туры килә. Бигрәк тә Галимҗан Ибраһимов иҗатында бу ачык чагыла. Сез аның 1911—1914 еллар арасында язган хикәя, повестьлары белән мәкаләләрен генә чагыштырып карасагыз да, тел җәһәтеннән болар арасында ярылып яткан аерма күрерсез... Димәк, шушы фактган чыгып, югарыдагы сорауга беренче җавапны да бирергә була:

— Әдәби телебезне сафландыру һәм камилләштерүдә Галимҗан Ибраһимовның тоткан роле гаять зур.

Сыйфат ягыннан үсүнең икенче мисалы итеп, мин прозада жанрларның төрләнүен һәм ачык билгеләнүен әйтер идем. Озак та үтми, романны озын хикәядән (повестьтан), озын хикәяне кыскасыннан аерып була башлый (билгеле, күләм җәһәтеннән генә түгел). Болар жанр буларак формалашу белән бергә, һәркайсының зур осталары да мәйданга чыга. Һәр өч жанрның, бигрәк тә повесть белән хикәяләрнең, гүзәл үрнәкләрен Фатих Әмирхан белән Шәриф Камал бирәләр. Мәгәр шулай да бу

өлкәдә дә Галимҗан Ибраһимов иҗаты ныграк аерылып тора. Киң колачлы, социаль эчтәлекле романнарны, төгәл, камил язылган хикәя, повестьларны безнең әдәбиятта башлыча ул тудыра. Димәк, әлеге сорауга тагын бер җавап:

— Татар әдәбиятын прозаның төрле жанрлары белән баетуда Галимҗан Ибраһимовның роле шөбһәсез бик зур.

Һәм безнең проза үзенә иң якын торган бөек рус прозасына хас художество чараларын озакламый күпмедер дәрәҗәдә үзләштерүгә дә ирешә. Мәсәлән, әсәрдәге персонажларның портретларын бирү, характер үзенчәлекләрен ачу, эчке кичерешләрен чагылдыру; вакыйганы хикәяләгәндә тормыш күренешләрен, көнкүреш шартларын сүз ярдәмендә ачык картиналар итеп сурәтләү; кара-каршы сөйләшү формаларын төрләндерү, эчке монологларны киң куллану, хикәяләүне ничек тә тасвирлырак, җанлырак итеп алып бару; ниһаять, табигать күренешләренә киң урын бирү, табигатьне вакыйга белән бәйләү, образның рухи халәтен ачу яки автор фикерен көчәйтү чарасы итеп куллану... Билгеле, бу чараларны һәрбер язучы үзенчә куллана, ләкин инде шулардан башка әсәр язу юк.

Шул рәвешчә безнең яңа реалистик прозабыз күп булса бер 20—25 ел эчендә сүз сәнгате буларак тәмам өлгереп җитә. Моннан тагын бер нәтиҗә:

— Матур әдәбиятыбызның сәнгать булып җитешүендә Галимҗан Ибраһимовның роле шулай ук бик зур.

Ихтимал, мин журнал куйган сорауга тулы җавап биреп бетерә алмаганмындыр. Шулай да әйтелгән кадәресеннән дә ике төрле мөһим нәтиҗә ясарга хакым бардыр дип уйлыйм. Беренчедән, Фатихлар, Галимҗаннардан соң әдәбиятка килгән язучыларга алардан өйрәнмичә, үрнәк алмыйча иҗат итү мөмкин түгел иде инде. Алар «мәктәбен» узмаган берәр язучы булды микән?! Тик моны сукыр иярү, кабатлау дип кенә аңламаска кирәк... Һәрбер чын язучы, нинди генә «мәктәп» узмасын, ахыр чиктә бары үзенчә, үзе аңлаганча иҗат итә.

Икенчедән, безнең яңа реалистик әдәбиятыбыз революциягә кадәр тугандаш төрки халыклар өчен дә күпмедер дәрәҗәдә үрнәк иде. Безне укыдылар, бездән өйрәнергә тырыштылар... 1957 елны Алма-Атада Мохтар әкә Ауэзов белән очрашып сөйләшкән чакта, ул миңа:

— Тукай белән Галимҗан Ибраһимов сезнең генә түгел, безнең дә остазларыбыз! — дип әйткән иде.

Әдәбиятыбызга әнә шундый дан-абруй китерде безнең классикларыбыз!

*«Казан утлары», 1987, 3 сан*

## ЧЫНБАРЛЫК ҺӘМ ТУГАН ТЕЛ

Чынбарлык... нидән гыйбарәт ул?.. Без, ниһаять, ике телле халыкка әйләндек. Ягъни без хәзер ике телдә — рус һәм татар телендә сөйләшәбез, укыйбыз, язабыз. Мәгәр рус теле безнең тормышыбызда беренче урында тора. Бу һич тә арттырып әйтү түгел. Чөнки рус теле ул дәүләт теле, шушы телдә эш йөртелә, сөйләшүләр алып барыла, балалар һәм яшьләр шушы телдә укытыла — ул фән теле, техника теле һәм дипломатия теле дә. Кыскасы, бу телне үзләштерү безнең өчен хәзер бер зарурияткә әйләнде — ансыз инде яшәү дә, эшләү дә мөмкин түгел диярлек.

Шул ук вакытта безнең буыннардан буыннарга күчә килгән үз телебез дә бар бит әле... Газиз туган телебез!.. Без бу телдә үзара сөйләшәбез, китаплар, газета-журналлар укыйбыз, хатлар язышабыз, эч пошканда җырлап та алабыз. Туган телебездә әле матур әдәбият, театр, җыр-музыка яшәп килә. Әмма шуның белән телебезне гамәлдә куллану бетә дә дияргә ярый.

Күрәсез, ике телнең функцияләре арасында аерма бик зур. Шушы аерма телнең әһәмиятен дә һәм аңа булган мөнәсәбәтне дә, һичшиксез, билгели. Татар кешесе, мәсәлән, кая гына бармасын, яшәр һәм эшләр өчен ул, беренче нәүбәттә, рус телен яхшы белергә тиеш. Ә үз телен белү исә бу кадәр үк зарури түгел — хәзерге шартларда ансыз да яшәп була.

Минем кулымда статистик мәгълүматлар юк, әмма һич тә икеләнмичә әйтергә мөмкин: татар халкының 60 яшькә кадәр булган иң зур күпчелеге русча сөйләшә дә һәм укый-яза да белә. Чөнки алар барысы да диярлек совет мәктәпләрендә укып, русчаны яхшы ук өйрәнеп чыккан кешеләр.

...Инде 20—30 яшьтәгеләргә килсәк, болар өчен рус телендә сөйләшү яки уку үз телендә сөйләшү-укуга караганда да җиңелрәктер дип уйлыйм. Чөнки бу яшьтәгеләрнең бик күбесе шәһәрләрдә яшиләр, фабрика-заводларда, төзелешләрдә, сәүдә һәм көнкүреш хезмәтендә эшлиләр — ә монда инде, билгеле булганча, беренче нәүбәттә, рус теле гамәлдә йөри. Саф үзебезчә сөйләшүче яшьләрне бары авылларда гына күрергә мөмкин, ләкин аларның да урта мәктәп бетергәннәре русчаны да яхшы беләләр. Кыскасы, рус телен белмәүчеләрне авылыннан беркая да чыкмаган 70—80 яшьлек картлар һәм карчыклар арасында гына очратырга була. Мәгәр алар да, күпмедер вакыттан соң, «ахирәткә» китеп бетәчәкләр.

...Әйткәннәрдән күренә ки, рус теле безнең тормышыбызда хәзер беренче урында тора, ул кирәгрәк, ул күбрәк гамәлдә йөри, ә туган телебез исә икенче урында, арттарак, әһәмияте дә аның кечерәйде, кирәклеге дә шактый ук кимеде... Әгәр эшләр шулай барса, аның, шигъри күн шикелле әкренләп кечерәя-кечерәя, бөтенләй юкка чыгуы да бик мөмкин. Әлбәттә, бу әле бары юрау гына, андый хәл, ихтимал, булмас, булырга тиеш тә түгел, әмма куркыныч бар, шуны тою безне менә ирексездән хәвефләнергә мәҗбүр дә итә.

Кыскасы, хәзерге көндә тел мәсьәләсендәге чынбарлык әнә шуңардан гыйбарәт. Әйтергә кирәк, безнең ике телле халыкка әйләнүебез ул күптән башланган процесс. Бу процесс аеруча сугыштан соң көчәйде. Хәтеремдә, илленче-алтмышынчы елларда татар урта мәктәбен бетерүчеләрнең күбесе рус телен тиешенчә белмәү аркасында вузларга керә алмый башладылар, хәтта алтын медаль белән килүчеләр дә конкурстан үтә алмыйча калгалыйлар иде. (Чөнки телдән имтихан биргәндә, бернинди ташлама юк иде аларга.) Инде нәкъ шул елларда ата-ананың баласын үзләре теләгән телдә укытырга хаклары бар дигән мәгълүм закон чыккач, шәһәр җирендәге татарларның бик күбесе балаларын тизрәк рус мәктәпләренә бирә башладылар. Һәм бу бик табигый иде, чөнки һәркем иң элек баласының киләчәген кайгыртырга тиеш иде. Нәтиҗәдә шәһәребездәге татар мәктәпләре бушап кала, ә дүрт-биш елдан инде алар ябылып та бетәләр. Шулай да татар балаларын туган телдән бөтенләй мәхрүм итмәс өчен нииндидер чара күрергә кирәк иде. Ахырда безнең мәгариф органнары бердәнбер чара рәвешендә рус мәктәпләрендә туган телне өстәмә дәрес итеп керттеләр. Дәрес, мәҗбүри түгел, имтихан бирәсе юк, өлгергәнлек аттестатына кермәячәк. Нинди бала бөтен дәресләрдән соң калып, шул «өстәмә» дәрестә күңел биреп утыра алсын ди?! Һәм шушы бала өчен дә, укытучысы өчен дә бәрәкәтсез газаплы бер эшкә әйләнгән «дәрес» менә 20—25 елдан бирле инде дәвам итеп килә... Ихтимал, кайбер аралаш мәктәпләрдә мондый укытуның зур тырышлыклар аркасында күпмедер уңай нәтиҗә биргәне дә бардыр. Ләкин без моны ачык кына белмибез, гомуми хәлне чагылдырган мәгълүматлар да юк бугай, ә менә шәһәр мәктәпләрендә «өстәмә дәрес» алган татар яшьләреннән үз телендә юньләп сөйләшә белмәүчеләрне, кызганычка каршы, елдан-ел күбрәк очратабыз.

Безнең төп таянычыбыз моңарчы авыл мәктәпләре иде, шуннан чыга иде туган телне яхшы белүчеләр дә. Авыл

әле үз телендә сөйләшә, баласын да бишектән үк үз телендә тәрбияли. Ә моның әһәмияте гаять зур, бала урта мәктәпне бетергәнче үзенең табигый мохитендә яши, укыту сыйфаты әллә ни югары булмаган тәкъдирдә дә ул инде ана телен гомерлеккә өйрәнеп, белеп кала. Шуның өстенә әле ул рус телен дә 8—10 ел буена укып, яхшы ук үзләштереп, чын грамоталы кеше булып чыга. Ата-ана да канәгать, үзе дә бик канәгать — теләсә кая бара, теләсә нинди эшкә керә ала ул хәзер!..

Бу табигый процесс иде. Авыл һәм аның мәктәпләре безгә моңарчы милли җирлегеннән аерылмаган заманга яраклы кешеләрне биреп килде. Әмма соңгы 15—20 ел эчендә республикада төзелгән яңа шәһәрләр авылны бик нык суыра башлады. Күпме кызлар һәм егетләр шул шәһәрләрнең торак йортларына, баракларына күчеп беттеләр. (Мин инде аңа кадәр Бөгелмә, Әлмәт, Алабуга, Чистай кебек иске шәһәрләргә күчкәннәрне әйтеп тә тормыйм.) Хәзерге вакытта халкыбызның 70 проценты шәһәрләрдә тупланган булырга тиеш. Шунда яңа гаиләләр оеша, шунда ук яшенә җиткән меңнәрчә балалар үсә. Ә татар мәктәпләре юк, булганнары ябылган. Тагын балаларны, «ата-ана теләге» дигән булып, рус мәктәпләренә бирәләр, тагын шул ук бәрәкәтсез «өстәмә дәрес» белән ана телен укытып маташалар. Бала өчен бик кирәкле милли җирлек югала, телләрне үзләштерүдәге табигый процесс бозыла, нәтиҗәдә андый мәктәптән үз телендә юньләп укый-яза белмәгән космополитлар җитешеп чыга.

Баланы «ата-ана теләгән телдә» укыту милли телләрне чикләүгә, кысрыклауга китерәчәген алдан күрергә мөмкин идеме? Әлбәттә! Миңа калса, бу законны да моңарчы илебездә хөкем сөргән административ-бюрократик аппарат тудырган булырга тиеш, чөнки аның өчен бер генә телдә эш йөртү һәр җәһәттән, һичшиксез, уңайрак булгандыр. Билгеле, бу милли телләр мәсьәләсендә Ленин принципларын бозу иде. Әгәр моннан соң да эшләр шулай барса, безнең яңадан бер телле халыкка әйләнеп калуыбыз бик ихтимал. Тагын берничә буыннан без, бәлки, рус теленә күчеп тә бетәрбез. Нәрсә югалтабыз?.. Туган телебезне,— бары шул гына... Әмма телне югалту ул — милләт булудан туктау дигән сүз. Чөнки халыкны милләт иткән нәрсә — аның теле, шушы телдә тудырган милли мәдәнияте, шушы тел белән бәйләнгән гореф-гадәтләре, әхлакый кагыйдәләре — болардан башка милләт төшенчәсе үзенең мәгънәсен югалта. Кайбер «интернационалист», бәлки, әйтер дә: бик әйбәт, бөек рус куль-

турасына күчәбез, үзебезнең иске культурадан да шәпләрен алырбыз, дияр. Ләкин бу — нәсел-нәсәбен югалткан демагог сүзе. Беренчедән, чын мәгънәсендә интернационализм булсын өчен иң элек милләтләр яшәргә тиеш. Икенчедән, рухи байлык нинди телдә тудырылган булса, бары тик шул телдә генә аның кадере һәм кыйммәте дә. Тукаебызны гына алыйк, ул үз телендә бөек, үз телендә укыганда гына аның бөтен шигърияте тоеп, ләззәтләнеп булачак. Бүтән телдә ләззәтләну түгел, мәгънәсен дә дөрес кенә аңлап булмаячак (сыналган нәрсә). Аннары бер халыкның рухи хәзинәсеннән чүпләп кенә алган байлыкны икенче телдәге хәзинәгә күчереп булачак дип ышану — кысыр хыял, үз-үзеңне алдау гына ул... Без әле хәреф алыштыру нәтиҗәсендә генә күпме байлыгыбыздан аерылдык.

Шулай да мин туган телебезнең хәзерге хәвефле хәлен татар балаларының рус мәктәпләренә күчеп бетүләренә генә кайтарып калдырмас идем. Мондый хәлгә китереп җиткергән безнең үз хаталарыбыз да аз булмады. Шуларның берсе һәм иң зурысы — кыска гына вакыт эчендә ике мәртәбә хәреф алыштыру булды. Ашый торган ризык шикелле һәркемгә кагылган бу гаять мөһим, тәвәккәл чара халык хөкеменә куелмыйча гына хәл ителде ул чакта... Ә кирәк булган халык хөкеменә кую, бик кирәк булган икән!..

Дөрес, латинга күчәр алдыннан бәхәсләр бик күп булды. Күпчелек күчү ягында иде — бигрәк тә укучы яшьләр. Мәгәр тел галимнәре һәм өлкән буын язучылар күчүне мәгъкуль күрмәделәр. Аеруча Галимҗан Ибраһимов хәреф алыштыруның вакытсыз, кирәксез, хәтта зарарлы икәнен, теше-тырнагы белән дигәндәй, исбат итәргә тырышты. Халыкны уку-язудан гына түгел, гасырлар буенча җыела килгән рухи мирастан да аеру булачагын, моның культура революциясе барган чакта һич ярамаячагын кат-кат әйтеп чыкты. Латинга күчүнең вакытлы гына булачагын, иртәме-соңмы барыбер руска күчәргә туры киләчәген дә ул алдан кисәтеп куйды.

Әмма без, һичнигә карамастан, тәвәккәл адымны ясадык. Нәтиҗәсе ни булып чыкты? Культура революциясе вакытында (егерменче-утызынчы еллар арасында) ликбезлар аша халкыбызны камилләштерелгән гарәп әлифбасы белән грамотага өйрәтүебез җилгә очты, элегрәк мәктәп бетергәннәр уку-язудан мәхрүм ителде, киләчәк буыннар исә бөтен язма мирасыбыздан аерылды да куйды. Ләкин монда бичара гарәп хәрефләренең бер гаебе дә юк иде. Шулар ярдәмендә Коръәнне генә түгел, Ленинны

да бик җиңел укып була иде. (Алыштырган чакта гарәп хәрефләрен безгә дин белән килгән дип яманладылар, әйтерсең башка хәрефләр дин белән таралмаган.) Ун елдан соң, латиннан руска күчкәндә инде бернинди дә шаушу булмады, тыныч-шома гына үтте дә китте бу эш... Хәер, бәхәскә керерлек кешесе дә калмагандыр — Галимҗан Ибраһимовлар юк иде инде ул чакта.

Рус хәрефләренә күчкәндә нинди максат беренче нәүбәттә күздә тотылды?.. Күчүнең файдалы яклары турында сүз күп булды, әмма иң төп максат — рус теленә якынаю, рус телен өйрәнүне җиңеләйтү иде. Шушы максаттан чыгып, бездә рус әлифбасын үзгәртмичә генә кабул иттеләр, тик ахырына кайбер җитмәгән авазлар өчен рус шәкелләрен үзгәртебрәк хәреф өстәделәр, мәгәр телебездә иң күп очрый торган ике авазга — каты «г» белән каты «к»га — аерым шәкел бөтенләй алынмады да. Бу исә һәрбер тел өчен зарури булган канунны бозу булып чыкты: телне бит әлифбага түгел, ә әлифбаны телгә яраклаштыралар. Башка төрки халыклар, рус хәрефенә күчкәндә, шулай эшләделәр дә. Ә без менә күпме еллардан бирле инде телебезнең табигатенә туры килмәгән әлифба һәм гарип орфография белән яшәп киләбез.

Күчүнең янә бер нәтиҗәсен без алдан күрә белмәгәнбез. Әйткәнемчә, күчү рус телен өйрәнүне бик җиңеләйтергә тиеш иде бит. Әмма ике тел өчен дә хәрефләрнең бер үк булуы, өйрәнүне җиңеләйтүдән бигрәк, туган телне ташлап, рус теленә күчүне генә ансатлаштырды. Һәм моңа гаҗәпләнергә дә туры килми, чөнки уку-язу рәвеше белән русчадан һич тә аерылмаган ана телен өстәмә дәрескә калып, өйрәнеп утыруның бала өчен бер дә кызыгы юктыр, дип уйлыйм. Бала бит ул бер-берсенә охшамаган нәрсәләр белән күбрәк кызыксынырга ярата...

Билгеле инде, бу әйткәннәрем искегә кайтуны дәгъва итү түгел, һәм ул мөмкин дә түгел, тик шулай да без бер хакыйкатьне аңларга тиешбез: һәр халыкның мәдәни үсеше, шул җөмләдән мәгариф эшләре дә, өзлексез бара торган табигый бер процесс ул. Бу процесска яңалыклар өстәлүе, реформалар керүе мөмкин, иллә мәгәр ун ел эчендә ике мәртәбә хәреф алыштыру кебек табигый барышны шартлатып өзгән кинәт сикерүләр булмаска тиеш. Шул чагында гына көтелмәгән югалтулардан һәм авыр торгынлыклардан сакланып булачак.

Яңадан төп мәсьәләгә күчик. Югарыда әйтелгәнчә, без хәзер ике телле халыкка әйләндек. Бу әйбәт, бу кирәк, бу — заман таләбе... Рус теле ярдәмендә безнең халыктан күпме югары белемле белгечләр һәм галимнәр

җитешеп чыкты (академикларга кадәр). Киләчәктә дә алар елдан-ел арта гына барачак. Тик бу үз телебезне оныту, ташлау исәбенә булмаска тиеш. Татар халкы гасырлар буена сузылган иң караңгы, иң авыр чакларда да үз телен, иманы шикелле, саклап килде, хәтта көчләп чукындырылганнары да үзенең газиз теленнән аерылмады. Революциядән соң туган телебез, яңа канатлар чыккандай, аеруча бер үсү, күтәрелү чорын кичерде... Кызганыч ки, бу озакка бармады. Ленин үлеменнән соң башланган тискәре үзгәрешләр әкренләп милли мөнәсәбәтләрнең ленинчыл принципларын бозуга да китерде. Ә торгынлык заманы исә бөтен нәрсәгә битараф, бөтенесенә күнеккән халыкны ирексездән «денем өчен түгел, көнем өчен» дип яшәргә өйрәтте. Бары шушы «көнем өчен» дип кенә яшәүнең аяныч бер нәтиҗәсе дип карыйм мин телебезнең бүгенге авыр хәлен дә.

Интернационализм — зур сүз, күпкырлы сүз. Без бу сүзне еш кулланырга яратабыз, ләкин кайчагында берьяклырак кына итеп тә... Мәсәлән, халыклар дуслыгы турында сүз чыкканда, без, гадәттә, зур төзелешләрдә, әйтик, КамАЗны салганда, күпме милләт кешесе катнашуын, беренче нәүбәттә, мисал итеп китерәбез. Әйе, бу мисал интернационализмның мөһим бер ягын, һичшиксез, чагылдыра. Әмма шуның белән генә чикләнәме соң ул?! КамАЗ әйләнәсендә өр-яңадан төзелгән Чаллыда хәзер 500 мең чамасы халык яши, ди. Шуның биш кенә проценты, ягъни егерме биш меңе, башкорт яки чуашлар, ди. Менә шул башкортларга яки чуашларга балаларын үз телләрендә укытырга мәктәп бармы, бу халыклар өчен шәһәрдә аерым китапханә ачылганмы, үз телләрендә Уфада яки Чабаксарда чыккан газета-журналларга алар языла алаламы?.. Әгәр боларның берсе дә юк икән, ул чагында нинди интернационализм турында сүз булырга мөмкин? Хикмәт бит төрле халыкларның бер җиргә җыелып, бергә эшләүләрендә генә түгел. Иң мөһиме — һәр халыкның, үз илендәме, читтәме, бер үк тигез хокуклар һәм мөмкинлекләр белән гамәлдә файдалана алуында. Чын интернационализмны шулай аңларга кирәктер, минемчә.

Безнең татар халкы өчен моның әһәмияте тагын да зуррак. Мәгълүм булганча, алты миллионнан артыграк халкыбызның 75 проценты Татарстаннан читтә яши. Ул чиксез зур илебезнең бөтен почмакларында яши. Әмма ул, таралып яшәвенә карамастан, бөтен бер милләт. Һәм кайда гына яшәмәсен, телен, язуын, мәдәниятен сакла-

ган халык иде. Революциягә чаклы ук әле ул Петербург һәм Мәскәүдән алып бөтен Идел буе, Урал, Себер, Урта Азия шәһәрләрендә үзенең мәктәпләрен ачты, балаларын ана телендә укытты. Төрле шәһәрләрдә аның бөтен Россиягә даны таралган зур мәктәп-мәдрәсәләре бар иде. Күп шәһәрләрдә татарча китаплар басыла, газета-журналлар чыга иде. Болар барысы да билгеле нәрсәләр, тик шуны гына өстәп әйтик — татар халкының бу бөтенлеге утызынчы елларга кадәр әле сакланып килде. Административ чикләр дә моңа комачаулык итмәгән иде.

Шуннан соң күп сулар акты, күп җилләр исте, күп хәлләр баштан кичте, дөньябыз да бик нык үзгәрде. Боларны яза башласак, сүз бик озынга китәчәк. Җыеп кына әйткәндә, без, 6 миллион халык, һәр җәһәттән бер милләт булсак та, күптән инде элеккеге бөтенлекне югалттык, үзара бәйләнешләр өзелеп бетте диярлек. Һәм моның уку-укыту эшләренә дә, гомумән, культурабыз үсешенә дә тискәре йогынтысы менә хәзер күз алдыбызда. Элек, мәсәлән, безнең әдәбиятка һәм сәнгатькә яңа көчләр төрле яктан килеп тора иде (Тамбовтан — Такташ, Оренбургтан — Муса, Уралдан — Туфан), хәзер инде мондый талантларның читтән килүен көтеп тә булмый. Сәбәбе дә билгеле. Әлеге күпләп татарлар яшәгән зур һәм кече шәһәрләрдә татар мәктәпләре ябылып бетте. Хәтта кайчандыр үзенең мәктәп-мәдрәсәләре белән дан тоткан Оренбург, Уфа, Троицк кебек шәһәрләрдә дә ана телендә мәктәп юк, калмаган... Ә бит халык бар, халык беркая да китмәгән, кайда укыта ул хәзер баласын?.. Тел бит ул буыннан буынга күчә торган нәрсә. Әгәр шушы бәйләнеш өзелсә (ә ул өзелгән инде), моның ахырын күз алдына китерүе читен булмас, дип уйлыйм.

Бу язганнардан нәтиҗә ясап, нәрсә әйтәсе калды? Әйе, без хәзер ике телле халык. Әмма тормышыбызда аларның тоткан урыннары бер түгел — аерма бик зур. Үткәндәге хаталар, соңгы елларда көчәйгән игътибарсызлык, сансызлык аркасында, бигрәк тә совет һәм партия аппаратларында утыручыларның нигилистик мөнәсәбәте нәтиҗәсендә, туган телебезне бүгенге хәвефле хәленә китереп җиткердек. Шәһәрләрдә мәктәпләрнең ябылып бетүе, рус мәктәпләрендә туган телгә бик кечкенә урын бирелүе, авыл мәктәпләрендә дә укыту сыйфатының түбән булуы әлеге хәвефне тагы да көчәйтә төште. Ниһаять, без туган телебезне әкренләп югалту куркынычын тоя башладык.

...Милли телләрнең бүгенге хәле бөтен җирдә дә бертөсле генә түгелдер, билгеле... Мәсәлән, Азәрбайҗанда

җиңелрәк, ә бездә, киресенчә, авыррак булуы мөмкин. (Чөнки шартлар һәм мөмкинлекләр башка.) Бездәге хәлләр исә, беренче нәүбәттә, бездән туган телебезне тигез хокуклы итүне, үз урынына куюны, аның абруен күтәрүне таләп итә. Әмма моңа ирешүе җиңел булмаячак. Бигрәк тә шәһәр шартларында, чөнки мондагы ата-аналарны без балаларын ана телендә укытмаска өйрәтеп бетердек. Мәсьәләнең читен-четерекле ягы да әнә шунда. Мәгәр бөтен карарлардан да өстен, барлык халыклар өчен дә уртак, табигать бирмеш янә бер закон бар әле: бала бер генә телле булып туа һәм бу тел аңа анасыннан күчә. Шуңа күрә дә ул туган тел (родной язык) дип атала. Һәм бөтен дөньяда баланы укырга, язарга өйрәтү дә иң элек туган теленнән башлана. Без менә шушы тәртипне боздык түгелме?

Бу мәкалә партия Үзәк Комитетының Февраль (1988 ел) пленумына чаклы ук язылган иде. Аннан соң менә партиянең XIX конференциясе дә булып узды. Конференция, билгеле булганча, милли мөнәсәбәтләр турында махсус карар да кабул итте. Көтеп алынган бу карар безне борчыган күп мәсьәләләргә зур ачыклык кертте. Аны укып, танышып чыкмаган кеше юктыр дип беләм. Цитаталар китереп тору да кирәк булмас дип уйлыйм. Тик карарның тел мәсьәләсенә кагылган өлешенә генә игътибарны тупламакчы булам, чөнки минем бу мәкаләмдә, башыннан ахырына хәтле диярлек, туган телебез язмышы турында сүз барды.

Конференция карары телләргә карата нәрсә әйтте соң? Җыеп кына алганда, аның әйткәне ике төп моментка кайтып кала: беренчесе — милли телләр яшәргә, тәрәккый итәргә, тигез хокуклы булырга һәм гамәлдә кулланганда шул хокук белән тулысынча файдаланырга тиешләр. Ягъни милли телне бер яктан та, берничек тә чикләү булмаска тиеш — шулай өстәп аңлатасым килә минем бу моментны. Икенчесе — һәр халык үз теле белән бергә рус телен дә өйрәнергә һәм белергә тиеш. Рус теле ул күпмилләтле безнең илдә халыкларның үзара аралашу теленә әйләнде, шуңа күрә аны белү, алда әйткәнемчә, үзе бер заруриятькә әверелде. Кыскасы, һәрбер милләт кешесе безнең шартларда ике телле булырга тиешле. Карарда тагын менә мондый сүзләр дә бар: туган телне өйрәнү һәм куллану хокукы үз республикасыннан читтә яшәүчеләргә дә бирелә. Безнең татар халкы өчен бу исә аеруча мөһим момент.

Инде әнә шул бик әһәмиятле карар нигезендә без нәрсә эшләргә тиешбез?.. Билгеле, һәр милләт тел мәсьәләсен

үз ихтыяҗыннан чыгып хәл итсә кирәк. Безгә дә үзебездәге хәлләрдән чыгып уйланырга кирәк булачак. Ә хәлләрнең ни дәрәҗәдә хәвефле булуын без югарыда күреп уздык инде. Туган тел мәсьәләсе ул хәзер, асылда, татар халкының милләт буларак саклануы белән бәйләнгән үтә җитди бер мәсьәләгә әйләнеп бара дияргә дә ярый. Арттырып әйтүем түгел, чынбарлык үзе безне шулай уйларга мәҗбүр итә; ялгышсам, бик әйбәт, әмма тыныч, ваемсыз булырга безнең хакыбыз бармы соң? Дөресен генә әйткәндә, телебезне әкренләп югалта баруны без инде күптән күреп килә идек, мәгәр милләтчелектә гаепләнүдән куркып, озак еллар ул хакта дәшми килдек. «Милләт» дигән сүз өчен дә авызга сугарга торган ортодоксаль догматиклар моңарчы һаман да булып торды, хәзер дә әле алар юк түгел, ләкин инде бүгенге шартларда алардан, Тукай әйткәнчә, «курку белән өркү хәрам».

Кыскасы, тел язмышы — милләт язмышы. Менә шуннан чыгып, без тел мәсьәләсен хәл итәргә дә тиешбез. Ничек итеп?

Әйткәнебезчә, без хәзер ике телле халык. Инде шушы ике телнең кайсысына игътибарны юнәлтергә, кайсысы аның менә хәзер «ашыгыч ярдәмгә» мохтаҗ?

Рус телен белүнең кирәклеген һичкем инкарь итмәячәк, аны белү — тормыш таләбе, шуңа күрә дә аны барлык мәктәпләрдә бик интенсив рәвештә укыталар да. Димәк, рус телен белмичә калу куркынычы бездә юк.

Ә туган телебезне укытуның никадәр түбән, зәгыйфь икәнен без инде күреп уздык.

Үз тарафымнан мин кичектергесез зарури чаралар итеп түбәндәгеләрне тәкъдим итәр идем: 1) баланы бары ана телендә укыта башларга; 2) бөтен сабакларны да саф ана телендә укыту дүртенче сыйныфка чаклы, ягъни башлангыч мәктәп программасын тәмамлаганчы дәвам итәргә тиеш; 3) рус телен балаларга икенче елдан гына укыта башларга. Шулай иткәндә бала үз телен, башка тел белән бутамыйча, җиңелрәк үзләштерәчәк. Рус телен үзләштерүе дә соңга калмаячак — бала бит аны урта мәктәпне бетереп чыкканчыга кадәр укыячак.

Татар балалары, шул рәвешчә башлангыч мәктәп программасын үткәннән соң, теләгән мәктәпләренә күчеп, укуларын дәвам иттерә алачаклар. Шәһәрләрдә алар, билгеле, рус мәктәпләренә күчәрләр. Бик әйбәт, гимназиягә кергән шикелле булыр. Әгәр эш шулай куелса, бу, беренчедән, татар баласын үз теленнән мәхрүм итеп калдырмаячак, икенчедән, әлеге «ата-ана теләге» дигән принцип та әллә ни бозылмаячак. Мәгәр эшне әнә шушылай

оештыру ул тулысынча дәүләт органнары өстендә. Партиянең XIX Бөтенсоюз конференциясе карары моның өчен аларга тулы хокук та бирә һәм алардан чын эш тә таләп итә.

Конференция карарының тагын бик мөһим бер моментына тукталыйк. Сүз бередә үз республикаларыннан читтә яшәүчеләрнең милли ихтыяҗларын үтәү турында бара. Карар менә шуларга да үзләренең милли ихтыяҗларын үтәргә, ягъни балаларын ана телендә укытырга, иҗади эшләренә мәйдан ачарга, культура учакларын булдырырга, шулай ук диннәрен тотарга да хокук һәм мөмкинлек бирә. Бирү генә түгел, бу эштә аларга булышлык күрсәтергә чакыра. Тик менә күптән көтелгән гаять кирәкле шушы карардан ничек итеп файдаланырга?

Яшереп торуның һич тә кирәге юк, төрле республика һәм өлкәләрдә күпләп яшәүче халкыбызның милли ихтыяҗларын үти алу мөмкинлеге бик кысылды, тарайды, бетте, дисәк тә була. Төрле шәһәрләрдәге кайчандыр гөрләп торган культура учаклары да күптән инде сүнде. (Оренбург, Әстерхан, Троицк, Уральскиларны искә төшерү дә җитә.) Һәм кайчандыр мәктәп-мәдрәсәләр аша, матбугат, әдәбият ярдәмендә яшәп килгән җанлы бәйләнешләр дә өзелде, онытылды, бердәмлек тә югалды — хәзер инде татарны бөтен бер милләт дип атавы да читен. Сталин заманыннан ук башланган бу аеру, тузгыту, кысрыклау безнең халыкны бүгенге торгынлыкка китереп тә җиткерде.

Әмма хәзер аңа яңадан терелергә, милләт буларак үзенең рухи ихтыяҗларын үтәргә мөмкинлек бирелә. Моны партия инициативасы белән башланган үзгәртеп коруның гүзәл бер нәтиҗәсе итеп кабул итәргә кирәк. Инде эш бүген шушы мөмкинлектән файдалануга кайтып кала.

Әмма бу әйтергә генә ансат. Күптән сүнгән учакларны кем кабызыр, әллә кайчан ябылган мәктәпләрне кемнәр ачар? Инициатива бит һәр шәһәрнең, һәр төбәкнең үзендә туарга тиеш. Башлап йөрүчеләр кирәк булачак... Билгеле, алар табылыр, табылмыйча калмас, хәтта яшьләр арасыннан да, чөнки милли рух ул тиз генә сүнә торган нәрсә түгел. Бәлки әле алар берәр төрле законлы оешма төсен дә алырлар, үзләренең таләпләрен җирле оешмалар алдында да куярлар. Ихтимал, каршылыкларга да очрарлар. Бездә бит бер эш тә ансат кына эшләнми. Бюрократизм көчле, азаплар күп... Озын сүзнең кыскасы, минем әйтергә теләгәнем шул: татарлар яшәгән җирләрдә туачак бу табигый хәрәкәткә ниндидер бер

үзәктән ярдәм итү кирәк булачак. Һәм бу ярдәмне иң элек Казаннан көтәчәкләр. Казан — татар халкының мәдәни үзәге булу беләнбергә, ул — Татарстан дигән автономияле республиканың башкаласы да. Димәк, ярдәм дә бездән барырга тиеш. Ничек, ни рәвештә — культура һәм мәгариф министрлыклары ашамы яки моның өчен махсус берәр идарә төзү кирәкме,— бу кадәресен безнең җитәкче органнар уйларга тиешләр. (Тик иске гадәт буенча инициатива күрсәтүдән, җаваплылык алудан куркып тору булмасын иде.) Әлбәттә, җәмәгатьчелек тә бу эштән читтә калмас дип ышанасы килә. Хәзерге вакытта табигатьне саклау, тынычлыкны саклау, культура истәлекләрен саклау кебек киң җәмәгатьчелекне үзенә тарткан җәмгыятьләр барлыкка килде. Милли культураларны саклау-үстерү дә әнә шундый кичектермәс бер эшкә әйләнде дияргә ярый. Кайда гына яшәмик, без бөтен бер халык, аралашырга да, ярдәмләшергә дә хакыбыз бар, бүгенге хәбәрдарлык һәм демократия шартларында административ чикләр моңа комачаулык итмәскә тиештер дип беләм. Чын интернационализм да, XIX Бөтенсоюз конференциясе карарында әйтелгәнчә, халыкларның үзара аралашуы һәм ярдәмләшүе аркасында гына туачак.

*«Казан утлары», 1988, 9 сан*

## ХАЛЫКНЫҢ КҮЗЕН АЧА БЕЛҮ ДӘ КИРӘК

*(Язучыга 80 яшь тулу уңаеннан үткәрелгән әңгәмә)*

*— Әмирхан ага, Сез, халкыбызны борчыган проблемаларны күтәреп, матбугатта даими рәвештә чыгышлар ясап киләсез. Соңгы елларда тел һәм аның язмыше хакында да үз уйларыгыз белән уртаклаштыгыз. Биредә дә сүзне шуннан башлыйк әле: татар теленең киләчәк язмышына Сез ничек карыйсыз? Кайберәүләр аның хәле мөшкел, диләр, мондыйларга ничек җавап бирергә?*

— Әйе, туган телебез турында миңа язгаларга туры килде. (Соңгысы «Казан утлары»ның 1988 елгы 9 нчы санында басылган иде.) Ләкин анда язылганнарны яңадан кабатлап торуның кирәге бармы икән? Телебезнең авыр хәле бәхәссез, киләчәге шактый хәвефле, әкренләп югалу куркынычы да юк түгел, билгеле, моңа күз йому гафу ителмәслек сансызлык булыр иде. Дөресен генә әйткәндә, соңгы 25—30 ел дәвамында туган телебезгә карата булган игътибарсызлык, нигилистик мөнәсәбәт аны бүгенге аяныч хәлгә китереп тә җиткерде.

Хәзер инде без аның киләчәк язмышы турында борчылырга мәҗбүрбез. Телне саклап калу өчен нииндидер ашыгыч чаралар күрергә кирәк,— әгәр соңга калмаган булсак... Әмма хәзерге шартларда безгә үз телебезнең хәлен җиңеләйтү ансат булмаячак. Чөнки, бердән, рус теле безнең тормышыбызда һәр җәһәттән өстенлек итә; икенчедән, балаларны кайсы телдә укыту мәсьәләсе элеккечә ата-ана ихтыярында кала. Бер караганда, бу принцип бик гадел дә, бик демократик та кебек, мәгәр туган тел файдасына түгел... Икеләнмичә әйтергә була ки, үзләре татарча укымаган яшь ата-аналар балаларын, билгеле, рус мәктәпләренә бирәчәкләр. Ә андыйлар елдан-ел күбәя бара, димәк, телебезнең киләчәк язмышын да шулар хәл итәчәк. Татар теленең киләчәгенә ышанмыйча карау да әнә шуннан килә, минемчә... Нишләргә кирәк соң? Бәлки, яшьләрдә милли аң уянуын көтәргә кирәктер?.. Юк, аң уянганын көтеп яту донкихотлык булыр иде. Тел бит буыннан буынга күчә торган нәрсә, әгәр дә бу күчеш берничә буынга өзелеп торса, телне саклап калу, ихтимал, мөмкин дә булмас. Димәк, безнең үзебезгә тизрәк уянып, ашыгыч, радикаль чаралар күрергә кирәк булачак.

...Без милли республикада яшибез. Безнең сайлап куйган Югары Советыбыз бар, хөкүмәтебез бар. Шулай булгач, безнең республика шартларында төп халыкның теле, рус теле шикелле үк, бер үк хокук белән файдаланылырга тиеш. Моның өчен татар телен, дәүләт теле итеп, республиканың Конституциясенә кертергә кирәк (хәзергә әле анда рус теле генә дәүләт теле итеп беркетелгән). Бу чара телебезне саклауда законлы гарантия булачак. Кәгазьдә генә түгел, гамәлдә дә!.. Ә дәүләт телен белү һәркем өчен зарури булырга тиештер инде — бигрәк тә һәрбер татар кешесе өчен... Мәсьәлә шулай куела икән, димәк, татар балаларын туган телдә тәрбияләү һәм укыту да башкача хәл ителергә тиеш. Беренчедән, бөтен җирдә ана телендә укыту дүртенче класска чаклы мәҗбүри булырга тиеш. Икенчедән, урта мәктәпне бетереп чыкканда, татар укучыларының өлгергәнлек аттестатына туган тел белән әдәбиятны да кертергә кирәк. Өченчедән, Казан вузларына керүче татар яшьләре шулай ук туган телдән һәм әдәбияттан имтихан бирергә тиешләр. Бербересенә бәйләнгән бу чаралар туган телебезнең тормышта тоткан урынын, һичшиксез, ныгытачак. Иң мөһиме — киләчәк буын туган теленнән мәхрүм булмаячак. Кайберәүләрдә рус телен өйрәнүгә моның зарары булмасмы, дигән уй туарга мөмкин. Миңа калса, һич зарары булма-

ячак, чөнки рус телен укыту да башлангыч класслардан алып мәктәпне бетереп чыкканчыга кадәр әүвәлгечә дәвам итәчәк. Гомумән, рус телен белмичә калу куркынычы юк — татар халкы ике теллегә әйләнде инде дисәк тә була.

Икенче төрле сорау да туарга мөмкин: татар телен дәүләт теле иткәч, русларны да татарча укыту кирәк булмасмы икән? Минемчә, кирәк булмас, чөнки укытып маташудан барыбер мәгънә чыкмаячак. Татарстанда яшәүче халыкның яртысы диярлек руслар, рус теле дә дәүләт теле, безнең республикада ул моңарчы нинди урын тоткан булса, моннан соң да шул урында нык торачак — бәс, шулай булгач, рус кешесенә татар телен өйрәнеп азапланунының ни кирәге бар? Өйрәнмәячәк ул аны... Инде кызыксыну йөзеннән өйрәнергә теләүчеләр табыла икән, рәхим итсеннәр! Моның өчен аларга бөтен шартларны тудырырга кирәк.

Без үзебезне кайгыртырга тиешбез. Милли горурлык хисе булган халык үз тамырына үзе балта чапмас. Ятлар колагына, бәлки, бик үк ягымлы ишетелмәгән «татар» исемен йөртүче безнең күпне күргән, татыган, чыдам, тырыш, уңган, ватанпәрвәр халкыбыз ике телне дә камил белергә тиеш. Әмма иң газизе аның өчен туган теле — вәссәлам!

*— Милли горурлык хисе, дидегез. Хәзер бездә аңа төрлечә караш яши. Ә Сез бу хакта ничек уйлыйсыз?*

— Милли аң, милли горурлык һәрбер халыкта бар, тик ул берәүләрдә ачыграк, көчлерәк, ә икенчеләрдә яшеренрәк, зәгыйфьрәк чагыла. Безнең татарлар, минемчә, менә шул икенчеләр рәтенә керә. Бәлки, бу аларның таралышып, башка халыклар белән аралашып яшәвеннән килә торгандыр.

Әмма милли аң, милли горурлык — бик табигый, бик кирәкле сыйфат, аны милләтчелек белән һич тә бутарга ярамый. Халыклар арасындагы дуслыкка да аның һич зарары юк — дуслыкны бит күп очракта ике арадагы тигезсезлек боза.

Милли аңын, милли горурлыгын югалткан халыкны мин мескен халык дияр идем — андый халык милли хосусиятләрен дә тизрәк югалта, тизрәк башкаларга яраклаша-буйсына ук башлый. Билгеле, мондый хәлнең бик эрактан килгән тарихи сәбәпләре булырга мөмкин, әйтик, кайчандыр бер халыкның икенче халыкны басып алуы нәтиҗәсендә; әмма бу очракта да милли аңын, милли горурлыгын югалтмаган халык үзен милләт буларак та саклап кала алган. Татар халкының үз тарихы да шуның бер мисалы түгелме?!

*— Сез ничек уйлыйсыз: Казанны татар шәһәре дип әйтеп буламы?*

— Казан — татар шәһәре, ул шулай танылган, шулай яшәп тә килгән. Дөрес, руслар кулына күчкәннән соң, ул инде саф татар каласы булудан туктый. Берничә гасыр дәвамында төзелгән чиркәүләре, монастырьлары, рус стилендәге таш йортлары белән ул Россиянең башка күп шәһәрләренә охшап кала. Шулай да әле безнең Казанны бу гасырның утызынчы елларына кадәр татар шәһәре дип тә атарга мөмкин иде. 1925 елны беренче мәртәбә Казанга килгәч, мин моның шулай икәнен аеруча нык сизгән идем. Чөнки татарларның иң зур күпчелеге ул чакта шәһәрнең аерым төбәгендә — Болак аръягында оешып яшиләр иде, мәчетләре, мәктәп-мәдрәсәләре, базарлары да шул якта иде, һәм бу якта йөргәндә, үзеңне чынлап та татар дөньясына килеп кергәндәй хис итә идең... Мәгәр бу аерма күптән инде бетте. Казан тарихи йөзен бөтенләй үк югалтып бетермәсә дә, ул инде урбанизация нәтиҗәсендә башка бик күп шәһәрләр төсле үк стандарт бер шәһәр булып калды. Татарстанның башкаласы булса да, аның архитектурасында татарныкы дип әйтерлек бер нәрсә дә юк. Бары халкының милли составы ягыннан гына аны рус һәм татар шәһәре дип атарга була.

*— Хәзер безнең әдәбиятның яңа күтәрелеш ясавы өчен нинди шартлар кирәк? Нәрсәләр эшләү кирәк?*

— Махсус шартлар кирәк микән? Әдәбият теләсә нинди шартларда да яшәвен дәвам итә. Бу шартлар әдәбиятның активлыгы өчен уңай яки уңайсыз булырга мөмкин. Мәсәлән, безнең әдәбият утызынчы еллардан башлап сиксәненче елларның урталарына чаклы бик тар, кысан шартларда яшәп килде һәм шушы озын дәвер эчендә ул, асылда, рәсми политикага буйсынган, үзгәреп торган конъюнктурага хезмәт итүче булып кала бирде. Тик аерым язучыларның аерым әсәрләре генә бу гомуми кагыйдәне ара-тирә бозгалады. (Һәм моның өчен каты тәнкыйтькә дә дучар булдылар.)

Хәзер исә шартлар бик нык үзгәрде, мәйдан да киңәйде, хөрлек тә артты. Бигрәк тә язучының үзендә Чехов әйткән эчке хөрлек хисе уянды. Ә бу — иҗат итүнең беренче шарты. Ләкин язучыларның активлыгы хәзер үзгәртеп кору китереп чыгарган проблемаларга күчеп, аеруча публицистикада чагылыш тапты. Теге яки бу темага мәкалә язмаган әдип, шагыйрь, тәнкыйтьче калмады диярлек. Куанычлы күренеш!

Әмма тормышның үзендәге тирән үзгәрешләрне ач-

кан чын әдәби әсәрләрне күрмибез әле. Миңа калса, моңа артык гаҗәпләнергә дә туры килми. Чөнки хәзерге тормыштагы үзгәрешләр шулхәтле тирән, катлаулы һәм каршылыклы ки, моны белү, аңлау, тою өчен, һичшиксез, күпмедер вакыт кирәк булачак. Ашыгырга ярамый. Чын язучы конъюнктурадан бик нык сакланырга тиеш. Бердәнбер максат — бары чын дөреслек! Без шуңа бик сусадык.

*— Әмирхан ага, Сезнең 1965 елда ук язылган «Әйтелмәгән васыяте»гез шундый алдан күрүчән сүзләр белән тәмамлана: «...Ә син учагын карый тор, учагын! Учагында ут сүнмәсен!» Шул уңайдан бүгенге авыллар язмышы белән милләт язмышы арасында ниндидер бәйләныш күрмисезме?*

— Дөрес, авыл язмышы белән милләт язмышы арасында тирән бәйләнеш бар. Милләткә хас күп нәрсәләр — туган тел, гореф-гадәт, әхлак кагыйдәләре күбрәк авылларда саклана. Авылларның кимүе милләтнең зәгыйфьләнүенә китерүе бик мөмкин. Мәгәр милләт язмышын авыл язмышы белән генә бәйләп карау дөрес булмас иде. Авыл кимесә дә, халык кимеми — ул әнә шәһәрләргә тула. Миңлебай карт әйткән учак авылда сүнсә, ул яңа урында — шәһәрдә кабынырга тиеш. Әнә Европа илләрендә халыкның иң зур күпчелеге шәһәрләргә тупланып беткән, әмма учаклары сүнмәгән, учаклары, киресенчә, гөрләп янып тора. Моннан нәтиҗә: халыкларның милләт буларак яшәүләре торган урыннарына карап кына йөрми. Иң мөһиме, халык кайда гына торса да, үз язмышына үзе хуҗа булырга тиеш. Менә шул чакта учаклар сүнмәс, сакланыр!

*— Татар халкының шәһәрләшүенә мөнәсәбәтегез ничек?*

— Шәһәрләшү бөтен ил күләмендә бара һәм барлык халыкларга да кагыла ул. Котылгысыз процесс. Иске шәһәрләр өзлексез үсә, яңалары һаман туып тора. Кем исәбенә? Билгеле инде, башлыча авыл исәбенә. Шуңа күрә дә бит шәһәрдә торучылар елдан-ел арта, авылда калучылар исә кими бара. Бу хәлнең җитди экономик сәбәпләре бар, әлбәттә. Ләкин аларына тукталып тору минем эшем түгел.

...Шәһәрләр аеруча яшьләрне үзенә суыра. Шәһәрдә тору алар өчен кызыклы, җиңелрәк (квартир да ала калса), төрле ихтыяҗ-теләкләрне үтәү өчен мөмкинлекләр дә күбрәк. Дөрес, кеше монда табигатьтән ераклаша, начар һава сулый, кысылып һәм ашыгып яшәргә мәҗбүр була. Ләкин ул моны уйлап тормый, ул авылдан туйган, шәһәр кирәк аңа...

Мәгәр бу мәсьәләнең бер ягы гына әле. Шәһәрләшү (урбанизация) халыкның рухи дөньясына да бик зур йогынты ясый. Чөнки ул инде үзенең табигый җирлегеннән аерыла, яңа шартларга ияләшергә, төрле милләт кешеләре белән аралашып яшәргә тиеш була. Менә шундый шартларда аңа, әйтик, безнең татар халкына, үзен милләт буларак саклар өчен, үзенең рухи таләпләрен канәгатьләндерер өчен нәрсә кирәк? Беренче нәүбәттә, ул үзенең бөтенлеген һәм бердәмлеген сакларга тиештер инде, аннары туган телен сакларга, балаларын шул телдә тәрбияләргә, ата-бабадан килгән әйбәт гореф-гадәтләрен югалтмаска, ниһаять, милли әдәбиятыннан һәм сәнгатеннән аерылмаска тиештер. Хәлбуки шәһәрләшү шуларның барысыннан да аерылуга, аннары әкренләп югалтуга да китерүе мөмкин. Куркыныч әнә шунда. Мисал өчен үзебезнең Чаллыны алырга мөмкин. Кыска гына вакыт эчендә ул 500 меңлек шәһәргә әйләнде. Күпме татар яши хәзер анда! Ләкин шул халыкка үз телләрендә мәктәп тә юк, матбугат та юк, театр-мазар да юк... Бу бит милли политикада гаделлек принципларын тәмам бозу дигән сүз! Шәһәрләшү үзе ул хәтле үк куркыныч нәрсә түгел. Ә менә шәһәрләшү аркасында милли тигезлекне, милли хокукларны югалту — зур куркыныч! Бигрәк тә интернационализм битлеге астында. Сүз дә юк, интернационализм халыклар өчен бик кирәкле нәрсә, тик ул буш сүзгә һәм алдауга әйләнмәскә тиеш.

— *Әдәби әсәрләр халыкның аңына, фикерләвенә бик тәэсир итә. Ә Сез үзегезнең кайсы әсәрегез күбрәк тәэсир итте дип саныйсыз?*

— Белмим, ачык кына әйтә алмыйм... Тәэсир итү ягыннан төрлесе булгандыр. Укучылар да бит бертөрле генә түгел. Берәү яратканны икенчесе яратмаска мөмкин. Шулай да минем әйберләргә карата шундыйрак бер хәлне күзәтергә туры килгән иде: каты тәнкыйтькә очраганын укучылар ничектер кызыксынып кабул иттеләр (мәсәлән, «Рәшә» повестен). Хәер, без кичергән заман өчен бу гомуми бер күренеш иде. Начар тәнкыйть яхшы реклама булды.

— *Әмирхан ага, Сез, моннан унөч ел элек (1976 елда) яшьләр белән әңгәмә вакытында, әдип өчен иң мөһим сыйфат хакында сүз алып барып, болай дигән идегез: «...халык күңелен бик нечкә сизә алу, халыкның иң түрендә яткан өмет-теләкләрен «күрә» алу кодрәтенә ия булу». Халыкның күзен дә ача белү кирәк.*

*Әдәбиятыбызның соңгы еллардагы күренешләренә әнә шул ноктадан карап фикер йөртсәк, нинди‑рәк нәтиҗәләр чыгар иде икән?..*

— Моннан 13 ел элек әйткән сүзләремне дөрес дип саныйм, кирәксә, яңадан да кабатлый алам. Ләкин соңгы еллардагы әдәбиятка, шул әйткәннәрдән чыгып, бәя бирүне өстемә ала алмыйм, чөнки барлык әсәрләрне дә укып барырга, кызганычка каршы, һич өлгереп булмады. Артык күбәеп китте укыр нәрсәләр — күзләр генә чыдасын!

Шулай да, кайчандыр әйткәннәргә өстәп, минем шуны да әйтәсем килә: заманның әдәбиятка таләбе үзгәреп тора, һәм әдәбият шуңа яраклашырга тиеш була (теләпме, теләмичәме,— анысы икенче мәсьәлә). Менә хәзерге үзгәртеп кору да язучылар алдына гаять җитди сораулар һәм проблемалар китереп куйды. Без хәзер 60—70 еллык тарихыбызны өр-яңадан карау, өйрәнү, аңлау процессын кичерәбез. Бу һич кенә дә җиңел эш түгел... Без үзгәртеп коруны бик хуплап каршы алсак та, иске карашлардан һәм гадәтләрдән бик авырлык белән, әкренләп кенә арынабыз. Гади халыкның күпчелегендә исә бу иске караш, гадәтләр, минемчә, тагы да тирәнрәк утыра. Ә бит ул канга сеңгән нәрсәләрдән арынмыйча торып, үзгәртеп кору куйган максатларга ирешү гаять авыр булачак. Димәк, үткәндәге хәлләргә халыкның күзен ачу, фикерен уяту һәм бүгенге катлаулы проблемаларны дөрес аңлауда аңа ярдәм итү — менә без кичергән заманның әдәбият алдына куйган таләбе шул... Һәм, әйтергә кирәк, язучылар бернинди өндәүне көтеп тормыйча, бу бик җаваплы эшкә җиң сызганып керештеләр. Барлык жанрларга караганда да публицистиканың беренче сафка чыгуы — шуның ачык бер мисалы. Әмма эшләр җиңелдән түгел, фикерләр дә бер түгел, искенең яңага каршы торуы да бик көчле — кыскасы, гаять катлаулы, авыр көрәш бара... Күрәсең, мондый чакта язучыга «халык күңелен нечкә сизү» өстенә, аны, ягъни халыкны, үз иманыңа ышандыру да бик кирәк...

— *Илебездә Яңарыш процессы бара. Шул уңайдан Сез ничек уйлыйсыз: бүгенге җәмгыятебездә ул процессның җиңүен тәэмин итәрдәй нык иманлы, рухи яктан таза һәм актив көчләр ни дәрәҗәдә исән, тере? Ягъни бүгенге җәмгыятьнең рухи яктан тазалыгы турында Сез ни уйлыйсыз?*

— Җәмгыятьтә таза көчләр бервакытта да бөтенләй үлеп бетми, нинди генә авыр хәлдә калсалар да, уңай шартлар туу белән, алар яңадан терелә башлый. Үзгәртеп кору менә шуны ачык күрсәтте: үзгәреш башлану белән, аның яклы көчләр бик тиз хәрәкәткә килде. Бигрәк тә интеллигенция бу яңарыш өчен көрәштә зур ак-

тивлык күрсәтеп килә. Әмма шулай да җәмгыятебезнең рухи тазалыгы, тулаем алганда, әйбәт, канәгатьләнерлек дип әйтергә иртәрәк әле. Моны шул ук үзгәртеп коруның авыр баруы, күп каршылыкларга очравы үзе дә күрсәтеп тора. Хикмәт нәрсәдә?.. Хикмәт шунда ки, Сталинның мәкерле явызлыгы, ничәмә миллион кешенең башына җитү белән бергә, гомумән, халыкны рухи колга әйләндерде. Иман качты, кешегә ышану бетте, фикер сүнде, ихтыяр сынды, бары җанны биләп алган курку да, шул тиранны Аллага тиңләп, аның итекләренә табыну калды. Әнә шундый сукыр коллыкка төшү нәтиҗәсендә кеше мөритләрчә ярарга, яраклашырга, башын сакларга тырышты. Хәтта Сталинның явызлыгын күреп торган, килешә алмаган кешеләр дә намусларын көчли-көчли башларын ияргә, тешләрен кысарга мәҗбүр булдылар. Моның ише гомуми коллыкка төшү тарихта күрелмәгән алдану аркасында булды: янәсе, Сталин тарафыннан ниләр генә эшләнмәсен, болар барысы да ил бәхете өчен, социализм өчен! — һәм халык шушы ялганны кул чабып кабул итте, шушы ялганга ышанып, Сталинның канлы җинаятьләрен акларга, ә үз вөҗданын тынычландырырга тырышты.

Билгеле инде, мондый тирән сеңгән рухи коллыктан кеше тиз генә чыга алмый. Моның өчен вакыт кирәк, иҗтимагый шартларның үзгәрүе кирәк. Хрущев вакытында Сталинның шәхес культы фаш ителсә дә, аның зарарлы йогынтысын бетерү өчен радикаль чаралар күрелмәде. Тормыш иске эзеннән бара бирде. Ә инде шактый озакка сузылган Брежнев заманнарында рухи торгынлык яңадан көчәйде, тормышның бөтен тармакларына үтеп керде, хәтта бу рухи гариплек яшь буынга да күчте. Һәм хәзер дә әле очрап торган бөтен ямьсез эшләр, әхлакый бозыклыклар, һәртөрле җинаятьләр — барысы да Сталиннан мирас булып калган көчләү һәм алдау юлы белән халыкны «җитәкләп» маташуның нәтиҗәсе ул.

Бу рухи торгынлыктан ничек итеп чыгарга соң, ничек итеп җәмгыятьнең рухи тазалыгын тәэмин итәргә? Үзгәртеп кору моның ике чарасын күрсәтте. Беренчесе — җәмгыятьтә иҗтимагый гаделлекне булдыру; икенчесе — җәмгыять тормышын хәбәрдарлык һәм демократия нигезендә төзү... Сез әйткән «таза көчләр»гә әнә шулай гына юл ачылыр дип ышанырга була.

*— «Демократия» дигән сүзне без бик еш кулланабыз. Ләкин чынлыкта әле без аның «нәрсә белән ашала торган әйбер» икәнлеген аңлый гына башладык бугай... Сезнең бу хакта ниндирәк фикерләрегез бар?*

— Дөрес, демократиянең нәрсә икәнен без әле татып караганыбыз юк. Ләкин без инде демократиягә йөзебез белән борылдык, хәзер әкренләп шуңа таба барабыз. Күптән түгел Конституциягә кертелгән кайбер үзгәрешләр, сайлау тәртипләрен үзгәртү буенча кабул ителгән карарлар әнә шул юлда беренче адымнар... Мәгәр тулы демократиягә без тиз генә, ансат кына ирешербез дип ышанырга, минемчә, иртәрәк әле. Тормышта бер генә нәрсә дә тәмам җитлегеп, әзер килеш тумый — аңа ныгыр өчен күпмедер вакыт кирәк булачак.

Бу уңай белән мине дә уйландырган кайбер моментлар бар. Мәгълүм булганча, XIX партконференциядә яңадан сайланачак Советларның председательләре партия комитетларының беренче секретарьлары булсын иде дигән теләк рәвешендә бер пункт кабул ителде. (Бу пункт тикшерелгәндә, делегатларның күпмеседер аңа каршы да булганнар.) Монда иң элек шундый сорау туа: карарның бу пункты безнең хәзерге Конституциягә сыя микән?.. Ягъни Советларга депутат булып сайланган партиясез кешене алдан ук Совет председателе булу хокукыннан мәхрүм итмиме?.. Әгәр итсә, бу — демократияне бозу булмыймы?

Конференция карарында теләк рәвешендә генә әйтелгән тәкъдимнең тормышта даими законга әйләнеп китүе бик мөмкин. Чөнки бу очракта халыкка күптән сеңгән психология төп рольне уйнаячак. Чыннан да, коммунистны югары, җаваплы урынга сайлау ул инде гадәткә кергән нәрсә. Каршылар булмаячак — булса да, алар азчылык тәшкил итәчәк. Димәк, иң югарыдан алып түбәнгә чаклы бөтен җирдә яңа Советларның председателе итеп партия комитетларының беренче секретарьлары сайланачак — бу көн кебек ачык, шикләнергә урын юк. Ихтимал, кайбер очракта, әйтик, шәһәр күләмендә Советның председателе итеп фиркасыз да сайланыр, ләкин бу инде кагыйдәдән чыгарма гына булачак.

...Әмма председательлекне дә кулына алган секретарьлар кемнәр алар, барысы да лаек кешеләрме? Моңарчы бит һәр өлкәдә, һәр шәһәрдә, бигрәк тә район җирендә, беренче секретарь төп җитәкче, төп «хуҗа» иде. Халык та инде аларны күптән шулай дип таный, алар үзләре дә шул рольне башкарырга күптән өйрәнеп беткән. Бигрәк тә торгынлык заманында формалашкан секретарьлар өчен бу бик табигый хәл иде. Хәзер менә шундый секретарь Совет председателе дә булып алгач, ике җитәкчелекне дә үз кулында туплап, өйрәнелгән гадәт буенча, иске эздән китмәс микән дигән шик туа. Һәм нәтиҗәдә без чын

демократия урынына ярым демократик, ярым бюрократик, авторитар бер власть алмабызмы икән?

...Әйе, демократиянең бездә зур сынаулар үтәсе бар әле. Әмма ул кирәк, ул зарур — ансыз һич тә мөмкин түгел.

— *Бүгенге кеше язмышы табигатьтән башка һич тә күзалланмаска тиеш. Шул уңайдан Татарстан табигате бик нык уйландыра...*

— Моңарчы кешелек дөньясы өчен беренче зур куркыныч булып атом коралы санала иде. Хәзер инде, галимнәрнең әйтүенә караганда, беренче урынга экология куркынычы күчте. Чөнки атом коралы кеше кулында, ул аны худка җибәрүдән тыела ала, теләсә, юкка да чыгара ала. АКШ белән безнең дәүләт арасында ирешелгән килешү атом коралын киметергә, ахыр чиктә бөтенләй бетерергә дә мөмкин икәнлеген ачык күрсәтте.

Ә табигатьне без озак еллар дәвамында туктаусыз кысрыклап киләбез, бозабыз, талыйбыз — шул рәвешчә без аны әкрен-әкрен һәлакәт чигенә китереп җиткерәбез. Бу хәвефне сизсәк тә, туктый белмибез. Табигать бит ул ни булачагын алдан ук безгә кычкырып тормый. Әмма инде чигенә килеп җиткәч, безнең башларыбызга бөтен коточкыч һәлакәтен китереп каплаячак. Арал диңгезе белән булган хәл — шуның бик ачык бер мисалы. Һәм андый хәлләр күп җирләрдә безне хәзер сагалый.

Алыйк үзебезнең Татарстанны... Аның табигате дә бик мөшкел хәлдә — күп регионнарга караганда да, территориябез әллә ни зур да түгел, ә аның җир-суларына төшкән йөк гаять авыр булса кирәк. 40—50 ел буе нефть чыгару күпме басу-кырларыбызны ертып, бозып, пычратып бетерде, күпме чишмәләрне корытты, коелардан сулар качты, яшел болынлы саф елгаларны үлек суларга әйләндерде. Болар яңадан терелерме, иске хәленә кайтырмы — без моны ачык кына белмибез. Табигатьне болай бозу-имгәтүнең кешеләргә тискәре, начар йогынтысын без әле исәпкә дә алмыйбыз.

Соңгы ун-унбиш ел эчендә республикабызның төп елгасы Камага да күтәрә алмаслык йөк төште. Чаллыдан алып Чистайга чаклы, күп булса, 100—120 километр арада, гигант заводлар корылды, зур-зур шәһәрләр барлыкка килде, аларда яшәүче халыкның саны миллионнан артып китте. Йөк исә һаман арта бара. Алабуга янында, кирәксез дип табылган трактор заводы урынына, икенче автомобиль гиганты салына. Менделеевскида яңа химия производстволары төзеләчәк... Һәм болар барысы да Каманың суын эчәчәкләр, тотачаклар, пычракларын шун-

да агызачаклар — йә, бу кадәр йөкне безнең батыр елгабыз күпмегә чаклы күтәрә алыр икән?! Мин инде аның ике ягындагы кырлар, урманнар турында әйтеп тә тормыйм — алардан иртәме-соңмы киек-җәнлекләр һәм кошлар качып бетәрләр, бетәчәкләр... Әле бит, җитмәсә, шушы тыгызлык арасына, елганың нәкъ өстенә заманның иң хәвефле объекты — атом электростанциясе дә төзелеп ята.

Иң аянычы шунда ки, болар барысы да халыкка әйтмичә, халыктан сорамыйча эшләнә. Каядыр югарыда, әйтик, госпланда яки министрлыкта утыручылар тоталар да, Татарстанның фәлән җиренә фәлән нәрсә салырга, дип карар чыгаралар. Һәм меңләгән кешене, йөзләгән техниканы туплап сала да башлыйлар. Халык исә белми дә кала. Ләкин бит әле безнең үз хөкүмәтебез дә бар, Татарстанның җир-сулары аның карамагында, аңа тапшырылган. Теге яки бу объектны салыр алдыннан аның белән сөйләшәләрме, аның ризалыгын алалармы, әллә аңа боералар гынамы? Бу гаять мөһим мәсьәлә... Хәлбуки бер генә төзелеш турында да мин Татарстан хөкүмәтенең үзе чыгарган карарын яисә халыкка җиткергән үз фикерен ишеткәнем юк.

Хәзер менә атом электр станциясе турында бәхәс бара. Җәмәгатьчелек борчыла (Чернобыль аның күзен ачты). Җәмәгатьчелек ул станциянең ни өчен Татарстан җирендә салынуын аңламый — ул аңа каршы. Мәгәр ничә елдан бирле корылып яткан, инде күпме акча исраф ителгән төзелешне туктатып булачакмыни?! Берзаман ул салынып та бетәр, эшли дә башлар. Чернобыль шикелле шартламас та, бәлки, тиеш тә түгел. Әмма халыкның күңеленә шом кереп калды, атом аның өчен, гомумән, бик куркыныч нәрсә, ул аңардан һәрдаим шомланып, нинди дә булса мәкерле зарарын көтеп яшәргә мәҗбүр булачак. (Җәяләр эчендә әйтәсем килә: Көнбатыш Европаның Татарстан шикелле җире аз, халкы күп илләрендә, мәсәлән, Бельгия, Голландия, Даниядә, атом станцияләре кору закон белән тыелган дип ишеткәнем бар.)

Кыскасы, экология куркынычы хәзер беренче урынга чыкты. Ничек итеп бу куркынычтан сакланырга? Һәм ни өчен бу хакта күп сөйләнсә дә, нәтиҗәсе бер дә сизелми диярлек?.. Монда бер парадокс бар: бездә җир-сулар, урманнар, барлык табигать байлыклары гомумдәүләт милке булып санала. Ә дәүләт милкенә сан юк, дәүләт милкен теләсәң күпме туздырырга, әрәм-шәрәм итәргә, хәтта эштән чыгарып ташларга да ярый. Мондый мөнәсәбәт

булганда, табигатьне, билгеле, саклап булмаячак. Бары тик һәр авыл, һәр район, һәр өлкә яки республика үзенә тигән җир-суларга чын хуҗа булып танылганда гына һәм шул җир-сулар өчен җаваплылыкны да аларга йөкләгәндә генә экология куркынычыннан, ихтимал, котылып булыр. Тереклек дөньясын сакла — кешенең үзен саклау — бу хакыйкатьне онытырга берәүнең дә хакы юк!

*— Татарстаннан читтә бик күп милләттәшләребез яши. Әйтик, Башкортстан җирендә генә дә алар 1 миллионнан артык. Андыйларның киләчәк язмышын Сез ничек итеп күзаллыйсыз?*

— Бу бик җитди мәсьәлә, уйландыра һәм борчый торган мәсьәлә. Әйе, татар халкының бөтен Союзга таралып яшәве милләт буларак үзен саклау җәһәтеннән аның хәлен бик нык читенләштерә. Билгеле, моның ерак тарихтан килгән сәбәпләре дә бар, әмма революциядән соң бу таралу аеруча көчәйде. Мәсәлән, гражданнар сугышы вакытында һәм ачлык елында күпләп читкә китүләр, колхозлаштыру вакытындагы сөрүләр, сугыштан соң төрле якка эшкә җыеп җибәрүләр — әнә шул таралуның ачык күренешләре... Шулай да егерменче елларның ахырына кадәр без бөтен бер халык идек әле, үзара бәйләнешләр дә дәвам итә иде, татарлар тупланып яшәгән җирләрдә ана телендә мәктәпләр бар иде, хәтта театрлар да эшли иде. (Бу культура учакларын санап тормыйм — алар күпләргә билгеле.)

Сталин хакимлеге урнашкач, татар халкы милләт буларак таркала башлады, бәйләнешләр өзелде, бердәмлек бетте. Соңгы 30 ел дәвамында бу таркалу процессы аеруча көчәйде. Хәзер инде күп җирләрдә ана телендә укыту бетте, ә газета, китап, театр кебек нәрсәләр турында әйтеп торасы да юк — алар инде сагынып сөйләргә генә калды... Хуш, моның нәтиҗәсе нәрсә соң? Минем күзәтүем буенча, татарларның руслар арасында яшәүчеләре әкренләп руслаша, Казахстанда торучылар — казахлаша, Үзбәкстанда — үзбәкләшә... (Аеруча бу шунда туып-үскән яшьләргә кагыла.) Шул ук вакытта алар чын руска, казахка яки үзбәккә дә әверелеп җитмиләр кебек. Ата-бабадан килгән җепләр өзелә, нигез таркала. Әнә шундый язмышка дучар безнең халык...

...Сез менә Башкортстанны да телгә алдыгыз. Башкортстан — минем туып-үскән җирем, аның хакында сөйләү миңа бер дә җиңел түгел. Башкорт халкына хөрмәтем зур, бервакытта да башкортка карата кимсетү сүзе әйткәнем юк. Балачактан ук аралашып үскәнгә күрәдер инде, мин татар белән башкортка бертуган халык итеп

карый идем. Һәрхәлдә, алар арасында зур аерма күрми идем. Ләкин бу һич тә башкорт халкын үзенә аерым, башка бер халык итеп танымау дигән сүз түгел. Киресенчә, мин башкортны үзенә аерым бер халык дип саныйм, шулай булган ул, шулай яшәп килгән, тик дин берлеге, тел якынлыгы аркасында һәм бер үк җирләрдә яшәгәнгә күрә, татар белән башкорт бер-берсенә шактый нык якынайганнар, аралашып, кәсеп итешеп, кыз бирешеп тә бергә гомер сөргәннәр... Менә шул тугандаш ике халыкның арасына соңгы вакытларда салкын кара күләгә төшүенә мин, әлбәттә, бик борчылам, гаҗәпләнәм, дөресен генә әйткәндә, аңлап та бетермим. Мәсәлән, татар авылларын башкортка әйләндереп язу яки татар мәктәпләренә ана теле урынына башкорт телен кертергә тырышу нигә кирәк булды икән? Мин ишеткәнемне әйтәм, әгәр ялгышсам, гафу итсеннәр!..

Башкортстан да күпмилләтле республика, ләкин сан ягыннан өч халык күпчелек тәшкил итә. Болар — башкорт, татар, рус... Күптән бергә яшиләр, бергә икмәк үстерәләр, нефть чыгаралар, завод-фабрикаларда эшлиләр... Мәгәр үзләренең милли ихтыяҗларын үтәү ягыннан алар тигез шартларга куелганмы, бер үк мөмкинлек белән файдалана алаламы?.. Мәсәлән, ни өчен туган телне укытуда, китап чыгаруда, театр ачуда, радио-телевидениедән сөйләүдә, әйтик, русларга бирелгән мөмкинлек татарларга да бирелми?.. Мондый чикләү кайдан, кемнән чыга?..

Һәрбер халыкның, саны күпме булуга һәм кайда яшәвенә карамастан, үзен милләт буларак сакларга да, милли ихтыяҗларын үтәүгә дә тулы хакы бар. Бу хакта соңгы вакытларда иң югары партия трибунасыннан каткат әйтелде дә инде... Хокуктан тулы файдалану өчен бер генә нәрсә кирәк: һәр эштә, һәр җәһәттән тигезлек!.. Бары бөтен яктан тигезлек кенә милли мөнәсәбәтләрдәге гаделсезлекне, киеренкелекне бетерергә ярдәм итәчәк.

Башкорт һәм татар — ике мөстәкыйль милләт. Берсе яшьрәк, икенчесе картрак, әмма үзләренең хәзерге аңбелем, культура дәрәҗәләре ягыннан тигезләнделәр дип әйтерлек. Шулай булгач, алар арасындагы борыннан ук килгән дуслык-туганлык тагы да ныгый төшәргә тиеш иде. Иманым камил, хәзерге ике арадагы киеренкелек түбәннән, халыкның үз арасыннан чыккан нәрсә түгел, ә каяндыр югарыдан яки бер катлам кешеләр тарафыннан ясалма рәвештә китереп чыгарылган вакытлы бер низаг булса кирәк! Һәм ышанам ки, башкорт дуслар да, татар туганнар да уртак тел табарлар, бөтен чи төеннәрне

чишәрләр, татулыкка, һичшиксез, ирешерләр... Ике халыкның да рухи тазалыгы өчен! Үзгәртеп кору шартларында башкача булуы мөмкинме соң?!

*— Яңарыш чорында дөньядагы барлык демократик көчләрнең берләшергә омтылуы күзәтелә. Аларның гомум кешелек максатлары өчен, тынычлык өчен берләшүе бара. Шул җәһәттән безнең партия һәм хөкүмәт җитәкчеләребезнең дә дингә карашлары мәгълүм. Ә Сез, язучы кеше, бу турыда нәрсә уйлыйсыз?*

— Диннең әхлак кагыйдәләре Аллага ышану белән бәйләнгән. Ә ышану бер үк вакытта Аллага сыену һәм Алладан курку да ул... Һәр дин Алланың барлыгын үзенчә аңлаткан һәм Алла исеменнән үзенең гамәли (шәригать) кануннарын да төзегән.

Менә ислам дине дә шундыйларның берсе. Аның да нindидер гамәлләрне үтәүне таләп иткән, нindидер эшләрдән катгый рәвештә тыйган үз кануннары бар. Фарыз гамәл һәм хәрам эш, савап һәм гөнаһ дигән төшенчәләр дә әнә шул кануннар белән бәйләнгән.

Татар халкының ислам динен кабул итүенә дә 1000 елдан артып китте. Шушы озын дәвер эчендә шәригать кушкан яки тыйган гамәлләрнең күбесе, әхлак кагыйдәсе буларак, халыкның гореф-гадәтенә дә кереп калган. Мәсәлән, дин мөселман кешесенә хәмер эчүне тыйган, һәм халык авылда аракы саттырмаган. Яки татар халкы пакьлек-чисталыкка өйрәнгән — моны да шәригать таләбенең бер нәтиҗәсе дияргә була. Шулай ук шәригать талау, урлау, алдау, яла ягу кебек начар эшләрдән тыйган; кешеләргә карата шәфкатьле булырга, җан ияләрен кызганырга өндәгән... Һәм халык та яхшысын үтәргә, начарыннан тыелып яшәргә тырышкан. Шуның белән бергә ул дин аркасында милләт буларак бөтенлеген дә саклаган.

...Инде менә җитмеш ел без Алласыз һәм динсез яшибез. Мәктәптән үк безгә Алла юк, дин зарарлы, дип тукыдылар һәм без шуңа ничектер бик ансат кына ышандык та. Бу да бит үзенә күрә бер азатлык иде. Әмма бу «азатлык» бер ише бәндәләрне бөтенләй бәйдән ычкындырды. Утызынчы елларның башларында бөтен җирдә диярлек мәчетләрне яптылар, күбесенең манараларын кисеп яки ишеп төшерделәр, эчендәге китапларын чыгарып яндырдылар, ә муллаларын читкә сөрделәр. Кемнәр эше бу?.. Һәрхәлдә, халык эше түгел, халык якын да бармады. Шулай ук чын укымышлы кешеләрнең дә монда һич катнашы юк. Асылда, бер төркем кара надан, фанатик вәхшиләр эше иде. Ихтимал, шулар нәтиҗә-

сендәдер, бездә атеизм өндәүләре халыкка юньләп тәэсир итә алмады, иске әхлак кагыйдәләрен яңа бер чыны, яхшырагы белән алыштыра алмады. Аның каравы диннең моңарчы төрле бозыклыклардан, ярамаган эшләрдән тыеп килүе бетте диярлек. (Моның мисалларын китереп тору кирәк микән — бик мәгълүм нәрсәләр.) Ләкин шул ук вакытта халыкның күпмедер өлешендә «Алла» дигән бер кодрәт иясенә ышану һаман да әле сүнеп бетмәгән — киресенчә, соңгы елларда бу ышануның көчәюе ачык сизелеп тора. Диннән бөтенләй надан, «Аллаһы әкбәр» дип бит сыйпаудан башканы белмәгән хәзерге кешеләрнең күбесе шәригать кушканны ничек булса да үтәргә тырыша. Шул рәвешчә кеше, изге бурычымны үтәдем дип, үзенә җиңеллек таба, күңелен тынычландыра. Моны мин табигый бер хәл дип карыйм, чөнки кеше дигәнең элек-электән үк үзенең авыр, мәшәкатьле һәм гөнаһлы тормышында һәрвакыт нәрсәдәндер юаныч табарга, күңелен нәрсә беләндер тынычландырырга мохтаҗ булып килгән. Аллага ышануның бүгенге көндә дә кешеләрдә саклануы, хәтта көчәюе, бәлки, әнә шул табигый ихтыяҗдан килеп чыга да торгандыр... Башкасы юк бит, табылмады... «Совет кешесенең мораль кодексы» дигән нәрсә булды, ләкин гамәлдә ул кодексны адым саен боздылар — шуннан соң халыкка нәрсә кала — йә сыналган искегә кайту, йә бернинди «кодекссыз» яшәү?! Хәер, бу философлар темасы, алар баш ватсыннар.

Минем бары, бүгенге үзгәртеп кору таләпләреннән чыгып, дингә һәм дин тотучыларга мөнәсәбәт турында гына кыскача әйтеп үтәсем килә. Без Аллага ышануны һәм дин тотуны кешенең вөҗдан эше, дибез. Шулай икән, кешегә вөҗданы кушканны эшләргә тулы ирек һәм мөмкинлек бирелергә тиештер инде... Хәлбуки дин тоту формаль рәвештә конституция белән рөхсәт ителгән булса да, җирле власть органнары соңгы елларга кадәр дингә ничек тә аяк чалырга тырышып килделәр. Әгәр бу тенденция киләчәктә дә сакланса, бездә чын демократия була алмаячак һәм кешенең гражданлык хокукы да тулысынча сакланмаячак. Динлегә дә, динсезгә дә мөнәсәбәт һәр җәһәттән бертөсле булырга тиеш. Аларның берсен (динлесен) түбән санап, икенчесен өстен куюы дөрес булмаячак. Гражданнар буларак алар тигез хокуклы, ә Аллага ышану наданлыктан гына булмаган шикелле, Аллага ышанмау да бары тик укымышлы булудан гына килгән нәрсә түгел. Берәүнең Аллага ышануы һәм дин тотуы, икенчесенең исә Алланы танымавы һәм дин тотма-

вы демократик җәмгыятьтә табигый хәл булып саналырга тиешле.

Инде әхлак мәсьәләсенә килгәндә, таләп һәммәсенә дә бер: яхшылыкка омтылу, начарлыктан тыелу, миһербанлылыкка өндәү, кансызлыкка каршы тору — рухи тазаруга мохтаҗ җәмгыятьтә һәркемнең намус бурычы ул!..

...Югарыда мин хәзерге халыкның дин мәсьәләсендә бик надан булуын әйткән идем. Һәм гаҗәп тә түгел — берәүнең дә бит дин сабагы алганы юк. Менә шушы гомуми наданлыктан файдаланып, мәчет тирәсендә кулдан язылган ниндидер догалыклар сатучы яки чакырган җиргә барып «Коръән укырга» әзер торучы, үзе дә үтә надан кешеләр йөри дип ишеткәнем бар... Әгәр дә дин тоту, шәригать гамәлләрен үтәү җитди эштән санала икән, аның чын укымышлы, мәдәниятле, халык җанлы әһелләре дә булырга тиештер инде. Кем кайгыртырга тиеш моны, мин әйтә алмыйм, әмма халыкның рухиятен һәртөрле чүп-чарлардан сакларга кирәктер дип уйлыйм. Фәндә дә, диндә дә, гомумән, һәрбер эштә ялган, ярамлашу, фальсификация булмаска тиеш дип беләм.

*«Казан утлары», 1988, 3 сан*

## ТӘВӘККӘЛЛЕК ТЕЛИМ

*(Әмирхан Еникинең «Татарстан АССР халык язучысы» дигән исем алганда сөйләгәне)*

Хөрмәтле иптәшләр!

Язучы өчен иң читене — үз иҗатыңны, үзеңнең әдәбиятта тоткан урыныңны дөрес аңлау һәм дөрес бәяләү... Монда ялгышуы бик ансат: йә бәяләп бетермисең, йә арттырып уйлый башлыйсың. Ә кеше дигәнең, гадәттә, арттырып уйларга ярата. Моның ахыры исә тора-бара бик күңелсез булып бетүе, ягъни көткән дан урынына билгесезлек килүе бик мөмкин. Шуны сизгәндәй, мин, кыйналган чакта гына түгел, макталган чакта да үзем турында арттырып уйлаудан сакланырга тырыштым. Кешенең эшен дә, тоткан урынын да ахыр чиктә вакыт билгели — менә мин дә үземне вакыт хөкеменә тапшырган идем. Вакыт ялгышмас, вакыт дөресен әйтер дип ышана идем.

Инде менә миңа Татарстан Верховный Советы указы белән «Халык язучысы» дигән мактаулы исем бирелде. Бу — вакыт хөкеменә караганда ничектер иртәрәк булды шикелле... Мин үзем дә моны көтмәгән идем... Лә-

кин бит исемне кешегә тере чагында бирәләр, аннары 80 яшь аз гомер дә түгел, күрәсең, мин күпмедер дәрәҗәдә вакыт сынавын үткәнмендер дә инде. Әгәр шулай икән, әгәр шуннан чыгып безнең Язучылар союзы мине әлеге мактаулы исемгә тәкъдим итүне, ә Верховный Советыбыз президиумы, ниһаять, миңа шул олы исемне бирүне кирәк тапкан икән, мин, әлбәттә, аларга чын күңелдән тирән рәхмәтемне белдерәм. Шулай ук бу эшне хуплап каршы алучы укучыларыма да һәм каләмдәш дусларыма да тирән рәхмәтемне әйтмичә кала алмыйм: рәхмәт сезгә, дуслар, рәхмәт, туганнар!..

Билгеле, «Халык язучысы» дигән шәрәфле исемне кер төшермичә йөртүе, бигрәк тә аны аклавы җиңел булмаячак. Үткәндәге эшләр белән генә түгел, яңа эшләр белән дә акларга кирәк булачак. Әмма язучы, ничә яшьтә булуына карамастан, һәрвакыт алга карап яши ул. Теләге, өмет иткәне, күрәсе килгәне барысы да алда — яшәве дә, эшләве дә аның бары шулар хакына!

Без бит бик хикмәтле бер чор кичерәбез. Хәзерге яңарышны, үзгәртеп коруны революция, диләр, революция белән тиңлиләр. Ә безнең әдәбиятта, Тукайлар заманында, революцияне таң ату, яңа көн туу белән чагыштырганнар. Тик ул заманда безнең халык өчен таң бик әкрен аткан.

Менә ничек башлана, мәсәлән, Сәгыйть Рәмиевнең «Таң атканда» дигән шигыре:

Таң вакыты... Татар йоклый...
Мин йокысыз, уянам,
Уянам да, тиле кебек,
Тик бер үзем уйланам.

Уйланам, уема батамын,
Тормыймын үзем, ятам,
Ятмас идем дә, җибәрми
Атадан калган хатам.

Инде Тукайны тыңлап карыйк:

Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән,
Эшкә дәгъвәт итте безне кемдер изге нам белән.

Булса да ул чакта бездә керсез иман, саф күңел,
Күз һаман булды эренле, йөз дә саф һәм пакь түгел.

Күрәсез, икесендә дә сүз инкыйлаб таңы турында... Әйе, бу беренче таң вакытында татар халкы авыр уянган, ата-бабадан калган хаталар, гасырлар буе сузылып килгән изү-кысулар, шуның өстенә наданлык һәм хорафат аңа тиз генә уянып торырга мөмкинлек бирмәгән. Әмма

инде бер торып баскач, ул кыска гына вакыт эчендә бик кызу алга табан атлап китә. Татар дөньясының ике революция арасындагы бу гаҗәеп омтылышын без әле тиешенчә белеп тә, аңлап та җиткергәнебез юк.

Әйтергә кирәк, безнең хәзерге таңыбыз да шактый озак, шактый авыр ата. Күпме еллар буенча җыела килгән аянычлы хаталардан да һаман әле котылып бетә алмыйбыз, күзләрдән көн яктысын караңгылап торган томан пәрдәсе дә әле төшеп бетмәгән. Мондый хәлдә алга таба туры, кыю атлау җиңел түгел, әлбәттә... Димәк, иске карашлардан һәм гадәтләрдән ничек тә тизрәк арынырга кирәк. Шунсыз яңару мөмкин булмаячак. Ә инде халыкны әнә шул иске догмалардан азат итү, күзен ачу, рухын сафландыру, фикери хөрлеккә өндәү — бу әдәбият эше, иптәшләр, бу безнең төп эшебез! Һәм мин бу эштә үземә дә, каләмдәш дусларыма да көч-куәт һәм тәвәккәллек телим.

Рәхмәт игътибарыгыз өчен!

*«Казан утлары», 1989, 7 сан*

## ТАТАР МӘСЬӘЛӘСЕ

### I

Бик борыннан яшәп килгән, хәзергә кадәр тиешенчә хәл ителеп бетмәгән бер четерекле мәсьәлә ул — «татар мәсьәләсе». Казан ханлыгы бетерелгән вакыттан башлап санаганда да аның дүрт гасырлык тарихы бар. Һәркемгә ачык мәгълүм булганча, бу мәсьәлә турыдан-туры урыс-татар мөнәсәбәте белән бик нык бәйләнгән. Асылда, аның гаять озакка сузылган тарихы да, ахыр чиктә хәл ителү кадәресе дә шушы мөнәсәбәтләргә кайтып кала.

Нидән гыйбарәт соң бу мөнәсәбәтләр?

Бик тирәнгә кермичә, ерак тарихыбыздан ике мөһим моментны гына искә төшерәсем килә. Беренчесе: безнең халыкның борынгы исеме болгар, һәм шушы исемдәге шактый алга киткән дәүләте дә булган. Болгар белән урыс кенәзлекләре арасында вакыт-вакыт бәрелешләр булгалап торса да, алар күбрәк алыш-биреш итешеп тыныч яшәгәннәр.

Икенчесе: XIII гасырның беренче чирегендә каяндыр Кытай чикләреннән кубып чыккан бихисап татар-монгол явы бәләкәй атларда, кәкре кылычларын уйнатып, кара болыттай ябырылып киләләр дә Болгарларны да яндырып, таптап узалар, бөтен урыс җирләрен дә ба-

сып алалар*. Шуннан соң татар-монголлар урыслар өстеннән 200—250 еллар чамасы хакимлек итәләр. Бары Алтын Урда таркалгач кына урыслар татарлар кул астыннан чыгалар. Мәгәр аңа карап кына татар белән урыс арасындагы тартыш-кырылыш бетми, һаман кабатланып тора, тик Казан ханлыгы бетерелгәч кенә (1552), ниһаять, туктый. Шул рәвешчә чыгышы (этносы) һәм дине бөтенләй башка бу ике халык арасындагы дошманлык 300 елдан артыграк дәвам иткән.

Инде яңадан искә төшерик: татар-монгол явына кадәр без болгарлар идек. Алтын Урда кулында калгач, татар исемен урыслар безгә дә күчерә... Шушы тагылган исем белән без менә ничә йөз ел инде яшәп киләбез. Халкыбыз озак гомерләр бу кушамат белән килешергә теләмәгән, үзен йә мөселман, йә болгар дип йөрткән, моның чагылышын без кайбер әдәби әсәрләрдә дә күрәбез. Мәсәлән, Гаяз Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән әсәрендә, татар димичә, болгар дип яза. Ә бу бит шушы гасыр башында гына язылган әсәр... Әмма инде урыслар өчен һәм алар аша бөтен дөнья өчен без — татар. Та-тар! Көйдереп баскан тамга шикелле йөртәбез без бу данлыклы хәтәр исемне!.. Теге Кытай чигеннән килгән чын татарлар юк, китеп беткәннәрме, әллә җирле халык арасында эреп юкка чыкканнармы — Ходай белсен! — мәгәр без бар, без һаман үз җиребездә, һәм менә без урысның шул «татар» дигән исемгә булган карашын һәм мөнәсәбәтен күпме заманнардан бирле үз җилкәбездә татып киләбез дә инде.

Бәлки, «татып киләбез» дип әйтү хәзер урынлы да түгелдер, «татып килдек» дип әйтү, бәлки, дөресрәк булыр иде. Үзара сугыш-кырылыш беткәнгә дә дүрт гасыр узып киткән бит инде, аннан соң, вакытлар үтү белән, ике арада, ниһаять, татулык та урнашкан. Ә соңгы 70 ел дәвамында без гел дуслык турында сөйләдек, урыс халкын «олы агабыз» дип тә атадык, һәм бу сүзләрдә күпмедер дөреслек тә бар иде. Зарланырга сәбәп юк кебек. Әмма шуңа да карамастан урыс-татар мөнәсәбәтләрен һәр җәһәттән дә канәгатьләндерерлек дип әйтүе дә читен. Ниндидер бер гайре табигый ят күрүме, яратып бетермәвеме — һәрхәлдә, ике араны киеренке иткән нидер бар... Гүя «татар» дигән бер сүз үзе үк урыс кешесендә тискәре тойгы уята. Акылы белән ул татарга ят кеше итеп карамый да торгандыр, ә менә ирексездән уянган тискәре тойгысы аның, бәлки, ихтыярыннан тыш, еш кына

---

*Сүз озынга китмәсен өчен, вакыйгаларны гомумиләштереп алырга туры килә.— *Ә.Е.*

үзен сиздереп куя. Һәм моңа артык гаҗәпләнергә дә туры килми. Күпме гасырлар дәвамында татар урысның дин һәм кан дошманы булып саналган. Шул хакта елъязмаларда күпме язылган, чиркәү мөнбәрләреннән күпме сөйләнгән, урыс дәүләте исә татарга карата даими рәвештә кысу-изү сәясәтен үткәргән. (Татар халкын утырган җирләреннән сөрүләр, көчләп чукындырулар, һәртөрле хокуктан мәхрүм итүләр — болар бит барысы да булган.) Шул рәвешчә татар милләте урыслар өчен, хәзерге тел белән әйткәндә, «дошман образы» буларак ерак заманнардан бирле сакланып килгән. Бусы гаҗәп түгел, дидек. Мәгәр гаҗәбе шунда ки, күпме буыннар алышынганнан соң да, «дошман» сүзе күптән онытылып беткән булса да, аның «образы» бүгенгә чаклы хыялларда үзгәрмичә һаман яшәп килә — гүя кан белән күчкән ул! Нәрсәдә күрәбез без моны?.. Һәркемгә мәгълүм булганча, шушы көнгә кадәр урысча мәктәп дәреслекләрендә, матур әдәбиятта, газета-журнал битләрендә, экскурсоводларның туристларга сөйләп йөрүләрендә «татарское нашествие», «татарское иго» дигән сүзләрне еш кына укыйбыз һәм ишетәбез. Без инде моңа күнегеп беттек диярлек. Ләкин бит ул бик тәфсилләп язылган яки сөйләнгән нәрсәләрне йөзләгән милләт халкы укый һәм ишетә. Шуннан соң аларда татарларга карата нинди хисләр уянганын чамалау, минемчә, бер дә читен түгел.

Тагын бер гаҗәбе шунда ки, бу язу һәм сөйләүләрдә монгол исеме гадәттә телгә алынмый. Ни өчен? Монголлар, шартлы рәвештә генә булса да, үзләренә аерым «мөстәкыйль» бер дәүләт булганга күрәме?.. Ләкин берәүнең хәтерен саклап, бөтен гаепне икенче берәүгә сылап калдыру тарихи дөреслекне тупас бозу була түгелме соң?!

Аннары бик борыннан ук урыслар белән күрше болгар-татарны Кытай чигеннән яу булып килгән чын татарлардан аерып тору да юк. Алар бер үк халык түгел ләбаса! Моны бит тарих белән азмы-күпме таныш урыс иптәшләр беләләр. Белсәләр дә, аерып тормыйлар. Димәк, безнең татар өстенә ни сөйләсәң дә ярый булып чыга... Бусы да әлеге шул «татарны» «образ» итеп караудан килә булса кирәк.

Янә бер гаҗәпләнүебезне әйтмичә булмый. Татар-монголларның Болгар илен һәм урыс җирләрен басып алуларына җиде гасырга якын вакыт үтеп киткән. Шуның баштагы өч йөз елы урыслар өлешенә, соңгы дүрт йөз елы безнең өлешкә тия. Урыслар үзләренә тигән 300 елны бер дә онытмыйлар: «татарское нашествие», «татарское иго» дип, безнең исебезгә һаман төшереп кенә

торалар. Хәлбуки бу 300 елда урыслар гел изелеп кенә яшәмәгәннәр, үз җирләренә үзләре хуҗа булып тынычтату торган чаклары да булган; Алтын Урда ханнары арасында өзлексез ызгыш-тартыш барган чагында, алар, әкренләп көч җыя-җыя, татарларның үзләрен тукмый башлаганнар. Ниһаять, Казан ханлыгын да тар-мар итеп, тулы җиңүгә һәм татар өстеннән гомерлек хакимлеккә ирешкәннәр.

Ә без үзебезгә тигән соңгы 400 елда ничек яшәгәнбез, ниләр күргәнбез, ниләр кичергәнбез?.. Бу хакта үзебез дә сөйләмибез, урыслар да язмыйлар. Ләкин бит урыс изүе татар изүеннән бер дә җиңел булмаган. Киресенчә, сакланып калу ягыннан куркынычрак та булган. Хәзерге вакытта арабызда яшәүче керәшен кардәшләребез шуның ачык бер мисалы түгелмени?! Татар халкы моны хәтерли, татыган, тик әле бу хакта кычкырып әйтүдән заман аны тыелырга өйрәткән.

Инде бу сөйләгәннәрдән нинди нәтиҗә ясарга була? Күргәнебезчә, урыс белән татар арасында 300 ел буена барган канлы көрәш бу ике халыкның язмышында хәлиткеч зур роль уйнаган, берсен ахыр чиктә биеклеккә күтәргән, икенчесен түбән төшергән, мәгәр икесен ике якка аерып җибәрмәгән, ә бер җирдә, бер үк кояш астында гомер бакый бергә яшәргә калдырган. Кешелек тарихында сирәк очрый торган гаҗәеп бер күренеш дияр идем мин моны... Әмма бер нәрсәне кистереп әйтергә кирәк: безнең хәзерге шартларда урыс һәм татар арасында нindидер күзгә күренеп торган дошманлык бар икән дип уйлау зур хата булыр иде. Юк андый дошманлык — татарда да, урыста да юк. Әмма бик ерак заманнардан сакланып калган «дошман образы» урыс халкының аңында, каядыр бик тирәндә яшеренеп ята... Сүз әнә шул хакта бара. Халык бик чуар бит, аның төрлесе бар. Мәсәлән, укымышлы чын урыс интеллигентының, хорафатлардан өстен торып, татарга яхшы каравына ышанырга була. Ә менә шовинизм сөременнән арынып бетмәгән берише халыкның яхшы каравына ышанып буламы — бигрәк тә аның исенә «нашествие» белән «иго»ны әледән-әле төшерә торсалар?.. Мондый очракта инде тискәре караш үзен ничек тә сиздермичә калмаячак. Һәм без моны (яшерен шовинизмны) Советларга сайлаулар вакытында ачык сиздек тә: сайлаучыларның күпчелеге урыслар булган шәһәрләрдә, хәтта Казанның үзендә дә, СССР Югары Советына бер генә татарны да үткәреп булмады.

Бу әйткәннәрдән икенче нәтиҗә шул: үткәндәге хәл-

ләрне искә төшерү бер генә яклы булмаска тиеш. Әлбәттә, тарих фәне, әгәр ул чыннан да фән икән, бер нәрсәне дә юри яшермәскә яки юри күпертмәскә тиеш. Аның бердәнбер критериесе — дөреслек! Хәлбуки урыс халкының кайчандыр ничек изелгәнен өзлексез тәкрарлап та, татар халкының язмышында ниләр булганын һаман әйтмичә килү ахыр чиктә ике халык арасында кирәкмәс киеренкелек тудыруга сәбәп була да инде. Без моны бик яхшы тоябыз, кайчагында бит үзеңнең татар икәнеңне әйтү дә уңайсыз була башлый. Һәм, ниһаять, 600—700 ел үткәннән соң, бездә яңадан болгарга күчәргә кирәк дигән таләпләрнең ишетелә башлавы да бер дә юкка гына түгел ич!

Озын сүзнең кыскасы, татулыкны бозуы ансат, мәгәр төзәтүе бик читен. Мисалларын күреп торабыз... Урыс, татар арасындагы татулыкның нормаль булуына без әле шөкер итә алабыз. Әмма аны саклый да белергә кирәк. Хәтта әнә шул кайсыдыр ерак заманнардан торып калган кәкре кылычлы «образ» да ике арага салкын кара күләгә булып ятмаска тиеш.

## II

Хуш, әлеге үзебезгә тигән 400 ел турында без нәрсә беләбез? Мин үзем, мәсәлән, бик аз беләм. Бу шулкадәр озын бер дәвер ки, аның тәүге 100 елында да бик күп вакыйгалар булып узарга тиеш кебек иде. Ничәмә буын кешеләр алышынган, патшалар бер-берсен алыштырган, Мәскәү дәүләтендә ниндидер чуалышлар булган, читләр белән һаман сугышлар булып торган, ә безнең татар дөньясында ниләр, нинди зур вакыйгалар булганын без ачык кына белмибез.

Җиңүчеләр «Казан ханлыгының» җирләрен «үзләштерә» башлаганнардыр, әлбәттә; татар авылларын зур су буйларыннан куулар, алар урынына урысларны күчереп утыртулар, дворян-алпавытларга иң әйбәт җирләрне бүлеп бирүләр, Казанның да таза урыннарыннан татарларны сөрүләр, калабызның шактый тиз «урыслашып» баруы, бер-бер артлы чиркәү һәм монастырьлар салына башлавы — болар барысы да җиңелгән, буйсындырылган халык өчен табигый вакыйгалар, алар турында куертып, зар җылап нигәдер сөйләп торасы да килми... Мәгълүм бит инде: Казан өчен соңгы сугыш нихәтле генә каты булмасын, ул кыска гына вакыт эчендә үткән дә киткән, ә менә аңардан соң башланган фаҗига татар халкы өчен йөз мәртәбә авыррак булгандыр, чөнки ул әнә ничә йөз

елга сузылган. Һәм бу чиге күренмәгән дәвер миңа ни өчендер төньякның алты айга сузылган кояшсыз төнен хәтерләтә. Дөм караңгы да түгел, ачык кына бернәрсәне дә шәйләп булмый — әйтерсең бөтен әйләнәдә тирәнтен бушлык хөкем сөрә.

Әллә мин ялгышаммы? Менә әдәбиятыбыз тарихын алып карыйм, анда йөз елга бер шагыйрь, ә гыйлем өлкәсен алсак, Курсавидан башка үзен таныткан бер шәхес тә юк диярлек. (Мәрҗани соңрак.) Ә бит Болгары да, Казаны да кайчандыр әдәбиятка һәм гыйлемгә бай булган, диләр. Нидән бу рухи фәкыйрьлек, халык бар бит, халык яшәгән ич, кая китеп беткән аның акыл көчләре?.. Ихтимал, моңа татарның үзендәге бер сыйфат гаепледер. (Тизрәк башкаларга яраклашу.) Әле Алтын Урда таркала башлаган вакытта ук инде, татар түрәләре һәм морзалары урыслар ягына чукынып яки чукынмыйча чыга башлыйлар. Казан ханлыгы вакытында да, бигрәк тә ул җимерелгәч, татар морзаларыннан христиан динен кабул итүчеләр күбәя. Билгеле ки, татар каны кушылган урыслардан тора-бара мәшһүр язучылар, зур галимнәр дә чыга. Гомумән, татарның «аксөякләре» урыс дәүләтенә бик итагатьле хезмәт итәләр.

Иллә мәгәр татар халкының абсолют күпчелеге (шулай ук морзаларның да күпчелеге) өзлексез кысу-көчләүләргә карамастан, динен дә, телен дә ташламаган. Дин халыкны done бербөтен милләт итеп саклау җәһәтеннән иң көчле фактор. Дөрес, без моны соңгы елларга кадәр инкяр итәргә тырыштык. Әмма татарның өч-дүрт йөз ел буена сакланып килүе нәрсәдән? Әлбәттә, диннән. Шуңа күрә дә бит урыс дәүләте һәм православие чиркәве иң элек аның диненә каныга да. Татар халкының бик озак заманнар рухи торгынлыкта калуы турыдан-туры әнә шул дини һәм милли изелүе белән бәйләнгән дә инде... Әйе, «мескен булып торган өч йөз елда тәкъдир безне ничек изгәнен» (Тукай) аңа, ягъни татар халкына, Рәсәйнең барлык халыкларына караганда да озаграк һәм катырак татырга туры килгән.

Болай изелеп яшәүнең бер нәтиҗәсе мине еш кына уйландыра. Хәзерге көндә урысларның саны 145 миллионга җитә, ә татарлар 7 миллион чамасы гына... Ничек итеп, нәрсә белән бу кадәр чамасыз зур аерманы аңлатырга? Моннан 400 ел элек мондый аерма булмагандыр, шәт! Фәндә моны төшендерү бармы — белмим, очратканым юк. (Мондый аерма бик борыннан сакланып килгән булса, татар бервакытта да урысны үзенә буйсындыра алмаган булыр иде.) Әгәр дә ки бу — соңгы җиңелүнең, ирексездән

качып, таралып бетүнең һәм көчләп чукындыруның нәтиҗәсе икән, димәк, безнең халык үзенең сакланып калуы өчен гадәттән тыш зур бәһа түләгән булып чыга.

Казан ханлыгыннан соң башланган фаҗигале язмышыбызның, елъязмалардагы шикелле, тулы, эзлекле тарихы булмаганга күрә дә күп нәрсәләр турында юраргына туры килә. Ниһаять, былтыр гына чыккан Ш.Мәрҗани китабында да ул дәвер турында мәгълүмат бик аз... Монда бик мөһим бер моментны истә тотарга кирәк: без Россия үзәгендә торучы халык, безнең аша зур сәүдә юллары уза, империянең тарихи, мәдәни үзәкләреннән дә ерак тормыйбыз. Ә ике милләтнең матди һәм рухи үсешендә, җир белән күк арасы шикелле, нинди зур аерма! Петр I заманыннан алып, бигрәк тә XIX гасырга кергәч, урыс милләтендә искиткеч бер күтәрелеш башлана ки, гасыр ахырында инде Россия дөньяның иң бай, иң куәтле империяләреннән берсе булып танылa. Ә без, шул империя эчендә яшәүче халык, гүя калын юрган астында тончыгып, йоклап ятабыз. Бернинди уяну хәрәкәте сизелми диярлек. Урыс әдәбиятының даны бөтен дөньяга таралган бервакытта бездә әле беренче романның да язылганы юк иде. Нидән бу? Гасырлар буена һәртөрле хокуктан мәхрүм булып яшәүнең нәтиҗәсе түгелме? Мәгърифәтне, яктылыкны кайдан алырга? Гимназияләр, университетлар юк лабаса татар дөньясында!.. Ә шулай да урыс дөньясындагы бөек прогрессның тәэсире безгә дә кагылмыйча калмаган, әкренләп булса да уяткан безне, хәрәкәткә китергән... Моның шулай икәнлеген замана үзе тиздән бик ачык күрсәтте. Гомумән, татар дөньясындагы хәлләрне Россия эчендә барган зур вакыйгалардан аерып карау мөмкин дә түгел икән.

Унтугызынчы гасырның икенче яртысында башланган уянуны без мәгърифәтчелек хәрәкәте дип атадык. Исеменнән күренгәнчә үк, бу хәрәкәтнең максаты татар халкын караңгылыктан яктыга чыгару, наданлыктан йолып алу, аң-белемгә ирештерү иде. Озакламый мәгърифәтчелеккә җәдитчелек хәрәкәте кушылды. Ә бу хәрәкәт, үз нәүбәтендә бик көчәеп, татар дөньясының алга китешендә ифрат зур роль уйнап өлгерде. Бөтен алдынгы фикер ияләре аның тарафдарлары иде. Билгеле, көрәшсез генә бармады яңа хәрәкәт — кадимчеләр (иске-лек яклылар) белән җәдитчеләр арасындагы көрәш буларак тарихыбызга кереп калды ул.

Бу прогрессив хәрәкәтләрне алга сөрүчеләрнең төп кайгылары татарның милли аңын уяту, искелек богауларыннан азат итү, Европа мәгънәсендәге алдынгы милләт

булуга өндәү иде, һәм, шушы теләкләрдән чыгып, алар үзләренең сүз-гамәлләрендә башлыча бөек урыс культурасы белән азыкланырга, урысның алдынгы укымышлы вәкилләреннән үрнәк алырга чакырдылар. Нә әдәбиятта, нә матбугатта татарны юри урыска каршы куюу кебек тенденция булмады шикелле — һәрхәлдә, мин андый нәрсәне хәтерләмим.

Мәгәр урыс самодержавиесенең татар халкына карата тоткан сәясәтендә үзгәреш юк иде. Без һаман инородец, без бил бөгеп, буйсынып кына торырга тиешбез. Татар дөньясында милли азатлыкка омтылу хәрәкәте башлангач, патша хөкүмәте бу омтылышта пантюркизм күргән булып, аны ничек кенә булса да чикләргә, басарга тырышты. Архивларда утыручыларның әйтүләренә караганда, патша охранкасы да, урысның үзендәге революция хәрәкәтеннән бигрәк, татарлар арасындагы хәрәкәт белән ныграк кызыксынган, имеш. Бәлки, дөрестер дә, чөнки 1905 елдан соң инде, 10—12 елларда, охранка безнең мәдрәсәләрдә тентүләр үткәреп, кайберләрен туздырып (мәсәлән, Буби мәдрәсәсен), күп кенә татар газеталарын ябып куйган иде.

Хәлбуки татар халкының азатлыкка омтылышы Россиядә кузгалган һәм көчәя барган гомуми революцион хәрәкәттән аерылгысыз ул. Әле кайчан гына уянып күзен ачкан татар халкы Бишенче ел революциясенә һәр җәһәттән диярлек җитлегеп килеп керә — кыска гына вакыт эчендә төрле фиркаләрнең оешуы, төрле юнәлештәге газеталар чыга башлавы шуның ачык мисалы. Революция җиңелсә дә, замана кире чигенми, иске эзенә кайтып төшми инде... Хәтта көчәеп киткән реакция дә тарихның алга омтылышын туктата алмый. Парадокс шунда ки: нәкъ менә кыска гомерле революциядән соң, татар дөньясы өчен бөтенләй яңа чор башлана — тарихыбызның иң парлак чагы дияр идем мин бу чорны... Уйлап кына карагыз: ике революция арасы бары 12 ел, әмма шул вакыт эчендә татар галәме тарихта мисалы булмаган гаҗәеп бер күтәрелеш кичерә. Әйтерсең татар халкының гасырлар буена яшеренеп яткан потенциаль куәте ачыла. Октябрьгә чаклы төрле шәһәрләрдә 58 исемдә газеталар, 37 исемдә журналлар чыга. Россиядәге барлык милләтләргә караганда да татарлар үз телләрендә күбрәк китап нәшер итәләр. Күпме-азмы татарлар яшәгән җирләрдә җәдит мәктәпләре ачыла, татарның икътисади һәм мәдәни үзәге булып саналган шәһәрләрдә читтән килеп укучылар өчен таштан зур-зур мәктәп биналары салына.

Без, гадәттә, татар байларын яманларга бик остардык. Хәлбуки әнә шул эшләрнең һәммәсе дә диярлек алар акчасына эшләнә. Бер-ике генә мисал: Казан арты Битаман авылыннан чыккан Уфаның бай сәүдәгәре Садретдин Нәзиров «Галия» мәдрәсәсен салдыру өчен 100 мең сум акча биргән; Оренбург байлары Хөсәеновлар хәзер дә әле шәһәрне бизәп торган зур мәдрәсә бинасы салдырганнар, шуның өстенә Әхмәт бай үләр алдыннан мәгариф эшләренә тотар өчен 500 мең сум акчасын васыять итеп калдырган. (Бу хакта Риза Фәхретдиновның «Әхмәт бай» исемле китабында әйтелә.) Билгеле, татарның барлык байларын да Хөсәеновлар белән тиңләргә ярамый, әмма ул заман шартларында милләтне тәрәккый иттерү байлар катнашыннан башка һичтә мөмкин булмаган. Милли азатлык хәрәкәтендә милли буржуазиянең уңай ролен Ленин үзе дә бит инкяр итмәгән.

Әйткәнебезчә, болар барысы да бик кыска вакыт эчендә булып ала. Миргазиян Юныс бу феноменны «татар дөньясындагы Ренессанс» дип бик дөрес атаган. Әгәр шул Ренессанс тагын бер 20—25 ел дәвам итсә, татар дөньясы, белмим, нинди югарылыкка ирешкән булыр иде икән?!

Иллә дә мәгәр алга китеш никадәр генә көчле булмасын, татар халкы өчен милли азатлык та, бәйсезлек тә юк әле. Кайдан, ничек килергә тиеш ул — азатлык? Самодержавие шартларында мөмкинме соң ул? Патша хөкүмәтенең татарлар арасындагы хәрәкәткә ничаклы шикләнеп һәм сагаеп караганын күрдек инде... Ә татарның киләчәк язмышы турында сүз күп, матбугат өзлексез язып тора, матур әдәбиятның да төп темасы шул диярлек. Монда аларны искә төшереп бетерү мөмкин дә түгел. Әмма берсен, миңа калса, иң әһәмиятлесен, һичшиксез, искә төшерергә кирәк. Азатлык мәсьәләсенең турыдан-туры урыс-татар мөнәсәбәтләренә бәйләнгән булуын иң дөрес аңлаган кешебез — ул да булса безнең даһи Тукаебыз!.. Менә ул, «революцион-демократ» шагыйребез, үләренә ике ай чамасы вакыт калганда, үзенең мәшһүр «Олугъ юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре» дигән шигырен бастыра. Бу — Романовлар нәселенең Россия тәхетендә утыруына 300 ел тулу уңае белән язылган шигырь. Ул мәдхия рәвешендә башлана да:

Кардан ак, сөттән дә аграк, актан ак
Падишаһ ачты «Монафис» нам канат.
Җыела халкы шул канатның астына,
Тулды өч йөз ел Романов нәселенә.

Әмма үлем түшәгендә яткан бала-шагыйрьнең әйтергә теләгәне бөтенләй башка. Шигырьнең дәвамын укып карыйк:

Рус җирендә без әсәрле, эзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без.
Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып,
Бергә тормыш, бергәлек чиктән ашып,
Без шаярыштык, вакытлар алмашып.
Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? —
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.
Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? —
Хаккыбыз* уртак Ватанда шактый ук!

Инде уйлыйк, бик ачык язылган бу гаҗәеп шигырь нәрсәсе белән безнең игътибарны үзенә җәлеп итә?.. Беренчедән, бөек шагыйрь үз халкын һич кимсетмичә, түбәнәйтмичә, киресенчә, мактап, горурланып, өстен урыс халкы белән тиң куеп сөйләшә. Хәтта әле, сүз арасында «Без шаярыштык, вакытлар алмашып» дип, кайчандыр татар халкының да өстенлек итүенә оста гына ишарә дә ясый. Икенчедән, шагыйрь хокук мәсьәләсен ялварып сорау рәвешендә түгел, ә туп-туры таләп иткәндәй, кабыргасы белән куя: «Хаккыбыз уртак Ватанда шактый ук!» һәм кем алдында диегез? — иң зур империянең тәхетендә утыручы патша алдында!.. Иманым камил ки, безнең Тукай нәкъ әнә шул таләбен куяр өчен язган да инде бу мәдхия шигырен. Берәүдән дә курыкмыйча һәм тартынып тормыйча!.. Һәм без бүген дә ул шигырьнең соңгы ике юлыннан башкасын кабатларга бик яратабыз. Әмма Тукай үзе, әгәр исән булса, әнә шул сорау-таләбен безнең СССР Верховный Советы алдында да һич икеләнмичә кабатлар иде.

## III

Февраль революциясеннән соң татар дөньясы да аеруча бер җанлану кичерде. Монархия җимерелде, хөррият килде, телләр чишелде, һәм бик табигый рәвештә безнең җәмәгатьчелектә татарның киләчәге турында кызу бәхәсләр башланды.

---

*Бу сүз «Мәктәп» журналында чыккан беренче тексттан алып Тукайның барлык җыентык һәм томнарында «Хаклыбыз» дип басылып килә. Мәгәр логика буенча «Хаккыбыз» дип укылырга тиеш. Монда икесенең берсе: йә авыру Тукай ул сүзне хатарак язган, яисә басылган чагында бозылган (Ике «къ» урынына «кълъ» киткән). *Ә.Е.*

Әмма бу кыска гомерле хөррият заманы көн тәртибенә берьюлы бик күп мәсьәләләрне китереп куйды. Россия яңа юл сайлау зарурияты алдында калды. Менә шул хакта мәйданга күтәрелеп чыккан күптөрле партияләр арасында аяусыз талаш-тартыш бара иде. Әле канлы сугыш та бетмәгән, илнең экономик хәле көннән-көн начарлана, социаль каршылыклар көннән-көн кискенләшә, ничек итеп бу гаять авыр кризистан чыгарга? Хөкүмәт үзе дә бит әле «вакытлы» гына! Шуңа күрә озакламыйча бөтен ил күләмендә Учредительное собраниегә сайлаулар башлана. Сайлауларга барлык партияләр дә үз исемлекләре белән катнаша. Россиянең язмышын әнә шул собрание хәл итәргә тиеш иде. Һәм шул җөмләдән күпсанлы милләтләр язмышын да!..

Ләкин ул да булмый, большевиклар партиясе, Россиянең гаять авыр хәленнән файдаланып, артык кан түкмичә генә, властьны үз кулына ала. Яңа власть беренче көннән үк халыкны үз ягына аударырлык бик мөһим «Солых» һәм «Җир» турындагы декретлары белән беррәттән, тиз арада «Милләтләр азатлыгы турындагы» декретын да игълан итә. Бу декретның төп мәгънәсе, Галимҗан Ибраһимов язганча, «Һәммә милләтләрнең үз язмышларын үзләренә тапшыру, Русиядән аерылып чыгуга кадәрле милли мохтарият бирү»дән гыйбарәт иде.

Менә шуннан соң инде «Татар мәсьәләсен» конкрет рәвештә хәл итү көн тәртибенә куела. Ничек итеп, нинди юллар белән? Баштарак әле моны чишүдә Октябрь революциясен кабул итүчеләр белән бергә кабул итмәүчеләр дә актив эшлиләр. Эш бик кызу бара, ике як та үзләренең съездларын, мәҗлесләрен, киңәшләрен үткәрәләр. Кискен бәрелешләр күп була, күп карарлар чыгарыла. Нәтиҗәдә татар язмышын хәл итүнең ике төп юлы формалаша. Болар — «милли мәдәни мохтарият» һәм «тупраклы автономия». Галимҗан Ибраһимов аларның беренчесен «унитаризм», икенчесен «федерализм» дип атый. «Унитаризм» дигәне Россиянең теләсә кайсы почмагында яшәүче татарларга бер үзәктән идарә ителә торган «милли-мәдәни мохтарият» бирүдән гыйбарәт... Моның өчен Россия күләмендә аерым мөстәкыйль татар парламенты сайлау күздә тотыла. Татар халкына кагылган бөтен эшләр белән шул парламент идарә итәргә тиеш була. Шуңа күрә аны «унитаризм» дип атаганнар да.

Ә «тупраклы автономия» дигәне татарлар тупланып яшәгән территориядә аерым милли җөмһүрият (республика) төзүдән гыйбарәт булырга тиеш. Ләкин бу ике вариант арасындагы кискен көрәш озакка бармый. Чөнки

беренче вариант большевикларга бер дә ошамый, гадәтләренчә алар «милли-мәдәни мохтарият»не бары буржуазия максатларына хезмәт итүдә, ә аның тарафдарларын милләтчелектә гаеплиләр. «Унитаризм»ны үткәрү юлында татар уңнарының корган барлык интригалары, провокацияләре юкка чыкты» дип, усал яза Галимҗан Ибраһимов та («Татар-башкорт җөмһүрияте» дигән җыентыкның кереш сүзендә).

Шулай итеп, «милли-мәдәни мохтарият» бетерелә, көн тәртибендә бары «тупраклы автономия» генә кала. Татар халкының киләчәге өчен мәсьәләнең болай хәл ителүе дөрес идеме? — моны киләчәгебез күрсәтергә тиеш иде. Һәм ул безгә күрсәтте дә — ләкин бу хакта сүз соңрак булыр.

Инде «тупраклы автономия»не гамәлгә ашыру эше башлана. Моның беренче проекты «Идел-Урал штаты» исеме белән Уфада үткәрелгән «Милләт мәҗлесендә» туа. Һәм аны кадетлар белән меньшевиклар гына түгел, сул эсерлар, «уралчылар», «социалистлар» да мәгъкуль күрәләр. «Тупракчылар шул Идел-Урал штаты белән киттеләр, Казанда шуны эшләргә тотындылар» диелә Галимҗанның әлеге кереш сүзендә. Штатның территориясе дә бик зур булмакчы; татар һәм башкортлар яшәгән барлык җирләр белән бергә аңа чуаш, марилар да керергә тиеш була. (Чуашлар исә удмуртлар белән мордваларны да кертүне сорыйлар.) Казан, Уфа, Оренбург — менә аның төп үзәкләре.

Мәскәүнең бу проектка мөнәсәбәте ничек булгандыр, әйтә алмыйм, мәгәр «Идел-Урал штаты»н төзү хыялы бик кыска гомерле булып кала. Башкортларда Зәки Вәлидинең Дутовка кушылуы, Казанда «Болак арты республикасы» дигән бер фетнәнең килеп чыгуы «штатны» тәмам бетереп ташлый.

Шуннан соң, 1918 елның язында, штат урынына «Татар-башкорт шуралар җөмһүрияте»н булдыру идеясе туа. Совет хөкүмәте бу идеяне хуплый һәм кабул итә. Озаклямый аның проекты да төзелеп, югары партия һәм дәүләт органнарында карала. Ленинның да бу эшкә якыннан торып катнашуы мәгълүм.

Проектның керешен һәм беренче ике пунктын биредә күчереп үтәсе килә:

Татар-башкорт шуралар җөмһүрияте

*Бөтен Россия эшче, солдат һәм авыл халкы шуралары вәкилләренең өченче корылтае тарафыннан, үз көче белән көн итүче халыкларның милли мохтариятләре хакында кабул ителгән әсасларга таянып, милли эш-*

*ләрне карый торган халык комиссариаты, эчке Россия мөселман эшләре комиссариатының муафәкате илә, Татар-башкорт шуралар җөмһүрияте хакында түбәндәге карарларны чыгарадыр:*

*1) Җәнүби Урал һәм Урта Идел тупрагы Россия шуралары федерациясенең Татар-башкорт шуралар җөмһүрияте итеп игъланкылынадыр.*

*2) Бу җөмһүриятнең чикләрен билгеләүдә Татар-башкорт революционный оешмалары тарафыннан эшләнгән лаихәләр (проектлар.— Ә.Е.) әсас итеп тотыла.*

Карарга Сталин, Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Манатов кул куйганнар. Датасы 1918 ел, март ае.

Өстәп тагын шуны да әйтергә кирәк: шушы ук елның апрель ахырында Мәскәүдә «Татар-башкорт җөмһүрияте»н төзүгә багышланган икенче киңәшмәдә чуаш һәм мари вәкилләре үз халыкларының булачак җөмһүрият составында калырга теләүләрен белдерәләр. (Бу бик мөһим момент, укучы моны исендә тотсын иде.) Документлар җыентыгында җөмһүриятнең чуаш белән мариларны да кертеп һәм алардан башка гына сызылган картасы да бирелгән. Ул карталарга карагач, шактый зур территориядә көчле бер автономиянең туарга тиеш булганлыгын күрәсең. Аны игълан итәчәк Учредительный съездның вакыты белән урыны да билгеләнә: ул 1918 елның 15 сентябрендә Уфада ачылырга тиеш булган.

Әмма ни үкенеч, съездның җыелуы да, җөмһүриятнең игълан ителүе дә көчәеп киткән гражданнар сугышы аркасында тукталып кала. Баш күтәргән чехлар унсигезенче елның августында Казанны алалар. Мәскәүдән махсус йөкләмә белән җибәрелгән Мулланур Вахитовны тотып алалар. Ә бит ул Татар-башкорт җөмһүриятен төзүдә иң башлап йөргән, җиң сызганып эшләгән һәм күп каршылыкларны җиңә-җиңә ике тугандаш халыкның тулы хокуклы автономиясен булдыруны гамәлдә хәл иткән кеше иде. Һич тә икеләнмичә аны туачак милли республиканың атасы дияргә мөмкин. Кызганычка каршы, аның вакытсыз үлеме бу гаять мөһим зур эшнең вөҗүдкә ашуын ярты юлда туктатып калдыра.

Мәгълүм ки, революция вакыйгаларында аерым шәхесләрнең роле аеруча көчәя — моның мисалларын тарихтан күп табарга була. Әгәр Татар-башкорт җөмһүриятен төзүдә Мулланур Вахитов нинди роль уйнаган булса, аны, ягъни уртак җөмһүриятне, җимерүдә төп рольне уйнаучы кеше — Зәки Вәлиди булды, диясем килә. Чөнки вакыйгалар шуны күрсәтә. Зәки Вәлиди 1917—1918

елларда башкорт хәрәкәтен кузгата һәм шуның башында тора. Башкорт мәнфәгатен алга сөрүчеләр барысы да аның тирәсенә туплана. Шуларга таянып, Зәки җирле халыктан шактый көчле армия дә оештыра, үзе шуңа командалык итә, башкортлар исеменнән әле акларга кушылып, әле кызыллар ягына чыгып, гражданнар сугышында катнаша. Һәм, иң мөһиме, ул, Мәскәүнең рөхсәтен көтеп тормыйча, аерым башкорт автономиясен игълан итә. (Кече Башкортстан, мәркәзе Стәрлетамак.) Менә шул автономияне Мәскәү таныса, армиясе белән кызыллар ягына чыгачагын белдерә.

Зәки Вәлиди хәрәкәтенең кыскача хронологиясе әнә шулардан гыйбарәт. Дөрес, башкорт тарихчылары аерым башкорт автономиясенең тууын моңарчы Зәки Вәлиди исеме белән бәйләмәскә тырыштылар. (Зәки бит соңыннан, советлар белән килешмичә, Төркиягә чыгып китә.) Тарихчылар беренче урынга Шәфиев, Халиков кебек кешеләрне куйдылар. Ихтимал, Башкортстанны аерым итүдә аларның да катнашы булгандыр, мәгәр, безнең белүебезчә, Зәки хан (башкортлар үзләре шулай диләр иде) — бу эштә баш рольне уйнаган шәхес.

Аның хакында берничә сүз әйтеп китмичә булмас. Әхмәт Зәки Вәлиди Башкортстанда туган типтәр (ишетүем шулай), Казанда укыган, яшәгән, тарихчы булып танылган. Революция чоры башлангач, бер карт әдипнең әйтүенчә, Вәлиди, татарлар арасындагы фирка ызгышларына катнашып тормыйча, тота да туган якларына кайтып китә һәм яңа гына күзен ача башлаган башкортларны, баена-ярлысына аерып тормыйча, милли азатлык хәрәкәтенә күтәрә. Сүз дә юк, көчле кеше. Ә көчле кеше үз-үзенә ышанучан була, башкалар өстеннән хакимлек итәргә ярата. Башкорт хәрәкәтенә якыннан торып катнашкан Шәехзадә Бабичның Вәлидигә элегрәк багышлап язган ике юллык эпиграммасы аның характерын, минемчә, бик дөрес чагылдыра:

> Яшь тарихчы карт Зәкине әрләделәр кәрлә, дип,
> Мин дә әрлим, кәрлә көйгә бик тәкәбберләнмә, дип.

Һәм шушы укымышлы «кәрлә», Татар-башкорт җөмһүриятен харап итеп киткәннән соң, Төркиядә озак яшәп, Европа күләмендә зур галим-тюрколог булып танылa да инде.

Мәскәү башкортлар таләбен тиз һәм җиңел кабул итә. Һәр халыкның аерым автономиягә хакы бар, бәс, шулай булгач, башкортлар теләгән үтәмәскә ярыймы соң?! Аннары армияләре белән кызыллар ягына чыгабыз дип то-

ралар, ә бу хәзерге авыр шартларда советлар өчен бик кирәк булачак... Кыскасы, шундый исәпләрдән чыгып булса кирәк, Мәскәү 1919 елның мартында ук шактый зур территориядә Башкортстан автономияле совет республикасы төзелүен рәсми рәвештә игълан итә. Әмма бу актның телдән әйтелмәгән икенче бер сәбәбе дә юк микән дигән шик туа күңелдә: ягъни Идел-Урал арасында татар-башкортның зур һәм көчле бер җөмһүриятен төзүгә караганда, аерым-аерым кечерәк республикалар төзү Мәскәү өчен һәр җәһәттән, ихтимал, хәерлерәк булгандыр. Һәрхәлдә, милли эшләр белән идарә итүче Сталин моңа эченнән, һичшиксез, куанган булырга тиеш. Аның төрки халыкларга «мәхәббәте» берәүгә дә сер түгел ич!

Шулай итеп, баштагы киң колачлы проектлар бер-бер артлы юкка чыга. Әмма «татар мәсьәләсе» көн тәртибеннән төшкәне юк, аны да совет власте игълан иткән «үзбилгеләнү» нигезендә хәл итәргә кирәк. (Димәк, шул ук Сталин катнашы белән.) Ниһаять, башкортлардан бер ел соңга калып, татар халкының 75 процентын читтә калдырып, 1920 елның июнендә шушы республикабыз дөньяга килә. Хәере белән килсен инде... Тик шулай да яңа тумыш республикабыз шактый өтек иде, территориясе белән ул күрше Башкортстаннан ике тапкыр кечерәк, шуның өстенә якын тирәсендәге татарлар тупланып яшәгән җирләр дә ни өчендер кермичә калган иде. Ләкин без булган кадәресенә дә бик шат идек. Татарстан социаль шуралар җөмһүрияте! Теләп, көтеп алган авономияле дәүләтебез ич бу!.. Билгеле, ул бездә горурлык хисе уята. Гүя без мөстәкыйльлеккә ирештек, гүя без тулы хокуклы халыкбыз. Моннан соң инде без, республикабызда чын хуҗа булып, үзебез теләгәнчә яшәячәкбез. Баштарак ул шулай бара да башлаган кебек иде. Халыкта дәрт зур, рух күтәренке — бигрәк тә нэпка кергәч, дәрт-рух көчәеп киткән иде. Хәрби коммунизм чорының азабын шактый татыган Фатих Әмирхан да әнә, татар зыялыларын үзебезнең шуралар җөмһүриятенә чын ихластан хезмәт итәргә өндәп, мәкаләләр язды. Һәм татар халкы үзен бөтен бер милләт итеп тойган хәлдә яши вә эшли дә башлаган иде. Мәгәр зур өметләр уяткан мондый рухи күтәренкелек озакка бармады. Тиздән нэп бетерелде, авылны көчләп колхозлаштыру башланды, сыйнфый көрәш, кемдер юри өреп көчәйткәндәй, аеруча кискенләште — билгеле инде, мондый шартларда нинди дер милли мәнфәгатьләрне кайгырту үзеннән-үзе онытылды, алар турында уйлау гына да куркыныч була башлады. Егерменче елларның ахырында иске татар зыялыларының бик

күбесен нәкъ менә милләтчелектә гаепләп юк иттеләр дә. Алар артыннан ук Татарстанга автономия алуда актив катнашкан татар совет һәм партия эшлекләләрен, солтангалиевчелектә гаепләп, җыеп алдылар. Әйтергә кирәк, «милләтчелек» ул совет чорында күп халыкларның баш өстендә асылынып торган канлы бер кылычка әйләнде. Хәзерге көндә дә без «милләтчелек»тә гаепләнүдән азат түгелбез. Шуның аркасында һәр милләтнең таза, бәйсез потенциаль көчләре тәмам бетә язып, алар урынына күбесенчә лакейлык хезмәтен үтәүче кол табигатьле кешеләр килде. Билгеле инде, болар барысы да «интернационализм» битлеге астында эшләнде. Милли хокук, милли тигезлек, ниһаять, милли гаделлекне «онытып», бары милләтара хезмәттәшлек һәм дуслык турында гына «кайгырту» китте. (Хәлбуки хезмәттәшлек белән дуслыкның бердәнбер нигезе тигезлек белән гаделлек икәнен кем генә белми?) Хәтта ки, бу юнәлештә тырыша торгач, «милләтне» «совет халкы» дигән уртак сүз белән алыштыруга кадәр барып җиттек. Кыскасы, халыкларның милли мәнфәгатьләре белән хисаплашмыйча, тиз генә «җирдә җәннәт» (коммунизм) төзибез дип, аларны еллар буена алдап та көчләп буйсындыру ахыр чиктә нинди канлы нәтиҗәләргә китереп чыгарганын менә хәзер күреп торабыз, кызганычка каршы!

Менә без дә күптән түгел республикабызның 70 еллыгын билгеләп үттек. Тантана көннәрендә иске гадәт буенча уңышлар белән мактанырга мөмкин иде. Күпме нефть биргәнбез, күпме яңа гигантлар төзегәнбез, аларда хәзер күпме татар эшли, күпме йортлар, клублар, мәктәпләр, шифаханәләр салынган — болар бар бит, барысы да күз алдыбызда. Ләкин нигәдер шулар белән мактанасы килми. Чөнки аларның нәрсә бәрабәренә килгәнен яхшы beләбез. Мәсәлән, миллиард тонна нефть биреп тә, республика казнасына сукыр бер тиен дә алмавыбыз өстенә, күпме җир-суларыбызны бозып, эштән чыгарып бетерделәр.

Әмма мәсьәләнең чын асылы хуҗалык өлкәсендә түгел — башкада. Хокуклар өлкәсендә, дияр идем мин... Татарстан үзенең 70 еллык гомерендә татар халкына нәрсә бирде — үстердеме, күтәрдеме ул аны, чын азатлык, бәйсезлек китердеме ул аңа, бөтенлеген, бердәмлеген саклый алдымы? Бүгенге хәлебездән чыгып җавап бирергә тырышсак, «әйе» дип раслап әйтү һич тә мөмкин түгел. Милләт буларак үстек, күтәрелдек, дияр идек, туган телебезне югалту куркынычы алдында торабыз. Ә бу инде бетүгә табан йөз тоту дигән сүз. Шулай ук безнең халык

чын азатлык белән бәйсезлеккә дә ирешә алмады. (Аның язмышы һәрвакыт башкалар кулында булды.) Кайчандыр бөтен бер милләт булып саналган халкыбыз әкренләп үзенең бөтенлеген дә югалтты диярлек... Нидән бу? Билгеле инде, Татарстан автономиясенең артык чикләнгән булуыннан, бер эштә дә мөстәкыйльлеккә ия була алмавыннан, республикадан читтә яшәүче татарларның ихтыяҗларын үтәүдә бернинди хакы булмаудан — кыскасы, «автономияле республика» дигән вывеска йөртеп тә, Россиянең гади бер өлкәсе булып калуыннан болар барысы да.

Җыеп кына әйткәндә, безнең бу җитмеш елыбыз гапгади, әмма гаять аянычлы бер алдану булып чыкты. Хәер, кайсы гына халык алданмады икән, хәтта бөек урыс халкы үзе дә бик нык алданды түгелме соң?! Бигрәк тә соңгы вакыйгалар моны бик ачык күрсәтте: әнә шул алданып яшәүдән чыгар өчен бит инде Россия коммунистлары үзләренә аерым партия булып оешты. Кыскасы, урыс халкы тулы бәйсезлеккә һәм мөстәкыйльлеккә ирешүне үзенә төп максат итеп куйды.

Менә без дә шундый ук хәлдә — «татар мәсьәләсе»н яңадан көн тәртибенә куярга туры килә. Ничек итеп аны кабат алданмыйча гына чишәргә соң?

## IV

Мәсьәләне чишкәндә, түбәндәгеләрне истә тотарга кирәктер дип беләм:

1) Без кайчандыр күрше дәүләтнең агрессиясе аркасында аерым бер мөстәкыйль ил булып яшәүдән мәхрүм ителгәнбез. Моңа инде дүрт гасырдан артык вакыт узып киткән. Әмма күпме генә вакыт узмасын, агрессия агрессия булып кала, ә шуның корбаны булган халык үзенең мөстәкыйльлеген кайтару хокукын беркайчан да югалтмый.

2) Без Советлар Союзында иң сибелеп, таралып яшәгән халык. Хәзерге вакытта халкыбызның 25 процент чамасы гына Татарстан эчендә яши. Димәк, калган 75 процент һәртөрле автономия хокукларыннан мәхрүм.

3) Мәкаләнең баш өлешендә язылганча, безнең язмыш күп гасырлардан бирле урыс халкы язмышы белән бик нык үрелеп килә. (Тукай әйткәнчә: «Без туган бер җепкә бергә теркәлеп».) Шулай ук без башка, аеруча төрки халыклар белән дә бик борыннан аралашып, яшәп киләбез. Совет заманында, гүя язмыш кугандай, башкалар арасына китеп яшәү бигрәк тә көчәйде.

«Татар мәсьәләсе»н чишкәндә, мин иң элек шушы соңгы моментны истә тотудан башлар идем. Ягъни без үзебезне моңарчы бергә аралашып яшәгән халыкларга каршы куймаска, бигрәк тә урыс халкы белән араны бозудан сакланырга тиешбез. Без яшәргә телибез, без милләт буларак сакланырга телибез. Һәм моңа без бары татулык шартларында гынаирешә алачакбыз. Онытмыйк, без 145 миллион урыс арасында, океан эчендәге вак утраулар шикелле, таралып яшәүче халык. Янә онытмыйк, урыс халкының күпчелегендә безгә булган карашны: әгәр эш, Алла сакласын, ачык бәрелешкә барып җитсә, безгә бик каты сугачаклар. Бик борыннан каядыр тирәндә яшеренеп яткан ачу-нәфрәтнең тайфун шикелле безне кинәт басып китүе мөмкин.

Әмма шул ук сакланып калу хакына, башкалар шикелле үк тыныч-имин яшәү хакына, ниһаять, чын тигез, дуслык-татулык хакына без үзебезнең бәйсезлегебез белән мөстәкыйльлегебезне яңадан кайтарырга тиешбез. Моның өчен, билгеле инде, Татарстанның статусын үзгәртергә кирәк булачак, ягъни аңа союздаш республика статусы һәм турыдан-туры Советлар Союзы федерациясенә керү хокукы бирелергә тиеш. Һәм, әлбәттә, союздаш статусын алган Татарстан барлык татар халкының уртак Ватаны булып танылырга тиеш. Мәсьәлә шулай чишелгән тәкъдирдә генә татар халкының бөтенлеген һәм бердәмлеген саклап булачак. Мәгълүм ки, СССР Югары Советы күптән түгел кабул иткән яңа закон буенча, үз республикасыннан читтә яшәүче халыкларга үз телләрен, үз мәдәниятен саклау, үстерү һәм файдалану хокукы бирелде. (Бу кайчандыр большевиклар кире каккан «милли-мәдәни мохтарият» түгелме соң?) Ә читтә яшәүче татарлар халкыбызның кимендә биш миллионын тәшкил итәләр. Мәгәр читтә милли автономия алган халкыбызга һәрьяклап ярдәм итү иң элек Татарстан өстенә төшәчәк. Ләкин моның өчен дә аның союздаш республика булуы зарур... (Хәзерге автономия статусы аңа андый хокукны бирмәде.) Һәр халыкның кайларда гына яшәвенә карамастан, күз текәп торган төп ватаны һәм рухи каласы була. Әйтик, урысның Россия дигән ватаны һәм Мәскәү дигән изге каласы бар. Әрмән һәм грузин, үзбәк һәм таҗик өчен дә ул шулай. Билгеле инде, татар кешесенең дә, кайда гына яшәмәсен ул, Татарстан дигән ватаны, Казан дигән рухи мәркәзе булырга тиеш.

Иллә мәгәр без хыял иткән бу максатларга ирешүе гаять читен булачак. (Хәтта булмас та, ахрысы.) Чөнки РСФСР составындагы 16 автономияле республиканың һәр-

кайсысына союздаш статусы биреп, Россиядән аерып чыгаруны мин күз алдына да китерә алмыйм. Урыс халкы һәм коммунистлар партиясе моңа юл куймаячак. Бәс, шулай булгач, Татарстанның үзенә генә яңа статус бирелүен өмет итеп буламы?

Хәлбуки сорарга нигезебез бар. Әш шунда ки, безнеке шикелле халыкның 75 процентын читтә калдырып төзелгән башка республика Советлар Союзында юк. Ә мондый хәл татар халкы өчен әкренләп югалу куркынычын тудырды. Димәк, сүз шушы борынгы халыкны саклап калу турында барырга тиеш. Статусны үзгәртү, асылда, әнә шуңа кайтып кала. Әгәр шулай икән, димәк, «татар мәсьәләсе» дәүләтнең югары органы — СССР депутатлары съездында каралырга тиеш, минемчә... (Төньякта яшәүче халыклар мәсьәләсен караган шикелле.) Бөтен бер халык язмышы мондый игътибарга һичшиксез лаек.

Тик бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк: «Милли мохтарият» турындагы декрет һәр милләткә үз язмышын хәл итүне үзенә тапшыра: димәк, статус мәсьәләсен хәл иткәндә, аны республикада яшәүче башка милләтләр теләге белән бәйләп карау декретның төп принцибын — үзбилгеләнүне ачыктан-ачык бозу булыр иде.

Дүрт йөз ел буена каны һәм тире белән Россия дәүләтенә хезмәт иткән күндәм вә чыдам халыкның милли гаделлеккә хакы бардыр, ниһаять!

* * *

Сүз ахырында баштан чыкмаган янә бер идеяне әйтәсем килә. Ул идея әлеге гамәлгә ашмыйча калган «Татар-башкорт җөмһүрияте» тарихы белән танышкач туган иде. Хәтерлисездер, төзеләчәк җөмһүриятнең проектын тикшергәндә чуаш һәм мари вәкилләре үз халыкларының шул җөмһүрият эчендә калырга теләүләрен белдергәннәр иде. (Идел-Урал штатына да алар керергә теләгәннәр.) Теләк гамәлгә ашмаса да, идея кала бит, идея бервакытта да юкка чыкмый ул... Кыскасы, әнә шул дүрт халык — татар, башкорт, чуаш, мари, янә удмуртны да өстәп — хәзерге шартларда берләшә алмаслар иде микән? Ягъни үзара килешеп, бөтен бер федерация төзергә риза булмаслар иде микән? Сизәм, бу идея күпләргә ят, тузга язмаган булып тоелырга мөмкин. Мәгәр тыныч кына уйлап карыйк әле.

Урта Идел-Урал арасы биш республиканы эченә алган үзенә аерым бер регион. Республикалар бер-берсе белән чиктәш. Халыклары бик борыннан аралашып яши-

ләр, шушы регионның төп халыкларын тәшкил итәләр. Бер-берсен бик яхшы беләләр, көнкүреш, хуҗалык итү ягыннан да якын торалар. Элек-электән үк аларның михнәтләре дә, кайгылары да уртак булган. Һәм бүгенге көндә дә уртак проблемалар, уртак вакыйгалары булырга тиеш. Әйтик, безнең шикелле үк аларның да үзләрен, телләрен, рухи байлыкларын саклыйсылары килә торгандыр. Моның өчен алар үзләренә союздаш статусын сорыйлардыр, мөгаен... Әмма ләкин милли мәсьәләдә күпчелеге Сталин «мәктәбен» үткән аппаратчы коммунистлардан торучы Югары Советлар аларга аерым-аерым союздаш статусын бирмәячәк... Ә менә биш республика бердәм рәвештә үзләренә аерым бер федерация булып оешуны таләп итсәләр, ничек булыр иде микән?.. Мондый таләп кайчандыр куелган бит, нигезе бар дигән сүз. Әгәр бу эш барып чыкса, «Идел-Урал федерациясе» (шулай дип атыйк) турыдан-туры Советлар Союзына тулы хокуклы дәүләт сыйфатында керә алыр иде.

Инде федерациянең үзенә килгәндә, аның юридик әсаслары, эчке төзелеше, идарә итү формалары турында сөйләп тормыйм, бу — дәүләт төзелеше белән шөгыльләнүче белгечләр эше. Минем төп максат турында гына әйтәсем килә: федерацияне төзүдән төп максат исә аңа кергән халыкларның мөстәкыйльлеген саклаган хәлдә, һәркайсының милләт буларак яшәешен бердәм рәвештә тәэмин итүдән гыйбарәт булырга тиеш. Моның өчен алар арасында милли гаделлек, тигезлек, татулык хөкем сөрергә тиеш. Телләрен, мәдәниятләрен федерация эчендә яшәүче милләттәшләренә таратуда бернинди чикләр, административ киртәләр булмаска тиеш. Мөмкин эшме болар?.. Минемчә, бик мөмкин, чөнки борын-борыннан ук бер үк шартларда аралашып яшәгән бу халыклар үз хәлләрен, читтән торып хөкем итүчеләргә караганда, һичшиксез, ныграк аңлыйлар... Инде үзара уртак тел дә тапсалар, изге максат өчен берләшә дә алырлар иде.

Мин вариант рәвешендә идея тәкъдим итәм. (Моннан ике ел элек тә аны бер зур җыелышта әйткән идем.) Игътибарга лаекмы ул идея, күршеләребезгә барып җитәрме, уйландырырмы ул аларны? Бәлки, бу хакта түгәрәк өстәл тирәсенә җыелып, алар белән бер сөйләшү кирәктер. Сөйләшү, аңлашу һич тә зарар итмәс иде, минемчә.

Әмма аңардан катгый нәзар, без, татар җәмәгатьчелеге, «татар мәсьәләсе»н ниһаять, хәл итүгә, ягъни Татарстанга союздаш статусын алуга юнәлдерелгән хәрәкәтне, әлбәттә, дәвам иттерергә тиешбез.

*«Идел», 1990*

# САРЬЯН

Шушы җыйнак, матур исем белән әдәбиятка керде. Үзенә килешеп торган шушы исеме белән ул безнең хәтерләрдә дә саклана. Тик ул исемен фамилия итеп, фамилиясен исем иткән иде: Хәсән Сарьян... Туган елы 1930, үлүе 1978 елның сентябрендә. Бары 48 ел гына ул дөньяда яшәп калды.

Җитмеш сигезенче елның көзендә мин Ялтадагы иҗат йортында идем. Минем китәр вакыт җиткәндә генә, Казаннан мәрхүм Галимҗан Латыйп килде һәм, иң беренче хәбәр итеп, ул миңа Сарьянның кинәт үлеп китүен әйтте. Бу шулхәтле көтелмәгән, акылга сыймас бер мәгънәсез хәбәр булды ки, гүя башка төшкән кирпеч шикелле, ул мине тәмам һушсыз итә язды. Кайчан, ничек, нидән? Галимҗанның сөйләвенә караганда, Сарьян кичтән үз бүлмәсендә ятып йоклаган, ә иртән янына керсәләр, йөзтүбән капланган, тавышы-тыны юк, селкетсәләр дә уянмаган... Үлгән кеше!.. Ходавәндә, шулай ансат кына да үлеп була микәнни?! Ул бит, Сарьянны әйтәм, типсә, тимер өзәрлек көчле, нык, таза ир иде. Бары 48 яшендә!

Үз гомеремдә миңа күп кешеләрнең дөньядан китүләрен күрергә туры килде, арада бик үкенечлеләре дә булды, әмма ки Сарьян үлеме шикелле хәйран иткән үкенечлесе минем өчен, юк, булмады. Һәм бик озак мин бу югалту белән һич кенә дә килешә алмыйча, дөресен генә әйткәндә, көтелмәгән сәер үлемнең чын сәбәбен дә аңламыйча шактый аптырап йөрдем...

...Еллар узды... Сарьянның вафатыннан да инде ун елдан артты. Дөнья мәшәкатьләренә күмелеп яшәсәк тә, мәрхүм вакыт-вакыт искә төшә иде, уйландыра иде, юксындыра иде, әмма тора-бара — сәер бер хәл! — аның вакытсыз үлеме мине инде гаҗәпләндерми дә башлады. Киресенчә, кыска гомер аның туган чагында ук тәкъдиренә язылган булса кирәк дигән уй ничектер үзеннән-үзе күңелгә кереп урнашты. Чынлап та, тәкъдир дигән нәрсәгә ышану бар. «Кутәрелми күңелләрем, кыскадыр гомерләрем» диелә бит халык җырында да. Хәер, бу очракта эш ышану яки ышанмауда түгел. Хикмәт шунда ки, мин Сарьянны үлгәннән соң гүя ныграк аңлый башладым. Гүя аның тумыштан ук билгеләнгән язмышы миңа тирәнрәк ачылгандай булды. Ә язмыш дигәнең, яшерен кодрәткә ия бер көч шикелле, кеше белән сиздермичә генә идарә итә, диләр. Шулайрак аңларга өйрәнгәнбез без аны... Менә мин дә, шуны истә тотып, тере Сарьянны еш кына күз алдыма китерәм һәм аның шул чактагы

рухи халәтен аңларга тырышам. Әйтергә кирәк, миңа Сарьян мәрхүм белән күп аралашырга туры килде. Шуңа күрә һич икеләнмичә әйтә алам: талантлы, дәртле, энергияле, кулыннан һәртөрле эш килүенә карамастан, Сарьянның җаны бервакытта да тыныч була алмады, ниндидер бер канәгатьсезлек — әллә үзеннән, әллә тормыштан — аның бәгырен гел кимерде дә торды. Хәтта яшьлеге, тазалыгы китергән, мәхәббәттә яки эшендә уңышлар кичергән шат, ваемсыз чакларында да ул әлеге каядыр тирәндә яткан канәгатьсезлек тойгысыннан котыла алмады. Аның бу хәлен, үзе телдән әйтеп бетермәсә дә, мин ничектер сизмичә калмый идем. Бигрәк тә моңаеп җырлаган чакларында аңарда, җан тынычсызлыгы өстенә, тагын ниндидер яшерен хәсрәтле сагышы да бар кебек тоела иде. Ә ул, мәрхүм, озын көйләрне үзенчә бер тою белән, тавышын да артык көчәйтмичә, бик үтемле итеп җырлый торган иде... Менә шуларның барысын да искә төшергәч, аның кыска гомерле булуы башта ук тәкъдиренә язылмады микән дигән уй ирексездән күңелгә килә дә инде. Чөнки тирән торгынлыкка төшкән кешеләрнең озак яши алмаулары тормышта булгалый торган хәл. Моны инкярь итүе читен.

Әмма ләкин торгынлыкның бик җитди сәбәпләре булырга тиештер бит инде. Мәсәлән, Сарьяндагы җан тынычсызлыгы һәм канәгатьсезлек кайдан ул, нәрсә аркасында, ничек туган?.. Дөресен генә әйткәндә бит, тынычсызлык белән канәгатьсезлек безнең күбебездә бар иде, чөнки без кичергән заманның ялганнарын, кимчелек һәм гаделсезлекләрен күзе ачык кешегә күрмичә тору мөмкин түгел иде. Тик менә күрә торып та шулар белән килешә алмау, борчылу, ризасызлык белдерү кадәресе бер түгел — бусы инде төрле кешедә төрлечә.

Билгеле ки, Сарьянның да бөтен тормышы һәм рухи халәте әнә шул без күреп уздырган ясалма-ялган заман белән турыдан-туры бәйләнгән иде. Һәм икеләнмичә әйтәсем килә, аның күңел сизгерлеге һәм эчтән уйланулары күпләрнекеннән тирәнрәк тә, газаплырак та булып чыкты. Бер караганда бу гаҗәбрәк тә тоелырга мөмкин, чөнки Сарьянның тормыш юлы артык авыр сынаулар аша узмаган да шикелле. Дөрес, аның бала чагы фаҗигале утызынчы елларга туры килә (бу елларның каһәре кайбер якыннарына да кагылган бугай — сүзләреннән шулайрак хәтеремдә калган), ә үсмер чагында инде аңа рәхимсез сугыш елларының бөтен коточкыч авырлыгын татырга туры килә. Сугыштан соң да әле ул, нужа тырнагыннан тиз генә ычкына алмыйча,

авылдан авылга, сукыр музыкантларны җитәкләп, тамак хакына концертлар куеп йөрергә мәҗбүр була. (Кызганычка каршы, үзеннән-үзе кәгазьгә төшүне сорап торган аның шушы бик гыйбрәтле материалы, минем каткат әйтүемә карамастан, ни сәбәптер язылмыйча, әрәм булып калды.)

...Әнә шундый шатлыгы аз, михнәте күп ач-ялангач еллар аша уза Сарьянның һәм аныңише авыл малайларының нәкъ җитлегер, ныгыр чаклары. Бу еллар аша узган Сарьян буыны бик тирән җан ярасы алып кала, минемчә... Ахыр чиктә нәкъ шул еллар күпләрнең тормышка мөнәсәбәтен һәм яшәү кагыйдәләрен билгеләдә дә булса кирәк... Монда икесенең берсе: яки һичнигә карамастан беткәнче заманга яраклашу; яки кешелегеңне саклап, намусың кушканча яшәргә тырышып карау...

Һәм Сарьян да шуның беренчесен сайларга тиеш кебек иде. Чөнки нужа мәктәбен узганнан соң, ниһаять, аңа да киң юллар ачыла. Башта Бөре педагогия мәктәбен, аннары Уфа педагогия институтын тәмамлый. Уфа аңа якын, туган җиренең башкаласы... Ул шунда төпләнә, өйләнә, хезмәт юлын башлый — редакцияләрдә эшли, башкорт университетында лекцияләр укый... Шулай әйбәт башлана, әйбәт бара, инде хәзер аңа үргә табан кыю, туры атларга гына кирәк. Моның өчен акылы да, сәләте дә, тырышлыгы да җитәрлек. Ихтимал, ерак китә дә алган булыр иде ул...

Әмма, туры гына барасы урында, Сарьян тота да кинәт кискен борылыш ясый: ул, Уфаны ташлап, Казанга күчеп килә. Башта (1960 елда) ялгызы гына, ә күпмедер вакыттан соң гаиләсен дә китерә... Нинди сәбәпләр аркасында соң күпләр өчен көтелмәгән мондый кискен борылыш?..

Мәрхүм Казанга килү белән мине эзләп тапкан иде. Беренче очрашудан диярлек без уртак тел таптык һәм ничектер җиңел генә якынаеп та киттек. Күп сөйләшүләрдән чыгып, мин аның Казанга килүен, беренче нәүбәттә, болай аңлатыр идем: ул — язучы, ул язарга тиеш, әмма аның татар телендә язасы килә, иллә мәгәр Уфа шартларында татарча китап бастыру мөмкин түгел. Казанда гына мөмкин... Кыскасы, ана сөте белән кергән туган теле аны Казанга тартып китерә. Бу бик табигый хәл, минемчә: Башкортстан туфрагында туып та, татар әдәбиятына хезмәт итәргә теләп, үз халкының мәдәни үзәгенә килүчеләр аз булдымыни безнең дәвердә?! Бу уңай белән Дәрдмәнд сүзләрен искә төшерү дә урынлы булыр кебек:

Ни газизрәк — бу Ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән
Ул изге сөткә ни җитәр!
Сөт калыр, Ватан китәр!
Сөт калыр, Ватан китәр!

Әйе, бу сүзләрдә тирән мәгънә ята: Ватан китсә дә, «изге сөт» кала. Аерым кешеләр язмышында гына түгел, бөтен бер халыклар язмышында да без моны ачык күрдек.

Тик шулай да Сарьян мәсьәләсенә килгәндә, уйландыра торган бер момент бар. Иң элек әле Башкортстан белән Татарстан арасында Ватан булу ягыннан әллә ни зур аерма да юк. Мәсәлән, мин үзем ул аерманы сизмим диярлек — берсендә туганмын, икенчесендә яшим — һәр икесе дә минем өчен бик кадерле. Билгеле, Сарьян өчен дә ул шулай булырга тиеш иде. Шул ук вакытта башкорт теле дә аңа бер дә ят түгел. Ул инде Уфада башкортча яза да һәм басыла да. Шуңа күрә Казанга китүенең сәбәбен бары тел мәсьәләсенә генә кайтарып калдыру дөрес булыр микән?.. Бүтән, тирәнрәк сәбәп тә юк микән?..

Безнең бу хакта да сөйләшүебез күп булды. Чыгышы, милләте белән кем ул?.. Сарьян үзе, бабасыннан ишеткән сүзләрне исенә төшереп, болайрак аңлаткан иде: без җирбиләүче буларак башкорт, мәгәр милләтебез белән татар!.. Һәм бабасының шул сүзләренә ул, мәрхүм, бик нык ышана иде.

Үзеннән-үзе сорау туарга мөмкин: башкорт булып саналгач, телен дә белгәч, аңа Уфадан китүенең нигә кирәге булды икән? Алдагы язмышы өчен китми калу, бәлки, отышлырак та булган булыр иде... Күреп тора бит, күпме татар дуслар иҗади язмышларын башкорт әдәбияты белән бәйләделәр — кайсы шагыйрь, кайсы әдип — башкортка әйләнеп яки әйләнмичә генә. Ә аңа әйләнеп торуның кирәге дә юк, күкрәк киереп чын башкорт булып йөрер иде. Бөтен хокуклардан файдаланып, ихтимал, тыныч-рәхәт кенә яшәр дә иде. Башкортлык аның табигатенә күпмедер дәрәҗәдә хас та иде — мин моны бик ышанып әйтә алам.

Иллә мәгәр Сарьян кайсы әдәбиятны сайлау мәсьәләсен андый фани дөнья исәпләреннән өстен торып, вөҗданы кушканча хәл итәргә тырышкан. Ләкин бу тел сайлау белән генә түгел, үзеңне кайсы милләт кешесе итеп тану белән дә бәйләнгән булырга тиеш иде. (Һич тә җиңел булмагандыр бу аның өчен!) Татар белән баш-

корт икесе ике халык, әмма күп заманнардан бирле бер үк җирләрдә яши-яши алар үзара якынаеп, аралашып киткән халык... Анда татарлашкан (тел җәһәтеннән) башкортлар бар; башкортлашкан яки башкорт булып саналган татарлар бар. Әмма үзенең йөзен, телен, тарихи бөтенлеген саклаган саф башкорт белән саф татар ике халыкның да күпчелеген тәшкил итә. Инде менә шушы бер-берсенә бик якын тугандаш халыкның үзара мөнәсәбәтләре ничек булырга тиеш иде? Бу бик нечкә, бик четерекле мәсьәлә. Чөнки сан ягыннан да, милләт булып формалашу җәһәтеннән дә аерма шактый зур. Хәлбуки республика исемен йөрткән башкорт халкының аң-белемен, мәдәниятен үстерүне, бигрәк тә кадрларын җитештерүне тизләтергә кирәк. Бу законлы таләп. Ләкин ничек итеп? Республика җитәкчеләре моның ансат юлын табалар — ягъни татар халкының рухи ихтыяҗларын, культура таләпләрен чикләү, кысу исәбенә «башкортны үстерергә» керешәләр. Баштарак бу тенденция үзен артык сиздерми кебек, ләкин инде ул елдан-ел отыры көчәя бара. Моның нинди ямьсез нәтиҗәләргә китереп чыгаруын әйтеп тору кирәк тә түгелдер, бик мәгълүм алар, әмма бер нәрсәне шулай да әйтмичә булмый: бер халыкны чикләү, кысу хисабына икенче халыкны үстерергә, көчәйтергә тырышу бу бездә күптән яшәп килгән командалык итү системасының бик зарарлы бер күренеше... Зарарлы, чөнки ул дуслыкны да какшата, гаделсезлек тә тудыра, һәртөрле гаепләүләргә, дөреслекне бозуларга да юл ача. Һәм моның мисаллары да соңгы вакытта, кызганычка каршы, бик күбәеп китте.

Сарьян менә шуларны күрә, күрү генә түгел, үз җилкәсендә татый башлый. Билгеле инде, аның хөр табигате моның ише гаделсезлек белән килешә алмый. Ул үзен ике халыкның баласы дип санаса да, алар арасында ясалма рәвештә тудырылган ялган хәлдән чыгу юлын эзләргә мәҗбүр була. Казанга күчеп китүен тизләткән төп сәбәпләрнең икенчесе, минемчә, әнә шунда иде.

Әйтергә кирәк, Казан Сарьянны кочагын җәеп каршы алмады. Бездә дә шул ук система бит — әдәбиятың, мәдәниятең барысы да аның кулында. Дөрес, бездә татар-башкорт проблемасы юк, аның каравы кешегә шикләнеп, ышанмыйча карау бар. Сарьянга карата да башта шундыйрак караш сизелде: ник килгән, нәрсә мәҗбүр иткән, «тегендә» нәрсә эшләгән?.. Билгеле, Сарьян мондый карашны, телдән әйтелмәсә дә, тоймыйча калмады. Нилләр кичергәнен эченә йотты, кире чигенү мөмкин тү-

гел иде, ни күрсә дә, аңа шушы каты туфракта калырга һәм тамырланырга кирәк иде.

Унсигез ел яшәп калды ул бу туфракта. Зур өметләр баглап килгән хыялларына ирешә алдымы соң ул? Мин моны өзеп әйтмәс идем. Мәгәр бер хакыйкатьне өзеп әйтергә була: Казан Сарьянны, ниһаять, таныды, белде аның нинди талантка ия икәнен... Тик, кызганыч, шактый соңлап. Ничектер шулай килеп чыкты ки, Сарьян башта үзен җитди тел белгече, аннары гына чын художник — әдип итеп танытты. Уфадан килеп, ул безне туган телебезнең нечкәлекләрен аңларга, сүзләрне белеп, дөрес кулланырга өйрәтә башлады. Газеталарыбызның, радио тапшыруларының шактый чүпләнгән, бозылган, агачланган телен анализлап язган мәкалә һәм чыгышлары бик вакытлы да, бик кирәкле дә бер эш булып чыкты. Әнә шулай тел бабында авторитет казанып, ул ахырда Татарстан радиосының «Тел күрке — сүз» дигән даими тапшыруларын алып бара башлады. Телебезнең сафлыгын, байлыгын саклауда күрсәткән аның бу тырышлыгын без, әлбәттә, онытмаска тиешбез.

Мәгәр, әйткәнемчә, Сарьянның әдәби иҗаты болай тиз генә җәелеп, үсеп китә алмады. Сәбәпләрен белү җиңел түгел, иҗат итү бик нечкә, бик катлаулы эш. Һәрбер язучыда ул гаять үзенчәлекле... Шулай да башта язганымны кабатлап әйтәсем килә: Сарьян мәрхүм гомеренең ахырына кадәр җанын гел борчып торган нindидер эчке бер канәгатьсезлектән котыла алмады. Ул үзе бу хакта күп сөйләшергә яратмый иде, әмма канәгатьсезлекнең тирән яткан бер сәбәбе, һичшиксез, әдәби иҗаты белән бәйләнгән иде — мин моны бик ышанып әйтә алам. Ул бит иҗат мәсьәләсендә гаять таләпчән иде — үзенә дә һәм башкаларга карата да... Инде үзенә килгәндә, мин аның кебек бүтән рәхимсез таләпчәнне белмим диярлек. Яза торган әсәрен һәр җәһәттән камил итү өчен ул күпме көч түкми, күпме газапланмый, әмма никадәр генә тырышмасын, газапланмасын, тулы камиллеккә ирешү юк, мөмкин дә түгел, бу — күптән билгеле хакыйкать. Шуңа күрә һәр язучы, хәтта иң таләпчәне дә, ирешелгән кадәресе белән килешергә мәҗбүр. Ә Сарьянда килешү юк, сизелми — гүя эшеннән канәгатьсезлек аны гел кимерә дә тора. Хәер, чын язучы өчен бу табигый хәл. Ләкин Сарьяндагы канәгатьсезлекне бары иҗат газапларына гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Тагын бер искә төшерик: мәрхүмнең Казандагы гомере тулысынча торгынлык заманына туры килде. Тыштан бу шактый тыныч-имин вакыт иде, ә чынлыкта исә мактану,

шапырыну, тормышны буяп күрсәтү, чын хәлне халыктан яшерү, башлыча табигатьне талап яшәү чорына әйләнгән иде. Дан-исем һәм байлык артыннан куу бик көчәйде бу чорда... Һәм моңа ирешүчеләр дә булды, тик моның өчен тизрәк килешеп, тизрәк яраклаша белү генә кирәк иде.

Хакимлек итүче чор идеологиясенә буйсынган безнең әдәбият та башлыча әнә шул ялган-ясалма таләпләргә көйләнгән иде. Әмма ләкин чын хәлне күрә белгән, уйлый белгән, үзенең иҗатында тормышны ничек тә дөрес чагылдырырга омтылган язучылар да бар иде. Боларның күбесе алтмышынчы елларның кыска гына «җылыту» вакытында әдәбиятка килгән яшьләр иде — һәм Сарьян да нәкъ шулар җөмләсеннән. Чын талант, хис кешесе, сәнгатьне тирән аңлаучы, әсәр язуның да бөтен нечкәлекләрен белә, әмма үз ишләреннән характеры белән нык аерыла иде ул. Нәкъ менә язу эшендә башкалардагы активлык җитми иде аңарга. Ул күп уйлана, тик нигәдер аз эшли... Күңелендә йөрткән темалары да күп (материалга бай иде ул), язасы килүе дә көчле, тик үзен утырып язарга гүя мәҗбүр генә итә алмый. Әйе, иҗат аның өчен үтә җитди эш, бөтен җанын, кодрәтен салырга тиеш ул аңа. Моның өчен язучыда, таланттан башка, Чехов әйткән эчке хөрлек хисе дә булырга тиеш. Ә ул юк яки бик зәгыйфь, нәкъ үзең теләгәнчә генә язып булмый, ирексездән өстеңдә торган ниндидер ят көчләргә буйсынырга кирәк. Бу инде Сарьян табигатенә сыя торган нәрсә түгел, яраклашып, үзен көчлекөчли язуны ул булдыра алмый... Аз язуын, авыр язуын башкача ничек аңлатырга? Күрәсең, «теләк» белән «таләп» каршылыгын ул аеруча тирән кичерә торган булган...

Әмма шуңа да карамастан иҗат процессы аның эчендә өзлексез дәвам иткән. Ул яза, ул язачак! Торгынлык кичергән, утыра алмаган чагында да ул туачак әсәре турында уйланудан бер генә минутта да туктап тормаган. Һәм әсәр, ниһаять, туган!

Шуны да әйтергә кирәк, мәрхүмнең янә бер бик әйбәт һөнәре бар иде. Атасыннан калган һөнәр — «Әткәм һөнәре» дип китап та язган иде... Бик шәп балта остасы иде ул. Бөтен кирәкле кораллары да бар иде. (Атасыннан калган пыяла кискеч алмазны чиста чүпрәккә төреп кенә йөртә иде.) Гадәттә, бик теләп тотына иде ул бу балта эшенә. Онытылып, ләззәтләнеп эшли торган иде. Эшләп бетергәч, ясап куйган әйберенә сокланып, еш кына: «Менә сылап куйган кебек булды!» — дип әйтә тор-

ган иде... Мәгәр бу һөнәрен ул кәсепкә әйләндермәде. Кәефе килсә эшләде, килмәсә — юк.

...Аның мавыгып китеп, балта эшенә күп вакыт сарыф итүе бер яктан иҗатына зарар да итәдер кебек иде... Ә бәлки, киресенчә, файда да иткәндер. Җаны тынычланып, үзенең көченә ышанычы артып, язарга утырган чакларында аңа һәртөрле шик-шөбһәләрне селтәп ташлатырлык чын илһам да китергәндер. Гомеренең ахырына таба язган ике үлемсез әсәре — «Бер ананың биш улы» белән «Җәза» повестьларына карап әйтәм мин моны... Тормышның чын йөзен бизәмичә һәм кешеләрнең катлаулы язмышын шомартмыйча кыю сурәтләгән, мәгәр хиссияткә бирелмичә, тыелыбрак тыгыз язылган, шуңадыр, ахры, беркадәр Хемингуэйны да хәтерләткән бу әсәрләре Сарьянның нинди зур талантка ия булуын ачык күрсәтте. Әйе, бу җитди, таләпчән әдиптән күпне көтәргә була иде әле. Әмма, ни кызганыч, бик вакытсыз өзелде аның ачылып кына килгән иҗаты. Үз үлеме белән дөньядан китсә дә, ни сәбәптер ул миңа авыр, каршылыклы заманның бер корбаны булып тоелган иде. (Такташ үлгәннән соң да күңелдә шундый тойгы калган иде.) Сарьян мәрхүмнең озак онытылмавы, һаман уйландыруы, ихтимал, шуңардан килә дә торгандыр... Вакытсыз киткәннәр алдында без һәрвакытта бурычлы!

*«Казан утлары», 1990, 3 сан*

## КЕМ ҖАВАПЛЫ?

Без көтелмәгән бер чорга килеп кердек. Сиксән бишенче елның язына чаклы дәвам итеп килгән «Мактаулы заман» беркайчан да үзгәрмәс төсле иде. Хәлбуки үзгәрүен, үзгәрергә тиешлеген эчебездән генә көтсәк тә, өмет-ышаныч бик аз иде. Чөнки мактаулы заманыбызның тәртип-низамнары, тимер бетоннан коелгандай, һич тә какшамас кебек иде. Аларның шулай нык, мәңгелек булуына безне 70 ел буена өзлексез ышандырып килделәр... Инде менә какшамастай итеп төзелгән социализм атлы якты бинабыз көтмәгәндә селкенеп куйды, төрле җирендә тирән ярыклар күренде, хәтта ишелә дә башлады, һәм, ниһаять, аның эчтән тәмам черегән, тик тыштан гына сылап-буяп куелган бер корылма булуы ачыкланды.

Баштарак моңа бик үк ышанасы да килмәгән иде, алай ук куркыныч-хәтәр түгелдер әле дигән шик тә бар иде. Әмма аяусыз чынбарлык һәртөрле шикләрне себе-

реп ташлады: әйе, без моңарчы яшәп килгән дөньябызның таудай гөрселдәп ишелүен, аның җимерек хәрабәләре астыннан яңа дөньяның көч-хәл белән чыгып килүен күреп торабыз. Искесе нигезенә чаклы ишелеп бетәрме, яңасы ахыр чиктә чынлап күтәрелә алырмы — менә нәрсә хәзер безнең акылыбызны биләп, җаныбызны өзлексез борчып тора. Нинди булачак безнең киләчәк заманыбыз, азатлык белән иркенлекне күрербезме, ниһаять?! Уйлану күп, сүз-бәхәс күп, мәгәр көткән ачыклык юк та, тулы ышаныч аз хәзергә!

Шушы вакыйгалар уңае белән, мин яшьләрнең без картларга төбәлгән шикле һәм үпкәле карашларын күреп торам. Гүя алар бездән: «Ничек итеп сез илнең шушы хәлгә бер килеп төшәчәген алдан күрмәдегез, әйләнәгездәге гаделсезлекне, изү-талауны, алдау-көчләүне вакытында фаш итмәдегез, нәрсә карадыгыз сез, язучылар?» — дип, туп-туры бәреп сорыйлар кебек... Әмма моңа дөрес җавап бирүе бер дә җиңел түгел.

Иң элек бер ачыклык кертәсе килә: бөтен гомеребез совет чорына туры килсә дә, күп хәлләрне үзебез күреп кичерсәк тә, без бик күп нәрсәләрдән шулай да хәбәрсез яшәдек. Партия һәм совет органнары үз эшләренең бик күбесен халыктан яшереп килгән. Бары хәбәрдарлык дигән яңа бер сәхифә ачылгач кына, әллә никадәр һич көтелмәгән чын хәлләрне без дә беренче мәртәбә шаккатып белдек.

Аннары инде, картларның үзләренә килгәндә, алар бит барысы да бер калыптан төшкән кешеләр түгел иде. Бик төрле иде бит алар — үзләре дә, язмышлары да, иманнары да... Һәм заманга да аларның мөнәсәбәтләре бик төрле булды. Җаны-тәне белән ышанучылар бар иде (болар күпчелек), ышанып бетмәүчеләр дә аз түгел иде, хәтта заманны кабул итә алмаучылар да юк түгел иде. Мин үзем, мәсәлән, яңа заманның ясалма-ялган булуын ничектер тирем белән бик иртә тоя башладым, әмма аңа ышанырга, аңа иярергә тырышып яшәдем... Дөресен генә әйткәндә, бу өч төрле «картлар» арасында замана мәсьәләсендә бернинди бәхәс, фикер көрәше юк иде һәм булуы мөмкин дә түгел иде, чөнки безнең өстән хакимлек итүче идеология, аны бик уяу саклаучы тоталитар власть һичбер төрле бәхәскә, фикер хөрлегенә юл куймый иде. Шул сәбәпле эчеңнән ни генә уйласаң да, син хаким идеологиягә буйсынырга һәм иҗатың белән тормышыңны да шуңа көйләргә мәҗбүр идең. Кыскасы, Сталин, Хрущев, Брежнев чорларын кичергән бүгенге картларның ул чактагы гамәлен ике төрле нәрсә билгеләде: ал-

дану һәм курку. Алдану — ышану өчен, курку — башыңны саклау өчен кирәк иде. Моңардан түбәндәге нәтиҗәне дә ясарга мөмкин: әгәр дә бүгенге яшьләргә без кичергән заманнарда яшәргә туры килсә, шик юк ки, аларның язмышлары нәкъ безнеке төсле булыр иде.

* * *

Әнә шул алдану белән куркуның бик ачык мисаллары итеп, мин безнең әдәбият дөньясыннан үзем кичергән берничә вакыйганы язып калдыруны, ниһаять, кирәк таптым. Боларны «Соңгы китап»ка кертергә дә исәбем бар иде, ләкин вакыты җитмәгән әле, дип кичектергән булдым. Хәзер исә җиту генә түгел, шактый соңга да калдым шикелле. Хәер, гыйбрәтле фактлар беркайчан да әһәмиятен югалтмаска тиештер дип беләм.

Сүз биредә сугыштан соңгы елларда безнең язучылар союзының өч рәисе белән минем арада булып узган һәм күңелемдә гомерлеккә уелып калган бик үкенечле дә аянычлы өч вакыйга турында барачак. Шуның беренчесе Афзал абзый Шамов вакытында булды.

* * *

1956 елның әллә җәй ахыры, әллә көз башы иде, минем шәһәр читендәге кечкенә генә агач өем алдына Язучылар союзы машинасы килеп туктады. Ул чакта Союзның бердәнбер иске җиңел машинасын Майшәкәр исемле ифрат уңган җитез хатын йөртә иде. Өйгә килеп керү белән ул, кабалана биреп: «Әмирхан абый, Сезне алырга килдем»,— диде. Мин аптырабрак: «Ни өчен?» — дип сорагач, Майшәкәр: «Белмим, Афзал абзый тизрәк алып килергә кушты»,— ди.

Шактый ук сәер булып тоелды бу миңа... Союз машинасының беренче мәртәбә мине алырга килүе... Нигә ул хәтле кирәк булдым икән мин персидәтель абзыйга?

Кузгалып киткәч тә, Майшәкәр әйтте: «Инде хәзер Нәкый абзыйны кереп алабыз». «Ул да кирәкмени?» «Әйе, аны да китереп җиткерергә кушты Афзал абзый!»

...Ала-ай, кызык бит әле бу... Союз Нәкый абзыйны сирәк кузгата торган иде, нинди гадәттән тыш вакыйга килеп чыкты икән анда? «Тагын кемнәрне алып килергә кушты Афзал абзыең?» — дип сорадым мин, сак кына... «Барыгызны да чакыртты... Сезнең телефон юк бит, менә миңа барырга туры килде»,— диде Майшәкәр.

Нәкый абзыйлар ул чакта Кольцодан чак кына ары-

рак, Тукай һәйкәле артындагы яңа йортта торалар иде. Майшәкәр, җитез генә төшеп, аларга кереп китте. Мин машинада калдым. Шактый гына көтәргә туры килде — Нәкый абзый, кем генә чакырса да, кабалана торганнардан түгел... Ниһаять, чыктылар, исәнләштек, һәм кузгалып киттек. Бер-ике минуттан Матбугат йортына барып та җиттек. Баскычтан менешли, Нәкый абзый миннән әкрен генә сорап куйды: «Бу ни тамаша, нигә кирәк булдык икән без Әбзәлетдин иптәшкә?» «Менә хозурына кергәч, белербез инде»,— дидем мин аңа.

Әле көннең беренче яртысы гына булганга күрә, союз тирәсендә «каләм әһелләре» күренмиләр иде. Афзал абзый бүлмәсендә ялгызы гына иде, ул безне аягүрә каршы алды, утырырга кушты, үзе һаман баскан килеш калды. Кыска гына хәл-әхвәлне сорашканнан соң, бернинди кереш сүзсез туп-туры бездән сорады:

— Пастернак турында ишеткәнсездер инде?

Безнең өчен бу шактый көтелмәгән сорау булды. (Без бит үзебездә берәр хәл булмады микән, дип уйлабрак килгән идек. Баксаң, эш әнә нәрсәдә икән.) Дөрес, соңгы вакытларда Борис Пастернак исеме тирәсендә зур шаушу купканын без күпмедер дәрәҗәдә ишетеп тә, укып та белә идек. Тора-бара бу шау-шу бер кампания төсен дә алып өлгерде. Аңа «Доктор Живаго» дигән әсәре өчен Нобель премиясе бирелгәч, шагыйрьне каты гаепләү һәм яман тиргәү аеруча көчәйде... Әйе, болары безгә мәгълүм диярлек. Мәгәр безне менә бүген машинада җилтерәтеп бирегә китерү нигә кирәк булды соң? Нинди гадәттән тыш вакыйга бар тагын?

Афзал абзый моны да безгә бик ачык әйтеп бирде:

— Пастернакны Язучылар союзыннан чыгарганнар!

Шунда ук «ни өчен» дигән сорау туса да, без аны биреп тормадык — туктаусыз кыйналып килгән шагыйрьнең ахыр чиктә союздан чыгарылуы бер дә искитәрлек вакыйга түгел иде. Безнең заманда андый хәлләр һаман булгалап тора... Күптәнме әле Анна Ахматова белән Зощенконы да, дөнья шаулатып, әдәбияттан кудылар... Шулай да Афзал абзый, без бирмәгән сорауны үзе сизгәндәй, эшнең ничек булганын бераз аңлатып та бирде:

— Мәскәүдә язучыларның зур җыелышы булып узган. Шунда Пастернакның совет язучысына һич тә килешмәгән гамәлен бик каты тәнкыйть иткәннәр... Алай гына да түгел, аны Союздан чыгарырга дип, бертавыштан карар да кабул иткәннәр... Берәү дә яклап чыкмаган, беләсегез килсә!

Нәкый абзый, гадәтенчә, сүзне уенга борырга теләде:

— Һа, эшне тиз тотканнар икән, безнең ризалыкны көтеп тормаганнар. Бик әйбәт... Алайса, Әбзәлетдин, безгә бүрекләрне кияргә дә ярый торгандыр инде.— Һәм ул китәргә җыенгандай кузгалып куйды.

— Карале, Нәкый, бу бит бер дә уен эш түгел,— диде Афзал абзый, гаҗәпләнү һәм әзрәк ачу белән дә.— Сүз, беләсегез килсә, гаять җитди политик мәсьәлә турында бара... Совет язучысы исемен йөрткән Пастернак, асылда, безнең революциянең изге максатларын бозып, яманлап әсәр яза, шуны чит илдә бастыра, шуның өчен, җитмәсә, Нобель премиясен дә ала.

— Алмаган шикелле әле,— дидем мин икеләнебрәк.

— Алыр, баш тартмас,— диде Афзал абзый, сүзен кызу гына дәвам иттереп.— Буржуазия белә бүләкне кемгә бирергә... Кыскасы, Пастернакның бу антипатриотик эшенә без, татар совет язучылары да, үзебезнең мөнәсәбәтебезне билгеләргә тиешбез.

— Ничек итеп? — диде Нәкый абзый.

— Ягъни без, татар язучылары, Пастернакның ул гамәлен хөкем итәргә һәм аңа карата күрелгән чараны дөрес дип санарга тиешбез.

Алай икән. Без сүзсез генә утыра бирдек. Бу бик киеренке бер мизгел иде. Афзал абзый, шуны тоеп булса кирәк, бераз акланырга теләгәндәй:

— Бездә генә түгел, барлык союз оешмаларында да бу шулай эшләнә,— диде.— Тиешле урыннар белән сөйләшеп, киңәшеп... Бер минем инициатива гына дип уйламагыз!

— Соң сез дә, кирәксә, Союз исеменнән шулай эшләгез... Минем моңа ни катнашым бар?! — диде Нәкый абзый, иңбашын җыера биреп.

— Юк, Нәкый, синең дә катнашың бар,— диде Афзал абзый кистереп.— Һәрбер намуслы язучының...

Ләкин Нәкый абзый, ни әйтәсен алдан ук белгән шикелле, аның сүзен бүлде:

— Гаҗәп, гаҗәп!.. Мәскәүдә әнә, бездән сорап тормыйча, Пастернакның эшен бетереп куйганнар бит инде... Тагын ни кирәк?

— Синең сүзең кирәк, Нәкый... Әнә шул Мәскәү язучылар җәмәгатьчелегенең Пастернакка карата чыгарган карары белән килешәсеңме, юкмы?.. Мин, мәсәлән, Татарстан язучылары килешергә тиеш дип беләм. Чөнки сүз бер язучының союз уставын тупас бозуы, ягъни уставта әйтелгән совет позициясеннән читкә тайпылуы турында бара.— Без менә,— диде ул, сүзен дәвам итеп,— язучылар исеменнән Мәскәүгә җибәрергә хат яздык, ул

әнә алдыгызда ята... Күп кенә иптәшләр аңа кул куйдылар инде. Сез дә укып карагыз... Килешсәгез — кулыгызны куясыз, килешмәсәгез — юк, мәгәр позициягез ачык булырга тиеш.

Нәкый абзый кинәт кычкырып көлеп җибәрде.

— Кара син аны! Позицияне ачыклар өчен генә син безнең арттан машина җибәргәнсең икән ләбаса!

Афзал абзый кара янып китте, ләкин тынычлыгын саклап калды.

— Сезнең ише мөхтәрәм язучыларны җәяү йөртеп булмый бит инде,— дигән булды ул.

Ә Нәкый абзый шунда ук бик җитдиләнеп, аны бөтенләй тыңламагандай, үз уйларына бирелгән иде.

Инде минем үз хәлемә күчәсем килә. Афзал абзыйны тыңлап утырганда ук, миндә ирексездән ике төрле уй үзара тартыша башлады. Күптән инде үзем дә кагылыпсугылып килгәнгә күрә, кешегә политик гаеп ташларга бер дә яратмый идем. Менә хәзерге шикелле бөтен вөҗүдем андый эшкә каршы, һәм моңарчы минем һич кемне дә политик яктан гаепләп чыкканым булмады.

Аннары, Борис Пастернакның зур шагыйрь икәнлеген ишетеп белсәм дә, хәзергә кадәр миңа, оятыма каршы, аның бер әсәрен дә табып укырга туры килмәде. Ә каядыр читтә басылганын әйтеп торасы да юк... Димәк, мин аңа ташланган гаепнең чынмы-ялганмы икәнен белмим, шулай булгач, кешелек ноктасыннан караганда, минем аны гаепләргә хакым бармы?.. Юк, һәм булмаска да тиеш!..

Әйе, минем үз акылым миңа шулай ди, бу гаепләү кампаниясенә кушылмаска, намусымны кочләмәскә куша. Әмма шул ук вакытта фани исәпләрдән туган икенче бер уй да миңа үзенекен тукый, җанга тынычлык бирми иде. Дөресен генә әйткәндә, минем бу уем да әнә шул күптән кагылып-сугылып килүләрдән туган иде. Без кичергән чорларда идеология һәм политика аркасында кыйналулар да, бөтенләй харап ителүләр дә бик күп булды. Әнә хәзер дә Афзал абзый: «Позициягез ачык булсын!» — ди. «Позиция» дигән бу сүз хәзер бик модада — аны гел искә төшереп кенә торалар. Позициясе туры килмәгән кеше әллә ничә төрле күзәтү астында яшәргә мәҗбүр. Аны төрлечә кыса башлыйлар (мәсәлән, язган әйбереңне басмыйча йөдәтәләр яки нәшрияттагы китабыңны планнан сызалар). Ә кая барасың, ни эшли аласың, ничек яшисең бу ирегең һәм җаның богаулы бер заманда?! Әнә шундый бер-берсе белән килешергә теләмәгән «ике фикер» көрәше арасында идем мин...

Ә Афзал абзый, бөтен мәһабәт гәүдәсе белән үрә басып, безнең кузгалганны көтеп тора. Барлык язучыларныкына караганда да Нәкый Исәнбәт белән минем нишләргә уйлавыбыз аның өчен әһәмиятлерәк иде кебек... Үзенә күрә безне тагын бер сынап карау!

Мин, билгеле, Нәкый абзыйдан узып ни дә булса эшләргә тиеш түгел идем. Ул яше белән дә, дәрәҗәсе белән дә миннән күп өстен, һәм миңа караганда күбрәк кыйналган да кеше. Әле кайчан гына җәдитчелектә гаепләп, каты гына кыйнадылар — Хрущевның үзенә барып җитәргә мәҗбүр булды агаебыз!.. Аннары гади әдәп дигән нәрсә дә бар бит әле — сүзне башлап олы кеше әйтергә тиеш.

...Тынып тору озаккарак китте булса кирәк, Афзал абзый коры гына:

— Ягез, иптәшләр, мин көтәм! — дип куйды.

Шуннан соң Нәкый абзый, бер сүз әйтмәстән, кинәт кенә сикереп торды да хатка күз дә салмыйча, астына тиз-тиз генә кулын куеп, каләмен ташлады. Аның бу хәрәкәтләре миңа ничектер «чәнчелеп китегез!» дигән шикеллерәк тоелды. Һәрхәлдә, аның кул куюы теләп, килешеп эшләнгән эш түгел иде. Соңыннан ул моны үзе дә миңа әйтте.

Инде минем чират... Торып, өстәлдә яткан хатны өстән-өстән генә карап чыккан булдым. Билгеле, хатның эчтәлеге белән танышу өчен дә, аңа карата нидер әйтер өчен дә түгел. Бары вакытны сузар өчен генә. Ахырына җиткәч, сүзсез генә кулымны куйдым — монда имзалар җитәрлек иде инде...

Шул рәвешчә Нобель премиясенә лаек булган шагыйрьне хөкем итүгә без дә катнаштык. Бу кичерүе читен түбәнлеккә бару иде, әмма намусыбыз кушканга түгел, ә ирексездән ниндидер өстен бер рәхимсез көчкә буйсынып... Нинди көч соң ул безне шулай еш кына сындыра? Бу сорауга җавапны мин иң ахырдан гына бирәчәкмен. Хәзер исә менә мондый сорауга үзеннән-үзе җавап сорала шикелле: ирексездән кылган гамәлебезне вөҗдан хөкеме алдында аклап буламы? Юк, булмый, мөмкин түгел!.. Иллә мәгәр түбәнлеккә баруыбызны беркадәр җиңеләйткән сәбәп шулай да бар иде. Эш шунда ки, шагыйрь Пастернакны соңгы вакытларда бөтен матбугат тирги, каһәрли, русның безнең өчен авторитет булган зурзур язучылары аны гаепләп чыга, беркем тарафыннан яклау сүзе ишеткәнебез юк. Шуннан соң безгә, гел шик астында яшәүче ике татар язучысына, нәрсә эшләргә ка-

ла?.. Әгәр Пастернакны гаепләү нахак булып чыкса (ә нахаклыгын алдан ук күрергә мөмкин иде), бу бөтен совет әдәбиятына җуелмас оят китерәчәк һәм бөтен җавабы да безнең һәммәбез өстенә төшәчәк. Кампания колына әйләнү коточкыч нәрсә ул!

Миңа калса, Афзал абзый үзе дә — кампания колы. Татар язучылары исеменнән Пастернакка каршы хат язарга аңа, мөгаен, обком кушкандыр әле. Моның кебек җитди эшне ул үз белдеге белән генә эшләргә, ихтимал, җөрьәт итмәс иде. Безнең председательләр көн саен диярлек обкомга йөреп торалар. Бер генә эш тә шул бинада утыручы эреле-ваклы «җитәкчеләр»нең кушуыннан яки рөхсәтеннән башка үтәлми бездә...

Билгеле, Афзал абзый үзе кол булуын инкяр иткән булыр иде. Партия кушкан һәр эш аның өчен, күңеленә хуш килсә дә, килмәсә дә, һичшиксез, дөрес һәм хаклы! Ул бит, үзе әйтмешли партиянең «тугрылыклы солдаты» иде, мәрхүм!

* * *

Үкенечле вакыйганың икенчесе Союзда Ибраһим Гази рәислек иткән чагында булды. Бусы да «кул кую» белән бәйләнгән, әмма мине иң аптыраткан һәм авыр газапка дучар иткәне!..

1968 ел, августның соңгы яртысы, ә мин җәй буе диярлек яңа квартирага ордер алалмыйча җәфаланып йөрим. Шәһәр читендәге кечкенә агач өебезне сүтәргә тиешләр. Күрше өйләрне сүтеп бетерделәр инде, безнең дә капка-коймаларны ваттылар, бакчабыздагы алмагачларны да кистеләр, япа-ялгыз утырып калган өйдән безнең чыгып киткәнне генә көтәләр. Монда зур яңа йорт сала башлаячаклар, материалларын да инде ташырга тотындылар.

Менә шундый бик кыен хәлдә калып аптырагач-йөдәгәч, мин Союзга, Ибраһим Гази янына бардым. Бердәнбер ярдәм сорарлык җиребез шул союз гына — бигрәк тә минем өчен... Ибраһим эшенә килсә, иртә килә торган иде. Мин килгәндә, ул инде бүлмәсендә ялгызы гына нидер язып утыра иде. Кыяфәте бик җитди, мине дә: «Ник вакытсыз йөрисең?» — дигән төслерәк каршы алды. Яза торган кәгазен дә каплабрак куйды. Җитди эшеннән аерылуын күргәч, мин дә сүземне кыска тоттым.

— Гафу ит, Ибраһим! — дидем.— Аптырагач, сиңа килдем... Әллә кайчан билгеләгән квартирага һаман да ордер алалмыйча йөрим. Ә үземне көн дә өйдән куалар.

— Кем бирергә тиеш?

— Горсовет инде...

Шунда ук телефон трубкасын алды, номерын җыйды, кем беләндер коры гына исәнләште һәм туп-туры аңа болай диде:

— Күктә бит фәрештәләр генә торалар, ә без, җирдә йөрүчеләр, барыбыз да гөнаһлы бәндәләр, хөрмәтле Фәлән Фәләнович!.. Ни өчен язучы Еникеевны аңа билгеләнгән квартирага ордер бирмичә интектерәләр? Кайчан бетәр бу волокита?!

«Ай-һай!» — дип, эчемнән пошынып куйдым, аның бу кадәр туры бәрүен ишеткәч... Фәрештәләр белән гөнаһлы бәндәләрне искә төшерүе дә, мөгаен, минем хакта нидер аңлатырга теләве булгандыр... Гомумән, Ибраһим Газиның, ачуы килгәндә, берәүдән дә курыкмыйча ярып әйтә торган гадәте бар иде. Хәтта әнә үзеннән югары утыручыларга да!..

Шулай сөйләшкәннән соң, Ибраһим шап иттереп телефон трубкасын куйды.

— Миңа яңадан шалтыратырга тиешләр,— диде ул, күзлеген киеп.— Син, Янкәй, пока чыгып тор, минем менә бик ашыгыч эшем бар, хәбәр алгач, үзем чыгып әйтермен.

— Булырмы соң ул хәбәр?

— Булырга тиеш. Ишеткәнсеңдер, мин горкомның беренче секретаре белән сөйләштем. Ә ул хәзер үк горсовет белән сөйләшергә булды. Пока шул... Көт, яме!

Мин ничектер кыенсынып кына чыктым да коридорда арлы-бирле йөрергә тотындым. Язучының язучыга чыгып торырга кушуын ишетүе бик үк күңелледән түгел... Хәер, Ибраһим Миңгазыев иптәш безнең председатель дә бит әле: үпкәләп тору бу очракта урынсыз да булыр. Ашыгыч эшем бар, ди бит... Ашыгыч эшләр, гадәттә, обкомнан килә шикелле яки Мәскәүнең үзеннән... Эшнең бик җитдие булса кирәк, Ахунга да тапшырмаган, иртүк үзе килеп утырган. Хәтта яза торган нәрсәсен миннән дә яшерергә тырышты. Гаҗәп әле бу!..

Шулай уйланып, коридор буйлап йөргәндә, Ибраһим да бүлмәсеннән чыкты, үзе яныма килде.

— Сөйләштем, ордерны бирерләр, алырсың,— диде ул миңа һәм, кулларын артка куеп, зур тоташ тәрәзәдән урамга карап тора башлады. Аңарда бераз йончыганлык сизелә иде. Мин, рәхмәтемне әйтеп, китмәкче булдым.

— Тукта, китмә,— диде ул, һаман тәрәзәдән урамга карап торган килеш. Аннары шактый көттереп, әкрен генә сорады: — Чехословакиядәге хәлләрне ишеткәнсеңдер?

Мин икеләнебрәк калдым: нинди хәлне сорый икән?.. Чехословакиядә яздан бирле инде төрле җитәкчеләр арасында ниндидер көрәш-тартыш барганлыгын газеталардан укып белә идек. Дубчек дигән берәүнең җитәкчелекне кулына алуын да ишеткән идек, ләкин безнең газеталар аны мактап түгел, яманлап язганнар иде. Ибраһим шуны сорыймы, мәгәр бу бит инде иске хәбәр. Тагын нәрсә бар икән?

— Юк, ишеткәнем юк,— дидем мин ахырда.

— Радиодан тыңламадыңмыни?

— Бүген иртәнгесен тыңламыйча калдым.

— Жәл, бик мөһим белдерүне ычкындыргансың. Безнең танклар Прагага кергәннәр...

— Ягъни?

— Ягъни безнең хөкүмәт Чехословакиягә гаскәр кертүне кирәк тапкан...

Ибраһим соңгы сүзләрен бер дә күпертмичә, гади генә итеп әйтте. Минем дә артык исем китмәде — гүя көтелгән бер нәрсә турында сүз бара иде.

— Әнә шулайрак эшләр,— диде Ибраһим, көрсенгәндәй.— Без хөкүмәтнең бу чарасын хупларга тиешбездер инде, шулай түгелме?

Мин дәшмәдем — нинди «хуплау» турында сүз булырга мөмкин?!

Ибраһим, ниһаять, миңа таба борылды.

— Кыскасы, болай, Еники,— диде ул,— язучылар исеменнән мин отклик яза идем, бетергәч, син дә кул куярсың шуңа!

— Һай, Ибраһим! — дидем мин, бик борчылып,— хәзер миндә ул кайгымыни?.. Үземнеке үземә җиткән, беләсең бит инде!

— Сүз бит Чехословакияне саклап калу турында бара!..

— Аңлыйм, Ибраһим... Ләкин минем бит бу хакта радиодан да ишеткәнем, гәзиттән дә әле укыганым юк... Белер-белмәс көе тот та нәрсәгәдер кул куй, имеш! Ярыймыни алай?

— Нигә, миңа ышанмыйсыңмыни? — диде Ибраһим, ияген учлап.

Билгеле, сүз ышану-ышанмау турында бармый иде. Совет Армиясенең чехларга бәреп керүенә берсүзсез ышанырга була — безнең сәясәт өчен бик нормаль күренеш ул. Юк, минем әнә шул сәясәтне хуплаган кәгазьгә чынлыкта кул куясым килми иде. Тик менә шуны Ибраһимга туп-туры әйтергә кыюлыгым җитми. Гомумән, Ибраһим белән сөйләшкәндә артык чишелеп китүдән дә тыелырга мәҗбүр идем мин...

Ибраһим Гази ортодоксаль коммунист иде. Совет властена тел-теш тидергәнне бер дә яратмый иде, чөнки үзенең яшәвен, кеше булуын бары тик шул власть аркасында гына дип белә иде. Әмма ул аягүрә катып калган догматик та түгел, тормышның кимчелекләрен дә күрә белә, җитәкче органнарның начар эшләрен тәнкыйтьләүдән дә куркып тормый, бюрократлашып беткән кайбер аңгыра-мокыт түрәләрне ул еш кына «чуен башлар» дип атый торган иде.

Инде безнең мөнәсәбәтләргә килгәндә, нәрсә диярга мөмкин? Безнең танышлык бары сугыштан соң гына башланды. Бер эш кешеләре буларак, без союзда үткәрелгән җыелышларда, төрле утырышларда очрашабыз, бергә кайткан, бергә сөйләшеп утырган чакларыбыз да була иде. Бервакытны, җәйнең матур бер көнендә, Ибраһим белән Афзал абзый һич көтмәгәндә минем шәһәр читендәге өемә дә килеп чыкканнар иде. Бу «визит» мине гаҗәпләндерде дә һәм куандырды да... Бакчада күпмедер сөйләшеп утырганнан соң, өчәүләшеп йөрергә чыгып киттек. Казан суы буйларында озак кына йөреп, шактый арып-талып Ял паркына да күтәрелдек. Ә анда цистернадан сыра сатып яталар. Ничек инде салкын сыраны эчмичә үтеп китәргә мөмкин ди?! Мин юлдашларымны кыстап карадым, ләкин алар цистернага якын да килмәделәр. Минем сыра күбеген өрә-өрә тәмләп эчкәнне бер читтә сабыр гына көтеп тордылар. Эчү мәсьәләсендә бик тәүфыйклы иде алар, мәрхүмнәр!

Кыскасы, Ибраһимның миңа мөнәсәбәте начар түгел иде, дип әйтә алам. Дөрес, ул минем карашларның рәсми идеологиягә туры килеп бетмәгәнен белә иде, мәгәр аңа карап мине чит-ят итмәде. Язучы дип таныды, әсәрләремә карата каты сүз әйткәне булмады. Ул әле мине бер хикәямнең исеме белән «Ялгыз каз» дип тә атый иде. (Очрашканда еш кына: «Нихәл, син, ялгыз каз!» — дип уза торган иде.)

Безнең ара-тирә кайбер актуаль мәсьәләләр буенча ачык кына сөйләшкән чакларыбыз да булды. Аңа каршы сөйләсәм дә, ул чыраен сытмый, усалланмый иде. Гадәтенчә, шаблон сүзләр кулланмыйча гына, беркадәр юмор да кыстырып, үзенекен аңлатырга тырыша һәм ахырдан гына: «Сиңа, парин, Марксны күбрәк укырга кирәк»,— дип өстәп куя иде. Үзе ул язучылар арасында марксизм-ленинизмны бөтенесеннән дә яхшырак белүче булып санала иде.

Гәрчә без бер-беребездән шактый ерак торсак та, мин

аңардан шикләнми идем, гадел кеше булуына ышана идем. Ләкин аның ортодоксаль карашларын белгәнгә күрә, мин, әйткәнемчә, сакланыбрак сөйләшергә дә мәҗбүр идем. Ачуын китерсәң, Ибраһим Гази иптәшнең, хәтер саклап тормыйча, бик туры бәреп әйтә торган гадәтен дә белә идем.

Инде менә Чехословакиягә безнең армияне керту уңае белән аның ниндидер «хуплау» язып маташуы миңа бер дә ошамады — ошамау гына түгел, күңелдә «нигә кирәк булды әле ул?» дигән авыр сорау да тудырды. Шәт, Ибраһимның үзенә дә ачыктыр инде — күрше дус илгә гаскәр керту — бу бит аның эчке эшләренә дорфа рәвештә тыгылу, көч белән аны үз ихтыярыңа буйсындыру дигән сүз... Саклап калу, имеш! Кемнән, нәрсәдән?.. Агрессиянең икейөзле бер формасы ич бу!.. Күп күрдек без моның ише хәлләрне!.. Сугыш вакытында безнең гаскәр азат иткән илләрнең һәркайсында властьны коммунистлар кулына алып бирдек. Җитәкчеләрен дә без куйдык, ярамаганнарын алып ташладык, хәтта суд ясатып, кайберләрен аттырдык та — кыскасы, барысы да безнең боерык буенча эшләнде. Инде без таккан системага халык түзә алмыйча баш күтәрә башласа, гаскәр керттек, танклар белән бастык. Тик без моны һәр очракта халыкка әлеге дә баягы империалистлардан саклап калу дип аңлатырга тырыштык.

Инде менә Чехословакия. Шул ук ялган сылтау, шул ук танклар өере, шулай ук, карта алыштырган шикелле, җитәкчеләрне алыштыру... Һәм мин шушы вөҗданым кабул итмәгән эшне «хупларга» тиешмен, имеш! Дөресен генә әйткәндә, мин Ибраһимның да үз теләге белән «хуплавына» ышанып бетми идем. Мөгаен, аңа бу эшне «югарыдан» кушканнардыр... Шуңа күрә ул, иреннәрен кысып булса да, ашыгыч мөһим боерыкны үтәргә мәҗбүрдер... Мәгәр мин болай фараз кылуымны аның үзенә, билгеле, әйтеп тормадым. Бу очракта бит ул Союз председателе буларак хәрәкәт итә, һәм аның карашы рәсми позиция белән, һичшиксез, туры килергә тиештер инде... Ләкин минем үземә нишләргә соң? Ул әнә минем җавапны көтә: хуплау кәгазенә кул куярга мин ризамы, түгелме? Әлбәттә, риза түгел, әлбәттә, теләмим!.. Тик ничек итеп моны аңа әйтергә? Әмма сизәм, менә хәзер үк туп-туры әйтеп бирергә кыюлыгым җитмәячәк. Бердән, әлеге каһәр суккан сагаю тота, икенчедән, Ибраһимның кәефен дә бозасым килми. Шуңар күрә, үземә калса, дусларча гына әйтеп котыласым килде.

— Ибраһим, кичер, мин хәзер көтеп тора алмыйм.

Син, давай, ул нәрсәңне язып бетер, чакырырсың, килербез, сөйләшербез... Анда тагын күз күрер...

— Синең тизрәк ычкынасың килә инде,— диде Ибраһим, мәгънәле генә көлемсерәп.— Бар алайса, бар!

— Мин синнән качмыйм, Ибраһим! — дидем мин аңа, ихлас күңелдән.

Шуның белән сүз бетте, Ибраһим үзенә кереп китте, мин дә үз юлым белән китеп бардым. Бу урында бик мөһим бер моментны әйтеп үтәсем килә: безнең иң соңгы сүз алышуыбызның һәркайсыбыз өчен яшерен мәгънәсе булган икән. Мин, мәсәлән, Ибраһимның «ычкынасың килә инде» дигән сүзен «кул куюдан качарга телисең» дип аңладым. Ә минем җавапны аның ничек кабул иткәнен миңа соңрак аңларга туры килде. Тагын өстәп шуны да әйтим: мин, билгеле, яңадан Союз тирәсенә барып йөрмәдем, һәм, чакырсалар да, бармаска, дип, күңелемне беркетеп куйдым.

Бер-ике көн үтте микән, «Татарстан» газетасында Ибраһим Гази тарафыннан язылган һәм бер төркем язучылар кул куйган әлеге «хуплау» басылып та чыкты. Тексты зур түгел иде, анысын өстән-өстән генә укып, мин тизрәк кул куючыларга күз төшердем: башта Ибраһим Гази үзе, аннары Афзал Шамов, Гомәр Бәшир, тагын берничә мөхтәрәм язучының исеме һәм шулар арасында... минем исем дә! (Кызганычка каршы, ул газета миндә сакланмады, шуңа күрә исемнәрнең хәтердә калганнарын искә төшерү белән генә чикләнәм.)

Үз исемемне күргәч, минем кечкенә күзләрем атылып чыга язды. Бу ни хәл?! Кайдан, нигә, ни өчен монда минем исем? Күрмәгән, укымаган, кул куймаган белдерүдә?! Аңлый алмыйм, күзләремә ышанасым килми, әллә нәрсә бу!

...Ярый, «хуплау»ның үзен ул югарыдан кушу буенча язсын ди, әмма аның астына кемнәрнең исемнәрен куеп чыгаруны да кушып тормаганнардыр инде... Һичшиксез, бу — Ибраһимның үз эше! Димәк, ул, коммунист иптәш, Чехословакияне танклар белән таптатуны үзе генә хуплау түгел, минем исемнән дә хуплата! Мин аның өчен үз акылым, үз вөҗданым белән яшәүче шәхес түгел, минем белән теләсәң ни эшләсәң дә һәм миннән теләсәң ни эшләтсәң дә ярый икән ләбаса! Җанны иң нык сыкратканы һәм тетрәткәне әнә шул хакыйкатьне ачу булды. Гаҗәеп бер ачыклык белән мин үземнең партия диктатурасы шартларында гади бер чүпрәк уенчыкка әйләнүемне аңлагандай булдым.

Әйе, әнә шул рәвешчә мин үз ихтыярымнан тыш мөр-

тәтлеккә дучар ителдем, үз теләгемнән башка тарих битендә канлы бер җинаятьне хуплаучы булып калдым. Әйтәсе дә түгел, моның газабы минем өчен бик авыр иде һәм озакка сузылды.

Бераз айный төшкәч, минем кемгә дә булса зарымны сөйлисем килә башлады. Тәвәккәлләп Гомәр абзыйга шалтыраттым. Ленин бакчасында очрашырга булдык.

Укучыда сорау туарга мөмкин: ни өчен Гомәр Бәширгә, ни өчен Ибраһим Газиның үзенә түгел? Әйе, беренче минутларда ук миндә андый тыелгысыз теләк туган иде. Ләкин эш узгач, ярсып барып, талашып кайтудан ни мәгънә?! Ә минем бу акылга сыймас күңелсез вакыйганың чын сәбәпләрен ныграк аңлыйсым килә. Гомәр абзый — Ибраһимга кадәр үзе дә безнең оешманы җитәкләгән кеше, әдәбиятыбызның танылган авторитеты, югарыдагы җитәкчеләр белән дә даими бәйләнештә... Аннары иң мөһиме, мин аңа ышанам, курыкмыйча барын да сөйли алам. Ә хәзер миңа бары тик шундый кеше кирәк.

Икенче көнне очрашкач һәм бакчаның аулаграк бер җиренә барып утыргач, мин аңа булып узган вакыйганы бик ачынып сөйләп бирдем. Әмма Гомәр абзыйның моңа һич тә исе китмәде.

— Мин дә укымадым, мин дә кул куймадым,— диде ул, мине шаккатырып.

— Ә башкалар?

— Белмим... Юктыр, булмагандыр... Ибраһим үзе генә кирәк кешеләрнең исемен куеп чыккандыр... Ашыгыч эш, гадәттә, шулай эшләнә инде ул... Әнә некролог язганда да имза җыеп йөрмиләр ич!

Соңгы мисалы бик кызыклы, әмма урынлымы ул, ничек итеп мин мондый аңлату белән килешә алыйм ди?!

— Гомәр абзый, бу бит үтә җитди вакыйга! — дидем мин, кызып китмәскә тырышып.— Бер дәүләт икенче дәүләтнең җиренә гаскәр кертә, аны көч белән үзенә буйсындыра, һәм шушы... ямьсез эшне, ризалык сорамыйча гына, безнең исемнән хуплыйлар!.. Йә, әйтегез, килешеп буламы мондый башбаштаклык белән?..

— Анысы шулай инде,— диде Гомәр абзый, киң, шәрә маңгаен ышкыштырып.— Вакыйгасы да бик күңелсез, «хуплау»да бик үк дөрес эшләнмәгән... Ибраһим телефон белән генә сорап чыкса да, яхшы буласы икән дә бит, күрәсең, югарыдан бик ашыктырганнардыр инде... Ләкин син, Әмирхан, артык борчылма. Кем андый «хуплауларны» укып тора?.. Бездә шулай бит инде ул, зуррак вакыйга булса, югарыдан тоталар да тизрәк йә «хуплау», йә «яманлау» оештырырга кушалар... Вакыйгасы-

на карап... Мәгәр үтә дә китә ул, кеше аңа игътибар да итеп тормый... Оныт син аны!..

Әнә шулай юатты Гомәр абзый мине... Ул инде тәҗрибәле кеше, ихтимал, аның үзенә дә оештырырга туры килгәндер андый белдерүләрне. Гадәти эш, диде ич!.. Мәгәр бу хакыйкатьне белүдән җанга тынычлык киләмени, юк, киресенчә, ачуны һәм газапны көчәйтә генә ул!.. Ни өчен соң мин Ибраһимның үзенә шул чакта ук бернинди кәгазьгә кул куймаячакмын, дип туп-туры әйтмәдем?.. Әмма ләкин үземә күрсәтмичә генә шундый җитди кәгазьгә минем имзаны да кыстырырлар дигән уй ник бер башыма килсенче?!

Бу хәлләрне мин шул чакта ук бер блокнотыма язып та куйган идем. Ихтимал, киләчәктә бер кирәк булыр дип... Шуның белән бергә Ибраһим Газиның үзенә дәниләр кичергәнемне әйтәсем килә иде. Белсен, белмичә калмасын, дия идем мин һаман да үземә. Ләкин бик озак җай таба алмыйча йөрдем. Председатель союзга сирәк килә, килсә дә, һәрвакыт янында кешеләр була. Ахырда көннәрдән бер көнне Ибраһимның үзен генә бүлмәсендә туры китердем. Исәнләшеп, әзрәк хәл-әхвәл сорашкач, мин аңа иплэп кенә әйттем:

— Быелгы җәй минем өчен шактый авыр, мәшәкатьле булып чыкты. Ләкин алары үтәр, онытылыр... Тик күңелдәге авыр бер төер генә онытылмас, ахрысы... Шуны сиңа әйтмичә кала алмыйм: хәтерлисеңме, Чехословакиягә армия керту уңае белән син үзең язган хуплау кәгазенә, минем ризалыгымнан башка, исемемне куеп чыгардың?..

Әйтеп бетерергә өлгермәдем, Ибраһимның йөзе кинәт үзгәрде, бик җитдиләнде, күзләре дә күзлеге аша зурая төшкәндәй булды. Менә хәзер миңа ташлана инде дип көткән идем, ләкин ни гаҗәп, ул кабынып китмәде, ничектер үзен тыеп калды. Ияген учлап, шактый гына дәшми торганнан соң, миңа туры карап әйтте:

— Нигә, алайса, берәр гәзитәгә, минем ул кәгазьгә кул куйганым юк, дип язып чыкмадың? Кирәк иде, төер саклап йөрткәнче...

Инде мин аптырап калдым аның бу җавабына: чынлап әйтәме, әллә үртәпме?.. Әлбәттә, үртәп, чөнки андый белдерүне бер гәзитәнең дә басмаячагын белеп тора ич ул! Шулай да ул, акыллы баш, бик нечкә җирдән тотты. Җавапсыз калмас өчен генә мин:

— Чынлап та, син әйткәнчә эшләргә кирәк булган икән,— дигән булдым.— Кызганыч, вакытында уйлый белмәгәнмен.

Ибраһим әче генә елмайды:

— Белсәң дә, язарга йөрәгең җитмәс иде.

— Ни өчен?

— Шулай. Синең дә башың ике түгел бит.

«Синең дә» — ничек аңларга моны?.. «Минеке дә ике түгел»,— дип әйтмәкче буламы әллә?.. Әгәр тел төбендә шул икән, димәк, ул да каяндыр, кемдер кушканны теләсә-теләмәсә дә үтәргә мәҗбүр булган.

Ходаем, кемнәр соң без? Һәртөрле явызлыкны аклап тору безнең бурычыбызмыни?! Кайдан бу мөртәтлек, икейөзлелек, ниһаять, куркаклык?

Моның җавабын мин шушы язманың ахырында әйтергә тырышырмын.

* * *

Инде рухи коллык заманы өчен «типик» булган аянычлы вакыйганың өченчесенә күчик. 1967 елны минем «Салават күпере» дигән хикәяләр җыентыгым Язучылар союзы тарафыннан Тукай премиясенә тәкъдим ителде. Башта кагыйдә буларак мәсьәлә идарә утырышында каралган. Билгеле, мине тәкъдим итү шома гына узмаган. Идарә әгъзаларыннан Хәсән абзый Туфан, Фатих Хөсни, Рафаэль Мостафин яклап чыксалар да, союзыбызның җитәкчесе Мирсәй Әмир шактый нык каршы торган. (Аңа кушылучылар да, әлбәттә, булгандыр дип уйлыйм.) Ләкин тавышка куелгач, күпчелек белән шулай да мин үткәнмен. Әйтергә кирәк, җитәкче фикеренә каршы бару, һәр җирдәге шикелле, безнең Союзда да бик сирәк була торган хәл иде.

Мин үзем бу вакытта каядыр читтә идем, бары кайткач кына идарә утырышында ниләр булганын ишетеп белдем.

...Күпмедер вакыттан соң газеталарда Тукай премиясенә тәкъдим ителүчеләрнең исемнәре басылып чыкты. Алар өч кандидат иде: рәссам Бакый ага Урманче, язучылардан мин һәм Татар академия театрында куелган «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә катнашучылардан бер төркем. Аларның тәкъдим ителгәнен күргәч тә, премиянең миңа тимәячәген аңладым. Хәтта мине үткәрмәс өчен аларны, югарыдан кушу буенча, тәкъдим иткәннәрдер әле, дигән гөнаһлы уй да күңелемә килгән иде.

Инде спектакльнең үзе һәм анда катнашучылар турында берничә сүз: «Гүзәлем Әсәл» — Чыңгыз Айтматовның «Тополек мой в красной косынке» исемле повесте буенча эшләнгән инсценировка. Тәрҗемәсен миннән

эшләткәннәр иде... Әсәрне сәхнәгә Ташкенттан махсус чакырылган үзбәк режиссеры Хаджиев куйды. Декорацияләрен Качалов исемендәге театрның баш рәссамы Гельмстан ясаттылар, баш рольләрне Наилә Гәрәева белән Ринат Таҗетдинов башкара... Күрәсез, тәкъдим ителүчеләр барысы да бик лаек кешеләр.

Шуңа күрә дә мин, конкурентның бик көчле булуы белән бергә, Мирсәй Әмирнең дә каршы икәнлеген белеп, башта ук премиянең миңа булмаячагына күңелемне беркетеп куйган идем. Аннары обкомда утыручыларның да миңа карашлары шәп түгеллеген күптән инде ничектер тирем белән сизәм. Ә Тукай премиясен кемгә бирүне, асылда, шунда хәл итәләр — бу кадәресе дә берәүгә дә сер түгел... Шул сәбәпле нидер өмет итеп, борчылып йөрүнең һич тә кирәге юк иде.

Гомумән, мин беркайчан да дан-шөһрәт артыннан кумадым. Һәртөрле исем-бүләкләргә нәфсемне дә сузмадым. «Үз эшеңне бел дә тыныч кына йөр!» — шулай юата торган идем мин үземне.

Әмма бу юлы минем тынычлыгым уйламаганда бозылып куйды. Апрель аеның епшек бер кичендә без, күп кенә язучылар, Гази Кашшафка 60 яшь тулу уңае белән «Татар ашлары йорты»нда үткәрелгән мәҗлестә булдык. Гадәттәгечә, мул ашау-эчү, ялкынлы котлау-мактаулар, дәртле җыр-биюләр үз чираты белән бара торды. Беләсез инде, Гази тыйнак кеше, мәҗлесе дә аның, үзенә охшап, ыгы-зыгысыз, күңелле-җылы гына узды. Бик соңга калмыйча гына барыбыз да бер үк вакытта диярлек кузгалдык та... Профсоюз урамы буйлап төркем-төркем кайтып барган чакта, без Мирсәй Әмир белән ничектер бергә туры килдек. Берәүләр алга китте, берәүләр арткарак калды, ә мин Мирсәйдән аерылып китәргә яхшысынмадым. Бераздан ул үзе сүз башлады.

— Әмирхан,— диде ашыкмыйча салмак кына,— тиздән Тукай комитетының утырышы булачак. (Пауза.) Мин, уйлана торгач, синең кандидатураны якларга булдым... Ник дисәң, Тукай премиясе ул иң элек үзебезнең оригиналь әсәрләргә бирелергә тиеш. Ә Академия театрының спектакле нәрсә ул? — тәрҗемә әсәр, куючысы читтән чакырылган, художнигы да читтән — аларга Тукай премиясен биреп, без нәрсә отабыз?.. (Пауза. Мин аның сүзен ничек тә бүлмәскә тырышам.) Дөрес, башта мин сине тәкъдим итүгә каршы идем, ләкин ахырда, нык кына уйлагач, башкалар фикере белән килештем; хикәяләрең минемчә дә зур бүләкне күтәрерлек... Үтәр дип ышанам...

Мин аны бик игътибар белән тыңладым, сүзен бүлмәдем, сорау да бирмәдем. Мирсәй сүзен җилгә ташлый торган кеше түгел,— шуңадыр бик җиңел ышандым мин аңа... Бары чын күңелдән:

— Рәхмәт, Мирсәй, рәхмәт! — дидем.— Бүләкне бирерләрме-юкмы, анысы мине ул кадәр борчымый, әмма синең карашың үзгәрүе минем өчен кыйммәтрәк!..

Бүтән нәрсә дим? Минем бит бу хакта аның белән сүз башларга һич уйлаганым да юк иде — ул үзе башлады, үзе әйтте. Билгеле, миңа карата уен үзгәртүе аңа бер дә җиңел булмагандыр — үз позициясендә нык торучы икәнен барыбыз да яхшы беләбез. Ә шулай да әнә үзгәрткән. Димәк, аны уйланырга мәҗбүр иткән җитди сәбәпләр булгандыр. Берсен ул үзе үк әйтте: Тукай премиясен оригиналь әсәргә бирергә кирәк, диде. Идарә утырышында күпчелекнең минем файдага тавыш бирүе дә аны нык кына уйландыргандыр, мөгаен. Аннары Тукай премиясенә тәкъдим ителүчеләр турында матбугатта чыгып барган фикерләрнең дә аңа, һичшиксез, йогынтысы булмыйча калмагандыр. Мәсәлән, «Татарстан»да басылган Гази Кашшаф мәкаләсен күрсәтергә була. Гази үзенең шул зур мәкаләсендә премиягә тәкъдим ителгән ике әсәр — минем хикәяләр җыентыгы белән «Гүзәлем Әсәл» — турында фикер йөртеп, ахырында: «Мин Тукай бүләген Әмирхан Еникигә бирү ягында»,— дип, ачыктан-ачык язган иде... Башкалар тарафыннан да минем хикәяләргә карата уңай фикерләр әйтелгән иде.

Һәрхәлдә, Мирсәй Әмир әнә шуларның барсын да исәпкә алгандыр дип ышанырга була. Төпле кешенең, тискәрелеккә бирелмичә, фикерен үзгәртә алуы үзе генә дә чын егетлек ул!

Апрельнең епшек кичендә, мәҗлестән кайтышлый көтелмәгән бу кыска сөйләшүнең, әйтәсе дә түгел, минем үземә тәэсире көчле булды; күптән инде сүнгән өмитне ул яңадан терелтеп җибәрде... Ходаем, булмас нәрсәмени ул?! Танылган олы язучы, Союз җитәкчесе, премия мәсьәләсе каралганда, мине яклап сүз әйтә икән, моның бит, һичшиксез, хәлиткеч әһәмияте булырга тиештер инде?! Анда әле башка яклаучылар да булачак — мин моны белә идем. Дөрес, тавыш бирүнең нәтиҗәсе бүтәнчәрәк тә килеп чыгарга мөмкин, әмма ничек кенә булмасын, минем өмит-ышанычым бик нык үскән иде. Комитет утырышына кадәр калган вакытны мин аз гына борчылу-дулкынлану кичергән хәлдә әйбәт, күтәренке кәеф белән үткәрдем.

Белмим инде, язмышның бер шуклыгы булдымы —

Тукай комитетының карарын мин көне-сәгате белән үк белдем. Ленин урамы буйлап Союзга таба китеп барам, ә Кремль ягыннан Рафаэль Мостафин кайтып килә. Матбугат йортына төшә торган урам чатында очраштык. Күрештек.

— Каян киләсең? — дип сорыйм.

Рафаэль, читкә карабрак:

— Совминнан,— ди.

— Әллә комитет утырышыннан?

— Әйе, шуннан... Яңарак кына бетте...

...Сүз ничектер өзелеп калды. Мин утырыш нәтиҗәсен сорарга кыймыйча торам. Ул да әйтергә ашыкмый. Бу инде шунда ук күңелдә авыр шик уятты, ләкин шулай да мин үзем башлап сорадым: йә, нәтиҗә ничегрәк соң?

Рафаэль нигәдер шактый ашыгып җавап бирде:

— Комитет Тукай премиясен Бакый Урманче белән «Гүзәлем Әсәл»гә бирергә булды.

Ала-ай!.. Кай җиремдер нәрсәдер чәнчеп куйды. Мәгәр тыштан мин тыныч идем. Рафаэль, минем нәрсә көткәнемне белеп, шулай ук ашыгыбрак, сүзен дәвам итте:

— Сезнең хакта да шактый бәхәс булып алды. Якладык. Хәсән абый да, мин дә, Җәүдәт Фәйзи дә... Яклап язылган хатлар да бар иде — аларның да кайберләрен укыдылар.

Шул мизгелдә үк тел очыма килде, һәм түзмәдем, сорадым:

— Ә Мирсәй?.. Мирсәй ни диде?

— Әгәр Мирсәй абый да якласа, нәтиҗә, конечно, башка булачак иде,— диде Рафаэль.

Якласа?! Аңлап җитә алмыйм, валлаһи!

— Нәрсә әйтте соң ул?

Рафаэль икеләнгән шикелле көттеребрәк җавап бирде:

— Кеше сүзен җиткерүе әллә ничек килешми дә, ну сезгә әйтмичә дә булмый, чөнки аның сүзе барыбызны да бик гаҗәпләндерде... Мирсәй абый болай диде: Әмирхан Еники совет әдәбиятының олы юлыннан читтә торган язучы, хикәяләре әдәби эшләнгән булса да, идея-эчтәлекләре белән безнең заман рухына туры килеп бетми, диде. Җәүдәт Фәйзи шунда ук: ничек инде ул алай, Еникине Язучылар союзы тәкъдим итә, Союз җитәкчесе каршы чыга, һич аңлый алмыйм мин моны, дип гаҗәпләнүен белдерде. Ә Мирсәй аңа кыска гына, мин башта ук каршы идем, диде. Менә шул!..

Рафаэль әйткәннәр, чәнчеп кенә калмыйча, башыма чукмар белән китереп органдай булды. Минем инде шун-

нан артыгын сорыйсым да, тыңлыйсым да килмәде. Союзга төшеп тормадым, Рафаэльгә ияреп бераз бардым да Ленин бакчасына борылдым. Барышлый аңардан тагын шуны да ишеттем: комитет утырышында миңа да 5—6 кеше тавыш биргән икән.

Әлбәттә, миңа аулак урын кирәк иде. Ленин бакчасының кардан арынып, яңа кипкән, яшәрә башлаган чагы, эскәмияләре дә былтыргы сары яфраклардан чистарынып бетмәгән — мин шуларның берсенә барып утырдым. Әлбәттә, минем башымда премия кайгысы түгел иде — ул шунда ук онытылды, юкка чыкты. Миңа Мирсәяф Әмир иптәшне аңлау кирәк иде. Аның вәгъдәсен бозуы мине бөтенләй хәйран итте, ток суккандай тетрәтте, хәтта зиһенемне дә бер мәлгә чуалтты. Ничек кенә аңларга соң чал чәчле мөхтәрәм язучының бу гамәлен?! Миндә әле аңа карата ачу да, рәнҗү дә юк иде. Мин тик аны аңлаудан гаҗиз идем. Әмма күпмедер вакыт ни уйларга белмичә, шулай сыкранып утырганнан соң, мин кинәт үзем өчен бер хакыйкатьне ачкандай булдым: әлбәттә, бу — Мирсәйнең үз эше түгел. Вәгъдәсен бозарга аны мәҗбүр иткәннәр. Бу, һичшиксез, шулай!.. Күптән билгеле бит инде: Тукай премиясен кемгә бирү мәсьәләсен башта обкомда хәл итәләр. Мөгаен, бу юлы да шулай эшләгәннәрдер; утырыш алдыннан Мирсәйне, Союз җитәкчесен, чакырып алганнардыр да әйткәннәрдер: «Ә.Еники премиягә лаек түгел, син шуны исбат итәргә тиешсең!» — дигәннәрдер. Ә аның сүзе комитетта хәлиткеч роль уйнаячагын боерык бирүчеләр, әлбәттә, белеп торганнар. (Комитет әгъзаларының, председателеннән башка, күпчелеге исә әдәбият һәм сәнгатьтән бик ерак торган кешеләр.)

Башкача мин Мирсәй Әмирнең гамәлен аңлый алмыйм. Яклыйм дигән вәгъдәсен мин аңардан тартып алмадым, үз теләге белән башлап әйтте, шулай булгач, миңа хәзер нәрсә генә уйларга кала?!

...Ыграк уйлаган саен, Мирсәйнең үзенә карата рәнҗүем дә арта баргандай булды. Ничек инде, ничек инде ул, арабызда иң төпле, иң акыллы кешебез, үз карашында һәрвакытта нык торучы Мирсәй Әмир, чал башы белән вәгъдә бозу кебек түбәнлеккә барды икән?! Аңа бит «Вәгъдә — иман!» дип кистереп бер әйтү дә җиткән булыр иде. Моның өчен беркем дә олы яшьтәге мөхтәрәм язучыга кагылырга җөрьәт итә алмас иде.

Әйе, әйтәсе дә юк, каләмдәшем Мирсәй Әмирнең ул гамәле мине тәмам хәйран итте, миңгерәүләтте, тирән яра салды бәгырьгә!.. Һәм мин шактый вакыт рухи авыруга сабышып йөрдем. Союз тирәсенә барып йөрүдән тук-

тадым — бигрәк тә Мирсәй белән күзгә-күз очрашудан кача идем. Һәм сизә идем кебек: Мирсәйнең дә очрашырга бер дә теләмәвен... Ул шулайрак булды да — шактый озакка сузылды бу ике яклап очрашудан качу... Вәләкин барыбер очрашырга туры килде — бер үк юллардан йөрибез ич!.. Көннәрнең берендә мин Матбугат йортының баскычыннан кызу гына төшеп барам, ә түбәннән Мирсәй авыр гына менеп килә. Секундның бер мизгелендә «Туктаргамы?» дип уйлап алдым, ләкин Мирсәй үзе, мине күргәч, туктады һәм якынаюыма үзе үк сүз дә башлады.

— Әмирхан,— диде әкрен генә.— Синең миңа үпкәң зурдыр инде?

Җавап көткәндәй, аз гына тукталды, ә мин җилкәмне генә җыергандай иттем.

— Аңлыйм,— диде ул, башын кагып.— Ләкин син дә белергә тиешсең эшнең миннән генә тормаганын...

— Беләм! — дидем мин дә әкрен генә һәм шунда ук түбән төшеп тә киттем. Бәлки, болай ук ашыгырга кирәкмәс тә иде, әмма ләкин бу очрашуның, бу кыска гына сүз алышуның Мирсәй өчен дә, минем өчен дә никадәр авыр икәнлеген тоймыйча мөмкин түгел иде. Мәгәр шушы ике авыз сүз дә безнең арага күпмедер ачыклык керткәндәй булды...

Вакыт — иң көчле дәва, дип, юкка гына әйтмәгәннәр... Менә җәйләр үтеп, көзләр дә җитте. Союзда эшләр дә җанлана төште, төрле җыелышлар да ешрак була башлады. Билгеле, ул җыелышларда без икебез дә булабыз. Мирсәй күбрәк президиумда, мин — залда. Инде каракаршы туры килсәк, тыйнак кына исәнләшеп узабыз.

Баскычта очрашып сүз алышудан башка безнең арада бүтән аңлашу да булганы юк. Нигә кирәк ул — мәсьәлә болай да үтә ачык. Иң яхшысы — барысын да тизрәк оныту...

Әмма ләкин Мирсәй мәрхүмнең җаны шулай да тыныч булмаган икән, нидер аның күңелен һаман да борчып торган. Моның ике дәлиле бар.

Берсе: Союзда җитәкчелек алмашынып, идарәгә Гариф Ахунны председатель итеп куйгач, Мирсәй Әмир мине яңадан Тукай премиясенә тәкъдим итүне кузгатып карамакчы булган. Мәсәлән, «Гөләндәм туташ хатирәсе» чыккач, ул Гарифка әйткән: «Әмирханның бу әсәрен Тукай премиясенә тәкъдим итәргә кирәк иде!» — дигән. Гариф аңа болай дип җавап биргән: «Мирсәй абый, ни өчен әле син үзең эшләгән хатаны миннән төзәттермәкче буласың?» — дигән. Мәгънәсе аңлашылса кирәк...

Күрәсез, Мирсәй чынлап та «хатасын» төзәтмәкче булып караган. (Гариф моны миңа үзе сөйләде. Исән-сау кеше, әйткәннәреннән, шәт, баш тартмас дип ышанам.)

Икенче дәлил: Мирсәй Әмирнең миңа җитмеш яшем тулган көннәрдә язган хаты... Хатның эчтәлеген шәрехләп торудан тыеласым килә. Укучы үзе укып, үзе нәтиҗә ясарга тиеш.

*«Хөрмәтле Әмирхан туган!*

*Без синең белән Казанга бер чорда килгән, татар мәдәнияте йорты бусагасын бергә бер елларда таптый башлаган; син дә, мин дә хөрмәт иткән Такташларны, Кутуй, Туфаннарны, Галимҗаннарны тыңлап үскән кешеләр.*

*Бөтен серләребезне уртаклашырлык якын дуслар була алмадык. Язган әсәрләребезгә карата бер-беребезне хуплаган кебек, «тукмаган» чакларыбыз да булды.*

*Бүген, сиңа җитмеш тулган көндә, кулымны күкрәгемә куеп, чын күңелдән әйтәсем килә: «Дус кеше»ңнән башлап, шушы көнгә кадәр мин синең талантлы художник икәнлегеңне һаман күреп, танып, икърар итеп, тылсымлы каләм көчеңә сокланып киләм.*

*Аерым әсәрләреңә карата канәгатьсезлек күрсәтүләрем булса да, үземчә хөсни нияттән чыгып (хәзер инде ялгышкан чагым булмагандыр, дип тә әйтә алмыйм), сиңа һәм әдәбиятыбызга карата яхшылык теләүдән генә булды.*

*Һәр әсәреңне мин дә, Фәүзия дә кызыксынып яратып укыйбыз. Зур юбилееӊ белән, җиңү бәйрәмеңә сокланырлык матур уңышлар алып килүең белән чын күңелдән котлыйбыз!*

*Исәнлек-саулык, сүнмәс иҗат дәрте, гаилә бәхете теләп, Әмирханча язылган яңа әсәрләреңне көтеп калабыз.*

*Мирсәяф, Фәүзия Әмирләр.*
*1.03.1979. Казан».*

Тик бер фикеремне әйтүдән тыеласым килми: «Саф күңел» әсәрен язган әдипнең үз күңеле, үз намусы турында борчылып яшәве аның күп кенә еллардан соң миңа юллаган әнә шул хатында ачык чагыла, дияр идем.

* * *

Яңадан әлеге «Без кемнәр идек соң?» дигән сорауга кайтырга вакыт. Хәер, баштан кичкәннәрне сөйләгәннән соң, сорауны икенче төрлерәк тә куярга була: безнең гамәлебезне һәр очракта кем, нәрсә билгеләде?

Кыскасы, безнең гомеребез, бала-чагыбыздан алып, вакыйгалар еш алышынып торган мавыктыргыч-кызыклы, әмма киеренке-куркыныч заман шартларында узды... Мин әле шул гаять катлаулы заманның рухи дөньябызга ничек тәэсир итүе турында язу белән генә чикләнмәкче булам.

Мәгълүм ки, заманны кулында авызлыклап тотучы, аны үзенә кирәкле якка теләсә ничек боручы бердәнбер көч — большевиклар партиясе иде. Бу партиянең алдау белән көчләүгә нигезләнгән һәр адымын аклаучы бердәнбер тәгълиматы — марксизм-ленинизм иде (Сталин аңлатуында). Менә шул идеология безне һава шикелле чорнап алган иде. Сыйнфый нәфрәт белән сугарылган бу идеология күпләрнең аңына гына түгел, канына үтеп керде. Шәхес иреге һәм фикер хөрлеге дигән төшенчәләрне юкка чыгарды. Алай гына да түгел, какшамас догмага әйләнгән ул идеология һәр нормаль кешедә булырга тиешле вөҗдан, намус, инсаф-шәфкать кебек әхлак кагыйдәләрен басып китте, тәмам бетерә язды. Әгәр дә кеше, аеруча коммунист кеше, берәр җитди мәсьәлә алдына килеп басса, ул, үзендәге кешелек сыйфатларын буып булса да, партия идеологиясе таләбенә буйсынырга мәҗбүр иде. Әнә шулай кешене үз ихтыярыннан тыш мескен кол итү яки алдап-көчләп ерткычка әйләндерү коточкыч репрессия елларында бөтен караңгы тирәнлеге белән ачылды. Шундый вакытлар булды ки, халык әллә сарык көтүе, әллә бүреләр өере — аерып та булмый башлады.

Без әнә шуларның барысын да күреп уздырдык. Ә бик күпләргә партия тудырган тоталитар системаның бөтен кансыз ерткычлыгын үз җилкәсендә дә татырга туры килде. Шулай булгач, Мирсәй Әмирне обкомга чакырып, аның кулына су салырга да ярамаган кемдер берәү вәгъдәсен бозарга мәҗбүр иткән икән, моңа гаҗәпләнеп буламы соң?! Дөрес, мин моның белән Мирсәй тиз бирелүчән йомшак кеше иде дип әйтергә һич тә җыенмыйм. Киресенчә, нык кеше, моны ул 1937 елны төрмәдә утырган чагында да күрсәтә алган. Әмма бөтен хикмәт шунда ки, Мирсәй Әмир әлеге марксизм-ленинизм идеясенең хаклыгына тулысынча ышанган, шул идеяне байрак итеп күтәргән партиягә беткәнче бирелгән кеше иде. Шуңар күрә дә бит ул, мәрхүм, 1937 елны Сталин палачлары аның башына тимер кыршау кидерсәләр дә, гомеренең ахырына кадәр шул партиягә барыбер тугрылыклы булып калды.

Бездәге бөтен аерма да әнә шунда иде. Мин — фир-

касыз, партия диктаты миңа турыдан-туры кагылмый. Мин күпмедер дәрәҗәдә хөр кеше, үземчә фикер йөртә алам. Бер генә мисал, әйтик, Мирсәй өчен (шулай ук Афзал абзый белән Ибраһим өчен дә) бездәге «социализм» — теләп, көрәшеп алынган чын, табигый тормыш иде. Мин исә адәм сөякләре өстендә төзелгән социализмның чын, табигый булуына үземне ышандыра алмый идем, ничектер аның ялган-ясалма бер җәмгыять булуын гүя күңелем белән тоеп яши идем. Бу зур, җитди аерма... Әмма шундый аермага карамастан, без барыбыз да шул ясалма җәмгыять шартларында, шул җәмгыятьне тудырган бердәнбер партиянең чикләнмәгән хакимлеге астында яшәдек. Безнең бөтен уй-фикеребезне, бөтен эш-гамәлебезне шул партия билгеләде, юнәлдерде, гел үзенә буйсындырып килде. Шуңар күрә дә мин инсаният таләпләренә хилаф бөтен гөнаһларыбызны Ленин-Сталин партиясенә кайтарам, аның өстенә салам. Тарих алдында җавабын да ул тотсын!..

...Сүзем бетте кебек... Югарыда сөйләнгән үкенечле эшләребез өчен замандашларымның берсенә дә минем дәгъвам яки үпкәм юк. Мәрхүмнәрнең авыр туфраклары җиңел булсын! Без барыбыз да ярлыкауга мохтаҗ бәндәләр...

*«Казан утлары», 1991,4 сан*

## ЯЛГАННЫ ЯКЛАУ

Тукай клубында булып узган бер җыелышны минем искә төшерәсем килә. Аңа инде егерме елдан артыграк вакыт үтеп китте. Числосын-көнен дә тәгаен генә хәтерли алмыйм, әмма җыелышның үзен һич тә онытасым юк.

Безнең гомердә җыелышлар күп булды, төрле заманда төрлесен күрергә туры килде — күбесе инде онытылып та бетте. Тик турыдан-туры үзеңә кагылганы гына каядыр хәтер төбендә онытылмыйча сакланып ята. Мин сөйләргә теләгән җыелыш әнә шундыйлардан. Үземә кагылган өчен генә сөйләп тору кирәкмәс тә иде, бәлки, әмма бу очракта сүз башлыча Тукайга кагыла — Тукаебыз турында барачак. Бары шуңа күрә генә мин моннан 20 ел элек булып узган ул җыелышны яңадан искә төшерүне кирәк таптым.

1971 елны безнең нәшрият «Тукай атеизмы» дигән бер китап бастырып чыгара. Авторы З.А.Ишмөхәммәтов. Күргән, белгән кешем түгел. Бары күпмедер вакыттан соң гына аның Казан университетында философия

кафедрасы укытучысы икәнлеген ишетеп белдем. Тукайга багышланган китабы белән фәлсәфә өлкәсендәге фәнни хезмәте булгандыр.

Шунысы кызыклы, бу кешенең китабы турында миңа шул ук университет профессоры, Тукай иҗаты белән махсус шөгыльләнүче Ибраһим Нуруллин башлап әйтте: «Тукайны дәһри иткән бер китап дөньяга чыкты, син шуны табып укы әле»,— диде...

Билгеле, мин тиз арада ул китапны табып алдым — урта форматта, 71 бит, бәясе дә 11 тиен генә... Һәм шунда ук бик игътибар белән мин аны укып та чыктым.

Төп мәсьәләгә күчкәнче, алдан ук шуны әйтеп куясым килә: китапның авторы бу фани дөньяда юк инде. Әмма китабы турындагы минем карашны, уйлыйм ки, ишеткән булырга тиеш. Чөнки менә монда язылачак фикерләремнең күбесен мин әлеге Тукай клубындагы җыелышта чыгып әйткән идем инде. Үзе ул җыелышта булмаса да, кемнәрнең нәрсә сөйләгәнен аңа җиткергәннәрдер, әлбәттә. Китап турындагы сүз автор колагына барып җитмичә калмый ул.

Ишмөхәммәтов кереш сүзендә үк инде ачыктан-ачык «Тукай — атеист» дип белдерә. Бу сүзнең мәгънәсен яхшы аңласам да, бертөрле дә шик калмасын өчен, русча-татарча сүзлекне ачып карарга булдым. Әйе, дөрес, нәкъ мин аңлаганча бирелгән: «атеист — дингә (Аллага) ышанмаучы, динсез, Алласыз, дәһри»... Тукаебыз әнә шундый кеше икән! Минем өчен бу өр-яңа бер ачыш булса да, артык гаҗәпләнмәдем. Идеология таләпләреннән чыгып, бездә Тукайны төрле вакытта төрлечә бәяләү аз булмады; кайчандыр аны милләтче дип тә, вак буржуа шагыйре дип тә атадылар. Соңгы елларда инде аңа революцион-демократ дигән исем беркетелде. Гомумән, Тукаебызны коммунистик идеологиягә кыскарак тезген белән ныграк бәйләп куярга тырышу һаман үзен сиздереп килде. Ишмөхәммәтовның бу хезмәте дә шуның бер үрнәге түгел микән?

Хуш, мөхтәрәм философ Тукайның атеист (дәһри) булуын нәрсәдән чыгып, ничек итеп нигезли соң? Цитаталарга күчик. «...Күренә ки,— дип яза китап авторы,— марксистик-ленинчыл идеология йогынтысында шагыйрь азатлык җырчысы, хезмәт ияләрен социаль һәм милли изелүдән коткару өчен актив көрәш юлына баскан революцион-демократ булып формалашты. Сыйнфый көрәш логикасы Тукайны социализм идеясенә китерде» (8—9 бит).

Болай булгач, Тукайның атеист икәнлеген исбат итү

бер дә читен булмаска тиеш. Марксизм-ленинизм йогынтысына эләккән кеше ата дәһри инде ул!.. Һәм Ишмөхәммәтов та моны һәрьяклап исбат итәргә тотына: «Ул (ягъни Тукай.— *Ә.Е.*) ислам диненең халык интересларына ят нәрсә икәнен, диннең эксплуататорларга халык аңын томалау коралы булып хезмәт итүен ачып салды, динне сыйнфый һәм милли изүне аклау чарасы итеп файдаланган реакцион көчләрне фаш итте, ислам руханилары белән полиция аппараты арасындагы союзның реакционлыгын күрсәтте. Тукай ислам диненең күп кенә догмаларын, әхлак нормаларын, дини йола һәм бәйрәмнәрен кискен тәнкыйть утына тотты» (66—67 бит).

Җитмәс микән?.. Юк, аккорд рәвешендә тагын бер кыска гына өзек китерик: «Иҗатының соңгы елларында хәзерге диннәрнең төп идеясен — Алла идеясен тәнкыйтьләү югарылыгына күтәрелде»,— дип яза автор... Ягъни мәсәлән, Тукай Алланы инкарь итүче шагыйрь дә икән әле. Хәер, бусы инде үзеннән-үзе дә аңлашыла: атеист бул да, Алланы инкяр итмә, имеш!

Дөресен әйтергә кирәк, Ишмөхәммәтов Тукай иҗатын шактый тирән сөреп чыккан. Тукайга таккан һәр сәяси тезисын ул шагыйрь иҗатыннан күп мисаллар китереп, үзенчә дәлилләп тә бара.

Ә Тукайдан барысын да табарга була. («Күктә ни булмас дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул!») Турыдан-туры атеизм тегерменәнә су коярдайларын да! Тормыштан аерылган кадим мәдрәсәләрдән, кара, надан ишан-муллалардан, комсыз-азгын байлардан әче көлеп яки ачынып язган юллар азмыни аңарда?! Алар барысы да безгә мәгълүм. Тик биредә шуны гына ачыклап үтәсе килә: Тукай атеизмга хезмәт итәрдәй әнә шул шигъри юлларын кем йогынтысына бирелеп язды икән?.. Китап авторы «марксизм-ленинизм йогынтысында» ди. Ләкин минем моңа нигәдер ышанып бетәсем килми. Бик яшьли, бик вакытсыз үлеп киткән шагыйрь Маркс белән Ленин исемен, ихтимал, ишетеп белгәндер, әмма аларның тәгълиматын төннәр утырып «моталәгә кылырга», мөгаен, өлгермәгәндер. Минем фикеремчә, шагыйрьгә иң көчле йогынтыны тормыш үзе ясаган булырга тиеш. Кыска гына гомер, ә нинди ачы язмыш! Бала чагыннан ук күпме «какканны-сукканны» күрмәгән ул!.. Кан төкерсә дә, соңгы сулышына чаклы кулыннан каләмен төшермәгән... Күзе күпне күргән, колагы күпне ишеткән. Шуның өстенә Ходай аңа сизгер акыл, көчле рух та биргән. Аның заманында төрле фикри юнәлешләр, төрле сәяси агымнар күп булса да, ул шуларның берсенә дә иярмичә-тагылмыйча, дөнья

турында фәкать үзенчә уйлаган, үзенчә фикер йөрткән. Барысыннан да өстен торган ул! Ихтимал, шуңа күрәдер дә ул чактагы татар дөньясы бөтен каршылыклары, бөтен якты, караңгы яклары белән үзенең тулы чагылышын аның иҗатында таба да инде. Һәм менә шушы гаять бай әдәби хәзинәдән кемнәр генә хәзер файдаланмый да, кемнәр генә үз максатына хезмәт иттерергә тырышмый?! «Тукай атеизмы» шуның кычкырып торган бер мисалы түгелме?

Тырышкан китап авторы, нык тырышкан! Күп чүпләгән Тукайдан үзенә кирәкне... Шагыйрь иҗатын өстән генә белүчеләрне (әйтик, бөтен шигырьләрен дә укый алмаганнарны) тәмам ышандырырлык. Әмма без беләбез ич, Тукайның Аллага инанып, Аллага сыенып язган шигырьләрен дә. Андыйлары да аның аз түгел ич! Билгеле, китап авторы да аларга күз йомып үтә алмый, теләсә-теләмәсә дә: «Тукай иҗатында дини мотивлар да юк түгел»,— дип әйтергә мәҗбүр була. Хәтта әле, кемнәр беләндер килешкәндәй, «Тукай Аллага ышанган дигән фикер табигый» дип әйтергә дә мәҗбүр... Ләкин шуның артыннан ук ул бу «табигый фикерне» тизрәк кире кагарга да ашыга. Иң элек Тукайдагы дини мотивларның кайдан килүен аңлатып, автор болай дип яза: «Сүз Тукай атеизмының чикләнгәнлеге турында бара. Дини традицияләр йогынтысыннан ул тәмам арынып җитә алмады, дингә карата килешмәүчәнлек принцибын ахырына кадәр эзлекле үткәрмәде, дини идеологиягә ташламалар ясады»... Әмма нидән килә соң Тукайның мондый «принципсызлыгы»? Баксаң, ул, бичара, «эшчеләр сыйныфының тарихи миссиясен, аның пролетариат диктатурасы аша социализмга илтүче сыйнфый көрәшенең асылын тирәнтен аңлый алмаган» икән. Кызганыч, әлбәттә... Ләкин мондый үтә җитди нәрсәләр турында минем философ кеше белән бәхәскә керәсем килми. Бәлки, шулайдыр, бәлки, алай түгелдер, мәгәр шагыйребезне «атеист» дип атаган икән инде, аңардан бик гади бер сорауга ачык кына җавап аласым килә: йә — Тукай Аллага ышанганмы, әллә ышанмаганмы?..

Билгеле ки, бу иң төп сорау һәм җавап та бик төпле, ышандырырлык булырга тиеш. Шуны яхшы аңлап булса кирәк, Ишмөхәммәтов башта К.Марксны үзенә ярдәмгә чакыра. Маркс бабай болай дип әйткән икән: «Атеизм Алланы инкяр итүдән, бу инкяр итү аша кешенең барлыгын раслаудан гыйбарәт». (Бик үк аңлап та җиткермәдем: нигә, Аллага ышанучы кешенең барлыгына ышанмый микәнни?!) Әнә шуңа таянып инде Ишмөхәммәтов

җавап бирергә әзерләнә: «Шушы теоретик положениене,— дип язып китә ул,— критерий итеп алып, без өйрәнелә торган проблеманы ике яклы итеп куябыз: 1) шәхес буларак Тукай Аллага ышанганмы? 2) халык тормышында Алла идеясенең роленә аның карашы?»

Хәзер инде бу куелган сорауларга Тукайның үзеннән җавап бирдерергә дә була. Моның өчен китап авторы шагыйрьнең «Үземнән гыйлавә» дигән ике юллык шигырен китерә:

> Ышандык бер Ходайга, бер вә бардыр, дип, вә ялгыз, дип,
> Сөйли тел: кайнигәч, кайне, кәләш, дип һәм дә балдыз, дип.

Һәм шушы гүя уйнап кына язылган ике юллыктан чыгып, философ иптәш үзенең гаять җитди нәтиҗәсен ясый да инде: «Тукай бу әсәрендә гүяки: әгәр дә мин «Алла» сүзен еш кулланам икән, аны Алла барлыгына ышанганлыктан кулланмыйм, бары тик «кайнигәч», «кайне» сүзләрен кулланган кебек кулланам, ди. Димәк, бу әсәр нигезендә (нинди көчле дәлил! — *Ә.Е.*) Тукай Аллага ышанган дип әйтеп булмый, киресенчә, әсәрдән моңа капма-каршы нәтиҗә килеп чыга» («Тукай атеизмы», 34 бит).

Гафу итегез, әмма мондый нәтиҗә белән килешүе һич кенә дә мөмкин түгел. Бу зур ялган һәм ачыктан-ачык фальсификация!.. Мин, Тукайны кече яшьтән укып үскән кеше буларак, аның Аллага инанып һәм Аллага сыенып язган шигырьләрен күп китерә алыр идем. (Совет заманында җыентыкларына кертелмәгән кайбер шигырьләрен дә хәтерлим әле мин.) Ләкин Ишмөхәммәтов «нәтиҗәсен» юкка чыгарыр өчен шагыйрьнең күпләргә мәгълүм «Васыятем»не искә төшерү дә җитә. Соңгы юлын гына алыйк:

> Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем:
> Күр, нә рәсмә тулган иман берлә Коръән садремә!

Садремә, ягъни күңелемә, ә «әһле тәкфир» дигәне алласыз, динсез дип әйтүчеләрне аңлата; димәк, шагыйрьнең ул сүзләре аны атеист (Алласыз) ясаучыларга каршы турыдан-туры әйтелә. Васыять ул — үләр сәгатен көткән кешенең соңгы сүзе, соңгы теләге, һәм ул, һичшиксез, үтәлергә тиеш. Шуңа күрә дә, Тукайны җирләгәч, Касыйм хәзрәт аның васыятен кабере өстендә кычкырып укый да.

Инде «Васыятем»нән башка Алланы яд итеп язган бик күп шигырьләрен, аеруча балаларга атап язганнарын да искә төшерсәк, Тукайның «атеизмыннан» нәрсә

генә кала?.. Менә мәктәпкә аяк атлап керү белән без ятлый башлаган һәм күмәкләшеп җырлаган «Туган тел»нең соңгы ике юлы:

> И туган тел! Синдә булган иң элек кылган догам:
> Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

Йә, бу юллар бала күңелендә Аллага сыену хисен уятмыймыни?! Яки менә «Васыятем» белән бер елда (1909) басылган «Аллаһе тәбарәкә вә тәгалә» исемле шигырьнең беренче юллары:

> Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
> Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!

Минемчә, бу юлларны шәрехләп торуның һич кирәге юк. Инде уйлап карыйк: үзе Аллага ышанмаган шагыйрь балаларны ышанырга өндәп шигырь яза алыр идеме? Бигрәк тә һәртөрле яраклашудан өстен торган Тукай?.. Әгәр без бер генә минутка Ишмөхәммәтов нәтиҗәсе белән килешсәк, Тукаебыз кем — сабыйларны да алдый алучы икейөзле, бик түбән бер кеше булып чыга түгелме соң?! Бу бит бөек Тукайны соң дәрәҗәдә хакарәтләү була лабаса!.. Китап авторы әзрәк шуны уйлый белде микән?

Ләкин аның, бик гайрәтләнеп, бездән шагыйрьнең дингә, муллаларга, байларга каршы язган ачы тәнкыйтьләрен кая куясыз, дип соравы мөмкин. Әйе, Тукайда күп алары да һәм берәү дә моны инкяр итәргә җыенмый... Тукай бит ул татар халкының көчле уяну вакытында мәйданга күтәрелеп чыккан һәм милли азатлык белән социаль гаделлекне үзенең иҗатында бик нык үрә белгән шагыйрь. Әмма аның тәнкыйть сүзләре, Ишмөхәммәтов язганча, «Урал» үрнәгендә диннең капиталга хезмәт итүен яхшы аңлауданмы, әллә булмаса искелекнең, наданлыкның милли прогресска киртә булып торуын җимерергә теләүдәнме туганнар?.. Миңа калса, соңгысы дөресрәк булырга тиеш. Чөнки, беренчедән, бик кыска гомерле «Урал» гәзитәсенең Тукайга нииндидер җитди йогынты ясавына ышануы читен; икенчедән — бусы иң мөһиме — Алланы яд иткән шигырьләренең бик күбесе «Урал»дан соң язылганнар. Шулай булгач, нинди үрнәк, нинди йогынты турында сүз булырга мөмкин?..

Аннары ул заманның алдынгы әдипләре искелек тарафдарларын аз тәнкыйть иткәннәрмени, мәгәр берәү дә бит аларны «Алласызлар» дип игълан итәргә ашыкмый. Ни өчен әле бер Тукайга гына мондый мәртәбә?.. Чөнки Тукай ул — татар халкының аңында һәм йөрәгендә сакланып килгән иң якын, иң кадерле зат иясе. Менә ни

өчен аны безнең коммунистик идеологиягә ныграк бәйләү кирәк тә булган. Әмма бер шарт белән — революцион-демократ булу өстенә, ул әле атеист та булырга тиеш!

Тик шулай да күрәләтә ялганга бару нигә кирәк иде? Нигә Тукайның рухи халәтенә саграк килеп, аны тирәнрәк аңларга тырышып карамаска? Кешенең рухи дөньясы бик катлаулы, бик серле, кайчагында ул үзе дә аңлап бетерә алмый аны... Чынлап та, «Болгар»ның тар бүлмәсендә яткан, мәчетләргә йөрмәгән, мәгәр Коръәнне укырга яраткан, кайбер хәрәм эшләрдән дә тыела белмәгән хөрлек сөюче Тукай шулай да ни өчен әле Аллага инанган, Аллага сыенган? Моңа җавапны, бәлки, аның ачы язмышыннан — ятимлегеннән, ялгызлыгыннан, әҗәленә тигән авырудан эзләргә кирәктер. Ни үкенеч, шундый иртә ачылган даһилык, тумыштан ук гарше әгъляләргә җилкенгән күңел, ә япь-яшь көенә аны нинди тәкъдир көтә?.. Караңгы салкын кабер... Мондый хәлдә ничек итеп ул изге бер кодрәт иясенә сыенмасын, шуңардан үзенә юаныч өмет итмәсен ди?!

Тукайның «Васыятем» белән бер айда «Әлислах»ның бер үк санында басылган «Күңел» шигырен генә алып карагыз. Бу ике шигырь арасында шагыйрьнең шул чактагы рухи хәлен аңлаткан тирән уртаклык бар.

> Инкисар ит гадәтеңчә, ян, күңел, сызлан, күңел!
> Күп сөекледер бөтеннән — Тәңрегә сыенган күңел,

— дип башлана ул... Күрәсез, бер үк вакытта язылган ике шигырендә дә Тукай үзенең Тәңрегә инанганын һәм сыенганын ачыктан-ачык әйтеп тора. Йә, тагын ни кирәк? Мисалларның китерелгән кадәресе дә җитәр шикелле — калганын һәркем үзе дә табып укый ала. Монда иң мөһиме, Тукайдан идеология эзләү белән генә чикләнмичә, аның рухи халәтен тоя-аңлый белү дә кирәк. Шул чакта гына чын хакыйкатьне дөрес чамалап булачак.

Болар барысы да фәлсәфә укытучысы Ишмөхәммәтовның китабын укыгач, табигый рәвештә үзеннән-үзе күңелемдә туган уйлар. Кабатлап әйтәм, сүз 1971 елда чыккан китап турында бара. Әмма ләкин югарыда изһар ителгән уйларым, гәрчә егерме елдан соң язылса да, турыдан-туры шул чактагы кичерешләрем белән бик нык бәйләнгән... Дөресен әйтим, ул кичерешләр миңа бер дә тынгы бирмәделәр. Бездә бит тарих һәм әдәбият өлкәсендәге «фәнни хезмәтләр»дә ялган — фальсификация белән шөгыльләнү аз булмады. Ахырда менә Тукайны, чүт ли большевикка әйләндереп, Алланы инкяр итүче

дәһри дә ясадык. Йә, бу да оят белмәгән әрсез ялган түгелмени?!

Билгеле, мондый ялган белән килешеп, дәшми калуны акыл да, намус та күтәрә алмый иде. Ничектер — языпмы, сөйләпме — мин үз сүземне әйтергә тиеш идем. Шунсыз күңел һич тә тынычлана алмас кебек иде. Мәгәр матбугатка ышаныч аз. Идеология сагында торучыларның миңа сүз бирүләре бик икеле... Һәм мин сүземне язучылар җыелышында әйтергә булдым. Тукаебызга кагылган шундый нечкә мәсьәлә, минем уемча, аларны, һичшиксез, кызыксындырырга тиеш иде.

Җыелыш, башта әйткәнемчә, 1971 елның җәендә, дөресрәге, август аенда булды шикелле — шулайрак хәтеремдә калган[1]. Тукай клубында халык шактый иде — «Аккош күле»ндә һәм үз дачаларында ял итүчеләр дә килгәннәр иде. Җыелышның нинди уңай белән чакырылганын хәзер инде хәтерли алмыйм, ләкин башта ук әзерләнеп килгән чыгышымның көн тәртибенә сыйганын яхшы хәтерлим. Чөнки бу мине борчып торган мәсьәлә иде. Чыгыш ясарга яраганлыгын белгәч тә, мин сүз сорап, президиумга записка да җибәрдем. Һәм ни хикмәттер, миңа сүзне озакламый бирделәр дә.

Тагын шуны да әйтергә кирәктер: ул елларда әле минем үз замандашларымның да һәм үземнән өлкәннәрнең дә бик күбесе исән-саулар иде. Алар алдына чыгып сөйләвем беренче генә түгел, яхшы беләләр мине, шулай ук төрлесе төрлечә уйлыйлар да минем хакта. Без кичергән чорыбыз өчен бу бик табигый хәл иде... Менә мин яңадан шул замандашларым алдында.

...Минем кулымда чыгышымның алдан әзерләп килгән кыскача гына тезисы бар иде. Шуның буенча мин өч мәсьәләгә тукталырга тиеш идем: 1) Аллага мөнәсәбәт. 2) Дингә мөнәсәбәт. 3) Дин әһелләренә мөнәсәбәт.

Билгеле инде, 10—15 минутлык чыгышта әйтәсе килгәннәрнең барысын да әйтеп бетереп булмый; шул ук кулдагы тезис буенча гына да барып булмый — аны бер читкә куеп, тизрәк башыңа килгәнне әйтеп калырга ашыгасың... Сөйләү осталыгы да мактанырлык түгел, тотлыгам, кабаланам, сузып сөйлим. Вакытны да һич чамалап булмый, шуңадыр, ахрысы, минем алдыма: «Әмирхан абый, бәлки, җыйнаклый төшәрсез»,— дигән записканы да тиздән китереп салдылар. Мәгәр монысы вакытны күп алудан гына түгел иде шикелле...

---

[1] Җыелыш протоколын эзләтеп карасам да, хәзергә әле ул табылмады. — *Ә.Е.*

Хуш, нәрсә әйтеп өлгердем мин?.. Әгәр моны искә төшерә башласам, моңарчы язганнарны яңадан кабатларга туры килер иде. Төп максат исә минем Тукайның Аллага ышанган шагыйрь булуын исбат итәргә тырышу иде. Калган ике мәсьәлә буенча мин китап авторы белән зур бәхәскә кереп тә тормадым. Әйе, дидем мин, Тукай дини хорафатларны, реакцион дин әһелләрен күп тәнкыйть иткән, ләкин нинди караштан чыгып — автор язганча, диннең капиталга хезмәт итүен нәкъ большевикларча аңлапмы, әллә булмаса көчле уяну чорын кичергән татар халкының тәрәккыятенә комачаулык итүчеләрне, һаман да искелеккә тартучыларны фаш итү максаты беләнме — бу икенче мәсьәлә, моны һәркем үзенчә аңлата ала. Әмма дә динне, муллаларны тәнкыйть итү — ул әле Алладан ваз кичү түгел. Дини догмаларны тәнкыйть итеп тә, Аллага ышанучылар тарихта аз булмаган. Тукай яшәгән заманда моның бик ачык үрнәге — Лев Толстой. Шушы бөек зат гомере буенча диярлек рәсми чиркәүне һәм аның иң югары әһелләрен рәхимсез тәнкыйть итеп килде. Шуның өчен аны, бәддога укып, чиркәүдән аердылар. Әмма Толстой соңгы сулышына кадәр Аллага беткәнче ышанган кеше булып калды. Һәм берәүнең дә башына аны атеист итү кебек тузга язмаган уй килмәячәк.

Ә ни өчен әле без Тукаебызны ансат кына атеистка, ягъни Алласызга әйләндерәбез? Шул ук Толстойга Тукайның мөнәсәбәте үзе генә дә безгә аны дөресрәк аңларга ярдәм итмимени? Бөек философ-әдипнең тирән мәгънәле аерым фикерләрен шигырьгә салган Тукай аның үлү хәбәрен, ниһаять, ишеткәч, «Русиянең мөхтәрәм мөхәррирләреннән тезелгән мөбарәк тәсбихның очындагы бисмилласы, Мәрьям анасы яки имамы өзелде»,— дип язды түгелме соң? Алласыз кеше бу очракта дини төшенчәләрне шулай рәттән кулланып язар идемени?..

Безнең шагыйрьнең Аллага инануын, Аллага сыенуын бик күп шигъри юллары, бигрәк тә балаларга атап язган шигырьләре ачыктан-ачык әйтеп торалар ич!.. Һәм мин кире кагуы мөмкин булмаган дәлилләр рәвешендә, вакытка сыйган кадәр, аның «Васыятем»ен дә, балалар өчен язылганнарын да укып күрсәттем. Иң ахырдан Ленинның «правда не должна зависеть от того, кому она должна служить» дигән сүзләренә таянып, мин Тукайга карата да бертөрле дә, аз гына да ялган булмаска тиеш, дидем.

...Сүземне тәмамлагач, сәхнәдән төшеп, үз урыныма барып утырдым. Дулкынлануым көчле булган икән, һа-

ман үземне тынычландыра алмыйм, хәтта бер теземнең сикергәләп куюын да тыя алмыйм. Ә залның реакциясе нинди, бармы ул?.. Халык никтер тик кенә, тын гына утыра. Президиумда да хәрәкәт сизелми. Бу хәл миндә гаҗәпләнү катыш ниндидер бер ямьсез шик тудырды: мин сөйләгәннәрнең аз гына да тәэсире булмады микәнни? Сүз бит Тукай турында, нинди дә булса бер реакция уятырга тиештер бит инде ул! Ләкин ни өчен бөтенесендә дә мондый салкын битарафлык?.. Янәшәмдә утыручылар да гүя шул битарафлыкны бозмас өчен таш сындай селкенмиләр дә...

...Президиумга карыйм. Анда кимендә биш-алты кеше утыра. Хәзер инде мин шуларның икесен генә хәтерлим: урта бер җирдә, өстәлгә кулларын җәеп салып, туп-туры залга карап, Гариф Ахун утыра; өстәл очында, аз гына читтәрәк, үзен кочаклагандай беләкләрен тотып, авыр башын ия төшеп, алдына гына карап Хәсән абзый Туфан утырган... Ниләр уйлый икән аның чал башы?!

Күпмедер авыр тынлыктан соң президиумда утыручылардан кемдер берәү, ниһаять, торып сүз башлады. Кем иде соң ул? Һич кенә дә бит исемә төшерә алмыйм. Гариф Ахун түгел иде микән? Аның сөйләгәнен хәтерлим, ләкин беренче булыпмы — тәгаен генә әйтә алмыйм... Кызганычка каршы, мин җыелышлардагы чыгышларны язып барырга өйрәнмәгәнмен, ә 20 елдан соң барысын да төгәл искә төшерү мөмкин түгел икән. Әмма бер нәрсәне бик ачык итеп әйтә алам, ул җыелышта башлап сөйләүченең дә, аңардан соң чыгучыларның да әйткәннәре барысыныкы да бертөсле булды: Тукайның Аллага ышануын исбат итеп маташу нигә кирәк әле? Тукай безнең өчен Аллага ышануы белән кадерлемени?.. Шуның белән бөекмени ул? Һәм, гомумән, Тукай иҗатының дини ягына игътибарны туплауны берничек тә аклап булмый. Кыскасы, Еникинең бүгенге чыгышы урынсыз һәм кирәксез бер чыгыш, иптәшләр!

Ахырдан гына Хәсән абзый да торып сөйләде. Тукайны бик яхшы белүче һәм бик яратучы дәшми калуны килештермәгәндер инде. Аның нәрсә әйтәсен көтеп утыручылар да булгандыр — ул шуны да, ихтимал, сизгәндер... Дөресен генә әйткәндә, аның хәле шактый четерекле иде — мин моны сөйли башлавы белән үк сизеп алдым. Нәрсә диде ул безнең күп газап кичергән шагыйребез?

— Тукайның бит «Васыятем»еннән башка «Мөхәрриргә» дигән шигыре дә бар ич!.. Без әнә шуны күбрәк

истә тотарга тиешбез — дини рухтагыларын түгел, ә гражданлык рухындагыларын...

Менә аның китергән мисалы һәм әйткән фикере шул. (Билгеле, мин монда төп мәгънәсен генә китердем.) Мәгәр Тукайның «Мөхәрриргә» дигән шигыре турыдан-туры Гаяз Исхакыйга атап язылганын Хәсән абзый белергә тиеш иде. Чөнки моннан берничә ел элек кенә Ташкенттан Казанга килеп киткән, кайчандыр Гаязга бик якын торган Шакир карт Мөхәммәдъяров Хәсән абзый бүлмәсендә сөйләшеп утырганда (Маяковскийда торган чагында), безнең икебезгә ул шигырьнең махсус Исхакыйга атап язгылганын, һәр юлын укый-укый, бик әйбәт аңлатып биргән иде. Онытты микәнни, әллә онытмаса да кыюлыгы җиттеме?.. Шигырьнең бит кемгә атап язылганы Тукай томнарындагы искәрмәләрдә юк. Шулай булгач, җыелышта утыручыларның да бик күбесе аны белми торганнардыр — инде белсәләр дә, Хәсән абзыйга берәр төрле гаеп ташлау мөмкин булмас иде. Чөнки Тукайның һәр җыентыгына кергән шигырен Гаяз Исхакый исеме белән бәйләү үзе гаять зур гаептән саналыр иде... Хәлбуки ул шулай; охранка күзәтүе аркасында күп вакытын читтә үткәрергә мәҗбүр булган мәшһүр мөхәррирне Тукай чакырып-дәшеп яза:

И мөхәррир! Кайсына биргән яшен күз кибриа!
И мосаувир! Кемгә биргән пакь вә чын сүз кибриа!

Кайт әле монда Ватанга, кайт әле, саргайтмәле!
Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия!

Җанлырак тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,
Бер-берен чәйни бишенче елдагы күп әүлия[1].

Алты ел торды чупансыз, айрылышты яшь көтү;
Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя.

«Ул Гомәрдән курка шайтаннар» дигән төсле рәсүл,
Бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя...

Гаҗәеп шигырь!.. Нинди тирән хөрмәт һәм өмет булган Тукайда Гаяз Исхакыйга карата!.. Хәзер инде бу исбат ителгән бәхәссез хакыйкать.

Ярый булмаса, яңадан Тукай клубындагы җыелышка кайтыйк әле... Күрдегез инде, бөтен сөйләүчеләрнең дә минем чыгышка мөнәсәбәте бертөсле булды: нигә кирәк, ни әһәмияте бар, урынсыз чыгыш!.. Миңа кушылу-

[1] Бу юллар безнең хәзерге заманга да гаҗәп туры киләләр; кичәге коммунист җитәкчеләр бүген бер-берсен чәйнәмиләрмени?! — *Ә.Е.*

чы, һич югы, мине аңларга тырышучы берәү дә булмады. Тулы бердәмлек! Йа Хода, дип сыкранып утырам, сүз бит Тукайның Аллага ышануын аклау турында бармый, ә бәлки бөек шагыйрь турында бары тик саф дөресен язу кирәклеге турында бара. Неужели шуны аерып булмый, бик ачык әйттем ләбаса!.. Юк, хикмәт монда мине аңламауда түгел шикелле. Төп сәбәп тирәндәрәк ята булса кирәк, чөнки берәү дә минем белән килешмичә, Тукай, әлбәттә, Аллага ышанмаган, дип әйтмәде. Шулай ук мине чыгып сөйләргә мәҗбүр иткән китап турында да ләммим!.. Әллә берсе дә күрмәгән-укымаган, әллә инде Тукайны марксист итәргә тырышучы галимгә каршы чыгуны кирәк тапмаган?! Гаҗәп түгел... Уяулык белән саклык безнең гамәлләрдә ул чакта һәрвакытта алдан йөри — без моңа күптән өйрәнеп беткән идек инде.

Шулай итеп, мин, дөреслекне яклыйм дип, башыма бер дә кирәкмәгән авыр газап алдым. Җыелыштан рухи кыйналып, тәмам ватылып кайттым. Икенче көнне нәшриятта эшләүче шагыйрьдән, дачада очрашкач, юри генә:

— Йә, кичәге җыелыш синдә нинди тәэсир калдырды,— дип сораган идем, ул чыраен сыта биреп, бер генә сүз белән:

— Кызганыч! — диде.

— Нәрсә... кызганыч?

— Сезнең чыгышыгыз.

Шулай ук та мыни әле?! Бу инде чөй өстенә тукмак булып төште... Һәм мин берничә көннәр буена һаман бер нәрсәне уйлап баш ваттым: хатам минем нәрсәдә, кайсы ягы белән чыгышым кешеләргә бу хәтле ошамады икән?.. Әйтергә теләгән фикеремнең дөреслегендә бөртек тә шигем юк. Алайса, хикмәт нәрсәдә?.. Бәлки, чыгышымда акцентларны дөрес куя белмәгәнмендер?.. Моның әһәмияте зур, кешеләр бит сүзеңә карап кына түгел, ничегрәк итеп әйтүеңә карап та хөкем итәләр... Бәлки, Тукайның томнарына кермәгән шигырьләрен укуым да күпләргә ошап бетмәгәндер. Нәтиҗәдә Тукай берьяклырак — артык динлерәк килеп чыккандыр... Моны яратмаулары бик мөмкин.

Әмма ләкин эшнең асылы минем ничек сөйләүдәмени, мин күтәреп чыккан мәсьәләдә түгелмени?! Сүз нигә шул хакта бармый, нигә барысы да бер балык башын чәйни — кирәкми, ярамый, имеш!.. Бу бит төп мәсьәләдән качу!.. Йә, кем кызганыч — алармы, минме?!

Әнә шулай күпме генә баш ватсам да, төрлечә уйлап, күпме генә үземне газапласам да, акылым минем, ком-

пас теле шикелле чайкала-чайкала да, һаман бер юнәлеш ноктасына килеп төртелә: кем хаклы — минме, әллә теге, кем үзе, философ иптәшме?.. Менә шуны кемнәндер әйттерәсем килә. Әйдә, ул кем дигәнем, миңа каршы сөйләүчеләрнең күбесе шикелле үк, коммунист булсын, идеологиясе дә бик төзек булсын, тик Тукайны яхшы белсен дә, дөресен әйтүдән курыкмасын!.. Һәм ничектер үзеннән-үзе минем исемә кылт итеп Сәйфи агай Кудаш килеп төште. Гаҗәп тә түгел, чөнки ул — читтә яшәүче, бездәге хәлләргә бертөрле дә мөнәсәбәте юк, димәк, аңа чын үз фикерен әйтү бер дә читен булмаячак. Аннары иң мөһиме — ул исәннәр арасында иң карт шагыйрь, Тукайның замандашы диярлек, Тукай иҗатын энәсеннән җебенә чаклы белүче дә... Менә кемгә мөрәҗәгать итәргә кирәк, дидем мин бер дә икеләнмичә.

Мәгәр мөрәҗәгать хатымны Сәйфи агайга ни өчендер 3 октябрьдә генә җибәргәнмен. Күрәсең, уйланып йөрү дә һәм утырып язу да бик озакка сузылган. (Гадәтем шундый — уйлаганны тиз генә әйләндереп сала белмим.) Кызганычка каршы, хатның күчермәсен үземдә калдырмаганмын, ничегрәк, нинди сүзләр белән язылгандыр инде ул — хәзер, билгеле, исемә төшерә алмыйм. Сәйфи агайда сакланса, дөньяга, бәлки, бер килеп тә чыгар әле.

Билгеле, мин хатыма җавапны ышанып көттем, чөнки моңа кадәр дә аңа язган хатларым бервакытта да җавапсыз калмый иде. Сәйфи агайның, хат язу минем өчен иҗат эше ул, дип әйткәне дә бар иде. Ә монда Тукай мәсьәләсе! — картны ул, һичшиксез, кузгатырга тиеш иде.

...Һәм менә аның 15 октябрь куелган 34 битлек хаты озакламый миңа килеп тә җитте. Гаҗәеп бер хат бу!.. Иң элек минем хатым Сәйфи агайның бик борчулы һәм мәшәкатьле чагына туры килгән. Җәмәгате Мәгъфүрә апа каты авырып киткән булган. Сәйфи агай көне-төне диярлек авыру карчыгын карау-дәвалау хәстәренә керешкән. Мондый чакта каяндыр, кемнәндер килгән хатны онытып тору да бер дә гаеп булмас иде. Ләкин кайгысы-мәшәкате нихәтле генә зур булуга карамастан, Сәйфи агай минем хатны бер генә минут та онытып тора алмаган. «Чөнки Тукай мәсьәләсе безнең үз язмышыбыз. Тукай — халкыбызның вөҗданы, намусы һәм иманы! Шуңар күрә мин мондый вакыйгаларга тамашачы булып кына кала алмыйм»,— дип яза ул җавап хатының башында ук. Әйе, минем мөрәҗәгать хатым карт шагыйрьне чын-чынлап дулкынланырга мәҗбүр иткән икән; «Әгәр

дә дулкынланмасам, бу хатны язарга кулга каләм дә алмаган булыр идем мин»,— ди ул үзе дә. Һәм бераздан янә өстәп яза: «Синең хатыңны укыгач, мин башка эшләрне баштан чыгардым. Тик Мәгъфүрәнең генә кәефе начарланмасын! Мине хәзер ике нәрсә биләп алды: Тукай һәм аның намусын, сафлыгын һәм дөреслеген яклаган өчен әрләнгән Әмирхан Еникиев дигән язучы биләп алды». (Җәя эчендә генә шуны да әйтеп узыйм: күптән түгел Казаннан килеп киткән, миңа һәрвакыт тискәре караган бер әйбәт шагыйрь: «Без әле үзебездә Әмирхан Еникине тәмам зур иттек»,— дип сөйләнеп йөргән. Бу хәбәр дә, хаттан күренгәнчә, Сәйфи агайның колагына килеп кергән икән.)

Әнә шул рәвешчә кайгысы зур чакта, эш-мәшәкатьләр арасында Сәйфи агай, ирексездән күңелендә туганнарын ак кәгазьгә салыр өчен, үзенең 34 битлек хатын язарга керешә дә инде. Билгеле, мондый озын хатны ул берничә көннәр буена, бүленә-бүленә, хәтта бер кичне дачасына китеп, ялгызы Тукай рәсеме каршысына утырып та яза. Хатның эчтәлеге гаять бай: Тукайның үзе, иҗаты, яшәгән заманы, шулай ук аның исеме тирәсендә төрле заманда булып узган бәхәс-карашлар турында, аннары Сәйфи агайның Тукайга шәхсән үз мөнәсәбәте турында да бик иртә Тәңресенә юнәлгән үксез-ялгыз шагыйребезгә карата әрнүле, тирән йөрәк җылысы белән бик тәфсилле итеп язылган... Әмма мин, бик теләсәм дә, бу хатны иясе исән чакта, аның рөхсәтеннән башка дөньяга чыгара алмыйм. Иске әлифбада кулдан язылган хатның күчермәсен машинкада бастырып, Сәйфи агайның үзенә җибәргән идем, иншалла, дөньяга бер чыкмыйча калмас дип ышанам.

Хәзер исә мин үзем кузгаткан мәсьәләгә ачык җавап булырдай урыннарын күчерү белән генә чикләнәм. Иң элек Сәйфи агай «Тукайның дини хискә сугарылган һәм Алла кодрәте алдында баш игән шигырьләрен»нән күп кенә аерым юлларны тезеп чыга. 32 шигырьдән ул, махсус сайлап тормыйча, бары күзенә ташланганнарын гына күчереп алган. Һәм бу шигырьләр барысы да бишенче елдан соң, «Урал»да чыгуыннан туктагач, 1908 белән 1913 еллар арасында (үлгән көненә кадәр) язылганнар. Ягъни алар Тукайның шагыйрь һәм акыл иясе буларак тәмам җитлеккән, фикри хөрлеккә ирешкән чагына туры киләләр.

Сәйфи агай әлеге шигъри юлларны китергәннән соң, менә нинди нәтиҗә ясый: «Тукайның халык күпчелеге

тарафыннан шулай бик тиз танылуын, сөелүен һәм табыныр дәрәҗәдә культка әйләнүен мин үзем шушы рухтагы шигырьләрнең катнашуыннан башка күз алдына да, акыл капкасы төбенә дә китерә алмыйм».

Янә болай диеп тә яза: «Әгәр дә Тукай шушы шигырьләрен язмаган булса, киң халык катламы аны ул чакта шулай кабул итмәгән һәм йөрәк кәгъбәсенең түренә утыртып та куя алмаган булыр иде!» Димәк, Сәйфи агай Тукайның халык шагыйре булып танылуын турыдан-туры дини рухтагы шигырьләре белән дә бәйләп карый.

Шулай да Тукайның андый рухтагы шигырьләрен халык ни өчен шулкадәр яраткан, күңеленең түрендә саклаган, күбесен яттан белгән — бигрәк тә балаларга атап язганнарын?.. Моның сере нәрсәдә?..

Сәйфи агай моны болай аңлата: «Алар (ягъни ул шигырьләр) дини, илаһи булулары белән түгел, бәлки, балаларда сафлык, пакьлек, тугрылык, аңлылык, туганлык, кешелеклелек, намуслылык һәм ата-анага, олыларга хөрмәт итү тойгылары тәрбияләүләре белән әһәмиятлеләр»... Һәм бу аңлату белән килешмичә һич мөмкин түгел — кайсыбыз гына бала чагыбызда Тәңрене даими исебезгә төшерүче Тукай абыебыздан әхлак сабагы алмадык соң?!

Сәйфи агай хатыннан мин тагын бик күп өзекләр китерә алыр идем, ләкин чикләнергә мәҗбүрмен. Хат Тукайның Аллага, дингә мөнәсәбәтенең бик күп якларына кагыла, бик күбесен үзенчә аңлата, ләкин боларның барысы белән дә танышыр өчен хатның үзен укып чыгу кирәк. Әйткәнемчә, киләчәктә мондый мөмкинлек, һичшиксез, туар.

Инде монда китерелгән кадәресе безне кызыксындырган мәсьәләгә, минемчә, тулы ачыклык кертте: Сәйфи агай да Тукайның Аллага инанган һәм сыенган шагыйрь булуын раслый, шуны күп дәлилләр белән исбат итә. Янә иң мөһиме — Сәйфи агай хатын укыганнан соң, мин Тукайның Аллага мөнәсәбәтен тагы да тирәнрәк аңлагандай булдым. Татар халкы бит күпме гасырлар буена Аллага инанып яшәгән, авыр язмышын да, киләчәккә ышанычын да Аллага баглаган һәм бу аның какшамас иманына әверелгән. Менә шуны бик яхшы белгән, бөтен барлыгы белән тойган Тукай да, билгеле инде, халыкның иманына тугрылыклы булып калган. Әмма бу иман аңа үз заманының иң алдынгы фикер иясе булырга, халыкның аңын томалап торган бөтен ис-

келекне, динне кәсепкә әйләндерүне, наданлыкны, түбәнлекне, бозыклыкны кодрәтле каләме белән көйдерергә һич тә комачаулык итмәгән. Ул бит чын мәгънәсендә милли азатлык, социаль гаделлек, рухи тазалык җырчысы иде.

Сәйфи агай хаты минем хаклы булуымны раславы белән күңелемне тынычландырса да, мин әле һаман да башымнан кичкән хәл турында гаҗәпләнеп уйланудан туктый алмый идем. Әлеге җыелышта утыручыларның күбесе, бигрәк тә өлкән яшьтәгеләре, Тукай иҗатын Сәйфи агайдан ким белми торганнардыр лабаса. Бәлки әле Тукайның Аллага мөнәсәбәтен дә нәкъ аныңча аңлый торганнардыр. Ләкин ни өчен соң алар Сәйфи агай кебек чын уйларын әйтергә теләмичә, барысы да миңа каршы чыктылар? Кайда, нәрсәдә моның төп сәбәбе? Һәрхәлдә, Тукайны Алласыз дәһри дип тануда түгелдер инде. (Берәү дә бит ачыктан-ачык алай дип әйтмәде.) Төп сәбәп — чын хакыйкатьне белеп торган хәлдә, аны икърар итәсе килмәүдә түгел микән?.. Без бит үзебез өчен уңайсыз, әйтик, намусыбызга кагыла торган дөреслекне күрмәмешкә салынырга күптән өйрәндек.

Гаҗәп, кайчагында без гади генә нәрсәне дә аңлый алмыйча җәфаланабыз. Менә минем белән дә шулай булды. Туктале, мин әйтәм, җыелышта утыручыларның һәммәсе дә алласызлар ич! Җитмеш-сиксән проценты коммунистлар, болар инде ата дәһриләр... Башкача булуы мөмкин дә түгел. Чөнки большевиклар властьны тартып алган көннән башлап, без халыкны диннән, Алладан биздерү шартларында яшәп киләбез. Динне, дин әһелләрен төрлечә кысу, чикләү һәм хурлау большевикларның көндәлек сәясәтенә әйләнде. Ахыр чиктә, бөтен җирдә мәчетләрне ябып, муллаларын сөреп яки үтереп бетерделәр. Билгеле, бу барлык диннәргә карата да шулай эшләнде. Бөтен империя күләмендә дин корытылды, бары кайбер җирләрдә генә аның зәгыйфь учаклары сакланып калды. Советлар Союзы тоташы белән диярлек алласызлар иленә әверелде.

Инде язучыларга килсәк, алар бит нәә шул дәһрилекне (фәнчә әйтсәк, атеизмны) рәсми сәясәткә әйләндергән коммунистик идеяләргә бил бөгеп хезмәт итүчеләр. Бәс, шулай булгач, совет язучысының Аллага ышануы асла мөмкин түгел. Теләсә-теләмәсә дә, ул Алладан ваз кичәргә тиеш. Безнең берише картрак әдипләребез исә, кайчандыр шәкерт чакларында тәһарәт алып мәчеткә йөрүләренә карамастан, революция булу белән үк диннән һәм Алладан тизрәк ваз кичтеләр. Күрәсең, алар моны

үзенә күрә бер рухи азатлык дип кабул иттеләр. Һәм шул «шатлыктан» динне корытуда шактый активлык та күрсәтеп өлгерделәр. (Моның өчен ул елларда язган әсәрләрен искә төшерү дә җитә.)

Минем яшьтәгеләргә исә дин йогынтысы бик аз тиде. Мәктәпләрдә дин сабагы укыту бетерелде. Мин үзем, мәсәлән, динне ике генә кыш укып калдым. Аннары безнең яшьлек комсомол көчәеп киткән вакытларга туры килде. Ә комсомол булып йөрүчеләр өчен агрессив дәһрилек зур җегетлектән санала иде.

Шуннан совет чорында дөньяга килеп, сугыштан соң әдәбиятка аяк баскан яшьләрне алсак, алар инде тумыштан ук дәһриләр. Чөнки күбесенең ата-аналары алласыз, ягъни атадан балага күчкән дәһрилек. Кайчандыр Аллага ышану буыннан буынга күчеп килгән булса, безнең нисбәттән бик кыска совет чорында да алласызлык шундый ук күренешкә әйләнде, дияргә ярый.

Инде Тукайга мөнәсәбәт мәсьәләсенә килгәндә, безнең алласыз язучыларыбыз һәммәсе дә аны халкыбызның иң сөекле бөек шагыйре дип таныйлар, аның даһилыгы алдында берсүзсез баш ияләр. Бу инде бәхәссез хакыйкать!

Һәм менә мин, алар шикелле үк күптән Алланы оныткан бер язучы, Тукай мәсьәләсендә аларның объектив гадел хөкемнәренә ышанып, Тукай атеист (ягъни Алланы инкяр итүче) дигән ялганга каршы чыгуны шулай да кирәк таптым. Һәм мөхтәрәм язучыларның минем чыгышны ничек, нинди канәгатьсезлек белән каршы алуларын сез күрдегез инде.

Ничек кенә аңларга соң бу һич көтелмәгән феноменны?.. Озак газаплы уйланудан соң, мин ахырда шундый нәтиҗәгә килергә мәҗбүр булдым: күрәсең, Тукайның Аллага ышануын исләренә төшерүне алар үз вөҗданнарына кагылу, үз намусларына тукыну шикеллерәк кабул иттеләр. Чыннан да, Тукайның Алланы инкяр итмәвен исбатлап тору, бигрәк тә дини шигырьләрен укып күрсәтү, аларга нигә кирәк? Болай да беләләр ич! Ә менә Ишмөхәммәтов язганча, Тукай, чынлап та, алласыз дәһри булса, аларның җаннары тынычрак булыр иде... Әнә шул рәвешчә, моннан егерме ел элек мөхтәрәм язучыларыбыз җан тынычлыгын саклау өчен һәм безне тәмам биләп алган рәсми идеология хакына, Тукай турындагы ялганны, теләпме-теләмичәме, күмәкләшеп якларга мәҗбүр булдылар. Дөреслектән качуны мин башкача аңлый да алмыйм, аңлата да алмыйм.

*«Казан утлары», 1992, 4 сан*

## ПРЕЗИДЕНТ МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВКӘ ЯЗУЧЫ ӘМИРХАН ЕНИКИДӘН АЧЫК ХАТ

Мөхтәрәм Минтимер Шәрипович!

Сезгә бик мәгълүмдер ки, без бик авыр, бик хәвефле бер заманда яшибез. Халыкның абсолют күпчелеге бик интегә, киләчәге өчен курка, өзлексез борчыла, сабырсызлана, мәгәр тешен кысып булса да сабыр итәргә, түзәргә тырыша. Мондый шартларда Сезнең кул астындагы идарә органнарының халыкка кагыла торган һәр эше, һәр адымы бик нык уйланган, һәръяклап үлчәнгән булырга тиештер инде.

Мин илебез һәм халкыбыз язмышы турында шулай ук борчылып яшәүче бер язучы буларак, Сезнең җитәкчелек дилбегәсен кулыгызга алган көннән башлап, Татарстаныбызның киләчәге, иминлеге, тынычлыгы һәм туклыгы өчен сайлаган юлыгызны һәм шул юлдан уңгасулга тайпылмыйча баруыгызны бик хаклы санап, үземнең телдән сөйләгән яки язма чыгышларымда һәрвакыт аклап вә яклап килдем. Мәгәр мин, һәртөрле идарә итүчеләрдән бик читтә торганга күрә, Сезнең катлаулы һәм күпьяклы дәүләт эшләрен гамәлдә ничек үтәп баруыгызны, әлбәттә, белмим. Ихтимал, әнә шул идарә итүчеләр кайбер «вак» мәсьәләләрне Сезне борчымас өчен үзләре генә хәл итеп куя торганнардыр. Әмма кем генә, ничек кенә хәл итмәсен, халык аны барыбер Сезнең исемегез белән бәйли, Президент рөхсәте белән ул шулай эшләнгән дип саный.

Яхшы эш икән, Сезгә үк рәхмәтен әйтә, ә яманы өчен... ни әйткәннәрен ишетмичә калмыйсыздыр. Кыскасы, Минтимер Шәрипович, илдә ниләр генә эшләнмәсен, һәммәсе дә Президент әйбәт, Президент начар! Хәлбуки киртәсеннән тәмам чыккан тормышны аңлаудан гаҗиз халыкның кәефен бозар өчен сәбәпләр көн саен туып кына тора.

Шушы уңай белән мин Сезнең идарәчеләр тарафыннан соңгы вакытта үткәрелгән бер генә чара турында әйтеп китәсем килә. Июнь аенда шәһәр читендәге бакчаларга йөри торган автобусларның билет бәясен 2 сумнан 15—16 сумга чаклы күтәрделәр. Ел башыннан бирле өзлексез бәяләр артып килүдән болай да миңрәүләнер хәлгә килеп җиткән халык бу «реформа чарасын» аерыуча авыр кабул итте. Нинди вакытта диегез әле?! Шәһәр халкының шактый зур өлеше, бигрәк тә аның пенсионерлары, тол хатыннары, үзләренең 4—5 сутый җирләрендә тир түгеп эшләгән чакларда гына билет бәяләрен

кинәт чамасыз күтәреп җибәрүне аңлавы, чынлап та, бик читен. Халыкның ризыкка юлын кисү була түгелме соң бу? Ризык хәстәрләү кайгысы белән йөрүчеләргә моны ничек аңлатырга?.. Һәм, гомумән, халык ни дә булса аңлаудан узмады микән инде?!

Хәлбуки мин монда бәяләр күтәрүнең йөздән бер мисалын гына китердем. Ярты ел эчендә кайбер әйберләрнең бәяләре йөз тапкырга артты. Ярый әле Татарстан хөкүмәте азыкның кайбер төрләренә бәяләрне бөтенләй үк ычкындырып җибәрмәде — югыйсә халыкның яртысы, мөгаен, ачтан кырылып беткән булыр иде. Шулай да дәүләтнең хезмәт хакларын, пенсияләрне арттырып торуы бәяләр артыннан һич тә куып җитәрлек түгел. Шуның өстенә алар һәрвакытта шактый соңга калып эшләнә. Билгеле инде, мондый сәмум җиледәй кинәт башланган икътисади реформа халыкның 70—80 процентын, бик тиз хәерчелек чигенә китереп җиткерде, ә фәкыйрь пенсионерлар, толларны хәерчелекнең төбенә үк өреп төшерде.

Хәер, болар барысы да Сезгә күптән мәгълүм булырга тиеш. Һәм минем максатым да нәүбәттәге бәя күтәрүнең газабын сөйләү түгел иде. Куанычлы хәл, хөкүмәтебез яңарак кына автотранспортта йөрү бәяләрен берничә айга яртылаш төшереп торырга булды шикелле. Максатым, бары тик шушы мисалдан чыгып, үземне борчыган кайбер уйларны Сезгә җиткерү иде.

Иң элек Сез күп кенә чыгышларыгызда: «Без базар мөнәсәбәтләренә иплән, йомшак кына кермәкче булабыз»,— дип әйткән идегез. Реформаның нәрсә икәнен татып өлгергән безнең Татарстан халкы мондый «йомшак керү»не бик хуплаган иде. Татарстан җитәкчеләренең реформа газабын җиңеләйтергә тырышулары бик кирәкле һәм бик акыллы сәясәт иде. Бу әле халыкны күпмедер дәрәҗәдә тыныч тоту, реформа белән килештерү өчен генә түгел, безнең яңа туып килгән мөстәкыйльлек белән бәйсезлегебезне ныгыту өчен дә бик кирәк иде. Хәтерләсәгез, бер очрашуда мин Сезгә Татарстанның тук яшәве безнең бәйсезлекнең нигезе ул, дип тә әйткән идем... Чөнки тук илдә иминлек саклана, ач илдә фетнәләр башлана — бу инде күптән билгеле хакыйкать.

Әмма Сез, мөхтәрәм Минтимер Шәрипович, халыкка биргән вәгъдәгездә нык торасызмы соң?.. Гафу итегез, торырга теләвегездә шигем юк, мәгәр безнең халыкта җан тели дә, язык җибәрми дигән хикмәтле сүз бар. Мәсьәлә үтә җитди, үтә катлаулы... Мөгаен, ялгыз Татарстанның үзенә генә реформа мәсьәләсендә үз сәясәтен үткә-

рүе бик читендер. Ирексездән, хәтта чарасыздан гомуми тенденциягә буйсынырга туры киләдер. Шөкер, моңарчы әле бездә базар мөнәсәбәтләренә керү, чынлап та, «йомшак» барды, азык бәяләре дә артык котырып китмәде. Мәгәр бөтен республикалар һәм регионнар күләмендә барган рәхимсез каты реформаның безгә дә кагылмыйча, безне дә үз орбитасына тартып кертмичә үтүе мөмкин түгел. (Без моны бик яхшы сизеп тә торабыз.) Шуңа күрә дә бөтенесе, бигрәк тә Россия китергән гомуми бөлгенлек, иҗтимагый киеренкелек, сәяси тотнаксызлык безгә дә килеп җитмичә калмас... Кешеләрнең тормыш шартлары, икътисади мәнфәгатьләре аларның нинди милләттән булуына карап йөрми — байлык та, хәерчелек тә һәр милләттә бертөсле үк. Ә хәерчелекнең чигенә китереп җиткергән бөлгенлек иҗтимагый киеренкелекне хәтәр кискенләштерү белән бергә, моңарчы җөмһүриятебездә сакланып килгән милләтара татулыкны да җимерүе бик мөмкин. «Барлык яраштырыр, юклык талаштырыр» дигән борынгылар.

Аннары мондый үтә хәвефле бервакытта куркынычны төрле яктан көтәргә була. Шуның иң хәвефлесе — бөтен җирдә, шул җөмләдән безнең Татарстанда да, яңа власть тирәсендә иске коррупция һәм яңа номенклатура бик әрсезләнеп башын күтәрә — Сез моны үзегез дә, шәт, күреп торасыздыр. Шулардан туган, баеп калудан башканы белмәгән һәм һичбер нинди мораль кагыйдәләрне танымаган яңа «эшкуарлар» аркасында халык өзелеп көткән, халыкка муллык белән иркенлек китерергә тиешле булган реформаның ахырын без, мөгаен, күрә дә алмабыз.

Инде соңгы сүзем шул: әгәр халыкның чыдавы чиктән ашып, Россия, ниһаять, шартласа, безнең кечкенә җөмһүриятебез дә аның хәрабәләре астында күмелеп калачак. Мәгълүм ки, галәмәт зур Россиянең ишелеп китүеннән дөньяның иң көчле илләре дә шомланып куркып торалар. Ә Татарстан аның кыл уртасында, күпме җепләр белән уралып беткән — моны истән чыгарырга һич тә ярамый. Әмма, үзебезнең шушы җөмһүриятебездә демократиягә тугрылыклы була алсак, икътисади реформаны Сез әйткәнчә йомшак, газапсыз үткәрә алсак, һәм иң мөһиме — кеше хокукларын яклауны иң беренче изге бурычыбыз итеп куйсак, без кечкенә Татарстаныбызны һәлакәттән саклап калу гына түгел, Россиянең хәзерге шактый хәвефле авыр хәлен җиңеләйтүдә дә күпмедер уңай йогынты ясый алыр идек. Чөнки бөтен тирәягыбызда тынычлык һәм иминлек үрнәге була алыр идек.

Билгеле инде, моңа бары тик чын мөстәкыйльлек һәм бәйсезлек шартларында гына ирешергә мөмкин.

Соңгы вакытта тынгылык бирмәгән әнә шул уйларымны, ниһаять, Сезгә җиткерәсем килде. Борчуым өчен кичерегез!

Сезгә олы ихтирам белән: Татарстан халык язучысы.

*«Татарстан хәбәрләре», 1992*

## БИЕКТӘН КАРАП ТОРАСЫМ КИЛӘ

*— Мәйданнарга, митингларга нигә йөрмисез, дигәч, Сез, Әмирхан ага, «тапталудан куркам» дигән идегез. Бераз шаяртып әйткән бу сүзегездә, бәлки, митингларга чыгу көрәшнең берләнбер юлы түгел дигән мәгънә ятадыр. Сез, беренчеләрдән булып, милләт тарихы, тел язмышы турында матбугатта олы сүз әйттегез. Инде хәзер тел йозаклары алынган, мөмкинлекләр бирелгән заманга кердек шикелле. Сезне нәрсә шөбһәләндерә?*

— «Тапталудан куркып митингларга йөрмәү» көлеп әйтелсә дә, ул сүзләрдә күпмедер дөреслек тә бар. Минем кебек сиксәннән узган бабайларга халык арасында буталып йөрүнең кирәге юктыр, мөгаен. Чәчәннәрдәге шикелле безне барыбер алга тезеп утыртмыйлар. Үз урыныңны белеп утыру хәерлерәк. Минем урыным исә өстәл артында. Әмма ләкин мин митингларның кирәклеген һич тә инкяр итмим. Демократия шартларында халык теләген белдерүнең көчле бер чарасы ул. Тик тәртипле узсын да файдалы нәтиҗәләр генә китерсен.

Сез миннән «нәрсә шөбһәләндерә» дип сорыйсыз. Дөресен генә әйткәндә, шөбһәләнмичә, уйланмыйча торган көнем юк диярлек... Хәзерге вакытта мин генә түгел, күпләрне нык борчыган ике проблеманы, беренче нәүбәттә, атыйсым килә. Беренчесе — икътисади реформа китергән бөлгенлектән, хәерчелектән ничек чыгарга, базар мөнәсәбәтләренә күчүнең газабын ничек җиңеләйтергә? Икенчесе — Татарстанның мөстәкыйльлеген һәм бәйсезлеген ничек итеп, нинди чаралар белән ныгытырга? Бу бер-берсенә гүя бер дә охшамаган проблеманың үзара турыдан-туры бәйләнеше бар: суверен Татарстан үз халкын моңарчы, башка бик күп регионнарга караганда, иң кирәкле азык-төлек белән, чагыштырмача түбән бәяләрдә тәэмин итеп тора алды. Президент Минтимер Шәймиевнең «Без базар мөнәсәбәтләренә ашыкмыйча, йомшак керәчәкбез» дигән вәгъдәсе дә моңарчы үтәлеп килде дияргә ярый. Һәм төрле милләт кешеләре Та-

тарстанның мөстәкыйльлек, бәйсезлек дәгъва итүе никадәр хаклы вә зарур булуын үз җилкәләрендә татып белделәр.

Кызганычка каршы, Россияне каплап алган коточкыч кризис безнең Татарстан өстенә дә зур авыр таш булып ятты. Кыскасы, Россиядә барган тискәре процесслардан без бернинди киртә-коймалар белән дә аерылмаганбыз — анда ниләр эшләнсә, шулар һәммәсе безгә дә килеп керә. Һич көтелмәгән хәлләргә юлыгуыбыз бик мөмкин. Менә шулар барысы да безне киләчәгебез өчен ирексездән гел шомланып, шөбһәләнеп яшәргә мәҗбүр итә дә инде.

*— «Соңгы китап» дигән автобиографик әсәрегезнең баштагы өлешен редакцияләү хәтердә. Сак кына әйтелгән кайбер фикерләрегезне цензура төшереп калдырган иде. Бик язасы килеп тә, баш очында торган «дамокл кылычы»н истә тотып, кайбер вакыйга-уйлануларны кәгазьгә төшермәвегез турында әйткән идегез. Хәзер бу әсәрегезне тулыландырырга ниятегез бармы?*

— «Соңгы китап» вакытыннан иртәрәк язылды, иртәрәк басылды һәм, тиражы кечкенә булу сәбәпле, бик тиз таралып та бетте. Билгеле, минем аны яңадан чыгарасым килә. Мәгәр мин бер тапкыр язылган әсәрне икенче тапкыр үзгәртеп язып чыгаруны бер дә яратмыйм, моны яраклашуның бер төре дип саныйм. Ләкин беренче тапкыр басылганда цензура тарафыннан сызылган урыннарын китапка яңадан кертер идем.

*— Күп кенә проза әсәрләрен кабат укып булмый. Сезнең әсәрләр белән кабат яшәп була. Кайта-кайта укыганда да повесть-хикәяләрегездән яңа төсмерләр табасың. Ялган данга, тамак ялына кызыгып, күпләр вакытлы тема белән мавыкканда, әдәбиятта үзешчәнлек хөкем сөргәндә, күпме кыерсытылып та, Сез ничек иманыгызга тугры калдыгыз, кызыгып, конъюнктур әсәрләр язудан ничек тыелып яшәдегез?*

— Конъюнктурага бирелеп китмәүнең сәбәбе, минемчә, бер генә: әсәрне бары тик укучы өчен генә язуда... Укучыга исә алдашмыйча һәм яраклашмыйча язарга кирәк, чөнки укучының да төрлесе бар. Аннары әсәр, һичшиксез, укылырга тиеш. Язган чакта бөтен сәләтең-көчең шуңа китсә, дан, мактау турында уйланулар үзеннән-үзе онытылып торачак. Инде укучы әсәреңне яратып һәм ышанып кабул итсә, дан дигән дәрәҗә сине иртәме-соңмы сәке астыннан да эзләп табачак.

*— Сез нәп дәверен кичергән кеше. Менә тагын котырып баю һәм ярлылану процессы башланды. Бу ике чорның охшашлыгы һәм аермасы нәрсәдә?*

— Мәгълүм булганча, нэп 1922—1923 елларда башланды. Октябрь революциясеннән соң вакыт күп узмаган иде әле, сакланып калган иске сәүдәгәрләр дә бар иде, аннары зур байларда эшләп остарган приказчиклар да күп иде. Нэпның беренче көненнән үк менә шулар сату-алу эшләрен башлап җибәрделәр. Ә халыкта дин белән кергән, бигрәк тә элеккеге сәүдә мөнәсәбәтләреннән эшләнеп калган әхлак кагыйдәләре көчле иде. Хәрәмләшү, алдашу, талап алу кебек әшәкелеккә алар бервакытта да бармыйлар иде. Гөнаһтан курку гына түгел, сатып алучыны күбрәк җәлеп итү, конкуренция дигән нәрсә үзе аларга мөмкин кадәр гадел булырга куша иде. Дөрес, люмпеннан чыгып, сату эшенә тотынган бәндәләр генә бернинди җинаятьтән дә тыелып тормыйлар иде. Бүген тапканын көне белән ашап-эчеп бетерүчеләр иде алар.

Хәзерге эшкуар коммерсантларның да күбесе шулар токымыннан. Люмпеннан яки номенклатурадан чыгып баеп китүчеләр өчен дә бернинди әхлак та, «ярамый» да юк — халыкны ачыктан-ачык талый алалар. Аерма тик шунда: нэп заманында намуслы, гадел сәүдәгәрләр күпчелек, ә җинаятьчел элементлар азчылык иде. Хәзер исә киресенчә, бөтен сату-алу эшләре җинаятьчел мафиозилар кулына кереп бетте, дияргә була. Нэп бер-ике ел эчендә илне азык-төлеккә күмеп ташлады, кибетләрдә җаның теләгән бөтен нәрсә бар иде. Кесәңдә 15 тиен акчаң булса, шуның белән дә тамак туйдырып була иде...

*— Сез гүзәл Дим буенда туып үскәнсез. Башкортостандагы элеккеге Уфа губернасы татарлары хәлен яхшы беләсез. Татар хисабына башкорт халык санын арттыру процессына да күңелдән рәнҗедегез. Бүгенге көндә дә тарихны оятсызларча бозып, фәнни нигезләнмәгән, уйдырма хезмәтләр язган галим-голәмәләргә, милләтен алыштырган язучыларга карата ни әйтер идегез?*

— Татар-башкорт мөнәсәбәтләре мине гел борчып, әрнетеп торган бик четерекле мәсьәлә ул. Вакытында мин бу хакта язып та чыктым. Кеше һәм язучы буларак мин татарны да, башкортны да тигез итеп күрәсем һәм икесенә дә чын күңелдән яхшылык телисем килә... Хикмәт нәрсәдә, бу четерекле мәсьәләнең асылы нәрсәгә кайтып кала? Билгеле булганча, башкортлар үз республикаларында сан ягыннан татарга караганда азрак. Хәлбуки статистика буенча аларның саны 1 миллион 400 меңгә җитә һәм күбесе Башкортостан тирәсендә генә яшиләр дә. Әгәр дә ки башкортлар яшәгән шул күрше җирләрне Башкортостанга яңадан кайтарып булса, республиканың

төп халкы берничә йөз меңгә артып китәр иде. Ул чагында татар авылларын башкорт итеп язуның кирәге дә булмас иде.

Аннары милләтнең куәте, җегәрлеге аның санына карап кына йөрми. Башкорт борынгы халык, әмма яшь милләт, ә яшь милләтнең яшәү сәләте бик көчле була. Башкортлар да әнә шундый сәләткә ия; үзләрен дә, телләрен дә, көнкүрешләрен дә бик әйбәт саклый алачаклар.

Иманым камил, һәм мин кабатлап әйтәм: татар белән башкортның киләчәге дошманлыкта түгел, бары тик дуслыкта! Бер-берсенә арка таянычы булып, «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» яшәүдә!

Инде татардан чыккан кешеләрнең башкорт әдәбиятына һәм сәнгатенә хезмәт итүләренә килгәндә, бу билгеле бер шартларда үзеннән-үзе туган котылгысыз күренеш иде. Ләкин моның өчен милләтне алыштыру кирәк булды микән?.. Бәлки, монысы да ирексездән эшләнгәндер, чөнки Башкортостан җитәкчеләре бер халык исәбенә икенче халыкны үстерү сәясәтен еллар буена үткәреп килделәр. Милләтне алыштыру шул мәкерле сәясәтнең нәтиҗәсе буларак тугандыр да, ахры.

Хәзер инде милләтара мөнәсәбәтләр үзгәргән булырга тиеш. «Кайт аслыңа, аслың яхшы»,— дигән Тукаебыз. Бәлки, кире үз милләтеңә кайтырга да ярый торгандыр... Хәер, гомерләрен башкорт әдәбиятына багышлаган әдип һәм шагыйрьләр өчен бу бик газаплы эштер, бәлки, аның һич кирәге дә юктыр. Ике тугандаш халык арасында тулы тигезлек сакланганда, татар яки башкорт булып саналуның ни әһәмияте бар?! Башкортлашкан татар яки татарлашкан башкорт аз булмаган ич элек тә!

*— Кайбер өлкән язучылар, без соңгы могиканнар, дигән кебек, артка бик борылып карарга тырышмадылар. Сез яшьләр иҗатын ничек бәяләр идегез? Көч бармы? Тел коесы саекмыймы? Сәламәт рух сизеләме?*

— Кызганычка каршы, соңгы елларда гына мәйданга чыккан яшьләр иҗаты белән танышып бара алмадым. Укыр нәрсә бик күбәеп китте, вакыт җиткерә, өлгерә алмый башладым... Өстән генә күзәтүем буенча, шигърияткә яңа талантларның бик күп килүен күрәм. Ләкин прозада алар ни өчендер һаман аз күренә.

Иҗат итү шартлары хәзер бик нык үзгәрде. Бер яктан хөрлек килде, җаның теләгәнне язып була башлады. Икенче яктан китап чыгару гаять читенләште. Яшьләрнең матди хәле бик авырдыр инде... Шуңа да карамастан мин аларның рухи таза булуларына ышанам. Ләкин

безнең ышанулар коры сүз генә булып калмасын өчен, аларга конкрет ярдәм кирәк. Монысын без хөкүмәтебездән таләп итәргә тиешбез.

*— Сезнең кебек каләм иясеннән «мәрхәбә!» дигән сүзне ишетү яшьләрне үсендерәдер, әлбәттә. Аларның бит әле Сезнең буын кагылмаган тарихи катламнарга да төшәсе бар... Тарих дигәннән... Әмирхан ага, Сезнең үкендереп торган, язылмыйча калган әсәрегез хыялда бармы?*

— Иҗат эшенең серләрен үзегез дә беләсез, күңелдә туган кайбер фикерләр еш кына кәгазьгә язылмыйча да кала. Йә үзең аңардан баш тартасың, йә уең-хыялың башкага күчә. Миндә дә булды тумыйча калган нәрсәләр... Ләкин мине иң үкендергәне — гомумән, аз язуым... Язар өчен үзеңне мәҗбүр итә белергә кирәк — илһамың килсә дә, килмәсә дә. Ә мин, утырып эшләүгә караганда, күбрәк уйланып йөрергә яратам. Аннары язу минем өчен энә белән кое казу шикелле бик газаплы бер эшкә әйләнә иде. Тиз генә, җиңел генә язып ташлауны белмәдем диярлек. Нишләмәк кирәк, Ходай шулай яраткач!.. Тик бер нәрсәне тәгаен әйтә алам: күп яза алмавымны белгәнгә күрә, мин хәлемнән килгән кадәр әсәрнең сыйфат ягын кайгырттым. Язганнарымда кибәк азрак, бөртек күбрәк булырга тиеш, дип, үземне юаткан да булам.

*— Еникеев — бик борынгы фамилия. Бу исемне йөртүчеләр эре сөякле, сәламәт рухлы, дәрәҗәле, иманлы шәхесләр. Әдәбият-сәнгать тирәсендә сәләтсезлек, донос, яла ягулар, мескенлек хөкем сөргәндә, шул мохиттә чиста калып, затлы нәселнең байрагын күңелегездә йөртү авыр булмадымы?*

— Дөрес, Еникеевлар бик борынгы фамилия. Әмма ләкин бу фамилияне йөртүчеләр башкаларга караганда затлырак та, өстенрәк тә, чистарак та, дип әйтү хата булыр иде. Бер фамилиядәге ишле халык арасында гына түгел, бер гаилә эчендә дә һәммәсе бертөсле үк була алмый, Совет заманы моны аеруча шәрәләндереп ачып күрсәтте. Безнең авылның яртысы диярлек Еникеевлар иде. Колхозлашу вакытында Еникеев — Еникеевны саткан, Еникеев — Еникеевның башын ашаган... Бу фаҗигане мин ишетеп кенә түгел, татып та беләм. Шуңа күрә кешенең фамилиясенә карап кына фикер йөртү без кичергән әшәке заман шартларына һич тә туры килми.

*— Сез Президентыбыз Минтимер Шәймиев командасы белән Төркиягә визит ясауда катнашачак бердәнбер язучы идегез. Авырып китүегез сәбәпле, бара алмый*

*калдыгыз. Сез сәламәтләнгәнче визитны кичектереп тормавы өчен Президентка үпкәләмисезме?*

— Әйе, кызганычка каршы, Президентыбызны Төркиягә озата баручылар арасына мин авыру сәбәпле эләкмичә калдым. Мине көтеп, визитын кичектереп тормаганы өчен Президентка үпкәмне белдерергә ашыкмыйм, чөнки аның миңа Төркиягә җибәрермен, дигән вәгъдәсе бар. Онытмаса, вәгъдәсен бер үтәр әле, дип көтеп торам... Ә минем урынга Мөхәммәт Мәһдиевне алып китеп бик дөрес эшләгәннәр. Ул һәр җәһәттән миңа караганда җитезрәк. Әнә кайтып җитүе белән нинди шәп мәкалә дә язып өлгерткән... Миннән андый мәкалә кайчан чыгар иде әле.

— *Соңгы сорау. Казанның матур бер җиреннән үзегезгә һәйкәл урыны сайлап куймадыгызмы?*

— Моңарчы бу хакта баш ватарга туры килмәде. Инде үлмәс борын миннән: «Әмирхан әфәнде, һәйкәлегезне кая куйыйк икән?» — дип сорасалар, мин, әлбәттә, Югары Ослан тавын күрсәтер идем. Казан тирәсендә аңардан да биегрәк бүтән урын юк. Ә минем бу «үзе матур, үзе тар» фани дөньяга бик биектән мәгърур гына карап торасым килә.

*«Шәһри Казан», 1993*

## КЕМ ХАКЛЫ?

*(Конституция турында фикерләр)*

Үткән елның алтынчы ноябрендә Татарстан Югары Советы кайнар бәхәсләрдән соң, ниһаять, Республикабызның яңа Конституциясен кабул итте. Депутатларның барысы да диярлек бу тарихи актны аягүрә торып котладылар. Алай гына да түгел, Конституция кабул ителгән көнне бәйрәм көн дип игълан иттеләр. Һәм Республика халкы да бу бәйрәмгә, бу шатлыкка кушылды, чөнки ул яңа Конституция Татарстан мөстәкыйльлеген ныгытуга таба ясалган мөһим бер адым дип кабул итте. Мин үзем дә шулай дип кабул иттем, чөнки Татарстанның суверен дәүләт икәнлеге һәм халыкара субъект булуы Төп Законда — Конституциядә беркетелгәч, моны инде берәүнең дә инкяр итәргә яки кире кагарга хакы булмаячак дип уйладым. Мәскәүнең бездән яңа Конституцияне кабул итмичә торуыбызны таләп итүе дә башкача уйларга урын калдырмаган иде. Инде кабул ителгәннән соң, Россия депутатларының яңа Конституциябезне сөңгегә элеп алулары да ул бәндәләрдә нинди зур канәгатьсезлек ту-

дырганын бик ачык күрсәтте. Ә үзебездәге Мәскәү тарафдарлары да Конституциянең кабул ителүенә күпме генә аяк чалып маташмадылар!

Кыскасы, әнә шундый гаять каршылыклы һәм хәвефле шартларда авыр газап белән туган Конституциябездән, нинди генә кимчелекләре булуга карамастан, без канәгать хасил итәргә тиеш идек. Чөнки ул, әйткәнемчә, мөстәкыйльлегебезне ныгытуда тагын бер тәвәккәл адым иде. Һәм без бу адымны республикабызда милләтара иминлекне бик әйбәт саклаган хәлдә ясый алдык. Барлык милләт кешеләре, аеруча татарларның үзләре өчен моның никадәр әһәмиятле булуын сукыр да күрә торгандыр, минемчә...

Әмма ләкин озак та үтмәде, без яңа Конституциябезнең, Татарстан өчен, татар халкы өчен файдалы булудан бигрәк, гаять зарарлы, бөтенләй кирәксез бер нәрсә икәнлеген хәйран калып белә башладык.

Иң элек мөхтәрәм Әбрар Кәримуллинның «Шәһри Казан»да (№ 214, 1992 ел) «Татарстан Конституциясе яки империя арбасына тагылган дегет чиләге турында уйланулар» дигән мәкаләсе басылып чыкты. Мәкаләнең исеме үк инде авторның яңа Конституциягә карашын һәм мөнәсәбәтен ачыктан-ачык әйтеп тора. Әлбәттә, яшермичә әйтергә хакы бар аның. Шулай да бик авырлык белән Югары Советыбыз кабул иткән һәм халкыбыз тарафыннан да тулаем кабул ителгән төп дәүләт законын дегет чиләгенә тиңләп язарга минем кулым бармас иде... Хәер, бу кадәресе инде безнең характерлардан килә торгандыр.

Хуш, мәкаләдә сүз конкрет нәрсә турында бара соң? Автор өч сорау куеп, шуларга үзенең җавабын язып чыга. (Болар дәүләт теленә, ике гражданлык мәсьәләсенә һәм ассоциацияләнү дигән төшенчәгә карыйлар.) Җавапларның нидән гыйбарәт булуын мин монда язып тормыйм — кызыксынган һәркем үзе дә табып укый ала. Тик шуны гына әйтергә кирәк, яңа Конституциядә шул өч мәсьәләгә кагылышлы маддәләрнең һәркайсын Әбрар Кәримуллин, үзенчә бик дәлилләп, катгый рәвештә кире кага. (Телгә карата ясаган нәтиҗәсе белән мин дә килешәм.) Әмма шуннан соң Әбрар Кәримуллинның тулаем бөтен Конституциягә карата чыгарган хөкеме белән килешергә мөмкинме? Тыңлап карыйк аның бу катгый хөкемен дә: «Кыскасы, 6 ноябрьдә кабул ителгән Татарстан Конституциясе әле азмы-күпме сакланып килгән татар милләтенең юкка чыгуына юл ача». Янә: «Бу Конституция безгә бернинди азатлык, мөстәкыйльлек

бирми һәм моны чит илләрдә бик тиз аңладылар»... Соңгысы: «Мин бу Конституцияне безнең мөстәкыйльлегебезгә түгел, Россия коллыгында калуга юнәлдерелгән Конституция дип санийм».

Бик ачык әйтелгән. Инде хөрмәтле укучы мөхтәрәм галимнең яңа Конституцияне ни өчен «империя арбасына тагылган дегет чиләге»нә охшатуын, шәт, яхшы аңлагандыр: ул Конституция суверен Татарстанга түгел, фәкать Россия империясенә хезмәт итәчәк икән...

Ләкин шулай да замандашым Әбрар Кәримуллин белән, әгәр колак салырга теләсә, минем әзрәк бәхәскә керәсем килә. Безнең хәлләребез, ул әйткәнчә, шулкадәр үк куркыныч микәнни? (Ул бит мәкаләсенең соңгы юлын: «Куркам, без бу юлы үзебез кул күтәреп, 1552 елның 15 октябрен кире кайтардык түгелме?» — дип бетерә.) Һәм бу гаять куркыныч хәлдән чыгар өчен нишләргә кирәк соң?

Әбрар Кәримуллин моның да юлын күрсәтә: аныңча, «үзен мөстәкыйль итеп күрергә тырышкан илнең конституциясендә үз армиясе, үз акчасы, үз таможнясы кебек атрибутлары булырга тиеш» дип яза ул... Бик дөрес, һәрбер суверен, бәйсез дәүләтнең ачык сызылган чикләре дә, шул чикләрне саклаучы армиясе дә, шулай ук үз акчасы да була — кәгазьдә генә түгел, реаль чынлыкта! Әмма бөтен хикмәт шунда ки, безнең суверен бәйсез дәүләт булуыбызны дөньяда әле бер генә илнең дә рәсми рәвештә таныганы юк. Һәм Мәскәүдән узып берсе дә танымаячак, чөнки кечкенә бер республика хакына галәмәт зур вә куркыныч (хәрби җәһәттән) Россия белән арасын бозарга теләмәячәк. Димәк, Татарстанның суверен дәүләт һәм халыкара субъект булуын иң элек Россия рәсми рәвештә танырга тиеш. Бары шуннан соң гына башкаларның да бер-бер артлы әкренләп танулары һәм дәүләт дәрәҗәсендә безнең ил белән мөнәсәбәткә керә башлаулары мөмкин. Шуңа ирешмичә торып, армия төзүләр, акча сугуларның ни мәгънәсе кала? Үзебез өчен генә бик кадерле «бәйсезлек» эченә кереп бикләнү безгә нәрсә генә бирәчәк? Һәм, гомумән, мөмкин эшме бу?

Менә монда инде Татарстан алдына гаять җитди мәсьәлә килеп баса. Россия безнең суверен дәүләт һәм халыкара субъект булуыбызны танысын өчен нинди юл сайларга: көрәш юлынмы, әллә килешү юлынмы?.. Моны дөрес хәл итәр өчен бер хакыйкатьне бик нык истә тотарга кирәктер дип беләм. Хакыйкать исә менә нидән гыйбарәт: без Россия уртасында торып калган халык, без Россиядән бер якка да аерылып чыга алмыйбыз, без үзебез-

нең шушы борынгы җиребездә урыслар белән уратып алынган һәм урыслар белән тәмам аралашкан хәлдә яшәргә мәҗбүрбез. Без Россия империясенә озак еллар дәвамында бик күп, бик таза баулар белән һәр җәһәттән уралып-бәйләнеп беткәнбез. Бу безнең тарихи ачы язмышыбыз, башыбызны ташка орсак та, без инде аны тиз генә, ансат кына үзгәртә алмаячакбыз... Билгеле инде, мондый шартларда иң дөресе — килешү юлын сайлау. Чөнки килешүдән башкасы, иртәме-соңмы, мотлак канлы бәрелешкә китерәчәк. Яки үз арабызда Таҗикстан фаҗигаләре башланачак... Татарстан җиренә кан-үлем, күпме һәлакәт киләсен махсус язып тормыйм — халык болай да аларны биш-алты ел буена ишетеп-күреп туеп та беткәндер инде. Ихтимал, безне сындырыр өчен танклар кертүнең кирәге дә булмас, бары тик блокада белән әйләндереп алу да җитеп торыр.

Бу куркыту түгел, бу ниләр буласын күз алдына китерергә тырышу гына... Россиянең кыл уртасында, милли республикалар урнашкан регионда кабынып киткән сугыш утының кая кадәр җәеләсен дә, күпмегә кадәр дәвам итәсен дә алдан күреп бетерү мөмкин түгел. Әмма янгын гаять көчле булачак, иң элек ул Татарстан өстендә дөрләячәк. Күпме һәлакәт китерәчәген, күпме корбаннар алып китәчәген әйтеп торасы да юк.

Әмма моның ахыры ни белән бетәчәк? Бик ихтимал ки, урыс халкында электән үк сакланып килгән бөекдержавачылык шовинизмы тагын да көчәеп китәр, шуның нәтиҗәсендә большевикларныкы сыман тоталитар хакимият күпмедер вакытка яңадан әйләнеп кайтыр. Моны бик теләп, көтеп торучылар бар. Аларга сылтау гына кирәк, берәр сылтау чыгу белән безнең бугазга ябышачаклар... Менә шул чагында «мөстәкыйльлек!» дип, авызыңны ачып кара инде. Озын сүзнең кыскасы, хәзергедәй төрле хәйлә-мәкер, провокацияләр белән тулы ышанычсыз бер заманда Татарстан өчен дә, Россиянең үзе өчен дә бары тик үзара килешү юлы гына дөрес булачак. Татарстан башта ук шушы юлны сайлады. Без инде моның шактый гына уңышлы нәтиҗәләрен дә күрдек. Милләтара иминлекне саклаган хәлдә мөстәкыйльлегебезне арттырдык, байлыкларыбыздан күбрәк файдалана башладык, күпмедер дәрәҗәдә хөрлек килде, милли аңыбыз үсте, милләтебезне терелтү, яңарту эшенә чынлабрак тотындык. Һәм Мәскәү безнең бу хәрәкәтебезне, гәрчә сары кайнаса да, туктатырга җөрьәт итә алмады. Чөнки без, бердән, демократия юлы белән бардык, икенчедән, бер генә халыкның да хокукларын, ирекен чикләмәдек.

Менә бу акыллы, ачык сәясәт Татарстан җитәкчеләренең генә түгел, татар халкының да абруен шактый ук күтәрде. Безне дөнья белә башлады, безнең белән дөнья кызыксына башлады, читләр белән аралашуыбыз көчәя, эшлекле мөнәсәбәтебез арта.

Димәк, Россия белән бозылышмыйча килешү юлын сайлавыбыз дөрес. Шушы юл белән барганда, без максатларыбызга, бәлки, тизрәк якынаербыз?.. Гомумән, ике ара мөнәсәбәтләргә ачыклык кертергә вакыттыр инде. Татарстанның Россия белән тигез хокуклы аерым килешүе булырга тиеш. (Президентыбыз автономияләр өчен төзелгән стандарт договорга кул куюдан да баш тартты.) Аерым килешү турында авыр сөйләшүләр күптән дәвам итеп килә. Бу эштә безнең вәкилләрдән уяулык та, ныклык та таләп ителә. Билгеле, «ассоциацияләнү»коры сүз генә булып калмас, ниндидер ташламалар ясарга, ниндидер вәкаләтләрне бирергә дә туры килер, әмма иң мөһиме — Татарстанның суверен дәүләт, халыкара субъект булуы килешүдә ачык әйтелергә тиеш. (Бу — Конституциябез таләбе.) Әгәр шушы положение килешүдә ачык беркетелсә, безнең өчен моның әһәмияте гаять зур булачак. Башкалар тарафыннан да безне рәсми рәвештә тану башланачак. Аннары җөмһүриятебездә Татарстан законнары алдан йөриячәк, без шул законнарга буйсынып яшәячәкбез. Россия үз халкын яклаган шикелле, Татарстанның да читтәге татарларны якларга хакы булачак. Шуңа күрә Әбрар Кәримуллинны бик өркеткән әлеге ике гражданлык мәсьәләсе дә мине ул хәтле үк куркытмады. Киресенчә, ул «маддә»нең безнең файдага эшләве дә бик мөмкин бит. Әйтик, читтә яшәүче татарлар Татарстан гражданы булырга теләсәләр, шул «маддә»не файдалана алмас释лармыни?.. Инде безнең үзебездә яшәүчеләргә килгәндә, алар беренче нәүбәттә Татарстан гражданнары, аларның вазифаларын да Татарстан законнары билгеләргә тиеш булачак...

Ахыргы нәтиҗәне ясарга да вакыттыр... Беләм, Россия белән ассоциацияләнү нигезендә килешү Татарстанга барыбер тулы мөстәкыйльлек һәм бәйсезлек китермәячәк дип әйтүчеләр булачак. Килешәм, чөнки тулы мөстәкыйльлек белән чын бәйсезлеккә бары чын демократия шартларында гына ирешергә мөмкин. Ә Россия аңардан ерак, бик ерак әле... Без реаль чынбарлык белән килешергә мәҗбүрбез. Калганы киләчәк эше. Тулы азатлык өчен көрәшне вакытлы бер кампания дип карарга ярамый. Көрәш әле бик озакка сузылыр, ә хәзер исә безгә азатлыкның булган кадәресеннән бик әйбәт файдала-

ныргa кирәк. Хокукларны киңәйтергә, байлыкка күбрәк хуҗа булырга, мәгърифәтне җәелдерергә, мәдәниятне үстерергә, фәнне көчәйтергә, тирән белемле, киң эрудицияле яшьләр тәрбияләргә — иң заруры безгә менә шулар!.. Илебезнең абруен, дәрәҗәсен шулар күтәрәчәк, тулы мөстәкыйльлек белән чын бәйсезлекне дә шулар тәэмин итәчәк. Әлбәттә инде, боларның барысына да милли азатлык хәрәкәтен демократия өчен көрәш белән тыгыз бәйләп барганда гына ирешеп булачак. Барлык халыклар белән берлектә!

* * *

Мөхтәрәм Әбрар Кәримуллин белән бәхәсем тәмам. Ләкин бу бәхәскә керешкәнче, мин Фәүзия Бәйрәмованың да мәкаләсен телгә алган идем. Бик гаҗәпләндергән, уйландырган мәкалә булды ул — аның хакында да кыскача гына булса да әйтмичә узу ярамас. Яңа Конституцияне Фәүзия ханым «Муендагы элмәк» дип атаган. Бу инде дегет чиләгенә тиңләү генә түгел. Дегет чиләген чүплеккә дә ташлап була, ә элмәкне муеннан кем салдырыр? Җитмәсә, аның очы Мәскәүдәге шашканнар кулында икән! Коточыргыч бит бу!.. Моны бит Конституциянең һәр статьясын тикшерүдә, кабул итүдә актив катнашкан депутат яза.

Нәрсәдә соң мондый җөдә куркыныч хәлнең сәбәбе? Бактың исә һаман әлеге шул гражданлык мәсьәләсе икән: яңа Конституция буенча без ике илнең — Татарстан белән Россия гражданнары булып калачакбыз... Фәүзия ханым шушы мәсьәләгә кагылышлы статьяларны бик җентекләп тикшерә дә үзенең шаккатыргыч нәтиҗәләрен берәм-берәм чыгара. Ә нәтиҗәләре аның менә болайрак: «Без Россия президентының бөтен указларына буйсынырга, Россия парламенты чыгарган законнарны үтәргә тиешбез. Ул указлар һәм законнар Татарстанның мөстәкыйльлеген юкка чыгара, байлыгын талый, милләтебезне юк итә торган булса да, без аларга буйсынырга тиеш булабыз. Чөнки без — Россия гражданнары...». Янә: «Менә шулай, милләттәшләр, 440 ел элек нәрсәдән башласак, шуңа әйләнеп кайттык — коллыкка. Без җимерелеп барган империягә терәү булдык, үзебез генә түгел, ирекккә тилмергән күпме милләтләрне шул төрмәдә бикләп калдырдык. Россиянең коллыкта газапланган халыклары безгә моны беркайчан да гафу итмәсләр». Бу сүзләрне укыганда ничектер күзләреңә ышанмыйча торасың: мескен татар, бөтен гаеп синең өстеңә, бөтен нәләт синең башыңа! Әмма хаклымы соң бу?.. Берәүгә дә кан-

үлем китермичә үзенә азатлык яулаган халык гаепләнүдән бигрәк акланугa лаектыр, бәлки?! Ләкин шунда ук күңелдә икенче бер сорау туа: ничек итеп депутатларның Ф.Бәйрәмовадан башкалары, шундый алама, шундый зарарлы Конституция кабул итүләрен аз гына да күрә-чамалый белмәделәр икән?.. Югары Советта утыручы татарларның барысы да уң белән сулны аера белмәгән мокытлар түгелдер ләбаса!..

Фәүзия ханым, талантлы каләм остасы буларак, яңа Конституциянең гражданлык турындагы статьясын һәрьяклап сүткәннән соң (монда игътибарга лаеклы дөрес фикерләр дә бар), башыбызга төшкән бәхетсезлектә Татарстан җитәкчелеген, аеруча Югары Советны ачыктан-ачык гаепли. Мәкаләсенең ахырында ул менәниләр яза: «Татарстан дәүләте җитәкчеләренә нәкъ менә шундый Конституция кирәк иде, чөнки алар беркайчан да тулы бәйсезлек, Россиядән сәяси яктан аерылу мәсьәләсен куймадылар». Һәм: «Татарстан Югары Советының бу составы нәрсәгә сәләтле икәнен инде күрсәтте, аңа өмет аз».

Сүз озынга китмәсен өчен мин артык күчереп тормыйм — кыскасы, Фәүзия ханым Югары Советны яңарту мәсьәләсен көн тәртибенә куя. Аныңча, Югары Советыбыз дәүләт, милләт җанлы кешеләрдән торырга тиеш. Әлбәттә, шулай! Әмма бу очракта властька дәгъва юк микән?.. Фәүзия ханым — «Иттифак» фиркасенең җитәкчесе. Милләт мәҗлесенең танылган лидеры. Милли хәрәкәтебезнең бу канаты күптән инде Югары Советны Милли мәҗлес белән алыштыру турында хыяллана. Әмма власть алыштырып уйнау вакытымы соң хәзер? Республиканың тынычлыгы, иминлеге, ниһаять, тук яшәве өчен хәзерге законлы властьны яратсаң да, яратмасаң да саклау хәерлерәк түгелме? Халык бит бүгенге властьтан тулаем канәгать, алыштырырга теләүчеләр артыннан ул иярмәячәк. Әлбәттә, властька карата оппозиция булырга тиеш, тәнкыйть кирәк — бу демократия таләбе. Мәгәр бер нәрсәне истән чыгарырга ярамый: бөекдержавачылык шовинизмы да, чамасыз тар милләтчелек тә бик хәтәр күренеш, иртәме-соңмы аларның йә большевизмга, йә фашизмга илтеп чыгаруы бик тә мөмкин.

Бүген исә «Муендагы элмәк»не укыган кешеләрдә башка сорау туачак: кемгә ышанырга, кем хаклы? Зур чыдамлык күрсәтеп, күп көч куеп, яңа Конституцияне Югары Совет аша үткәрүгә ирешә алган Президент Минтимер Шәймиевме, әллә булмаса бу Конституцияне хәзерге хәлендә кабул итүгә теше-тырнагы белән каршы торган тынычсыз депутатыбыз Фәүзия Бәйрәмовамы?..

Кайсы хаклы, кайсы бүгенге буталчык, киеренке шартларда татар халкының милли мәнфәгатьләрен дөресрәк аңлый һәм остарак яклый? Миңа калса, халкыбызның иң зур күпчелеге, һичшиксез, Президентыбыз М.Шәймиевкә ышана, аның ягында тора. Гафу итегез, мин үзем дә күбрәк аңа ышанам. Ә калганын вакыт хөкеменә калдырыйк.

*«Ватаным Татарстан», 1993*

## ФРОНТ ДӘФТӘРЕННӘН

### Кечкенә генә кереш

*«Фронт дәфтәре»ннән чүпләп алган кыска гына язмаларның бер өлеше 1994 елның маенда «Ватаным Татарстан» гәзитәсендә басылып чыккан иде инде. (Ватаным Татарстан.— 1994.— № 97.— 20 май.) Быел мена Бөек Җиңүгә 50 ел тулу уңае белән шул ук дәфтәрдән кыска язмаларның калган өлешен дә өстәп матбугатка бирергә булдым. Ул язмалар көндәлек рәвешендә языла башлаган иде. Ротада писарь булып утырганда, аен-числосын да күрсәтеп, язып бара алганмын... Каравыл хезмәтенә күчкәч, андый мөмкинлек бетте. Кайчан, кайда, ничек туры килсә, шулай гына язып бара башлаганмын. Әйтергә кирәк, хәрәкәттәге армиянең гади солдатына ниндидер дәфтәр тоту, шуңа күргән-ишеткәннәрен язып бару бик читен һәм бик хәвефле эш иде. Ятлар кулына төшмәсен дип, дәфтәрне дә иңемдәге кыр сумкасында гына йөртергә туры килә иде. (Сержант дәрәҗәсендәге разводящий булгач, минем сумка асып йөрергә хакым бар иде.) Язганнарым, билгеле, бик чуар — күргәннәрем дә, кичергәннәрем дә бергә аралашып беткәннәр. Шуңа күрә мин, капчыкны төбеннән тотып селекмәс өчен, дәфтәргә язылганнарның төрлесеннән чүпләп кенә алырга булдым. (Алары да шактый ук җыелды.) Хөрмәтле укучы, әлбәттә, бер хакыйкатьне исендә тотарга тиеш: аңа тәкъдим ителгән бу кыска язмалар моннан 50—53 еллар элек авыр, газаплы, куркыныч фронт шартларында язылган иде. Хәзер исә мин шуларны иске дәфтәрдән ак кәгазьгә сүзгә-сүз күчереп кенә чыктым.*

*10 декабрь, 1941.*

Көн томанлы һәм җылымса... Йөрәктә җыр һәм сагыну...

Бу сугыш беренче дөнья сугышының дәвамы, һәм

хәзерге һәлакәтнең башлыча гаепчесе Англия булырга тиеш... дип уйлыйм мин.

Минем белән хезмәт итүче Горбунов сөйли: без бит биш бертуган армиягә алынган идек. Берсе су асты көймәсе белән һәлак булды, икенчесе очучы иде — самолеты белән янды, өченчесе пехотада үлде. Янә иң кече сеңелебез госпитальдә эшли иде, мәҗрух немец пычак белән кулына чәнечкән... Горбунов моны миңа елмайган чырай белән, кычкырып, бүлмәне яңгыратып сөйли. Гүя сүз күпме аракы эчә алу турында бара... Аңла кешене!.. Алдамаса?!

*11 декабрь.*

Күктә батмаган ай, морҗалардан төтеннәр туры күтәрелә... Янә салкынайта.

Менә өченче көн инде йотлыгып гәзитә укыйбыз. Япония Америка һәм Англия өстенә ташланды. Әфәнделәр үзара килешә алмадылар: берсе сораганны икенчесе бирмәде, һәм океан сугышы башланды.

Күпләр бу яңа сугышның безнең өчен шактый зур киртә булуын әйтәләр... Ләкин һәркем диярлек Американың сугышка тартылуына эченнән куана, «үз җилкәсендә татып карасын әле» диләр. Чыннан да, сугышмыйча гына сугышка катнашу зур оятсызлык булырга тиеш. Халык моны сизә.

*12 декабрь.*

Көнбатыштан җил исте... Түбәләрдән тамчы тама, кар басыла, өсте бик юка гына шадраланып ката... Юллар, сукмаклар каты, тайгак... Урман өстендә көзге томан.

...Бер генә илнең дә солдаты сугышның ни өчен кирәклеген, ни өчен сугышканын бервакытта да белмәде һәм белми... Кан коюның чын сәбәпләрен халык бервакытта да аңламый, чөнки беркемнең дә вакытсыз үләсе килми... Халыкны сугыштырган нәрсә — власть, көчләү... һәм өндәү, үгетләү белән исертү...

Шекспирны укып маташам, ләкин авырлык белән... Ничектер безнең әдәбиятка хас ясалмалык аңарда бар кебек... XIX гасырда бер генә бөек язучының да аңа ияреп маташканын хәтерләмим.

«Әй күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы...»

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Яшьлекнең ләззәте сызлану яшьләренә манчылган беренче мәхәббәте хакында язасы килә... бик килә... Ә сугыш?!

*16 декабрь.*

Бүген ишелеп кар ява. Юлларда көрт, йөрүе авыр. Өй түбәләренә, агач ботакларына кабартылган мамыктай кар

өеләһ... Көн шактый җылынды... Гаҗәп, һава көн саен үзгәреп тора.

Соңгы 3—4 көн эчендә фронтлардан күңелле хәбәрләр килә башлады. Егетләрдә күтәренке рух... Бу хәбәрләр белән чыккан сүз сиздермәстән һаман сугышның кайчан бетү мәсьәләсенә кайтып кала. Һәркем тизрәк бетүен тели, ләкин бик аз кеше генә тиз бетүенә ышана.

Гаҗәп, бу тирәләрдә гел урман булса да, кошлар бер дә күренмиләр. Тик ала каргалар гына юл буенда сикерә-сикерә йөриләр. Хәтта чыпчыклар да юк.

*18 декабрь.*

Нәкъ кичәге һава... Бер дә сугыш барлыгын хәтерләтә торган көн түгел.

Бу сугыштан беренче сабак: масаймау һәм чама белмичә мактанмау...

Бу сугышта җиңүнең әһәмияте Үктәбер революциясенең әһәмияте белән бәрабәр булачак. Шуңа күрә бу сугыштан җиңеп чыккан халыкның бик күп хакы булырга тиеш.

*20 декабрь.*

Кичә кичке 6 дан бүген кичке 6 га кадәр штабта дежур булып тордым. Бу үзенә күрә мәшәкатьле генә бер эш... Көннең нинди икәнен дә юньләп күрми калдым. Ләкин йомшак, матур кебек иде.

Штабка шактый картайган, ләкин чибәрлеген җуймаган бер хатын килде. Аның ире каты авыру икән, шуны күрергә килгән. Хатынының бәхете бар, күрәсең, бүген ирен каядыр икенче бер госпитальгә озатырга җыенган вакытта килеп өлгерде... Бичара хатын иртәдән алып кичкә кадәр иренең санчастьтан чыгарылганын көтеп, салкын коридорда утырды... Мин аңа кухнядан ике котелок белән аш һәм ботка китереп бирдем. Рәхмәт әйткәндә, тавышы калтырап, күзеннән яшьләре тәгәрәп китте... Мин дә аның яныннан тизрәк китәргә ашыктым.

Сугыш вакытында үлемнән курку кайчагында салкын суга кереп, чиркану алу шикеллерәк булып тоела (чиркану алганнан соң курку кими дип тә өстисем калган икән).

*23 декабрь.*

...Юеш җил исә, ара-тирә түбәләрдән тамчылар ычкынып очып китә, кар җепшекләнеп басыла, йөргәндә кисәк-кисәк аякка ябыша... Нигәдер бик күңелсез...

...Ничәмә гасырлар буенча акыл ияләре кешелек, туганлык, гаделлек идеяләрен трибуналардан сөйләделәр,

романнарда яздылар, шигырь белән җырладылар, киндергә буяу белән яздылар, музыкага салдылар... Һәм менә каяндыр бер явыз кеше килеп чыкты да, балалар уенчыгын тибеп очырган җиңеллек белән, ул идеяләрнең һәммәсен таптап, дөньяның астын өскә китерде.

Идея — тормыш түгел, аның бер бизәге генә икән ул... Идеяне таптау — ачу килгәндә тоз савытын күтәреп бәрү белән бер икән.

Бу заманда идеяләргә кытлык юк. Теләсә нинди хәрәкәтне аклар өчен кешелек базарыннан яраклы идеяне табып була.

*24 декабрь.*

«Ян йөрәк, ян, кан бирелгән сиңа янарга».

Ә шулай да бу заман — бер-ике-өч идеянең монополия заманы... Идеяләр монополиясе тудырган бу сугыш та кешелек тарихында моңарчы күрелмәгән иң коточкыч, иң дәһшәтле бер сугыш... Ярминкә шикелле идеяләргә бай XIX гасырда мондый сугышның булуы мөмкин түгел иде.

Бүген үземә артык уйланмаска, йөрәкне сизмәскә, башкалар кебек солы боткасын тыныч кына ашарга һәм гырылдап йокларга сүз биргән булдым.

*27 декабрь.*

Бүген буран, суык, мәрхәмәтсез буран... Җылы учак алдында куырган борчак ашап, әкият тыңлап утырган балачаклар кайда?!

Буран басылды, акрын гына караңгы төшә... Тынлык, моңсу тынлык... Кешеләр, кайда сезнең бәхетегез?..

*30 декабрь.*

Кичәдән бирле безнең полкка бик күп җәрәхәтле һәм өшегән кызылармеецлар киләләр... Йөзләрендә аларның һичбер нинди кайгы да, куаныч та юк кебек...

**Искәрмә:** 1941 елның декабрендә дәфтәргә язылганнардан чүпләп алынган кыска гына өзекләр хәзергә шуның белән тәмам. Бу өзекләр фронттан шактый еракта Кафтино дигән станция тирәсенә урнашкан 153 нче запас полкның штабында хезмәт иткәндә язылганнар иде. Күчерелгән кадәресендә дә минем шул чактагы уй-кичерешләрем күпмедер дәрәҗәдә чагылса кирәк...

**Икенче искәрмә:** 1942 елның башыннан ук запас полкта чират көтеп ятучылардан хәрәкәттәге бер армия өчен аерым рота төзеп, тиз генә фронтка озаттылар. Мин дә шул ротада писарь булып китеп бардым. Моннан соң дәфтәргә язганнарның барысы да ротада хезмәт иткәндә

күргән-кичергәннәрдән гыйбарәт. Билгеле, аларның да бик аз өлешен генә чүпләп күчерәм.

*6 гыйнвар, 1942.*

Бер атна вакыт яшен тизлеге белән үтте дә китте. Запас полк урнашкан, элек заманда алпавыт имениесе булган өч катлы, зур террасалы, манаралы һәм бай китапханәле йорттан ничек аерылганымны сизми дә калдым. Әйтерсең җил очырып алып китте... Кыска гына вакыт эчендә ике урынга күчү һәм яңа кешеләр белән очрашу... Кызганыч, язарга мөмкинлек юк.

Яңа ел туган булды... Ничек һәм нинди кәеф белән каршы алуымны яза алмый калдым. Тик гомеремдә беренче мәртәбә үткән елны кызгандым. Киресенчә, артыннан төкереп каласым килде... Барыбер гомер үтә инде, әйдә аның мәгънәсез, газаплы өлеше тизрәк, тизрәк үтә бирсен!

Дөньясын, сугышын онытып, «Анна Каренина»ны укыйм. Иптәшләрдән уңайсыз, ләкин тыелырга һич тә әмәл юк.

*8 гыйнвар.*

Эш күп, тәртипсезлек тә җитәрлек... Хатлар язарга иде, һич бушап булмый... Яңа эш, яңа кешеләр, үзара талаш...

Гоголь, Толстой, Чехов, Горькийлар тәнкыйть иткән сыйфатлар урыс кешеләрендә бик нык саклана әле. Ул сыйфатлардан иң әшәке һәм көчлеләре — тупаслык, масаю... Һәм унтер пришибеевчылык... Күрәсең, яхшы белән яман сыйфатлар бик озак заманнар бергә килешеп яши алалар.

*11 гыйнвар.*

Аз гына эштән бушадым, һәм әрнеп эч поша башлады. Вак писарлык эше, талашу һәм сүгенүләр белән гасабиланып көн буена бәргәләнү вакытны үтерә, уйлар һәм дөнья хәлләре белән кызыксынулар югала... Бу кечкенә авылда яшәү — ташландык утрауда яшәү кебек... Бирегә килгәннән бирле бер гәзитә күргән, бер сводка ишеткән юк... Берничә көн әүвәл станциядән кайткан егетләр, безнекеләр Одессаны, Харьковны, Смоленскийны алганнар, дип сөйләделәр. Башта ук күңел ышанып бетмәгән иде, чыннан да, ялган хәбәр булды шикелле... Чөнки бу куанычлы хәбәрне егетләр бик тиз оныттылар.

Ә бу комсыз сугыш йотар әле, йотар!.. Һәр иртә өмет белән уянган халыкның башын, таулар ишелгәндәй, яңадан-яңа һәлакәтләр белән исәнгерәтер әле...

*13 гыйнвар.*

Бүген янә алга таба китәбез... Чатнама, тешләргә тия торган суык... Алда нәрсә көтә — белгән юк.

*19 гыйнвар.*

Менә өченче көн инде дошман самолетлары һаман килеп «күчтәнәчләрен» ташлап, борчып торалар. Корбаннар аз гына булса да булгалап тора. Чын сугыш та юк, тынычлык та юк... Нервларга Ходай чыдамлык бирсен. Тәрәзә яныннан торып китүем булды — бомба шартлавыннан бөтен өлгеләр чәчрәп төштеләр... Берничә секунд кузгалмыйча торсам, битем пыяла ватыгы белән тулган булыр иде.

*25 гыйнвар.*

Кичә һәм бүген җелекләргә үтә торган суык. Температура 40 тан түбән... Менә шул «корал» белән без шактый отып калырга тиешбез. Ә корал шулай да ике-йөзле...

Немецлардан бушаган авылларда булдым... Кисәү исе көчле иде.

Мин торган йорт янына бомба төшеп, бөтен квартираларның бер таза җирен калдырмады. Ишелгән стеналар, каерылып ташланган ишек-тәрәзәләр, чәлпәрәмә килгән җиһазлар... Хәтта мичләрдә бүрек кадәр тишекләр... Берничә үлгән кеше һәм бик күп авыр яраланучылар... Әгәр шул чакта мин өйдә булган булсам?!

*1 февраль.*

Һәркемнең уенда бары бер сорау: кайчан бетәр икән? Һәркемнең күңелендә борчылып көтү: кайчан ул көн туар икән?.. Туасы яз — табигать язы гына түгел ул... Һәркем үз язын көтә... Табигать язы тумыйча калмаган кебек кешелек язы да тумыйча калмас.

*11 февраль.*

...Тын, кояшлы көн... Күк аяз, сыек зәңгәр... Түбәләрдән беренче тамчылар, нурлар чагылдырып, ак мамыктай күперенгән кар өстенә тамалар... Һавада яз сулышы... Йөрәктә озак яшәү, яңа бәхетләргә ирешү өмете... Мондый көнне сугыш та каты, үлем дә күп була, гадәттә...

*17 февраль.*

Кыскартып күчерәм.

Кичә кич белән безнең ротага пленга төшкән дүрт немец солдатын китергәннәр иде. Бүген шуларны кухняда күрдем. Ашап утыралар. Безнекеләр, 7—8 кеше,

аларны чорнап алганнар һәм ашауларын зур игътибар белән карап торалар... Немецлар бик кызганыч кыяфәттә күренәләр. Дүртесе дә бик яшьләр. Өсләрендә юка, сәләмә шинель, башларында җәйге пилотка, аякларында итек өстеннән кигән иләмсез зур каталар... Һәркайсының чәчләре җиткән, йөзләре ак... Кулы мәҗрух күзлеклесе бөтенләй бала кыяфәтендә... Ләкин алар безнекеләргә бик тыныч, бер дә шүрләмичә, ничектер ышанып карыйлар. Безнекеләр дә гадәтләре буенча сүгенмиләр дә, ачу да күрсәтмиләр, сүзсез генә карап торалар... Повар исә аларны көчли-көчли күбрәк ашарга кыстый... Немецларның берсе баш бармагын авызына куеп, эчәсе килгәнен аңлатты. Бер иптәш котелок белән су китереп бирде... Бу күренешнең тәэсире кызык кына иде: гүя бернинди сугыш та, дошманнар да юк кебек... Чыннан да, бу дүрт немецта аз гына булса да гаебен тою, оялу, вөҗдан газабы дигән нәрсә бар микән?..

*23 февраль.*

Кичә һәм бүген дошман самолетлары зур активлык күрсәттеләр. Корбаннар һаман булып тора.

Бүген безнең станциягә ташланган бомбадан 6 кеше үлеп, 13 кеше җәрәхәтләнде... Платформа өстендә торган бер тракторны әллә кая кадәр күтәреп ыргыткан.

*25 февраль.*

Якындагы станцияне дошман самолетлары бик каты бомбага тоттылар. Алар 4 мәртәбә безнең баш очыбызга әйләнеп килделәр. Һәр килүләрендә дистәләп ыргытылган бомба һәм пулеметтан сиптерү... Һәркемнең нервлары бик җигелде... Агарынган йөзләр, калтыранган иреннәр... Безнең бер иптәшне җәрәхәтләде, берәү һәлак булды.

...Дәһшәтле көн үткәннән соң, кич белән баракның зур, салкын бер бүлмәсендә тавышлы кино күрсәттеләр. Картина «Концерт-власть» дип атала иде. Д.Ойстрахны, И.Козловскийны тыңладым, Лепешинскаяны күрдем. Балет «Аккош күле» иде. Картина миңа бик ошады. Тормыш иң вафасыз, иң кабахәт дәһшәтләрне дә гөлләр белән бизи белә...

Йотлыгып Сенкевичның «Без догмата»сын укыйм. Ифрат ошый. Мәгънәгә, хисләргә бай әсәр.

*7 март.*

Без янә яңа урында. Бу инде дошманнан бушаган җир. Хәзергә тынычлык. Хәер, дошман без килгәнче үз эшен эшләп өлгергән инде...

Яз аеның беренче көннәре каты суыклар белән башланды.

*13 март.*

Бүген суык, буран. Яз килергә ашыкмый. Хәер, мондый һавадан зарлану юк. Киресенчә, һаман шулай булып торуын телиләр. Кичә аяз иде һәм дошман самолетлары безне яхшы ук «сыйлый» киттеләр. Бүген станция тирәсендә бик күп ат гәүдәләре аунап ята. Бу мәхлуклар фронтта эшләп хәлсезләнгәч, авыргач, ял өчен тылга кайтып баралар иде...

...Бушлык... Һичнәрсә турында уйлыйсы килми... Дөнья тарихының бөек көннәре!.. Ә иртәгә нәрсә буласы белән кызыксынырга ирендерә. Бу хәл күп кешеләрдә сизелә. Уйлау ничектер авыр йөк булып тоела башлады.

«Человеческая душа, точно пчела, которая ищет сладости даже на горьких цветах». (Г.Сенкевич. «Без догмата».)

*15 март.*

Кичә һәм бүген үткен пычак шикелле кисә торган җил... Бу җил тәнне генә түгел, йөрәкне дә өшетә кебек... Кичә дошман самолетлары өч тапкыр килеп, бомбага тотып киттеләр. Зарар һәм корбаннар шактый булды... Безнең бер иптәшнең бары аркасы гына торып калган иде. Башын эзләсәләр дә, таба алмадылар.

Бүген бер иптәш үлекләрнең кесәләреннән вак-төяк әйберләрен җыеп алып кайтты. Кешенең кесәсеннән ниләр генә чыкмый: өеннән килгән хатлар, тузган бумажник белән акчасы, чүпрәккә төргән сабын кисәге, тәмәке янчыгы, берничә кара сохари, ниндидер каеш кисәкләре, кадаклар, атылган гильзалар... Нәрсәгә кирәк булгандыр алар бичарага?!

Кич белән сүз һаман сугышның кайчан бетүе турында булды.

*20 март.*

...Каяндыр шушындый хәбәр таралган: имеш, 22 мартта сугыш бетә икән... Кычкырып торган уйдырма булуына карамастан, бу хәбәр күпләрнең теленнән төшми. Күрәсең, күңелләренә якын ялганнан аерыласылары килми.

*21 март.*

Бүген иртәнге ашка дошман самолетлары килеп җиттеләр. Кызык хәл, каргалар, самолет тавышын ишетүгә, көтүләре белән һавага күтәрелеп, кычкыра-кычкыра оча башлыйлар. Бичаралар, үлемнән алар да куркалар...

Үлгән вакытта кешенең уена бөтен үткәне һәм якыннары килә, диләр. Белмим ничектер... Ләкин туктаусыз

үлем куркынычы астында йөргән кеше үткәнен дә оныта, киләчәге турында уйларга да иренә... Кеше ничектер үзендә авыр бер бушлык тоя, уйлыйм дисә дә, уйлый алмый... Еш кына аның йоклыйсы гына килә...

*25 март* .

Хәзергә тынычлык. Сугыш, үлем барлыгын акыл гына исендә тота.

*31 март.*

«Местам и годам нет возврата». (Пушкин.)

Кайчан башыма: кешелек дөньясының бөтен фаҗигасе кешеләрнең кыска гомерле булуларында түгелме икән дигән җүләр уй килә.

Мин күрәм: сугыш һәркемнең чын табигатенә каршы чиркандыргыч бер нәрсә... Бу, минемчә, бөтен дөнья, бөтен халыклар өчен дә шулай... Шул ук вакытта бөтен илләрнең халыклары җылап, сыкрап, сугышны нәләтлинәләтли сугышалар... Йә, моңардан да зур фаҗига булырга мөмкинме?!

*6 апрель.*

Язның сөенече аз. Көн аяз булган саен, куркыныч шулхәтле көчлерәк... Зәңгәр күктән иңгән сөенеч, дәрт нурларына төренеп гүя үлем килә. Кичә безне иң әшәке рәвештә бомбага тоту булды.

Үлемне белмәгән кеше аңардан курыкмый, яки еш очраткан кеше аңарга ничектер ияләшә. Үлем белән очрашуның бик ансат булуын белгән, ләкин ияләнергә өлгермәгән кеше исә аңардан бик курка.

*9 апрель.*

Бүген сыерчыклар килделәр.

*11 апрель.*

Өч-дүрт көн тыныч кына торганнан соң, бүген безне янә һавадан бик каты «сыйлап» киттеләр.

Аз гына томанлы, җылы, талгын көн иде... Бүрәнәләр өстендә ак кәҗә аякларын сузып йоклап ята... Бер өйдән патефон тавышы ишетелә. Тереклек — таза үскән олы бер чәчәк ул... Үлем исә — ара-тирә кинәт исеп куйган зәһәр җил... Җил, чәчәкнең берәр яфрагын өзеп китсә дә, аны бервакытта да ега-сындыра алмый...

*13 апрель.*

Кояшлы тын иртә... Талпынып-талпынып сыерчыклар сайрыйлар. Юка боз астыннан чылтырап елгачыклар ага... Җир ашыкмыйча гына тирли, парлана.

Сугыш?.. Юк ул!.. Бу минутта һәркемдә бала йөрәге, ә бала йөрәге хәтәр барын белми, беләсе дә килми.

*16 апрель.*

Бүген мин үлемгә бик якын булдым, бомба миннән бер 15 метрда гына шартлады.

*24 апрель.*

Бүген дошман үзенең бомбасын без торган җиргә төбәп ыргытты. Бер бомба атлар сараеның почмагына эләкте. Хайваннар кычкырмыйча, сукранмыйча соңгы сулышларын алып яталар. Бер атның корсагы тишелеп, эченнән карта-эчәкләре чыгып, асылынып тора иде. Ат сарайдан үз аягы белән чыкты... Әкрен генә атлап китте, бераз баргач туктап, башын борып, актарылып чыккан эченә карап торды да, ашыкмыйча гына таза ягы белән җиргә ятты... Командир, килеп, аның маңгаена атты һәм атыбыз «шулай кирәк» дигәндәй, тыныч кына җан бирде.

...Ат җигеп торган солдатның башын да, аякларын да таба алмадылар. Кесәсеннән күптән түгел генә төшкән фотосы чыкты... Хәзер ул миндә... Ничек кенә итеп мин аны гаиләсенә җибәрим икән?!

Нигъмәт исемле солдатка Башкортстанда яшәүче сеңлесе Шәрифәдән килгән хаттан бер өзек:

«Сезки сөекле дөньяда иң якын күргән кадерле абыем сиңа безки туганың Шәрифәдән күңелемнең иң нечкә җирләреннән парланып чыккан ялкынлы саф сәламемне җибәреп, алма бакчасында төрле матур гөлләргә кунып, тирән уйларга чумып сайраган сандугач-былбыллар санынча сагынып, саргаеп, абыем, синең нурлы йөзләреңне бер күрергә зар-интизарлар булып, өзелеп, күп сәламнәремне, абыем, сиңа бүләк итәм...»

Йа Хода! — нинди бәгырь өзгеч тирән сагышлар яткан кеше күңеленең төпкелләрендә! Бу хатны Нигъмәт абый түш кесәсендә догалы бер бөти итеп йөртәчәктер, мөгаен... Бәлки, әле аңа туган иленә исән-сау кайтырга да насыйп булгандыр... Һәр солдатның иң яшерен бердәнбер теләге шул иде бит!

*30 апрель.*

Кичә салкын иде... Бүген иртә белән кар яуды. Җир өсте янә ап-ак булды... Көн уртасына таба һава ачылды, кояш чыкты. Кар ашыга-ашыга эреде. Җир парлана, һава җылына — һәм язның куркынып агарган йөзе дә нурланып елмайган кебек булды...

Кәеф тә бүгенге һава кебек иде... Иртәгә бәйрәм ди-

гән уйдан ул иске гадәт буенча куанып та карады, әрнүле сагышка да бирелде, өметләнеп, гамьсез дә булырга тырышты... Ләкин ерактагы хәрәкәтсез зәңгәр офык шикелле һаман да бер ялкау моңсулыкка төренеп кала бирде.

Кичке тынлык... Ә шулай да «Галиябану» бик матур көй...

*6 май.*

Беренче май көннәре үтеп китте... Яз артта калган кебек... Кичә көн буена зәһәр, суык җил исте... Бүген исә җир өсте тагын ап-ак кар... Әле дә һаман явып тора.

Кайберәүләр 4—5 көн буена баш күтәрмичә эчтеләр. Безнең старшина 4 көн буена кайда кунганын, наганын кайда югалтканын, кем белән сугышканын белмичә йөрде. Кансызлык, авызын ачкан саен сүгенү дә алдашу, урлашуны иң мактаулы егетлектән санау — менә аның чын йөзе... Аның ул «егетлекләрен» һәркем белә, ләкин күпләр аңа каршы сүз әйтүдән саклана: «көчле белән көрәшмә!» янәсе. Әмма шул кабахәтне көчле дип тану өчен, никадәр түбән һәм куркак булырга кирәк.

Ә менә Чакмагыштан бер иптәшне рөхсәтсез 50 грамм аракы алып эчкән өчен, 5 елга хөкем итеп, алгы сызыкка җибәрделәр... Гомумән, бездәге хаклыкны «аучының сарыгын кем ашаган?» мәсәле белән бик яхшы аңлатып бирергә була.

*7 май.*

Менә икенче көн инде дошман самолетларының һавада күренгәннәре юк. Алар күренмәгәч, күпләргә сугыш та юк булып тоела башлый.

Безнең солдатлар арасында каяндыр төрле хәбәрләр дә тарала башлады инде, имеш, немецлар солых сорыйлар икән, май аенда сугыш, һичшиксез, бетәргә тиеш, безнең фронттан солдатларны өйләренә җибәрә дә башлаганнар, имеш... Мондый хәбәрләрнең көче шундый зур ки, кешеләр сүзләрен әйткәнче иң элек ирексездән бөтен битләре белән җәелеп елмаялар... Чыннан да, әгәр шуннан сугыш кинәт туктап куйса, кайберәүләр куанычларыннан акылдан шашарлар иде бугай.

...Язучы бервакытта да искренно (татарчасын эзләп торырга вакыт юк) була алмый... Башына килгән берәр нәрсәне язарга утыру белән, әйтерсең ниндидер бер күзгә күренмәс көч каләменең очыннан тотып ала да, язучының чын уйлары белән артык хисаплашмыйча, үзенчә йөртә дә башлый.

Кешенең тел байлыгы акыл байлыгыннан артта калып йөрми микән?.. Алай дисәң, Толстой бар, Ленин бар...

*10 май.*

Кичә без торган җирне иң әшәке рәвештә бомбага тоту булды. Бүген инде күпләр үзләренең моннан берике көн элек кенә «сугыш бетә» дип, балаларча куануларыннан оялып йөриләр.

Соңгы көннәрдә сугыш үзенең усал чыраен тагы да ачыграк күрсәтә башлады... Кай көннәрне һава һөҗүме безне бөтенләй җиргә кадаклап куя.

Бер бомба мин яшеренгән окоптан 2—3 метрда гына төшеп шартлады... Бәләкәе булгандыр, ахрысы...

**Искәрмә:** шушы урында бу «көндәлек» шактый озак вакыт өзелеп тора (Фронтта бөтенләй дә өзелүе мөмкин ич!)... Бары дүрт айдан соң гына мин тагын язгалый башлаганмын. Фронтта сугышның тыныч торган чагы иде, без дә бөтен җәебезне Охват дигән зур гына күл буендагы кара урманда, караңгы землянкаларда эшсез ятып үткәрдек.

*24 август.*

Өч ай ярым вакыт кызу, ләкин сизелмичә аккан су шикелле үтте дә китте. Бу вакыт эчендә ниләр булды?.. Әгәр тыныч яткан күлдәге балыкларның ара-тирә генә чумып куюын хәтерләткән вак-төяк вакытларны бергә җыйсаң, шулар җәйнең бер озын көненә сыеп бетәр иде, мөгаен... калган вакыт исә нәрсә белән тутырырга мөмкин булмаган ниндидер бер бушлыктан гыйбарәт. Әйләнә-тирәбездәге җанлы табигать тә бездән читтә кебек, без аны ничектер тоймыйча яшибез. Ара-тирә тукранның агач чукыган тавышы яисә берәр тиеннең ботаклар селкетеп бер агачтан икенче агачка сикерүе генә безне кайчагында барган җиребездән туктап калырга мәҗбүр итә, һәм без әйләнәбездәге шушы тере сулышлы, серле табигатькә яңа гына күргәндәй гаҗәпләнеп карыйбыз. Әмма бик тиз янә онытабыз... Ни өчен бу болай?..

Бүген беренче мәртәбә айлы кичне күрдем. Тулган ай күл аръягындагы караңгы агачлар өстендә түп-түгәрәк зур бер сары тап булып хәрәкәтсез генә тора. Аңардан нур таралганы һич тә сизелми; әйтерсең сыек зәңгәр күлне түгәрәкләп тишкәннәр дә, кәгазь ябыштырып, артына лампа яндырып куйганнар.

...Кичке табигатьнең хәрәкәтсезлегенә һәм тынлыгына искитәрлек иде. Әгәр җирдән, судан сизелер-сизелмәс җылылык бөркелеп тормаса, аны тәмам үлгән дип уйларга мөмкин булыр иде. Мин юри басмага төшеп, тирә-юньгә бик озак колак салып тордым. Судан булсын, агачлардан булсын, ник бер шылт иткән тавыш ишетелсен, ник бер зәгыйфь кенә хәрәкәт барлыгы сизелсен!..

Бу тынлык, бу хәрәкәтсезлек шулкадәр тирән иде ки, хәтта минем сулыш алуым табигатьнең бу бөек тик торуын боза кебек тоела иде үземә...

*8 ноябрь.*

Бөек Октябрь революциясенең 25 еллыгын үткәрдек. Былтыр бу бәйрәмне мин бер авылның кара мунчасында ялгыз каршы алган идем. Инде бер ел үткәнгә һич ышанасы килми. Бәйрәмнәрнең килеп китүе гомернең никадәр тиз үткәнен генә күрсәтә. 1917 елны миңа сигез яшь иде, хәзер утыз өч яшь.

Кичә бераз аракы һәм самогон эчтем. Ихластан сөйләшергә бер генә дә якын кеше юк...

Кичкә таба ике дошман самолеты, килеп, берничә бомба ташлап киттеләр. Безнең яңа начальник башына бомба кыйпылчыгы тиеп һәлак булды. Безгә килүенә бер 15 кенә көн иде. Мин аны юньләп күрмичә дә калдым.

Кич белән кәеф начар иде һәм әрнетеп эч пошты.

Юлбашчының кичә сөйләгән сүзләрен безнең ишеткәнебез юк әле. Көтәбез.

Быел һәркем дошманны тизрәк тар-мар итү, җиңү теләге белән яна.

Былтыр исә тизрәк сугыш бетсен өчен җиңелүне теләүчеләр дә юк түгел иде.

*25 ноябрь.*

Соңгы хәбәрләр кешеләрнең йөрәкләрен дә, хыялларын да канатландыра. Аларда шундый көчле теләк ки, дошман белән эшне мөмкин булса, бер айда, бер атнада, бер көндә бетерерләр иде. Чыннан да, күпләрдә сугышның бетүе бик тиз булыр дип уйлау көчле... Тик аерым кешеләр генә хыялларын йөгәнләбрәк торалар, вакыйгалар турында салкын кан, айнык акыл белән уйларга тырышалар. Алданудан саклананалар булса кирәк... Шулай да сугыштан туйю кешеләрнең теләкләрен бик нык берләштерә...

Сугыштан соң булачак тормыш белән кызыксыну юк дәрәҗәдә аз. Ләкин бер кызыклы сөйләшү булды. Соңгы хәбәрләр турында сөйләшеп утырганда, үзеннән-үзе бер сорау туды: бу сугыштан соң яңадан сугыш булырмы?.. Тынычлык дәвере озак дәвам итәрме?

Сөйләшүчеләрнең фикере шул иде: тынычлык дәвере шактый озак булыр... Һәрхәлдә, соңгы ике зур сугыш арасындагы дәвергә караганда да озаграк дәвам итәргә тиеш. Ләкин барыбер иртәме-соңмы яңа сугыш тагын да катырак сугыш булачак... Әлбәттә, безнең белән калган илләр арасында.

«Человек, которому плоть дороже его чести — низкий тип». (*Автор неизвестен.*)

Бу сүзләрнең мәгънәсен мин аеруча тирән аңлыйм.

«Гений никогда не упреждает своего времени, но всегда только угадывает его не для всех видимое содержание и смысл». (Белинский.)

Әгәр мин бөтен уйлаганымны әйтеп бетерә алмасам, димәк, мин ирекле, хөр кеше түгелмен.

*29 гыйнвар, 1943.*

Үткән төнне дошман самолеты станциягә бары бер бомба ташлап китте. Ләкин бу бер бомбаның афәте бик зур булды. Дистәгә якын вагон янды. Мин вагон астында янып яткан кешеләрне күрдем. Өч кеше тәмам янып беткәннәр иде. Бик кечерәеп калган һәм кеше гәүдәсе икәнен кара кисәүләрнең ни рәвештә ятуыннан гына белергә мөмкин иде. Шул кисәүләр уртасында тәрилкәгә салган шикелле, кешенең эчәкләре өелеп ята!.. Аксары эчәкләр күмерләнгән кара кисәүләр уртасында!.. Мин моны бервакытта да онытмам!

Кешеләргә нәрсә кирәген белеп була, ә менә кешегә нәрсә кирәк?

Безнең гаскәрнең соңгы зур җиңүләре уңае белән сугышның язмышы турында уйлану, хыяллану, сөйләнү тагы да көчәя төште.

Мин каршымда утырган иптәшкә сорау бирәм:

— Әгәр немецлар бер җирдә дә безнең һөҗүмне туктата алмасалар, һәр фронтта аларны чорнап алу, кырып бетерү дәвам итсә, гомумән, немецларның безгә каршы фронты туракланып бетсә, немец армиясендә тоташ җимерелү һәм бөтен җирдә дә тәртипсез качу башланмасмы?

Иптәшнең җавабы кыска:

— Юк, немец армиясеннән моны көтеп булмый.

Мин сорыйм:

— Әгәр Германия үзенең көчен союзниклар көче белән чагыштырып карау нәтиҗәсендә безне һәм союзникларны җиңә алмаячагын төшенсә, якын киләчәктә капитулировать итмәсме?

Иптәш янә бик мәгънәле генә итеп җавап бирә:

— Германиянең капитулировать итүе җиде кат җир астында әле... Алар хәзергә Мәскәүдән 150 километрда гына торалар.

Иптәш салкын акыл кешесе, ә мин хыялланырга яратам.

*20 март.*

Без Великие Луки шәһәрендә.

Иң беренче уй: кеше нәрсәгә остарак — төзергәме, җимерергәме?.. Шәһәрдә бер генә исән калган телеграмм баганасы да юк ичмасам!

Кешелек дөньясының бөтен тарихы буена җыйган акыл һәм рухи байлыгы адәмнәргә нәрсә бирде? Шушы сугышнымы?

Кеше үз-үзен алдамыйча тора алмый булса кирәк... Һәм озак та үтмәс, шушы сугышны да законлаштырырга, кешелек дөньясының үсеше өчен кирәкле булган чарасыз бер баскычы итеп күрсәтергә тырышырлар.

Менә ике ай буена шәһәрдәге үлекләрне җыеп бетерә алмыйлар. Элек кеше мәче үләксәсе яныннан да чирканмыйча үтә алмый иде. Хәзер исә үлгән солдат җимерек шәһәрнең бер чүбе булып ята бирә. Әйләнеп караучы да юк. Немец үләксәләре яныннан көлеп, сүгенеп үтәләр... Кызганыч, менә үзебезнекеләрнең гәүдәләре урам буйларында айлар буена аунап яталар... Ә без бит алар хакында күпме мактау сүзләре язабыз!

Без урнашкан ватык йорттан 100—150 метрда гына бер олы өем үлекләр ята иде. Шуларны бомба чокырына ташлап, бик юка гына итеп күмделәр. Хәзер шул җиргә көн саен каргалар көтүе төшеп утыра.

*23 март.*

Кичә дошман снарядыннан ике кешебез җәрәхәтләнде. Бүген аты белән үлекләр ташып йөргәндә, кызылармеец Ефимов мина шартлавыннан һәлак булды. Минага арба арткы тәгәрмәче белән менгән булса кирәк. Арбадагы үлекләр кисәкләргә өзгәләнеп һавага очалар. Арба янәшәсендә дилбегә тотып барган Ефимовның битен, ярты башын актарып ташлый... Ат исә ничектер исән кала.

Ефимов бик юаш, аз сүзле, әйбәт кеше иде. Без аның белән 42 нче елның гыйнвар башыннан гел бер частьта булдык. Бичара, минем белән очрашкан саен, «Исәнме, писарь» дип дәшмичә калмый иде.

*27 март.*

Безнең союзниклар, имеш!.. Бу «союзниклар» безнең халыкның йөрәгендә хәзер ниләр кайнаганын аз гына белсәләр иде, ичмасам! Һәр үткән көн белән безнең кешеләрдә аларга каршы ихтыярсыз ачу кабара, йөрәкләрендә нәләт үсә. Аларның икенче фронт ачып безгә ярдәм итүләренә беркем дә ышанмый, ә сүз белән юатуларына оятсыз алдау дип карый. Чөнки алар тарафыннан сөйләнгән сүзләрнең безнең бер корбан бәясенә дә тормаганын һәркем бик яхшы аңлый.

...Күпләрдән минем:

— Англиягә каршы сугышсак, ирекле булып сугышырга барыр идем,— дип әйткәннәрен еш ишетергә туры килде.

Сыерчыкның сызгыруы кайчагында пуля сызгыруына охшап куя.

Мин постка йөри торган юлдан 10—15 метрлар читтә алты немец солдатының мәетләре череп ята. Алар әйләнәсендә җирдән беренче яшь үлән баш күтәреп чыгып килә... Һавада сабан тургайлары кояшка каршы очыпталпынып сайрашалар...

— Йә, комрадлар, яз матурмы? — дип дәшәсе килә... Тәүбә, тәүбә!..

Бүген пасха бәйрәме... Кайчандыр кешеләрнең балаларча шатлана торган көне иде. Бу гадәт күптән үтерелде. Һәм менә бүген кеше шатланасы урында үзен хәзерге олы бәхетсезлекләрнең гаепчесе итеп тоя... Уңайсыз, читен, гүя шатлану хакы бөтенләйгә югалган...

Повар безгә ит сумсасы пешереп маташа. Аның бик бәйрәм итәсе килә, кешеләрне бик теләп сыйлыйсы килә, тик алар бүген бәйрәм дип белсеннәр, тойсыннар, куансыннар гына иде. Кичә ул үзе:

— Ну, иртәгә пасха!.. Мин барыгызны да сыйларга тиеш,— диде.

Без аның өчен бәйрәмнең мәгънәсе идек... Ә без сумсаның пешкәнен түземсезлек белән көтәбез, ләкин арабыздан «бүген бәйрәм бит, егетләр!» диюче юк.

Мин мунча кереп чыктым. Минем тәнем чиста, җиңел, ул яши, тоя... Ә менә мунча юлы өстендә немецлар һаман череп яталар.

Сугышның кагыйдәсе шул инде. Бүген берәүләр йөри, икенчеләр аларның юлы өстендә череп яталар. Иртәгә, кем белә, тәннең чисталыгына, җиңеллегенә сокланган кеше аяк астында аунап ятыр, ә башкалар бер дә үлмәстәй булып йөрерләр.

«Я не позволю тащить меня на веревке даже в рай...» (М.Горький «Чудаки») Сүз дә юк, һәйбәт әйтелгән!..

**Искәрмә:** 1943 елның җәен без Великие Луки белән Невск арасындагы авылларда торып үткәрдек. Безнең фронтта һөҗүм сугышлары да шактый вакыт тынып торды. Бу, ихтимал, Латвиягә бәреп керер алдыннан зур хәзерлек, күп көч туплау белән бәйләнгән булгандыр... Шул сәбәпле минем кыска гына язмаларымда да сугыш юк диярлек. Ара-тирә ишеткән-күргәннәремне генә язып куйгалаганмын.

Бүген 22 июньдә бу тирәдә яшәүче халык печәнгә төште. Бер авылдан кайтышлый, мин бер төркем печән чабучыларны күрдем. 13 кешенең берсе — карт, уникесе хатын кыз... Алар торналарча тезелешеп, ашыкмыйча гына чабып баралар. Аякларын аерып куеп, бөгелмичә, җиңел, иркен чабалар... Кайчак туктап, чалгыларын кайрыйлар. Кайракларын кайда тоталардыр — күрмәдем. Безнең агайлар ыштан бөрмәләренә яки тула оек балагына тыгып куялар иде.

Яланнан бал исе килә.

Авылдан кайтышлый бер Җаек татарын очраттым. Алгы сызыктан авырып госпитальгә китеп бара. Очрашу кыска гына булса да, шактый сүз сөйләп өлгерде.

— Дүрт тапкыр сугышка кердем, бер генә тапкыр ранен да булмадым ичмасам, ди... Мин үзем нестроевой, ашказаным авырый, йөрәкнең дә рәте юк. Шуның аркасында мине һаман позициядән артка таба озаталар. Ә мин артта тора алмыйм, эчем поша, йөрәгем ярсый... Рапорт бирәм дә кире алгы позициягә кайтам. Менә бишенче тапкыр сугышка керү нияте белән барган идем, бәхетсезлеккә каршы, оборонада яталар икән. Чын сугыш юк, тик шунда бер-берсен үчекләп вакыт әрәм итәләр... Көтеп ята торгач, янә авырый башладым... Ахырда командирга әйттем: мин болай мылтык кочаклап ята алмыйм, разведкага җибәрегез, йә шунда үлеп калам, йә медаль алып чыгам, дидем. Көлә, мәлгунь!.. Сине, ди, кире артка җибәрәбез, әгәр яңадан терелеп кайтсаң, шул кайтуың өчен генә медаль бирербез, ди... Нишлисең, китәргә туры килде... Ленинград фронтында бер ай буена яман кызу сугыш эчендә булдым, күпме халык кырылып бетте, әллә ничә тапкыр пополнение килде — алар эреп бетә торды, ә миңа бернәрсә дә булмады. Тагын авырып чыгарга туры килде... Иптәшләр көләләр: ну, Галиев, өеңә хаҗдан кайткан шикелле кайтасың инде, диләр. Алар мине бөтенләйгә кайтып китә дип уйлаганнар. Чынлап та, миндә сугыштан алып чыккан өч немец сәгате, ике немец итеге бар иде... Йөри торгач, барсын да югалтып бетердем... Шулай, парин!.. Иллегә җитеп киләм инде, ә позициядән башка җирдә үземә тынычлык таба алмыйм.

Мин сорыйм:

— Илеңә кайтасың киләме?

— Килмәгән кайда ул!.. Йөгерә-йөгерә кайтып китәр идем... Миңа шул икесенең берсе булсын: йә өйгә, йә позициягә!..

Карабодай кыры яныннан үттем. Ул умарта шикелле

гөжләп тора иде. Аның һәрбер ак чәчәгендә бал корты утыра.

Урамда балтырган көпшәсе табып ашадым. Мин башта аны танымадым. Тик пәке белән кисеп алып, әрчеп ашый башлагач кына, тәменнән таныдым... Малай чактан ук үз кулым белән өзеп ашаганым юк иде.

Сугышның безнең территориядә бетүе дә бик мөмкин. Ләкин җиңү союзниклар тарафыннан булганга күрә, герман гаскәрләрен безнең җирдән чыгарырлар.

Июнь аенда безнең ротадан шактый халык алгы сызыкка озатылган иде... Хәзер кайберләренең җәрәхәтләнүе яки үлүләре турында хәбәрләр килә башлады... Әле күптән түгел генә киткәнгә күрә, аларның тере кыяфәтләре күз алдында саклана.

Фронтларда безнең уңышлар зур булган саен, икенче фронтның ачылу ихтималы ераклаша бара. Кара реакция Гитлерның безнең тарафтан тар-мар ителүен теләми булса кирәк.

Җәй үтте...

Көн шактый кыскарды. Хәзер караңгы төшүдән алып яктыра башлаганчыга кадәр йокыны тәмам туйдырып була... Иртә-кичләрен суык була башлады. Кеше әкренләп җирдән, табигатьтән ераклаша.

Яланнар бушап калды... Ялгыз моңаеп калган җир үзенең яңа хуҗасы — кышны көтеп алалмыйча интегер кебек... Болыннардан кешеләр эшләрен бетереп күптән киттеләр. Тик анда сирәк-мирәк башларына корыган чыбык кадаган кибәннәр генә торып калдылар... Килер вакыт, ул кибәннәр әйләнәсендә уралып бураннар уйнар... Хәзер исә ялгыз күбәләк, сөйгән чәчәген эзләп, кая кунарга белмичә аптырап очынган була.

Иртәләрен җир куе салкын ак томанга төренә. Һәр көн кичегеп чыккан кояш шул томан аша гүя теләртеләмәс кенә күтәрелеп маташа. Көн уртасында ул юмартланып балкыса да, әүвәлгечә табигатькә җан өрә алмый инде... Бары аның җылыкай-йомшак нурлары белән җир өстенә хәлсез ялкаулык, моңсу талгынлык кына җәелә. Дөнья төпсез дәртсез, бер уйга чумган кебек... Әйе, җәй үтте.

«Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы» («Хаҗи Морат»тан).

Кеше үзендә зур эшләргә көч һәм сәләт барлыгын сизә. Ләкин ул кечкенә эшләр колы булып яшәргә мәҗбүр. Чөнки аның заман хорына (күмәк җырга) катнашырга тавышы ярамый... Яки аңарда әрсезлек белән ялагайлык җитәрлек булмый. Менә шундый кешеләр-

нең бозылуларын һәм бик бозык булуларын күп күргәнем бар.

Илдә иҗтимагый һәм сәяси тормышның какшавы яки бер эзгә ныклап төшеп җитмәве нәтиҗәсендә, бозыклыкның гомуми төс алуы, «халыклашып» китүе бик мөмкин. Шулай ук фаҗигале вакыйгалар чорында (мәсәлән, сугыш вакытында) бозыклыкка каршы көрәш йомшарып, ул афәт корчаңгы чиредәй үзеннән-үзе тарала башлый. Билгеле, халыкта тормыштан гомуми ризасызлык үсүе дә аның таралуына бик нык ярдәм итә.

Минем атай карт сөйли торган иде:

— Таң Чулпаны калыкмыйча, таң әтәче кычкырмыйча торып, кеше сәфәргә чыкмый иде. Таң әтәче тавышыннан төнлә йөргән бөтен җен затлары качып бетәләр... Бөтен дөнья әтәчләре бер үк вакытларда — төн уртасында, таң атканда, көндезге сәгать 12 дә кычкыралар. Күктә Алланың бер әтәче бар, алар шуның тавышын ишетеп кычкыралар, имеш.

*9 март, 1944.*

Өч төрле шик безнең кешеләрнең йөрәгендә саклана:

1. Кырык дүртенче елда сугышның бетүенә ышанмау.

2. Союзникларның 44 нче елда икенче фронт ачуларына ышанмау.

3. Безнең белән союзниклар арасында чын дуслыкның булуына ышанып бетмәү.

Кем белән генә сөйләшергә туры килмәсен (солдаттан алып офицерга чаклы), шушы өч төрле шикне теге яки бу рәвештә әйтмичә калмыйлар. Матбугат ышандыруларына карамастан, халыкта мондый шикләрнең яшәве, кешеләрнең үзләренчә уйларга тырышуларын күрсәтә.

Сугышның тизрәк бетүен теләү һәм сугышны тизрәк бетерергә тырышу өчен, безнең халык татыган ике нәрсә Англия һәм Америка халыкларына җитми булса кирәк:

1. Бу сугыш китергән газап, бөлгенлек һәм бу сугыш йоткан корбаннар.

2. Дошманга карата булган ачу-нәфрәт.

Әгәр шушы ике нәрсәне алар безнең халык күргән, хис иткән дәрәҗәдә күрсәләр, хис итсәләр иде, һичшиксез, сугышның тизрәк бетүен якынлаштырырлар иде.

Ач бала тук баладай уйнамас,
Тук бала һичнәрсә турында уйламас.

*Казакъ мәкале*

«Я ненавижу ложь и насилие во всех видах» (Чехов).

Бөек әдип! Рөхсәт итегез, Сезнең бу сүзләрегезгә бөтен тәнем-җаным белән кушылырга.

*Июль.*

Безнекеләр Латвиянең түренә үк кереп киттеләр. Латвиягә барып кайткан кешеләр андагы крестьяннарның сигезәр сыеры бар, дип сөйлиләр. Аларда колхоз булырмы икән, юкмы икән дип кызыксыналар...

Бүген шуннан кайткан бер мәҗрух сержант белән сөйләштем... Немецлар үзләре артык каршылык күрсәтмиләр, бигрәк тә власовчылар һәм латышлар нык каршы торалар, усал сугышалар, дип сөйләде ул... Кулга төшкән власовчыларны безнекеләр шунда ук атып үтерәләр икән.

Бүген (29 июльдә) кыска гына бер төш күрдем:

Бик күп халык поездда китеп барабыз, имеш. Бермәлне вагон тәрәзәсеннән карасам, алда юлның рельслары юк, имеш. Ләкин поезд тизлеген һич әкренәйтмичә, рельссыз юл белән китте дә барды... Юл бик начар, чокырлы-чакырлы... Вагоннар, авып китәрдәй булып, әле бер якка, әле икенче якка селкенәләр... Ләкин бу начар юл озын булмады. Паровоз, яңадан рельслы юлга чыгып, шәп кенә китеп барды, һәм озак та үтмичә без бер станциягә җитеп тә туктадык...

Бу төшне торгач, казах солдатларга сөйләдем. Барысы да яхшы, бик яхшы! — диештеләр һәм төшне тиздән сугыш бетүгә юрадылар. Аннары төшнең чынга чыгуын теләп, кул күтәреп дога да кылдылар.

«Заря сияла, на востоке, и золотые ряды облаков, казалось, ожидали солнца, как царедворцы ожидают государя...» (Пушкин «Барышня-крестьянка».)

Кешенең бәхете белән бәхетсезлеге бергә култыклашып, артыннан ияреп йөриләр.

1944 ел. Сентябрьнең егерме тугызы... Айның янә бер көне калды... Калган бер көн эчендә сугыш бетмәс дип әйтсәк, шаять, ялгышмабыз. Шулай итеп, бик күпләрнең сентябрь сугышның соңгы ае дип юраулары дөрескә чыга алмады. Сугыш октябрьдә дә дәвам итәргә булды.

Инде октябрь турында юраулар башланды. Коммунист Акшаловның төшенә караганда, сугыш 7 октябрьдә бетәргә тиеш, янәсе... Солдат Байәхмәтов октябрьдә бетүе турында яз көне үк бер төш күреп куйган, имеш... Күпләр исә төшләр юрап маташмыйча да, фронтлардагы җиңүләргә карап, сугышның октябрьдә бетеп куюы да мөмкин, диләр... Кайберәүләр Октябрь революциясе бәйрәменә кадәр, һичшиксез, бетәргә тиеш дип баралар. (Болар бөек бәйрәмгә һәртөрле йөкләмәләрне үтәп өйрәнүчеләр.) Скептиклар да юк түгел. Алар сугышның кай-

чан бетәсен тәгаен әйтә алмыйлар, ләкин октябрьдә бетүенә һич тә ышанмыйлар... Мин үзем былтыр ук сугыш 45 нче елда бетәр дигән идем, әмма октябрьдә бетүенә дә һич каршы түгелмен...

Бу язганнар барсы да гади солдатларның уйлары, ә генераллар ничек уйлый торганнардыр — ул кадәресе безгә мәгълүм түгел.

## Сугыш хикмәтләре

Былтыр, 43 нче елны, немецлар Великие Лукины даими рәвештә авыр туптан атып тордылар. Станция янындагы бер складны безнең рота солдатлары саклыйлар иде. Аларның торган җире тимер юл буендагы җимерек заводның кечкенә бер бинасында иде. Төннәрдән бер төнне алар торган шул бинага немецлар җибәргән снаряд килеп төшә. Бу минутта өй эчендә 9 кеше була. Шуларның җидесе сәкеләрдә йоклап яталар, ә икесе — Акшалов белән Хаҗиниязов — өстәл янында карта уйнап утыралар... Авыр снаряд өйнең түшәмен тишеп, өрлеген сындырып килеп керә дә, цемент идәнне дә ватып, каядыр түбәндә бик яман шартлый... Өй эче төтен, тузан белән тула, ишек-тәрәзәләр тупсаларыннан каерыла, идән уртасындагы авыр чуен мич тә ачык ишектән тышка оча. Ләкин өй эчендәге тугыз кешенең берсенә дә берни булмый. Үлүче дә, яралanучы да юк. Башта котлары очып, исәнгерәп калалар... Бераздан исләренә килгәч, өйдән чыгып качалар... Аннары барсы бергә җыелалар — һәммәсе дә исән-саулар! Тик кайберләренең бит-куллары гына вак таш кисәкләре тиеп тырналган була... Бу искиткеч хәлдән аптырамаган кеше калмады.

Сыңар аягы өзелгән бер солдатны носилкага салып санбатка китерәләр. Кемдер солдатка бер сохари биргән. Солдат шуны акрын гына кимереп носилкасында ята икән. Шуны күргән Дурду әйтә:

— Тамакның никадәр яман нәрсә булуына шул чакта иман китердем,— ди.

Танаев сөйли:

— Кышкы суык төнне бер урман кырыена постка куйдылар. Бу урынга безнең часть яңа гына килеп туктаган иде... Йөри торгач, минем аякларым арыды, утырып ял итмәкче булдым. Төн караңгы, берни күренми, мин аягым белән капшанып, берәр агач-бүрәнә кебек нәрсә эзләргә тотындым. Ахырда эзләнә торгач, аякларым озынча бер каты нәрсәгә бәрелде: бүрәнә булса кирәк... Иплән кенә шуның өстенә утырдым, аякларымны суздым, рәхәтләнеп ял итәм... Шактый вакыт узгач, акрын

гына таң ата башлады, тирә-юнь дә әзрәк яктырды... Бермәлне утырган нәрсәмә карасам, ни күрим, астымда туңып каткан немец ята, гой! Атаңа нәләт...

Танаевны тыңлаган башкалар да моңа ышандылар — кышкы караңгы төннәрдә туңып каткан мәеткә абынып егылу яки ышыкланып ятулар була икән.

20 июньгә каршы төндә немец самолетлары Великие Луки станциясен бик яман бомбага тоттылар. Шул тирәдәрәк булган берәү безгә самолетлар киткәннән соң бер хатынның телеграф баганасына итәге белән эләгеп асылынып торуын сөйләде. Хатын үлек, ләкин яраланган җире юк — бомба шартлавы аны шулай багана очына чөйгән булырга тиеш, ди.

*Май башы, 1944.*

Вакыт-вакыт күңел сәбәпсезгә нечкәрәп куя... Әле дә менә җиргә ятып, яңа баш күтәргән яшь үләнгә битне ышкыйсы килә.

Вакыт-вакыт йөрәк шундый әрнү белән сызлана ки, ирексездән чәчләргә ябышып үкерәсе килә.

Бүген 5 октябрь. Октябрьдә сугыш бетмәде. Ноябрьнең бу 5 көнендә дә нәрсә булыр икән дип көтеп карадык, ләкин сугыш, исереп тилергән фахишә шикелле, кабахәт котыруыннан туктамады. Октябрьдә сугыш бетә, өйләребезгә кайтабыз дип төш күргән солдатлар (мәсәлән, Байәхмәтов) алгы сызыкка китеп бардылар. Хәзер инде кешеләр төшне сирәк күрә һәм сакланып юрый башладылар. Бөек бәйрәмгә бетә дип торучылар да тынып калдылар... Хәер, кайберәүләр сугышның 1 майга бетүе турында кыюсыз гына сүз ачкалыйлар... Йөкләмә үтәп өйрәнгән кешеләр сугыш шикелле һичбер кеше ихтыярына буйсынмый торган вакыйганы да хуҗалык планын үтәү кебек бер эш итеп караудан котыла алмыйлар.

Ничек кенә булмасын, ләкин сугышның тизрәк бетүен теләмәгән солдат юк. Гитлер никадәр катырак каршы торып маташкан саен, аңа карата булган ачу-нәфрәт шулкадәр көчәя бара... Бу хәл һәркемнең сүзеннән сизелеп тора.

Фронт дәфтәреннән чүпләп күчергәнем шушының белән тәмамлана. Беркадәресе хәзергә калып тора... Билгеле, фронт шартларында кешеләрдән яшеренә-яшеренә күргән-ишеткәннәрнең йөздән берен дә дәфтәргә теркәп булмады. Мәгәр язылган кадәресе дә 50 елдан соң укыр өчен кызыклы булыр дип уйлыйм.

Аеруча бер нәрсәгә укучы игътибар итмичә калмас, мөгаен: дүрт елдан артык дәвам иткән сугыштан солдатлар тәмам туйды, гарык булды... Бөтен уйлаганнары су-

гышның тизрәк бетүен теләү иде... Берәүләргә аның беткәнен күрү насыйп булды, бик күпләр исә, күрә алмыйча, эче тулы өмет-сагышлары белән сугыш кырында ятып калдылар...

Сугыш кеше табигатенә каршы нәрсә, кеше үләргә теләми, яшәргә тели — мәҗбүр ителгәнгә күрә генә ул үлемгә бара. Әмма мәҗбүр итүчеләр үзләре күп вакытта исән калалар. Кешелек дөньясының олы бер фаҗигасе бу...

## КОЯШ БАЕР АЛДЫННАН

### Яңа заман

* * *

...Гомерем кояшы баюга табан әкрен генә төшеп бара. Тиздән кичке тынлык иңәр, көн сүнәр, артыннан ук төн килер... Монда язганнарым кичке гыйбадәт шикелле чын ихластан керсез, ялгансыз булсын иде.

* * *

...Кояшы баеп бара... Ничектер картлыгы кинәтрәк килеп җиткән кеше турында шулай дип әйткәнне элек тә ишеткәләгәнем бар иде. Күбрәк кешенең артыннан сак кына әйтелгән бу сүзләрдә ирексездән тирән уфтану ишетелә кебек иде: «Һай гомерләр, үтә бит, үтә!»

* * *

...Озак яшәгән кешенең гомере җәйнең иң озын көне кебек, кояшы да аның бик әкрен, озак бата. Әмма инде яңадан чыкмаска бата. Соңгы көннең, соңгы сәгатьнең кайсыдыр бер мизгелендә булачак бу... Бетте, тәмам!.. Инна лиллаһи вә инна иләйһи раҗигун!

* * *

Кеше дөньяга аяк баскан көннән алып үзенең шул соңгы серле мизгеленә табан бара да бара. Менә мин дә барам, кояшымның инде офыкка әкрен генә якынлашуын күрә-күрә барам...

...Юлым үрләр менә, үрләр төшә, тирән чокырлар аша да уза ул... Бу юлны миңа тәкъдирем сызган, юнәлешен үзгәртергә, уңга-сулга каерылырга хакым юк. Мин бары тик атларга, атларга — моннан сиксән ел элек башлаган

атлавымны дәвам иттерергә тиеш. Тагын күпме атлыйсым калгандыр, белмим. Тик шуны гына беләм — алда мине соңгы тукталышым көтә. Шул тукталышта мин фани дөнья арбасыннан төшеп калачакмын.

* * *

...Үлем мине ни сәбәптер куркытмый. Көннән-көн аңа якыная барсам да, ниндидер бер тыныч битарафлык саклыйм мин үлемгә карата. Әмма ул истә, даими истә, тик аның турында уйлау да юк, борчылу да юк... Билгеле инде, мондый сәер хәл ул иң элек кешенең картлыгы белән бәйләнгән. Котылгысыз үлемгә картлык алдан ук әкренләп әзерләнә башлый... Мәгәр үлемгә карата битарафлыкны мин бары картлык белән генә бәйләмәс идем. Хикмәт нәрсәдә соң? Кемгә ничектер, әмма миңа калса, яшәү белән үлем мәсьәләсе без кичергән заман белән бик нык бәйләнгән булып чыкты. Ягъни безнең картлык миһербансыз кабих бер заманга туры килде. Шуның аркасында яшисе килү белән дөньядан бизү гүя үзара тигезләнделәр. Торсаң да ярый, китсәң дә җәл түгел. Мондый битарафлыкны без үз гомеребездә беренче мәртәбә кичерәбез... Йа Хода, әйтерсең ахыр заман якынлаша!

* * *

Дөресен генә әйткәндә, мин заманга кагылмаска тиеш идем... Минем заманым үтеп китте, бөтен уем-сагышым әнә шул үткәнемдә! Бүгенгесе белән алыш-бирешем юк, тәмам, бары хушлашасы гына калды... Картлыкның ваемсыз, тыныч ахыры шулай гына булырга да тиеш кебек иде.

Әмма заман үзе мине, чыраен ыржайтып, «ашыкма, карт!» дигәндәй, бугазымнан буып алды. Селкенергә дә әмәл юк. Кая ул хатирәләргә бирелеп, тыныч кына яшәү!

Кеше замана колы, рәхим итеп буйсын син аңа! Беләм, бик яхшы беләм... Иллә мәгәр Вакыт колы булуымны белгән хәлдә, минем бу заманга үз карашым, үз мөнәсәбәтем бар. Менә шуларны дөнья белән бәхилләшүче карт булып түгел, ә җәмгыятьнең актив бер әгъзасы буларак, әйтеп каласым килә... Ишетсен һәм белеп торсын замана!

* * *

Инде кадерле заманыбызның үзенә күчик. Бик ераккa кермичә, соңгы бер-ике елны гына һич булмаса күздән кичерик.

1991 елның августында без Нәҗия ханым белән Юрмала шәһәрендә ял иттек. Юрмала — Рига култыгы буйлап сузылган курортлар шәһәре. Шәһәр үзе бик чиста, бик пөхтә. Кеше кулы монда шәһәр төзелешен әйләнәдәге табигать белән ничектер матур итеп килештерә белгән; карт тирәкләр дә үз урынында сакланган, яшел чирәмлекләр дә тапталмаган, һәр йорт әйләнәсендә оя-оя чәчәкләр дә үсеп утыра. Тулаем, Юрмала үзенең электән сакланып калган, бер-берсенә һич охшамаган, сокланып туймаслык матур йортлары, кечкенә магазиннары, җыйнак кафелары, зиннәтле рестораннары белән без күрмәгән икенче бер дөньяны хәтерләтә кебек... Аның һавасы да башкачарак — сулар өчен җиңелрәк тә, йомшаграк та төсле.

Менә шул Юрмаланың Дубулты дип аталган җирендәге иҗат йортына язучылар бик теләп, бик яратып килә торганнар иде. Монда зур исемле танылган язучыларның күбесен очратырга була иде. Мин үзем дә аз йөрмәдем бу ятрак илдәге гел үзенә тартып торган иҗат йортына...

Бер җәйне шушында мәрхүм Павел Нилин белән очрашып бик күңелле вакыт уздырган идек. Күпне күргән, күпне белгән, әмма гаять кешелекле, бик гади, бик ачык йөзле әдип белән очрашу миндә һич онытылмаслык матур тәэсир калдырган иде.

Инде бу 91нче елны алсак, илдәге хәлләрнең көннәнкөн начарлана баруы безгә бик ачык билгеле иде. Без күптән аны күреп, белеп, тоеп яшибез. Латвиядәге хәлләр дә безгә сер түгел. Балтыйк буе илләрендә барлык республикаларга караганда да милли азатлык хәрәкәтенең иртәрәк башлануын, һәркайсының үзенә бәйсезлек таләп итүен һәм, ничек кенә булса да, Советлар Союзыннан аерылып чыгарга теләвен күптән белә идек. Аларның инде азатлык өчен үз туфракларында каннары да коелды. Әмма большевиклар империясе аларны тырнагыннан ычкындырырга теләми, алдап, көчләп булса да тота, аерылып чыгарга һичбер ничек тә юл куймый иде...

Латышлар урысларны ачыктан-ачык яратмыйлар. Йөзләренә бәреп әйтмәсәләр дә, артык яшереп тә тормыйлар. Рәсәйдән Латвиягә барып йөргән һәркем моны бик ачык сизә. (Билгеле, сүз рәсми даирәләр турында бармый — анда үзара мөнәсәбәтләр бик шома булырга тиеш.) Мондый хәлнең төп сәбәбе — бик дәү Советлар Союзының кечкенә Латвияне ансат кына басып алуында. Латыш халкы болай кинәт кенә үзенең азатлыгын югалтуы һәм читләр кулына төшүе белән, әлбәттә, килешә

алмый. Читләр исә аның өчен беренче нәүбәттә урыслар, чөнки урыслар бик күп, чөнки бөтен җирдә алар хакимлек итә.

Әмма бу тышкы төп сәбәптән башка тагын борыннан ук сакланып килгән эчке бер җитди сәбәп тә бар иде. Хикмәт шунда, «кечкенә» латышлар үзләрен «дәү» урыслардан һәр җәһәттән дә өстен саныйлар. Чынлап та, тормышлары, көнкүрешләре, эшкә мөнәсәбәтләре, тәртип-низамнары, ниһаять, эчке һәм тышкы культуралары белән алар урыслардан бик нык аерылалар. Алтмышынчы елларның башында беренче мәртәбә Ригага килгәч, мин бу шәһәрнең шулкадәр бай, матур, чиста булуына исем киткән иде. Һәр бина үзенә бер новелла кебек, туктыйсың да ирексездән сихерләнеп карап торасың. Урамнарында йөргәндә үзеңне ничектер җыйнак, әдәпле тотарга мәҗбүрсең. Әгәр бездәге гадәт буенча сигарет калдыгын аяк астына ташласаң, каршыңа килүче берәр латыш әдәп белән генә төпчекне иелеп алырга һәм йорт стенасына беркетелгән кечкенә чүп тартмасына салырга куша иде. Ләкин озак та үтми, Рига үзенең бу чисталыгын, пөхтәлеген әкренләп җуя башлый. Бигрәк тә аның урамнарында йөрүче халык күзгә күренеп диярлек үзгәрә — гүя үз халкы һаман кими, ят халык исә отыры арта бара...

Хәер, мондый үзгәрешләр Латвия Советлар Союзына «кушылган» көннән үк башланган булырга тиеш. Латышларның күпмеседер читкә чыгып киткәннәр, калганнарының да яңа властька ярамаганнарын Рәсәй түренә сөргәннәр... Алар урынына, билгеле, урыслар килеп тула.

Сугыштан соң отставкага чыккан папахалы генераллар, полковниклар, алар артыннан күпсанлы ваграклар да шушы бай шәһәрдә һәм аның тирәсендә төпләнеп калалар. (Гомумән, Ригада хәрбиләр бик күп, чөнки монда Балтыйк буе хәрби округының штабы урнашкан.) Шулай ук яңа салынган заводларга да эшче көчләрне күбрәк Рәсәйдән китерәләр. Ә инде Советлар Союзының барлык почмакларыннан мондагы затлы товарларга килүчеләрнең исәбе-хисабы да юк... Алар, урам тутырып, агылып йөриләр. Әмма иң аянычы — урысларга ияреп, бирегә әрсезлек, тәртипсезлек, шапшаклык, аннары инде кытлык та килә. Шул рәвешчә латыш халкы, бердән, үз җирендә сан ягыннан шактый ук кими, икенчедән, электәге шикелле үзе теләгәнчә иркен, мул, тыныч кына яши дә алмый.

«Кытлык» сүзен мин монда юкка гына кулланмадым.

Ризыкка муллык элек ничек иде дә, хәзер ничегрәк — моны инде Латвиягә килүче һәркем үз күзе белән күреп тора. Ләкин мин, бу язманың рухына бик үк туры килмәсә дә, бер-ике генә рәсми мәгълүмат та китермәкче булам. Баксаң, Латин кайбер азык-төлекне үзенең бай күршеләренә караганда да күбрәк җитештергән икән. Мәсәлән, ит белән сөтне Швеция җан башына 67 килограмм һәм 394 килограмм, Финляндия 61 килограмм һәм 690 килограмм, Норвегия — 45 килограмм һәм 454 килограмм җитештерсә, Латвия шулай ук җан башына итне 108 килограмм, сөтне 754 килограмм җитештергән. (Бу мәгълүматлар 1977 елда чыккан «Латвийская ССР» дигән брошюрада китерелгән.) Һәм шушы муллык елдан-ел күзгә күренеп кими бара. Билгеле, моның сәбәбе безнең ише килүчеләрнең җөдә тәмле латыш каймагын вә казылыкларын күп ашау нәтиҗәсендә генә булмыйча, ә бәлки, азык-төлекне моннан эшелонлап Советлар Союзына (бигрәк тә БАМ төзелә башлагач) озату аркасында икәнлеге берәүгә дә сер түгел. Нәкъ шул елларда Латвия партия Үзәк Комитетының беренче секретаре булып Восс фамилияле берәү утырды. Җирле халык аның фамилиясен болай дип шәрехли торган иде: Все отдал Советскому Союзу!

Озын сүзнең кыскасы, латыш халкы туйган бу комсыз Союзның үзеннән дә, аның савым сыеры булудан да, шулай ук урысның «кече туганы» булып яшәүдән дә бик туйган. Без моны ишетеп кенә түгел, күреп тә белә идек.

Шушы уңай белән Риганың үзәк урамындагы ике һәйкәлне искә төшерәсе килә. Бер-берсеннән ерак та тормаган бу скульптураларның берсе «Азатлык» һәйкәле, икенчесе исә Ленин һәйкәле. «Азатлык» һәйкәле Латвия Советлар Союзына «кушылмас» борын 1935 елда куелган. Аның сурәте — бик биек мәрмәр багана өстендә аркасы белән көнчыгышка (Россиягә), йөзе белән көнбатышка (Европага) каратып бастырылган, ике кулы белән бер-берсенә ялганган өч йолдызны күтәреп торган бик зифа яшь хатын сыны... Һәйкәл бик нәфис эшләнгән, чын сәнгать әсәре, һәм бик тирән мәгънә дә бар аңарда... Тукталып, сокланып карап тормыйча үтеп китү мөмкин түгел. Әсәрләндерә дә, уйландыра да... Әйләнәсендә һәрвакытта яңа чәчәкләр... Хәзер монда, «Азатлык» янында, латышлар еш кына үзләренең митингларын үткәрәләр икән.

Моннан ерак та түгел Ленин һәйкәле... Җыйнак кына гранит пьедестал өстенә Ленинны инде йөзе белән

көнчыгышка, аркасы белән көнбатышка каратып куйганнар. Ул да, уң кулын күтәреп, сезнең кыйблагыз әнә тегендә дигән шикелле, Россиягә табан күрсәтеп тора... Кая гына барсаң да очрый торган бихисап Ленин һәйкәлләре белән чагыштырганда, бусы ничектер тыйнаграк та, пөхтәрәк тә кебек... Ул миңа ошаган да иде.

Хәер, кулын сузган Ленин безнең йоклаганда да күз алдыбызда, һәйкәле яныннан күтәрелеп карамыйча да узып китәргә була. Ә менә «Азатлык» кебек һәйкәлләрне нигәдер кат-кат күрәсе килә. Аның яныннан инде адымыңны әкренәйтмичә, күтәрелеп карамыйча узып китә алмыйсың... Әле менә шушы язмага утыргач та, ул һәйкәлне ачыграк күз алдына китерер өчен мин өйдә сакланган Рига турындагы ике китапны һәм өч фотоальбомны карап чыктым. Мәгәр «Азатлык»ны таба алмадым. Юк аның фотосы берсендә дә! Ә менә «Азатлык»ка арты белән торган Ленин һәммәсендә дә бар. Бу нәрсә мине шактый ук гаҗәпләндерде: ни өчен латышлар «Азатлык»ны күрсәтмәскә булдылар икән? Ленин белән янәшә куясылары килмәгәнгә күрәме? Әллә инде Ленин «Азатлык»ка караганда алар өчен кадерлерәк булганга күрәме?.. Моның сәбәбен без 1991 елның августында үз күзебез белән күреп тә, белеп тә кайттык.

* * *

Юрмалада хәзергә тынычлык. Халыкның күпчелеге ял итүчеләр. Шунлыктан монда латышларның азатлык өчен көрәшләре бөтенләй сизелми дә диярлек. Ялга килүченең бөтен кайгысы бу аулак-тыныч җирнең рәхәтен мөмкин кадәр тулырак күреп, тазарып-ныгып, ел буе җыйган акчасын туздырып кайтып китү — латышларның эчке эшләренә тыгылырга аның бернинди теләге дә, вакыты да юк. Тик монда да электәге муллык шактый кимегән, дефицит көчәйгән, кайбер азык-төлекне җирле халыкка гына саталар — моның өчен «визитка» дигән бернәрсә дә уйлап чыгарганнар.

Рига магазиннары элек бик бай була торган иде. Керсәң — чыгасың килмәс, чисталык, пөхтәлек һәм җаның теләгән әйберне сайлап алырга була иде. Хәзер дә кибетләр буш түгел, көн саен ни дә булса ташлыйлар (безнеңчә әйтсәк), тик бәяләр генә ике төрле: затлырак, үтемлерәк әйберләрне коммерческий бәя белән, ә үтемсезрәк нәрсәләрне дәүләт бәясе белән саталар...

Куян бүреккә коммерческий бәя куелмаган иде әле — соңгы баруымда мин шуны әләктереп калдым. Әлхасыйль,

акча учлап килгән Рәсәй түтәйләре моннан сумкаларын тутырмыйча китмиләр иде 1991 елның җәендә дә.

Иҗат йортында тәртипләр башкачарак. Бирегә килгән язучылар вакытларын юкка-барга исраф итмәскә тырышалар. Иртәнге аштан соң холлда яки бакчада әзрәк сөйләшкәләп утыралар да, тизрәк бүлмәләренә таралалар. Серле иҗат эше башлана. Өч-дүрт сәгать баш күтәрми утырырга тиеш союз члены — бу аның профессиональ бурычы. Ә йөрү, гадәттә, кичке аштан соң, диңгез култыгы буйлап еракка-еракка сузылган киң пляжда... Әкрен генә сүнеп барган көн тын-тымызык, инде сүрелеп өлгергән дымлырак һава бик саф, шул йодлы һаваны сулый-сулый йөрүе җиңел, рәхәт.

Пляжның ике очына табан йөрүчеләр күп монда. Ләкин күмәкләшеп йөрү юк диярлек. Ике-өч кеше, күптәнге якын танышлар гына...

Теләсә кем белән аралашып йөрүне алар өнәмиләр булса кирәк.

Килгән саен мин монда бер үк кешеләрне очратам. Ләкин һичберсе белән танышып сөйләшә алганым юк. Күбесенең исем-фамилиясен дә белмим. (Тик бик мәшһүрләрен генә танып беләм.) Шулай ук миңа да берсенең дә килеп дәшкәне, сүз башлаганы юк. Әгәр үзебезнең татар-башкорттан танышлар булмаса, мин монда моңаеп йөрүче бер... «ялгыз каз»!

Кайчагында сәер хәлләр дә булгалый: килгән саен очрата торгач, кайберәүләрне күрү белән үк таныйсың, ул да сине мотлакан таный, хәтта туры килгәндә берберебезгә чак кына баш та каккандай булабыз. Әмма барыбер танышып, сөйләшеп китә алмыйбыз.

Нидән бу?.. Мин үзем табигатем белән кешегә җиңел генә якыная алмыйм. Бигрәк тә урыс кешесенә, чөнки тел тоткарлый. Бер генә сүзне дә минем хата әйтәсем килми... Татарча уйлау һәм сөйләү миңа шулкадәр нык сеңгән булса кирәк, гомер буе урыслар белән аралашырга туры килсә дә, тел киртәсен мин җиңел генә атлап үтә алмадым. Бары мәрхүм Павел Нилин белән танышып киткәч кенә мин тел киртәсен онытып, бик иркенләп сөйләшә алдым (хәер, ялгыш әйтүләр дә аз булмагандыр, ләкин мин моны үзем сизмим, ул да гүя берни дә сизми, чөнки Павел Филиппович үтә әдәпле бер кеше иде).

Әмма шунысы гаҗәп, ни өчен урыс яки яһүд үзе миңа сүз катып карамый?.. Белә торганнардыр ич минем бирегә бер язучы буларак килеп йөрүемне... Бәлки, татар булуым моңа сәбәптер... Бу инде мине кимсетә, ирек-

сездән читләшергә мәҗбүр итә... Хәлбуки татар язучыларыннан урыслар белән бик якын аралашканнары да аз түгел. Рәхәтләнеп йөриләр дә, сөйләшәләр дә, аратирә утырып эчәләр дә. Андый чакта да мин бер читтә торып калам. Хәер, һич тә гамь чикмим ул хакта... Карчыгым янымда, чәй кайнаткычыбыз бар — ялгызлыктан зарлану юк.

Аннары монда һәр килүдә электән үк күргән-белгән танышлар да очрамыйча калмый. Бу юлы да ике татар, бер башкорт белән туры килдек. Ике татарның берсе мин, икенчесе Уфадан башкорт язучысы, ә башкорт дигәнем русча язып, Мәскәүдә яшәүче... (Кайбер исәпләрдән чыгып, мин аларның исем-фамилияләрен ачмаска булдым.) Бу уңай белән бер кызык хәлне искә төшереп үтәсем килә. Малеевка иҗат йортында да шулай төрле яктан килгән язучылар очраштык: татар, башкорт, үзбәк, урыс, казах язучысы...

Әмма алар һәммәсе дә милләтләре белән саф татарлар иде. (Кемнеңдер бүлмәсендә сыйланып утырганда, бу хакта рәхәтләнеп бер көлештек тә.) Әйтергә кирәк, аларның һәркайсы үзе яза торган телдәге әдәбиятның вәкиле булуы белән бик канәгать иде. Тормышлары татар язучысыныкына караганда һәр җәһәттән әйбәтрәк, шуның өстенә кайберсенең зур гына исем-дәрәҗәсе дә бар...

Менә болай төрле милләт әдәбиятына хезмәт итеп яшәү яһүд белән татарга гына хас булса кирәк.

Хуш, ә без — мондагы ике татар, бер башкорт очрашканда нәрсәләр турында сөйләшә идек? Билгеле инде, күбрәк «мактаулы заманабыз» турында...

Иртәнге аштан соң, бакчага чыгып, яшел эскәмияләрнең берсенә утырабыз да ашыкмыйча гына гәпләшә башлыйбыз. Сүз гадәттә вак-төяктән башланса да, заманыбызның хәзерге вакыйгаларына барып тоташмыйча калмый иде.

Искә төшерик, бу — 1991 елның август ае... Илдәге хәлләр буталчык, киеренке, хәвефле. Икътисади һәм сәяси кризис тагы да көчәя, тормыш көннән-көн начарлана бара. Җитмәсә, илнең төрле читләрендә милләтләр үзара ызгыша, сугыша — бусы инде бөтенләй акылга сыймаслык эш! (Кайчан гына әле без бердәм какшамас дуслык белән мактана идек.) Бөтен җирдә җинаятьчелек йогышлы чирдәй көннән-көн күбрәк тарала. Власть органнарында, түбәннән югарыга кадәр, коррупция, ришвәтчелек тамыр җәя. Телебезгә инде мафия дигән сүз дә килеп керде. (Туган җире ерак Сицилия атавыннан.) Хуш, нәрсә соң ул матур сүз мафия?..

Дөньяга таралган яманаты буенча, аны илне талаучы җинаятьчеләр берлеге дип атарга була.

Кемнәр керә ул берлеккә? Хода белсен! Безнең шартларда аңа гади рэкетирдан алып, власть органнарында утыручы номенклатурага кадәр керә булса кирәк. Максат бер — ничек кенә булса да тизрәк баеп калу...

Буталчык заман — болганчык су кебек, нәкъ шул чакта «балык»ны күбрәк тотып калалар да инде!.. Мафия шулкадәр киң җәелгән һәм тирән тамыр җибәргән гаять көчле берләшмә ки, аның хәтта бөтен бер дәүләтне селкетеп торырга да кодрәтеннән килә.

Менә шундый-шундый хәлләр Җир шарының алтыдан бер өлешендә. Кыскасы, көн буе сөйләшеп утырсаң да бетмәслек...

Югарыда әйткәннәрдән тыш без әле үзебезгә аеруча якын татар-башкорт мөнәсәбәтләре турында да һаман сөйләшкәләп торабыз. Әлеге башкорт язучысы — татар бу мөнәсәбәтләрне читтән күзәтүче булып кына түгел, ә бик якыннан барысын да күреп торучы буларак та белә иде. Күп нәрсәләр сөйләде ул миңа... Мәсәлән, Мидхәт Шакировның татар халкына каршы үткәргән мәкерле сәясәте турында моңарчы ишетмәгәннәрне аңардан ишетергә туры килде. Мин бит үзем дә күптән инде татар-башкорт мәсьәләсе белән авырып йөрүче бер кеше, шуңа күрәдер, ахры, аның сөйләгәннәре ничектер чөй өстенә тукмак булып төште. Аеруча бер сүзе хәтердә нык уелып калды: Башкортстанда канлы бәрелеш башланса, ул бары башкорт белән татар арасында гына булачак, диде күпне белүче танышым.

Минем бу темага артык җәеләсем килми — күпме сөйләсәң дә, бер балык башын чәйнәү булачак.

Тантаналы очрашулар вакытында макташулар да, ант итешүләр дә күзгә төтен җибәрү генә икән ул... Чынлыкта исә бернинди туганлык та, дуслык та юк — барысы да ялган, ачуым килмәгәе! Инде әрмәннәр белән азәрбайҗаннар шикелле үзара кырылышмасыннар өчен бер генә нәрсәне теләргә кала: Ходай үзе башкортка сабырлык, татарга түземлек бирә күрсен иде! Бәлки, заман үзе тора-бара аларны йә килештерер, йә бөтенләй аерыр... Үзләре теләгәнчә яшәсеннәр өчен!..

Әмма халыклар өстенә ябырылган бу бәла-казалар каян, кемнәр аркасында килде соң?! Күпме генә сөйләшсәк тә, без бу сорауга уртак җавап таба алмадык. Уфалы иптәш бөтен бәхетсезлекне, бөтен фаҗигане Горбачев башлап җибәргән «үзгәртеп кору»дан күрә. Моның өчен ул Генеральный секретарьны беренче очраган телеграф ба-

ганасына асып куярга да әзер. Мин аның бу хәтле ачу-нәфрәт саклавының сәбәбен аңлыйм, әлбәттә, ләкин һич тә килешә алмыйм. Дөрес, Горбачевның дәрәҗәсе соңгы вакытта бик төште, башлаган эше ярты юлда тукталып калды, үзе ул күп сөйләүче бер тел бистәсенә әйләнде. Мәгәр башлаган эше бик кирәкле, бик өметле иде, баштарак көтелмәгән куанычлы нәтиҗәләр дә бирде. (Мәсәлән, гласность — хәбәрдарлык белән фикер хөрлеген.) Инде өметле эш тирәнәя алмыйча тукталып калган икән, монда бөтен гаепне бер Горбачев өстенә аудару, әлбәттә, дөрес булмас иде. Ихтимал, аның төп хатасы ялган социализм белән чын демократияне килештерергә маташуындадыр, әмма ләкин ут белән суны кемнең генә әле куша алганы бар?!

Бүгенге авыр кризисның тамыры, минемчә, бик тирәндә ята. Берәүләр аны Сталинга сылтыйлар, барысы да шул явыздан башланды, диләр; икенчеләр, бөтен фаҗиганең башы итеп, Октябрь революциясен саныйлар, шуның аркасында Россия ялгыш юлга кереп китте, диләр. Ә, бәлки, фаҗига тагы даерактанрак, әйтик, социал-демократларның большевикларга һәм меньшевикларга аерылуыннан башлангандыр... Казына китсәң, ихтимал, тагы да ераккарак кереп була торгандыр, ләкин бу сәясәтчеләр һәм тарихчылар эше — алар казынсыннар...

Ярый, без, булмаса, хәзерге кризисның үзебезгә күренеп торган бүгенге сәбәпләренә тукталып карыйк. Беренче сәбәп: бөтен партия исеменнән башланган эшне большевиклар тарихында беренче мәртәбә шул ук партиянең үзендә кабул итмәү, каршылык күрсәтү, хәтта ничек кенә булса да аны өзәргә тырышу... Үзәк Комитеттан алып, шәһәр, район комитетларында утыручы партократиягә бернинди үзгәртеп корулар кирәкми, киресенчә, бик шәп көйләнгән иске тәртипләрне ничек тә сакларга кирәк. Әзрәк алдашып, яраклашып булса да... Бөтен гамәлләреннән аларның икейөзле була белүләре ачык күренеп тора. Башкача алар була да алмыйлар, чөнки хакимият биргән өстенлектән, иркен, мул тормыштан ваз кичәргә аларның әле башларына тай типмәгән. Кыскасы, власть дигән көч-кодрәт бары алар кулында гына булырга тиеш!

Икенче сәбәп: илдәге экономик хәлнең елдан-ел начарлана баруы... Күзгә күренеп бөлгенлек килә, хәерчелек көчәя. Халык аптырауда, халык борчыла, канәгатьсезлеге көннән-көн арта бара.

Хәлбуки үзгәртеп кору безгә көтелмәгән бер яңалык ачты. Экономика өлкәсендә бездә зур-зур галимнәр (ака-

демиклар) күп икән ләбаса! Элек кайда булганнар, ни эшләп ятканнар — Ходай белсен!.. Хәзер исә мөхтәрәм галимнәр төрлесе төрле яктан үзләренең бөлгенлектән чыгу юлларын тәкъдим итәләр. Безнең Президентыбыз шул берсеннән-берсе шәбрәк тәкъдимнәрнең кайсын сайларга белмичә, тамгалы башын ватып азаплана. Аныңча: бүре дә тук, сарык та бөтен булырга тиеш, күрәсең.

Өченче сәбәп: милләтара мөнәсәбәтләрнең аеруча кискенләшеп китүе... Илнең төрле почмакларындагы кайбер халыклар арасында чын сугыш, кырылыш бара — төшкә дә кермәгән хәл ич бу! Әйе, «үзгәртеп кору» большевиклар партиясенең милли мәсьәләдә никадәр мәкерле, икейөзле, астыртын сәясәт үткәреп килүен ачты да салды. Хәер, бу сәясәт алай бик яшерен дә түгел иде. Интернационализм битлеге астында партиянең барлык милләтләрне руслаштырып, «Совет халкы» дигән тоташ бер кол массага әйләндерергә тырышуын күптән инде күреп, белеп килдек. Мисаллары да күз алдыбызда иде. (Татар мәктәпләренең ябылып бетүен генә искә төшерик.)

Мондый хәлне барлык милли республикаларда күзәтергә мөмкин иде. Шуның өстенә, бу республикаларны төзегән чакта ук инде, алар арасында һәртөрле «низаг орлыгы» да салып калдырыла; йә территорияләрен дөрес, гадел бүлмиләр, яисә бер үк милләт халкын бер-берсеннән аералар. (Әйтик, әрмәнне — әрмәннән, татарны — татардан.)

Кыскасы, бер генә халыкның да юкка чыгасы килми, һәркайсының милләт буларак сакланасы килә. Эш әнә канлы сугышларга кадәр барып җитә. Сакланып калу теләге һәм бу юнәлештәге хәрәкәт бөлгенлектән чыгарга тырышудан да көчлерәк дияр идем мин... Әмма мәркәздәге большевик җитәкчеләр бу проблеманы чишүдән гаҗизләр — искечә дә калдырып булмый, яңача да хәл итәселәре килми.

Шуңа күрә дә милләтләр язмышы, милли республикаларның киләчәге бүгенге кризисның иң газаплы — авыр, иң буталчык — четерекле мәсьәләсе булып кала бирә.

Инде искә төшерик: югарыда язганнар 91 нче елның августында без, Дубултыда ял итүче өч язучы, үзара сөйләшеп утырган чакларда әйтелгән фикерләр иде. Заманның барышы, бер-берсенә бәйләнеп килгән хәвефле вакыйгалар кешеләрне ирексездән бертөрлерәк уйларга мәҗбүр иткән иде. Иллә мәгәр без, бер-беребезгә һич тә охшамаган ике татар, бер башкорт, бүгенге хәлләр ту-

рында бертөслерәк уйлап, күпме генә акыл сатсак та, иртәгә тәгаен ни буласын белмичә пошамансыз гына яши бирә идек. Илдәге миллионлаган ватандашларыбыз шикелле үк... Дөньяның кайсы якка авып китәсен президентлар үзләре дә белмидер әле... Ә безгә монда рәхәт, буфет эшли, көннәр җылы, әйләнә-тирәдә әлегә тынычлык. Аллага шөкер!

Һәм менә шундый рәхәт-тыныч көннәрнең берсендә, безнең өскә, аяз көнне яшен суккандай, һич көтелмәгән әллә нинди ситуация ишелеп төште. Бу 19 августның иртәсе иде. Мәскәүдә ниндидер бер комитет төзелгән, шул властьны вакытлыча үз кулына алган һәм бөтен ил күләмендә фәүкылгадә әхвәл игълан иткән, имеш! Мин моны үзем бик очраклы рәвештә генә вестибюльдәге телевизордан күреп-ишетеп калдым. (Кешеләр ни карыйлар икән дип, якынрак барган идем.) Экранда озын өстәл, шуның артына безгә бик таныш дәүләт җитәкчеләре тезелешеп утырганнар. Пресс-конференция бара икән... Уртада утырган вице-президент Янаев сөйли. Аның ике ягына тезелгән Крючков, Пуго, Павлов, Язов, Бакданов һәм башкалар таш сындай шылт та итмичә, гадәттән тыш җитди чырай белән, иреннәрен кысып, туптуры залга текәлгәннәр. Янаев, сөйләүдән бигрәк, кулындагы кәгазьне укый, кулы әкрен генә калтырый, әледән-әле яулыгын чыгарып борынын сөртә — томау эләктергән, ахрысы... Ни үкенеч, баштагы сүзләрен ишетмичә калдым — ишеткәннәрем исә шул булды: президент Горбачев авырып китү сәбәпле, аның вазифасы закон буенча вице-президентка, ягъни Янаевка күчкән, ләкин озакка түгел, президент терелгәч тә үз урынына кайтачак икән. Янаев янәшәсендә дәшмичә генә утыручылар бүгенге гаять авыр хәлдән чыгу өчен махсус төзелгән комитет әгъзалары икән. Һәм алар, иң беренче эшләре итеп, бөтен ил күләмендә фәүкылгадә әхвәл дә керткәннәр икән инде. Болар дәүләтнең имән баганалары, Горбачевның иң ышанычлы терәкләре — властьны кулларында тота беләчәкләр, әлбәттә!..

Бу пресс-конференция рәсми белдерү өчен генә чакырылган булса кирәк, сорау бирүләр булмады диярлек, тик Эчке эшләр министры Пуго гына тагын нидер әйтте, шуның белән конференция бетте — телевидение музыка тапшыруга күчте.

Әйе, әйтәсе дә юк, фәүкылгадә белдерү булды бу үзе дә!.. Әмма шунда ук күңелдә үзеннән-үзе бер сорау да туды: ни өчен Президент указы юк?.. Вәкаләтен тапшыру... Ниндидер комитет ләбаса?! Үлем түшәгендә ят-

мыйдыр, шәт?! Юк, бер дә аңлашылмый әле бу бик тә сәер, көтелмәгән яңалык!

Телевизорны караучылар да шунда ук таралдылар да беттеләр. Ичмасам, аз гына сүз алышу да булмады. Гаҗәп халык!.. Ник анда дөньяның асты өскә килми, тизрәк үзенең кәгазь кыстырган машинкасына ашыга. Дөрес эшлиләр, явыллар! (Мишәр дьяволны шулай ди.) Мин дә әйләндем-тулгандым да, үз бүлмәмә менеп киттем. Лифт монда, ике этаж арасында туктап калмаса, шәп йөри.

Тик шулай да җан тынычлыгы югалды, эшкә җигелеп булмый, уйлар яңа гына ишеткән хәбәрдән һич тә ычкына алмый... Гаять җитди яңалык ишеттек ләбаса!.. Бөтен илгә вә һәрбер кешегә кагыла ич бу яңа ситуация! Бүгеннән безнең язмышлар әнә шул караңгы чырайлы, каты бәгырьле кечкенә бер төркем кешеләр кулына күчә. Тик бернәрсә һич тә аңлашылмый — кем бирде соң алар кулына шундый зур хакимиятне? Президентмы, Югары Советмы? Ләкин бит ул хакта бер генә сүз дә ишетмәдек... Юк, нәрсәдер, нәрсәдер җитми монда. Кичәме-бүгенме Горбачев үзе дә Кырымнан кайтырга тиеш иде шикелле — ни булган аңа? Бүтәннәр ни уйлый бу хакта — шуны белү дә бик кирәк иде хәзер...

...Ярый әле, Янаевны тыңлау аркасында, бүгенге «иҗат сәгате» кыска булды. Тиздән төшке аш вакыты да җитте. Шуңа сөенеп, без дә тизрәк түбән төштек... Язган идем бугай, ашханәгә керә торган юл өстендә җыйнак кына буфетыбыз бар. Монда затлы шәраблар гел булып тора. Эшләп арыган каләм әһелләре, миләрен әзрәк җиллләтер өчен, биредә тукталырга яраталар. Бүген исә тукталучылар күбрәк тә иде. Без инде үзебез туктамыйча гына үтеп китәргә тырышабыз.

Аштан соң, гадәттәгечә, йорт алдындагы иркен, чәчәкле мәйданга чыктык. Һәркем бераз вакыт шушында саф һава сулап, якын күргән кешеләре белән сөйләшеп ала... Әйттем дә шикелле, монда бергә җыелып, күмәкләшеп сөйләшергә яратмыйлар. Менә бүген дә, гадәттән тыш вакыйга булуга карамастан, төрле урында икешәрөчәр кеше генә үзара, үткән-сүткәннәргә дә ишетелмәслек итеп кенә, сөйләшеп торалар... Сүзләре, әлбәттә, бүгенге ситуация турында булырга тиеш.

Ашап чыккач без дә, өч төрки, очрашып, иyläшкән яшел эскәмиябезгә барып утырдык та, кереш сүзсез-нисез, телне кычыттырып торган әлеге яңалык турында сөйләшеп тә киттек. Иң элек Мәскәү язучысы үз сүзен әйтергә ашыкты. Шактый кызып ул:

— Күптән кирәк иде, күптән! — диде.— Менә хәзер порядок булачак, вакханалия бетәчәк... Карагыз, кемнәр ул комитетта?.. Болар инде сумеют и порядок навести и кризис преодолеть! Ә халык шуны көтә, шуны!..

Бу хәтле ачыктан-ачык катгый яклауны ишеткәч, без, аның ике ягында утыручы ике татар, бер мәлгә тынып калдык. Неужели мондагы язучыларның күбесе яңа комитетны шулай кабул иттеләр икән, дип, мин эчемнән генә уйларга мәҗбүр булдым.

Чөнки күп аралашып йөрүче дустыбызның кайбер язучылар белән сөйләшеп тә өлгергән булуы мөмкин иде... Инде башкорт язучысы татар ни әйтер икән — минем аны да ишетәсем килә иде. Ләкин ул, ни гаҗәптер, сүзен әйтергә ашыкмады, тыныч кына сигаретын суырып утыра бирде. Тик дәшми утыруны килештермәгәнгә күрә генә, ахрысы, кыска гына әйтеп куйды:

— Бөтен этлекнең башы Горбачевта!

Бу көтелмәгән сүз иде. Әйтергә кирәк, сүзгә бик җор иптәшебез партия-дәүләт сәясәтенең кухнясын безгә караганда якыннан торып белүче иде. Аның күп вакыйгаларга дөрес бәя бирә белүе шөһбәсез иде. Ләкин бу юлы да ул, бүгенге вакыйгага һич кагылмыйча, тотты да тагын Горбачевны рәхәтләнеп каезлый башлады. Гүя аның урынына Янаевны түгел, иблиснең үзен утыртып куярга да әзер иде ул!.. Мин беркадәр беләм аның Генеральный секретарьга ни өчен бу хәтле ачу-нәфрәт саклавын...

Мин аңа кызмыйча, уйлап кына болай дидем:

— Мин үзем дә Горбачевтан бизгән кеше, әмма законсыз эш белән килешә алмыйм. Президент указы да, Югары Совет карары да юк, ә бер төркем кешеләр властьны тоталар да үз кулларына алалар! Переворот була түгелме соң бу?!

— Ашыкма, указы да, приказы да булыр! — диде ул, ничектер серле генә итеп. Бәлки әле, аңарда берәр төрле өмет тә уянгандыр. Шуңа күрә комитет турында ләм-мим!

Ә мәскәүле шунда ук үз сүзен кыстырды:

— Ә чрезвычайное положение объявить итү үзе закон түгелмени?.. Бик кирәк чакта!

— Ахыры ни булып бетәр бит әле,— дидем мин, сүзсез калмас өчен генә.

Хәзергә бәхәс шушы өстән-өстән генә сөйләшү белән тәгәлләнде дияргә дә ярый. Ситуация бик яңа, информация дә бик аз әле, ни буласын берәүнең дә алдан юрап утырасы килми иде. Мондый чакта кеше ихтыярсыздан сагая — әнә күпне белүче коллегабыз да тишелеп китмәде бит... Димәк, көтү хәерлерәк.

Без төшке аштан соңгы ялга таралыштык. Ләкин бер дә кереп ятасы килми, ялгыз гына йөрисе килә. Тынычлык юк, тынычлык качкан... Рухи халәт әллә нинди генә — өркетелгән җәнлекнеке кебек димме?! Сынаганым бар, кеше һич көтмәгәндә гадәттән тыш берәр вакыйга алдында кинәт торып калса, үзен бик кечкенә, бик көчсез итеп тоя башлый. Кырык беренче елның июнь таңында Германиянең безнең илгә бәреп керүен ишеткәч, әнә шундый бер гаҗизлеккә төшүне кичерергә туры килгән иде.

...Дүшәмбе көн булгач, бездә бүген газеталар да сатылмый. Кызганыч. Хәбәрдарлык заманында хәбәрсез утыр инде (соңыннан ишеттек, яңа комитет кайбер газеталарны «япкан» ди, имеш!).

Ахырда, бер әйләнеп кайтыйм дип, пляжга төшеп киттем. Иң сәере — бөтен җирдә тынлык һәм тынычлык... Кайдадыр, ниндидер искитәрлек эшләр эшләнә, ә монда кешеләр, кояш җылысында күзләрен йомып, рәхәткә талып, кызынып яталар. Күрәсең, беркемнең дә Горбачевны Янаев алыштырган өчен генә кадерле ялын бозасы килмидер. Власть башынданиләр генә булмас (заманы шундый), ә кеше үзе теләгәнчә яшәргә тиештер инде. Соңрак бездән Ригага барып кайтучылар да зур калада бернинди үзгәреш юклыгын, искечә үз тәртибе белән яшәп ятуын, тик урамнарда төркем-төркем йөрүче хәрбиләрнең гадәттәгедән күбрәк булуын сөйләделәр. Һәртөрле җыелулар, демонстрация, митинглар тыелган икән инде. Димәк, фәүкылгадә әхваль үз эшен эшли!

Фәүкылгадәнең нәрсә икәнен без икенче көннең иртәсендә белдек. Ул турыдан-туры без әкиятләр язып ятkan йортка килеп кагылды. Бу йортның латыш шоферын төнлә Ригада атып үтергәннәр. Машинасы белән кайдыр китеп бара икән, ОМОН солдатлары аңа туктарга кушканнар, туктамагач, артыннан атканнар. Белмәгән, бичара, фәүкылгадәнең нәрсә икәнен... Яшь хатыны, ике баласы торып калды. Без, ял итүчеләр, семьясына бер ярдәм булсын дип, хәлдән килгәнчә акча җыеп бирдек.

Августның 20 нче числосы илдәге хәлләрнең иң киеренке, иң хәвефле көне булгандыр, мөгаен... Информация бик аз, газеталар килми, радио һаман музыка яңгырата... Ельцинның халыкка мөрәҗәгате булган, имеш, ләкин аны да без ишетә алмадык. Шул арада Мәскәү язучыларыннан кайберәүләр (мәсәлән, Сергей Залыгын) ашыгыч рәвештә кайтып та киткәннәр икән... Күпчелек исә иртәгә ни буласын белмичә, борчылу-шомлануларны эчкә яшереп, искечә яшәп яткан булабыз. Әмма билгесезлектән дә әшәке нәрсә юк!

Һәм менә кыска гына билгесезлекнең ис-акыл китәрлек ахыры: әлеге иң зур дәүләт әһелләреннән торган, бик зур эшләр башкарырга тотынган гадәттән тыш комитет өч көн эчендә, сабын куыгыдай, шартлады да куйды. Егерме икесендә инде без аның тәмам җиңелүен ишеттек. Кинәт ерылган буадай безне яңадан информация күмеп китте. Радио, телевидение, газеталар бу өч көн дәвамынданиләр булганын өзлексез, бәйнә-бәйнә сөйләп тора башладылар. Ул бик хикмәтле, бик гыйбрәтле вакыйгаларны монда кабатлап торуның кирәге юк — алар бөтен дөньяга мәгълүм... Җыеп кына әйткәндә, Ельцин тарафдарлары җиңде (моны без демократия җиңүе дип атадык), өч корбан алып киткән өч көнлек фетнә бетерелде — фетнәчеләрнең үзләрен җыеп, «Матросская тишина»га утырттылар. Бары тик аларның тарих битләреннән беркайчан да җуелмас ГКЧП дигән исемнәре генә торып калды.

Без дә, ниһаять, тынычландык. Хәер, тынычлану микән бу? Фетнәнең башын кешеләр төрлечә кабул иткән шикелле, бетүен дә төрлечәрәк кабул иттеләр бугай. Берәүләр кулларын уа-уа сөенсәләр, икенчеләр тешләрен кысып көенгәннәрдер, мөгаен. Без, өч төрки, бу хакта фикер алышмадык. Һәркайсыбыз уй-кичерешләрне үз эчебездә саклап, тыныч кына йөри бирдек. Сөйләшер өчен темалар болай да җитәрлек иде. Сүз уңаеннан шуны да әйтәсе килә: уфалы язучы белән минем ара моннан берничә ел элек кенә бик ерак иде әле, әмма хәзерге әкәмәт заман безне дә күпмедер дәрәҗәдә тигезләп өлгерде. Күп сөйләштек, күп аңлаштык (бигрәк тә милли мәсьәләдә) һәм бик җылы аерылыштык та. Инде пәри туедай үтеп киткән фетнәнең бу кадәр тиз җиңелүен ничек аңларга соң? Моны демократиянең көчлерәк булуы белән аңлатырга тырыштылар — янәсе, «Ак йорт»ны сакларга җыелган берничә йөзме-меңме кешеләрнең батырлыгы фетнәчеләрне чигенергә мәҗбүр иткән... Минемчә, бу төп сәбәп түгел. Беренче нәүбәттә, фетнәне башлаучыларның кыюсызлыгы, таркаулыгы аларны харап итте. Кулларында шундый зур көч була торып, алар башлаган эшләрен, һичнигә карамыйча, дәвам иттерә белмәделәр. Күрәсең, кара эшләрен законга сыйдырыбрак эшләмәкче булганнардыр. Президент белән Югары Советка ышанып торганнардыр. Бәлки әле, алдан үзара сөйләшеп куйю да булгандыр. Югыйсә ни өчен алар Кырымга, Горбачев хозурына фатиха бирүен сорап баралар? Ахмак түгелләр ич! Ленин-Сталин шәкертләре — властьны ничек итеп алу, ничек итеп кулда тоту чараларын бик яхшы беләләр.

Мондый чакта рөхсәт сорап йөрмиләр, кыю вә тиз хәрәкәт итәләр... Менә шул хәлиткеч вакытны алар ычкындырдылар — Югары Совет соңга калды, ә Президент белән уртак тел таба алмадылар һәм... «уенны» оттырдылар.

Демократия җиңде, дип оран салырга, миңа калса, бик иртә әле. Бу очракта демократия вәгъдә иткән яңа җитәкчеләрне диктатура яклы фетнәчеләрдән күпмедер Мәскәү халкы гына саклап калды. Ә демократиянең үзенә килгәндә, ул әле Рәсәй киңлекләрендә яңа шытып кына килә, бик чуар, бик таркау, бик зәгыйфь — күпләр өчен исә хәзергә бер битлек кенә әле ул!

Мәгълүм булганча, зур сәясәткә мәкерлек тә, хыянәт тә, җинаять тә хас нәрсәләр — без моны башыбыздан кичкән тарихыбыздан да бик яхшы беләбез. Яңа гына булып узган вакыйгалар әнә шундый сәясәтнең бүген дә кабатлану ихтималын тагын бер тапкыр сискәндереп безнең исебезгә төшерде.

Әмма шулай да ГКЧП әгъзаларына берзаман һәйкәл куярлар әле. Аларның өч көнлек фетнәсе берәүнең дә төшенә дә кермәгән, бөтен галәмне шаккатырган нәтиҗәләргә китерде: дөньяның иң куәтле, иң дәһшәтле державасы — Советлар Союзы таралып китте; шулай ук дөньяның иң көчле, иң хәтәр партиясе туздырылды... Моны бит бер генә президент та гомере буе эшли алмаган булыр иде. Кыю, батыр Ельцин да, ГКЧП кулын чишкәч кенә, җимерелү-таркалуны төгәлләп куйды. Америка һәм Европа моның өчен кемгә — Ельцингамы, әллә ГКЧПгамы кул чабарга тиеш икән?!

Хәлбуки җиңү артыннан ук инде без мондагы дөньяның ничек тиз үзгәрүен, башка рәвешкә керүен үз күзебез белән күрдек. Ике көннән соң Наҗия ханым белән Ригага барган идек. Башта каланың борынгы тар урамнарыннан уздык, аннары әлеге һәйкәлләр урамы буйлап киттек... Менә биек, зифа, мәгърур «Азатлык» һәйкәле! Әйе, бу чын мәгънәсендә сәнгать әсәре... Бүген аның әйләнәсендә туп-тулы чәчәкләр. Бераз баргач, «Азатлык»ка аркасы белән торган, җыйнак-пөхтә генә эшләнгән Ленин һәйкәле... Барып җиттек... Бәй, бу ни хәл? Лениныбыз юк бит, җилләр искән! Хәтта постаментын да алып ташлаганнар, кара туфрагын да тырмалап-тигезләп куйганнар. Гүя монда беркайчан да даһи Ленин басып тормаган! Сәер бушлыкны күргәч, ничектер күңелсез булып китте, ирексездән эчемнән генә «Ашыкканнар латыш туганнар, саклау кирәк иде, саклау!» дип уйладым, чөнки бу икесе ике якка — капма-каршы ике дөньяга карап торган һәйкәлләрнең тирән символик мәгънәсе бар иде.

Мондагы үзгәрешләрнең бу хәтле тиз булуына артык гаҗәпләнергә дә туры килми. Латышлар аңа алдан ук әзерләнеп торганнар. Фетнә бетү белән үк алар бөтенесеннән бәйсез мөстәкыйль дәүләт булып, үзләре теләгәнчә яши дә башлыйлар. Читендер, авырдыр, проблемалары да күптер, әмма инде алар азат халык, азат ил.

Бер атнадан безнең китәр көнебез дә килеп җитте. Күңелне биләп өлгергән бу тансык җирдән китүе ямансу иде. Әмма без, исән-сау торсак, тагын да килербез әле, дигән сабыйларча ышану белән киттек. Дөньяның болай ук тиз үзгәрәчәген чамалау түгел, уйлый да белмәдек. Шул ук елның октябрендә без әле Ташкент якларыннан да йөреп кайттык. Әмма бу йөрүләр безнең соңгы сәфәрләребез булган икән. Советлар Союзын ташлап чыккан Латвия турында әйтәсе дә юк, хәтта элек-электән үк аралашып-йөрешеп торган әнә шул тугандаш илләргә дә юлларыбыз киселде (күпләрнең бит анда туганнары да яши). Советлар Союзы урынына СНГ дигән, җитлекмичә туган гарип бер нәрсә пәйда булгач, ул илләр безнең өчен заграницага әверелде. Ә без Россия эчендә бикләнеп калдык. «Якындагы чит илләр» дип атыйлар да хәзер аларны... Ләкин инфляция аркасында алар бездән Япониягә караганда да ераграк шикелле.

ГКЧПга тагын бер мәртәбә рәхмәт әйтми булмас, ахрысы. Алар фетнәсеннән соң президент Ельцин Россияне икътисади һәлакәттән саклап калу өчен, ниһаять, үзенең реформасын башлап җибәрде. Бу реформа безне базар мөнәсәбәтләренә алып керергә һәм ярты елдан инде тормышыбызны да җиңеләйтергә тиеш иде. Әмма ләкин ул реформа баштан ук халыкның күпчелеген хәерчелек чигенә китереп җиткергән, вәгъдә ителгән җиңеллек урынына бары чиге күренмәгән читенлек кенә китергән, аңлавы да, килешүе дә читен булган әллә нинди бер кыргый, оятсыз, мәрхәмәтсез процесска әверелде. Аның, ягъни реформаның, гади халык аңларлык ачык кына идеалы да, мораль кагыйдәләре дә юк иде.

* * *

Бу «изге эшнең» башлануына ел ярым тулып узды, ГКЧПның җиңелүенә дә озакламый ике ел тулачак. Шушы уңай белән, күргән-кичергәннәрдән чыгып, кайбер нәтиҗәләр ясыйсы килә. Язманың башында, әйткәнемчә, гүя заман үзе миннән шуны таләп итә. Һәм мин аңа буйсынырга мәҗбүрмен.

1. 1991 елның августында без демократия җиңде дип

бүрекләрне чөйдек, әмма чын демократиягә барыбер ирешә алмадык. Фетнәгә кадәр обком, горкомнар тырышлыгы белән сайланган һәм 80—90 проценты кичәге коммунистлардан торган хакимият һаман да безнең белән идарә итмәктә. Аларның күпчелеге ГКЧП яклы, шуның демократиягә һәм реформага каршы көрәшен астыртын гына дәвам иттерәләр. Президент белән Югары Совет арасында барган өзлексез көрәш шуның ачык дәлиле.

2. Бу көрәш фәкать власть өчен. Власть кем кулында булса, ил байлыгы да шуның кулында булачак. Ә байлыкка хуҗа булуның ике юлы бар: искечә дәүләт кулында саклау; яңача — үзара бүлешеп алу... Ельцин—Хасбулатов арасындагы көрәш шул ике юлның берсен сайлауга кайтып кала. Халык мәнфәгатенең монда бертөрле дә катнашы юк.

Депутатлар да шушы ике лагерьның берсенә керәләр. Кызык хәл күзәтелә: нотык сөйләгәндә алар барысы да халык мәнфәгатен кайгырта кебек; гамәлдә исә бик күбесе берәр груһ яки фирка файдасына, шулай ук үз мәнфәгатен дә онытмыйча хәрәкәт итә, чөнки власть өчен көрәштә ул инде үзен бик кирәкле фигура дип саный башлый.

— Власть кешене боза! — дип, Горький кайчандыр бик дөрес әйткән иде.

3. Коммунистлар партиясе тыелды, әмма партия яшәмәктә. Чын коммунистлар кызыл билетларын үзләрендә кадерләп саклыйлар, ә партаппаратчылар бер урыннан икенче урынга күчеп кенә утырдылар. Власть структурасының иң югары ноктасыннан алып иң түбәнге тармакларына кадәр идарә итү эшләре әүвәлгечә алар кулында. ГКЧП җиңсә дә, аларның абсолют күпчелеге үз урыннарында, һичшиксез, калган булырлар иде. Билгеле, сүз монда аерым шәхесләрнең башлары турында бармый. Тулаем номенклатура дигән таифә (каста) теләсә кемгә, теләсә нинди властька да яраклашырга тайяр ул!.. Хасбулатов, сәясәт пычрак эш, диде. Аның шулай икәнен без күптән беләбез.

4. Советлар Союзы өч кешенең халыктан яшерен үзара килешүләре аркасында таралды да куйды. Һич көтелмәгән бу шаккатыргыч вакыйганың тирән сәбәпләрен аңлауны киләчәккә калдырып торыйк. Нәтиҗәдә исә һәр союздаш республика гүя хөрлек алды, бәйсезлеккә иреште. Мәгәр шуның белән бергә күптән дәвам итеп килгән, әйбәт кенә көйләнгән үзара бәйләнешләр ничектер үзеннән-үзе өзелә дә башлады. Бу нәрсә, беренче нәүбәттә, һәркайсының экономикасына китереп

сукты, эшләп чыгару кимеде, яшәү шартлары көннән-көн авырлаша барды. Ниһаять, кешеләр арасындагы дуслык, туганлык җепләре өзелде. Әмма болардан да зуррак фаҗига — милләтара мөнәсәбәтләрнең аеруча кискенләшүе... Хәтта бер республиканың үз халкы — таҗик белән таҗик үзара сугыша башлады. Күпме кан коела, күпме кеше кырыла — тик бу фаҗиганең очыкырые гына күренми... Һәм беркем, бер дәүләт тә туктата да алмый. СНГ дигән нәмәстәкәй бик таркау, бик булдыксыз булып чыкты.

Кыскасы, бөтен бер зур дәүләтнең таралып китүе халыкларда аптырау гына түгел, тирән канәгатьсезлек тә тудырды. Бөтен бәхетсезлек-фаҗигаләрне алар күптән ияләшеп, яшәп өйрәнгән уртак Ватанның таралып китүеннән күрәләр. Миңа калса, Союзны җимермичә дә чын милли азатлыкка һәм мөстәкыйльлеккә ирешеп булган булыр иде. Моның мисаллары җир йөзендә бар лабаса!..

5. Җинаятьчелек коточкыч көчәйде һәм җәелде. Ул инде үзе бер гаять куркыныч социаль күренешкә әйләнде. Һәм аны тиз генә авызлыклап та булмас, ахры. Чөнки социаль-икътисади зәмине бик уңдырышлы аның: хәрәм юллар белән баючылар күбәя барган саен, талаучы-үтерүчеләр дә арта барачак. Революция елларында большевиклар ташлаган «Грабь награбленное!» («Талаганны тала!») дигән өндәүне алар, билгеле, исләренә төшергәннәрдер. Һәммәсе дә Совет мәктәпләрендә укыган грамоталы кешеләр — талау-үтерүне аклый торган үз фәлсәфәләре дә, мөгаен, бардыр әле... Һәм моңа артык гаҗәпләнергә дә туры килми. Кешеләрдә хәзер бер генә теләк, бер генә кайгы — ничек кенә булса да баерга тырышу. Ә мондый бөтен теләкләрдән дә көчлерәк теләк һәртөрле мораль кагыйдәләрне бер читкә себереп ташлый, законнарның һичберсе белән дә хисаплашып тормый, чөнки бары тик шул рәвешчә генә байлыкка ирешү мөмкин дип саный. Димәк, хәзерге бизнесмен, ришвәтче чиновник һәм кеше талаучы үзләренең теләк-максатлары буенча бер-берсеннән аерылмыйлар, тик эш итүләре генә төрлечә. Аннары реформатор хөкүмәт үзе дә эшен талаудан башлады бит: бәяләрне һич йөгәнсез ычкындырып җибәрү, саклык кассаларында яткан акчаларны йоту — халыкны талый башлауның бик ачык үрнәге иде. Менә шуңардан өлгер кешеләр «үрнәк»не алдылар да инде.

6. Һәм иң соңгысы — халык белән власть арасында аңлашу, бер-берсенә ышану юк. Халык үзенә, власть үзенә. Властьның ике тармагы әнә югарыда өстенлек өчен

тартышып ята, ә халык, бичара, түбәндә үзенең михнәт-нужасы белән көрәшеп маташа.

Элек большевиклар заманында власть күпмедер дәрәҗәдә халык ихтыяҗын кайгырта, ә халык, үз нәүбәтендә, властьның бөтен таләпләрен үтәргә тырыша — ике арада әнә шундый баланс (тигезлек) саклана торган иде. Хәзер исә ул баланс тәмам бозылды. Россияне «коткару» кебек гаять зур эшкә керешкән чакта югары власть халыкның аерым төркемнәренә нинди авырлыклар киләсен бөтенләй исәпкә алмады. Реформаны башлап җибәрү үзе үк инде власть белән кеше арасында газаплы каршылык тудырды. Гомумән, кеше белән санлашмау тормышыбызның гадәти бер күренешенә әйләнде, дисәк тә була. Бәяләрнең 500—1000 мәртәбә артуына карамастан, халыкны һәрьяклап талау һаман да дәвам итә. Әледән-әле арта барган хезмәт хакы һәм пенсияләр бервакытта да бәяләр артыннан куып җитмәячәк. Бу исә хезмәт ияләренең күп өлешен, иҗат кешеләрен, карт-корыларны чиге-ахыры күренмәгән бөлгенлектә яшәргә мәҗбүр итә. Кеше гаҗиз, кеше интегә, еш кына кая барып сыенырга, кемнән ярдәм сорарга белмичә аптырый ул...

Әле беркайчан да власть белән халыкның бер-берсеннән бу кадәр ерак-ят булганы юк иде.

Мин, социаль баскычның түбәнге басмасында торучы бер кеше буларак, озак, авыр уйланулардан соң әнә шундый нәтиҗәләргә килдем. Нәтиҗәләр каты вә караңгы диярсез. Килешәм... Әмма Россиядәге бүгенге чынбарлыкка карап, башкача уйларга, икенче төрле нәтиҗәләр ясарга мөмкинме соң?! Ихтимал, социаль баскычның югары басмасында басып торучы икенче берәү миңа: реформаның уңай нәтиҗәләре дә бар бит, нигә сез шуларны күрмисез, дияр, бәлки. Әйе, бар, әмма нинди «уңышлар» соң алар?! Без өстерәлеп, ыңгырашып булса да базар мөнәсәбәтләренә кереп барабыз. Көнкүрешебез турыдан-туры шул «мөнәсәбәтләр»гә бәйләнгән, нәрсә икәнен күрү генә түгел, тиребез белән тоеп яшибез.

Соңгы ел-ел ярым эчендә генә дә күпме банклар ачылды, күпме акционер җәмгыятьләр барлыкка килде, күпме чит ил фирмалары эшли башлады. Газета битләрен, телевидение, радиоларны шуларның әрсез рекламалары басып китте; хосусый вак сәүдә язгы ташудай җәелде, азык базарлары толчокка әверелде, урам чатларына сигарет, шоколад һәм кырык төрле эчемлекләр белән сату итүче киосклар тезелеште. Сатыла торган әйбернең иң күбесе импорт — кайдан, ничек килә торгандыр, Ходай белсен! Бәяләренә килгәндә, якын барырлык та түгел.

Бу коммерция шаукымы шулкадәр көчәйде ки, бик күп яшьләр — яшь табиблар, инженерлар, укытучылар, хәтта студентлар — бөтенесен ташлап, сәүдәгә ябыштылар. Шулар арасыннан да инде миллионерлар үрчи булса кирәк, тик ничә мең хәерчегә бер миллионер туры килә торгандыр, бу хакта статистика хәзергә дәшми әле.

Реформаның төп максаты — базар мөнәсәбәтләренә күчү. Менә шул күчүне Президент үзе дә, аның командасы да, тауга табан таш тәгәрәткәндәй, ничек тә ахырына кадәр илтеп җиткерергә тырыша. Бу гаять авыр, газаплы процесс белән дөнья кызыксына, демократик бай дәүләтләр аның барышын даими күзәтеп тора, ярдәм дә итмәкче була, хәтта әнә миллиардлар да вәгъдә итә. Әмма уңышсыз башланган эшнең барышы да уңышсыз. Күчүне хуплаучылар күпме булса, аңа аяк чалучылар да шулкадәр — хәтта әле күбрәктер дә. Шуның аркасында җәмгыять үзе икегә аерылды — байларга вә баерга теләүчеләргә һәм барлык бөлгенлеккә төшкәннәргә. Алар арасында упкын. Соңгылары абсолют күпчелек. Үзеннән-үзе табигый сорау туа: ни өчен соң бу күпчелек шулкадәр авырлыкларга түзеп тора ала? Нигә ул бунт күтәреп, бөтенесен ватып-җимереп ташламый? Моның җавабы, миңа калса, бер генә: күпчелекнең кире үткәнгә кайтасы килми, яңадан тамак хакына колга әйләнәсе килми. Күрде, белде инде ул большевиклар диктатурасының нәрсә икәнен.

Бер Бохара әмире әйткән, имеш, халыкны өмет белән курку арасында тотарга кирәк, дип... Большевиклар нәкъ Бохара әмире кушканча безне тоттылар да инде. Хәер, бүгенге көндә дә без шул билгесез «ике арадан» чыга алганыбыз юк әле. Әмма өмет куркудан көчлерәк — шул яшәтә кешене... Һәм өмет итә дә инде ул — бу авырлыклар урынына берзаман җиңеллек килер, хәзерге шәфкатьсез кыргый базар урынына, бәлки әле шәфкатьле, инабәтле базары да булыр... Үзе күрмәсә, балалары күрер. Иркен, мул, хөр яшәүгә ни җитә?! Ә түзәргә ул әзер, түзәргә ул күптән өйрәтелгән инде. Баш түбәсендә казык очласаң да чыдар кебек...

* * *

— Процесс пошел! — дип әйтергә ярата иде безнең хыялый Президентыбыз. Әйе, бара процесс, әмма ләкин кайда илтеп чыгарыр ул — бу кадәресен юрап тору хәзергә бикяр эш. (Бу бәхетсез Россия белән әлләниләр булып бетүе мөмкин.) Шуңа күрә мин дә ГКЧП фетнәсе

кузгаткан, төн йокыларын алган уйларыма соңгы ноктаны куям. Артык берни дә өстисем килми. Бердәнбер телэгем — әнә шул түзәргә өйрәтелгән бичара халыкның өметләре, ниһаять, аклана күрсен иде, Ходаем!

## Чорлар аша

Мин үткән юлның башы бар, ахыры юк әле. Хәер, ахырына җитәргә күп тә калмагандыр — кояш әнә офык читенә якынлашып бара. Мәгәр бер дә кабаланасым килми. Тик Ходай бирмеш һәр көнне ганимәт белеп, файдаланып кына булсын иде.

...Хуш, сүзем нәрсә турында?.. Әнә шул шактый озакка сузылган гомер юлын күздән бер кичерәсем килә. Искә төшерер нәрсәләр күп. Төшерәсе килмәгәннәре дә аз түгел. Һәрхәлдә, бу язма истәлекләр җыентыгы булмаска тиеш. Анысын бер язып карадым инде. («Соңгы китап»та.) Хәзер исә шушы озын гомерне эченә алган заманны күздән кичереп, ничектер аңларга тырышып карыйсым килә. Билгеле, үзем күргән-кичергәннәрдән чыгып... Әмма заман ул аерым кеше гомереннән күп мәртәбәләр өстен, биниһая зур, гаять тә катлаулы төшенчә. Аны, ягъни заманны, тоташ кына күз алдына китерүе дә, акыл белән колачлап бетерүе дә бик читен. Минем 80 елдан да артык гомерем, бала чагымнан алып, Совет заманында узды. Мәгәр бу гаять хикмәтле, катлаулы, фаҗигале заманны бары чорларга бүлеп кенә карарга мөмкин. Башкача булмый... Аннары Совет заманы ул үзеннән-үзе диярлек, аерым шәхесләр исеме белән бәйләнгән чорларга бик ачык бүленеп тә тора... Әйтик, Ленин чоры, Сталин чоры, Хрущев, Брежнев чорлары, хәзер менә Борис «патша» чоры... Тәмам әзер схема ич бу!.. Без дә артык баш ватмыйча гына шул схема буйлап китик.

## Ленин чоры

Бу кыска матур исемне кайчан ишетә башлавымны ачык кына хәтерләмим. Ихтимал, ул исем пайтәхеттән ерактагы безнең кечкенә Дәүләкәнгә Октябрьдән соң гына килеп җиткәндер. Аңарчы ишетүче-белүче булды микән? Хәер, минем бит әле сигез яшьлек кенә чагым, зурлар сүзенә колак та сала белмәгәнмендер... Ә менә Керенскийны ишетеп белә идем инде, чөнки күп кабатлана иде ул исем. Аннары шул исем белән 20 вә 40 сумлык кечкенә кәгазь акчалар да таралган иде... «Киринка» дип йөртәләр иде безнең атайлар ул акчаларны...

...Хәтер кызык нәрсә. Октябрьдән шактый иртәрәк килгән Февраль инкыйлабын мин ачык хәтерлим. Яз исе аңкыган кояшлы көннәрнең берсендә, безнең Дәүләкәндә беренче мәртәбә «нәмаеш» булып узды. (Демонстрацияне шулай дип язалар иде ул чакта.) Яшел әләмнәр күтәреп чыккан мөселман халкы, сафларга тезелеп, урам буйлап, епшек карга бата-чума «патша төшерелү»ен бәйрәм итеп йөрделәр... Мазлум халыкларга азатлык кояшы чыкты, дип сөйләделәр нотык тотучы мөхтәрәм абзыйлар. Ә яшьрәк абыйлар, йөгереп барып, яр башындагы каталажкадан берничә сукбайны да азат иттеләр, аннары тәртип саклаучы бер-ике стражникның да кылычларын салдырып алдылар, ләкин үзләренә тимичә куып кына җибәрделәр. Мондый тамашаны, әлбәттә, онытып булмый, хәтта менә сиксәннән узгач та.

Ә шул ук елның шыксыз, салкын, караңгы көзендә булган Октябрь инкыйлабын мин бөтенләй хәтерләмим. Хәбәре аның безнең Дәүләкәнгә дә килеп җиткәндер инде, иллә мәгәр шатлыктан кызыл әләмнәр күтәреп, «нәмаеш» ясап торулар булмады — булса, без, малайлар, күрмичә һәм аның тирәсендә буталып йөрмичә калмас идек. Көне ул түгел иде. Җылы өйләрендә утыручылар икенче мәртәбә «патша төшерү»гә бәлки юньләп игътибар да итмәгәннәрдер... Ә баксаң, ул инкыйлаб Рәсәй язмышын тамырыннан үзгәрткән, дөньяны тетрәнергә мәҗбүр иткән коточкыч зур вакыйга булган икән ләбаса! Шуннан башланган икән безнең күрәчәкләребез дә!..

Ленин исемен без, малайлар, совет мәктәбенә күчкәч ешрак ишетә башладык. Төгәлрәк әйткәндә, бу нәкъ 21 нче елның ачлыгына туры килә. Ачлык коточкыч каты булды. Мәктәптә безгә «Ар» оештырган ашханәдән алып кайтып, зур телем ак күмәч, ап-ак дөге боткасы һәм моңарчы без күрмәгән бик тәмле какао бирәләр иде. Күп малайлар шушы бер ашау белән җаннарын сакладылар дияргә дә була. Без ашаган тәмле ризыклар гәрчә Америкадан килгән булса да, ни өчендер аны безгә Ленин ач балаларны кайгырта, Ленин безне ашата, дип сөйлиләр иде... Элек дин сабагы укыган чакта, безне беренче сыйныфтан ук «Алла бардыр, бердер, тиңдәше вә охшашы юктыр» дип тәкрарларга өйрәтәләр иде... Хәзер инде без, ач малайлар, үзлегебездән диярлек, «Ленин бардыр, бердер, тиңдәше вә охшашы юктыр» дип кабатлый башладык. Алланы адәм заты белән алыштыруның нинди зур гөнаһ икәнлеген дә уйлый белмәгәнбез, күрәсең. Һәм бу гаҗәп тә түгел, чөнки Ленинның нинди бөек зат икәнлеген безгә көн дә диярлек тукып кына торалар иде.

Болай табына башлау пионерлар исемле бер җисем пәйда булгач, аеруча көчәйде. Алар телендә бары Ленин бабай гына: Ленин бабай шулай дип әйткән, Ленин бабай болай дип әйткән! Иң мөһиме исә — Ленин бабай укырга, укырга, укырга кушкан!.. Укырга Тукай абый да, Сәгыйть абый да кушкан («Безне адәм иткән уку. Адәмне алга илткән уку» дип такылдап йөри идек Сәгыйть абый шигырен), ләкин бит алар шагыйрь генә, ә Ленин бабай инде ул башка — ул даһи юлбашчы!

Ә ни өчен «юлбашчы»?.. Мәктәптә алган мәгълүматлар буенча ул, ягъни Ленин, Октябрь инкыйлабын ясаган икән, хезмәт ияләрен изелүдән азат иткән, инде хәзер безнең илдә «социализм» дигән яңа тормыш төземәкче икән. Шуңа күрә дә аны «даһи юлбашчы» диләр икән.

Безнең малай башларыбызга әнә шул кадәресен белү дә бик җиткән иде. Без барыбыз да аңа чын ихластан ышана идек, аңа эчкерсез табынырга да әзер идек. Чөнки ул даһи, әлбәттә, даһи!.. Әмма зурлар арасында Ленинга мөнәсәбәт бертөсле генә булмагандыр, мөгаен. Чөнки ул ясаган инкыйлаб төрле кешегә төрлечә кагылды — берәүләрне түбәннән кинәт югары күтәрде, икенчеләрне югарыдан түбәнгә бәреп төшерде. Бу соңгылар Ленин бабайга хөрмәт белән карамаганнардыр, билгеле... Ләкин аңа каршы ачыктан-ачык сүз әйтүче дә юк иде шикелле... Куркыныч булгандыр инде... Юлбашчыга тел тидергән өчен бугазыңнан алырга әзер торучылар да аз түгел иде ул чакларда.

...Тагын шунысы кызык — Ленинга мөкиббән бирелгән кешеләр үзләре дә даһины төрлечәрәк аңлыйлар, төрлечәрәк мактыйлар да иде. Бер ишеләр аның килешмәс катгыйлыгын, кыюлыгын, катылыгын беренче урынга куйсалар, икенчеләр күбрәк кешелек сыйфатларына — мәдәниятле, укымышлы, тыйнак, хәтта мәрхәмәтле булуына басым ясарга тырышалар иде. Катылыгын мактаучылар үзләре дә бөтен искене җимерергә, бетерергә әзер торсалар, яхшы ягын күрергә теләүчеләр Ленин бабайдан үрнәк алырга өндиләр иде. (Мәсәлән, безнең күп сөйләүчән укытучыларыбыз.) Кеше үзе нинди булса, даһи Ленинны да шундый итеп күрергә яраткандыр, ахрысы...

Ә тулаем алганда, Ленинның халык арасында абруе гаять зур иде. Акыллы, көчле кеше! — һәм бу кадәресен берәү дә, хәтта ачу саклаучы да инкарь итә алмый иде. Бигрәк тә нэп дигән нәрсәне игълан иткәч, аның дәрәҗәсе аеруча күтәрелде. Большевиклар тарафыннан җә-

берләнгән кешеләрнең дә аңа карашлары йомшарды, ирексездән хөрмәтләре артты. Үтә кызылланып йөрүчеләрнең нәптан чырайлары сытылды бугай, әмма халыкның иң зур күпчелеге бик тә канәгать иде. Моны аеруча авыл җирендә бик ачык күреп була иде.

Чынлап та, гаҗәеп бер нәрсә булып чыкты ул нэп дигәннәре... Күпме елларга сузылган сугышлар һәм ачлык нәтиҗәсендә тәмам эштән чыккан илне шушы рәхмәт төшкере нэп хәйран калырлык итеп үзгәртте дә куйды. Туклык килде, муллык килде, халыкның күңеле күтәрелде, тормышлар җанланды. Безнең Дәүләкәндә ничә ел ябылып торган барлык кибетләр ачылды, сүнгән тегермәннәр яңадан эшли башлады... Чиркәүләргә, мәчетләргә дә җан керде. Җомга намазына халык элеккечә бик теләп йөри башлады. Елына ике килә торган гает бәйрәмнәрен алдан ук хәзерләнеп, көтеп ала торган булдылар. Онытыла язган сабан туйлары һәм зур җыеннар да яңадан гөрләп үтә башлады. Бу бәйрәмнәрнең ул чактагы матурлыгын, шатлыгын сөйләп торасы да юк!

...Әмма ни үкенеч — болар барысы да бик ачык, ләкин бик кыска сихри бер төш кенә булып хәтерләрдә калдылар... Иң элек 1924 елның кошлар да оча алмаслык салкын-зәһәр гыйнварында, башлаган эшенең нәтиҗәсен дә күрергә өлгермичә, бөек Ленин үлеп китте... Әйтәсе дә түгел, даһиның үлемен бөтен ил, барлык халыклар да бик авыр кичерде. Бу чын кайгы, чын матәм иде. (Мин дә, малай гына булсам да, аның үлеменә багышлап, беренче мәртәбә елый-елый шигырь яздым.) Мондый көтелмәгән гаять зур югалтудан соң дөнья үзгәрмичә калмаячак иде. (Элек-электән үк ул шулай килгән — патшалар алышынган саен, дөньялар үзгәргән.) Хәзер дә халык шуны көтте, борчылып, хәвефләнеп көтте. Һәм бик җитди зур үзгәрешләр озак көттермичә килеп тә җитте. Бу хакта сүзне иң элек үземнән башлыйсым килә, чөнки илкүләм үзгәрешләр берәүнең дә язмышына кагылмыйча калмый ул... Уңай яктанмы, тискәре яктанмы — анысы икенче мәсьәлә.

Егерме бишенче елның җәендә мин Казанга килдем. Уналты яшемдә идем, бөтен теләгем — Ленин бабайның «Укырга, укырга, укырга!» дигән өндәвенә чын ихластан ышанып, берәр уку йортына керү иде. Әмма йөреп, имтиханнар биреп, рәссамнар мәктәбенә керә алсам да, миңа укуны дәвам итү насыйп булмады. Сәбәбе — социаль чыгышым. Минем атам атсыз-тунсыз бер вак сәүдәгәр иде, шуның аркасында мине стипендиядән мәхрүм иттеләр. (Бу хакта минем «Соңгы китап»тан тулырак та

белергә була.) Кыскасы, чыгышым «начар» булу аркасында мин 5—6 ел буена укудан мәхрүм булып тордым; йә керә алмадым, йә керсәм дә, ташлап чыгарга мәҗбүр булдым. Шулай итеп, минем җиң сызганып укый торган елларым җилгә очты.

Лениннан соң социаль чыгыш өчен кысулар аеруча көчәйде. Күп кенә сәләтле яшьләрне сәүдәгәрдән яки мулладан туганы өчен генә укудан кудылар. Бары чыгышын яшерүчеләр генә укырга керә алалар иде... Фаш ителсәләр, шунда ук куылалар да иде. Ни өчен ул алай, кайдан бу гаделсезлек?.. Без бит Ленинга ышандык. Дөрес, Ленинның эксплуататор сыйныфларны дошман күрүе берәүгә дә сер түгел. Ләкин яшьләрне укырга өндәгәндә ул бит, фәләннәрнең балаларын югары уку йортларына алмагыз, дип әйтеп калдырмаган... Үзе дә бит ул, абыйсы патшаны үтерергә җыенуда гаепләнсә дә, университет белемен алган кеше. Димәк, белем эстәү патша заманында сәяси ышанычсыз кешеләргә дә тыелмаган икән, ни өчен әле ул Совет заманында һич гаепсез яшьләргә чыгышы өчен генә тыелырга тиеш?.. Бу газаплы сорау меңнәр күңелендә, тик аңа ачык, ышандырырлык җавап кына юк.

Лениннан соң башланган үзгәрешләрнең мин үземә тигәнен генә мисал итеп китердем. Мәгәр бу бик кечкенә мисал... Әмма шушы мисал да миңа бик мөһим бер нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирде: минем күргәннәрем илдә башланган гаять зур, тирән үзгәрешләрнең кечкенә бер чагылышы гына икән әле ул... Аларын әле күрәсе бар икән... Әмма ничек аңларга соң дөньяның болай бик кызу үзгәрә баруын — Ленин васыятьләре нәтиҗәсендәме бу, әллә булмаса, бөтенләй киресенчә, Ленин васыятьләрен тупас бозу аркасындамы?.. Һәркемне өзлексез уйландырган, борчыган мәсьәләнең асылы әнә шунда иде. Моңа җавап табу гаять мөһим, гаять зарур һәм гаять читен дә иде. Бер генә мисал: Ленин тарафыннан озак дәвергә исәпләнгән нэпны Сталин дүрт-биш ел эчендә юкка чыгарды да куйды. (Шуңа күрә дә нэп бер төш кенә булып калды да.) Хәлбуки Сталин моны Ленин тәгълиматына таянып эшләде. Чынлыкта исә ул шулай идеме, түгелме? Мин әле бер генә мисал китердем. Тора-бара алар күбәячәк һәм һәрберсе күңелләрдә «Бу Ленин кушканчамы соң?» дигән шөбһәле сорау тудырачак.

Әйе, бик иртә, бик вакытсыз үлеп китте Ленин бабабыз. Бик кыю, бик тәвәккәл эшләр башлаган чагында гына... Ә озак та үтми инде эшләр Сталин кулына күчте. Менә шул чагында кешеләр авызыннан Ленинны са-

гынып «Их, тормады бит тагын ун гына ел, дөнья башкачарак юлдан киткән булыр иде!» дип сагаеп кына әйткәннәрен ишеткәләргә туры килә иде. Чынлап та, бу ике даһины бер итеп күрү, аеруча баштарак, һич тә акылга сыймый кебек иде. Аларны әле янәшә кую да мөмкин түгел иде. Университет белемле, дүрт-биш чит телләрне белүче, интеллигент кыяфәтле, Сократныкыдай киң маңгайлы, үткен туры сүзле Ленин белән урта белеме дә булмаган, русчаны да ватып сөйләгән, гади солдат шинеленнән йөрүче тар маңгайлы, кара мыеклы яшерен-йомык Сталин — йә, нинди генә охшашлык бар болар арасында?! Хәлбуки, хәлбуки, вәхәләнки... Нәкъ менә Сталин, башка һичкем дә түгел, Ленин эшен дәвам иттерүче бердәнбер даһи булып чыкты да... Бу бәхәссез хакыйкать! Димәк, алар арасында бик зур охшашлык та, бик тирән уртаклык та булган — шулай түгелме?!

Без бик озак чынбарлыктагы Ленин белән түгел, ә хыялдагы Ленин белән яшәдек. Большевиклар партиясе Ленинның үзен изгегә, тәгълиматын — талмудка әйләндерде. Изге затка табыну зарур, вәләкин аны тереләр белән тиңләштерергә ярамый, янәсе... Шуның өстенә без Ленин турындагы бөтен хакыйкатьне белми дә идек. Партия, гадәтенчә, күп нәрсәне халыктан яшерә килде. Ихтимал, шуңа күрәдер дә Ленинны әүлиядай саф, гөнаһсыз дип санау, аңа чын ихластан ышану. Сталинның җинаятьләре, башкаларның хаталары өчен ул җаваплы түгел дип карау халык аңында хәзергә кадәр сакланып килде дә... Янәсе, пәри башка да, җен башка! Әмма дөресме соң бу? Ленинны варисларыннан аеру мөмкинме? Варислары һәрвакытта, һәр эшләрендә «бөек остазларыннан» үрнәк алып, аңа таянып, ул кушканча хәрәкәт итteләр түгелмени?! Алар үзләре үк бит бөтен партия исеменнән Ленинга һәм аның тәгълиматына беткәнче тугрылыклы булуларын өзлексез кабатлап кына тордылар. Күпме сүз, күпме кәгазь моның өчен исраф ителмәдеме?! Ышанмас җиреңнән ышанырсың!..

Иллә мәгәр чынбарлык безгә — телдә генә ул шулай, гамәлдә исә бөтенләй башка! — дип, нәкъ киресен раслап тора иде... Менә кайдан ул шик-шөбһә! Безнең ялган белән, алдау вә көчләү белән тулы тормышыбызның башы кайдан — Лениннан килдеме, әллә булмаса, Лениннан читенү аркасындамы?

Мин Ленинны махсус өйрәнүче дә, яхшы белүче дә түгел, мин бары заманга колак салучы гына... Шуңа күрә ишеткән-белгәннәрдән ике кешенең генә әйткәннәрен искә төшерәм. Берсе аның танылган зур шагыйрь,

икенчесе авылдан килеп, шәһәр асфальтын таптарга мәҗбүр булган татар карты. Шагыйрь фикеренчә, бездәге бөтен кимчелекләр Ленин күрсәтмәләрен бозудан килә — бигрәк тә милли мәсьәләләрдә. Шуның өчен ул күпме җәфа кичерде... Шәһәр урамын таптаучы авыл карты исә, сугышка хәтле үк әле бер очрашканда, миңа бик уфтанып болай дигән иде:

— Их, туган, туган!.. Дөньяны бит, үзегезгә мәгълүм, ачу йоткан бер Сембер русы бутап китте... Шуннан соң мантый алганыбыз юк ласа!..

Бичара картның ачынып әйткән гади генә сүзләре минем хәтергә ничектер бик сеңеп калган. Бу инде без кичергән бөтен бәхетсезлекләрнең башы Лениннан килә дигән шактый ук кыю сүз иде ул чакта. Һәм, чыннан да, Ленинга караш-мөнәсәбәт халыкта күптән инде икегә аерылган иде. Берәүләр өчен аның исеме хәзергә кадәр изге, икенчеләр өчен — фаҗигаләр символы. Ихтимал, бу капма-каршы ноктада торучылар үзләренчә хаклылардыр... Хаклы булуларын исбат итәрлек дәлилләре дә җитәрлектер... Ләкин бөтен хикмәт шунда ки, Ленин үзе дә Россия демократиясен икегә аерган кеше. Икегә аерып, үзенә каршыларны юкка чыгарып бетергән кеше. Ул үстергән, ул өйрәткән, ул Советлар башына утыртып калдырган большевиклар Рәсәйне бүгенге чамадан тыш башбаштаклыкка, кабахәтлеккә, ниһаять, һәлакәт чигенә китереп җиткерделәр. Бу Ленин башлаган юлның котылгысыз ахыры түгелме соң?! Шушы бер гасыр буена сузылып килгән фаҗигале чынбарлыктан чыгып, тарих Ленинның үзенә дә, барлык гамәленә дә иң гадел бәяне бирмәс микән?!

Сорауны куюы ансат, әмма җавабын кем табар?.. Ленин бит кешелек тарихының яңа бер сәхифәсен ачкан, яңа бер чорын башлаган бөек шәхес. Андый шәхескә караш бервакытта да бер генә төсле була алмый торгандыр, минемчә. Һәр дәвер аңа үз бәясен бирәдер, мөгаен. Шулай булгач, безнең менә хәзер Ленинга нindидер төгәл, гади бәя бирергә тырышуыбыз, иләк белән су ташыган шикелле, бикяр эш түгелме?.. Бигрәк тә хәзергедәй бөтен төшенчәләр буталып беткән бер заманда?! Күрәсез ич, кайчандыр Ленин җимереп ташлаган капитализмны аның «тугрылыклы» шәкертләре кара тиргә батып яңадан торгызып маташалар. Иң кыргыены, иң әшәкесен. Хуш, нәрсә бу — остазның хатасын төзәтүме, әллә остаздан тәмам ваз кичүме? Без тагын баштагы соравыбызга әйләнеп кайтабыз.

...Бу «әйләнештән» чыгу өчен безгә Ленинны тыныч-

лыкта калдырырга, бер йөз елга онытып торырга кирәктер, ахрысы. Әгәр ул хаклы булса, әгәр аның юлы дөрес булса, кешелек дөньясы яңадан аңа мотлак әйләнеп кайтыр. Бер дә борчылмагыз, тарих кабатланырга ярата ул!

Кайчандыр бик күптән, мин малай, ул «бабай» иде. Хәзер инде мин аңардан утыз яшькә өлкәнрәк, аның исеме белән бәйләнгән бөтен чорларны күреп, татып уздырган чын бабай. Ленинның бөеклеген, әлбәттә, таныйм, әмма аңа табына алмыйм. Бөек шагыйрьгә, бөек рәссамга табынырга ярый, иллә мәгәр бөек сәясәтче — дәүләт җитәкчесенә табыну һич тә ярамый. Ул һәр заманда да берәүләр өчен изгелек, икенчеләр өчен явызлык символы булып калачак...

Инде рөхсәт итегез миңа бераз гына туктап торырга да. Әңгер вакыты, җанга ял кирәк. Тынлык вә тынычлыкка без һәрвакытта да бик мохтаҗ...

## Сталин чоры

Кыска гына Ленин чорын озак елларга сузылган Сталин чоры алмаштырды. Кыска гомерлесе гүя озын гомерлесен тудырды. Шушы чор дәвамында яңа буын туып, үсеп җитте. Минем яшьтәгеләрнең егет-ир булып җиткән, кабатланмас еллары да шушы чорга туры килде. Күрдек без ул чорны, татыдык, тере шаһитлары булдык — моның белән, бәлки, мактанырга да ярый торгандыр...

Сталин?! Русча «корыч» сүзен үзенә кушамат итеп алган бу грузинны без баштарак бик аз белә идек әле. Ленинга якын торучыларның берсе булса кирәк... Әмма без Ленинга якын торучылар дип, Троцкий, Зиновьев, Каменев, Бухариннарны белә идек. Болар бик югары, бик атаклы кешеләр иде. Ленин урынына да шуларның берәрсе булыр дип уйлый идек. Ләкин бу күп сөйләүче ялкынлы революционерлар артыннан, кып-кызыл кояштай, тавыш-тынсыз гына Сталин калкып чыкты. Мәгәр әкрен калыкса да, ул бик тиз югары үрмәли дә башлады. Аны чын ленинчы диделәр. Һәм моңа ышанырга да була иде, чөнки нәкъ менә ул — бүтән берәү дә түгел — Ленин табуты өстендә партия исеменнән ант та итте. Сүзләре дә аның фамилиясе шикелле үк кыска вә тыгызсаллы иде.

Сүздән дә бигрәк, чын эш кешесе булуын да ул бик тиз күрсәтә башлады. Теге бик күпне белүче Ленин көрәштәшләре үзара теоретик бәхәсләр белән мәшгуль булган арада, бу «чын ленинчы» ил язмышын үзенчә хәл

итәргә дә кереште... Ниләр эшләгәнен язып тору кирәк микән — бик мәгълүм нәрсәләр... Һәммәсен бергә җыеп, кыска гына итеп әйткәндә, ул, Сталин, үзенең һични белән чикләнмәгән диктаторлык чорында Советлар Союзын дөньяның иң куәтле, иң дәһшәтле империясенә әйләндереп калдырды. Без менә шул империяне торгызу вә ныгытуда Рим коллары шикелле ачлы-туклы баш күтәрмичә эшләдек, һәм соңрак, бөтендөнья сугышында җаннарыбыз һәм каннарыбыз белән аны саклап та калдык.

Шул ук вакытта Сталин аерым бер илдә социализм төзү мөмкин икәнлеген дә адәм балаларына күрсәтеп бирергә тиеш иде. Шулай ук корычтай каты чаралар белән... Һәм иң мөһиме — болар барысы да Ленинга таянып, Ленин кушканча эшләнә иде. (Янәсе!) Шуңадыр инде «корыч юлбашчыны» социализм төзү чорының Ленины дип тә атый башлаганнар иде... Ихтимал, болай дип атау нигездә хаклы да булгандыр. Чөнки Сталинның кылган эшләре Ленинныкыннан бер дә ким түгел, Ленинныкы шикелле үк дөньяны хәйран калдырырлык гаять кыю, бөек эшләр иде. Һәм заман үзе аларны безнең алдыбызга әнә шулай янәшә бастырып куйды да. Билгеле инде, даһилык җәһәтеннән дә алар тиң булырга тиешләр иде. Хәтта «корычныкы» Ильичныкыннан өстенрәк тә, күп яклырак та булмады микән әле?! Хикмәт шунда ки, Сталинның бөтен бөек эшләре массакүләм террор белән бергә үрелеп барды. Әле Ленин вакытында ук күп кулланылган бу «революцион чараны» ул һич икеләнмичә, ачыктан-ачык бөтен халыкка каршы ходка җибәрде... Дулкын артыннан дулкын булып ябырылды бу һичкемне — картны-яшьне, ирне-хатынны, бала-чаганы — аяп тормаган массакүләм террор!.. Менә шул чакта бөтен яклары белән ачылды да инде Сталинның бик сирәк шәхесләрдә генә очрый торган даһилыгы!.. Ул үзенең корбаннарын «халык дошманы» дип атады. Йә, нинди даһи акыл кирәк мондый һәркемне өркеткән, сагаерга мәҗбүр иткән исем уйлап табарга?! Бу оятсыз ялган гына түгел, коточкыч мәкерлек тә иде. «Халык дошманы» дип атау гаепсез кешене алдан ук каты җәзага дучар итү иде... Беркем бер сүз әйтә алмый, ышанмаса да, күңелендә шөбһә, аптырау туа, ихтыяры сүнә, теле бәйләнә... Ә Сталинга шул гына кирәк тә — трубкасын тыныч кына көйрәткәндәй, ул бер дә кабаланмыйча гына үзенең дошманнарын даими рәвештә кыра-бетерә барды. Репрессия тегермәне шулкадәр шәп көйләнгән иде ки, көне-төне һич туктамастан ул адәм башларын тарта барды... Минем бу хакта артык җәеләсем килми — бик чир-

кандыргыч тема... Аннары ул турыда күп язылды, һәм язылачак та әле, чөнки Сталин репрессияләре күләме белән дә, нәтиҗәсе белән дә (халыкның иң яхшы өлешен кырып бетерү җәһәтеннән), шулай ук соң дәрәҗәдә ялган, мәкерле булуы белән дә кешелек дөньясының моңарчы тарихта күренмәгән үзенә аерым бер кара канлы сәхифәсе, олы бер фаҗигасе иде... Төрле заманнарда, төрле диктаторлар тарафыннан үткәрелгән репрессияләрнең берсе дә Сталиннныкына якын да килми торгандыр дип беләм... Чын булса, аның тарафыннан ябылган, сөрелгән, үтерелгәннәрнең саны 60 миллионга җитә, имеш!.. (Бу сан матбугатта күренгән иде.) Ягъни тыныч вакытның корбаннары дүрт ел дәвам иткән дәһшәтле сугыш корбаннарыннан ике мәртәбә күбрәк! (Хәер, сугыш корбаннарының да яртысын Сталин чутына язарга була.) Әмма иң гаҗәбе шунда ки, мондый хәл тора-бара берәүне дә гаҗәпләндерми башлады.

Чынлап та Сталин «кояшы астында» без ничек яшәдек, безнең һәр гамәлебезне, һәр сүзебезне нәрсә билгеләде? Курку, бары тик курку!.. Ләкин алдан ук шуны да әйтеп куярга кирәк — халыкта Сталинга карата капма-каршы ике төрле мөнәсәбәт иде: берәүләр аңа ачыктан-ачык, итеген ялардай булып табынсалар, икенчеләр йөрәгендә бик тирән яшеренгән мәңге бетмәс ачы ләгънәт ята иде. Әмма шушы капма-каршы мөнәсәбәттә торучыларны уртак бер нәрсә берләштерә: ул да булса әлеге курку, бик зур курку! Үрмәкүч шикелле үргән җәтмәсеннән беркая да китмичә, Кремльдә генә посып яткан «даһи юлбашчы» бөтен халыкка, дуска-дошманга аермастан, бер үк дәрәҗәдә куркыныч иде. Шушы бердәнбер кешедән миллионнарча кешеләр үз башкайлары өчен калтырап тора торган булдылар... Гадәти хәл — кеше бүген бар, иртәгә юк — моңа инде берәүнең дә исе китми башлады. Чөнки белә, Сталин өчен «кеше» дигән адәми зат юк, бары аңа яраган яки ярамаган «винтик»лар гына бар, ул шуларны аера белергә генә тиеш. Ә ярамаганнарны юк итү өчен аның бер ым кагуы да җитә — шәп куелган бу эш. «Халык дошманы» дигән мөһерне теләсә кемгә чәпәргә мөмкин. Һәм шушы мөһере белән кемнәрне генә озатмады ул теге дөньяга!.. Атап кына да бетерерлек түгел. Тагын кара мөһернең кемгә сугылачагын берәү дә алдан белми, мәгәр һәркем эченнән генә калтыранып шуны көтәргә мәҗбүр. Гаепсез башы өчен хәвефләнеп яшәү бер нормага керде дияргә була, тик кеше, яшерен чиренә ияләшкәндәй, хәвефкә дә ничектер күнегебрәк китте.

Мәгълүм ки, даһи юлбашчы белән көне-төне бергә эшләгән, аның дачасында еш кына бергә ашап-эчеп утырган иң якын, иң ышанычлы яраннары да үз башлары өчен һич тә имин була алмаганнар... Алмаганнар, чөнки белеп торганнар — бу «кунакчыл» грузин, кирәк тапса, «яраннарын» гына түгел, якын туганнарын да «әһ» тә димичә җәһәннәмгә олактырачак. Булды андый хәлләр дә... Әлбәттә, күптәнге мәсләктәш хөрмәтле Кобага алар катрә кадәр дә ышанмыйлар, әмма ләкин аның һәр сүзен хуплап, һәр канлы гамәленә кул куеп кына торырга тиешләр. Исән калуның башка чарасы юк алар өчен...

...Дөньяда Сталин кебек тагын кем генә бөтен илне, бөтен халыкны, дәүләтнең иң югары көчләрен үзенә шулкадәр буйсындыра алды икән?.. Аптырагач, бу итекчедән күтәрелгән җитәкче табигать тарафыннан бирелгән нииндидер сихри куәткә ия түгелме икән дип тә уйлый башлыйсың.

Мәгәр чынлыкта хикмәт сихри куәттә түгел, билгеле, ә Сталинның диктатор буларак бөтен хакимиятне бары үз кулына туплап бетерүендә... Диктаторлар исә һәрдаим үзен һәм үзенең властен сакларга тиеш — бу аның иң беренче кайгысы... Шушы уңай белән грекларның бер мифлары искә төшә: күкләр алласы Уранның кече улы Кронос атасын үтереп, үзе алла булып алгач, минем дә улларым «изге» урынымны тартып ала күрмәсеннәр дип, һәр туган баласын йотып бара торган булган... Бу мифны шәрехләп тору кирәкмәстер дип беләм — чөнки мәгънәсе бик ачык.

Әмма бик мөһим бер хакыйкатьне истән чыгарырга ярамый: диктаторларга да халык кирәк, бик күп кирәк... Чөнки алар төзегән тоталитар система бары халык җилкәсендә генә яши ала. Ләкин бу бик чистартылган, тәүфыйкка утыртылган халык булырга тиеш... Шуңа күрә дә Сталин репрессияләре бер үк вакытта бик көчле оештырылган өндәү-үгетләү чаралары белән бергә алып барылды да. Репрессия кешене сындыру, сынмаса, бетерү өчен кирәксә, өзлексез өндәү вә үгетләү аны үзгәртү, системага яраклы итү өчен кирәк иде. Моның өчен Сталин кулында тәмам аңа буйсынган әллә ничә миллион коммунистлар бар — чистартуны да, агартуны да шулар алып баралар. Бу эштә алар, русчалап әйтсәк, эт ашаган халык... Кыскасы, ике «мәктәп»нең һәркайсы шәп оештырылган, шәп көйләнгән иде — һәрбер кеше шуларның берсе аша үтмичә калмады ул вакытта... (Без үзебез, мәсәлән, политукуга күп йөрдек.) Ләкин болардан да көчлерәк мәктәп — тормыш үзе иде. Кеше эченнән

ниләр генә уйламасын, зольмәт белән күпме генә килешмәсен, барыбер системага яраклашырга мәҗбүр иде. Чөнки бары яраклашып кына яшәргә, эшләргә, гаилә корырга, балалар үстерергә мөмкин иде. «Иелгән башны кылыч кисми» дип ихтыярсыздан әйтелгән ачы тәҗрибә мәкален еш кына ишетергә туры килә иде ул чакта...

Янә шуларга өстәп тагын бик мөһим бер нәрсәне әйтергә кирәктер: халыкны система белән килештерә торган ниндидер бер бөек идеал да булырга тиеш. Андый идеал большевиклар тарафыннан күптән табылган: бу — социализм төзү, коммунизмга бару — бөтенесе әнә шул бөек идеаллар хакына эшләнә, янәсе... Әйтәсе дә түгел, идеаллар шәп, мавыктыргыч, әмма ләкин аларның нигезендә дә һаман шул большевиклар яраткан кешене кешегә каршы кую, кешене кеше белән сугыштыру принцибы ята иде. (Мәгълүм ки, большевикларның бу сыйнфый көрәш дигәннәре халыклар язмышында гаять зур һәлакәтле роль уйнады.)

Кыскасы, югарыда әйтелгән кешене буйсындыру чаралары — көчләү, өндәү, алдау — барысы да шул ук репрессияләр вакытында тулысынча кулланылды. Гадәттә репрессияләрне бары каратель органнар эше дип кенә карау бар... Һич тә алай түгел — болары соңгы ноктаны куючылар гына... (Шагыйрь «Патша тарихына наган белән нокта куелды» дип язган иде, хәтерләсәгез...) Асылда исә, Сталин тарафыннан үткәрелгән ул канлы мәхшәргә барлык Совет җәмәгатьчелеге тартылган иде. Мәсәлән, бу эштә вакытлы матбугатның «тырышлыгы» аеруча зур булды. Башта корбанга билгеләнгән кешене берәр гәзитә, каяндыр югарыдан кушу буенча, бик әшәке рәвештә «фаш итеп» чыга: шуннан соң инде «органнарга» төнлә килеп ул бичараны «Черек күлгә» алып китү мәшәкате генә кала... Көн саен камалып торган кешеләрне судка хәтле үк гаепләп, пычратып язу матбугатның көндәлек эшенә әйләнде дияргә ярый.

Янә безнең Совет әдәбиятын алып карыйк. Ул да бит «заман таләбе»н бик теләп үтәргә тырышты. Кулакларны, муллаларны, иске зыялыларны Совет дошманы итеп күрсәткән, аларга карата ачу-нәфрәт уяткан күпме әсәрләр язылмады ул елларда?! (Аеруча безнең театр зур өлгерлек күрсәтте бу эштә.) Йә, болар Сталин репрессияләрен мораль яктан аклау түгел идемени?! Эш шуңа кадәр барып җитте ки, Совет әдәбиятының атасы Максим Горький «Если враг не сдается — его уничтожают» дигән махсус китап та бастырып чыгарды. Ә безнең татар язучыларының беришеләре үз гомерендә кыйбласын берни-

чә тапкыр үзгәрткән ул картның бишмәт чабуын тезләнеп үбәргә әзер торалар иде.

Шуларга тагын барлык җыелыш-митингларда «халык дошманнары»на каты җәза бирелсен дип чыгарган карарларны да өстәсәк, Совет җәмәгатьчелегенең миллионлаган корбаннар алдындагы гаебе үзеннән-үзе тулысынча ачылса кирәк... Әйе, бик әшәке, бик фаҗигале хәлгә куйды үзен безнең Совет җәмәгатьчелеге... Әмма иң явыз, иң кансыз тоталитар системада аның башкача булуы мөмкин идеме соң?! Бер генә идеологияне хак дип тану, бер генә идолга мөкиббән табыну кешеләрне гүя рухи наркоманга әйләндерде. Кеше теләсә, теләмәсә дә шул идеологиягә тугрылыклы булуын, шул идолга җаны-тәне белән бирелгәнлеген көне-төне изһар итеп кенә торырга тиеш иде.

Әмма парадокс шунда ки, бу беренче карауга өркетелгән сарык көтүедәй күренгән халык, асылда, бик төрле, бик чуар да иде. Сталинга берсүзсез ышанганнар һәм ышана алмаганнар, ахырынача бирелгәннәр һәм исемен дә ишетәсе килмәгәннәр, аңа мәдхия укыганнар һәм тирән нәфрәт саклаганнар — әнә шулай эчтән икегә аерылган, вәләкин уртак курку берләштергән һәм тулаем Совет халкы дип йөртелгән төссез-чырайсыз тоташ бер масса иде бу. Без менә шуның «винтик» дип аталган мактаулы әгъзалары идек. Сталинның гаять мәкерле, икейөзле була алуына исең-акылың китәр. Ул бит кансыз тиран гына түгел, «мәрхәмәтле» атабыз да иде... Һәрбер явыз эшен «изге» эшләр белән каплап бара иде. Меңләгән кешеләрне үтерткән бер вакытта, аның боерыгы белән шулай ук меңләгән кешеләргә орден-медальләр өләшенә, күпме кешегә мактаулы исемнәр, зур бүләкләр бирелә торган иде. Шушы уңайдан, үзебезнең әдәбият дөньясыннан да бер-ике генә мисал китерәсем килә: классик язучыларыбыздан Кәрим Тинчуринны һич гаепсезгә аттырса, Шәриф абзый Камалны Ленин ордены белән бүләкләндерә. Яки менә 1939 елны шагыйрь Шәйхи Маннурга Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бирсәләр, шул ук вакытта Сталин суды Хәсән Туфанны үлем җәзасына хөкем итә. (Мең шөкер, бу коточкыч хөкемне Совет хөкүмәте, ярый әле, үзгәртә...) Күрәсез, нинди кабахәт икейөзле мәкерлелек!.. Әлеге дә баягы кешене кешегә каршы кую, дуска-дошманга аерып хакимлек итү — нәкъ Ленин тәгълиматы буенча!

Илдә ниләр генә эшләнмәсен, барысы да Сталин акылы, Сталин ихтыяры белән генә эшләнә торган иде. Ул әйтте — Алла әйтте, бәхәскә урын юк!.. Үзе дә Алла

кебегрәк серле кеше, каядыр еракта, биектә ул, бөтен әйләнә-юне яшерен-серле аның... Зур бәйрәмнәрдә генә Мавзолей трибунасында күренә торган ярым хәрби киемдәге кара мыеклы кеше Сталин үзе түгел, ә аның төстәше (двойнигы) булган, имеш! — шулай дип яздылар соңыннан... Ихтимал, әнә шундый ерак-серле булганга күрәдер дә ул халыкның игътибарын һәрдаим үзенә тартып тора иде. Кремль курантлары суккан саен һәрбер кеше, кайда гына яшәвенә карамастан, иң элек ирексездән аны исенә төшерә: «Анда ул яши ләбаса!..» Йә сөенеп, йә сыкранып... Совет кешесе өчен Сталин һәм Ватан гүя бер төшенчәгә әверелде... Менә ни өчен Сталинны күкләргә чөю, аңа табыну чиктән ашты, шашыну дәрәҗәсенә барып җитте. Бу массакүләм психозга бирелү иде.

Әмма табыну — ярату дигән сүз түгел әле. Уйлыйм ки, Сталинның табанын яларга әзер торучылар да аны ярата алмаганнардыр. Чөнки курку барында чын яратуга урын юк... Курку һәм ярату бер-берсе белән сыеша алмый торган тойгылар.

Мин үзем «бөек юлбашчыга» бервакытта да табына алмадым һәм табынмадым. Бик иртә золымы үземә яки якыннарыма тия башлаганга күрә генә түгел... Башта ук Сталинның халыклар өчен канлы юл сайлавын күреп тордык. Шушы юлның күпме корбаннар алып киткәнен, күпме толлар, ятимнәр калдырганын, күпме күз яшьләре түгелгәнен күреп-белеп торганнан соң нинди табыну булырга мөмкин ди?! Бөтен илне каплап алган, тарихта мисле булмаган бу зольмәт бик тиз Сталинның үзенә дә, тоткан юлына да ышанмау, килешә алмау, җан газабы, хәтта яшерен нәфрәт тә тудырды. Шушы рухи авыр йөк белән, гел генә хәвефләнеп, сагаерга мәҗбүр булып, күпме еллар яшәргә туры килде.

* * *

Бөек Ватан сугышы һәм Сталин — боларны бер-берсеннән аеру мөмкин түгел, безнең хәтерләрдә алар һич җуелмас урын алып тора. Шул хакта да кыскача гына әйтеп киту, һичшиксез, кирәктер дип беләм.

Дәһшәтле сугыш Сталин өчен дә кинәт, көтелмәгәндә башланды. Шуның аркасында ул сугышның башын хурлыклы рәвештә оттырды. Хәлбуки, миңа калса, бу Сталин теләп алган сугыш иде. Аңа инде Җир шарының алтыдан бер өлеше генә җитми башлады, калган өлешләрен дә бик әйбәтләп үз кулына алырга тиеш иде. Ялгыз гына хакимлек итәргә яратучыларның бу котылгысыз

бер өянәге булса кирәк — тарих безгә шуны күрсәтә... Аннары большевизм белән фашизм вакытлыча килешкән шикелле булсалар да, алар янәшә бергә озак яши алмаячаклар иде. Моны Сталин да, Гитлер да бик яхшы белеп тордылар. Тик берсе сугышны башларга соңгарак калды, икенчесе — башлап өлгерде. Әмма безнең агрессия корбаны булуыбыз Сталинга шунда ук бик мөһим мораль өстенлек китерде. Ул хәзер кешелек дөньясы алдында үз илен, үз халкын агрессиядән саклаучы, хаклык һәм гаделлек өчен иң явыз, иң мәкерле дошманга каршы сугышырга мәҗбүр булучы... Тарих аңа әнә шундый гаять авыр, әмма бик изге миссияне йөкләде. Һәм тарих белә, бөек Сталин бу изге миссияне, һичбер нинди авырлыкларга карамастан, уңышлы үтәп чыкты: фашистларны нәкъ менә ул тар-мар итеп ташлады.

Зур җиңү Сталинга гаять зур дан китерде. Һәм бу бик хаклы килгән дан иде, чөнки Совет халкын яман көчле куркыныч дошманга каршы күтәрү, җанын аямыйча сугышырга рухландыру, ниһаять, җиңүгә илтеп җиткерү — бары Сталин исеме, Сталин кодрәте белән генә мөмкин иде... Дөрес, корбаннары чамасыз күп булды, ләкин санап-җәлләп тору булмады — адәм башкайлары сугышны очлап куярга җитте тагын... Сталинның зур масштаблар кешесе икәнлеге элек тә мәгълүм иде, бу сугыш барышында да ул моны янә кат-кат күрсәтте.

Хуш, дөньяны таң калдырган бөек җиңү исән калганнарга нәрсә бирде соң?.. Тугызынчы Май — Җиңү көнен халык шашынып елый-елый, көлә-көлә бәйрәм итте. Мәгәр бу бер көнлек шатлык тантанасы иде — ул шулай күңелләрдә уелып калды да... Инде шуннан соң җиңү халыкка нәрсә бирергә тиеш иде?.. Мин үзем, озын фронт юлларын үткән кеше буларак, шуны әйтә алам: солдатларның форсат чыккан саен бөтен сөйләгәннәре — сугыш беткәч, дөньяның һичшиксез үзгәрәчәге, тормышның бөтенләй башка булачагы, иркенлек-җиңеллекләр киләчәге турында хыяллану иде. Аеруча шушы иркенлеккә сусау, ичмасам, үзе теләгәнчә бер яшәп калу теләге исән солдатта бик көчле иде... Һәм бу сабыйларча ихлас теләкләренең вөҗүдкә ашуын ул, әлбәттә, Сталиннан көтте. Ә Сталин һаман шул ук Сталин иде. Кешене — кеше дип танымаган үтә шәфкатьсез тиран булып кала бирде. Җиңү тудырган халык өметләрен аклау аның уена, һичьюгы, бер генә тапкыр кереп чыкты микән?! Киресенчә, сугыш беткәч тә, ул үзенең тоталитар системасын ныгытыр өчен халыкны яңадан дуска-дошманга аера башлады. Әсирлектән кайтканнарның бик күбесен утыртты,

лагерьларга озатты. (Бу инде әсирлектә коточкыч газаплар кичергән үз солдатыннан ник үлмәдең, ник тере калдың дип үч алу иде.) Авылларда өелеп калган тол хатыннарны, ятим балаларны тагын 7—8 ел буена ач тотты. Җиңү аркасында әзрәк ачыла башлаган фикер хөрлеген шунда ук буды, бетерде. Советлар Союзын башка илләрдән «тимер пәрдә» белән тизрәк аерып куйды. Җитмәсә, 37 нче елдагы шикелле яңадан массакүләм репрессияләр башлап җибәрде.

Хикмәти Хода, тираннар һич кенә дә үзгәрә белмиләр икән шул!

* * *

...Сталинны үлем алмас кебек иде. Күпләрнең башына җиткән кешедән Газраил үзе дә куркадыр кебек иде. Ләкин без «корыч» кушаматын йөртүченең ныклыгына артыграк ышанганбыз. Газраил өчен ул да Аллаһы Тәгаләнең нәүбәттәге зәгыйфь бер колы гына икән... Шулай да Сталинның вафаты көтелмәгәндәрәк булды — уйламаганда зур бәхетсезлек килгәндәй, халык ничектер аптырап, каушап калды. Әйтәсе дә түгел, аның үлеме бөтен дөнья өчен фәүкылгадә зур вакыйга иде. Моннан соң ни булачак дип, кайда, кемнәр генә баш ватмаганнардыр...

...Совет халкы берничә көн тирән кайгы кичерде. Без, татар язучылары да, Тукай клубына матәм митингысына җыелдык. Сөйләүчеләрне аягүрә тыңладык. Зур үлемнең тәэсире дә гаять зур иде... Хатын-кызлардан үксепүксеп елаучылар булды, ирләрнең дә күбесе тавышларын чыгармыйча гына яшьләрен агыздылар, мин дә, билгеле, тыела алмадым... Халыкны биләгән көчле кичерештән котылу мөмкин түгел — моны кем генә сынамагандыр үз гомерендә!..

...Сталинның гәүдәсен мәрмәр Мавзолейга кертеп, Ленин белән янәшә куйдылар. Бу инде ике даһины бөтен дөнья алдында һәр җәһәттән дә тиңләү иде. Алар янәшә яткан кучкыл-кызгылт Мавзолей моннан соң да дөньяның янә бер кәгъбәсе шикелле халыкларны үзенә тартып торырга тиеш иде, һәм ул, чыннан да, шулайрак булды да: пыяла табутларда күзләрен йомып яткан ике даһиның «илаһи» йөзләрен күрер өчен Кызыл мәйданда борыла-борыла сузылган халык чираты беркайчан да өзелеп тормады.

...Күпмедер вакыттан соң шул чиратларның берсенә басып, мин дә, ниһаять, мәрмәр төрбәгә кереп чыктым. Ленинны элек тә карап узганым бар иде, бу юлы исә бөтен игътибарымны Сталинга юнәлттем. Пыяла табутта

батыбрак яткан кечерәк, юкарак кына гәүдә — өстендә гадәттәге хәрби китель, йөзе саргылт, шактый агарган чәч һәм мыек. Күбрәк менә шушы тар маңгайлы башына карадым: бу маңгай эчендә бик гаҗәп шәп көйләнгән бик көчле акыл эшли торган булган... Аның бит һәр әйткән сүзе дә бик ачык, бик аңлаешлы була торган иде. Примитив Совет халкы һәрбер сүзен симез калҗа капкандай, йотып кына бара иде... Тагын кителе өстендә яткан кулларына игътибар иттем. Гаҗәп, алар кызларныкыдай кечкенә-нәфисләр иде... Шунда ук күңелгә сәер бер уй килде: кара, шушындый кечкенә куллар да зур дөньяны йодрыгында тотып тора алган икән ләбаса!!!

...Ә халык Сталинны бер дә онытмый, еш кына исенә төшерә. Хәтта мин дә искә төшергәлим, чөнки бүгенге хәлебез бик әшәке, ниндидер ерып чыга алмаслык тончыктыргыч баткаклыкка кереп баттык шикелле. Сталин заманын күргән кешеләр өчен бәхәссез бер хакыйкать бар: хәзергедәй чамасыз башбаштаклык, җавапсызлык, сансызлык, баштан ашкан җинаятьчелек — боларның берсе дә Сталин вакытында асла мөмкин түгел иде. Моның ише яманлыкларны ул — Корыч абзый, көйдереп кенә ташлый торган иде... Ләкин сүз бередә Ленин-Сталинның халыкларны алдый-алдый, көчли-көчли төзергә тырышкан ялган социализмнарын аңардан тагы да күпкә ялганрак, вафасызрак, халыкны зар елаткан кыргый капитализм белән алыштырырга маташу турында бармый. Сүз бары дәүләт белән идарә итә белү турында гына бара. Менә шул күзлектән караганда, хәзерге җитәкчеләр Сталинның салып ыргыткан сыңар итегенә дә тормыйлар... Артыграк, катырак диярсез, бәлки... Әмма бүгенге бернинди әхлакка да, акылга да сыймаган хәлләргә карап башкача әйтергә мөмкинме соң?! Хәер, бу әле минем соңгы сүзем түгел, дәвамы булачак, тик миңа бераз тынып тору кирәк. Юлым кыска булса да, йөгем авыр...

## Хрущев чоры

Сталинның үлеме кешелек дөньясын өнсез калырга мәҗбүр иткән фәүкылгадә вакыйга иде. Аңа мөнәсәбәт тә бертөсле генә булуы мөмкин түгел иде. Дөньяның яртысы, ниһаять, җиңел суласа, икенче яртысы, һичшиксез, авыр сулагандыр... Әмма ул адәмгә мөнәсәбәтнең нинди булуына карамастан, аның исеме инде буыннар хәтерендә мәңге саклаviolачак... Андый шәхесләр кешелек тарихында бармак белән генә санала.

Без әле аның үлеменнән соң айнып та җиткәнебез

юк иде. Үлде, бетте, юк инде ул! — дигән уй аңыбызда һаман әле ныгып җитә алмый... Аның тере шәүләсе, аның хәтәр тылсымы безне һаман әле әсирлектә тота... Бу әсирлектән тиз генә котылып та булмас, ахрысы. Әнә «Литературная газета»ның баш редакторы Константин Симонов нәкъ шул көннәрдә: «Совет әдәбиятының хәзер иң изге төп бурычы — даһи Сталинның бөек образын мәңгеләштерү»,— дип, махсус мәкалә дә бастырып чыгарды... Әлбәттә инде, бу «мәңгеләштерү» шаукымы Ленинныкы шикелле үк күп елларга сузылачак, насыйп булса!

Әмма ләкин Сталин үлеме көне-сәгате белән үк ил алдына һич кичектермәс үтә җитди мәсьәләне китереп куйды: даһи юлбашчының «нәфис» кулыннан төшкән тимер авызлыкны хакимият тезгенен кем алыр, кем бушап калган иң югары урынга менеп утырыр?.. Изге урынны бит бер генә көн дә буш тотарга ярамый torгандыр... Билгеле, ил халкын беренче нәүбәттә шушы мәсьәлә гаять кызыксындыра, мәгәр бу мәсьәләне хәл итүдә аның һичбер төрле дә катнашы юк. Ул бары тик көтә — тегендә, Кремль эчендә ни уйлыйлар, ничек хәл итмәкче булалар... Ә Кремльдә ул хакта баш ватучылар — Политбюро әгъзалары... Халыктан гына түгел, күпмедер миллион партия әгъзаларыннан да сорап тормыйча гына мәсьәләне хәл итәчәкләр. Сталинның гәүдәсе суынып-суынмас алар арасында инде җитәкчелек тезгенен алу яки кемгә бирү турында яшерен уйлану, план кору, бер-берсеннән шикләнү һәм курку мотлак башланган да булгандыр... Бу бик астыртын нечкә уен булса кирәк. Монда һәркайсы ил язмышы турында гына түгел, үз башы турында да уйланырга, мөгаен, мәҗбүрдер. Кемгә ышанырга, кемнән сакланырга — моны бит алдан белеп тору кирәктер. Аларның кайсысы гына үзен Сталин урынында иң лаек кандидат дип санамас!.. Барысы да лаек, барысы да аның варислары, мәгәр бушап калган урынны кемдер бирәү генә биләргә тиеш!.. Кем ул «бирәү», кемгә язган ул иң югары урын?.. Барысын да күптәннән ишетеп беләбез, әмма үз араларындагы мөнәсәбәтләре турында һичнәрсә белмибез — ул кадәресе безгә төн кебек караңгы. Тик имеш-мимеш сүзләргә караганда, Сталин соңгы вакытларда күбрәк Маленковка ышанган, күбрәк аны үзенә якын тоткан, ә менә Молотовны нигәдер өнәми башлаган, имеш... Бу икедән кала даһига күптән якын торучылардан Ворошилов, Каганович, Микояннар да бар. Ләкин боларның берсе дә «корычны» алыштырырлык көчле шәхесләр имәс, минемчә...

Хәер, Сталин урынына кем булыр, дип, алдан юрап

маташудан мәгънә юк. Мәсьәлә бик тиз хәл ителсә кирәк, чөнки бу галәмәт зур илне җитәкчесез озак тотарга һич тә ярамыйдыр, билгеле...

Һәм Сталинны җирләмәс борын ук инде ашыгыч чакырылган Үзәк Комитет пленумы партиянең беренче секретаре итеп иптәш Хрущев Никита Сергеевичны раслый... Менә бу яңалык, ичмасам... Бик күпләр өчен көтелмәгән яңалык — алар мотлак Маленковны яки Кагановичны көткәннәрдер... Сталинга иң якын торучыларны, дәрәҗәләре белән эреләрне... Мәгәр моның хәзер ни әһәмияте бар?.. Хрущев агай да ваклардан түгел ич!.. Сталин мөридләренең күптәнгесе, тегеләр шикелле үк варисларның берсе, Политбюро әгъзасы... Менә үзара ничектер килешкәннәр дә тезгенне аңа тоттырганнар... Уен хәзергә шуның белән тәмам... Инде Никита агайның галәмәт зур илне ниндиерәк юлдан алып китүен, кая таба каергалавын көтәсе генә калды. Миңа калса, аның куллары таза, нык булырга тиеш.

Чынлап та Никита Хрущев озак көттермичә үзенең көчен-сәләтен безгә күрсәтә дә башлады. Ул — фотоларына караганда, тәбәнәк-юантык кына, зур авызлы чын урыс — гаять кыю, тәвәккәл һәм бик өлгер, җитез бер кеше булып чыкты. Сталинны бик зурлап, Мавзолейга, Ленин янына кертеп салганнан соң, яңа җитәкче эшен нәрсәдән башларга тиеш иде? Билгеле инде, традиция буенча үзенең хакимиятен ныгытудан — кемгә таянырга, кемнән котылырга?.. Менә бу соңгысы бик тиз табылды: барысы өчен дә иң куркынычы — Лаврентий Берия икән!.. Бу грузин кулында гаять зур көч тупланган, Сталин вакытындагы шикелле теләсә кемне тотып утырту гына түгел, хәтта бөтен Кремль оясын туздырып ташларга да хәленнән киләчәк... һәм хакимиятне үз кулына эләктереп тә алачак!.. Бер грузиннан котылыр-котылмас, икенче грузин тозагына төшүдән бер Ходай үзе генә саклый күрсен!

Хрущевның беренче батырлыгы — ул менә шушы гаять сизгер, сак, хәтәр адәмне ничектер бик оста, бик капыл гына тотып ала да, күптән кулланылып килгән әзер шаблон буенча аны «империализм агенты» булуда гаепләп, тиз генә теге дөньяга олактыра да... Бусы инде, мин язмасам да, күптән мәгълүм нәрсә. Тик шунысы гыйбрәтле — дәүләтнең иминлеген тәэмин иткән, большевиклар диктатурасын көне-төне уяу саклаган органның җитәкчеләрен моңарчы да әнә шулай юкка чыгара килделәр. Иң элек Ягоданы аттылар, аннары Ежовны, инде менә Берияне дә стенага терәделәр. Бу тоталитар систе-

маның үзенә күрә бер закончалыгы булса кирәк. Ул, мәсәлән, канлы җинаятьләр өчен гаепне «эшлә» дип боерык бирүчедән боерыкны тырышып үтәүче өстенә аударырга мөмкинлек бирә. Шул рәвешчә тоталитар система кирәге беткән яки хәтәргә әйләнгән куркыныч сакчыларны берәм-берәм юкка чыгара бара.

Әмма Хрущевка үз хакимиятен ныгыту өчен бер Бериядән котылу гына җитмәде. Ул үзенә конкурент булырдай барлык авторитетлардан да котылырга тиеш иде. Яңа җитәкче өчен бу зарур — шунсыз ул тынычлана алмаячак. Һәм, мәгълүм булганча, Хрущев абзаң Сталиннан калган Молотов, Каганович, Маленков кебек көчле-хәтәр варисларны да артык озакка сузмыйча гына җитәкчелектән төшереп, төрлесен төрле якка таратты.

Минем бу хакта язып торасым да килми, мин бары бөтен дөньяга билгеле фактларны гына теркәп узам. Алар җитәкчелек алышынганда була торган гадәти үзгәрешләр, тик без аның бөтен серләрен генә белмибез — белү безгә тиеш тә түгел... Ләкин югарыда ниләр генә эшләнмәсен, аның нәтиҗәсе безнең ише иң түбәндә авызын ачып, көтеп торучыларга да иртәме-соңмы килеп кагыла.

Әмма үзгәрешләрнең иң зурысын, иң җитдиен без соңрак күрдек. Хикмәт шунда ки, яңа җитәкче Сталин яраннарыннан котылу белән генә чикләнмичә, корыч юлбашчының үзе турында да чын дөресен әйтергә җөрьәт итә: партиянең нәүбәттәге XX съездында ул Сталинның җинаятьчел эшләре турында махсус доклад белән чыга... Аның сөйләгәннәре күпләр өчен, асылда, шаккатырлык яңалык та булмагандыр, әмма ләкин моңарчы Сталинның үзеннән генә түгел, исеменнән дә котлары алынып һәм аңа табынып яшәүче бик күпләрне Хрущевның батырлыгы, һичшиксез, таң калдыргандыр. Даһи, бөек, тиңсез, дәһшәтле юлбашчыны чикләнмәгән властька ия булуда, Совет законнарын даими бозуда, күпме кешеләрне нахакка үтереп бетерүдә гаепләп чыгу өчен иптәш Хрущевка күпме тәвәккәллек, күпме кыюлык кирәк булгандыр?!

Мәгәр каян мондый тәвәккәллек, мондый кыюлык?.. Ул бит үзе дә, чын большевик буларак, Сталинга урталай бөгелеп, җанын аямыйча хезмәт иткән, аның һәр сүзен, һәр гамәлен аклап-хуплап килгән, шулай ук җинаятьчел эшләрен үткәрүдә дә вакытында актив катнашкан кешеләрнең берсе... Югыйсә ул партия җитәкчелегенең иң югары баскычларына Сталин фатихасыннан башка күтәрелә алган булыр идемени...

Бу парадоксны аңлауның, миңа калса, ике ягы бар: беренчедән, яңа җитәкче үз сәясәтен, үз юлын билгеләргә тиеш. Ул сизә, халык аңардан яңа сүз, яңа эшләр көтә. Ул кемдер үткән юлны кабатламаска тиеш. Шул чагында гына ул үзенең кем, нинди җитәкче икәнлеген күрсәтә алачак.

...Икенчедән, кеше сөякләре өстендә социализм төзеп маташуның ахыры бик начар булып бетәргә мөмкин. Халыкның бик күп өлеше Сталин җинаятьләрен бервакытта да гафу итмәячәк... Димәк, ул җинаятьчеләрне партия үзе башлап хөкем итәргә тиеш — бары шулай гына Совет җәмгыятенең сәяси, рухи атмосферасын уңай якка үзгәртеп булачак.

Һәрхәлдә, Хрущев чыгышын большевиклар тарихында кечерәк бер революциягә тиң бөек вакыйга дип атарга да ярый торгандыр. Шуның аркасында мәңге какшамас булып тоелган Сталин культы һәм аның канлы җинаятьләре бөтен дөнья алдында ачыктан-ачык хөкем ителде. Ә ул гөрҗәнең үзен, Газазилне күктән сөргәндәй, Мавзолейдан чыгарып, җиргә күмделәр, бөтен илне каплап алган эреле-ваклы һәйкәлләрен алып ташладылар, кайларда ниләргә генә тагылмаган бихисап исем-шәрифләрен дә сызып бетерделәр.

Гаҗәеп вакыйга ич бу!.. Тоталитар системаның нигезен какшату түгелме соң бу?! Хәер, болай уйлап куанырга иртәрәк иде әле, Сталин сөреме кешеләр аңыннан тиз генә чыгып бетмәячәк иде әле... Озак сакланачак әле ул, озак...

Ләкин инде заман шактый ук үзгәрде, без бит башка чорга — Хрущев чорына кердек. Аның баштарак өлешен «оттепель» дип атадылар. Илья Эренбург шушы исем белән китап та чыгарып өлгерде. Чынлап та, көннәр ничектер яктырып, офыклар киңәебрәк киткәндәй булды... Җәмгыятьтә сәяси-иҗтимагый атмосфера йомшарды, гадәткә кергән курку-сагаюлар кимеде, иркенрәк сулый да башладык... Кәеф тә яхшыра төште, эшкә дәрт тә үсте.

Бәрәкәтле бу үзгәрешне мин иң элек үземдә тойдым. Сталин вакытында минем әдәбияттагы хәлем шактый мөшкел иде. Читләтү һәм кырын караш җанны бик борчый иде. Хәзер исә мин үземне башкалар белән тигез итеп тоя башладым. Иң мөһиме — үзем теләгәнне үземчә язу мөмкинлеге туды кебек... Мин, мәсәлән, «Ялгызлык», «Әйтелмәгән васыять», «Төнге тамчылар» һәм «Йөрәк сере», «Саз чәчәге» кебек хикәя-повестьларымны нәкъ менә «оттепель» елларында яздым.

...«Оттепель», билгеле, мине генә эретмәде — күпләргә җан өрде ул... Әйтик, сугыштан соңгы елларда әдә-

биятка бер-бер артлы килеп, канатларын җәя алмыйчарак йөргән Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләҗев, Шәриф Хөсәенов, Рафаэль Төхфәтуллин, Әхсән Баян, Мөхәммәт Мәһдиев кебек яшь талантлар әнә шул «Хрущев җылысыннан» ничектер дәррәү генә ачылып, күтәрелеп киттеләр... Һәм, озак та үтми, бу егетләр бер-берсенә һич охшамаган бик үзенчәлекле каләм осталары булып танылдылар да... Хәтта, әйтер идем, әдәбиятыбызның төп юнәлешен дә алар билгели башлады. (Ягъни купшы ялган урынына чын дөресен язарга омтылу көчәйде.) Мондый тенденцияне барлык совет әдәбиятында да күзәтергә мөмкин иде.

Билгеле инде, әдәбият дөньясындагы бу җанлану Хрущев китергән үзгәрешләрнең бер өлеше генә — аңардан да зуррагы, әһәмиятлерәге халык тормышында күренә башлады. Мәсәлән, Сталин вакытында үзе үстергән игеннең бөртеген дә алалмыйча, ачлы-туклы бушка эшләгән колхозчыларга Никита абзаң хезмәт көненә икмәк бирә башлады... Моның ише матур эшләре баштарак аз булмады бу тынгысыз-кыю җитәкченең... Кремльдә генә посып ятмый ул, күп йөри, халык белән аралаша, күп сөйләшә, бәхәсләшә... Үзе дә бөтен килеш-килбәте белән халыкка якын, гади кеше... Менә, ниһаять, әйбәт җитәкчегә тап булдык дип куанып яшисе иде дә бит югыйсә!.. Юк шул, өметләр көткәнчә үк акланмады, зур аянычка каршы... Гаҗәп хәл, большевик җитәкчеләренең барысына да бер уртак сыйфат хас: алар эшләрен матур башлыйлар, ямьсез бетерәләр. Мондый хәлне без Лениннан башлап Горбачевка хәтле күзәтеп килдек.

Нидән бу?.. Моның без белмәгән яшерен сәбәпләре күп булырга мөмкин, әмма күзле кешегә ачык күренеп торган ике сәбәбен әйтмичә булмый: аның берсе — большевиклар диктатурасын ничек тә саклау; икенчесе — бөтен властьның бер кеше кулында тупланып бетүе... Бу җәһәттән Сталин белән Хрущев арасында нинди аерма?.. Хрущев та властьны кулында нык тотарга һәм большевиклар диктатурасын уяу сакларга тиеш түгелмени? — бернинди йомшартып, җылытып маташуларга карамастан!.. Аларның бит тәгълиматлары бер үк марксизм-ленинизм, максатлары бер — коммунизм төзү, аерма тик шуңа ирешүнең ысулларында гына... Бу очракта инде аерма шактый зур. Иң элек аларның характерларында: берсен чамасыз явыз, икенчесен дуамал дип атау, бәлки, урынлы булыр иде. Чөнки аларның идарә итү ысуллары да шул характерлары белән бик нык бәйләнгән, дип уйларга җитәрлек нигез бар.

...Сталинныкын кабатлап торасы килми — аның утыз

елга сузылган канлы «ысулы» халык хәтерендә бик нык уелып калды — мәңге онытылачак түгел!.. Хрущев, билгеле, Сталин эзеннән китмәде, репрессияләрне кире какты, үзенә бөтенләй башка ысул сайлады. Ил язмышы һәм халык тормышы белән бәйләнгән бик күп проблемаларны хәл итәр өчен ул үз белдеге белән төрле яңалыклар уйлап чыгара башлады. Әйтик, икмәк кытлыгын хәл итәр өчен гомер бакый төрән кермәгән казах далаларын үзләштерергә кереште. Моның өчен Рәсәйдән бик күп урысны Казахстанга күчерде. (Шул ук вакытта урта Россиянең үз җирләре кул көче җитмәүдән буш ятып, сазлыкка әйләнеп бетте диярлек.) Чирәм җирләрне күтәрү икмәк кытлыгын күпмедер дәрәҗәдә киметте, билгеле, ләкин проблеманы шулай да тулысынча хәл итә алмады. Җитмәгән икмәкне барыбер капиталистик Америка белән Канададан китертергә туры килде.

Яки менә җан башына ит җитештерүдә шул ук Американы узып китәр өчен, Никита абзыкаең җиңел кулдан колхоз-совхозларның һәм аерым хуҗаларның да сыерларын мәҗбүри рәвештә «поголовно» суйдырырга тотынды... Шактый шау-шулы бер кампания булып узды бу... Мин ул чакларда «Бөреле» совхозына баргалап йөри идем. Совхозның һәр йортында сыер асрыйлар иде, һәр иртән поселок урамыннан зур көтү кырга чыгып китә иде... Берзаман кайтсам, поселок тын, көтү юк, сөт исе дә аңкымый, сыер мөгрәве дә ишетелми — суеп бетергәннәр мәхлукларны!..

Ит мәсьәләсендә Американы бер генә айга булса да куып җиттеме-юкмы — ул турыда рәсми белдерү булмады, ә менә Хрущев боерыгын аеруча тырышып үтәгән Рәзән обкомының беренче секретаре соңыннан үзен-үзе үтергәч, ул хакта гәзитәләр ничектер хәбәр иттеләр.

...Никита Сергеевичның болар ише «яңалыклары» аз булмады, һәммәсен дә санап чыгу лазем түгел, мәгәр бер файдалысы турында әйтеп китү кирәктер... Билгеле булганча, совет хөкүмәте утыз-кырык ел буена торак йортлар салу белән бөтенләй шөгыльләнмәде. Шәһәр халкы, байлардан калган йортларны вак кетәклекләргә бүлгәләп, шуларда тора бирде... Һичбер җае булмаганга һәм кысылып яшәгәнгә күрә аларны «коммуналка» дип атыйлар иде. Халык саны әкренләп арта, йортлар искерә-туза, шулай итеп, торак мәсьәләсе бик үткен проблемага әйләнә... Менә шуны ничек тә хәл итәр өчен Хрущев, гадәтенчә, үгезне мөгезеннән алгандай, тиз генә әзер блоклардан бишәр катлы тартма йортлар салдыра башлый... Дөрес, алар сокланып карарлык, яратып торырлык бул-

мый, мәйданы бәләкәй, түшәме тәбәнәк, шуңа күрәдер аларны «хрущевка» дип атадылар да («трущоба» урынына), тик шулай да алар «коммуналка»лардан күпкә яхшырак — кешеләр, ичмасам, ванна белән туалетлы квартираларга керделәр. Әмма иң мөһиме, ул йортлар торак кризисын күпмедер дәрәҗәдә җиңеләйттеләр...

...Тынгысыз картның кайбер гамәлләрен аңлавы да читен иде. Мәсәлән, ул ниндидер уңай белән, юмартланып китеп, тотты да Кырымны Украинага бүләк итте... Ә Сталин тарафыннан сөрелгән Кырым татарларын үз җирләренә кайтару турында уйлап та карамады... Хәлбуки Сталин җинаятьләрен фаш итүче бөтен бер халыкка карата эшләнгән коточкыч гаделсезлекне иң элек бетерергә, һич кичекмәстән аларның туган илләренә кайтарылуларын тәэмин итәргә тиеш иде. Юк, ул моны эшләмәде. Ә фаҗига кичерүче татарлар исә, әнә шул гаделсезлекне төзәтүне көтеп, кырык ел партия Үзәк Комитетының бусагасын сакладылар.

...Янә бер вакыйганы искә төшерик. Иптәш Хрущев, иптәш Ленин шикелле үк, империализмны бер дә яратмый иде. Шуның аркасында булса кирәк, ул алдын-артын уйлап тормыйча, тота да Кубага атом бомбаларын чөя торган ракеталарны күчерә башлый.

Янәсе, «азатлык утравын» империалистлардан саклый!.. Аның бу дуамал эше Советлар Союзы белән Америка Кушма Штатлары арасын бик хәтәр кискенләштерә. Хәтта сугыш башланып китү куркынычы да туа... Ярый әле, президент Кеннединың акыллы сабырлык күрсәтүе һәм безнең Никитаның да исенә килеп, вакытында чигенә белү нәтиҗәсендә генә ул атом һәлакәтеннән котылып калабыз... Тик шулай да Никита Сергеевичның бер дә сер бирәсе килми, җай чыккан саен ул империалистлар адресына үзе яраткан «Кузькин мать»ны һаман әйткәләп тора. (Мәсәлән, Берләшкән Милләтләр трибунасыннан.) Ул бит чын урыс, чын большевик, чын патриот иде. Һәр эшендә диярлек аның ул сыйфатлары күзгә ташланмыйча калмый иде.

Соңгы мисал итеп янә бер-ике эшен генә искә төшереп үтик — болары туп-туры безгә, язучыларга да кагыла... Кайсыдыр елның җәендә Никита Сергеевич кунакчыл, юмарт хуҗа буларак үзенең дачасына әдәбият һәм сәнгать әһелләрен чакыра, башта бик әйбәтләп сыйлый, аннары инде сүзгә-бәхәскә күчә. Гадәтенчә, бик тиз кызып китә, идеологиясе бик үк ачык яки дөрес булмаган кайбер кунакларына өстәл суга-суга каты тәнбиһ (кисәтү) дә ясый... Шагыйрь Андрей Вознесенскийны пешек-

ләгәндә, ул хәтта: «Сез әллә Сталин үлде, дип уйлыйсызмы?» — дип тә ычкындыра. Бу инде тугры юлдан тайпылучыларны ачыктан-ачык Сталин белән өркетү... Мондый сыйланудан соң күпләр атналар буе айный алмыйча йөргәннәрдер, мөгаен.

Ә менә бусы инде безнең иң нечкә җиребезгә кагыла: ул керткән закон буенча ата-ана баласын теләсә нинди телдә укытырга хаклы иде. Беренче карашка гүя демократик булып күренгән бу «хокук», асылда, ана телен әкренләп бетерүгә юнәлдерелгән бик мәкерле бер чара иде. Шушы «хокук» аркасында безнең Казанда бөтен татар мәктәпләре ябылып бетте диярлек. Кайчандыр үзенең мәктәп-мәдрәсәләре белән дан тоткан Уфа, Ырынбурларда да татарча бер генә башлангыч мәктәп тә калмады. Ырынбур өлкәсендәге авылларда да татар мәктәпләрен урысча укытуга күчереп бетергәннәр иде — мин моны үзем күреп кайттым.

Моның шулай булачагын алдан ук белеп торырга мөмкин иде. Чөнки урыс теле — өстен тел, дәүләт теле, киләчәктә югары белем алыр өчен дә, эшкә керер өчен дә иң элек аны белү зарур... Теләсәң-теләмәсәң дә балаңны урыс мәктәбенә җитәкләп илтмичә хәлең юк... Безнең мондагы җитәкчеләр исә милләт мәнфәгатен үзләре яклау түгел, ул хакта авыз ачып сүз әйтүчене дә бер дә яратмыйлар иде... Кайберәүләр, бәлки, хәтерли торганнардыр әле, язучыларның бер җыелышында, иптәш Табиев алдында мин татар теленең аяныч хәле турында сүз әйткәч, ул, бик яман кәефсезләнеп, миңа карата: «С кем мы имеем дело?» — дип, бик хәтәр кисәтү дә ясаган иде.

Урыс теленең кирәклеген берәү дә инкарь итми, әмма аны белү өчен туган телне нигә югалтырга? Урыс мәктәбен узган татар яшьләре хәзер үз телендә укый да, яза да, юньләп сөйләшә дә белми... Көчләп чукындырмыйча гына әкренләп урыслаштыру түгелмени бу? Тел язмышы — милләт язмышы дип, юкка гына әйтмиләр ич!

...Җитәр булмаса, туйдырды, ниһаять, бу «кызыклы» чор да... Һәм, әйтергә кирәк, Никита Сергеевич Хрущевның соңга табан артык дуамалланып, сул аягы ни кушса, шуны эшли башлавы югары җитәкчелектә утыручыларның да күбесен бик туйдыргандыр, ахрысы... Алтмыш дүртенче елның көзендә, Сочида ял итеп яткан җиреннән Мәскәүгә чакырып алып, Политбюро утырышында аны волюнтаризм һәм субъективизмда гаепләп, мәгәр гаугасыз гына бөтен вазифаларыннан азат иттеләр... Ә бит шул елның язында гына аның 70 яшен шаулатып бәйрәм иткәннәр иде... Нишләсен, дөнья юлбашчылар өчен

дә күләсә, кем әйтмешли. Соңыннан ишетелгән дә иде, Никита Сергеевич Политбюро утырышында ук, гарьлегеннән тыела алмыйча, чынлап җылаган да, имеш! Гаҗәп тә түгел. Властьтан аерылу — җаныңнан аерылу белән бер ул! Кеше властька теше-тырнагы белән ябыша — без моны бүген дә күреп торабыз.

...Аның урынына гел аңа тагылып йөргән киң күкрәкле, куе кара кашлы, мәһабәт Леонид Ильич Брежнев менеп утырды... Шул рәвешчә большевиклар практикасында беренче тапкыр бугай, иң югары җитәкчене кан коюсыз, шома гына алыштыру булып узды. Моны инде яхшыга юрарга да ярый иде.

* * *

Хуш, ни күрдек, ни аңладык, ниһаять, ничегрәк яшәдек без бу 7—8 еллык онытылмас Хрущев чорында? Билгеле, хикмәтле эшләрне күп күрсәк тә, ил язмышын тамырыннан үзгәртерлек зур вакыйгалар булмады диярлек. Кайбер иске хакыйкатьләр генә яңадан расланды: партия һәм дәүләт башындагы кеше, кем генә булмасын, ниләр генә кыланмасын, ул үзен тудырган системаның тугрылыклы хадиме булып кала бирә икән. Китә дә алмый, үзгәртә дә алмый ул һәммәсен үзенә буйсындырган, беркемне дә аямый торган тоталитар системадан. Шул ук вакытта система да үзенең беренче баш хадименә барлык шартларны тудыра — кирәксә, диктатор да ясый, хәтта «культка» да әйләндерә ул аны... (Чынлап та, Хрущев культы да туган иде инде...) Шулай да «Хрущев чорында» яшәве күпкә җиңелрәк булды. Әйткәнемчә, аңа ияреп килгән «оттепель» беркадәр хөрлек китерде, кыю гына әсәрләр дә язылды, телләр дә чишелә төште... Озакка сузылган бөлгенлектән дә әкренләп чыгып киләбез — кыскасы, яшәп булырлык иде. Әмма иң мөһиме — Сталин вакытындагы шикелле газиз җаның өчен калтыранып торулар бетте диярлек... Дөрес, Хрущев иптәш тә Советка тискәре кешеләрне бер дә яратмый иде, артык баш бирмәгәннәрне «психушка»ларга ябудан яки чит илләргә сөрүдән дә тартынып тормый иде. Ләкин юлбашчының характерын һәм властьның нәрсә икәнен яхшы белгәнгә күрә, без инде аңа ничек тә лояль булырга, ачуын китермәскә тырыша идек. Моңа инде без күптән өйрәтелгән идек.

...Җыеп кына әйткәндә, Хрущев исеме белән бәйләнгән кызыклы гына бер чор безнең тарихка кереп калды. Эшен яхшы башлап, ямьсезрәк бетерсә дә, ул тормышы-

бызга байтак кына үзгәрешләр кертеп китте. Шуңадыр, ахры, мәрхүмгә карата күңелләрдә һаман да әле үзенә бер хөрмәт хисе саклана. Үз идеалына бик нык бирелгән, үз иманында бик нык торган чын коммунист иде... Ул бит, мәрхүм, безгә сиксәненче елларның урталарында коммунизмда яши башларсыз, дип тә әйткән иде... Һай гомерләр, гомерләр... Килеп җиттек без менә ул вәгъдә иткән «коммунизм»га да. Үзе кайтып күрсә, ни эшләр иде икән, бичара?.. Яланаяк туп-туры «психушка»га чабар иде, мөгаен... Иманлы коммунистка шуннан башка урын калмады бу имансыз большевиклар заманында!

* * *

Мин язарга теләгән чорларның өчесен үттек... Әгәр Ленин чорын 17 елдан башласак, бу минем 8 яшемнән алып 15 яшемә чаклы елларга туры килә. Үсмер күңелнең елдан-ел һәр яңалыкка, яктылыкка ачыла барган чагы... Ә Ленин исеме белән безгә әнә шул яңалык һәм яктылык килде. Шуңа күрә аңа ышану бик көчле булды. Әмма соңыннан алдану да искиткеч авыр булды. Сталин чорына кергәч, озак та үтмичә, бөек Ленин исеме белән бәйләнгән өметләр, һәрхәлдә, минем өчен, төтен шикелле тарала да башлады... Сталин чорының нәрсә икәнен мин инде язып үттем — яңадан кабатланасым килми... Мәгәр ул каһәрле чор бик озакка сузылды, гомернең дә иң асыл чагын үзе белән алып китте... Ниһаять, анысы да үтте, мең шөкер!.. Мин, минем шикелле миллионнар, ул чордан рухи каты кыйналып (хәтта имгәнеп тә), ләкин шулай да газиз җанны саклап чыга алдык. (Мин монда Сталин чорының рәхәтен күрүчеләр турында язып тормыйм, анысы — алар эше...) Заяга узса да, бушка узмады гомер — күпне күрдек, күпне белдек, ачы тәҗрибә җыйдык, ялган сүзгә ышану бетте, ичмасам!..

...Инде менә Хрущев чорын да төгәлләдем... Нинди нәтиҗә ясарга мөмкин соң?.. Мәгълүм ки, бу өч юлбашчы — Ленин, Сталин, Хрущев — бер-берсеннән бик нык аерылалар — чыгышлары, тәрбияләре, белемнәре, акыллары, характерлары — кыскасы, бөтен яктан да!.. Шул ук вакытта аларны бер-берсеннән аерып та булмый, чөнки һәркайсының бөтен кайгысы, бөтен эше — властьны кулында тоту һәм тоталитар системаны какшатмыйча саклау иде... Без менә шуңа иялә штек, яраклаштык, нинди дә булса җитдирәк үзгәрешләрне чираттагы большевик җитәкчедән генә көтә торган булдык... Болай яшәүне ирекле коллык дип атарга да була.

Хрущев чоры беткәндә, миңа 55 яшь иде инде. Гомер уза... Күңелдә ирексездән шик туа, борчылу туа: «болай яшәүнең» ахырын бер күреп булыр микән?.. Тагын күпме көтәргә?.. Кояшым әнә төшлектән авышты... Гомер кояшы батканчы, өмет кояшы чыгып өлгерерме?.. Менә шуны күрәсе килү — яшәүнең мәгънәсе иде минем өчен... Хәер, өмет кояшын борчылып көтүче бер мин генәме соң?!

**Брежнев чоры**

Мәгълүм булганча, Хрущевны Брежнев алыштырды. Менә шул кеше исеме бәйләнгән чор турында сүз барачак... Сталинныкыннан соң бу иң озакка сузылганы — 18 ел чамасы дәвам итте булса кирәк... Ләкин минем аның хакында артык җәеләсем килми; бердән, ул чорны хәзерге заман кешеләре бик яхшы хәтерлиләр, икенчедән, Совет заманының иң тыныч, иң тотрыклы бер чоры булды ул...

Аңардан соң партия лидерларыннан ике авыру карт — Черненко белән Андропов — бер-бер артлы бик кыска гына вакытка җитәкчелеккә килеп, шулай ук бер-бер артлы бу фани дөньядан китеп тә бардылар. Алар турында язарлык нәрсә дә юк. Черненко башта ук бер тере мәет иде инде, аны ике ягыннан култыклап җитәкчелеккә утырткан булдылар. Шунлыктан ул бичара үзе турында халыкта кызгану тойгысыннан башка берни дә калдырмады.

Партиянең күптәнге көчле лидеры, унбиш ел буена КГБ башында торып, илнең хәлен бик яхшы белгән Андропов тоталитар системага нindидер яңалыклар кертергә тырышып караса да, Ходай аңа моның өчен җитәрлек гомер бирмәде. Җитәкче буларак тарихка ул безнең җиргә юриме, адашыпмы килеп кергән Көньяк Кореяның пассажир самолетын бәреп төшерергә кушуы белән кереп калды. Самолеттагы 300 ләп кеше диңгез төбенә киттеләр. Бу коточкыч фаҗигале җинаятьне дөнья җәмәгатьчелеге хәзер дә әле онытканы юк.

Әйтергә кирәк, җитәкчелек бик картайды, бер-берсен алыштырырга тиешле партия лидерларының бик күбесе 70—80 яшьлек бөкре бабайлар иде... Әмма Андропов үзенең соңгы васыяте белән җитәкчелекне бик нык яшәртте. Ил белән идарә итү ЦКның иң яшь секретаре Горбачевка тапшырылды. Биш елдан соң, аны таптап, властька Ельцин килде. Болар инде кыска бер чорны гына түгел, дөньяның үзен тамырыннан үзгәртеп ташладылар. Гүя Җир шары кире якка табан әйләнә башлады... Без

бүгенге көндә менә шуның шаһитлары. Мәгәр ни өчен болай булганын һаман да әле аңлаудан гаҗизбез... Ярар, алар турында вакыты җиткәч, ә хәзер «Брежнев чоры»н кыскача гына искә төшереп үтик.

Халык бу чорны сагынып яши. «Җәннәттә торганбыз икән»,— дип әйтүчеләр дә бар икән хәтта... Җәннәтнең дәрәҗәсен бу хәтле үк төшерергә ярамыйдыр инде, әмма мин ул чорны үзем дә еш кына сагынам. Салмак кына аккан тирән елгадай тыныч, хәвефсез генә дәвам иткән бер чор иде ул... Билгеле, без байлык дигән нәрсәне күрмәдек-белмәдек, ләкин тамагыбыз тук, өстебез бөтен булды... Мин әле хәзер дә шул Брежнев заманыннан калган киемнәрне өстемдә йөртәм. Акча кадерле һәм бәрәкәтле иде... Егерме ел буена мин 120 сум пенсия белән яшәдем. Шуңа күпме-азмы гонорарлар да өстәлә торды. Нәкъ шушы чор дәвамында мин күп йөреп тә калдым: елына ике мәртәбә карчыгым белән иҗат йортларына бара идек. Кырым, Пицунда, Дубулты, Малеевка йортларында ничәшәр мәртәбә булдык без... Алма-Ата, Ташкент, Ленинградтагы дуслар яки туганнар янына да барып кайта идек... Кыскасы, теләгән җиргә барып кайту җиңел дә һәм хәлдән дә килерлек иде. Тик мин «заграницы»га гына  чыга алмадым. Врачлар рөхсәт итмәгән булдылар... Хәер, врачлар артында нindидер бүтән бер бик көчле орган мине «саклаган» булса кирәк, югыйсә минем ул чакларда Җир шарының теләсә кайсы ноктасына барып кайтырлык җегәрлегем бар иде әле... Гүя кечкенә факт, мәгәр чорыбыз өчен бик характерлы ул...

Чынлап та, Брежнев исеме белән бәйләнгән ул чор нинди зур үзгәрешләр китерде безгә... Ярый, тормыш шартлары күпмегәдер яхшырды, күпме-азмы нормаль яши дә башладык ич. Бик әйбәт, күптән көтә идек без моны. Әмма заманыбыз шул ук совет заманы — безне чорнап алган һавабыз ул... Рәхәтенә дә, михнәтенә дә күптән инде ияләшеп, күнегеп беткәнбез. Лениннан башланып, Сталин, Хрущевлар аша килеп җиткән тоталитар системада бер якка таба да, бернинди дә үзгәреш юк. Шул ук власть, шул ук партия, шул ук идеология... Җитәкчелек алышынган саен әчтән генә өметләнеп көткән сүз-фикер хөрлеге юк, бәйсезрәк эшләү мөмкинлеге дә юк... Ирексездән күңелгә еш кына шундый уй килә: тук-тыныч яши башлаган адәм баласына рухи азатлык кирәк түгелдер, ахрысы... Ул канәгать, ул башкача яшәүне белми, күрмәгән.

Шуңа күрәдер дә Брежнев вакытында коммунистлар партиясе сан ягыннан бик нык үсте — 20 миллионга

барып җитте булса кирәк. Бу инде коммунизм идеясенә ышануның, шуны кабул итүнең ачык бер галәмәте иде...

Әмма идеядән башка икенче бер бик көчле сәбәп тә бар иде: тагы да әйбәтрәк, иркенрәк яшәү өчен дә партия сафында булу бик кирәк иде. Яхшырак урынга, исемдәрәҗәгә һәм шулар аша мулрак тормышка, бары партиягә кереп кенә ирешергә мөмкин иде. Юньлерәк урынга бервакытта да фиркасезне куймыйлар, хәтта мунча директоры итеп тә. Власть органнарында, хуҗалыкта гына түгел, фәндә һәм сәнгатьтә дә күтәреләсең, максатыңа ирешәсең килсә — партия ишеген шакы. Мондый хәл электән үк яшәп килә иде, шуңа күрә безнең бөтен тарихчыларыбыз, әдәбиятчыларыбыз партиягә кереп беттеләр. Шулай ук язучыларның да иң зур күпчелеге коммунистлар иде. Хәтта кыюрак фикер йөртүче яшьләр дә партиягә керүне кирәк таптылар. Шундыйларның кайберләре мине шактый гаҗәпләндергән дә иде. Чөнки керүенең сәбәбе — «денем өчен түгел, көнем өчен» икәнлеге бик ачык иде. Бик күпләрнең партиягә бары шулай уйлап керүләре «үзгәртеп кору» елларында тулысынча расланды да.

Бу чорда иң түбәннән алып иң югарыга кадәр, дәүләт органнарыннан башлап иҗат оешмаларына чаклы җитәкчелек итү бары тик коммунист иптәшләргә генә тапшырылды. Дәүләтебез «Советский» дип аталса да, ул инде баш-аягы белән тулысынча партия кулына күчеп бетте. Моны бик хаклы рәвештә, чын мәгънәсендә, партия диктатурасы дип атарга була. Районнарда райкомнарның беренче секретарьлары хакимлек итә, республика, өлкәләрдә обкомнарның беренче секретарьлары баш хуҗа булып утыра. Аларны шулай «хуҗа» (хозяин) дип кенә йөртәләр дә иде. Бездә, мәсәлән, Фикрәт Табиев, Башкортстанда — Мидхәт Шакиров әнә шундый строгий хуҗалар иде... Үзләрен алар, гадәттә, «удельный князь» шикеллерәк итеп тоталар да иде. Бөтен җирдә, бөтен эштә алар хөкеме йөри — кешене урынга кую яки урыннан алу алар ихтыярында. Каршы сүз әйтү — хәтәр, кеше ахырын уйларга мәҗбүр. Алар бит партия идеологиясен һәм сәясәтен тәэмин итүчеләр буларак, каршы әйтүчегә теләсә нинди мөһер суга алалар.

Бу уңай белән бер-ике эпизодны искә төшерәсе килә. Елын хәзер ачык кына әйтә алмыйм, ләкин Татарстан язучыларының чираттагы съезды якынлашкан көннәрдә, без бер кечкенә төркем язучылар Фикрәт Табиев янында булдык. Күп кенә төрле мәсьәләләр хакында сөйләшкәндә, булачак съезд турында да сүз чыкты. Без инде

обкомның Мирсәй Әмирне Союз рәисе итеп сайлатачагын ишеткән идек. Тартай теленнән табар дигәндәй, мин шул чакта мондыйрак сүз әйттем. Без, язучылар, булачак съездны көтеп йөрибез, кемне председатель итеп сайлау турында да үзара уйлашабыз, әмма обком бу мәсьәләне алдан ук хәл итеп куйган икән инде; Мирсәй, әлбәттә, танылган зур язучы, төпле, акыллы кеше, бәлки, без аны үзебез үк сайлаган да булыр идек, ләкин нигә Сез аны алдан ук безгә тагасыз, һич югы, иҗат оешмасында демократия дигән нәрсә булырга тиештер бит инде... (Минем бу әйткәннәрне каршымда Мирсәй үзе дә тыңлап утырды.) Әлбәттә, минем сүзгә кушылучы берәү дә булмады, ә мөхтәрәм Табиев коры гына миңа болай диде: демократией надо руководить!

Сүз шуның белән бетте, тиздән съезд да булып узды. Мирсәй Әмирне бертавыштан сайлап та куйдык, әмма ләкин Табиев алдында демократияне яклап маташуым соңыннан шулай да минем тез астына китереп сукты... Ничек итеп? Хәзер инде ул хакта сөйләп торасым килми... Үткән эшкә салават!

Икенче эпизодны миңа мәрхүм Сибгат Хәким сөйләгән иде. Бу Хәсән Туфанга кагыла. Хәсән абыйның 16 ел төрмәләрдә утырып, сөргеннәрдә йөреп кайтканнан соң, күпмедер вакытлар үткәч булган эш... Әйтергә кирәк, берара аның хәле тагын мөшкелләнә башлаган иде. Шигырьләрендә крамола таба башладылар. (Афзал абзый заманында безнең Союзда Хәсән абыйның иҗат отчетын тыңлаган булып, аның күп кенә яңа шигырьләрен «төрмә лирикасы» дип тә атаганнар иде.) Менә шул чакларда Сибгат Хәкимне ашыгыч рәвештә эзләп табып, кара «Волга»да Табиев хозурына китерәләр. «Хуҗа» аны аягүрә, караңгы чырай белән каршы ала һәм туп-туры әйтә: «Мин сезнең ул Туфаныгызны кире кайткан якларына куам, йөрмәсен монда заразы таратып!»

Сибгат, гадәтенчә, ашыкмыйча, сабыр гына әйтә:

— Гафу итегез, Туфан андый кеше түгел... Ул шагыйрь, ул шигырь тарата.

— Вот именно, шигырьләрендә аның довольно зарарлы, политический хата карашлары күренә дә! Так что куарга да хакыбыз бар.

— Бардыр, мөгаен,— ди Сибгат, сабырлыгын җуймыйча гына,— ләкин белегез, Хәсән Туфанның әдәбиятта тоткан урыны да, халык арасында даны да бик зур... Сөргеннән кайтуын бөтен әдәбият сөючеләр чын-чыннан куанып каршы алдылар. Әгәр Сез аны яңадан сөрсәгез, халык моны аңламаячак та һәм гафу да итмәячәк...

...Сибгат Хәкимнең миңа урам буйлап сөйләп кайтканы менә шуннан гыйбарәт — эчтәлеге өчен тулысынча җавап бирәм. Нәтиҗәсе безгә мәгълүм. Хәсән Туфанны беркем беркая кумады, ул яшел карасы белән шигъри җәүһәрләрен язып һәм ак чәчәкләр үстереп безнең арада яши бирде... Әмма иң көтелмәгән гаҗәбе шунда иде ки, шагыйрь күп тә үтми Фикрәт Табиевның иң хөрмәт иткән кешесенә әверелде. Һәм төрле тантаналы җыелышларда обкомның беренче секретаре Хәсән абзыйны аркасыннан сөеп, янына гына утырта торган булды... Мондый көтелмәгән үзгәреш өчен алар арасында, ихтимал, икәүдән-икәү генә бик ачык сөйләшү булгандыр, ул кадәресен мин белмим. Тик шуны гына әйтә алам, соңыннан Хәсән абзыйдан обкомда утыручы җитәкчеләрнең бик акыллы егетләр булуы турында сокланып әйткәннәрен ишеткәләргә туры килде. Әлбәттә, җүләр түгелләр инде... Безнең Табиев, миңа калса, обком секретарьлары арасында иң көчле, иң ышанычлылардан иде шикелле... Кешегә башта каты бәрелә торган гадәте булса да, соңыннан шактый ук йомшара да белә иде. Минем үземә дә моны татырга туры килде. Язучыларның бер җыелышында мин үземнең чыгышым белән президиумда утыручы беренче секретарьның бик каты ачуын китердем. (Мондый хәлләр минем белән еш кына булгалый иде.) Иптәш Табиев шунда ук минем «баш өстендә кылыч уйната башлады». Каты әйтте, хәтәр әйтте. Бу хәл башкаларны да хәвефләндерде булса кирәк, җыелыш беткәч, Нәкый абзый, Гомәр абзыйлар сәхнәдә чакта ук Табиевка: «Сез Әмирханны ялгышрак аңладыгыз, ул бит алай дип әйтергә теләмәгән иде. Сезгә яңадан аңлашырга кирәк»,— диделәр. Табиев икеләнебрәк, теләсә, мин каршы түгел, тик башта миңа шалтыратсын, диде. Бу вакытта мин дә сәхнәдә бер читтәрәк басып тора идем, ләкин ул үзенең сүзләрен миңа түгел, әлеге өлкән агайларга әйтте.

Шушы хәлдән соң мин шактый вакыт икеләнеп йөрдем: барыргамы, аңлашыргамы, әллә кул гына селтәргәме? Әйтергә кирәк, минем моңарчы «беренчеләр» хозурына бер генә тапкыр да кергәнем булмады. Йомышым да төшмәде, аннары кабул итүләренә ышанычым да юк иде. Мәгәр бу юлы «беренче» үзе инде икеләнебрәк булса да кабул итәргә ризалыгын белдергәч, әллә, мин әйтәм, форсаттан файдаланыргамы?.. Дөрес, мөхтәрәм Фикрәт Әхмәтҗановичның мине өнәмәгәнен күптән тоеп йөрим, бу очрашып-аңлашудан да күпне өмет итмим. Җитәкчеләрнең карашын үзгәртүе бик читен, гадәттә алар синең үзгәрүеңне көтәләр.

Шулай икеләнеп йөри торгач, мин ахырда бер урам автоматыннан тоттым да Табиевның приемныена шалтыраттым — бәлки әле, кабул да итмәс дигәнрәк уй белән. Трубкада «тыңлыйм!» дигән ир тавышы... Мин кем икәнемне, иптәш Табиевның үзе кушуы буенча шалтыратуымны әйттем. «Аз гына сабыр итегез»,— диде тавыш һәм аз гына көттереп: «Килегез, кабул итәр!» дип өстәде...

...Ничектер бик ансат кына булды бу. Шалтыратуым да обком каршысындагы Ирек мәйданыннан иде — 5—10 минут та үтмәгәндер, түбәннән пропуск алып, беренче мәртәбә беренче секретарьның кабинетына күтәрелдем.

Мин барып кергәндә, алгы бүлмәдә 5—6 кеше «хуҗаның» кабул итүен көтеп утыралар иде. Озак көтәргә туры килер, ахрысы, дип, эчемнән генә уйлап куйдым. Шул арада кабинеттан шактый тирләгән, кызарган берәү чыкты. Ишектән читтәрәк торган өстәл артында утыручы пөхтә киенгән яшь егет кабинетка кереп китте һәм шунда ук кире чыгып, миңа керергә кушты. Көтеп утыручыларны бу шактый гаҗәпләндерде бугай, карашларыннан шулайрак сизелде, ләкин һичберсе, хәтта кыймылдамыйча да, үз урынында утырып калды. (Ә алар арасында миңа таныш министр да бар иде.)

Фикрәт Әхмәтҗанович мине зур кабинетның түрендә утырган килеш кенә каршы алды. Кулы белән генә миңа утырырга ишарә ясады. Мин баш иеп исәнләштем һәм сәкедәй өстәл янындагы ул күрсәткән урынга утырдым... Хәл-әхвәл сорашып тору булмады. «Хуҗа» сүзен бернинди керешсез туп-туры миңа шелтә белдерүдән башлады:

«...Сез интеллигентикларның эчендә бер яман корт ята. Шул Сезне кимерә, шул Сезгә тынычлык бирми — тотасыз да урынлы-урынсыз, белер-белмәс, телегезгә ни килсә, шуны сөйли башлыйсыз...»

Бусы инде минем әлеге язучылар җыелышында ясаган чыгышым турында, димәк, сүз күбрәк шул хакта барачак. Аңлашуы, әлбәттә, җиңел булмаячак... Хәтта беркадәр хәвефле булуы да бик мөмкин, чөнки партия җитәкчеләре «милли темага» сөйләүчеләрне бер дә яратмыйлар. Әйткән сүзеңне алар онытмыйлар, исләрендә тоталар, ә кирәксә, тиешле нәтиҗәне дә ясыйлар. (Синең зарарыңа.) Шуңа күрә мин инде Табиевның беренче сүзләреннән үк сагаерга, бик нык уйланырга мәҗбүр идем. Аннары тагын бер психологик момент уемны гел биләп тора: республиканың беренче җитәкчесе минем үземә караганда да күбрәк бәлә кебек иде.

Сөйләшү дәвамында Табиевның ниләр әйткәнен, үземнең ниләр сөйләгәнемне менә хәзер сүзгә-сүз китерү мөмкин түгел, әлбәттә... Җитмәсә, ул күбрәк урысча, мин татарча сөйләдем. Җыеп кына әйткәндә, Табиевның бөтен сөйләгәне, Татарстанның һәм татар халкының бүгенге хәле бик әйбәт булуын, өметсезлеккә бирелергә һичбер төрле сәбәп юклыгын кабатлаудан гыйбарәт иде: экономикада уңышлар зур, халыкның тормышы яхшыра, культура үсә, милли кадрлар елдан-ел арта — әнә күпме завод-фабрикаларның директорлары, вузларның ректорлары шәп татар егетләре... (Табиев моны үзенең милләт файдасына эшләнгән бер зур эше икәнен миңа гүя сер итеп кенә әйтте...) Кыскасы, эшләргә кирәк, укырга кирәк, татардан галимнәр, укымышлы белгечләр җитештерергә кирәк — ә моңа бары урыс мәктәпләре, урыс вузлары аша гына ирешергә мөмкин.

Хуш, инде мин нәрсә әйтергә тиеш идем... Аның әйткәннәрендә дөреслек, әлбәттә, бар, ул үзенчә бик хаклы, бәхәскә керешү урынсыз, килешергә генә кирәк. Әмма ләкин мин дә бит нидер әйтергә — үземнекен әйтергә тиеш идем!

Билгеле, миңа теге җыелышта аның ачуын китергән чыгышымны акларга яки, һич булмаса, аңлатырга кирәк иде. Сүзен ул шуңардан башлады — яман корт Сезнең эчегезне кимерә, диде... Әйе, дөрес, кимерә!.. Мин, татар язучысы, туган телем турында борчылмыйча тора алмыйм. Мин генә түгел, күпләр телебез язмышы турында борчылып уйлана. Ә борчылырга сәбәпләр җитәрлек: шәһәрләрдә татар мәктәпләре ябыла, балаларыбыз урыс мәктәпләренә күчә, димәк, яңа буын укучыларыбыз бик нык кимиячәк... без инде моны хәзер үк тоя да башладык — китапларыбызның тиражлары әкренләп кими бара. Шуның өстенә хәвефле бер караш соңгы вакытларда үзен ачык сиздерә башлады: янәсе, татар теленең киләчәге юк, иртәме-соңмы ул йотылырга тиеш...[1]

Күрәсез, бу очракта инде сүз әдәбиятның гына түгел, гомумән, милли культураның киләчәге турында бара. Чөнки халыкның үз теленнән башка милли культурасы була алмый... Мәгәр мин партия карарларында «милли культуралар бетәргә тиеш» дигән тезисны күргәнем юк. Киресенчә, милли культураларның үсүе, «чәчәк атуы» турында гел әйтелә. Әгәр читкә чыгып, мәсәлән, үзбәк-

[1] Күпмедер вакыт элек бу карашны «нигезләп» вә хуплап Бадамшин һәм Г.Рябки кебек журналистлар «Татарстан» битләрендә озын-озын мәкаләләр дә бастырганнар иде.

ләргә яки казахларга барып карасак, моның чыннан да шулай икәненә ышанасың: милли мәдәниятләрен үстерү өчен алар көчләрен дә, акчаларын да җәлләмиләр... Хәер (дидем мин бу урында сүзем бер яклы гына булмасын өчен), безнең өлкә комитеты, Сез үзегез дә, Фикрәт Әхмәтҗанович, культура мәсьәләләренә һәрвакытта игътибар итеп килдегез... Әмма безнең халыкта бер акыллы мәкаль бар: түбәнгә карап шөкер ит, югарыга карап фикер ит!..

Һәм шушы урында Фикрәт Әхмәтҗанович минем сүземне бүлде:

— Кабатлагыз әле шуны яңадан! — диде.

Мин гаҗәпләнебрәк булса да мәкальне яңадан кабатладым, ә ул аны шунда ук аерым кәгазьгә язып та куйды. Мәкаль аңа ошады. Ни өчен?.. Беренче тапкыр ишеткәнгә күрә генә түгелдер инде... Киләчәктә бу мәкаль, бәлки, кирәк булыр дип уйлагандыр.

...Безнең сөйләшү бер 40 минут дәвам иткәндер. Сүз, билгеле, һаман шул бер нәрсә — мине борчыган, ә аңа исә ошап бетмәгән — миллият тирәсендә әйләнде. Барысын да хәтерләү мөмкин дә түгел, хаҗәте дә юк, әмма бик мөһим бер нәрсәне әйтү мотлак кирәктер. Сөйләшү дәвамында мөхтәрәм Фикрәт Әхмәтҗановичның миңа мөнәсәбәте шактый ук йомшарды. Каты сүзләр дә кулланмас булды, кырыс торуы да бетте диярлек. Хәтта кеше буларак ачыла да төште. Баксаң, обком секретаре да милли тойгыдан мәхрүм түгел икән... Сүз ахырында ул миңа карт әнисенең иртәнге татар концертларын бик яратып тыңлавын сөйләде. Үзе дә эшкә ашыкмаса, колак сала икән, якын икән аңа татар халык моңнары... Аннары ул миңа Фатих Әмирханны бик мактады, чын классик, диде. Хәзер шуның әсәрләрен мавыгып укый икән... Нинди телдә — анысын мин сорамадым, ул әйтмәде.

Сөйләшү дәвамында, эшле кешенең вакытын күп алмыйммы дип, һаман борчылыбрак утырган идем... Һәм ул сүздән туктагач та мин файдалы әңгәмә өчен рәхмәтемне әйтеп, урынымнан кузгалдым. Ул да урыныннан торды. Кергән чакта без күрешмәгән идек, чыкканда инде кул да бирештек.

Янә бер соңгы деталь. Кабинеттан чыгуыма әлеге таныш министр мине эләктереп алды да читкәрәк сөйрәп, пышылдап кына сорады:

— Әйт әле, Әмирхан, иптәш Табиев минем хакта сиңа берәр сүз әйтмәдеме?

Мин моңа шулкадәр гаҗәпләндем ки, хәтта көлеп җи-

бәрәсем килде. Ай-һай, министрларның да «хуҗа»дан котлары очып торыр икән!.. Белми идем, валлаһи!.. Бичараны тынычландырыр өчен аркасыннан йомшак кына кактым. Без бит бик күптәнге танышлар. Кайчандыр... Табиев та әле яңа гына туган заманнарда, без ике яшь кенә егет Меховойда гади эшчеләр булып эшли башлаган идек. Менә ул — исемен дә әйтим, булмаса — Бәдретдин дус, үсә-үсә, әнә министр дәрәҗәсенә менеп җиткән... Мин инде бары тик язучы гына булып калдым, ә шулай да «хуҗа» алардан элек мине кабул итте... Бәдретдиннең миннән үз итеп, борчылып соравына гаҗәпләнергә дә кирәк булмагандыр.

Мин шактый читкә тайпылдым. Сүз бит «Брежнев чоры» турында барырга тиеш иде. Хәер, бу тайпылу да шул ук чорга керә, һәм, бәлки, әле тагын да тайпылырга туры килер...

Ә чорның үзенә килгәндә, нәрсә әйтергә мөмкин?.. Ул бик ачык чор иде — үтеп киткәннәреннән аермасы юк диярлек: шул ук система, шул ук идеология, шул ук партия диктатурасы... һәм аның кимчелекләре дә сукыр булмаганнарга бик ачык иде.

Дөрес, җитәкчелек алышынган саен сәясәттә ниндидер үзгәрешләр булмыйча калмый. Яңа юлбашчы үзен ничек тә яңа яктан күрсәтергә тиеш... Шул чакта гына ул хакимлек иткән елларны аның чоры дип атарга була... Хуш, шактый озакка сузылган «Брежнев чоры» безгә ниләр китерде?.. Иң әһәмиятлеләрен генә санаганда, алар, минемчә, түбәндәгеләрдән гыйбарәт: Хрущев кебек төрле экспериментлар белән мавыкмыйча, илнең эчке хәлен тыныч-тотрыклы итү; халыкның көнкүрешен кулдан килгән кадәр җиңеләйтү; болардан да мөһимрәге — Совет дәүләтенең көч-куәтен даими рәвештә үстерә, ныгыта бару; һәм шулар аша Советлар Союзын дөньяның иң алдынгы, иң куәтле, иң дәһшәтле дә иле итеп таныту... Безнең дипломатия чат саен «Мир» диде, ә хөкүмәтебез мыштым гына көне-төне корал чүкеде. Бөтен экономика, идеология, өндәү-оештыру эшләре, эчке һәм тышкы сәясәт — һәммәсе дә әнә шул максатларга ирешүгә юнәлдерелгән иде. Әйтергә кирәк, бу чорда Советлар Союзының авторитеты бик үсте, дөнья аңа бер үк вакытта ничектер хәйран калып та, шомланып та карый торган булды.

Билгеле инде, бу уңышлар барысы да гадәттәгечә иң элек юлбашчы исеме белән бәйләп йөртелә. Күкләргә чөя-чөя мактау бары аңа гына ява... Леонид Ильич үзе дә дан-шөһрәт бишегендә оеп тирбәлергә бик һәвәс ке-

ше булып чыкты. Ә бездә мактау һәм мактануның чамасын белмиләр... Тәмам онытылып китеп, «Брежнев чоры»н җитлеккән (зрелый) социализм дип тә атадылар, ә аның үзен дүртме-бишме тапкыр Социалистик Хезмәт Герое иттеләр. Өстәвенә маршал да булды, лауреат та булды, такмаган орден-медальләр дә калмады — бу җәһәттән ул үзенә хәтле килеп киткән юлбашчыларның һәммәсен дә уздырып җибәрде... Ишеткән идем, чын булса, Үзбәкстаннан Шәрәф Рәшидов аның туган көненә саф алтыннан койган бюстын китергән дип... Булыр, Шәрәфкә дә бит Брежневның җылы, юмарт кулы кирәк.

Кыскасы, ЦКның Генераль секретарен, Югары Совет президиумы председателен мактау, зурлау, ярату хәттин ашты... Әмма ләкин шуңа да карамастан бу куе кашлы, калын тавышлы мәһабәт кеше безнең хәтерләрдә шәхес булудан бигрәк элеп куйган портрет булып кына саклана.

* * *

Бер генә заманда да властька, аның җитәкчеләренә һәм тоткан юлына кешеләрнең мөнәсәбәте бертөсле генә булмаган. Берәүләр хуплаган, яклаган, тел дә тидермәгән; икенчеләре исә килешмәгән, тәнкыйть иткән, ризасызлыгын белдергән... Советлар заманында да шулай иде. Тик репрессияләр вакытында кеше үзенең килешмәвен, ризасызлыгын бик тирән яшерергә мәҗбүр иде. Репрессияләр туктатылгач, кешеләр трибунага менеп властьны сүкмәсәләр дә, тәнкыйть сүзләрен чамалап кына әйткәли башладылар. Ә үзара инде, як-якка каранмыйча гына, ачыктан-ачык сөйләшә дә торган булдылар.

«Брежнев чоры»н да чагыштырмача әнә шундый йомшаграк, иркенрәк бер заман иде дип атарга була. Идеология басымы кочәйсә дә, режимны каты тәнкыйть итүчеләрне «психушка»ларга озату, читкә сөрүләр булгалап торса да, лояльность саклап, чама белән тәнкыйть сүзе әйтүнең баш китәрлек куркынычы юк иде. Ләкин шулай да шактый тәвәккәллек сорый торган мондый хөрлекне бәйсез фикер йөртүче кешеләр генә үзләренә рөхсәт итә алалар иде. Әнә шундыйлар язучылар арасында да бар иде. Алар бер-берсен беләләр, бер-берсенә ышаналар һәм үзара ачык сөйләшәләр иде. Шундыйларның берсе буларак мин дә бик макталган Брежнев чоры турында шуны әйтә алам: «Җитлеккән социализм» дигән уйдырмага без, әлбәттә, ышанмый идек... Җитлеккән белән җитлекмәгән социализм арасында нинди аерма?.. Яшәү

шартлары әзрәк җиңеләйгән икән — вакыттыр инде, сугыш беткәнгә дә 20—25 ел гомер узып китте... Нәрсә монда «җитлеккән»?! Калганы һәммәсе дә искечә, тормыш һаман да иске эзеннән тәгәри... Һаман да әле күп нәрсәгә кытлык, дефицит, озын-озын чиратлар... Совет сәүдәсе күптән инде мафиоз бер структурага әверелде. Аның беренче кайгысы иң элек үзен һәм түрәләрне тәэмин итү, ә шуннан калганы әнә урамда көтеп торучыларга. Бу гадәти күренеш, берәүнең дә аңа исе китми... Халык азга да канәгатьләнеп өйрәнгән, күпне таләп итми, рухи ихтыяҗы да түбән, күбрәк эчү белән юана... Эчү бер эпидемиягә әйләнде дияргә дә ярый — өйдә яки подъездда гына түгел, эш урынында, станоклар янында да эчә башладылар... Шулай ук урлашу да массакүләм төс алды диярлек. Заводта яки колхозда эшләүчеләрнең көн дә ни дә булса кыстырып кайтуы гадәти күренеш. Аларны карак дип тә атамыйлар, иркә сүз белән «несун» дип кенә йөртәләр. Хәлбуки кайбер «несун»нар әкренләп ташый торгач, йорт та салып керәләр, машина да алып җибәрәләр... «Җитлеккән» сүзе, бәлки, шуларга туры киләдер, әмма ни өчен социализмны ул хәтле түбәнәйтергә?! Хәер, «несуннар»дан башка партия һәм хакимият башында утыручы, ил байлыгына хуҗа номенклатура бар бит әле. Менә аларга инде «җитлеккән социализм» үлчәп теккәндәй туры да килә торгандыр...

Болары әйләнәдәге чынбарлыкның, әдәбиятчылар теле белән әйткәндә, типик бер ягы гына. Мәгәр «җитлеккән социализм» дигән төшенчәнең фәлсәфи һәм сәяси ягы да булырга тиештер, мөгаен... Шунысы да безнең өчен бик әһәмиятле... Моңарчы да без үзебезне күпме тир, күпме кан коеп төзелгән социализмда яшибез дип фараз кыла идек... Инде менә аның тагы да шәбрәгенә күчкәнбез икән... Йә, нәрсә китерде ул безгә, нәрсәсе белән куандырды?.. Әйтик, демократиягә таба борылуда, фикри хөрлеккә мәйдан бирүдә, кеше хокукларын яклауда?.. Юк ич, юк!.. Электән үк сызылган хокукый чикләр, сәяси кысалар бер үзгәрешсез саклана — без инде аңа, начар һавагаияләшкәндәй, күптән җайлашканбыз... Дөньяны үзебезчәрәк күреп, вакыйгаларга да үзебезчә бәя биреп, рәсми карашлардан башкачарак фикер йөртеп яши бирәбез. Мин моны эчке хөрлек дияр идем. Бик кирәкле нәрсә, аеруча — язучыларга... «Язучы булыр өчен таланттан башка эчке хөрлек тә (внутренняя свобода) кирәк» дигән әдәби иҗатның нәрсә икәнен бик шәп белүче Чехов... Ә андый язучылар безнең арада бар иде. Мәгәр «эчке хөрлек»тән бөтенләй мәх-

румнәр дә аз түгел иде. Бер җыелышта мин Чеховның әлеге сүзләрен әйтергә җөрьәт иткәннән соң, бер популяр язучыбыз «Еникигә тагын нинди хөрлек кирәк икән» дип, гәзитәдә язып та чыкты. Янәсе, язучыларга «хөрлек» болай да бик җиткән.

Мәгълүм ки, большевикларның сәясәте һәрвакытта икейөзле булып килде. Телдә бертөсле, гамәлдә исә шуның киресе... Ленин заманыннан ук килә ул. Мәсәлән, тышкы сәясәттә... Дәүләтара сугышларны кире каккан булып, гражданнар сугышына өндәү — шул юл белән хакимияткә ирешү... Яки чат саен «Мир!» дип кычкырган хәлдә, илләрне-халыкларны бер-бер артлы кулга төшерү, аларда безнең Совет системасын (дөресрәге, бер генә партия диктатурасын) урнаштыру... Бу сәясәт дөнья сугышыннан соң аеруча көчәйде... Күрше-тирә илләр белән генә чикләнмичә, безнекеләрнең шәрә озын куллары ерак кыйтгаларга хәтле барып җитте. Күпме көч, күпме корал, күпме акча халыктан яшерә-яшерә исраф ителде. Хәер, без капчыкта ятмый — барысы да ачылды, барысы да мәгълүм булды... Тик җыеп кына шуны әйтәсем килә: безнекеләрнең кулы җиткән җирләрдә тынычлык бетте, елларга сузылган канлы бәрелешләр башланды. Дөнья икегә аерылды. «Кайнар сугыш» артыннан ук «салкын сугыш» башланды. Бусы гүя корбансыз булса да, дистә еллар буена илнең бөтен куәтен, бөтен байлыгын суырып торды. «Салкын сугыш»ның кайнар сугышка әйләнеп китү куркынычы туды. Дөньяның астын өскә китерерлек кораллар кәшеф ителде. (Уйлап чыгарылды.)

Шул рәвешчә «салкын сугыш» барышында көне-төне ярыша торгач, бер-берсенә дошман ике система, ике лагерь кешелек дөньясын чын сугыш һәлакәте алдына китереп бастырды... Тик сәгате генә сукмыйча тора. Дипломатия эшли, сатулашулар дәвам итә, бер-берсен алдарга тырышулар бара... Безнекеләр бик актив, каршы якны ачыктан-ачык та, астыртын да һаман какшатырга, кысрыкларга тырыша... Бу дөньякүләм зур ярыш, зур «уен»!.. Бу уенда отар өчен бөтен чаралар да ярый — иң мәкерлесе дә, иң канлысы да...

Әнә шулай «уйный» торгач, без хурлыклы әфган сугышына да кереп баттык... Шуның аркасында «явызлык империясе» дигән исемгә дә лаек булдык. Хәлбуки мәңге какшамастай булып тоелган системаны җимерү өчен андый зур сугышның кирәге дә булмаган икән. Тик без мондый «кызыклы тамашаны» соңрак күреп шаккаттык!..

* * *

Большевикларга хас икейөзле сәясәтнең янә бер мисалы. Бусы милли мәсьәләгә кагыла... Бер караганда милли мөнәсәбәтләр ал да гөл кебек иде... Халыклар арасында татулык хөкем сөрә — күп аралаштык, йөрештек, «чәчәк атуыбыз» белән мактаныштык... Үзара сугышу ихтималы башка килү түгел, төшкә дә керми иде, мең шөкер!..

«Халыклар дуслыгы» турында йөзләгән, меңләгән фәнни хезмәтләр язылып, күпме кешеләр кандидатлар, докторлар булып беттеләр, шуңа күрә бу хакта артык җәелеп торуның хаҗәте юктыр дип беләм. Алайса милли сәясәтнең икейөзле булуы нәрсәдә күренә соң? Моны аңлар өчен татар халкының Совет чорындагы язмышына күз салу да җитсә кирәк.

Иң башта без большевикларның җиңүе өчен күпме кан койганнан соң, алар кулыннан җирле автономия алдык. Татарстан дигән үз җөмһүриятебез булды, аңа күпмедер хокуклар да бирелде. Без моны милли изелүдән чыгу, милләт буларак яшәү, тәрәккый итү дип кабул иттек, һәм, билгеле, моңа бик сөендек... Баштарак ул шулай тоелган да иде. Дөрес, бу автономия эченә татар халкының бары 25 проценты гына эләкте, 75 проценты исә автономиядән читтә торып калды. Әллә кайда еракта да түгел, янәшә күршебездә генә, мәсәлән, Ык аша Башкортстанда гына миллионнан артык татарлар торып калдылар... Моны аңлавы да читен иде. Ни өчен башкорт халкы үз республикасында азчылык тәшкил итә, нигә аның да күпмедер өлеше Ырынбур, Чиләбе өлкәләрендә бүленеп кала?.. Хәер, башка республикаларны төзегәндә дә моның ише киләчәктә халыклар арасын боза торган мәкерле «хаталарның» юри эшләнгәнен без менә хәзер генә белдек.

Бөтен бер милләт булып саналган халыкның бүлгәләнүе, элек-электән үк килгән җанлы бәйләнешләрнең өзгәләнүе, әлбәттә, милләт файдасына түгел иде. Күпчелек халкы белән бергә аның күпмедер көче-куәте дә читтә торып калды. Бу җәһәттән Татарстан кебек йолкынмыш вә алданмыш бүтән автономия Россия Федерациясендә юк та шикелле...

Советлар Союзы төзелгәч, Россия эчендә торып калган автономияләрнең хокуклары тагын да кечерәйде. Тулысынча Мәскәүгә буйсынып яши башладык. Икътисади хәлебез, мәгърифәтебез һәм мәдәниятебез Мәскәү күрсәткән юнәлештә, аның даими күзәтүе астында гына бара торган булды. Сугыштан соң озак та үтми, без инде

автономиябез эчендә дә шактый кызу урыска йотыла баруыбызны сиздек. Моның башы — шәһәрләрдә татар мәктәпләренең ябылып бетүендә иде... Мәгърифәт бетсә, милләт үзе дә иртәме-соңмы, Тукай әйткәнчә, бетәргә мәхкүм иде.

Мондый хәлнең безне, ана телендә язучыларны, никадәр борчыганын күрсәтер өчен, мин тагын артка чигенеп, бер мөһим вакыйганы искә төшерергә тиешмен.

* * *

Вакыйга менә нидән гыйбарәт: 1964 елның октябрендә обкомның беренче секретаре Фикрәт Әхмәтҗанович Табиев унике язучыны үз хозурына чакырып алды. Шуларның дүртесе фиркасезләр: Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Фатих Хөсни һәм мин. Күпчелек исә коммунистлар: Гомәр Бәшир, Мирсәй Әмир, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Гази Кашшаф һәм Ләбибә Ихсанова... Калган икесе онытылган, сорашып та белә алмадым... Әмма бер нәрсәне ачык әйтә алам: күп кенә зур коммунист язучылар, мәсәлән, Ибраһим Гази, Афзал Шамов, Гариф Гобәй кебекләр чакырылганнар арасында юк иде. Шулай ук сугыштан соң әдәбиятка килеп, инде танылып өлгергәннәрдән дә берәү дә чакырылмаган иде... (Бары Ләбибә Ихсанова гына, чөнки ул Язучылар союзының партоешма секретаре иде шул чакта.)

Инде чакырылганнарга килсәк, аларның барысы да диярлек үзләренчә фикер йөртүчеләр һәм җай чыкканда үз сүзләрен әйтә алучылар иде... Фикрәт Әхмәтҗановичка шундыйлар кирәк тә булгандыр, күрәсең, чөнки ул безне баштан ук ачыктан-ачык сөйләшергә чакырды: нинди проблемалар сезне борчый, нәрсә җитми, нәрсә кирәк — давайте, откровенно сөйләшик! — диде.

Без кайда, кем алдында утыруыбызны, әлбәттә, яхшы белә идек, шулай да аның чын ихластан чакыруын кабул иттек... Сталиннан соң 11 елдан артык вакыт үтеп киткән иде инде, Хрущев заманында күпме-азмы хөрлеккә дә өйрәндек... Шуңа күрә һәркем үз сүзен үзе кирәк тапкан кадәр, йә сакланыбрак, йә турырак әйтергә дә тырышты.

Безне тыңлаучылар өчәү иде. Каршыбызда, киң язу өстәле артында, таза, мәһабәт Табиев җәелә биреп утыра, аңардан сулда, аз гына читтәрәк, гүя дистанция саклап, Батыев белән Абдыразаков утырганнар... Әңгәмә дилбегәсе, билгеле, Табиев кулында, ул алып бара, тегеләре ара-тирә генә сүз кыстыргалыйлар.

Без киң өстәлгә терәп куйган озын өстәл әйләнәсенә шәкертләрдәй тезелешеп утырганбыз. Дәрәҗәбезгә һәм яшебезгә карап кына сүзгә керешәбез. Сөйләшү ике телдә бара — без саф татарча, Табиев татарча башласа да, бик тиз русчага күчә... Әйтергә кирәк, сөйләшү әдәпле, тыйнак кына башланса да, бик тиз кызу бәхәскә әйләнде. Яшь, кайнар секретарь безне тыңлау белән генә чикләнә алмыйча, еш кына безгә каршы төшәргә, тизрәк үзенекен әйтергә мәҗбүр иде. (Русчага күчүе дә шуңардан.) Мәгәр без дә инде, авызлыкны бер тешләп алгач, әйтергә теләгәнебезне әйтмичә калмый идек... Шуңа күрә дә бу гаҗәеп сөйләшү , сәгать 4 тә башланып төнге 11 гә кадәр, җиде сәгать дәвам итте. Ике тапкыр чәй дә эчтек, тәмәке дә күп тартылды.

Сүз-бәхәс нәрсәләр турында барды соң? Алдан билгеләп куйган мәсьәләләр юк иде, алар сүз барышында үзеннән-үзе туды. Безне уйландырган, борчыган күп мәсьәләләр кузгатылды, хәтта бик хәтәр Гаяз Исхакый мәсьәләсен дә телгә алдык. Аны Нәкый абзый кузгатты (Гаяздан башка әдәбият тарихыбыз тулы түгел, ул кешенең яхшы эшләрен начар эшләреннән аерып карарга вакыттыр инде, без бит марксистлар дигәнрәк мәгънәдә әйткән иде ул.) Ләкин Табиев Исхакый турында сөйләшүне катгый рәвештә кире какты... Кузгатылган мәсьәләләрнең һәммәсен дә санап чыгуның хаҗәте юктыр дип уйлыйм, чөнки аларның күбесе — әйтик, мәктәпләр хәле, телебез язмышы, әдәбиятыбызның киләчәге турында безнең арада күп сөйләнгән һәм җитәкчеләргә дә билгеле булган нәрсәләр иде... Әмма бер мәсьәлә турында махсус тукталмыйча булмый. Хикмәт шунда ки, ул мәсьәлә безнең тарафтан җитәкчеләр алдына беренче мәртәбә бик җитди рәвештә куелды... Һәм сүз дә, вакыт та күбрәк шуңа китте. Бу — Татарстанның статусын үзгәртү, ягъни аны союздаш республика итү мәсьәләсе иде. Мондый үтә җитди мәсьәләне кыюланып күтәрү өчен сылтавы да бар иде. Билгеле булганча, Советлар Союзының яңа Конституциясе төзелергә тиеш иде. Хрущев җитәкчелегендә зур бер комиссия эшкә дә керешкән... (Соңыннан аның председателе Брежнев булды.) Казанга Татарстандагы хәлләрне тикшерү өчен Үзәктән авторитетлы комиссия килүен дә ишеткән идек... Кыскасы, статус мәсьәләсен күтәрү өчен хәзер иң уңай вакыт иде. Ә республиканың союздаш булырга тулы хакы һәм бөтен шартлары бар иде, безнеңчә!

Әмма иптәш Табиев мәсьәләнең куелышы белән дә, без китергән дәлилләр белән дә баштарак һич тә киле-

шергә теләмәде. Ул безгә һаман Татарстанның хәле болай да бик шәп булуын, экономикасы һәм культурасы белән күп кенә союздаш республикалардан өстен торуын кат-кат исбат итәргә тырышты. Бәхәс бик кызды. Аның кайбер сүзләреннән хәтта кычкырып көлүдән дә тыела алмадык. Аеруча мәрхүм Шәйхи Маннур аңа каршы каты торды. Безне бала-чагага санийсызмы әллә, мөхтәрәм Фикрәт Әхмәтҗанович,— диде ул аңа,— сүз бит байлык турында түгел, хокуклар турында бара! Кемнең хокуклары күбрәк — кыргызныкымы, татарныкымы?!

Бу бәхәстә чакырылган язучыларның күпчелеге бер караштa, бер позициядә торуларын иптәш Табиев, ниһаять, аңлады булса кирәк, ахырда ул шактый йомшара төшеп, әйтергә мәҗбүр булды:

— Давайте, не будем торопить событий... Подождем выводы комиссии... И все!..— Һәм, сүз беткәнен белдереп, калын кулы белән өстәлгә сугып куйды.

Чыннан да, барыбыз да бик арыган идек. Җитәкчеләргә рәхмәтебезне әйтеп, хушлашып төн уртасында таралыштык. Дөрес, бу озын сөйләшү дәвамында бер генә мәсьәлә буенча да ачык килешүгә ирешмәсәк тә, без иптәш Табиевка, хәзергечә әйтсәк, бик рәхмәтле идек. Безне чакыруы өчен, түзеп тыңлавы өчен!..

* * *

Бу кызыклы очрашуда без әйтәсе килгәнне әйттек, әмма ләкин аңардан нинди дә булса зур нәтиҗәләр көтми идек. Зур нәтиҗәләрне Казаннан түгел, Мәскәүдән генә көтәргә була — безгә бу күптән билгеле иде инде. Тик шулай да бер өмет чаткысы күңелдә яши иде әле: шактый вакыт Казанда эшләгән Мәскәү комиссиясе ни әйтер икән, Татарстанны Союзный итәргә дә ярый димәс микән?.. Әлбәттә, бу сабыйларча ышану иде, ләкин безнең күк капусы ачылуга да ышанган чакларыбыз бар иде бит... Сабыйлык адәм баласына хас нәрсә ул!..

Атналар үтә, айлар үтә, мәгәр комиссия эше турында беркаян, бер кәлимә сүз дә ишеткәнебез юк. Гәзитләрдә дә берниндн информация күренмәде. Бәлки, комиссия күптән кайтып та киткәндер инде, аның отчетын да, мөгаен, Үзәктә генә тыңлаганнардыр да... Без бит гел шулай юрап яшәргә өйрәнгәнбез...

...Шуннан соң нишләргә?.. Кул гына селтәргә?! Кысыр хыяллар күп булды, җитәр, ахрысы... Юк, чигенергә иртә әле, иртә!.. Шулай уйлап мин һичкем белән сөйләшмичә-киңәшмичә генә тоттым да иптәш Брежневның

үзенә үк хат язарга булдым. Менә бу ике битлек хат минем өстәлемдә ята, 1965 елның 5 мартында язылган... Сүз дә анда, үзегез дә аңлыйсыздыр, Татарстанны союздаш республика итү турында бара. (Текстын күчереп тормыйм — артык эш.)

Вәләкин үтә җитди мәсьәлә турында язылган һәм иң югарыдагы кешегә адресланган хатны кемгә дә булса күрсәтергә кирәк иде. Бу бик четерекле мәсьәлә. Хаттан гаеп тапсалар, аның бәласе укыган кешегә дә тияргә мөмкин. (Группачылыкта гаепләнү хәтәр иде ул заманнарда.) Шуңа күрә мин, асылынсаң асылын алмагачның асылына дигәндәй, хатымны тоттым да Салих иптәш Батыевка илтеп күрсәтергә булдым. Сылтавы да бар: ул Татарстан Югары Советы Президиумының рәисе... (Үзен ул «президент» дип атарга ярата иде, тик аңарда Шәймиев хокукларының чиреге дә юк иде.) Әгәр хатны дөрес дип тапса, копиясен рәсми рәвештә аңа да калдырмакчы идем. Аннары Салих Гыйлемханович җитәкчеләр арасыннан миңа җылырак караучы бердәнбер кеше дә иде. Кайчан гына мөрәҗәгать итсәм дә, отказ юк, шунда ук килергә куша торган иде. Бу юлы да ул мине берсүзсез бик тиз кабул итте.

...Күрештек, утырыштык, һәм мин кереш сүзсез генә хатымны чыгарып, аның алдына салдым. Ул да сораулар биреп тормыйча гына хатны алып, креслосына ята төшеп, укырга кереште... Мин аның кара кашлы, кучкыл кара йөзенә бик игътибар белән карап утырсам да, берни дә чамалый алмадым...

Салих Гыйлемханович хатны укып чыкты, кире өстәлгә куйды, ике бармагын да подтяжкаларына кыстырды, шуннан соң гына әйтте:

— Дөрес язгансың, сорауларны да дөрес куйгансың, ләкин... җибәрергә кирәкми!..

— Ни өчен?

— Хат Брежневның үзенә кермәячәк, кире безгә әйләнеп кайтачак, ә без сине чакырып алып «аңлату» үткәрергә тиеш булачакбыз.

— Кызык! — дидем мин, ни әйтергә дә белмичә.

— Нәрсәсе кызык?.. Безгә артык мәшәкать, ә үзеңә?.. Монда синең белән шөгыльләнүебез кирәкме әллә сиңа?!

— Юк, сезнең минем белән шөгыльләнүегез кирәкми миңа...

— Алайса хатыңны кесәңә сал да куй.

— Ләкин ни өчен ул адресланган кешегә барып җитмәскә тиеш?..

— Бер генә хатны да ачып карамыйча, укымыйча иптәш Брежневка кертмиләр — тәртибе шундый... Бу эштә махсус кешеләр утыра. Көн саен килеп торган бихисап хатларның бик күбесен шулар «хәл итәр» яки «чара күрер» өчен тиешле урыннарга таратталар... Менә безгә дә моннан киткән хатлар еш кына кире кайталар. Әле күптән түгел, синеке төслерәк хат язган бер сантыйны Әгерҗедән чакырып китереп, үзенә әйбәт кенә аңлатырга туры килде.

— Димәк, җибәрүдән мәгънә юк?

— Абсолютно!.. Син әкиятләрне матур язасың, шуларны күбрәк яз!

— Ә милли мәсьәлә?!

Салих Гыйлемханович зур корсагын тибрәтә-тибрәтә рәхәтләнеп бер көлде генә... Безгә лимонлы чәй керткәннәр иде... «Әйдә, чәеңне эч, суытма!» — диде ул миңа.

* * *

Шулай итеп, мөһим мәсьәлә турындагы хат китмичә калды. Соңыннан мин аның ахырына Батыевтан ишеткәннәрне яздым да башка кәгазьләр арасына салып куйдым. Әмма «әкиятләрне матур язсам» да, мин бу каһәр суккан «милли мәсьәлә» шаукымыннан тәки котыла алмадым... Канга сеңгән, күрәсең, милли хәсрәт, милли моң булып...

Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә
Татар күңеле ниләр сизгәнен;
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Хәер, без тәкъдиребез белән әкренләп килештек тә бугай. Брежнев чоры унсигез ел чамасы дәвам итте. Тамак тук, өс бөтен, тыныч кына яшәмәктәбез... Халыклар дуслыгы да саклана, үзара сугышулар хәзергә юк әле...

Данлыклы коммунистлар партиясе бөтен нәрсәне дә, шөкер, безгә баш ватарга урын калдырмыйча, үзенчә хәл итеп кенә тора. Менә инкыйразга (бетүгә) шома гына якынлашабыз. Йөз баланың туксаны урыс мәктәпләрендә укый. Урыс теле гаиләләребезгә керде. Авылдан килгән әбиләребез оныкларыннан урысча сукаларга өйрәнәләр... Әдәбиятка яңа килгән татар яшьләренең шактый өлеше урысча гына яза. Ә без, өлкән язучылар, татар теле безнең гомергә җитәр әле дип юанган булдык.

Гүя болар барысы да бик табигый, гүя шулай булырга тиеш тә... Юк, алай булмаска тиеш, дип оран салучы да, башын ташка оручы да юк. Берише язучыларның мил-

ләт язмышын кайгыртып маташулары да комга киткән су шикелле үзеннән-үзе эзсез сеңде дә бетте...

Халык күңелендә һәрвакытта ике теләк яшәп килә — иҗтимагый гаделлек һәм милли тигезлек... Әмма милли тигезлек теләге никадәр көчле булмасын, шулай да иҗтимагый гаделлек аңардан көчлерәк һәм өстенрәк. Чөнки адәм баласына яшәү өчен иң кирәге шул...

Бүгенге Татарстан шартларында күпчелек халыкның Брежнев заманын сагынып яшәве шуның ачык мисалы, миңа калса... Әмма бу турыда сүз язманың ахыргы өлешендә барырга тиеш... Әгәр өлгерсәм... Кояшның соңгы нурлары әнә җиргә сузылды... Икенде, ахшам арасы... Фани дөнья гамьнәрен нәкъ әйтеп калыр вакыт!

## Алдану

Моңарчы мин Ходай биргән гомер юлымның — Лениннан башлап Горбачевка хәтле — нинди чорлар аша узганын сөйләп килдем. Ул чорлар һәммәсе дә алдану белән төгәлләнде: социализм әкренләп сүнә-сүнә юкка чыкты, аңардан көткән иркен мул тормышны күрмәдек, фикри вә рухи хөрлеккә ирешмәдек, ә коммунизм дигән «җәннәт» кысыр бер хыял гына булып калды. Шулай итеп, бөтен гомер нидер көтеп яшәү белән үтеп китте.

Инде менә 70 ел буена безгә «якты киләчәк» вәгъдә иткән шул ук партия инициативасы белән тагын бер бик өметләндергеч яңа чорга килеп кердек... Хәерле сәгатьтә! Тик монысын кем исеме белән атарга? Горбачев чоры диепме?.. Әмма ул бөтен бер чор була алмады. Бердән, бик кыска булып калды, икенчедән, Горбачев башлаганны бүген дә башка берәү дәвам итеп маташа. Ахыры билгесез, күпме дәвам итәчәген чамалавы да бик читен. Социализм төзеп азаплану җитмеш елга сузылды. Инде кайчандыр «тарих чүплегенә» ташланган галиҗәнап капитализмга кире кайту, ихтимал, йөз елга да сузылыр. Чөнки бу артка чигенүнең канлы юлы, чишелмәс каршылыклары, адәм башына төшкән газап-фаҗигаләре социализм төзегәндә күргәннәр шикелле генә булмас төсле. Шуңа күрә миңа аның үз өлешемә тигән унъеллык дәвамын гына күздән кичерергә туры киләчәк.

Әмма бу унъеллык та бер-берсеннән бик нык аерылган ике вакытка бүленә: Горбачев вакыты 91 нче елның көзенә хәтле; шуннан соң бары Ельцин исеме белән бәйләнгәне башлана... Әйтергә кирәк, берсенең бетүе, икенчесенең башлануы чын мәгънәсендә инкыйлаб булды... Инкыйлаб инде ул, үзегез дә беләсез, дөньяны тамырын-

нан үзгәртү дигән сүз... Бу җәһәттән 91 нче елның август инкыйлабы 17 нче елның октябрь инкыйлабыннан һич тә ким түгел. Тик соңгысының бөтен нәтиҗәләрен аңлап бетерү дә һәм аларга дөрес бәя бирүе дә хәзер генә, мөгаен, мөмкин түгелдер, вакыты җитмәгәндер әле. Мәгәр бер нәрсә бәхәссез — инкыйлабның бу соңгысын да большевиклар ясадылар. Тагын берничә инкыйлабны алардан көтәргә була әле. Без бит большевикларның кемнәр икәнен теге 70 елда гына түгел, менә шушы 10 ел дәвамында да бик ачык күрдек. Теге елларда миндә, мәсәлән, аларга ышану бөтенләй үк сүнеп бетмәгән иде, чөнки коммунистлардан бик намуслы, бик инсафлы дусларым бар иде. Әмма соңгы 10 елның вакыйгалары большевикларга ышануны төбе-тамыры белән йолкып ташлады. Минем өчен яңа чорның беренче нәтиҗәсе әнә шул!..

...Яңа чорны башлаучы үзе дә большевиклар штабыннан — Үзәк комитет секретарьларының берсе иде. Халыкка аз билгеле бу яшь партия лидерын Андропов үзеннән соң Генеральный секретарь итеп сайларга кушып калдырган, дип сөйләделәр. Ихтимал, ул шулай булгандыр да. Чөнки илнең киләчәге өчен зарури җитди үзгәрешләрне догматик картлардан көтеп булмый, моны бары яңача уйлый алырлык тәвәккәл яшьләрдән генә көтәргә була... Һәм 85нче елның башында Генераль секретарь урынын алган Горбачев Михаил Сергеевич гүя нәкъ шундыйлардан иде: үзе яшь, чибәр, дәртле, белемле, сүзгә дә бик оста... Тагын бер нәрсәсе бик ачык күзгә ташланды: шактый иртә шәрәләнгән башының маңгае өстендә зур гына көрән тамгасы да бар иде. Бик вак, әһәмиятсез бер деталь, ләкин халык шуңа игътибар итмичә калмады, һәм тикмәгә генә булмаган икән ул.

Җитәкчелек дилбегәсен кулына алу белән үк, ул үзенең яңа стратегик юлын (курсын) да игълан итте. Аңа «Перестройка» дигән исем бирелде (татарчасын «үзгәртеп кору» дип атадылар)... Хуш, нәрсәне үзгәртеп корырга кирәк иде?.. Без яшәп яткан, ләкин күп яклары белән безне канәгатьләндерә алмаган социалистик җәмгыятебезне камилләштерү, ягъни аны гуманлырак, инсафлырак һәм баерак та итү, моның өчен кеше хокукларын беренче урынга кую, рухи вә фикри хөрлеккә юл ачу, ниһаять, чын демократиягә табан борылу — менә, җыеп кына әйткәндә, үзгәртеп коруның төп максаты шулардан гыйбарәт иде, минем аңлавымча... (Моны хәтта «Социализмны кеше кыяфәтенә кертү» дип тә атадылар.)

Әйтәсе дә түгел, күптән көткән олы максат, изге максат!.. Әмма моңарчы хакимлек итеп килгән тоталитар

система шартларында бу максатларга ирешү мөмкинме? Ул система чын демократиягә юл бирәчәкме?.. Мәсьәләнең четерекле ягы шунда ки, күпме еллар дәвамында большевиклар тарафыннан ныгытылган, хакимлек итүләрен саклаган һәм хәзергә кадәр аларны әйбәт кенә яшәткән ышанычлы система ич ул! Аны какшату яки йомшарту шуларның барысын да кулдан ычкындыруга китермәсме?.. Ләкин шулай булса да үзгәртеп коруны большевиклар партиясе башлап җибәрде ич!.. Хикмәтле заман, кызыклы ситуация!

Һәрбер яңа эш башта җиңел китә, уңышлы гына бара. Аңа каршылар, исләренә килеп, хәрәкәт итә башлаганчы, ул инде нидер эшләп тә өлгерә.

Гадәттә, партия башлаган яңа эшне халык сүзсез-бәхәссез кабул итәргә күптән өйрәнеп беткән иде. Ышанса-ышанмаса да, теләсә-теләмәсә дә, ул югарыдан кушканны эшләргә мәҗбүр иде.

Бу юлы исә Горбачев башлап җибәргән «үзгәртеп кору»ны халык бик кызыксынып һәм теләп кабул итте. Күптән күңелендә яшеренеп яткан өмет-хыяллары аның кинәт уянгандай булды, зур үзгәрешләр булачагын гүяки алдан ук тоеп, шуңардан ул ничектер җанланып, рухланып та китте. Бигрәк тә интеллигенция «үзгәртеп кору»ны ике куллап күтәреп алды. Гади халыкның да эшләргә яраткан айнык өлеше аны бик хуплап каршы алды. Кыскасы, «үзгәртеп кору» җәмгыятьнең барлык катлауларын да әйтерсең төртеп уятты — бер генә сыйныф, бер генә груһ та аңа битараф кала алмады... Ә чит илләргә килгәндә, мөнәсәбәт, ихтимал, төрлечәрәк булгандыр. Һәрхәлдә, Советлар Союзы кебек галәмәт зур һәм дәһшәтле бер дәүләтнең шундый көтелмәгән кискен борылыш ясарга җыенуы аларда курку катыш сагаю тудырган булырга тиеш. (Алар арасында безнең дуслар да, дошманнар да аз түгел.) Әмма безгә капма-каршы лагерьда торучы Көнбатыш Европа белән Америка Кушма Штатлары Советларның демократиягә табан борылуын алкышлап диярлек каршы алдылар. Ә борылышны ясаучы Горбачев үзе аларда иң популяр, иң хөрмәт ителгән кешегә әверелде.

Әйтергә кирәк, «үзгәртеп кору»ның әнә шулай уңышлы башланып китүенә гласность (татарча — хәбәрдарлык) дигән нәрсә бик нык ярдәм итте. Бусы да безнең өчен һич көтелмәгән гаҗәеп бер яңалык иде... Мәгънәсе бит аның ачык язу, дөресен язу, барысын язу иде... Менә шуны күрү бәхетенә ирештек. Гласность ул «үзгәртеп кору»дан безгә мирас булып калган бердәнбер ачы-татлы ганимәт!

Ә яңа башланган чагында ул бик күп нәрсәгә күзебезне ачты, бик күп нәрсәне дөрес аңларга ярдәм итте. Асылда бит без «үзгәртеп кору»га күп нәрсәне белмичә, ялганга балаларча ышанып, сәяси яктан шактый томана хәлдә килеп кердек. Уйлану бар, сизенү бар, ә чын дөресен генә белү юк иде.

Ул чакларда мин өч-дүрт Мәскәү газетасына языла идем. Гласность башлану белән, аларда шаккатыргыч мәкалә, очерклар да басыла башлады. Укып кына өлгер!.. Һәм иң гаҗәбе — шуларның бик күбесендә мин электән үк үземдә туган уй-фикерләрне еш кына очрата идем. Бу кызыклы факт иде — фикерләрнең туры килүе... Димәк, күптән бертөслерәк уйлап йөргәнбез икән...

Аннары кайчандыр язылып та дөньяга чыга алмыйча яткан, шулай ук читкә сөрелгән язучыларның безгә килеп җитмәгән әсәрләре калын журналларда бер-бер артлы чыга башладылар. Шулардан да без үзебез яшәгән Совет заманының моңарчы бездән яшерелгән ямьсез, караңгы якларын күрдек, белдек. Аларны санап тормыйм, мәгълүм әсәрләр, мәгәр иске системага карата нәфрәт уятуда аларның тәэсире көчле булды.

Горбачев чоры әнә шулай искене какшатудан, яңаны куәтләүдән башланды. Әмма ул китергән үзгәрешләрне, ул тудырган проблемаларны санап бетерү мөмкин дә түгел, ерып чыгарлык та түгел. Тик бер нәрсә хәтерләрдә бик ачык уелып калды: «үзгәртеп кору»ның башыннан ук Советлар Союзы кемдер таяк тыгып бутаган олы кырмыска оясыдай тузгый башлады. Моңарчы гүя тыныч кына посып яткан бөтен яхшы һәм яман көчләр бердән урыннарыннан куптылар... Һәм иң көтелмәгәне — «үзгәртеп кору» башыннан ук диярлек ниндидер явыз көч котырткандай капма-каршы, үзара килештереп булмас сәер-серле, күп очракта фаҗигале вакыйгалар белән бергә үрелеп бара башлады. Моны аңлавы читен иде, төрле шик-шөбһәләр тудыра иде. Һәм ирексездән тынычсызланырга мәҗбүр итә иде.

Хәлбуки диктатурадан демократиягә күчәргә тырышуның җиңел-шома гына бармаячагын алдан ук чамаларга мөмкин иде. Иң элек «үзгәртеп кору»ны игълан иткән партиянең үзендә бу процесска бер үк караш, бер үк мөнәсәбәт юклыгы ачык сизелә башлады. Дөрес, ачыктан-ачык каршы чыгучылар юк та кебек, әмма гамәлдә кабул итмәүчеләр дә аз түгел иде шикелле... Бигрәк тә партия аппаратында утыручылар — югарыдан алып түбәнгә кадәр — ниндидер зур үзгәрешләр башлауны теләмиләр иде бугай. Чөнки бик әйбәт көйләнгән һәм җи-

тәкчелек итүне кулларында тотарга мөмкинлек биргән системаның җимерелү ихтималын иң элек алар сизделәр булса кирәк.

Әмма Горбачев үзе әйткәнчә, «процесс пошел!» Күптән көтелгән, туар вакыты да җиткән, мәгәр ничектер кинәтрәк башланып киткән процесс иде бу. Моның сәбәбе, бәлки, озак еллар үзгәрешсез яшәүгә ияләшеп бетүдәдер. Мөнәсәбәт, әлбәттә, бертөсле генә түгел иде — берәүләр аңа бик куанды, икенчеләр сагая калды. Моңарчы «бердәм, монолит» булып саналган Совет җәмгыяте, асылда, бик чуар, бик каршылыклы икән. Озак та үтми, андагы төрле катлаулар үз дәгъваларын күтәреп чыга башладылар, төрле груһлар арасында бәхәс-тартышлар китте, төрле җәмгыятьләр, хәтта партияләр дә туа башлады... Моңарчы тел тидерергә дә ярамаган большевиклар партиясенә һөҗүм көчәйде, аның хаталарын, җинаятьләрен фаш итүләр артканнан-арта барды... Ташу вакытында җыен чүп-чар өскә калыккан шикелле, ниндидер яшерен генә баеп яткан эшкуарлар «идән астыннан» чыга башладылар, алар тирәсендә колак ишетмәгән әллә нинди мафиозлар, рэкетчылар, «паханнар» күпләп пәйда булдылар. Инде шуларга тагылып, безнең киләчәкне юраучылар, багучылар, күрәзәчеләр һәм безне телевизор каршына утыртып, барлык авырулардан да терелтүче шарлатаннар чамасыз күбәеп китте...

Һәм менә болар барысы бергә кушылып, җәмгыятьтә тотрыксызлык, кешеләрдә исә аптырау-каушау тудыру өчен җитә калды. Ниһаять, биниһая зур бинабызның нигезендә, диварларында беренче ярыклар да пәйда булды. Бу инде ишелә башлауның башы иде, дисәк тә хата булмас. Хәер, без әле аны көтми дә, теләми дә идек, чөнки социализмны «кеше чырайлы» итү максат итеп куелган иде.

...Инде шул социаль хәвефле стихияләргә ни гаҗәптер бер-бер артлы килеп торган, күп корбаннар алып киткән зур-зур һәлакәтләр дә өстәлде. Яңа, өметле чорга керүебезгә ел үтәр-үтмәс, Чернобыль атом станциясенең бер казаны шартлады. Бу дәһшәтле һәлакәттән кешеләр өстенә яуган үлем куркынычы хәзер дә әле беткәне юк, һәм тиз генә бетмәс тә, ахры. (Радиация зәхмәте йөз елларга сузыла дип әйтәләр.)

Чернобыльдән соң Әрмәнстанда бик көчле зилзилә булып, берничә шәһәр җимерелде, меңләгән кеше хәрабәләр астында калып һәлак булды... Илдә киеренкелек көчәйгән бер заманда, моның кебек зур һәлакәтләр халыкны, билгеле, шомландыра калды.

...Тагын күпмедер вакыттан соң, Уфадан ерак түгел, тимер юл белән янәшә сузылган «газопровод» шартлап, шуңардан һавага таралган газ эченә килеп кергән пассажир поезды кинәт дөрләп янып китә. Йөзләгән кеше, күбесе ялдан кайтып килүче балалар, шул чагында янып үләләр... Җан өшеткеч фаҗига шулай ук бөтен илне тетрәтә.

...Боларга тагын Кара диңгез һәм Иделдә зур теплоходларның әллә ничек көтелмәгәндә батып, күпме пассажирларны су төбенә алып китүләрен дә өстәсәк, халыкның чынлап торып шомлануы һәм бу сәер-серле һәлакәтләрнең сәбәбен табарга тырышуы бер дә гаҗәп түгел... Элек ул моның ише коточкыч һәлакәтләрне күрмәгән, ишетмәгән (зилзиләдән башкасын), шуңа күрә дөнья аңа тыныч та, имин дә тоелган. Ә хәзер? Хәзер әнә бәхетсезлекләр бер-бер артлы килеп кенә тора! Нидән бу, кем аркасында? Һәм менә шул чакта мөхтәрәм Горбачевның маңгай өстендәге тамгасын исләренә төшерәләр дә; гүя ул тамга Тәңре тарафыннан сугылган мөһер, гүя ул мөһерле кешене Аллаһы Тәгалә адәм балаларын кыямәт көне алдыннан төрлечә сынап карау өчен җибәргән. Аны хәтта ахырзаман кешесе дип тә атый башлаганнар иде.

Бу, әлбәттә, хорафат. Күрәсең, кискен үзгәрешләр чорында халыкның хорафатка бирелеп китүе бик мөмкин икән. Хәер, хорафаттан башка да, әледән-әле кабатланып торган фаҗигале вакыйгалар «үзгәртеп кору» барышында үзенең салкын кара күләгәсен төшермичә калмады.

Хәлбуки «процесс» җәелмәктә һәм алга таба бармакта, билгеле, Коммунистлар партиясенең сизгер җитәкчелеге астында. ЦКлар, обкомнар, горкомнар, райкомнар — барысы да эшкә җигелгән. Генеральный секретарь М.С.Горбачев традиция буенча бөек «процесс»ның зирәк юлбашчысы, бөтен囲 эштә бары аның сүзе, аның хөкеме йөри. Әмма эшләр ул теләгәнчә, ул уйлаганча гына бармый кебек. Төп сәбәп, миңа калса, аның бер үк вакытта партия диктатурасын да сакларга, демократиягә дә мөмкинлек бирергә, ил байлыгын дәүләт кулыннан да ычкындырмаска, хосусый милеккә дә юл ачарга тырышуында, Хуҗа Насретдин әйтмешли, аңа кыз да булсын, буаз да булсын.

Әмма ләкин һәрбер тирән, зур хәрәкәт шикелле үк «үзгәртеп кору» да бик күп яңа проблемалар тудырды. Җитәкчелек исә аларны чишәргә өлгерә алмый, чөнки бердәм караш та, ачык билгеләнгән программа да юк. Һәр мәсьәләдә өзелмәс-бетмәс бәхәсләр. Нәтиҗәдә, яңа хәрәкәт көчәя барып, тормышның бөтен тармакларында

диярлек буйсынмас стихиягә әйләнә башлады. Ләкин мин шуның берсен генә искә төшермәкче булам. Бу — милли мәсьәлә һәм милләтара мөнәсәбәтләр.

«Үзгәртеп кору» әнә шул мәсьәләләрнең күп кенә яшерен якларын ачты. Баксаң, Советлар Союзындагы барлык халыклар да үз язмышларыннан канәгать түгел икән. Хәтта урыс халкы да! Ул, янәсе, электәге бөеклеген, шәүкәтен югалткан, башкаларга хезмәт итүче, нужа чигүче абруйсыз бер халыкка әйләнеп калган. Ә «башкаларның» бөтен кайгысы — урыс җәтмәсеннән котылу. Алар большевиклар тарафыннан «халыклар дуслыгы» дигән битлек астында әкрен генә руслаштыру сәясәте алып барылганын бик яхшы күреп һәм авыр кичереп яшәгәннәр икән. Инде хәзер партия диктатурасы йомшару белән аларда бик табигый рәвештә урыска йотылып бетүдән котылу, милләт буларак сакланып калу теләге туды. Бу теләк бик тиз көчәйде, киңәйде, озак та үтми чын мәгънәсендә милли азатлык хәрәкәтенә әйләнде. Бөтен республикаларда бер үк вакытта диярлек башланып киткән хәрәкәт иде ул. Тиз арада аның үз оешмалары, үз лидерлары да туып өлгерде. (Бездә, мәсәлән, Татар иҗтимагый үзәге, «Иттифак» фиркасе һәм аларның Марат Мөлеков, Фәүзия Бәйрәмова кебек беренче җитәкчеләре.) Инде шушы көчле хәрәкәтнең нәтиҗәсе буларак, барлык республикаларда да «суверенитет» игълан итүләр башланды. Урыс шовинистлары моны хәтәр бер шаукым дип тә атадылар. Ләкин бу шаукымнан Россия үзе дә читтә торып калмады, башкалардан күреп, тизрәк «суверенлыгын» игълан итте. Мәгәр һәркайсында моны власть башындагы большевиклар эшләргә мәҗбүр булдылар. Парадокс шунда ки, элеккеге Советлар Союзында да, хәзерге Рәсәйдә дә ниләр генә эшләнмәсен, асылда, гел генә большевиклар кулы белән эшләнә. (Бүгенге ялган демократия белән кыргый капитализм да алар эше.)

Әмма суверенитет игълан итү никадәр җиңел булса да, чын мөстәкыйльлек белән бәйсезлеккә ирешү күп республикалар өчен һич тә ансат булмады. Юлы аның канлы фаҗигаләр аша сузылды. Советлар империясен саклап калу өчен Горбачев командасы авыр танклар һәм ОМОН солдатлары ярдәмендә хәрәкәтне туктатырга тырышты. Коралны худка җибәрү большевикларның күптән сыналып килгән бердәнбер «ышанычлы» чарасы иде. Бу юлы да алар күпме шәһәрләрнең урам-мәйданнарын адәм каны белән юдылар — аларны сез беләсез, кабатлап торуның, мөгаен, кирәге юктыр. Әмма кешеләрне исерек солдаттан үтертеп булса да, халык күңелендәге азатлык-

ны үтереп бетереп булмый икән. Вильнюс, Тбилиси, Баку урамнарында түгелгән кан да утка керосин сибү генә иде — моның ахыры Советлар Союзының таралып китүе белән тәгәлләнде.

Әлбәттә, таралуның нигезендә бик тирән яткан бүтән сәбәпләр дә бардыр, ләкин мин аларны тәгаен ачык кына белмим. Гомумән, бу гаять катлаулы һәм гыйбрәтле азатлык хәрәкәтенең сәбәпләрен ачар өчен галимнәр башларын озак ватарлар әле. Мине исә, беренче нәүбәттә, Советлар Союзының таралып китүе котылгысыз идеме дигән сорау кызыксындыра.

Мәсьәлә бик катлаулы. Бәйсезлеккә омтылыш никадәр көчле булмасын, милли республикалар үзара һәм Россия Федерациясе белән аеруча һәрьяктан да шулкадәр тыгыз бәйләнешкә кереп беткәннәр ки, аларның ул бәйләнешләрдән кинәт кенә азат булуларын күз алдына китерүе дә читен әле. Һәрхәлдә, бу «башка чыгучылар»ның һәркайсына күтәрелмәгән авырлыклар китерүе дә бик мөмкин иде. Аннары тоташ бер илдә бернинди чикләр барлыгын сизмичә, үзара йөрешеп-аралашып яшәгән халыкларны кая куясың?! Озак еллар буена сакланып килгән, гадәткә кергән туганлык, дуслык җепләрен болай ансат кына өзгәләп ташлау белән алар килешәчәкме? Әйе, милли мәсьәлә әнә шундый каты чи төен ул! Җитмеш ел буена Ленин партиясе аны теш белән дә чишеп булмаслык хәлгә китерде. Әмма мондый төенне дә, «Гордиев узел»ны чапкан шикелле, үткен кылыч белән бер селтәнүдә кисеп ташладылар. Дөнья бер мәлгә авызын ачкан килеш өнсез калды.

Ләкин аңа хәтле Президент Горбачев «төенне» башкачарак чишәргә тырышып карады. Үз инициативасы белән ул барлык республикаларның җитәкчеләрен җыеп, озак бәхәс-сөйләшүләрдән соң тәгаен бер килешүгә дә ирешкән иде. (Аны Ново-Огарево килешүе дип атадылар.) Һәм аңа кул гына куясы калган иде. Ихтимал, ул килешү Советлар Союзын саклаган хәлдә, милли республикаларга мөмкин кадәр тулырак мөстәкыйльлек вә бәйсезлек бирү теләге белән төзелгән дә булгандыр. (Ишетүебезгә караганда, безнең Татарстанга да союздаш республика статусы бирелергә тиеш булган, имеш.) Әмма Горбачевның иң «ышанычлы» терәкләре, дәүләтнең иң югары урыннарын биләүче кешеләре (Крючков, Пуго, Язов һ.б.) Советлар Союзын иске хәлендә саклап калыр өчен дәүләт белән идарә итүне вакытлыча үз кулларына алдылар. (ГКЧП дип аталды ул.) Өч күнлек хәлифәләрнең фетнәсе әлеге килешүгә кул куюны да өзде. Совет-

лар Союзының таралып китүен дә тизләтте. Балтыйк буе республикалары фетнә бастырылу белән үк Советлар Союзыннан аерылып чыктылар. Башкалар ташлап чыгарга ашыкмадылар, дөньяның иң зур корабына су керә башласа да, йөзәрлек хәлдә иде әле.

Өч көнлек фетнәнең сәер яклары, ачылмаган серләре күп, әмма иң гаҗәбе Горбачевның шул көннәрдәге ихтыярсызлыгы һәм көчсезлеге. Ул бит Президент, ул бит барлык хәрби көчләрнең башында торучы, күпме мөмкинлекләр аның кулында. Кыска гына вакытлы әсирлектән котылып, башкалага кайту белән үк ул, ашыгыч чаралар күреп, таркалуны туктата алган булыр иде. Әле бит 87 процент депутатлары коммунистлардан торган Югары Совет та үзен таратып өлгермәгән иде. Барлык республикаларның башында шулай ук Мәскәү куйган партия җитәкчеләре утыра иде. Менә шулар ярдәмендә, кирәксә, закон көченә таянып, «процесс»ны туктатып булмас идемени? Инде хәзер Ново-Огарево килешүенә дә тиз арада җыелышып кул куярга мөмкин булган булыр иде. Мәгәр боларның берсе дә эшләнмәде. Кайчандыр бөек үзгәрешләрне башлап җибәргән чагында үз сүзен оста үткәрә белгән, кирәксә, кыюлык та күрсәтә алган мактаулы Президент бу юлы шиңгән куык шикелле бик кызганыч хәлдә калды. Бөтен эше аның ул көннәрдә фетнәчеләрне гаепләүдән, үзен аклаудан гыйбарәт булды. Күрәсең, иң якын, иң ышанычлы яраннарының хыянәте аның рухи халәтен тәмам сындырган иде.

Аның каравы күптәнге көндәше Борис Ельцин өч көнлек фетнә аркасында гаять күтәрелеп, көчәеп китте. Ул герой, ул демократияне коткарып калучы!

Ике Президентның сәяси язмышлары үзе бер гыйбрәтле тарих, ләкин аның төгәлләнгәне юк әле. Бөтен яктан да бер-берсенә һич охшамаган бу кешеләр икесе дә өстенлек белән беренчелекне бөтен нәрсәдән дә артыграк яратучылар булып чыктылар. Шушы нигездә алар арасында башта астыртын, соңрак власть өчен ачыктан-ачык каты көрәш башланды һәм бу көрәштә мужик табигатьле Ельцин интеллигент Горбачевка караганда үзен усалрак та, гайрәтлерәк тә итеп күрсәтте. Нәтиҗәдә, ул Россия Федерациясен суверен дәүләт ясап, шуның Президенты булуга да иреште.

Әйтергә кирәк, ике Президентның гамәлләрендә дә аерма зур иде. Горбачевта сүз күп, эш аз, күп кенә проблемаларны (мәсәлән, икътисади реформаны башлауны) хәл итү сузыла да сузыла, ә Ельцинда, киресенчә, сүз аз, эш күбрәк, кирәк дип тапканын тиз һәм кыю хәл итә.

Билгеле, бу аерма аларның авторитетында да чагылмыйча калмады, күп сөйләүче бик пөхтә Горбачевныкы ил күзендә әкренләп төшә барды, ә дорфа-тәвәккәл Ельцинныкы отыры күтәрелә генә барды.

Хәзер инде бер казанга ике тәкә башы сыймаячак. Ельцин бик тиз, бик кыю хәрәкәт итте. Кичекмәстән ул теге 7—8 кешенең фетнә чыгарып маташулары өчен 18 миллионлык компартияне тыйды-туздырды. Аннары күпмедер вакыттан соң Советлар Союзына да чират җитте. Ишелә башлаган Союз урынына бары бөек Россия дәүләте генә булырга тиеш. Бусы да гаҗәп ансат эшләнде. Мәгълүм булганча, Ельцин кыргый үгезләр йөргән Беловежская пуща урманына үзе белән Шушкевичны (Белоруссия) һәм Кравчукны (Украина) ияртеп барды да, хохол горилкасын чөмергән арада, Советлар Союзын тарату турындагы декларациягә кул да куйдырып кайтты.

Әнә шулай бер уңышсыз фетнә аркасында ситуация, кемдер әйтмешли, тамырыннан үзгәрде дә куйды. Партия туздырылды. Союз бетерелде, Горбачев төшерелде, аның Кремльдәге кабинетына, әйберләрен кыстырып чыгып киткәнен дә көтеп тормыйча, Ельцин кереп утырды. Михаил Сергеевич үтә әдәпле интеллигент кеше буларак, җиңү белән котлап, ни өчендер гел генә шешенке, кызыл чырайлы Ельцинның каты калын кулын да кысты.

...Шекспир каләме белән язылырлык трагикомедия әнә шулай тәмамланды.

Гафу итегез, мин дөньякүләм олы һәм фаҗигале вакыйгаларны бик гадиләштереп, бераз көлебрәк тә язган булдым. «Серьезный» абзыйларның моңа, бәлки, чырайлары да сытылыр. Ләкин нишләмәк кирәк? Халыклар язмышы белән бәйләнгән вакыйгаларның бик төптә яткан сәбәпләренә мин керә алмыйм, чөнки белмим аларны. Гомумән, белүчеләр бармы икән әле? Биекне яхшы күрер өчен читкә китеп карау кирәк — бу очракта исә вакыт ераклыгы кирәктер, мөгаен. Миңа калса, без кичергән вакыйгаларның сәбәпләрен бөтен тирәнлеге һәм чын дөреслеге белән яза алучы галимнәр тумагандыр да әле. Ихтимал, алар шашкан заманнан нормаль заманнарга күчкәч кенә туарлар.

Мине исә сәбәпләрдән бигрәк нәтиҗәләр кызыксындыра, ә нәтиҗәләр шаккатырлык! Һәрхәлдә, минем өчен.

**Беренче нәтиҗә.** Дөньяның иң көчле, иң күп санлы, бөтен кыйтгаларга даими йогынты ясап торган, бик күп илләрнең эчке эшләренә тыкшынып, аларны өзлексез шомланып торырга мәҗбүр иткән, дөньякүләм коммунистик хәрәкәтнең башында торучы бөек Ленин партия-

се бер кешенең — әле кайчан гына үзе дә шуның лидеры булган кешенең ихтыяры белән яшәүдән туктады. Билгеле, коммунизм идеясенә чынлап ышанган, Ленинны изге санап аңа табынганнар бу хәлне бик авыр кичергәннәрдер. Әмма партия әгъзаларының абсолют күпчелеге КПССның бетүе белән дә, үзләренең фиркасезгә әйләнүләре белән дә җиңел килештеләр булса кирәк. Партия тышауларыннан бушану аларга ошап та куйгандыр әле. Бу күпчелектә идеал да юк, иман да юк, бары «денем өчен түгел, көнем өчен» дигән коры исәп кенә бар. Әгәр ГКЧП җиңә калса, алар итагатьле коммунистлар булып йөри бирерләр иде, ә хәзер әнә дүрт ягың кыйбла, тик алданма, сайлый гына бел шуның кайсысына табынырга?!

**Икенче нәтиҗә.** Коммунистлар партиясен тыю — ул 70 ел буена күпме халыкның башына җитеп төзеп маташкан социализмнан тәмам ваз кичү иде.

Ленин өйрәтүләре Рәсәй шартларында яраксыз һәм кирәксез булып чыкты, һәммәсен ташларга туры килде. Хәтта Горбачевның «кеше чырайлы социализмга» чакырып азаплануы да берәүнең дә колагына кермәде, чөнки халыкның үз йөзе юк, большевиклар «тәрбиясе» аркасында ул үз йөзен күптән югалткан иде инде.

Димәк, социализмнан да шәбрәк яңа бер нәрсә уйлап табарга кирәк иде. Аны «базар мөнәсәбәтләре»нә күчү, диделәр. Нинди мөнәсәбәтләр бу. Ничек күчтек без аңа — ул хакта вакыты җиткәч.

**Өченче нәтиҗә.** Партияне туздыру Советлар Союзын таратуны тизләтте. Чөнки партия диктатурасы бетерелде. Хәзер инде ул һичкемне һичбер нәрсәгә мәҗбүр итә алмый. Полный хөрлек! Һәр республиканың ни кылса да иреге бар. Әмма Советлар Союзы бит ул республикалар берлеге генә түгел, ә большевиклар кулындагы иң дәһшәтле бер империя иде. Дөньяның коты алынып тора иде аңардан һәм шушы бөтен эче-тышы корал белән тулы империянең кинәт юкка чыгуы җиһанны, әлбәттә, таңга калдырды. Еллар буена атом һәлакәтен көтеп яшәүчеләр өчен бу гүя күктән иңгән бер могҗиза булды. Америка һәм Европа илләре моңа бүрекләрен чөя-чөя шашып кул чаптылар. Горбачевка Нобель премиясен бирделәр, ә пәһлеван Ельцинга миллиардлар вәгъдә иттеләр. Тик менә ГКЧП геройларына (ГКЧП игълан итүчеләргә) һәйкәл куярга гына оныттылар — шулардан башланды ич болар барысы да.

Әйе, дөнья хәйран калды, дөнья шашынып куанды, әмма үз илебездәге халыкларга Советлар Союзының та-

ратылуы әйтеп бетергесез газап-бәхетсезлекләр китерде. Бөтен бер ил өстенә кинәт ябырылып төшкән авырлыклар, канлы фаҗигаләр дә, асылда, шуңардан башланды.

Бөтен бер дәүләтне җимерү закон буенча җинаять булып саналырга тиеш шикелле. Вәләкин диктаторлар өчен закон язылмаган. Аларны соңыннан тарих кына хөкем итә ала.

**Дүртенче нәтиҗә,** һәм бик хикмәтлесе.

Коммунистлар партиясе бетерелсә дә, коммунистларның үзләренә бармак белән чиертүче дә булмады. Һәммәсе исән-сау искечә матур гына яши бирәләр, тик взнос түләмиләр дә партҗыелышларга йөрмиләр. (Мин инде монда ГКЧПга катнашучыларны телгә дә алмыйм, чөнки алар, бердән, бик аз, икенчедән, алары да исән-имин котылдылар.) Төп мәсьәләдә иң югарыдагы партократия белән алар тирәсендәге номенклатурада иде. Менә бу груһ ата коммунистларның берсенә дә җил-яңгыр тимәде, һәммәсе дә үзләренең җылы урыннарында әйбәт кенә утырып калдылар. Тик вазифалары гына үзгәрде. ҮК яки обком секретарьлары йә президент, йә губернатор булдылар. Әнә Төркмәнстан ҮКның беренче секретаре хәтта «Төркмәнбаши»га әверелде. Бөтен җөмһүриятләрдә, өлкә-крайларда, бөтен шәһәр-районнарда ул шулай барды да. Бер генә райком секретаре да эшсез калмады, барысы да йә хакимият башлыгы булды, йә министр булып күтәрелде.

Шул рәвешчә режим үзгәрсә дә, власть тулысынча «большевиклар» кулында калды. Алар үз араларына ятларны кертергә яратмыйлар. Кайчандыр тоталитар система белән килешә алмаган хөр фикерле кешеләрне алар арасында күрмәссең.

Шулай да ГКЧП җиңелгәннән соң демократия чикләре язгы ташудай аеруча киңәеп китте. Ә ташу белән ниләр генә өскә калкып чыкмый! Шуның шикеллерәк хәлне тиздән безгә дә күзәтергә туры килде. Кыска гына вакыт эчендә нинди генә исем белән нинди генә партияләр тумады?! Аларны белеп тә, исәпләп тә бетерерлек түгел. Хәзерге көндә вагы-төяге, чүп-чары белән йөзгә җитә бугай. Моны инде, бер уйлаганда, чын демократия дип тә атарга ярый торгандыр, бәлкем. Әмма ни гаҗәптер, бик күбесенең башында кичәге большевиклар! Яңадан берничә партия булып оешырга өлгергән коммунистларны әйтеп торасы да юк. Хәтта Россия тәхетенә патша утыртуны таләп итүче монархистлардан алып фашизм байрагын күтәреп чыккан нәсел-нәсәпсез Жириновскийга кадәр шул ук кичәге большевиклардан. Һәм

алар барысы да власть дәгъва итәләр. Барысы да һичнидән — алдаудан, җинаятьтән дә чирканып тормыйча, тештырнаклары белән властька омтылалар. Нидән бу, нәрсә аларны шулкадәр ярсыта — кызыл чүпрәк үгезне ярсыткан шикелле? Әллә Ленин бабайдан калган гадәт буенчамы? (Мәгълүм ки, Ленинның төп максаты властьны большевиклар кулына алу иде.) Җитмеш ел буена кулларында тоттылар бит инде, нигә тагын шуның өчен якалашырга?

Без бу яңа заманга күп нәрсәдән хәбәрсез, томана бер хәлдә килеп кердек. Әйтик, теге заманда власть өчен партияләр көрәше булмагач, Советларга кем сайланса да, безнең өчен барыбер иде. Сайлау участогына бара идек тә, бюллетеньне ачып та карамыйча, кызыл әрҗәгә салып кына җибәрә идек. Ә хәзер менә «барыбер» дип кенә котылу мөмкин түгел. Сайланучылар арасында кемнәр генә юк — коммунист, социалист, фашист, монархист һәм әллә ничә төрле демократлар. Аларны аера белергә кирәк ләбаса! Әмма иң аптыратканы: шулар һәммәсе дә, әйткәнебезчә, кичәге большевиклар. Кайчандыр бер сафта торып бер үк идея өчен көрәшүчеләр бүген исә берберсенең бугазын чәйнәргә торучы дошманнар! Йә, шаккатарлык әхвәл түгелмени бу?!

Мин менә шушы гадәттән тыш гаҗәеп әхвәлнең серен Ельцин режимына кергәч кенә беркадәр аңлагандай булдым. Гади генә итеп әйткәндә, эш менә нидән гыйбарәт икән: Советлар заманында алар дәүләт белән җитәкчелек итүче бердәнбер партия әһелләре буларак, барысы да бер казаннан ашадылар. Казан бик зур, бик тирән иде, аңа илнең бөтен җир өсте, җир асты байлыклары тутырылган иде. Без дә шул казаннан бәләкәй кашыкларыбызга салып биргән белән туендык.

Инде хәзер икътисади реформа уңае белән төпсез казанның теге вакытта ашаудан калганын аерым кулларга тарату башланды. Анысы да бихисап күп. Уртак малны эт җыймас, ди казах мәкале. Ә менә хосусый кулларга күчсә, мал сакланачак һәм артачак та. Асылда, бу дөрес булырга тиеш, дөнья тәҗрибәсе шуны күрсәтә. Ләкин бездә уртак малны (байлыкны) тарату белән хакимият үзе шөгыльләнә. Билгеле инде, ул иң элек үзен кайгырта, байлыкның күбрәк өлешен, беренче нәүбәттә, үзенә каерып ала. Бүгенге көндә иң бай хосусый милек хуҗалары — Совет заманында җитәкчелек иткән партаппаратчылар! Бер генә мисал. Кайчандыр ҮК аппаратында эшләгән бүгенге хөкүмәт җитәкчесе Черномырдин Рәсәйдәге миллиардерларның берсе икән («АИФ» атналы-

гы шулай дип язды), кичәге большевик кулында кайдан мондый капитал? Атасыннан калмагандыр бит?!

Кыскасы, дәүләт кем кулында, байлык та шуның кулында. Бу хакыйкатьне большевиклардан да яхшырак белүче бар микән? Җитмеш еллык тәҗрибә аларны күп нәрсәгә өйрәтте. Алар бары власть кешесе, аларга бары власть кирәк — власть булганда гына алар дәүләткә дә, аның байлыгына да хуҗа булачаклар. Бу — алар өчен аксиома!

Менә шушы факттан, минемчә, бик мөһим бер нәтиҗә чыгарып була. Ленин тудырып калдырган большевикларның чын асылы бервакытта да, бер генә шартларда да үзгәрми икән. Алар бары төсләрен генә үзгәртәләр. Алдагы 10 елда кем генә нинди генә битлек киеп властька килмәсен, ул — диктатура заманыннан калган большевик булачак.

* * *

Әйткәнебезчә, тормышыбызның соңгы 10 елы турыдан-туры ике кеше исеме белән бәйләнгән: башы — Горбачевныкы, дәвамы — Ельцинныкы. Берсенең көтмәгәндә «тәхеттән» төшеп калуы, икенчесенең тиз генә шуның урынына менеп утыруы 91 нче елның август фетнәсе аркасында булды.

Бөек чорны башлаучы Горбачев бер генә проблеманы да хәл итә алмады. Аның каравы ул безгә чын демократиянең хәбәрдарлык, фикер хөрлеге кебек гаять мөһим гонсорларын (элементларын) калдырды. Шуның аркасында ни сөйләсәң, ни язсаң да ярый торган бер заманда яшибез.

Бөек чорның Ельцин өлеше дә үтә җитди икътисади, сәяси-иҗтимагый, мораль үзгәрешләрдән башланды. Монысы инде «базар мөнәсәбәтләре»нә (капитализмга) күчү дип аталды. Без менә шуның нәрсә икәнен хәзергәчә бик шәп күреп, бик әйбәт татып киләбез.

Әлбәттә, бу шаккатыргыч үзгәрешләргә мөнәсәбәтләрнең бер генә төсле булуы мөмкин дә түгел иде. Аларга бәяне һәркем үз хәленнән чыгып кына бирә ала. Ә хәлләр исә төрлечә — кешеләр дә, теләкләр дә, аһ-зарлар да — һәммәсе дә бик төрлечә.

Капитализмга күчүне Ельцин чын большевикларча — кешеләрнең күптән күнеккән яшәү шартларын вату-җимерүдән башлады. Мондый кыю тәвәккәллек тиз арада халыкны социаль яктан ике котыпка аерды да куйды. Бер котыпта кинәт бөлгенлеккә төшүчеләр, икенче котыпта шулай ук кинәт баеп китүчеләр. Беренчесендә халыкның абсолют күпчелеге, икенчесендә кечкенә азчылыгы.

Мин үзем дә беренче котыптагы алданмыш бәндәләр төркеменә керәм. Мин дә бит реформаның башыннан ук таланган миллионнарның берсе. (Мәгълүм булганча, икътисади реформа халыкның дәүләткә ышанып саклык кассаларына салган акчаларын йотудан һәм әйбер бәяләрен күтәреп җибәрүдән башланып китте.) Әмма һәркемнең күз алдында булып узганнарны яңадан кабатлап торасы килми. Хәзер инде Ельцин режимының дүрт ел эчендә китергән нәтиҗәләре турында сөйләү урынлырак булыр.

Хуш, бу үзебез сайлаган режим безгә нәрсә бирде, нәрсәләр китерде? Иң беренче нәтиҗә — без елап, сыкранып булса да, ниһаять, базар мөнәсәбәтләренә кердек. Авызыбызны ачып, гаҗәпләнеп калдык, базарларда ниләр генә юк! Күгәрчен сөтеннән башкасы әнә өелеп ята. Магазиннарга керсәң, рәхим ит, җаның теләгәнеңне чиратсыз-нисез сайлап алырга мөмкин. Тик кесәңдә кыштырдап торган илле меңлекләр генә җитәрлек булсын. Акчада, бары тик акчада бөтен көч-кодрәт! Шул гына билгели кешенең көнкүрешен, җәмгыятьтәге урынын!

Менә моннан базар мөнәсәбәтләренең икенче бер нәтиҗәсе, медальнең икенче ягыдай, үзеннән-үзе ялтырап килеп чыга. Реформаның төп максаты — уртак ил байлыгын хосусый милеккә әйләндерү иде. Хакимияттәге ереле-ваклы номенклатура «приватизация» дигән хәйләле бер чара ярдәмендә ул байлыкны, төрле яшерен мафияләр белән берләшеп, үзара бүлешеп бетермәктә. Исәпсез байлык хәзер әнә шулар — төрле дәрәҗәдәге түрәләр, чиновниклар, бизнесменнар, банкирлар кулында. Ә халыкка нәрсә? Аның да уртак малга хакы бардыр бит?! Әлбәттә, әлбәттә. Халыкны онытырга ярыймы соң! Әнә Чубайс әфәнде аларга башта ук уртак малның законлы өлеше итеп ваучер дигән хикмәтле бер нәрсә өләште. Аның өлешенә тиячәк «байлыкның» күләме 10 мең сумлык иде. Хәзер инде бу суммага ярты кило колбаса да алып булмый.

Дүрт ел дәвамында икътисади һәм иҗтимагый хәлләр шулкадәр кискен, тирән үзгәрде ки, берәүләр балдамайда йөзә, икенчеләрнең авызларыннан үпкәләре күренә. Байлык белән хәерчелек арасында төпсез упкын. Моннан соң шушы упкын кешеләрне бер-берсеннән аерып торачак. Реформа моңарчы билгесез җыен вак-төякне өскә күтәрсә, җәмгыять өчен бик кирәкле чын кешеләрне түбән төшерде. Аеруча фән эшлеклеләрен, мәгариф-мәдәният хезмәткәрләрен, иҗат кешеләрен хурлыклы хәерчелек шартларында калдырды.

Кыскасы, алдау вә талау белән башланган реформа-

ның акыл җитмәс хикмәтләрен сөйләп бетерерлек түгел. Базар мөнәсәбәтләренә керү ул кыргый капитализмга күчү икән ләбаса! Халык моны баштарак белмичә, шәйләмичә калды. Ә кыргый капитализм бернинди мораль кагыйдәләрне белми һәм белергә дә теләми икән ул.

Өстәп тагын шуны да әйтәсе килә: хәзерге яңа байларны «яңа руслар» дип атыйлар (бездәгеләрне бәлки «яңа татарлар» дип атау кирәктер). Моны ничек аңларга? «Яңа руслар» Рәсәйне бөлгенлектән чыгарачаклар диепме? Әмма бу череп баючылар бөтен капиталларын чит ил банкларына күчереп яталар түгелме соң? (Гәзитләрнең язуларына караганда, ай саен 200 милиард доллар читкә китеп тора икән.) Миңа калса, бу «яңа руслар» Рәсәй җирендә вакытлы кешеләр. Власть алышынса, шунда ук алар капиталлары артыннан чыгып таячаклар. Зирәклек белән өлгерлек аларда җитәрлек. Унҗиденче елдан соң бөтен байлыкларын ташлап качарга мәҗбүр булган аристократларның нинди аяныч хәлдә калуларын бик яхшы беләләр. Болар инде алар шикелле Париж рестораннарында официант яки швейцар булып эшләмәячәкләр.

* * *

Реформаның өченче, тагын да әшәкерәк бер нәтиҗәсе — бөтен ил буйлап җинаятьчелекнең котырып үсеп китүендә. Күрәсең, реформаторлар үзләре эшләрен талаудан башлап җибәргәч, бернинди җинаятьтән дә чирканып тормаучылар өчен шул җитә дә калгандыр: сезгә яраган нигә әле безгә ярамый?! Мәсьәләне болай кую мантыйкка да туры киләдер, мөгаен. (Большевиклар тарихында «талап җыйганны тала!» дигән өндәү дә булган иде берзаман.) Шул рәвешчә җинаятьчелек йогышлы чир шикелле күчә-күчә һәм җәелә-җәелә җәмгыятьнең бөтен тармакларына үтеп керде. Хакимиятнең һәр катында түбәннән югарыга кадәр коррупция, банклар, бизнесменнар арасында табыш өчен рәхимсез сугыш һәм башка исәпсез күптөрле кан өшеткеч җинаятьләр бер-берсе белән үрелеп, бәйләнешеп беттеләр... Кешене талау гына түгел, үтерү гап-гади бер эшкә әйләнде. Берәүләр өчен ул баеп калу чарасы, икенчеләр өчен, бәлки, ач үлемнән котылу чарасыдыр — аның бөтен сәбәпләрен һәм масштабларын белүче бар микән?! Бу афәткә каршы көрәшүче дәүләт органнары да аны күпме-азмы чикләүдән гаҗизләр. Җинаятьчелек бик тирән тамыр җибәргән бер системага әверелде булса кирәк, чөнки йогынтысы шул ук дәүләт органнарының эшендә дә сизелә. Күп кенә

зур, канлы җинаятьләрнең ачылмыйча калуы ирексездән шулай уйларга мәҗбүр итә. Белмим, бу канлы вәхшәттән чыгар көн килер микән?! Инде үсмер малайлар куркып-кызганып та тормыйча кеше үтерәләр, ә хыялланып кеше үтерү үзе бер кәсепкә әйләнде. Миңа калса, бу коточкыч хәлгә безне Ельцин командасының тиешенчә уйланмаган, ахырын белмичә башлап җибәргән әлеге үтә рәхимсез, мәгънәсез реформасы китереп җиткерде («шоковая терапия», янәсе). Бабайлар бик белеп әйткәннәр: ни чәчсәң — шуны урырсың!

Инде менә шулар өстенә — Чечня сугышы... Бу сугышка мөнәсәбәтемне мин рус танклары Чечняга бәреп кергән көннәрдә үк язып чыккан идем. («Татарстан яшьләре», 22 декабрь, 1994 ел.) Кабатлыйсым килми, чөнки халыклар каргышын алган бу акылга сыймас сугыш турында күп сөйләнде, күп язылды. Мәгълүм ки, сугышны Ельцин хакимияте бәйсезлеккә омтылучы Чечня халкын үзенә буйсындыру, шуның белән башкаларны да өркетү өчен башлаган иде. Әмма горур Чечня халкы Ельцин-Грачевның тимер ташкыны алдында тез чүкмәде, ә халыклар исә алты ай буена сузылган бу канлы мәхшәрдән үзләре өчен бик мөһим сабакны алып калдылар. Бөек державачылык рухы белән сугарылган дәүләт куркыныч, ышанычсыз, ул халыклар иркен теләсә ни вакытта тотып буарга әзер, моны һәрдаим истә тотарга, уяу булырга һәм үз халкыңны тиешенчә яклый да белергә кирәк! Тик менә бичара рус халкы үзенә күпме кан-яшь, ә Россия дәүләтенә тиз генә онытылмас хурлык китергән шушы мәгънәсез сугыштан тиешле сабакны ала белерме икән?!

Мәгәр бик шикле, чөнки Чечня фаҗигасе рус җәмәгатьчелегенең башка халыклар язмышына никадәр игътибарсыз, битараф булуын бик ачык күрсәтте. Гаҗәбе шунда ки, русның хәтта югары катлавында, әйтик, укымышлы зыялыларында да Рәсәй кул астындагы милләтләрнең хәлен аңлау, алар урынына үзләрен куеп карау дигән нәрсә бөтенләй юк икән. Рус бары үзен белә, үзен кайгырта, үзен генә хаклы дип саный. Башкалар ничек яши, ни тели, ни кичерә — анда аның эше юк. Мин инде «вак» халыкларны тотып ашарга әзер торучы ата шовинист Невзоров кебекләрне әйтеп тә тормыйм. (Андыйларның депутатлар арасында да, Президент тирәсендә дә шактый күп булуын күрдек.) Хәтта Рәсәйне хак юлга өндәргә кайткан Александр Исаевич Солженицын да милләтләр язмышына карата үзенең карагруһларча уйлавын, ниһаять, ачты. Ул бит тарихны да бик яхшы белә, халыкара законнарны да белә торгандыр, ә шулай

да халыкларның азатлыкка, мөстәкыйльлеккә омтылышын инкарь итеп маташа: янәсе, алар үз җирләрендә азчылык, ә менә руслар күпчелек. Ә ни өчен ул алай булганын юри сакалы астына яшерә? Дөнья күләмендә танылган зур язучының болай фикер йөртүе очраклы һәм вакытлы Жириновскийның ахмак дуамаллыгыннан күп мәртәбә хәтәррәк.

Изү-кысу заманы үтте. Мисалы әнә Чечня — халыкны кырып бетерергә була, моның өчен корал җитәрлек, әмма аны буйсындыру мөмкин түгел инде, бигрәк тә халыкның җанын! Рус халкы, ниһаять, моны аңларга тиеш. Халыклар арасында һәр җәһәттән тулы тигезлек кенә Россияне саклаячак.

Бу язма дөньяга чыккан чакта, Чечня җирендәге яман сугыш, ихтимал, беткән булыр. Мин белмим, Чечня халкы рус хакимиятеннән күргән явызлыкны кайчан да булса оныта алырмы, кичерә алырмы икән, әмма сугышның бетүе кирәк. Чечняның яшүсмерләре, балалары, бишектәге сабыйлары өчен кирәк ул, чөнки Чечня халкының киләчәге хәзер әнә шуларда.

* * *

Ельцин режимының нәтиҗәләре әнә шундый. Алдау, бөлгенлек, җинаятьчелек, сугыш-кырылыш, ниһаять, билгесезлек. Моның ише вафасыз, намуссыз, имансыз режимның булганы юк иде әле. (Репрессия елларын исәпләмәгәндә.) Болай дию белән килешмәүчеләр дә булыр, режимның уңай яклары да бар бит, диярләр аңардан оста файдалана белүчеләр. Ләкин күпме генә соң алар?!

Без дә инкарь итмибез кайбер уңай үзгәрешләрне. Товар кытлыгыннан чыктык — акчаң гына булсын!

Әмма ул үзгәрешнең, дөресрәге, кыргый капитализмга күчүнең халыкка йогынтысы нинди соң?! Бик әшәке, бик хәвефле, дияр идем мин. Әхлакый нормаларны бозып бетерде ул. Берәүләрдә комсызлык, әрсезлек, оятсызлыкны уятты. Икенчеләрдә ачу-нәфрәтне яман көчәйтте. Шәфкать-мәрхәмәт, әдәп-инсаф бетте. Нервлар черегән җеп шикелле өзелергә генә тора — шуның аркасында күпме бәхетсезлекләр, фаҗигаләр. Әйе, кешеләр кыргыйланды. (Кыргыйлануны мин үзем дә сизә башладым.) Шөкер әле, безне ата-бабалардан килгән инсаният кагыйдәләре бөтенләй үк кыргыйланып бетүдән саклап тора. Ләкин озаккамы бу сабырлык, бу чыдау? Бөлгенлек бит һаман тирәнәя, халыкның кимендә яртысы хәерчелектән интегә. Ә байлык номенклатура белән нин-

дидер мафиозлар кулында туплана. Берәүләрнең балалары ач утырганда, икенчеләрнең маңка (гафу итегез) малайлары «иномаркаларда» чабалар. Берәүләр икешәр-өчәр катлы таш йортлар салдырганда, икенчеләр җан биргән якынын әйбәтләп гүргә куяр өчен акча таба алмый. Моның ахыры ни булып бетәр? Берзаман «ачлар вә коллар дөньясы» яңадан балтага тотынмасмы? Хәер, гомере буе коллыкка ияләшеп яшәгән халыктан моны көтеп булмыйдыр, мөгаен. Һәм була да күрмәсен... Канга гарык булудан бер Ходай үзе сакласын!

Менә шулайрак хәлләр, кәбәм! Ә тормыш дәвам итмәктә — үзенең президентлары, министрлары, депутатлары, жуликлары, банкирлары, әдип-шагыйрьләре, фахишәләре, шуларның һәммәсенә икмәк үстерүче игенчеләре, өчәр-дүртәр ай хезмәт хакы ала алмыйча эшләп маташкан эшчеләре белән һаман каядыр таба абына-сөртенә бармакта. Бәлки әле, иркенрәк, яктырак бер дөньяга да барып чыгарбыз. Кире искегә кайту булмас инде. Пенсионерлардан башка берәү дә теләми бугай аны. Кешегә икмәк шикелле үк хөрлек тә кирәк бит әле. Бәлки, әзрәк артка чигенеп, Ельцин бозган тормышны, нижгарлар әйтмешли, берсәк кенә юнәтергә кирәктер, валлаһ! Моны инде халык үзе хәл итәргә тиеш... Аллага тапшырдык!

## Юллар чатында

Моңарчы сүз элеккеге Советлар Союзы һәм бүгенге Россия турында барды, ә үзебезнең әлегә исән-имин генә яшәп яткан Татарстаныбызга һаман чират җитмичә торды. Хәлбуки бездә дә бит бик җитди тарихи вакыйгалар булып узды. Сүзебез хәзер шулар турында...

Күп җирләрдәге шикелле, бездә дә көчле милли-азатлык хәрәкәте туды, шуның нәтиҗәсендә Татарстан автономияләр арасында беренче булып, үзен суверен республика дип игълан итте. Аннары шуңа таянып, үзенең мөстәкыйль Конституциясен дә кабул итте. Ниһаять, суверен республика сыйфатында Россия хакимияте белән, шулай ук беренче булып, вәкаләтләрне бүлешү турында килешү дә төзеде... Менә бу дәүләт күләмендәге гаять әһәмиятле актлар аркасында җөмһүриятебез игътибар үзәгенә әверелде, исеме еракларга таралды, хәтта «Татарстан моделе» дигән яңа сүзләр гамәлгә кереп китте.

Әмма бик җитди, зур үзгәрешләргә караш һәм мөнәсәбәт бездә бертөсле генә булмады. Хәзер дә әле аларга карата бәхәс-тартышларның беткәне юк. Безнең көннәрнең тарихы кайчан да булса бер язылыр — ихтимал, төр-

ле кешеләр тарафыннан төрлечәрәк язылыр ул, ләкин без, шушы көннәрнең тере шаһитлары буларак, үзебез күргән-белгәннәрне арттырмыйча-киметмичә ак кәгазьгә теркәп калдырырга тиешбез... Менә мин дә шул эшкә керешмәкче булам... Әлбәттә, бары үзем белгәнне, үземә кагылганны язу белән генә чикләнәчәкмен.

Иң элек шуны әйтәсем килә: бездә милли-азатлык хәрәкәтенең башланып китүе өчен җирлек җитәрлек иде. Татар бик борынгыдан ук каты изелеп яшәгән халык, азатлыкка бик сусаган ул, азатлык өчен аның көрәш тәҗрибәсе дә бар, бу көрәштә үзен таныткан каһарман кешеләре дә булган... Азатлык чаткысы татар йөрәгендә бервакытта да сүнеп тормады. Хәтта Совет заманында да! Шул сәбәпле бездә милли-азатлык хәрәкәтенең тиз арада туып, җәелеп китүе һәм моның өчен вакытында кирәкле, тәвәккәл-кыю кешеләрнең табылуы да бик табигый иде. Сез аларның кемнәр икәнен яхшы беләсез... Татарстан бүгенге көндә азмы-күпме милли хөрлеккә ирешкән икән, моны әнә шул кешеләрнең фидакарь көрәше нәтиҗәсендә диеп тә аңларга кирәк.

Тик, кызганычка каршы, бездәге милли хәрәкәттә баштан ук җитәрлек аңлашу, килешү, бердәмлек була алмады. Чөнки хәрәкәткә тартылган көчләр бик чуар иде — саф татары да, руслашканы да, карты-яше, динле-динсезе дә — барысы да бергә буталган иде... Шулай ук татар хәрәкәтенә каршы урыс хәрәкәте дә баш күтәрде. (Бу инде бик җитди һәм хәвефле каршылык иде.) Аннары республика башындагы партия җитәкчеләре милли хәрәкәтне кулларыннан ычкындырмыйча, ситуациягә карап, аңа йә юнәлеш бирергә, йә аны чикләргә тырыштылар... Хәрәкәтнең үз эчендә дә коммунистлар җитәрлек иде, ләкин алар хәрәкәтне көчәйтү урынына күбрәк үзара лидерлык өчен тартышу белән мавыктылар булса кирәк.

Моңа артык гаҗәпләнергә дә туры килми, чөнки бөтен Советлар Союзы өчен бу гомуми күренеш иде. Һәр җирдә олы хәрәкәткә тартылган көчләр арасында бәхәс тә ызгыш, бер-берсен ишетү дә, аңлау да юк, һәркайсы бары үзенекен белә дә, үзенекен генә дәгъва итә... Читтән караганда, бу тамаша изге Тәүратта язылган борынгы кыйссаны хәтерләтә иде. Туфан (дөньяны су басу) китеп, җир ачылгач, кешеләр күккә менеп җитәрлек итеп, Вавилон манарасын сала башлаганнар. Мәгәр моңа ачуы килгән Аллаһы Тәгалә аларның бу эшен туктатыр өчен телләрен үзгәрткән, ягъни кешеләр төрле телдә сөйләшеп, бер-берсен аңламас булганнар. Эш тукталган, Вавилон манарасы салынып бетмичә калган.

Кыскасы, менә мин дә шул «төрле телдә» сөйләшүчеләр арасына тартылдым. Минем өчен бу табигый омтылыш иде, заманның барышы белән күптән кызыксынып яшәдем. Җай чыкканда теге яки бу мәсьәләгә карата үземнең сүземне дә әйтә идем, моның өчен каты гына кыйналган чакларым да булды. Инде хәзер көтелмәгән хәрәкәтләр туып торган бер вакытта, үзгәртеп кору китергән үзгәрешләргә битараф калу мөмкинме соң?! Дөрес, үзгәрешләр башланганда, миңа инде 76 яшь иде, вакытым узды, соңга калдым дияргә дә ярагандыр, мөгаен... Мөхтәрәм карт язучы сыйфатында читтән тыныч кына күзәтеп, ашыкмыйча матур хикәяләр язгалап яту, шәт, хәерлерәк тә булгандыр. Ләкин урысның бер мәкале бар: битому не спится, диләр... Әйтер сүзләр күп җыелган, яңасы да туып кына тора — ничек түзеп ятмак кирәк мондый чакта?! Әлхасыйль, заман шаукымына бирелеп, хикәят язуны бер читкә куеп, миңа да тынгысыз публицистикага тотынырга туры килде...

Әйтергә кирәк, мин инде утырган язучы, фикер-карашларым күптән формалашкан — күп нәрсәгә минем үз карашым, үз мөнәсәбәтем бар. Шул сәбәпле мөмкинлекләр ачылу белән үк, мин үземне борчыган мәсьәләләр турында яза да башладым (әйтик, телебез язмышы, мәктәпләр хәле турында). Аннары шуларга ялганып башкалар да язылды. Ләкин мин күп яздым, дип мактана алмыйм. Электән килгән гадәтем буенча, әкрен эшлим, ашыкмыйм, мәкаләләрем дә кеше укырлык булсын дип тырышкан булам.

Иң мөһиме — язганнарым нәрсәләр турында. Укучыны бит иң элек шул кызыксындырырга тиеш. Әмма барлык язганнарымны искә төшереп, сөйләп чыгуны кирәк дип тапмыйм. Тик бер мәсьәлә тирәсендә язганнарны кабатламыйча да булмый. Чөнки ул бик күп бәхәсләр тудырган, хәзер дә әле көн тәртибеннән төшмәгән, ахыры-чиге дә күренмәгән гаять җитди, зур мәсьәлә. Бу — татар халкының язмышы, бу — Татарстанның киләчәге... Милли-азатлык хәрәкәтенең төп асылы, үзәк мәсьәләсе ул... Билгеле инде, мондый мәсьәлә кайнар бәхәссез, талаш-тартышсыз, каты көрәшсез генә хәл ителә алмый. Кешеләрне ул груһларга бүлгәләде, фиркаләргә аерды, бер-берсенә каршы куйды,— ярый әле эш канлы бәрелешләргә хәтле барып җитмәде. (Ә мондый бәрелешләр, чын сугышлар төрле җирләрдә бара иде инде.)

...Күп кенә каләм әһелләре бу бәхәсләрдән читтә торып калмады — шул җөмләдән мин дә, билгеле. Без әле хәвефле-хәтәр вакытларда да, җае чыкса, үз сүзебезне

әйтергә тырыша идек. Мөхтәрәм Фикрәт Табиев алдында без, бер төркем татар язучылары, 64 нче елны ук Татарстанны союздаш республика итү мәсьәләсен бик җитди рәвештә күтәргән идек. Большевиклар диктатурасы вакытында шуннан башкасын таләп тә итеп булмый иде. Хәзер исә, әнә тулы мөстәкыйльлек, бәйсезлек, хәтта аерылып чыгу турында сүз бара...

Мәгәр, бәхәсләргә керешкәнче, алдан ук шуны әйтеп куясым килә: яшем узганга күрәдер инде, мин милли-азатлык хәрәкәтенә якыннан катнаша алмадым, хәрәкәт тудырган оешмаларның берсенә дә кермәдем — хәер, мине ул тирәгә чакыручы да булмады. Шулай ук еш кына була башлаган митингларга да йөрмәдем — аларның кирәклеген инкарь итүдән түгел, ә халык арасында буталып, кысылып йөрүне яратмаганнан... Аннары мин трибун түгел, нәгъръә орып күкрәк тә кага белмим, мин ялгыз эш кешесе — ялгыз гына уйланам, аулакта гына язарга яратам.

Тагын нәрсә?.. Ахрысы, үзем хакындагысын әйтеп бетерергә кирәктер. Минем бик әйбәт дусларым булды, бу җәһәттән шөкрана итә алам, әмма мин бервакытта да хакимият кешеләренә, югарыдагы җитәкчеләргә якын тормадым, алар арасына кермәдем, зарым белән хозурларына бармадым. Йомышым төшкәндә бердәнбер бара торган кешем Салих Гыйлемханович Батыев иде. Ул мине тиң күрде — бәлки, мине үземә караганда әйбәтрәк белгәндер дә.

...Мин властьтан ерак кеше, аның нәрсә икәнен гади гражданин буларак җилкәмдә татып кына беләм. Дөрес, үзебезнең Югары Советка беренче сайлауларда Язучылар берлеге мине дә депутатлыкка кандидат итеп куймакчы булган иде. Бәлки, берәр татар районыннан сайланган да булыр идем. Ләкин мин ул дәрәҗәле эштән баш тарттым: яшьрәкләрне тәкъдим итегез, шулар сайлансын, дидем. (Һәм шундыйларның кайберләре үттеләр дә.) Мин бары хәзер генә кешеләрнең ни өчен властька шулкадәр ябышып ятуларын аңладым. Власть ул — әфьюн, бер кыйлашсаң, ансыз торып булмый икән. Әмма мин властьтан читтә торуыма бик канәгатьмен — кешеләрнең күзләренә туры карый алам, ичмасам!

Бу керештән нәтиҗә шул: бөтен язганнарым минем саф үземнеке, кемгә дә булса ярарга тырышу юк аларда. Мин фикерләремне җәмәгатьчелек хөкеменә чыгарам — шуның гына хөкеме минем өчен әһәмиятле...

Әле Советлар Союзы исән-сау чагында, 90 нчы елның язында, «Татар мәсьәләсе» дигән озын гына бер мәкалә

язган идем. (Мәкалә «Идел» журналының шул елгы 10 нчы санында басылып чыкты.) Аның эчтәлеген сөйләп тормыйм. Җыеп кына әйткәндә, татар мәсьәләсе ул рус-татар мөнәсәбәтләре белән чи бер төен булып бәйләнгән. Мәсьәләне хәл итәр өчен әнә шул каты төенне чишә белергә кирәк. Ягъни гасырлар буена сузылып килгән мөнәсәбәтләр кысасында без ничек итеп мөстәкыйльлек белән бәйсезлеккә ирешә алабыз. Минем фикеремчә, бары сөйләшү-аңлашу юлы белән генә, әмма татарны урыска каршы кую юлы белән түгел. Бу юлның ахыры безнең өчен бик фаҗигале булып бетүе бик мөмкин. (Моның ерак тарихтан ук килгән сәбәпләре мәкаләдә ачык әйтелде...) Татар халкының азатлыкка, тигез хокукка хаклы булуын күрсәтер өчен мин Тукайның «Олугъ юбилей мөнәсәбәте берлән халык өмидләре» дигән шигырен дә китергән идем. Татарның нинди халык икәнлеген, урыс белән мөнәсәбәтнең нәрсә икәнлеген Тукайдан да дөресрәк аңлаучы булды микән?! Совет заманында исә ул мөнәсәбәтләр аеруча тирәнәйде, көчәйде, мәгәр Мәскәүгә тагын да ныграк буйсыну исәбенә...

Мәкаләдә ике теләк максат итеп куелган иде: берсе — Татарстанны союздаш республика итү; икенчесе — Идел — Урал арасындагы милли республикаларны үзләренә аерым федерация итеп төзү... Әмма аларның берсе дә була алмады. Шулай да бер теләккә ирештек: үзебездәге милли хәрәкәтнең көчле басымы астында безнең дә Югары Советыбыз 1990 елның 30 августында Татарстанның дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул итте. Бу — мөстәкыйльлек белән бәйсезлеккә беренче җитди адым иде. Һәм ул адымны кан коймыйча гына ясап булды. Халкыбыз өчен моның никадәр әһәмиятле булуын әйтеп тору кирәк микән?! (Шулай да кайберәүләрдән: «Азатлыкны сорап алмыйлар, сугышып алалар»,— дигән сүзләрне ишетергә туры килде. Бик дөрес, әгәр дә хәлеңнән килсә.)

Әлбәттә, мөстәкыйльлек белән бәйсезлек өчен көрәшәсе дә көрәшәсе иде әле... Беренче нәүбәттә игълан ителгән дәүләт суверенлыгын ничектер законлаштырырга, ныгытырга кирәк иде. Моның чарасы бер генә — ул да булса — яңа Конституция. Татарстанның суверен дәүләт булуы менә шул Конституциядә беркетелергә тиеш. Конституция һәр дәүләтнең иң югары Төп Законы — аны бозарга һичкемнең хакы юк... Ниһаять, яңа Конституция дә кабул ителде. Ләкин ул бик каты тәнкыйтькә юлыкты. Кайбер милли хәрәкәт лидерлары аны шунда ук яманлап, хурлап, катгый рәвештә кире кактылар. (Әб-

рар Кәлимуллин, Фәүзия Бәйрәмова мәкаләләрен хәтерлисездер.) Билгеле, яңа Конституция һәр җәһәттән дә безне канәгатьләндереп бетермәскә мөмкин, әмма реаль чынбарлыкны истә тотсак, ул бик киеренке, хәвефле шартларда кабул ителде. (Мәскәү аның кабул ителмичә торуын хәтта таләп тә иткән булган.) Ләкин һичнигә карамастан, беренче мәртәбә үзебез төзегән Конституциядә Татарстанның суверен дәүләт һәм халыкара хокук субъекты булуы ачыктан-ачык беркетелде. Әлбәттә, җөмһүриятебезнең Төп Законын «дегет чиләгенә» тиңләп, хурлау-таптау белән килешүе һич тә мөмкин түгел иде... Һәм мин, намусым кушуы буенча, ике авторга да каршы чыгуны кирәк таптым. (Мәкалә «Кем хаклы?» дип атала, ул «Ватаным Татарстан» газетасының 1993 ел, 22 гыйнвар санында басылып чыкты.) Оппонентларга каршы үз дәлилләремне китергәннән соң, әнә шул «кем хаклы?» дигән сорау үзеннән-үзе туа: зур чыдамлык күрсәтеп, күп көч куеп, яңа Конституцияне кабул иттерә алган Президент Минтимер Шәймиевне, әллә бу Конституциянең кабул ителүенә теш-тырнаклары белән каршы торучылармы? Кайсы як бүгенге буталчык, киеренке, хәвефле шартларда татар халкының милли мәнфәгатьләрен дөресрәк аңлый һәм остарак яклый? Җавабы бер: халкыбызның иң зур күпчелеге Президентыбыз Минтимер Шәймиевкә ышана, аның ягында тора. «Гафу итегез, мин үзем дә күбрәк аңа ышанам», дип белдергән идем мәкаләмдә.

Шуннан соң ике ел ярым вакыт үтеп китте, илдә зур, фаҗигале вакыйгалар булып узды, алар безне ничектер читләтеп үтте, әмма көтелмәгән хәлләр заманы узмаган әле, шуңа күрә соңгы нәтиҗәләрне ясарга да иртәрәктер, мөгаен... Ни генә уйлама, ни генә фараз кылма, бүгенге чынбарлыктан котылу мөмкин түгел. Минем өчен дә ул шулай — һәр сүземдә мин өч нәрсәне истә тотарга мәҗбүрмен: без бөтен Рәсәй күләмендә таралып яшәүче халык, ләкин без бөтен бер милләт, Татарстаныбыз шул халыкның рухи вә мәгънәви Ватаны, ләкин ул, океандагы бер утрау шикелле, галәмәт зур Россиянең нәкъ үзәгендә торып калган, хәзерге Россиянең үзендә исә бөекдержавачылык идеясе хөкем сөрә, хакимияте дә аның бик агрессив, куркыныч — аңа бервакытта да тулысынча ышанып булмый.

...Һәр очракта да әнә шул объектив өч фактордан чыгып фикер йөртергә туры килә. Мисалга, Россия Федерациясе белән Татарстан арасында төзелгән килешүне дә китерергә була. Аңа кул куелгач та, Татарстан телеви-

дениесе Гомәр абзый Бәшир белән миннән килешү турында фикеребезне сорады. Без әле Шартнамәнең үзе белән танышып та өлгермәгән идек, шулай да фикеребезне әйттек, авыр сөйләшүдән соң төзелгән килешүне без, нигездә, хуплыйбыз, дидек. Ни өчен? Моңа минем саф үз җавабым: килешү кирәк иде — Федерация хакимияте белән Татарстан арасындагы мөнәсәбәтләргә ачыклык кертү өчен (билгесезлектән дә начар нәрсә юк); Татарстан хөкүмәте үзенә тигән хокуклардан тулысынча файдаланып, мөстәкыйль рәвештә эшли алсын өчен; ике хөкүмәт арасындагы мөнәсәбәтләрне нормальләштерүнең башка чарасы булмаган өчен; ниһаять, Мәскәү хакимиятенең Татарстанны суверен дәүләт дип таныганы өчен!..

Миңа калса, болар — килешүне хупларлык җитди дәлилләр. Шартнамәсе белән танышмыйча әйтелсә дә, алар принципиаль әһәмиятләрен югалтмыйлар. Аннары килешүнең нәтиҗәләре турында сүз әйтер өчен күпмедер вакыт узарга тиеш — чебешне бит көз җиткәч саныйлар.

Күрәсез, һәр очракта диярлек миңа мөхтәрәм Минтимер Шәймиевнең Татарстан мәнфәгатьләрен яклауда тоткан юлын һәм үткәргән сәясәтен гел генә аклап-хуплап барырга туры килде. Шулай итеп, мин кайберәүләр телендә Президентка ярарга тырышучы кешегә әйләндем. Мондый гаеп мине бик гаҗәпләндерә, чөнки минем бөтен кимчелегем дә «әйләнә» белмәүдә... Шуның җәфасын да күп чиктем. Хәзер дә һичбернинди «әйләнү» сизмим үземдә. (Сиксәннән узган кешегә аның кирәге дә юк.) Мин бары үзем дөрес дип тапканны гына язарга гадәтләнгәнмен — кемнәргәдер яраса - ярамаса да!

Хәлбуки чынлабрак уйласаң, нәкъ менә мөхтәрәм Минтимер Шәймиев үзе «әйләнде» түгелме икән? Бөтен үткәне, тәрбиясе белән саф коммунист, партия таләпләрен берсүзсез үтәүче кичәге обком секретаре бүген татар халкының милли мәнфәгатьләрен якларга тырышучы, Татарстанның киләчәген кайгыртучы милләт хадименә әйләнде түгелме соң?! Һәм нинди заманда бит әле... Ирексездән Дәрдмәнднең «Кораб»ы күз алдына килә:

> Чыкты җилләр.
> Купты дулкын —
> Ил корабын җил сөрә:
> Кайсы юллар,
> Нинди упкын
> Тарта безне җан сорап?!

Менә шундый коточкыч хәвефле берчакта штурвалны кулына алган «капитаныбыз» ил корабын дәһшәтле

дулкын-упкыннар аша шактый оста алып бара белде ич. Без менә бүген исән-имин. Аның урынында бүген берәү булса, ихтимал, төпсез упкын безне йоткан да булыр иде...

Кыскасы, Президентыбыз Минтимер Шәймиев шушы киеренке-куркыныч елларда үзен аек акыллы, төпле, сабыр, көчле, нык дәүләт җитәкчесе итеп танытты... Без үзебез, тыныч-тук яшәү аркасында булса кирәк, танып җиткермәсәк тә, читләр, бигрәк тә милли дошманлыкның нәрсә икәнен күреп-татып белгәннәр аны, һичшиксез, шулай дип таныдылар да... Һич югы, әнә шул читләргә карап, безгә дә шөкрана итәргә кирәктер, мөгаен.

Дөрес, Президент Шәймиев без көткәннең һәммәсен дә биреп бетерде, дип әйтә алмыйбыз. Халыкта канәгатьсезлек бар, шулай ук минем үземдә дә... Моның аңардан гына тормаган объектив сәбәпләре дә күптер, әлбәттә, әмма Шәймиевнең үзенә генә хас объектив сәбәпләрне дә бик ачык күрергә була. Сәяси лидер буларак кем ул?.. Минемчә, коеп куйган коммунист-демократ!.. Алай була аламыни? Була ала икән шул... Мондый сәяси гибридны безнең яңа заман тудырды. Барлык республикаларның башында шундый лидерлар утыра да инде. Властьны кулларына алганчы, алар, әлбәттә, демократ: алып торып, менеп утыргач, иске асылларына кайталар.

Безнең мөхтәрәм Президентыбызда да шундый ук әверелешне күзәтәбез түгелме? Әйтик, Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен көрәшкәндә, ул үзен чын демократ итеп күрсәтте. Милли-азатлык хәрәкәтенә таянып, Татарстанны суверен дәүләт итеп таныта алды. Бу — аның Мәскәү белән килешүгә кадәрге эшчәнлеге. Килешүдән соң исә демократлык артка чигенде, аның коммунистлыгы яңадан алга чыкты. Нәрсәдә күренә бу? Барысыннан элек идарә итү ысулларында.

...Ул — дәүләтнең беренче кешесе. Беренче кеше буларак, аның электән үк җыйган шактый бай тәҗрибәсе бар. Аңа эшләүчеләр һәр җәһәттән сыналган бик ышанычлы, теләктәш кешеләр булырга тиеш. Аның тирәсендә (мәсәлән, Президент Советында) без теге заманнан ук үзләренең бәйсез фикер йөртүләре белән күпме-азмы танылган шәхесләрдән берәүне дә күрмәдек. Мәскәү белән вәкаләтләрне бүлешкәннән соң, Президентның шәхси власте тагы да ныгый-көчәя төште. Моның ачык мисалы — соңгы сайлаулар. Татарстан Дәүләт Советына ул районнарга үзе билгеләгән хакимият башлыкларын депутат итеп үткәрә алуга ирешә. Шул рәвешчә яңа законнар чыгарырга тиешле «парламентны» да һәртөрле оппозициядән чистартты диярлек.

Билгеле, мондый сәясәтнең үзенә күрә логикасы бар. Шушындый гаять катлаулы авыр бер заманда дәүләт белән уңга-сулга чайкалмыйча идарә итү һәм халыкның ихтыяҗларын тәэмин итә алу өчен Президент кул астында ышанычлы, тәҗрибәле, сәләтле кадрлар эшләргә тиеш. Аларның эреләрен хәзер номенклатура дип кенә атыйлар. Гадәттә күп мәсьәләләрне шулар хәл итә, төп эшләрне дә күбрәк шулар башкара.

...Без гүя яңадан обком заманына кайттык. Шул ук өч кешедән торган пирамида: иң югарыда Президент, икенче урында — Дәүләт Советы Рәисе, өченче урында — Премьер-министр. Көн саен диярлек без экраннар каршында шуларның кая баруларын яки кайдан кайтуларын карап утырабыз. Гомумән, безнең телевидениенең бөтен эше, берәр мулланың атнага бер тапкыр вәгазь сөйләвен исәпкә алмаганда, рәсми хәбәрләр тапшырудан һәм кыр эшләрен күрсәтүдән гыйбарәт. (Билгеле, җыр-музыка белән сипләп.) Халык ничек яши, җәмгыятьтә нинди процесслар бара, сүз-фикер өлкәсендә нинди бәхәсләр туа — болар бөтенләй диярлек чагылмый. Тормышның кайнар сулышы газеталарыбызда да бик зәгыйфь сизелә башлады. Күрәсең, фикри хөрлек, хәбәрдарлык заманалары үтеп бара.

Аның каравы «показуха» бик көчәйде. Төрле бәйрәмнәр, Сабан туйлары, ярминкәләр зур колач белән, бик бай, бик матур итеп үткәрелә башлады. Ходаем, нинди муллык, нинди шатлык! — күзгә хәтта яшьләр килә. Тик ни кызганыч, бу сокланып туймаслык тамашалар бер генә көнлек, үтә дә китә, ә көндәлек азап-нужа, бөлгенлектән чарасыз интегү һаман искечә кала бирә. Моның ише шаккатыргыч, ирексездән гаҗәпләнергә мәҗбүр иткән тамашаны аерым шәхесләрнең юбилейларын үткәргәндә дә күрергә туры килә. Әйтик, юбилярның борын төбендә машина ачкычын селкә-селкә аңа кара «Волга» бүләк иттеләр. Халык шаша, кара нинди юмарт безнең хакимият башлыклары!..

Иллә мәгәр бүләкне бирүчеләргә мәгълүмдер бит юбиляр шикелле үк иҗат итүчеләрнең көнкүреш хәлләре. Мәсәлән, язучы иптәш-әфәнделәрнең. Еллар буенча аларның кулъязмалары нәшриятта акча юклыктан дөньяга чыга алмыйча ята. Әлек язучыга иң зур бүләк транзистор иде, аның каравы ике-өч ел саен китабы чыгып торды.

Тагын бер көтелмәгән «бүләк»... Мөстәкыйльлекнең бишьеллыгын бәйрәм итәр алдыннан районнарның зур уңыш алуы, урып-җыюны вакытында төгәлләве, икмәк заданиесен арттырып үтәве турында көн дә диярлек ра-

портларын, Президентның аларга котлау телеграммалары җибәрүен нәкъ обком заманындагыча ишетеп тордык. Бу кәефләрне күтәргән куанычлы хәбәрләр иде... Инде менә дөнья шаулатып уздырган бәйрәмнең чүпләрен урамнардан себереп алырга да өлгермәс борын ук, «бәйсез» хөкүмәтебез кайбер азык-төлекләргә бәяне дә күтәреп өлгерде... Юк, обком заманында алар мондый оятсызлыкны эшләмәсләр иде. Ә хәзер ярый, бездәге базар мөнәсәбәтләре бернинди әхлак кагыйдәләрен белми ул. Аның бу хосусиятен номенклатура халыктан элегрәк белеп алды. Шуңа күрә ул алдаудан да, талаудан да тартынып тормый. Соңгы ел ярым-ике елда аның комсызлыгы, әрсезлеге аеруча көчәйде. Бәяләр бит атна саен диярлек артып тора... Бөлгенлек тирәнәя, ризасызлык көчәя, ә байлык яшерен-астыртын гына кемнәрдер (?!) кулына күчмәктә. (Хәер, халык аларның кемнәр икәнен дә бик яхшы белеп тора...) Менә шуннан инде әлеге куппы бәйрәмнәр бездәге ямьсез чынбарлыкны бераз чибәрләр өчен генә эшләнми микән, дигән сорау күңелләрдә үзеннән-үзе туа.

Юк, мондый күз буяуга корылган режим белән килешүе бик читен. Әгәр икътисади реформа социаль гаделлеккә нигезләнгән булса, чын базар мөнәсәбәтләренә керү алдау-талаусыз, табигый рәвештә барса (мәсәлән, нэп вакытындагы шикелле), вакытлы авырлыкларны да җиңелрәк күтәрер идек, хакимияткә теләктәшлек тә күрсәтер идек, ихтимал, инде бөлгенлектән чыгып, иркен-мул гына тора да башлаган булыр идек... Әмма юк бит, яхшыга табан үзгәреш сизелми, киләчәгебез дә шактый томанлы, билгесез... Дөрес, сүз күп, вәгъдәләр күп, йөрү дә күп, мактану да җитәрлек, мәгәр нәтиҗәләре кайда, нидән гыйбарәт?

...Менә без хуплаган Мәскәү белән килешүгә дә ел ярым вакыт узып бара. Аның да матди вә мәгънәви уңай нәтиҗәсен көткәнчә тоймыйбыз бит әле. Бу хакта мин бер очрашуда Минтимер Шәриповичның үзенә дә әйтергә җөрьәт иткән идем. Әлбәттә, зур сәясәт бик катлаулы, бик нечкә эш... Ләкин Президентыбыз гафу итсен! — ул безнең ни уйлап, ни көтеп яшәвебезне белеп торырга тиеш.

* * *

Миңа ике мәртәбә үз йомышым белән Президентка мөрәҗәгать итәргә туры килде. Икесендә дә кеше димләве белән: Язучылар берлеге рәисе урынбасары Зиннур Мансуров бервакытны миңа, яңа салынып беткән прес-

тижный йорттан квартира сорап, Президентка мөрәҗәгать итәргә кушты. «Сезгә мотлак бирерләр!» — диде ул... Мин андый йортның барлыгын да белми идем. Аннары квартира алмаштыру уе минем башыма кереп тә чыкканы юк иде. Ләкин Зиннурның әйткәне күңелгә вәсвәсә булып төште. Чынлап та, нигә сорап карамаска? Престижный йортта торып карарга миңа да ярый торгандыр, шәт! Тагын мәсьәләнең икенче ягы да бар бит әле. Язучыдан калган квартира закон буенча язучыга бирелергә тиеш. Ә язучылардан квартира көтеп интегүчеләр азмыни?!. Менә шуны да истә тотып, бирсәләр хуп — бирмәсәләр үпкә юк дип, һәртөрле икеләнүләрне дә басып, мин Президент исеменә үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә булдым. Үтенечем дә кеше өркетерлек түгел иде: шаушулы урамдагы 3 бүлмәле квартирымны тыныч урындагы яңа йорттан шундый ук өч бүлмәлегә алмаштыру турында гына иде.

...Шактый айлар узды, Яңа елга да кердек, ниһаять, 1994 елның февралендә шәһәр хакимиятеннән бер егет өемә килеп, миңа яңа йорттан квартира биреләчәген әйтте. Рәхмәт инде... Ул яңа өйнең адресын да калдырды, барып карагыз, диде. Без күчәргә туры киләчәк квартирны берничә мәртәбә барып карадык. Дөресен әйтим, квартира безгә ошамады — аңа бер яктан да кояш төшми, караңгы, салкын булачак иде. Ә карт сөякләргә җылы кирәк... Телефонын калдырып киткән егеткә мин 4 ай буена шалтыраттым, ләкин бер генә тапкыр да сөйләшә алмадым.

...1994 елның җәй уртасында без, Аллага тапшырып, өч бүлмәле әйбәт, җылы-җыйнак, кояшлы квартирабыздан, мәйданы зур, түшәме биек, әмма бер яктан да кояш төшми торган таш идәнле салкын-шыксыз өч бүлмәлегә күченә башладык... Нинди икеләнү, нинди җан газабы белән, аякларым тартмыйча күченеп йөрүемне үзем һәм бары якыннарым гына белә. Мәгәр бер акыл иясе әйткән: упкын аша сикергәндә ярты юлда туктамыйлар, диеп. Менә шулай... Ташынып беткәч тә, мин 25 ел гомер иткән квартирымның ачкычларын Язучылар берлегенә илтеп бирдем. Ләкин ни гаҗәп, ул квартира менә бер ел инде буш тора... Шушындый торакка кытлык бар заманда... Төшенеп бетмәссең «безнең шәһәрнең серләрен»!

Иң гаҗәбе шул — минем яңа квартирга күчүемне кайбер бәндәләр гайбәт итеп таратырга да өлгергәннәр икән. Янәсе, мин квартира алыр өчен генә Президентка ярарга тырышканмын, янәсе, иске квартирымны кызларыма биреп калдырганмын... Әлбәттә, бу түбән, вак җан-

нар гайбәте — аны кире кагып маташу да түбәнлек кенә булыр иде. Президентка икенче мөрәҗәгатем «Соңгы китап» дигән әсәремне дөньяга чыгару өчен акчалата ярдәм итүен сораудан гыйбарәт иде. Моны миңа нәшрият үзе кушты, сметасын да төзеп бирде. Менә шул сметаны да кушып, мин Президент исеменә үтенеч-гаризамны яздым. Мәгәр җавап алганым юк әле...

Инде минем Президентка карата булган мөнәсәбәтемә килгәндә, ул бөтенләй башка мәсьәлә, һәм бөтенләй башка сәбәп, башка уйлар белән билгеләнә дә. Шуңа күрә мөнәсәбәт гел бертөрле генә булмаска да мөмкин. Вакыйгаларга минем үз карашым бар, шуңардан чыгып мин хөкем дә итәм — һәртөрле фани исәпләрне бер читкә ташлап... Моны сез үзегез дә шушы язмадан сизгәнсездер, шәт!

Әмма мөхтәрәм Минтимер Шәриповичка минем бернинди узгынчы вакыйгалар белән бәйләнмәгән үзгәрмәс төп мөнәсәбәтем бар: халкыбыз тарафыннан сайланган Президентка мин һәрдаим чын ихтирам саклыйм. Гражданлык намусым куша. Аннары ул бүгенге көндә халык алдындагы абруе, читләр каршындагы авторитеты белән дәүләтебез җитәкчесе була алырлык бердәнбер лаек кеше дә. Һәрхәлдә, аны алыштырырлык бүтән берәү каршыбызда басып тормый әле хәзергә... (Әмир Мәхмүтне исәпләмәгәндә.)

...Беләм, аңа каршылар да аз түгел. Урыннан төшерелүен таләп итүчеләр дә бар. Ләкин күпме генә алар? Халык Шәймиев ягында, халык аны алыштырып маташуга юл куймаячак. Вакыты ул түгел. Кичү чыкканда атларны алыштырмыйлар, ди урыс мәкале. Тик Президент үзенә каршыларны парламент трибунасыннан тыңласа, үзе өчен дә, безнең өчен дә яхшырак булыр иде. Алда зур сынаулар көтә безне — ачыклык кирәк, хәбәрдар булып тору кирәк. (Үз сүзен туры әйткән каршы якка караганда, «ләббәйкә» дип кенә торучы Ялагай Куштановлар Президент өчен хәвефлерәк, минемчә. Моннан күп еллар элек Сәгыйдуллин дигән журналист Ленинннан соң партиягә агылып кергән коммунистларны әнә шулай «Ялагай Куштановлар» дип атаган иде. (Ахыр чиктә партияне бүгенге хурлыклы хәлгә шулар китереп җиткермәделәрмени?!)

* * *

Киләчәгебез турында без бүген бик нык уйланырга тиешбез. Хәзергә әле әйбәт кенә булып тоелган хәлебез ни дәрәҗәдә ышанычлы, хәвефсез?.. Менә шул хакта минем дә соңгы сүземне әйтеп каласым килә.

Чечня фаҗигасе бик күп нәрсәне кара тактага язгандай, безгә бик шәп аңлатып бирде: Россия нинди дәүләт ул, башында кемнәр; Чечня нинди ил, нинди халык; без үзебез кем, нинди халык, ни күрдек һәм ни аңладык бу ярты елда?

Россиянең нинди дәүләт икәнлеге моңарчы да сер түгел иде. Инде Чечня сугышы аның дөнья иминлеге өчен ни дәрәҗәдә куркыныч икәнлеген тагын бер тапкыр раслады. Шуңа күрә бит иң көчле демократик дәүләтләрнең җитәкчеләре дә «Чечня ул Россиянең эчке эше» дип, кечкенә бер илне кырырга, бетерергә тотынган агрессорны хөкем итүдән тыелып, бер читтә посып калдылар. (Чөнки бу күзен кан баскан агрессорның кулында 30 мең атом бомбасы саклана. Ышан син аңа?!)

Ә Чечня канга батып бетсә дә, шәһәр-авыллары хәрабәгә әйләнеп бетсә дә бирешмәде, тез чүкмәде, киресенчә, үзе урыс армиясенең йөзләгән техникасын ватып-җимереп, меңләгән солдатларын кырып, Мәскәү хакимиятен ахыр чиктә сугышны туктатырга, сөйләшүләр башларга мәҗбүр итте. Һәм шушы батырлыгы, каһарманлыгы белән дөньяны таңга калдырды.

Әмма хурлыклы мораль җиңелүгә тарыган Россия дәүләте башка халыклар өчен һаман да әле куркыныч булуыннан туктадымы соң?.. Миңа калса, юк, туктамады — бигрәк тә безнең өчен... Нигәдер аның чираттагы явызлыгы нәкъ менә Татарстан өстенә төшәр кебек. Бигрәк тә карагруһ шовинистлар хакимияткә килә калса... Алар Татарстанның Россия эчендәге башка милли республикаларга күпмедер дәрәҗәдә үрнәк булуын мотлак кичермәячәкләр. Бетерергә тырышачаклар бу «үрнәк тарату оясын»! Кирәксә, яңадан Чечня ысулын кулланып...

Әгәр шундый ситуация туа калса, без нишләргә тиешбез, һәм ни эшли алабыз? Географик урыныбыз белән Россиянең нәкъ үзәгендә без, халкыбызның дүрттән өч өлеше читтә, ә мондагы халыкның 40 проценты — урыслар. Бу җәһәттән без Чечнядан бик нык аерылабыз, без бөҗра эчендә. Кемгә таянырга, кайдан, кемнән ярдәм көтәргә?.. Дудаев кулындагы исәпсез корал да, алдан әзерләнеп торган күпсанлы сугышчыларыбыз да юк. Бу реаль чынбарлык, моны инкарь итү мөмкин түгел... Анннары татар кешесе чечен дә түгел бит, аның кебек Ватан өчен үлемгә әзер тору да, сугышчан рух та юк бит. Психологиясе башка, урыска мөнәсәбәте башка, язмышы аны урыс белән аралашып, җайлашып яшәргә өйрәткән. Милли хисе, милли аңы көчле булуга карамастан, ул урыс белән ачыктан-ачык дошманлашудан сакланырга мәҗ-

бүр. Шуңа күрә татар агаеның сакал үстереп, автомат асып, урман-тауларда көне-төне сугышып йөрүен күз алдына китерүе дә бик читен. Аңа йорты-җире, мал-туары кадерлерәк.

Әмма бөтен исәп-хисаплардан өстенрәк аяусыз бер хакыйкать бар: сугыш ул ил өчен, халык өчен гаять зур фаҗига-һәлакәт. Без моны җитәрлек күрдек һәм күреп торабыз. Хәлбуки көткән нәтиҗәне бирми торган һәлакәт. Мисалы әнә шул ук Чечня. Бәйсезлек өчен күпме кан түгеп, мораль җиңүгә ирешүенә карамастан, ул да Россия эчендә, аның субъекты булып калачак. Һәрхәлдә, күпмедер вакытка...

Кыскасы, сугыш безнең юлыбыз була алмый, сәламәт акыллы берәү дә ул юлга басмаячак. Бары Мәскәү белән уртак тел табу, килешү генә безнең максатларыбызга туры киләчәк. Бу хакта референдум үткәрелсә, ышанам ки, халыкның 90 проценты килешү ягында булачак. Хәзер дә бит әле илдәге иминлек, халыкның тыныч шартларда яши һәм эшли алуы безнең мөстәкыйльлекне корал күтәрүгә караганда ныграк саклый лабаса!

...Янә бер хакыйкатьне истән чыгармаска кирәк: власть бар, халык бар. Еш кына аларның теләк-максатлары капма-каршы була. Алыйк шул ук Чечня сугышын. Власть аны башлады, ә халык каргады... Инде безнең белән бер үк җирдә, бер үк һаваны сулап яшәүче урыслардан сорагыз — нәрсә кирәк аларга: иминлекме, әллә үзара кырылышмы?.. Әлбәттә, иминлек, диячәкләр. Чөнки һәрбер халык өчен дә үзен саклауның иң беренче шарты — ул милләтара татулык!

Тагын бер хакыйкатьне истә тотыйк: Россия бәреп кергән җирдә иртәме-соңмы халык үзара сугыша башлый. Моның классик үрнәге — Әфганстан. Бездә исә әнә Чечня — анда да үзара кырылыш булачак. Таҗикларда да шундый ук хәлне күреп торабыз. Әгәр Татарстанга бәреп керсә, бездә дә татар белән татар сугыша башлаячак.

Димәк, шушы тотрыксыз, ышанычсыз, шунлыктан аеруча хәтәр Россия эчендә безнең Россия хакимияте белән килешеп яшәүдән башка чарабыз юк. Хәзергә бу — котылгысыз кырыс язмышыбыз. Бәйләнешләр шундый тыгыз ки, Россиядә нинди сәяси режим булса, бездә дә шул ук режим булачак. Бүген дә ул шулай, сайлаулардан соң да шулай булачак. Властька коммунистлар килсә, бездә дә власть коммунистлар кулына күчәчәк. Кадрлары әзер. Хәзерге номенклатура иске урыннарына мыштым гына кайтып утырачак. Фашистлар яки монархист-

лар килә калса, Мәскәү белән төзелгән шартнамәбезне шунда ук ертып ыргытачаклар. Хәзер үк инде милли республикаларны губерналарга әйләндерәбез дип торалар.

Иншалла, анысы булмас, әмма шулай да Россия язмышына без битараф калырга тиеш түгелбез. Нинди Россия безгә кирәк? Моны без алдан ук уйларга тиешбез. «Рәсәй ул — чит дәүләт, безнең аңарда эшебез юк», дип кәперәеп йөрү ул саламторханлык кына. Синең аңардан эшең булмаса, аныкы синдә булачак, белеп тор, әфәндем!

Тукай тәгъбиренчә, «уртак Ватан» язмышын хәл итүдә татар халкы, һичшиксез, үз сүзен әйтергә, үз таләбен куярга тиеш. Аның өчен Россиядә нинди сәяси режимның булуы зарур? Әлбәттә инде — демократик режим! Бары демократия шартларында гына без милләт буларак сакланачакбыз. Дөнья тәҗрибәсе шуны күрсәтә — милли азатлык, мөстәкыйльлек һәм бәйсезлек халыкларга бары чын демократия аша гына килә. Дөрес, Россия чын демократиядән бик ерак әле, моның өчен буыннар алышынуы кирәк. Нишлисең, көтәргә туры киләчәк. Дүрт йөз ел түздек, тагын бер 40 ел ничек тә түзәрбез — тик милләтебез исән-имин генә булсын!

Ә хәзер теге тиргәлгән дә сүгелгән шартнамәне шулай да саклап калырга кирәктер... Власть башында кем утырса аны саклап булачак — Ельцинмы, Черномырдинмы, Гайдармы, Явлинскиймы — мин тәгаен генә әйтә алмыйм... Әмма Чечняны харап итә язган Ельцинның яңадан президент булуын теләмәс идем. Кем икәнен күрдек, белдек — җитеп торыр.

* * *

...Туксан бишенче елның да ахырына җитәбез. Алда зур сайлаулар булырга тора (була калса). Власть өчен бер-берсенең бугазын чәйнәргә торучы бихисап гөруһлар, фиркаләр, блоклар катнашачак ул сайлауларда. Аның нәтиҗәләре 93 нче елның октябрь нәтиҗәләреннән дә, ихтимал, хәтәррәк булыр. Җиһанны ни көтә, Рәсәйне ни көтә, Татарстанны ни көтә — моны бүген һичкем әйтә алмый. Тулы билгесезлек... Шулай да өметләрне өзми торыйк. Халыктагы яшәү көче, яшәү сәләте аны нинди генә һәлакәтләрдән алып чыкмады?!.

...Әгәренки дөнья исән-имин калса, мин Татарстаныбызны киләчәктә Европа тибындагы чын демократик, югары цивилизацияле бер мәмләкәт итеп күрергә теләр идем. Әйтик, Финляндиягә охшаш — милләтара кырылышлар-

дан азат, тыныч, бәхетле ил итеп... Һәртөрле экстремизмга, терроризмга, фанатизмга мин катгыян каршы кеше. Шуларны сәясәт коралы иткән режимнар миндә тирән нәфрәт кенә уята. Безнең юлыбыз бөтенләй башка булырга тиеш. Ирешелгән килешүгә таянып, хокукларны ничек тә киңәйтү, мөстәкыйльлекне ныгыту — хәзергә иң дөресе шул булачак.

Дәүләтебез һәм халкыбыз алдында гаять зур, катлаулы, бик мөһим эшләр тора. Татарда уңганлык белән тырышлык бар, диләр. Менә шулар өстенә югары белем, югары культура, югары әхлак та булырга тиештер инде. Шул сыйфатларга ия булган чакта гына, ул үзен дөнья мәйданында таныта алачак... Әмма моның өчен ике нәрсә — байлык белән мәгърифәт кирәк. Шушы ике нәрсә безне революциягә кадәр көтелмәгән югарылыкка күтәргән дә иде... Россиядәге төркиләр арасында без бик хаклы рәвештә иң алга киткән халыктан санала да башлаган идек.

Мәгәр байлык дигәндә сүз кемнәрнеңдер алдау һәм талау юлы белән җыйган байлыклары турында бармый, ә халыкның тырыш хезмәте, хәләл кәсебе белән тапкан байлыгы турында бара. Шундый байлык кына законга сыя. Шәригать таләпләренә туры килә... Башка төрлесе харам байлык — ул катгый рәвештә тыелырга тиеш.

Мәгърифәт дигәнебез дә бары уку-укыту эшләренә генә кайтып калмый. (Укытуга килгәндә, иң төп таләп — һәрбер бала үз ана телендә укый башларга тиеш. Менә шуңа ирешә алсак, без дә, иншалла, «телсез татар» булып калмабыз.) Мәгърифәт төшенчәсенә минем белемне дә, мәдәниятне дә, әдәбият-сәнгатьне дә, әхлакны да кертәсем килә. Бигрәк тә соңгысын...

Ахыры-чиге күренмәгән икътисади кризис, шуңа ияреп килгән чамасыз җинаятьчелек әхлак кагыйдәләрен тәмам җимерә. Комсызлык, әрсезлек, ялагайлык, монафикъльк, хөсетлек, вәгъдәсезлек бүгенге кешеләрнең гамәлендә гадәти бер нормага әверелде дияргә була... Кызгану белән оят тойгысы бетте диярлек. Моңа хәзер берәүнең дә исе китми. Хәтта тыштан болай инсафлы гына күренгән зыялыларыбыз да әхлак сафлыгын югалта башладылар. Кешенең хәзер төп кайгысы — иманын, намусын, кешелек абруен саклауда түгел, ә шушы һәртөрле әхлакый кагыйдәләрдән ваз кичкән кабих заманга яраклаша белүдә...

Менә шундый әхлаксызлык сазлыгына кереп баттык без. Һәм бу сазлыктан чыгу тиз генә, җиңел генә булмаячак. Монда комсомол яшендәге муллаларның мөнбәр-

дән вәгазь сөйләве генә җитми. Беренче нәүбәттә, халыкка социаль гаделлекне кайтарырга кирәк. Кечкенә бер төркемнең баеп ятуы, купчелекнең бөлгенлектән чыга алмыйча интегүе бетәргә тиеш. Ә бу исә иң элек хакимият әһелләренә турыдан-туры кагыла. Менә шулар әхлак таләпләренә кайтырга әзерме?

Шигем зур. Алар бит халыктан аерылыбрак торган төркем, үзләренә бер тайфә (каста) һәм бик әз дә түгел алар — Советлар вакытына караганда берничә мәртәбә артыграк, диләр. Һәр иҗтимагый төркемнеке шикелле үк, аларның да үз мәнфәгатьләре, үз ихтыяҗлары бар. Әйтик, зур урын биләүчеләре иркен, мул, рәхәт яшәргә өйрәнделәр. Әхлак таләпләрен онытып тору аларга, мөгаен, уңайлырактыр. Халык сукрана икән — зарар юк, ул инде чыдарга һәм көтәргә күптән өйрәтелгән...

Сүз биредә аерым кешеләрнең мораль йөзе турында бармый, әлбәттә... Сүз башлыча кыргый капитализмга күчеп маташу нәтиҗәсендә туган һәм бөтен халыкларны да биләп алган котылгысыз бер гомуми тенденция турында бара... Шул тарта, шул суыра әхлаксызлык сазлыгына һәркемне, аның кем, нинди кеше булуына да карамастан. Рухи гарипләр йотыла, тазалар ничектер саклanып кала.

Мин үзем хәзерге татарның байтагына сагаеп карасам да, халкыбызның фаҗигале сынаулар аша үткәнен белгәнгә күрә, бүгенге бик хәтәр сынауларны да иманын һәм күркәм сыйфатларын югалтмыйча үтә алыр, дип ышанасым килә. Бөтенләй үк бетмәгәндер әле бездә тирән белемле, киң карашлы, милли горурлыгын саклаган чын иҗади көчләр!

Шушы уңайдан Сәгыйть Сүнчәләйнең күптәнге бер шигырен искә төшермәкче булам. Шигырь Фәхрелислам Агиев туена багышлап язылган. Чама белән ул 1911—1912 еллар тирәсе булырга тиеш. Шагыйрь аны туй мәҗлесендә кычкырып укыгандыр да... Шигырь болай башлана:

Күктәге нурлы кояш бер, ихтимал, сүнсә сүнәр.
Яктысы калмас, бетәр, әмма ләкин сүнмәс татар.

Бу юллар безгә никадәр генә сәер, гаҗәп тоелмасын, әмма шагыйрьнең үз халкына булган иманына сокланмыйча мөмкин түгел. Ә шигырь әле болай дәвам итә:

Дөнья да бетсә бетәр: хаклык, туганлык, дин, иман,
Әмма бетмәс берсе дә — бетмәс борын безнең татар.

Нинди тирән мәгънәле, хикмәтле сүзләр! Ләкин шагыйрьнең үз язмышында бу сабыйларча ышануы аклан-

дымы соң? Билгеле булганча, Сәгыйть Сүнчәләй, солтангалиевчелектә гаепләнеп, 10 елга хөкем ителә. Срогы тулып, иреккә чыгар вакыт җиткәч, КГБ палачлары аны, башка солтангалиевчеләр белән бергә, Соловкида атып үтерәләр... Татар барында «хаклык, туганлык, дин, иман» бетмәс, дип язган шагыйрьнең гомере әнә шундый коточкыч алдану белән өзелә. Әгәр Сәгыйть абый безнең заманга хәтле яши алган булса, ул татар турында мондый шигырь, әлбәттә, яза алмас иде.

Ә кияүгә багышланган шигырь болай бетә:

Үтте шундый куркыныч төннәр! — алай да бетмәдек.
Үтте төн, дуслар! Туган илгә матур таң тиз атар!..

Гаять садә, саф җанлы шагыйрьнең тирән ышану белән әйткән бу якты өметләренә без дә, һичшиксез, бик теләп кушылабыз!.. Амин, янә бер кәррә Амин!..

* * *

Инде бу заманның башы белән ахырын ялгарга кирәктер, ахрысы. «Кояш баер алдыннан» дип куелган язма ул сиксәннән узган кешенең (ягъни минем) рухи халәте турында булырга тиеш иде. «Гомерем кояшы баюга табан әкрен генә төшеп бара» — менә аның беренче юллары. Билгеле, язма калган гомер шикелле үк кыска гына булырга тиеш иде. Иллә мәгәр кояшым да тиз генә батмады, язма да бик озынга сузылды... Озын гомернең калган өлешен генә түгел, башыннан ук аны күздән бер кичереп чыгарга туры килде. Нигә кирәк булгандыр инде — аңлата да алмыйм, һәрхәлдә, үземне көчли-көчли, теләмичә-яратмыйча утырып, шуңа биш ел вакытымны исраф иттем. Заяга узган кызыксыз гомер, шуңа күрә ул язар өчен дә кызыксыз булгандыр... Әгәр укучылар бу язманы озак яшәп киткән бер кешенең үз заманы турында калдырган чын шаһитлык сүзе дип кабул итсәләр, без фәкыйрегез дә шуңа бик канәгать булачакбыз.

Инде картлыкның үзе турында... Аның мин белеп җиткермәгән табышмаклары күп икән. Мәсәлән, картлык ул кешенең дөньядан акрынлап ераклашуы. Гомер кояшы аның әҗәленнән иртәрәк бата, җан биргәнче үк инде ул дөньядан аерылган була.

Аннары картлык ул — ялгызлык. Иң якыннары гына аның янында кала (әгәр алары булса)... Башка таныш-белешләр, дус-ишләр карт тирәсеннән әкрен генә китеп бетәләр. Хәзерге заманда бу ташлау, бу оныту аеруча көчәйде. Кабалана адәм баласы, үзенә дә шундый

көн киләчәген оныта. Мин моны үпкә белдерү рәвешендә әйтмим. Чөнки мондый хәл без яши торган заманның гадәти бер нормасы. Дөресен генә әйткәндә, үземнең дә дөньяга чыгып, кешеләргә күренеп йөрисем килеп тормый. Бигрәк тә һәртөрле тантаналардан, юбилейлардан биздем. Андый җыелышларда мин үземне артык, кирәксез бер кеше итеп тоя башладым.

Картлыкның тагын бер сере мине бик гаҗәпләндерә: гомер узды, ә ничек яшәргә кирәклеген һаман да әле белә алганым юк. Мәсәлән, кешеләргә яхшылык эшләү һәм үзеңә дә алардан шуны көтү, берәүне дә кимсетмәү һәм үз исемеңә дә кер төшермәү, намусны саклау һәм заманга да ярау өчен кеше нишләргә, нинди булырга тиеш — мин менә шуны тәгаен генә белмим. Яши белү — үзе бер осталыктыр, ахрысы. Мәсәлән, теләсә нинди режимга, теләсә кемгә ярар өчен битсез холуй булырга кирәктер. Шул рәвешчә бездә ваемсыз, рәхәт кенә яшәүчеләр азмыни?! Әмма минем бөтен табигатем моңа аякларын терәп каршы тора. Алла сакласын холуй булудан, кемдер кубызына биюдән!..

Ләкин мин үземне һәртөрле кимчелекләрдән азат, камил кеше дип һич тә санамыйм. Юк, минем дә һәрбер адәм баласыныкы шикелле үк гөнаһларым да, үкенечләрем дә бар... Без кичергән заманда чип-чиста, тәп-тәти булып калу мөмкин дә түгел иде. Шулай да бала чагымнан ук күңелемә кереп калган бер ышану мине карт көнемдә дә ничектер юата: кешенең ике иңбашындагы ике фәрештә аның кылган гамәлләрен язып бара икән: уңдагысы — яхшы гамәлләрен, сулдагысы — начар эшләрен... Менә шушы ышанудан чыгып, минем яхшы гамәлләрем начарларына караганда, һичшиксез, күбрәк булгандыр дип әйтә алам.

Минем күңелем бик тиз җәрәхәтләнүчән. Берәрсен ялгыш кына рәнҗетсәм дә, шуның газабын бик авыр кичерәм. Минем үземә дә төрлечә кимсетү, кыерсытуларны күп күрергә туры килде. Моны бик авыр кичерсәм дә, мин ачу саклый, үч ала белмәдем, әмма нахакка рәнҗетүчедән тәмам бизә торган булдым. Хәзер мондый хәлгә юлыгу аеруча көчәйде, шуңа күрә халык арасына чыксам, җан ярасы алмагаем, дип бик куркам... Чөнки үземнең дә берәрсенә ялгыш кына кагылуым бик мөмкин, ә «сдачаны» хәзер тутырып бирәләр.

...Менә шулайрак бүгенгесе көндә бабаегызның халәти рухиясе! Дөнья белән бәйләгән ике генә нәрсә калды — гаҗәпләнү һәм сагыну. Бик гаҗәпләнәм мин фронттан исән-сау кайтуыма. Бик ансат иде бит анда ятып калуы.

Анам догасы мотлак саклап калгандыр — тугыз баладан соң мин исән калып үскән унынчы бала идем. (Унберенчебез энем Илдархан иде, кечкенә чагыбызда безне «ике бөртек» дип кенә йөртәләр иде...)

Мин шушы яшькә җитүемә дә бик гаҗәпләнәм. Сабый чакта каты авырулар кичергәнмен. 17—18 яшьләремдә туберкулез ачылды — иң куркыныч авыру... Бик иртә тән сырхавына җан сырхавы да өстәлде. Асылда, бөтен Совет чорын мин үги бер кеше булып уздырдым.

Ике мәртәбә миңа бик авыр, рухи торгынлык кичерергә туры килде. Берсе аның утызынчы елларның башында — Сталин золымының аеруча көчәйгән чагында булды. Билгеле, мин бу золым белән килешә алмадым...

Икенчесе менә хәзер, шушы соңгы ике-өч елда кичергән торгынлык... Бусы бигрәк тә авырга туры килде. Матди яктан да, мораль яктан да ул мине бик каты сынады. Иң авыры — кешегә ышану бетте. Чөнки картлыкта алдану белән вәгъдәсезлекне кичерү үзенә бер зур газап икән. Тузган йөрәк ничек моны күтәрә дип гаҗәпләнергә генә туры килә.

Шуңа да тагын аеруча искитәрлек янә бер гаҗәпләнүне өстәмичә булмый. Бу — дөньядан киткәннәрне искә төшерү... Алар — газиз атам-анам, иң якын туганнарым, кардәш-ыруларым, бик якын дусларым, бергә йөргән-аралашкан дус-ишләрем, таныш-белешләрем — шулкадәр күп алар — исәпләп бетерерлек кенә түгел. Һәм барысы да бит минем белән бер заманда яшәгәннәр, һәммәсе диярлек, кайчан үлүләренә карамастан, тере төскыяфәтләре белән хәтеремдә саклана, күбесе еш кына төшемә дә керә... Мин һаман да бар әле, ә алар юк инде. Шушы гади генә хакыйкать миндә ни өчендер авыр сагышлы гаҗәпләнү тудыра.

...Әйе, мин еш кына ата-анамны өзелеп сагынам. Алар бик инсафлы, бик диндар кешеләр иде. Фарыз гамәлне үтәү, харам эштән тыелу — менә аларның яшәү кагыйдәләре. Алар рухи дөньялары белән үткән заман кешеләре иде, шул чакларын сагынып яшәделәр, совет заманына ияләшә алмадылар, әмма аның бөтен гаделсезлеген, михнәт-газапларын җитәрлек татып киттеләр. Әҗәлне тыныч кабул иттеләр. Каберләре янәшә... Яннарына барган чагымда еш кына күңелемә килә: алар каберләрендә дә минем бүгенге газапларымны күреп яталардыр төсле. Мин бит алар өчен «ике бөртек»нең берсе идем — хәлбуки атам яшен узган бабай булсам да...

Сагышларым бик татлы, бик ачы, җитеп торыр, ахрысы. Тик бер онытылмас төшемне генә искә төшерәсем ки-

лә. Бәхетлерәк егет чагымда мин Дим өстеннән яланаяк батмыйча атлап баруымны күргән идем... Шушы төшем мине еш кына юата: начар кешене су күтәрмәс иде!

Хәер, миңа үзем турында дөресен язып бетерү мөмкин дә түгел, чөнки бөтен дөресен мин бит әле белмим дә. Минем кем икәнемне әнә хикәяләрем әйтер. Аларны мин акча өчен дә, дан өчен дә язмадым. Аларда саф мин үзем!.. Башкасын бер Ходай үзе ярлыкасын!

Инде соңгы сүз... Бер үк мизгелдә кемнеңдер гомер кояшы бата, кемнеңдер яңа гына чыгып килә. Бу — яшәешнең мәңгелек әйләнеше... Без әзер, без тыныч. Кояшлары яңа гына чыкканнарга бездән хәер-фатыйха! Хушыгыз!

*Октябрь, 1995*

## СИХӘТЛӘНҮ

Русия президенты Борис Ельцин җитди операция кичерде. Гаять җаваплы бу операцияне аның йөрәгенә татар хирургы Ренат Сөләйман улы Акчурин ясады. Җиде сәгать дәвам иткән операция уңышлы үтте дип хәбәр иттеләр соңыннан... Президент инде кыска гына реанимация вакытын үткәреп, бик әйбәт кенә сихәтләнә дә башлады.

...Мин чын ихластан Борис Николаевичның тиз арада тәмам сәламәтләнеп җитүен телим. Йөрәгенең тамырларын татар хирургы Казанда эшләнгән энәләр белән теккәне өчен генә түгел, ә Президент буларак моңарчы эшләгән гамәлләренең яки эшләренең ахырын үзе күрсен өчен дә терелүен телим... Югыйсә аңа хәтле дәүләт белән идарә иткән большевик җитәкчеләрнең берсе дә, Лениннан алып Андроповка хәтле, башлаган эшләренең ахырын күрмичә дөньядан китеп бардылар. Күрсәләр, Русия бер үк бәхетсезлекләрне бәлки кат-кат кичермәс тә иде...

Менә хәзер дә шундый ук хәл кабатлана түгелме соң? Русия күз алдыбызда гаять җитди хәтәр авыру кичерә... Президент авыруы белән ил кичергән авыру арасында тирән охшашлык һәм уртаклык бар кебек... Ельцин власть өчен көрәшә-көрәшә йөрәген бетерде, ә илебез аның аркасында әнә нинди авыр хәлгә юлыкты. Берсенә әҗәл тырнагыннан ычкынырга кирәк булса, икенчесенә һәлакәттән ничек тә котылырга кирәктер бит инде.

...Язмышлар уртаклыгын Президент үзе дә ачык сизде бугай, операциядән соң күзләрен ачу белән үк, ул бик

хикмәтле беренче Указын да яздырды. Киләсе елдан башлап Октябрь революциясе көнен, 7 ноябрьне, «Килешү һәм татулашу көне» дип бәйрәм итәргә!.. Сүз дә юк, изге теләк... һәм бик кирәкле дә. Мәгәр килешү белән татулашу өчен изге теләк кенә җитәчәкме? Кем көчлерәк — теләкме, әллә чынбарлыкмы?.. Русия бит капма-каршы ике лагерьга аерылды. Берсендә — халыкның абсолют күпчелеге, икенчесендә кечкенә азчылык, ә арада үтеп булмаслык тирән упкын... Азчылык кулында власть белән байлык... Күпчелекнең хәлен әйтеп торасы да юк — ул инде даими бөлгенлектән, гаделсезлектән, өметсезлектән шартлар дәрәҗәгә җитеп килә. Ә азчылыкның аңарда гаме юк — ул әнә һаман байлык җыюны да хакимлек итүне генә белә.

Менә шушы ут белән судай кушыла алмас, бер-берсенә гаять дошман ике лагерьны килештерү мөмкинме?.. Моның өчен нәрсә эшләргә кирәк?.. Беренче нәүбәттә хәерчелек белән байлык арасындагы төпсез упкынны бик нык кечерәйтергә, ягъни күпчелек халыкның матди хәлен, көнкүреш шартларын бермә-бер яхшыртырга кирәктер, мөгаен. Халык, шуны өмет итеп, сайлау вакытында тавышын да господин Ельцинга бирде. Ул инде кире артка чигенергә, совет заманына кайтырга теләми, хәзерге базар мөнәсәбәтләренә дә башы белән чумды, бата-калка йөзеп тә маташа. Бүген аңа иң кирәге — адәм төсле әйбәт кенә яшәр өчен хезмәт хакын яки пенсиясен җитәрлек күләмдә һәм вакытында ала бару, дәүләткә ышанып тапшырган, ләкин реформа башында ук йотылган акчасын хәзерге микъдарда кире кайтару һәм, ниһаять, 70—80 ел буена җыелып килгән ил байлыгыннан үзенә тиешле өлешне таләп итү... (Чубайс өләшкән ваучер ул, гафу итегез, этләргә ыргыткан коры сөяк кенә.)

Мөхтәрәм Ельцин икенче тапкыр сайланыр алдыннан Русия буйлап халыкка бик күп нәрсәләр вәгъдә итеп йөрде. Ул власть кешесе, власть аның өчен яшәү мәгънәсе. Ул шуңа икенче тапкыр йөрәген имгәтеп булса да иреште. Хәзер инде биргән вәгъдәләрен үтәр вакыт җитте. Җитди авырудан соң, кешедә еш кына миһербанлык уяна... Борис Николаевичның да операциядән котылгач та, «Килешү белән татулашу» турында указ яздыруы, ихтимал, шундый үзгәрешнең бер галәмәтедер. Мәгәр олы максат өчен миһербанлы (добродетель) булу гына җитәме? Халык зарыгып көткәнне бирә алыр өчен хәзинәдә нидер булырга тиештер бит? Кайда ул ил байлыгы, кайда халык акчасы? Һәммәсе дә «яңа урыслар» кулына

кереп бетте түгелме? (Мин аларны «кинәт байлар» дип атар идем. Бердән, аларның бик күбесе һәм иң байлары чын урыс түгел, икенчедән, урламыйча, таламыйча икеөч ел эчендә котырып баю мөмкин дә түгел.) Ә бу тоташ бер мафиозга әверелүчеләр җаннарын бирсә бирерләр, әмма малларын бирмәячәкләр. Хәер, җаннарын да саклаячаклар. Дәүләт структурасының бөтен баскычларында түбәннән алып иң югарыга кадәр шулар үзләре яки шуларның кешеләре утыралар. Ярамаганны кысып чыгаралар, кирәклене табып утырталар. Әнә Чечня сугышын туктаткан ипсез генералны бик ипле бер бизнесмен белән алыштырдылар ич! Җәнҗал чыгудан да куркып тормадылар... Сәясәт оят дигән нәрсәне белми ул!

Билгеле ки, хосусый милеккә күчкәч, байның да, ярлының да булуы бик табигый. Бик борыннан шулай килә ул. Тик менә хакимият кем кулында, кемгә хезмәт итә ул — мәсьәлә шунда. Хәзерге режим баштан ук кеше зарарына эшли башлады. Җәмгыятьтә ничектер кинәт кенә башбаштаклык, җавапсызлык, гаделсезлек, аеруча җинаятьчелек бик нык көчәеп китте... Закон эшләми, закон көчсез... закон белән законсызлыкны аерып та булмый — гүя алар бергә үрелеп баралар... Бер генә зур җинаятьнең дә ачылганы юк.

Бу инде хаос — буталып бетү, һәм шушы хаосның озаграк саклануы кемнәргәдер бик кирәктер дә, ахрысы. Русиянең язмышында ниндидер читтәге көчләрнең дә кулы уйный бугай. Шулайрак сизелә... Карагыз, ашаган-эчкәнебезнең бик күбесе, өстебездәге киемнәрнең барысы да диярлек читтән агылып килә, ә без шуңа кытлык бетте, чиратлар бетте дип мактанган булабыз. (Ярый әле, ипи, бәрәңге, аракы үзебезнеке, шөкер!) Ләкин, миңа калса, читләрнең бик тирәндә яткан зур сәяси максатлары да бар булса кирәк.

Мәгәр иң гаҗәпләндергәне — урыс халкы үзе. Бөек әдәбият, бөек сәнгать тудырган бу халык кыйбласын югалтты, күрәсең. Әллә күп эчүдән, әллә күп бәхәсләшүдән гүя миңгерәүләнеп, уңы белән сулын аера алмый башлады. Теләсә нинди коткыга бирелүчән, теләсә кемгә иярүчән — соңгы сайлаулар моны ачык күрсәтте. (Тавышын кемнәргә генә бирмәде?) Иң аянычы — аның шовинизм сөременнән һаман да айный алганы юк. Бигрәк тә сәясәтне кәсеп иткән төрле типтагы ата шовинистлар Русиянең бөтенлеген саклау сылтавы белән элеге искереп-тузып беткән «бөек мәмләкәтчелек» идеясен яңадан ничек тә куертырга һәм файдаланырга тырыша-

лар. Чечня сугышы хурлыклы җиңелү белән беткәч, алар шул ачудан башка суверен республикаларны, аеруча Татарстанны, төрлечә кысмакчы булалар. (Гүя аларга яңа Чечня кирәк!) Чынлыкта исә Русияне таралып китүдән нәкъ шушы тук вә тотрыклы республикалар саклап тордылар да. Тарала калса, Русия Советлар Союзы шикелле үк, бары урысларның үзләре аркасында гына таралачак. Чамасыз байлыклар өстендә утырган Ерак Көнчыгыш, Себер регионнары киләчәктә дә хәерчелектән, ачлыктан котыла алмаслар. Мәскәү империясен мотлак ташлап чыгачаклар.

...Гафу, мин бераз читкә тайпылдым. Сүз бит Президент игълан иткән килешү белән татулашу турында бара иде. Ирешеп булачакмы шуңа?

Миңа калса, моның бердәнбер чарасы — гаепне тану һәм хаталарны төзәтү. Ап-ачык мәгълүм ки, Русиянең һәр җәһәттән гаять авыр хәлдә калуы — ул Ельцин хакимияте тарафыннан үткәрелгән икътисади сәясәт нәтиҗәсе. Бер сүз белән генә әйткәндә, реформа аркасында барысы да. Ул китергән бетмәс-төкәнмәс бәхетсезлекләр, бәла-казалар өстебезгә гүя ишелеп төште. Шулар өчен кемдер җавап тотарга тиеш ләбаса! Шуннан соң гына хаталарны төзәтү юлы белән халыкка югалган социаль гаделлекне кайтару бәлки мөмкин булыр. Моның өчен алдау һәм талау юлы белән хосусый кулларга күчкән ил байлыгын, читкә озатылган харам акчаларны кире дәүләткә кайтару мәсьәләсе хәл ителергә тиеш. Ниһаять, байлык өчен илдә купкан вәхши-кансыз җинаятьчелекне ничек кенә булса да авызлыкларга кирәктер. Закон һәм әхлак хакимлек итәргә тиеш җәмгыятьтә!

Кыскасы, моннан соң да бөтен байлык мафиозга әйләнгән «кинәт байлар» кулында калса, ә халыкның күпчелеге һаман да төпсез бөлгенлектән чыга алмыйча интексә, бернинди килешү дә, татулашу да була алмаячак. Президент үзе дә, шәт, моны аңлый торгандыр дип ышанасы килә. Ул бит коммунизм мәктәбен үткән кеше!

...Мин үзем Ельцин режимына һәрвакытта каршы булдым. Әмма бүгенге шартларда аның Президент булып саклануын һәм тизрәк сихәтләнүен телим. Чөнки илдәге вакыйгалар артык хәвефлегә әйләнеп бара. Күптән властька омтылучы, диктатура яклы тагы да хәтәррәк кешеләрнең максатларына ирешүләре бик мөмкин. Моңа юл куелмасын иде. Яхшымы-начармы, безгә күпмедер хөрлек биргән демократияне сакларга кирәк.

*«Татарстан яшьләре», 1996*

## ХАИНЛЕК

Русия генераллары Ичкерия Президенты Җәүһәр Дудаевны хаинләрчә үтерделәр. Моның өчен вакытны да бик белеп сайладылар. Президент Ельцин сугышны туктатырга әмер биреп, Дудаев белән сөйләшергә ризалыгын белдереп, Кытайга китеп баргач кына, бу кабахәт явызлыкларын эшләделәр... Ихтимал, алар Русия Президентын моның ише пычрак эштән читтә калдырырга теләгәннәрдер... Әмма шуңа да карамастан Дудаевның үтерелүе, беренче нәүбәттә, Президент Ельцин өстенә төшә. Белә бит ул генералларының кемнәр икәнен... Алыгыз сез аның оборона министрын гына... Төрки халыкларны фашистларча кыралмаган бу «герой» Президент әйткәнне дә еш кына үзе теләгәнчә борып, гел генә диярлек үз юлын үткәреп килде. Хәтта Ельцинның соңгы әмере белән дә хисаплашмыйча, сугышны һаман дәвам иттерде.

Бу агрессив сугышның бөтен канлы юлы һәртөрле шовинистик ялганнардан чистартылып, һәр көненә кадәр бик тәфсилләп язылыр әле берзаман. Хәзер исә аның иң фаҗигале бер мизгеленә — Дудаевның көтелмәгән һәлакәтенә генә тукталасы килә. Ни өчен сугышны туктатырга уйлагач кына аны үтерү кирәк булды?..

...Мәгълүм ки, сугышның башыннан ук агрессиягә каршы күтәрелгән Ичкерия халкының кыю, батыр җитәкчесен бетерү, юк итү урыс генераллары алдына төп бурыч итеп куелган иде. Аңа каршы шунда ук «җинаять эше» дә кузгатылды... Ельцин үзе дә бер чыгышында «Дудаевны атарга кирәк» дип әйткән иде. Бөтен сугыш буена күзләрен кан баскан генераллар Президентның шушы боерыгын үтәргә бик тырышсалар да, Дудаев алар өчен ни гаҗәптер һич тотылмас һәм бирешмәс булып кала бирде.

Хәзер инде хәл үзгәрде: сайлаулар якынлаша, яңадан сайланасы бар, ә чечен сугышы һаман да дәвам итсә, икенче тапкыр Президент булуы бик тә икеле. Менә ни өчен Ельцин сугышны бөтенләй туктату турында Дудаев белән теләсә-теләмәсә дә сөйләшүләр башларга тиеш булды. Чөнки бүтән чарасы калмады, чөнки аның да карары халыкларның күптән ялварып, зарыгып көткән кайнар теләге иде... Әмма бу теләккә ирешү өчен, Президент Ельцин Дудаевны, һичшиксез, сакларга да тиеш иде. Сөйләшүләр бит ике исән-сау кеше арасында гына булырга мөмкин... Җәүһәр Дудаев та бәйсезлеккә омтылу-

чы горур бер халыкның мөхтәрәм Президенты — ә президентлар җитди сөйләшүләр башлар алдыннан бер-берсенең иминлеген кайгыртырга тиешләр... Аннары шуны да истән чыгармаска кирәк, алар арасындагы сөйләшүләрдә арадашчы булуны Нурсолтан Назарбаев һәм Минтимер Шәймиев кебек, илләр күзендә танылган дәүләт җитәкчеләре үз өсләренә алдылар... Бик мөһим шушы факт үзе генә дә Дудаевның иминлеген саклауны таләп итә түгелме соң?!

Кыскасы, Ичкерия Президенты Дудаевны үтерү ул Русия халыкларын, дөнья җәмәгатьчелеген, кан коюны туктатуда ярдәм итәргә әзер торучыларны бик әшәке алдау булып чыкты. Кемгә кирәк булды бу явызлык?.. Сөйләшүләрне өзәргә, сугышны дәвам иттерергә теләүчеләр өченме?.. Андыйлар Ельцин тирәсендә дә, генераллар арасында да аз түгел, чөнки сугыш — Ичкерияне вату-җимерү, халкын кыру алар өчен байлык китерә торган шәп бер кәсепкә әйләнде... Шушы хәлләрне яхшы белгән Президент Ельцин үзенең карательләренә катгый кисәтү ясаса, Дудаевны, бәлки, саклап та калган булыр иде. Әмма ул үзе моны теләде микән?!

Ә менә сизгерлеген бер вакытта да югалтмаган Дудаев бу юлы Ельцинның бөтен дөньяга белдергән сүзләренә ышанып һәлак тә булды, минемчә... Ул бит аңа каршы башлаган бу кирәксез, мәгънәсез сугышның, урыс халкы тарафыннан да ләгънәт ителгәнен бик яхшы ишетеп-күреп тора... Шуңа күрә дә Русия Президентының сугышны туктату турындагы сүзләрен ишеткәч тә, чын ихластан аңа ышанып, менә нәрсә ди: «Сөйләшүләр өчен әгәр мине Мәскәүгә чакырсалар, мин, әлбәттә, барачакмын; әгәр дә Ельцин үзе Ичкериягә килсә, без аны иң кадерле кунагыбыз итеп каршы алачакбыз!..» (Моны күптән түгел Мәскәү телевидениесе «Совершенно секретно» дигән тапшыруда күрсәтте.)

Ә Русия Президенты Дудаевның үтерелүен ишеткәч, гәзитләрнең хәбәр итүенә караганда, болай дигән:

— Дудаев сугышырга теләде, ул Русиягә каршы сугыш башлады...

Димәк, Ельцин Дудаевның үтерелүен яклый?!

Димәк, аның белән сөйләшүләр башларга ризалык белдерүе сайлаулар алдыннан әйтелгән чираттагы ялган гына?! Әмма Русия халыкларында бу мәкерле ялган Президент Ельцинга карата соңгы ышануны да бөтенләйгә «үтермәс» микән — Ичкерия фаҗигасе аларны кемнең кем икәнлеген таный белергә бик нык өйрәтте.

* * *

Янә бик мөһим бер өстәмә: әгәр киләчәктә сайлаулардан соң сәясәт (ягъни власть өчен көрәш) әхлак нормаларыннан, гаделлек законнарыннан алда йөрсә, без беркайчан да адәм рәтле тормыш күрмәячәкбез. Кем генә сайланса да... Ичкерия — шуның ачык мисалы. Анда кем власте өстенлек итәргә тиеш — Дудаевныкымы, Ельциннныкымы?.. Менә шуны хәл итәр өчен башланган сугыш ел ярым дәвамында 70—80 мең (генерал Лебедь әйтүенчә) Ичкерия халкын кырып салды, авыл-шәһәрләрен җимереп бетерде, ничәмә мең урыс егетләренең башына җитте яки аяксыз-кулсыз калдырды. Ә Русиянең үзенә китергән бөлгенлек һәм казаны исәпләп бетерерлек тә түгел... Янәсе, Русия бөтенлеген саклау өчен кирәк булган бу яман сугыш?! Мәгънәсез сылтау гына бу... Киресенчә, әхлактан, гаделлектән мәхрүм сәясәт Русияне ахыр чиктә эчтән череп таркалуга китерәчәк.

*«Мәдәни җомга», 1996*

## БЕЗ ДӘ БАРДЫК ТӨРКИЯГӘ...

...Төркияне күрәсе килү безнең күңелләрдә күптән яши иде инде. Мин, мәсәлән, соңгы 4—5 елда гел шул хакта уйланып йөрдем.

Ни өчен Төркия безне үзенә тарта — Израиль яһүдләрне тарткан шикелле?.. Хәер, яһүднең Израильгә барасы килеп торуы аңлашыла, чөнки алар җир йөзенә шуннан таралган халык... Безнең татарларга килгәндә, алар бит Төркиядән Идел-Урал буйларына күчеп утырган халык түгел. Әмма тарта безне Төркия — ерактагы кадерле Ватаныбыз шикелле тарта.

Сәбәпләрен аңлавы читен түгел... Төркия бердәнбер мөстәкыйль, бәйсез төрки мәмләкәт — кайчандыр Якын Көнчыгышны һәм ярты Аурупаны кулында тоткан көчле Осман империясе... Империя үзе бетсә дә, тарихта шанлы исеме һаман саклана. Төрекләр безнең дин кардәшләребез, телләре дә якын — бер тамырдан. Шуңа күрә гасырлар буе дине ят, теле ят урыслар империясендә изелеп яшәүче татар халкының һәрвакытта рухи вә мәгънәви таяныч эзләп, Төркиягә тартылуы бер дә гаҗәп түгел... Мин тарихка тирән керә алмыйм, һәм бу очракта әллә ни кирәген дә тапмыйм. Әмма безнең халыкның Төркия белән аеруча мавыккан бер чорын искә төшермичә булмый... Мин моны бераз гына ишетеп-кү-

реп тә, аннары кайбер чыганаклардан укып та беләм. Бу чор үткән гасырның соңгы чирегеннән алып беренче дөнья сугышы башланганчыга кадәрге арага туры килә. Шушы вакыт эчендә татарларның Төркия белән мавыгуы бик көчәя, барып-кайтып йөрүләр ешая, укырга китүчеләр күбәя, хәтта бөтенләй күчеп китүчеләр дә шул елларда арта башлый... Кыскасы, төреккә иярү, төректән күчерү, телен белергә, әдәбиятын укырга тырышу гомуми бер гадәткә керә башлаган иде. Моның кайбер галәмәтләрен мин дә күреп калдым. Әйтик, безнең бер бүлмәбездә фатир торучы конторщик Мәхмүт абый төрек гәзитләрен һәм китапларын алдыра иде. Чахотка белән авыручы бу бик әйбәт абый туган авылына китеп үлгәч, аның мулла абзасы килеп, кием-салымнарын алып китккән чакта шул төрек китапларының шактыен «боларын шәкертләр укысыннар» дип, безгә калдырган да иде. Мин аларны Казанга киткәнче саклаган да булган идем, тик юньләп укый гына алмадым. Шулай ук малай чагыбызда энем белән икәү төрекнең бездә дә тарала башлаган кара чуклы зәңгәр фәсен дә киеп йөрдек... Аннары Каргалыда бабакайларның түр өендәге стенада безнең кебек фәс кигән, кылычына таянып төшкән бик чибәр төрек әфисәре — Әнвәр пашаның рәсеме дә эленеп тора иде...

...Болар минем үз күзем белән күргәннәрем, шуларга инде соңрак укып белгәннәр дә өстәлде. Иң элек шуны әйтергә кирәк, төрекнең безгә никадәр нык йогынты ясавын шул елларда туган балаларга кушылган исемнәрдән дә күреп була. Әнә шул ук Әнвәр, Шәүкәт, Җәүдәт, Мидхәт, Рифгать кебек исемнәр барысы да төрекләрдән... Телебездә дә төрекчелек шактый ук сизелә иде — «бәрадәр» (ир туган), «чук-чук» (күп), «тәшәккер» (рәхмәт)... сүзләрен еш кына куллана башлаган идек. Фатих Кәриминең «Истанбул мәктүпләре» яртылаш төрекчә язылган дип әйтергә мөмкин... Бу бик кызыклы һәм бик кыйммәтле китап... 1912 елны Болгария-Төркия сугышы барган чакта, Закир Рәмиев (Дәрдемәнд) киңәше белән «Вакыт» гәзитенең мөхәррире Фатих Кәрими махсус хәбәрче булып үзе Истанбулга китә. Һәм шуннан дүрт ай буена сугышның барышы турында да, Төркиянең гомуми хәле хакында да «Вакыт»ка озын-озын хатлар җибәреп тора. Шул хатларның җыелмасы 1913 елны ук 450 битлек китап булып басылып та чыга. Фатих Кәрими үзенең «Мәктүпләр»ендә Төркиянең шул чактагы эчке һәм тышкы хәлләрен бик тулы, ачык итеп яза. Мәгълүм булганча, Төркия ул сугышта бик каты җиңе-

лә. Һәм җиңелүнең төп сәбәбе — Төркиянең һәр җәһәттән артта калуында — менә шуны Фатих Кәрими бик объектив рәвештә ачып сала. Ул төрек хөкүмәтенең иң югары министрлары, армиянең башкомандующие белән очрашып сөйләшә, төрекнең төрле дәрәҗәдәге зыялылары белән фикер алыша, гомумән, күп кешеләр белән аралаша, аңлаша, шуңа күрә аның язганнары бик дәлилле һәм ышандырырлык та! Ул фронтка да бара, андагы хәлләрне дә күреп кайта... Билгеле, Фатих Кәрими язганнарның монда йөздән берен дә китерү мөмкин түгел. Әмма аның журналист буларак гаять зур өлгерлек күрсәтүенә, күп эшләвенә һәм гадел, тирән фикер йөртүенә чын-чынлап гаҗәпләнергә генә туры килә...

Мәктүпләрне укыгач, ул чакта татарларның фикер үсеше җәһәтеннән төрекләрдән шактый өстен торганлыгын күрәсең. Өстәп шуны да әйтергә кирәк — Төркиянең авыр хәлен аңлап, безнең татар хатын-кызларыннан һәм ирләрдән ирекле рәвештә төрекләргә ярдәмгә баручылар да булган. Китапта аларның исемнәре аталган һәм фоторәсемнәре дә бирелгән. Менә алар мәҗрух төрек солдатларын карауучы «шәфкать туташлары»: Өммегөлсем ханым Камалова (Чистайдан), Рокыя ханым Юнысова (Петербургтан), Мәрьям ханым Паташова (Ростов-Доннан), Мәрьям ханым Якупова (Ташкенттан). Ирләрдән сугыш башлангач ирекле булып баручылар: Гариф Кәримов (Фатих Кәримнең энесе), Шәриф Әхмәтҗанов (башкорт Манатов), Кәбир Бәкер, Фатих Рәхими — тагын берничә кешенең исеме атала. Мәсәлән, Йосыф Акчура — ләкин ул инде сугыш башлангач ук барган булырга тиеш.

Татарларның Төркиягә барып йөрүләре һәм урнашып та калулары Фатих Кәримигә күптән билгеле, әлбәттә. Шуңа күрә ул «Истанбул мәктүпләре»ндә «Төркиядә татарлар» дигән махсус бер бүлек тә биргән... Ул заманда Русиядән барган татарларга төрекләрнең мөнәсәбәте вә карашлары нинди булган — менә шул хакта яза Кәрими. Бу гаять кызыклы һәм гыйбрәтле... Кәрими язганнарны үз сүзем белән аңлата башласам, бүгенге укучының ышанмавы бик мөмкин. Шул сәбәпле хәбәрче әдипнең үз сүзләрен генә чүпләп китермәкче булам.

Төркиягә барып урнашкан татарларның нәрсә эшләүләрен, ничек яшәүләрен, бигрәк тә үзләрен ничек тотуларын күргән төрекләрнең аларга мөнәсәбәтләре турында менә ниләр яза ул: «Гомумиятлә төрекләрнең татарларга назарлары (карашлары) соң вакытларда бик күп үзгәргән. Татарларга рухлы, тырыш, фәгъгал (эшлекле) дип карыйлар. Русия татарларының ибтидаи тәгълим,

ана теле, икътисад җәмгыятьләре, кызлар укыту, әдәбият ахшамлары, милли театр, сайлау эшләре, мәдрәсәләр ислахы (реформасы), урыс мәктәпләренә керүләре кебек эшләренә төрекләр бик зур әһәмият биреп карыйлар. Бу мәдәни хәрәкәтләрнең нәтиҗәсе татарлар өчен бик хәерле булачак дип өмит итәләр».

...Шушыннан соң Фатих әфәнде төрекләрнең үз сүзләрен китерә: «Әхвале иҗтимагыя вә икътисадиядә сез шимали төрекләр (ягъни татарлар) без госманлы төрекләреннән һич шөбһәсез алдасыз...» Инде автор үзе болай ди: «Төрекләрнең бәгъзеләре үзләренең мәдәни хәрәкәтләрендә, иҗтимагый вә икътисади эшләренең төзәлүендә Русия мөселманнарыннан ярдәм көтәләр, без алардан гыйбрәт алырга мохтаҗмыз, диләр».

Төрек матбугатының да Русия мөселманнарына карашы уңай якка үзгәргәнен әйтеп үтә Фатих Кәрими. Хәтта бер гәзитнең түбәндәге сүзләрен дә китерә: «Кафкасия вә Казан төрекләре (татарлары) бүген тәрәккыяты маддияне кабул итүдә ихтималки японнар кадәр икътидар (ягъни булдыра алуларын) күрсәтмәктәдерләр».

Бигрәк тә безнең хатын-кызларыбыз төрекләрдә чын соклану һәм гаҗәпләнү тудырган икән. Менә ниләр яза Кәрими: «Дарелфөнүн таләбәсе (студенткалары) булган дүрт кызымызның үз башларына, үз теләкләре илә Истанбул тикле җиргә килеп, бушлай мәҗрухлар карарга керешүләре, Истанбул урамнарында качмаенча йөреп, лөзүме күрелгәндә (кирәк чакта) ирләр илә сөйләшеп, ирләр мәҗлесендә булып, үзләренең гыйффәт вә гыйсмәтләренә (намусларына) зәррә кадәр халәл (кимчелек) китермәүләре вә боннар хозурында төрекләр үзләрен Аурупа ханымнары хозурындагы шикелле бик тәртипле тотарга мәҗбүрият хис итүләре монда һәркемне хәйран калдырды».

...Менә шуларны язганнан соң, Фатих Кәриминең үзе ясаган нәтиҗәләре бик кызыклы. «Төрекләрнең татарларга болай яхшы караулары анларның (ягъни төрекләрнең) Русиягә хөрмәт вә мәхәббәтләре артуга бик зур сәбәп буладыр: «Бакыңыз, Русия эчендә ничек тәрәккый итәргә мөмкин, бакыңыз, Русия мәдәнияте үзенең кул астындагы мөселманнарга ничек яхшы тәэсир иткән диләр».

Фатих Кәриминең бу язганнары безнең өчен менә хәзер зур яңалык. Ләкин бер нәрсәне бик ачык әйтергә кирәк: ул заманнарда татарларның төрекләрдән алга чыгуы — урыс монархиясенең аларга тәрәккый итәр өчен махсус шартлар тудыруында түгел, әлбәттә. Бернинди

шартлар да, хокуклар да юк, киресенчә, татар-төрек мөнәсәбәтләренә урыс түрәләре һәм карагруһчылар тарафыннан панисламизм, пантюркизм дип яла ягарга тырышу гына бар (Фатих Кәрими үзе дә шулай дип яза). Әмма безнең тәрәккый итүебезгә көчле уңай йогынты ясаган бер факторны әйтмичә булмый. Ул — урысның бөек әдәбияты, бөек сәнгате, гимназияләре, университетлары, ниһаять, Русиядә туган көчле демократик хәрәкәт, фикер хөрлеге — менә шулар ача татарның да күзен, шулар аңа юнәлеш бирә, юл күрсәтә... Татар үзенә кыйбланы шәрыкка карап түгел, ә Русия аша гарепкә карап сайлый... Һәм моның нигезендә татарларда да капиталистик мөнәсәбәтләрнең көчәюе һәм хосусый байлыкның артуы ята... Әгәр Октябрь революциясе бер 20—25 ел гына булмыйча торса, татар халкы искиткеч алга киткән булыр иде, һәм төрекләргә генә түгел, бик күпләргә үрнәк була алыр иде.

Төркия турында тагын бер язманы искә төшерә алам. Бу — Таһир Ильясиның кулъязмасы. 1922 елның җәендә Уфадагы Диния нәзарәте Гобәйдулла Буби белән Таһир Ильясины бездәге ачларга матди ярдәм җыяр өчен Төркия һәм Мисырга җибәрә. Төркиянең дә бу шулай ук бик авыр чагы була. Беренче бөтендөнья сугышында Германия яклы булып сугышкан Төркияне союзниклар оккупациялиләр. Истанбулда Англия, Франция, Италия гаскәрләре, Урта диңгез буйларында греклар армиясе... Таһир Ильяси ярдәм җыяр өчен Мисырга китәргә тиеш, ләкин оккупация властьлары аңа рөхсәт итмиләр. Шуның аркасында ул өч ай вакытын Истанбулда гына үткәрә. Күп йөри, күп аралаша, күпне күрә. Менә шуларның һәммәсен дә көндәлек рәвешендә язып бара. Иң мөһиме — ул анда чакта Төркия язмышын үзгәрткән зур вакыйга — Мостафа Кемаль җитәкчелегендә демократик инкыйлаб булуын әйтергә кирәк. Солтан хакимияте бетерелә, җөмһүрият игълан ителә... Менә шушы вакыйгалар да Таһир Ильяси язмасында тасвир ителгән. Бу язма шул чактагы Төркия хәлләрен аңлау өчен бик кыйммәтле чыганак. Миңа калса, ул язма төрекләрне дә кызыксындырырга тиеш.

Сүз күпкә китте, ләкин аңлатасым килә: монда язганнарым — Төркия белән кызыксынуымның миндә күптән сакланып яткан җирлеге ул... Әлбәттә, барасы, күрәсе, beләсе килү бик табигый теләк иде. Нинди ил соң Төркия, табигате, халкы, яшәү шартлары нинди аның — моны бит үз күзләрең белән күреп кенә белеп була... Анда бит безнең татарлар да аз түгел, бик олы шәхеслә-

ребез шунда китеп кенә большевиклар золымыннан котылып калдылар, үзләренә гүя икенче Ватан таптылар... Әмма совет заманында нәкъ менә Төркиягә бара алу татар язучысы өчен кысыр хыял гына иде. Мәрхүм Салих Батталның бер әйткән сүзе искә төшә. Татар язучысы чит илләрне сугыш вакытында солдат булып кына күрә ала, дигән иде ул... Ләкин солдат булып та миңа чит илне күрергә туры килмәде. Сугышны мин Балтыйк буенда бетердем. Мәгәр Латвия, Литвалар чит илдән саналмый иде инде... Шулай да Латвиянең ялгыз утарларын, җыйнак, чиста шәһәрләрен күрү дә минем өчен бик кызыклы булган иде... Тик, кызганыч ки, Риганы күрү генә ул чакта насыйп булмады. Бары алтмышынчы еллардан башлап кына үзенең матурлыгы, чисталыгы белән мине тәмам әсир иткән каланы күрергә туры килде миңа... Күп йөрдем мин ул калага, әле дә аны сагынам, мәгәр Рига да безнең өчен хәзер чит илнең башкаласы — аңа да юллар киселде. Ә чын мәгънәсендәге чит ил каласын — Истанбулны сугыш бетеп 50 ел узгач кына күрү насыйп булды.

Шулай итеп, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев инициативасы, Татарстан Премьер-министр урынбасары Илгиз Хәйруллин булышлыгы, Язучылар берлегендәге егет-кызларның тырышлыгы белән без тиз генә җыенып, Казан аэропортыннан Истанбулга оча торган самолетка утырып, ниһаять, һавага күтәрелдек...

* * *

Менә безне, самолеттан каушый-каушый җитәкләшеп төшкән карт белән карчыкны, Истанбул аэропортында «Татурос» президенты Рево Рамазан улы Идиятуллин үзе һәм аның егетләре каршы алды: шәп машиналарда шәһәрдәге иң дәрәҗәле «Президент» кунакханәсенә илтеп урнаштырдылар. Чәйләр эчкәннән соң, Рево әфәнде үз машинасында Истанбул урамнары буйлап безгә борынгы каланы күрсәтеп тә йөретте. Безнең бәхеткә көне дә әйбәт иде.

...Кыскасы, Истанбулга аяк баскан сәгатебездән алып киткән көнебезгә кадәр без «Татурос» кунагы булдык. Һәр көнне иртән аның машинасы, берәр кешесе белән килеп, безне теләгән җиребезгә илтеп, тарихи урыннарны күрсәтеп йөретте (йөртүчеләребез башта Сергач татары Рөстәм әфәнде, аннары Иргиш исемле Болгариядән кайткан төрек егете булды). Рево Рамазан улы үзе дә, эше бик тыгыз булуга карамастан, безне онытып торма-

ды. Соңгы көнебездә дә ул җәмәгате белән кунакханәбезгә килеп, бай ресторанда матур гына сыйланып, озак кына сөйләшеп тә утырдык... Менә шуларның барысы өчен дә без «Татурос» ширкәтенә һәм аның президенты Рево әфәнде Идиятуллинга, төрекчәләп әйткәндә, тәшәккүрдән гаҗизбез.

Әмма безнең сәяхәтебезне икенче көнне үк инде һаваның яман начарланып китүе бик нык бозды. Көчле җил купты, салкын яңгыр гел явып торды, урамнарда йөрү һич мөмкин булмады. Гаяз Исхакый каберенә барырга чыккач та, кире борылып кайтырга туры килде. Алты көнебезнең дүртесе әнә шундый бик алама булды, тик соңгы ике көнебез генә кояшлы, җылы булып калды. Төркияне күрәсең килсә, ноябрь ахырларында барма икән...

* * *

Әмма бу һич тә үкенү түгел... Без җил-яңгырда да йөрүдән туктамадык, һәр көнне кая да булса бардык, Истанбулның күп җирләрен машина тәрәзәсеннән күреп уздык. Ләкин кайларда булуыбызны, ниләр күрүебезне язарга керешкәнче, бер бик мөһим вакыйга турында кыскача гына әйтеп китү кирәктер: без килгәннең икенче көнендә үк Истанбулда төрки халыкларның дүрт көнлек зур симпозиумы ачылды. Аңа элеккеге Советлар Союзындагы һәм хәзерге Русиядәге төрки халыклардан вәкилләр чакырылган булган. Безнең Татарстаннан да ике рәсми вәкил килгән икән. Өченче булып мондагы «Татурос» җитәкчесе Рево Идиятуллин да катнашачак... Менә аның әйтүе беләндер инде, миңа да чакыру кәгазе китерделәр.

Сөләймания мәчетендә үткәреләчәк симпозиумның беренче ачылу утырышында без дә булдык. Төшке ашка хәтле мин шундагы чыгышларны бик игътибар белән тыңлап утырдым. Утырышны кыскача нотык белән төрек галиме, доктор, профессор Туран Язган ачты. Аңардан соң төрекләрнең өч министры чыгыш ясады (берсе хәзерге министр, икесе — кайчандыр булганнардан). Алардан соң төрки җөмһүриятләрдән килгәннәр «чыга» башладылар.

Сүз нәрсә хакында?.. Чыгышларының төп юнәлеше — төрки халыкларны икътисади, иҗтимагый, мәдәни җәһәттән бер-берсенә якынайту турында иде, миңа калса. Төрки булып саналган халыклар җир йөзендә, дөрес ишеткән булсам, 250 миллионга җитә икән. Менә шуларны ничектер берләштерергә, үзенә бер төркиләр дөнь-

ясы итеп оештырырга кирәк икән (мәсәлән, гарәпләр дөньясы шикелле иттереп). Бу төркиләр дөньясы үз эченә үзбәк-казакълардан алып чуваш-якутларга кадәр алырга тиеш икән. Мондый идеяне әлеге Төркия министрлары аеруча нык куәтләделәр. Шул чагында гына төрки халыклар һәр җәһәттән алга китәчәк һәм дөнья күләмендә үзләрен танытачаклар икән!

...Бик мавыктыргыч шәп идея! — әгәр барып чыкса?! Әлбәттә, төркиләрнең болай берләшүе Төркия канаты астында булырга тиештер инде... Ул бит инде иң алга киткән, иң көчле төрки дәүләт — барыбыз да аңа карап торабыз бүгенгесе көндә. Мәгәр алар өндәгән «төрки дөнья»га керү дә, кергәч ниндирәк урын алу да һәммә төркиләр өчен дә бертөсле генә булмастыр, ахрысы... Чөнки төркиләр үзләре күп җәһәттән бигрәк тә Төркиягә якын тору ягыннан бик төрлеләр (мәсәлән, азәрбайҗаннар белән чувашлар кебек). Әмма төп мәсьәлә башкада: бездәге төрки халыкларның статуслары хәзерге шартларда бер түгел. Әйтик, Русиядән өзелгән, тулы бәйсезлеккә ирешкән азәрбайҗан, үзбәк, казакълар өчен «төрки дөнья»га керүе дә, кергәч, саннарына һәм байлыкларына карап лаеклы урын алулары да җиңелрәк булачак. Ә менә Русия эчендә торып калганнар өчен «төрки дөнья»га керү ансат булмаячак. Монда Русия белән бик нык хисаплашырга туры киләчәк. Үзендәге төркиләрнең Төркия кочагына омтылуларына ул, әлбәттә, тыныч кына карап тормаячак. Аннары Төркия дә үзенең хәвефсезлеге өчен күптәнге көндәше көчле хәтәр урыс дәүләтеннән сакланырга мәҗбүр булачак...

Симпозиумдагы чыгышларны тыңлаган чакта әнә шундый уйлар үзеннән-үзе күңелгә килде.

Җыелышта без Надир әфәнде Дәүләт (татар галиме) белән бергә утырдык, сөйләшкәләп тә алдык, олы тәнәфес вакытында мин беренче һәм соңгы тапкыр җыелыш хуҗасы Туран Язган бәй белән дә күрештем. Төшке ашны бергәләп ашаганнан соң, без рәхмәтебезне әйтеп китәргә булдык. Башка инде ул җыелышка барып йөрмәдек һәм төрек бәйләре белән бүтән очрашырга да туры килмәде.

* * *

Хуш, ниләр күреп өлгердек без бу биш-алты көн эчендә? Билгеле, көндез генә машина белән берәр җиргә барып кайта идек. Кичен чыксак та, торган йортыбыздан ерак китми идек. Монда адашуы бик ансат. Шуңа күрә иң элек Истанбулның үзе турында... Ишеткән дә, укы-

ган да бар иде аның хакында, әмма үз күзләрең белән күрү бөтенләй башка икән ул.

Без Истанбулның Византия заманыннан калган үзәк өлешендә тордык... Биш-алты гасыр дәвамында ул күпмегә үзгәргәндер, Ходай белсен, ләкин без үзебезне гүя борынгы Константинопольдә йөргән шикелле тоя идек. Урамнар тар гына, кайберләре озын, кайберләре кыска — еш кына тупыйкка барып терәлә. Шул урамнар буйлап гүя урын җитмәүдән бер-берсенә бөтенләй терәп салынган төрле төстәге кайсы биек, кайсы тәбәнәк тар гына таш йортлар. Түбәнге катлары тоташтан тезелеп киткән бер яки ике катлы, эреле-ваклы кибетләр. Югары катларда торучылар кайдан кереп йөри торганнардыр, чөнки капка-мазары юк, ә урам ишекләренең кайсын гына ачсаң да, кибеткә барып керәсең... Менә болар барысы да бик борын заманнардан бирле шулай сакланып киләдер шикелле тәэсир калдыра иде. Әнә Византия башкаласын кайчандыр әйләндереп алган таш дивар да һаман тора бит әле. Төрекләр XV гасырның урталарында Константинопольне сугышып алган чакта, кайбер урыннары исән калган һәм шул хәлендә саклана да ул. Аның иң биек җирендә бүген Төркиянең дәүләт флагы җилферди.

Әйе, Истанбул бик борынгы кала. Моны һәр адымда тоярга мөмкин. Ихтимал, ул дөньяның башка бер генә шәһәренә дә охшамагандыр да. Хәер, мин моны чамалап кына әйтәм — башкаларын күргәнем юк. Шуңадыр инде, Истанбулны карап йөргәндә, күңелгә һаман бер уй килә иде: без 70—80 ел буена, чынлап та ГУЛАГта яшәгәнбез икән. Бөтен Советлар Союзы безне башка дөньядан тимер пәрдә белән аерып торган үзе бер биниһая зур ГУЛАГ булган икән ләбаса! Күпме нәрсәне күрүдән, белүдән мәхрүм булып яшәгәнбез. Шуңа күрәдер инде, томана мокыт булып калганбыз да...

...Биш көн эчендә без тарихи урыннарның бик мәшһүрләрен генә карарга өлгердек. Мин аларның исемнәрен атау белән генә чикләнәм, чөнки алар турында бөтен мәгълүматны махсус язылган китаплардан табарга була. Аннары нидер язар өчен аларны бер тапкыр күрү генә җитми — тирән аңлар һәм тояр өчен кайта-кайта күрергә кирәк.

...Менә без бөтен дөньяга даны таралган Айя София мәчетен һәм аңардан ерак түгел Солтан Әхмәт мәчетен ашыкмыйча гына карап чыктык... Нәрсә әйтергә мөмкин? Тышкы яктан нечкә озын манаралары (Айя Софиянең — дүрт, Солтан Әхмәтнең — алты) һәм түбәләрен

тоташ каплаган гөмбәзләре белән бер үк осталар салгандай, бер-берен шулкадәр нык охшаган бу ике мәчетнең «яшь» аралары гаять зур Айя София VI гасырда төзелгән Византия чиркәве (төрекләр аны элек мәчеткә, соңыннан музейга әйләндерәләр), ә Солтан Әхмәт мәчете XVII гасыр башларында гына салынган — ягъни Айя Софиядан ул мең елга яшьрәк. Һәм шушы гүя игезәк ике мәһабәт мәчетнең эчен-тышын күз җиткән кадәр карап чыкканнан соң, ирексездән адәми затның иҗади кодрәтенә таң каласың. Билгеле, үзеннән-үзе сорау да туа — рухи вә мәгънәви җәһәттән без бу мәчетләрне төзүчеләр белән чагыштырганда алга киткәнбезме, әллә артка чигенгәнбезме? Дөрес, белем-фән үскән дә үскән, хәзер әнә космоста очып йөрибез, атом бомбасын да ясый беләбез, әмма кеше буларак кем соң без? Чын адәми затлармы, әллә рухи гарип вәхшиләрме? Мондый сорауның тууы Русиядән килүчеләр өчен бик табигый, минемчә.

Солтан Әхмәт мәчете (халык телендә «зәңгәр мәчет») гыйбадәт кылу өчен ачык, аңа аяк киемен салып керәләр...

Тагын беркөнне Әйюб мәчетен барып карадык... Бу Истанбулда төрекләр салдырган иң беренче мәчет (1458 ел). Аның һәр ташыннан борынгылык аңкып тора. Риваятьләргә караганда, мәчет Мөхәммәд пәйгамбәрнең ярдәмчесе Әйюб Әнсари исемле кеше күмелгән җиргә салынган икән (Әнсари — пәйгамбәргә ярдәм итүче, диелгән лөгатьтә)... Аның кабере дә мәчет ихатасында, махсус төрбә эчендә... Изгеләрдән саналган бу каберне килгән бер кеше зиярәт кылмыйча калмый. Кечерәк-җыйнак кына Әйюб Әнсари мәчете миңа теге гаять зур, мәһабәт, бай, зиннәтле Айя София белән Солтан Әхмәт мәчетләренә караганда күбрәк ошады. Кешене тегеләр шикелле шаккатырмыйча гына ничектер тынычландыра торган, чын мәгънәсендә изге гыйбадәт урыны булып тоелды ул... Үзе бик иске, бик борынгы, аның тирәсендә үскән чинар агачларының юанлыгына да ун кешенең колачы җитмәс, мөгаен...

Әгәр чын булса, Истанбулда һәм аның якын тирәсендә ике мең биш йөзләп мәчет бар икән. Без шуларның иң мәшһүр өчесен генә күрдек. Ләкин тагын бер мәчет турында әйтеп китмичә булмый: нәкъ без анда чагында ул мәчетнең нечкә озын манарасы авып төште. Телевизордан күрдек. Тамырыннан ук кубып ауган озын нарат шикелле манара бөтен буе белән мәчет бинасы өстендә сузылып ята иде. Ярый әле урамга аумаган, кешеләрне баскан булыр иде... Ә манараны яңадан, ин-

шалла, бастырып куярлар — төрекләрне андый эшкә бик оста, диләр.

Мәчетләрдән соң без солтаннар сараен карарга булдык. Башта «Топкалы» сараена бардык. Бу — төрек солтаннары өчен төзелгән беренче сарай. Монда берничә гасыр буена бер-бер артлы патшалык иткән егерме бишләп солтан гомер кичергәннәр. Сарай үзе бер катлы озын таш биналардан гыйбарәт. Архитектурасы искитәрлек түгел дияр идем, әмма эченә җыелган байлыкка исең-акылың китәрлек. Өстән-өстән генә карап узар өчен дә өч сәгать вакытыбыз китте. Һәм шактый арып та өлгердек. Шуңа күрә төрек солтаннарының «Долмабахчә» дигән сарайларын барып карауны икенче көнгә калдырдык.

«Долмабахчә» — ул чынында Босфор буендагы зур бакча. Сарайларга ике капкадан үтеп, шул бакчаны узасың... Барышлый юлдан аз гына читтәрәк балаларын имезеп яткан арыслан сынын да күрәсең. Ул безнең игътибарыбызны аеруча җәлеп итте, без аның янында рәсемгә дә төштек.

...Сарайлар үзләре дә Босфорга карап тора. Алар тоташтан тезелеп барган төрле зурлыктагы икешәр-өчәр катлы таш биналар. Тулаем бик нәфис, матур төзелгән үзенә бер ансамбль. 1853 елдан башлап төрек солтаннары менә шунда яшәгәннәр.

Сарайлар эчендә бер-берсенә охшамаган 300 бүлмә бар икән. Без менә шуларның күпмесендер карап чыктык. Әйе, һәр зал, һәр бүлмә үзенә башка! Аларны француз һәм итальян рәссамнары бизәкләгәннәр икән. Әмма алардагы һәркайсы үзенә аерым гаять затлы, гүзәл җиһаз вә зиннәтләрне атап бетерерлек тә, санап чыгарлык та түгел. Бу тиңсез, кабатланмас байлыкларны күргәч, кемгә дан җырларга белмисең: шуларны ясаган, күбесе исемсез даһи осталаргамы, әллә боларның һәммәсен дәүләтнең милли хәзинәсе итеп җыеп калдырган солтаннаргамы?! Күрәсең, икесенә дә дан җырларга кирәктер, чөнки берсеннән башка икенчесе була алмас иде.

Без төрекләрнең бөек кешесе Ататөрек җан тәслим иткән бүлмәдә дә булдык. Стенада аның йөрәге тибүдән туктаган вакытын күрсәткән сәгать эленеп тора иде.

...Бүген безнең өлешебезгә тигән бердәнбер кояшлы җылы көн иде. Сарайдан чыккач әле Босфор буенда ачык һавадагы кечкенә кафеның ипле ак урындыкларына утырып тәмләп кенә чәй дә эчтек... Иртәгә инде без, Алла боерса, үзебезнең Казаныбызга очарга тиешбез. Тагын бер шушындый көн җитмәде безгә. Бәлки, шулай кирәктер дә — үкенечле сагыну озаграк саклана, диләр.

* * *

Безнең иң беренче теләк — Гаяз Исхакый каберен зиярәт кылу иде. Ләкин әйткәнемчә, һаваның кинәт бик начарланып китүе аркасында, без барырга чыккан җиребездән кире борылып кайтырга мәҗбүр булдык. Бары өченче көнебездә генә җил-яңгыр туктаган арада, зиратка бара алдык (көн шулай да бик салкын иде, кар да төшкәләп тора иде). Бик чиста, бик тәртиптә сакланган зиратта каберләр барысы да бертөслерәк... Ләкин безне алып баручылар Гаяз ага каберен тиз таптылар. Менә без аның аяк очында тын гына басып торабыз. Мәшһүр әдипне мин малай чагымда ук укый башлаган идем. Күп кенә еллар без бер үк заманда яшәдек, аның илдә калган замандашларын да миңа күрергә туры килде, ә үзе белән очрашу бары кабере янында, менә хәзер генә насыйп булды. Минем өчен бу кабатланмас бер мизгел иде, шуңа күрә аның баш очындагы ак мәрмәр ташы янына басып рәсемгә дә төштек. Аннары безнең башта ук мәрхүм рухына Коръән укытырга ниятебез бар иде. Шуны әйткәч, зиратта эшләүче бер төрек агасын табып китерделәр. Ул куеныннан әфтияк сыман кечкенә китап чыгарып, вакыт-вакыт кына шуңа карап ясин укыды. Без бер читтә бөрешеп кенә тыңлап утырдык, дога кылдык, садака бирдек. Шул рәвешчә, изге йоланы үтәгәч, җанга ничектер җиңеллек тә иңгәндәй булды.

Аннары Гаяз Исхакыйдан ерак түгел, Йосыф Акчура каберен барып карадык. Бик әйбәт сакланган кабернең ташы безне аеруча гаҗәпләндерде һәм сокландырды. Ул таш — кечерәйтелгән Сөембикә манарасының нәкъ үзе иде!.. Мәрхүмнең үз васыяте беләнме, әллә кызларының акылы җитепме эшләнгән бу таш Сөембикә манарасы — олы шәхеснең туган иле белән мәңгелек бәйләнешен чагылдырган символы буларак басып торадыр.

Шушы урында минем кечкенә бер чигенеш ясыйсым килә. Мәгълүм булганча, Гаяз Исхакый гомеренең соңгы елларын Анкарада, кызы Сәгадәт ханым тәрбиясендә торып уздырды. Сәгадәт ханым да бу фани дөньяда юк инде, ләкин кабере аның Анкарада. Мәгәр эмиграциягә ялгыз чыгып киткән Гаяз Исхакый бердәнбер кызы белән кайчан, ничек очраша? Менә шушы хакта Кәрим Тинчуринның җәмәгате Заһидә апа Әхмәрова миңа сөйләгән иде. Вакыйга кыскача гына болай булган.

1921—1922 ачлык елларын Кәрим абзый белән Заһидә апа Ташкентта уздыралар. Шул чагында аларга Гаязның авылда калган үсмер кызын кемдер китерә (ихтимал, бу алдан хәбәрләшү буенча эшләнгәндер, дип уй-

лыйм мин). Сәгадәт авыр кышны Заһидә апаларда торып үткәрә. Егерме икенче елның җәендә Ташкентка Галимҗан Идриси (шулай ук бик билгеле шәхес) килеп Германиядә укытыр өчен шәкертләр җыя. Ул үзе Берлин университетының укытучысы була. Җыйган шәкертләре белән бергә Идриси Тинчуриннардан Сәгадәтне дә алып китә — әлбәттә, кем кызы икәнен бик яхшы белеп. Менә шул кешеләрнең игелеге аркасында Гаяз Исхакый бердәнбер кызы белән Берлинда очраша. Заһидә апаның миңа сөйләгәне әнә шул. Ләкин мин аңардан бер нәрсәне сорарга кыймадым: еллар узгач, репрессияләр вакытында атылган Тинчуринны Гаяз Исхакый белән бәйләнеш тотуда гаепләгәннәр, имеш, дигән сүзләр дә чыккан иде. Бу хакта сорашу Заһидә апаның тирән ярасына кагылу гына булыр иде.

* * *

Санаулы алты көнебез әнә шулай үтеп тә китте. Иртәгә юлыбыз туган илгә — «яшел бишек»кә, язган булса! Кайткач, Төркиядә булдык, Истанбулны күрдек, дип мактана алабыз... Әмма сөйләр сүзебез күп түгел. Истанбулдан читкә чыкмадык һәм бер генә төрек белән дә сөйләшергә туры килмәде. Шуңа күрә Төркия турында моңарчы белгәннәремә артык берни дә өстәлмәде диярлек.

Хәлбуки Төркия бит ул безнең өчен күпме еллардан соң кабат ачылган өр-яңа бер дөнья. Еш барып йөрүчеләр аның турында шаккатып ниләр генә сөйләмиләр?!

Кайчандыр без төрекләр өчен кыска гына берара үрнәк була алганбыз (моны Фатих Кәрими мәктүбләреннән күрдек). Хәзер инде төрекләр безнең өчен буй җитмәслек үрнәк икән ләбаса! Һәм, чынлап та, бу шулай булса кирәк. Безнең галимнәребез, әдипләребез, эшмәкәрләребез, эреле-ваклы чиновникларыбыз ике арада киләп саргандай өзлексез йөреп кенә торалар. Хәзер инде без төреккә иярәбез; төректән өйрәнәбез, күчерәбез, һәм төрекләрдән бик күп ташыйбыз да! Базар мөнәсәбәтләренә кергәндә, моңа һич тә гаҗәпләнергә туры килми... Шулай ук белем вә фән өлкәсендә дә бәйләнешләр бик көчәйде. Әнә күпме егетләребез-кызларыбыз бүгенгесе көндә Төркиянең урта һәм югары мәктәпләрендә укып яталар. Билгеле, дәүләт дәрәҗәсендәге сәяси вә икътисади мөнәсәбәтләр дә бик дустанә һәм тотрыклы булса кирәк. Әле менә Истанбулда чакта миңа шундый кызыклы бер нәрсә әйттеләр: үткән көз Президентыбыз

Минтимер Шәймиев анда ял иткән чагында, Төркия Президенты Сөләйман Демирел бәй үзе Минтимер бәй янына күрешергә барган икән. «Сез бездә ял итүче кунак, шуңа күрә мин үзем килдем»,— дигән, имеш. Бу хәбәр миңа бик ошап куйган иде.

Сүз дә юк, Президентлар арасындагы нәзакәтле җылы мөнәсәбәт бик әйбәт ул, әмма хәзерге заман төрекләре безне яхшы беләләрме, ике арада чын якынлык бармы, рухи бәйләнешләребез ничек, ни дәрәҗәдә?.. Әйтик, әдәбият, сәнгать өлкәсендә. Шушы сораулар монда йөргәндә күңелгә һаман килә торды. Төрекнең үзе белән аралашырга туры килмәгәч, дөресен генә белү бик читен иде. Шулай да мин монда яшәүче Мәхмүт әфәнде Ураллы белән озак кына сөйләшеп утырганда сорашып карадым (Мәхмүт әфәнде, асылда, башкорт булса да, Истанбулдагы татарлар җәмгыятенең җитәкчесе һәм танылган «татар» сәүдәгәре). Аның әйтүенә караганда, төрекләр Казан татарларын начар беләләр икән, алар өчен татар ул беренче нәүбәттә кырымлылар белән әзәриләр... «Мин Казан татары» дисәң, аптырабрак калалар, чөнки Казанның кайда икәнен дә ачык кына белмиләр... Шулай булгач, ерактагы татарның әдәбияты, сәнгате белән дә кызыксыну юк диярлек. Дөрес, җырчылар килгәлиләр, ләкин күбрәк Уфадан... Ә китапка килгәндә, ул бит товар, сораучы (укучы) булса гына аны базарга чыгаралар. Без монда бер генә язучының төрекчә чыккан китабын күрдек, бүтән берәүнекен дә күргәнебез юк...

Мәхмүт әфәнде әнә шулайрак сөйләгән иде. Аңа ышанмыйча булмый — заманасы шундый. Хәзерге кыргый базар шартларында безгә, мәсәлән, төрекнең поэзиясеннән бигрәк каеры туны (дубленка) кирәк, төрекләргә безнең нәфис әдәбиятыбыздан бигрәк нефтебез кирәгрәктер. Белмиләр төрекләр безнең беребезне дә — хәтта Туфан Миңнуллинын да! Шигырь башка да, дөньяны әйләндергән чыгыр башка! дигән Тукаебыз.

Хәерле булсын... Нәфасәт багында мөхтәрәм төрек бәйләре белән култыклашып йөрер вакытлар җитмәгән әле, күрәсең... Һәр халыкның үз кайгысы, үз проблемалары — шуларны чиләнә-чиләнә чишәсе бар әле. Кая гына барсаң да, кара сакалың үзеңнән калмый, кемдер әйтмешли...

Ә шулай да күңелгә бик хуш килгән бу меңләгән мәчетле төрек каласын тагын бер күрергә язсын иде кояшлы якты көннәрдә...

*«Мәдәни җомга», 1996*

## СӨРТЕНҮ

Чаллыда үткәрелгән Дәүләт Советына сайлауларда Фәүзия Бәйрәмованың яңадан депутатлыкка тәкъдим ителүен мин бик соңга калып ишеттем. Аңа каршы янә ике кандидат куелган — «Ак Барс» исемен йөрткән банк хуҗасы Тәлгать Абдуллин һәм Татарстан халкына яхшы мәгълүм Кашаповларның берсе... Көндәшләр бик җитди... Бигрәк тә банкир Абдуллин — ул, әлбәттә, хакимияткә кирәк кеше, аннары сайлау кампаниясен шәп итеп оештырыр өчен аның байлыгы да җитәрлек.

Шулай да минем Фәүзия ханымның сайлануын куәтләп матбугатта чыгасым килде. Миңа калса, шул өч кандидаттан депутат булып сайланырга Фәүзия Бәйрәмова һәр җәһәттән дә лаеграк иде. Мин болай дип яздым: «...Фәүзия Бәйрәмова татар халкының фидакарь кызы. Милли азатлык хәрәкәтенең батыр йөрәкле, кыю көрәшчесе...» «Иттифак» фиркасын оештырган, шуның җитәкчесе булып танылган сәяси лидер. Элеккеге Татарстан Югары Советының депутаты буларак та, бай тәҗрибә туплаган дәүләт эшлеклесе һәм иң мөһиме — татар халкының милли бер лидеры итеп аны Русия күләмендә дә, шулай ук чит илләрдә дә таныдылар. Безнең якынча тарихыбызда хатын-кызлардан мондый дәрәҗәгә күтәрелүченең булганы юк иде әле. Йә, шундый шәхеснең урыны безнең Дәүләт Советында булырга тиеш түгелмени?!

Фәүзия Бәйрәмованың Дәүләт Советына сайлануы халкыбызның милли мәнфәгатьләрен тормышка ашыру өчен кирәк. Татарстанда яшәүчеләрнең тормыш шартларын җиңеләйтерлек гадел законнар кабул итү өчен кирәк. Бер фирканың җитәкчесе буларак та сайлануы кирәк — бу демократиянең бездә дә яшәвен күрсәтәчәк. Ниһаять, Бәйрәмованың депутат булуы Президентыбыз өчен дә кирәк ул. Хәзерге Дәүләт Советында оппозиция бик зәгыйфь, ә дәүләт белән дөрес идарә итү өчен оппозициянең булуы зарурдыр...» Әнә шулай язган идем мин.

Өстәп, бәлки, шуны да әйтергә кирәктер, Бәйрәмова хәрәкәтеннән мин читтә торган кеше, аның белән килешмәгән, бәхәскә кергән чакларым да булды. Ләкин моның хәзер ни әһәмияте бар. Сүз бит кемнең депутат булып сайланырга лаеграк, хаклырак булуы турында бара. Тик, кызганыч ки, мин бу язганымны вакытында бирә алмадым. Сайлауларга бары ике-өч көн генә калган иде. (Бер мөхәрриргә чылтыраткач, ул миңа: «Әмирхан абый, соң инде»,— диде.)

...Чаллының үзендә сайлау кампаниясе ничек бар-

гандыр — хәбәрем юк. Казан газеталарында ике материал күренде: берсе, «Ватаным Татарстан»да Айдар Хәлимнең Бәйрәмова турында кыска гына, әмма тулы мәгълүмат биргән мәкаләсе чыкты. Икенчесе, «Татарстан яшьләре»ндә Фәүзия ханымның «Мин — Алла колы гына» дигән әңгәмәсе басылды. Бусы мине борчылырга мәҗбүр итте. Сайлауларның нәтиҗәсен алдан сизгәндәй, ул мистикага бирелә кебек тоелды миңа. Утны-суны кичкән тәҗрибәле сәясәтчегә болай бер Аллага ышанып тору гына җитәме? Хәрәкәт итәргә, эшне оештыра белергә дә кирәктер бит — кешеләр үз максатларына хәзер бары шулай гына ирешәләр ич!

Инде менә сайлаулар үтеп тә китте. Аның нәтиҗәләрен газеталардан белдек. Мин ала торган татар газеталарында кемнең сайлануы турында гына хәбәр ителде. Тик «Вечерняя Казань» гына кемнең күпме тавыш алуын язган иде: Тәлгать Абдуллин — 62, Кашапов — 20, Бәйрәмова бары 8 процент.

Абдуллинның сайлануына, Бәйрәмованың үтә алмавына артык гаҗәпләнмәдем. Башта ук шигем бар иде. Әмма тавыш алу ягыннан бу кадәр зур аерма булыр дип һич тә көтмәгән идем. Дөресен генә әйткәндә, пычаксыз суйды мине бу аерма! Ничек аңларга моны, сәбәпләре нәрсәдә моның?..

Милли азатлык хәрәкәтебездә күренекле урын тоткан берәүнең шундый уңышсызлыкка таруы борчылып уйландырырлык вакыйга ул, минемчә...

Татарстан җитәкчеләренә акчалы банкирның кирәгрәк булуы бик тә аңлашыла. Үзен хакимияткә каршы куйган Бәйрәмованың аларга, әлбәттә, кирәге юк. Ә район, авыл җитәкчеләре моны бик яхшы белеп, сайлауларны «тиешенчә» оештырганнардыр да билгеле...

Мәгәр тавышларын бирүчеләр халык бит әле... Һәркем бюллетеньне кулына алып, кабина аша үтеп, кызыл ящикка салып чыга. Үзе теләгәнчә яшерен тавыш бирә. Күпчелеге татарлардыр инде, Фәүзия Бәйрәмованың кем икәнлеген, нәрсә өчен җанын бирердәй булып, көрәшеп йөргәнен дә яхшы беләләрдер... Әмма тавышны бирүгә килгәндә, юк инде, гафу итсен, чибәрем!.. Бездә бүгенге көндә милләт кайгысы түгел, тамак кайгысы да баш кайгысы... Хезмәт хакын аласы бар, пенсияне вакытында китерсеннәр, терлеккә азык кирәк — кем бирә, кем эшли аларны? Түлке ха-ки-ми-ят!

Депутатны да халык әнә шулай көндәлек газаплы ихтыяҗларыннан чыгып сайлый. Моның өчен аңа үпкәләп тә, рәнҗеп тә булмый — бу аның мәнсезлеге түгел, бә-

хетсезлеге. Бик җөдәгән ул өзлексез алданудан һәм талanудан... Кая барсын, кемнән көтсен ул үзенә җиңеллекне?! Бары югарыдагы хакимияттән генә...

Бигрәк тә Президентыбыз Минтимер Шәймиевкә ышанып тора ул. Гаделлекне аңардан көтә. Халыклар арасында абруе зур, дөнья күләмендә танылган дәүләт эшлеклесе. Ә мин эчемнән генә уйлап куям: аның шушы дәрәҗәгә ирешүенә Фәүзия Бәйрәмованың Татарстан мөстәкыйльлеге өчен 18 тәүлек Ирек мәйданында ач утыруы да ярдәм итмәде микән?! Һәрхәлдә, мөхтәрәм Минтимер Шәрипович президент өчен җитәрлек мөстәкыйльлекне алды булса кирәк.

Озын сүзнең кыскасы, мин, милләт дигән булып, тигез җирдә сөртендем. Кемгә кирәк ул милләт өчен янукөюләр... Кайчандыр Фатих Әмирхан «Татар дуңгыз кылы, аңардан киез басып булмый» дип әйткән, имеш. (Моны безгә мәрхүм Мәхмүт абзый Бөдәйли сөйли торган иде.) Гаҗәпмени, Фәүзия Бәйрәмованы яклап замандаш каләмдәшләреннән сүз әйтүче дә булмады.

...Балаларча алдануымны мин авыр кичердем. Бигрәк тә Фәүзия ханым өчен. Тирән яра алгандыр ул бу артык көтелмәгән хәлдән. Әлбәттә, вакыт үтеп, җан тынычлыгы кайткач, тиешле нәтиҗәне үзе ясый белер. Ул бит әле талантлы язучы да. Сәясәтче булып калырмыюкмы, әмма сатылмас көчле язучы булып калуына иманым камил!..

*Татарстан яшьләре, 1997*

## ...ТАГЫН БЕР ЕЛНЫҢ СОҢГЫ КӨННӘРЕ

Күптән концертларда булган юк иде... Көн дә диярлек иртәнге чәй янында радиодан төрле җирләрдә зурзур концертлар булып торганын ишетәбез югыйсә...Алар хәтта күбәеп тә китте. Мәгәр безнең җыр тыңлап хозурланыр чакларыбыз үтебрәк китте шул инде... Аннары ноябрь-декабрь айлары да безнең өчен уңай вакыт түгел, бик иртә караңгы төшә, аяк асты тайгак. Алла сакласын!

Шулай да безне исләренә төшерүчеләр бар әле. Шуларның илтифатлы тырышлыгы белән без кыска гына арада бик матур ике концертта булдык. Унынчы декабрьдә Рөстәм Яхинга багышланган концертка безне Флора ханым Хәсәнова машина җибәреп чакыртып алды. (Соңыннан өебезгә китереп тә куйдылар.)

...Уналтынчы декабрьдә опера театрында үткәрелгән

Сара Садыйкова концертына безне фронтовик-замандашым Сөембикә ханым Вәлиева шулай ук машинада килеп алды, соңыннан китереп тә куйды. Безнең ише картлар өчен кадерлесе — кешенең ихлас җылы игътибары... Әлбәттә, без Флора ханымга да, Сөембикә ханымга да, борынгыча әйтсәк, тәшәккердән гаҗизбез!..

Рөстәм Яхинга багышланган кичә консерваториянең өр-яңадан төзелгән концертлар залында узды. Һәм бу бик тә табигый-урынлы иде. Мәрхүм композитор һәм яңа гүзәл бина — гүя бер-берсенә бик тиң килгәннәр. Үтә нәфис лирик музыка шушы аеруча бай зиннәтле бинада яңгырарга тиеш тә иде... Сәхнә түрендәге экраннан Рөстәм үзе дә пианиносы янына утырган килеш залга уйчан-тыныч кына карап тора иде... Билгеле инде, залда аны тыңлап утыручы тамашачылар да бу көнне башкачарак булганнардыр дип әйтәсе килә. Һәрхәлдә, кайда кемне тыңлап утырулары аларны элеккегә караганда үзләрен әдәплерәк тә, нәзакәтлерәк тә, затлырак та итеп тоярга мәҗбүр иткәндер, мөгаен... Чын матурлык, чын сәнгатьнең тәэсире гаҗәеп бит ул!..

Бу концертта безнең үзебезнең яхшыра-сафлана баруыбызны тоеп утыру бик куанычлы иде. Ләкин мин концертның гаять бай программасы турында язуны өстемә алмыйм — ул эшнең үз белгечләре бар. Әмма бер үзәк номерына карата әйтмичә дә калалмыйм: сүз Флора ханым Хәсәнованың оркестрга кушылып фортепианода уйнавы турында... Музыка үзе дә, аның башкарылуы да тамашачыларны тәмам әсир итте, таңга калдырды... Гаять көчле-мәһабәт яңгырады Рөстәмнең бу киң колачлы тирән әсәре... Монда оркестр белән идарә итүче дирижер Тургунбаевның да осталыгы ачык чагылды. Төп башкаручы Флора ханымны да тамашачылар озак алкышларга һәм чәчәкләргә күмделәр... Афәрин!..

Кичәнең ахырында шул ук Флора Хәсәнова җыеп чыгарган Рөстәм Яхин турындагы истәлекләр китабы белән таныштыру булды. Моны да бик кирәкле, күркәм бер эш итеп кабул иттек.

Инде менә без Сара Садыйкованың 90 еллыгына багышланган концертта — опера театрының күптән таныш залында утырабыз... Ике зур бүлектән гыйбарәт концерт бары аныкы гына иде. Белмим, Сара апага исән чагында мактаулы опера театры сәхнәсеннән бай иҗатының шактый тулы өлешен ишетергә туры килде микән?! Ә без менә бүген аның чын милли рухтагы саф татар музыкасын тирән ләззәтләнү һәм дулкынлану белән тыңлап утырабыз. Ирексездән, ерак заманның бер

вакыйгасы хәтеремдә уяна: мин бит моннан 70 ел элек, 1926 елның гыйнварында, хәзерге Тинчурин театрында «Сания» операсын караган идем. Сания булып яшь кенә туташ Сара Садыйкова уйнаган иде. Шул елларда ук беренче татар операсының туып сәхнәгә куелуы чын мәгънәсендә бер милли бәйрәм төсен алган иде... Мәдәниятебез, сәнгатебез өчен милли горурлык хисләре кичергән идек шул чакта. Аннары минем өчен өстәмә бер шатлык — шул спектакльдә мин икенче тапкыр Фатих Әмирханны да күргән идем. Тәнәфес вакытында аны креслосы белән фойега чыгарып стена буена куйдылар. Шунда ук аны әсәрләрендәге геройларына охшаган студент формасындагы яшьләр һәм калфаклы туташлар уратып алдылар. Мин дә шулар артыннан аяк очларыма басып, әдипнең аз гына елмаюлы уйчан йөзен күреп калырга тырыштым. Бүген бу залда шул заманнарны исенә төшереп утыручы тагын бүтән берәр кеше бармы икән?!

Әмма гаҗәеп икән ул заманның агышы һәм борылышлары... Моннан 70 ел элек «Сания» операсында җырлап безне сокландырган яшь туташ бүген әнә халкыбызның иң сөекле композиторы... Теге вакыттагы шикелле бүген дә ул безнең күңелләрдә милли горурлык хисләре уята... Сәйдәш-Җиһанов-Яхиннар шикелле үк, ул да музыка сәнгатебезне төрле милләт халыкларына җиткергән бөек талант иясе.

Билгеле инде, мондый яңалыклар өчен аның тарихи шартлары да туарга тиеш иде... Татарстанның чикле рәвештә генә булса да суверен дәүләт булып танылуы, татар халкының күпмедер дәрәҗәдә мөстәкыйльлеккә ирешүе кирәк иде. Опера һәм балет театрының иркен сәхнәсендә өч сәгать буена бары Сара Садыйкованың музыкасы гына яңгырап торды — бу, әлбәттә, безнең мөстәкыйльлекнең үзенә күрә бер өлгергән җимеше иде. Дөрес, моныңише өлгергән җимешләребезнең мул уңышы белән хәзергә мактана алмыйбыз... Нинди авыр шартларда яшәвебезне яхшы беләбез. Әдәбият һәм сәнгатьнең хәзерге хакимиятебез өчен арбаның бишенче тәгәрмәче булып кына исәпләнүен дә яхшы күреп торабыз... Әмма халык уяна, әкренләп булса да уяна, дәрт-теләк тә сизелерлек көчәя бара. Рөстәм Яхин белән Сара Садыйкованың концертлары әнә шул көчәя барган дәрт-теләкнең ачык чагылышы иде... Бу концертларны матур итеп, көчле итеп оештыра белүчеләргә иң зур, иң ихлас рәхмәтләребезне җиткерәсебез килә.

Концертлардан соң миңа бер татар гимназиясендә дә булырга туры килде. Шунда укучы 16 яшьлек Сөмбел

Гаффарованың беренче әкиятләр китабы басылып чыккан икән — менә шул китап белән таныштыру кичәсенә мине дә килеп алдылар... Бу, әлбәттә, бик күңелле вакыйга — мәктәптән үк әдәбиятка аяк атлавы... Япь-яшь авторны ихлас котладык, киләчәге дә өметле һәм укымышлы булсын, дидек.

Гимназия, гомумән, яхшы исәптә икән... Укыту һәм тәрбия эшләре яхшы куелган булса кирәк. Балаларны җырга, музыкага да өйрәтәләр, матур гына концертларын да карадык.

Ләкин күңелле кичә беткәч, директор бүлмәсендә чәй эчеп, сөйләшеп утырганда шактый күңелсез бер хәлне ишетергә туры килде: башлангыч сыйныфларда укытучы югары белемле яшь педагоглар аена бары 300 мең сум хезмәт хакы алалар икән. Аның да кулларына 250—260 меңе генә тия икән... Моны хезмәт хакы дип булмый — бу хәерче садакасы... Ашау-эчүләренә җитә микән... Һәрхәлдә, ул акчага укытучы бичара үзенә алмашка яхшырак күлмәк тә сатып ала алмый торгандыр... Оят һәм хурлык!.. Әмма бу оят, бу хурлык «укытучы апаны» шундый хәерчелектә яшәргә дучар иткән хакимият өстенә төшәргә тиеш...

Әйтергә кирәк, башлангыч сыйныфларда укытудан да изгерәк һәм җаваплырак эш юктыр, минемчә... Дөньяга яңа күзе ачыла башлаган бала өчен «апа» бөтен җәһәттән дә үрнәк — аңардан күчерә ул чисталыкны да, пөхтәлекне дә, нәфислекне дә, күркәм әдәпне дә...

Президент урынында булсам, мин аларга хезмәт хакын 500 меңнән дә ким куймас идем. Моның өчен нефть акчасының билгеле бер өлешен бары шуларга гына күчерер идем... Байлыкка чумган нефть «хуҗаларының» керемнәрен әзрәк кыскартып булса да... Ата-аналар моны кул чабып алкышлар гына иде...

*«Шәһри Казан», 1997*

## ДӨНЬЯ БЕЗНЕ ТАНЫСЫН!

Милләтнең яшәве һәм тәрәккый итүе өчен байлык белән мәгърифәтнең зарур икәнлеге күптән билгеле. Моны без үз тарихыбыздан да күреп беләбез. Октябрь инкыйлабына кадәр татар милләтенең кыска гына вакыт эчендә һәр җәһәттән дә гаять тиз үсеп, күтәрелеп китүе шул ике потенциаль көчнең — байлык белән мәгърифәтнең кушылуы нәтиҗәсендә булды. Ирекле кәсеп — сәүдә аркасында шактый зур байлыклар татарлар ку-

лында туплана. Мәгариф өлкәсендә җәдитчелек хәрәкәте җиңә, мәктәп-мәдрәсәләргә дөньяви белемнәр керә... Татар байлары булган һәр шәһәрдә мәчет-мәдрәсәләр салына. Китап басу һәм китап сәүдәсе бик нык алга китә. Ниһаять, Русиядә бүтән бер халыкта да булмаган көчле матбугат туа...

Бу эшләрнең милли хәрәкәтебездә аеруча зур урын тоткан кайберләрен искә төшереп узыйк: үткән гасыр ахырында татар бае Мөхәммәтҗан Галиев тарафыннан Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе төзелә. Бу мәдрәсәдә соңыннан татарның олы шәхесләре булып танылган Фатих Әмирхан, Гали Рәхим, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт укыйлар... Ырынбурда Әхмәт бай Хөсәенов үз акчасына бөтен шәһәрне бизәп торган зур мәдрәсә бинасы салдыра. «Мәдрәсә-и-Хөсәйния» Русиядәге мөселман мәдрәсәләренең иң мөкәммәледер дип яза «Заман календаре». Татарча, русча кул куюдан башка грамотасы булмаган бу байның укыту эшләренә тоткан чыгымнарын исәпләп бетерерлек түгел. Шуның өстенә Әхмәт бай үләре алдыннан халык мәгарифенә тотар өчен 500 мең акчасын вакыф итеп калдыра. (Хәзерге акча белән 500 миллиардка җитә торгандыр.)

...Без байларны яратмаска, дошман күрергә өйрәндек. Ә менә олы галим, дин һәм әхлак мәсьәләсендә гаять таләпчән Ризаэтдин Фәхретдинов хәзрәтләре Әхмәт бай Хөсәенов турында махсус китап та язып чыгара. Чөнки белә ул гади татар кешесенең озак еллар тир түгеп, хәләл кәсеп белән байлыкка ирешкәнен. (Хәзер инде «хәләл кәсеп» дигән сүзнең кирәге бетте.)

Әлбәттә, байларның юмартлыгы милләткә мәхәббәттән генә булмагандыр, үз мәнфәгатьләрен дә алар исләрендә тотканнардыр. Шул ук Әхмәт бай эшләре киңәйгәч, Берлин белән Лондонда үзенең сәүдә конторaларын ача. Ләкин Европа шартларында эшли алырлык бер генә дә әзерлекле-белемле татар табылмый. Инглиз белән немецларга көчле көндәш була алмыйча зарар күрә башлагач, Әхмәт бай конторaларын ябарга мәҗбүр була. Шулай дип яза әлеге «Заман календаре» һәм үзеннән «заграница тиҗарәтендә (сәүдәсендә) Русия татарларына бу бер сабак булды» дип тә өсти. («Заман календаре»н чыгаручы Шәрәфетдин Шәһидуллин белән миңа 1926 елның кышында китап кибетендә бергә эшләргә туры килгән иде. Кечерәк буйлы, ап-ак мыеклы, бик мөлаем бер абзый булып истә калган.)

Инде Уфага күчик. Монда да аз гына соңрак, Сәлимгә-

рәй морза Җантурин һәм дин галиме Зыя Камали тырышлыгы белән, Уфа байлары акчасына салынган мәшһүр «Галия» мәдрәсәсенең ишекләре ачыла. «Галия» күп мәдрәсәләрдән шәкертләргә бирелгән хөрлеге белән аерыла һәм исеме дә еракка тарала. Анда Галимҗан Ибраһимов укый һәм укыта, шәкертләре арасында без Шәехзадә Бабич, Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан кебек затларны күрәбез.

Озын сүзнең кыскасы, кайда байлык белән мәгърифәт, шунда тәрәккыят!.. Татарлар тупланыбрак утырган бөтен төбәкләрдә һәм шәһәрләрдә без шул тәрәккыятнең ачык галәмәтләрен күрәбез: мәчет тә, мәктәп тә бар, китапханә дә ачылган, гәзитә-журналлар да килеп тора. (Мин үскән кечкенә Дәүләкәндә Шәймәрдән Гайнетдинов дигән «купич» аерым китап кибете дә ачкан иде.) Ул елларда ана телендә укымаган татар баласы булды микән?! Шәкерт дип аталу укучы өчен абруйлы сүз иде. Әнә шул шәкертләрдән бит инде бөек Исхакыйларыбыз, Тукайларыбыз, Фатих Әмирханнарыбыз туа. Шәкертләрдән шулай ук беренче артистларыбыз, композиторларыбыз, беренче рәссамнарыбыз сәнгать мәйданына чыгалар. Гаҗәп түгелмени, нибары биш-алты ел эчендә яңа классик әдәбиятыбыз туып өлгерә. Шундый ук кыска гына вакыт дәвамында татарның үз зыялылары, галимнәре, фикер ияләре хасил була. Әнә шулар аркасында татарлар Русиядәге төрки халыклар арасында иң алдынгы милләт буларак таныла да.

Игътибар итегез, бу тәрәккыят монархия заманында иде бит, патша хөкүмәтенең татарларга аеруча ышанмыйча кырын караган, милли хәрәкәтен ничек тә буарга тырышкан бервакытта бит!.. Шуңа да карамастан татарның асфальт астыннан төртеп чыккан үлән шикелле бик тиз үсеп китүенең котылгысыз тарихи сәбәбе бар иде. Русиядә елдан-ел бик кызу көчәя барган капитализм урыс белән аралашып яшәүче татарларны иң элек үз эченә суырып алды да сәүдәгә, кәсепкә, һөнәргә киң юллар ачылды. Ә сәүдә-кәсеп татарга элек-электән үк хас сыйфат. Бер-ике генә мисал китерәсем килә: Сембердәге Акчуриннарның сукно (постау) фабрикалары сугыш вакытында бөтен патша армиясен киендерә.

Киевта яшәүче Максудовлар Петербургтан Кырымга кадәр сузылган тимер юл буендагы барлык зур рестораннарны һәм ресторан вагоннарны кулларында тотканнар. (Шулар бит инде улларын-кызларын татарча укытыр өчен Казаннан Галимҗан Ибраһимовны чакыртып алалар.)

...Әгәр дә тагын бер 20—25 ел шулай ирекле тәрәккый итү дәвам итсә, татар халкы, белмим, нинди югары-

лыкларга гына күтәрелмәс иде икән?! Кызганыч, бик иртә өзелде ул тәрәккыят, мәгәр патша аркасында түгел, большевиклар аркасында...

Билгеле, татарның үз гаебе дә монда җитәрлек. Ялгышулар да, алданулар да күп булды. Күп фаҗигаләр кичердек. Халкыбызның иң сәләтле, иң булдыклы өлеше юкка чыкты, калганнарының яртысы диярлек телен югалтты.

Инде менә җитмеш ел Гаяз Исхакый язган инкыйраз (бетү) куркынычы астында яшәгәннән соң, без яңадан терелә, җанлана башладык шикелле. Яңа тәрәккыят чорына кереп барабыз бугай... Әмма бу юлы инде юмарт байларга исәп тотып булмаячак. Алар әллә бар, әллә юк, билгесез. (Мин, мәсәлән, Кашаповлардан башка берәүне дә белмим.) Ил байлыгы эре чиновниклар, банкирлар һәм монополистлар кулына кереп бетте. Аларның бөтен кайгысы ансат кына эләккән байлыкны саклау, моның өчен властьны ычкындырмау. Хәзерге режим әнә шуннан гыйбарәт.

Әмма ләкин шул ук режим шартларында булса да, безнең хәзер Татарстан дигән суверен дәүләтебез бар. Ул законнар чыгара, салымнарны да үзе җыя, бюджетны да үзе төзи. Димәк, тәрәккыят өчен кирәкле чыгымнарны да без бары аңардан гына көтә алабыз. Ул, бичара, без көткәнне бирергә тели дә, тик хәленнән генә килми кебек. Байлык бар, акча юк. Ни өчен ул алай—моның серләрен аңлап та булмый. Кыскасы, безнең бюджет мәгърифәткә, аеруча әдәбиятка, сәнгатькә һәм фәнгә дигән акчаны бармаклары арасыннан кысып кына тамыза. Ә бит Казан урамнары машиналар белән тулды — җәяүлегә йөрер юл калмады.

...Әлеге бөтен Русиядә хөкем сөргән чамасыз байлык белән чиксез бөлгенлек режимы бездә дә кемнәргәдер бик тә ярап тора булса кирәк.

Әмма ниләр генә кичермик, Русия уртасында күпмеазмы мөстәкыйльлек белән файдалана алган суверен Татарстанның булуы зур казаныш, зур бәхет ул дияр идем мин. Татар дөньясының бер таянычы ул — Татарстан дигән дәүләтебез!.. Шуңа карый, шуңа ышана, шуннан үзенә нидер көтә татар халкы...

Аеруча Казанның татар дөньясы өчен тоткан урыны гаять зур. Читтәге татар Казанны үзенең рухи Ватаны, мәгънәви үзәге итеп күрергә тели. Аның өчен, Тукайча әйтсәк: «Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур». Бәлки, Тукай бераз арттырып та җибәргәндер, һәрхәлдә, Казанның нуры еракка төшеп читтәге та-

тарларны үзенә бик үк тартып тормый әле. Миңа калса, моның сәбәбе ниндидер җирле тар карашыбызда булса кирәк — читтән кайтучыларга ишекләребезне ачып тормыйбыз.

Шушы уңай белән бик җитди бер мәсьәләгә тукталасым килә. Мәгълүм булганча, Русиядә гасыр башында туган милли хәрәкәтнең иң төп изге бурычы — татар халкын бөтен, бердәм бер милләт итеп саклау иде. «Милли мәдәни мохтәрият»нең тууы да шул максат өчен иде, чөнки сибелеп, бүленеп яшәргә мәҗбүр булган халыкны саклауның ул бердәнбер чарасы иде. Хәзер дә иң төп бурыч шул ук — бөтен бердәм милләт булып саклану һәм яшәү. Бу язмыш мәсьәләсе. II Бөтендөнья татар конгрессының игътибар үзәгендә дә нәкъ шушы мәсьәлә торыр.

Татарстанда татар, иншалла, сакланыр. Ә менә Русиядәге өч-дүрт миллион халкыбызны нинди язмыш көтә?.. Билгеле, милли азатлык җилләре аларга да кагылды, аларны уятты, хәрәкәткә китерде. Күп төбәкләрдә татар үзе өчен нидер эшләргә дә тырыша. Мәгәр аерым, ялгыз башына, үзе белгәнчә...

Бу таркау хәрәкәт белән дә кемдер берәр үзәктән җитәкчелек итәргә тиештер бит. Моңарчы бу вазифаны Казандагы Индус Таһиров комитеты үтәп килде. Ләкин аның вәкаләте һәм колачы җитте микән? Русия гаять зур, аннары Казан башка, Мәскәү башка аңа гына буйсыналар Федерация регионнары. Русия гражданнары буларак аңа хезмәт итеп, салымын түләп, шул регионнарда яшәүче татарларның оешырга да, җитәкче үзәкләрен булдырырга да тулы хокуклары бар, минемчә.

Әле Тукай мәрхүм «Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» дигән шигырендә:

> Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк,
> Хаклыбыз уртак Ватан да шактый ук,—

дип язган иде. Игътибар итегез. Русияне «уртак Ватан» дип атый ул...

Әгәр Тукай белән килешсәк, уртак Ватанда татар милли үзәгенең булуы бик хаклы, ә таләпләре аның бик законлы булачак. Кирәксә, ул таләпләрен турыдан-туры Дәүләт Думасына һәм Россия Президентына да җиткерә алачак. Конституция аңа мондый хокукны, мотлак, бирә торгандыр.

Аннары, мәгълүм ки, Русиядә татарларның интеллектуаль көчләре — фәндә, сәнгатьтә, хуҗалык эшләрендә шактый күп. Аларның байтагы динен, телен югалтса да, татарлыгын югалтмаган. Милли хәрәкәтнең Русиядә ое-

шуы менә шуларны да кузгатырга, тартырга бик нык ярдәм итәр иде.

Әлбәттә, бу әйткәннәрне Русия татарларын Казаннан читләштерү дип аңларга һич тә ярамый. Киресенчә, үзара бәйләнеш, якынаю көчәергә генә тиеш. Уяна, терелә башлаган татарларның Казан ярдәменә ихтыяҗлары да артачак кына... Шул ук вакытта оешкан, куәт җыя барган Русия татарлары да бердәнбер татар дәүләте — Татарстанга ышанычлы таза терәк булыр дип ышанасы килә. Милли хәрәкәт безне аермас, берләштерер генә... Икенче конгресс сайлап калдырачак комитетның да эше нык үзгәрер, мөгаен. Бәлки, ул төрле илләрдәге татар милли хәрәкәтенә юнәлеш бирүче, киңәшче югары бер орган булыр. Һәрхәлдә, конгресс аның статусын һәм бурычларын ачык билгеләр, шаять.

Бөтендөнья татарлары исеменнән эш йөрткәч, аның бурычлары бик җитди, дәрәҗәсе югарырак булырга тиештер инде. Статусын һәм хокукларын да конгресс ачык билгеләр.

Югарыда сүз мәгърифәт турында да барган иде. Бу очракта мәгърифәт уку-укытуга гына кайтып калмый. Аңа тәрбия чараларының һәммәсе дә керә. Татар кешесен һәр җәһәттән дә камилләштерү күздә тотыла. Бигрәк тә әхлакый яктан Татар милләтен алдынгы цивилизацияле халыклар югарылыгына күтәрү — менә төп максат.

Дөнья безне танысын, без шуңа лаек булыйк.

*«Шәһри Казан», 1997*

## КҮҢЕЛ ЙОЛДЫЗЫ

...Зөһрә ханым сәхнәгә бик килешле ап-ак күлмәктән чыкты. Башында да таҗ сыман кечкенә ак калфак иде... Әйтерсең изге бер эшкә керешер өчен ул шулай тоташ актан гына киенгән... Иң беренче башкарган җыры да Тукайның «Тәэссер» дигән шигыре иде. Көен дә Зөһрә үзе язган... Аны ул озын саплы, сыңар кыллы думбрага кушылып җырлады... Тәэсире искиткеч булды... Мин мактауга юмарт кеше түгел, әмма күргән-ишеткәнемне яшерә алмыйм... Борынгы көйләребезгә тартым бик моңлы көй, ерак заманнардан бирле сакланып килгән думбраның гаҗәеп бер сихри-сәер тавышы һәм шуның ялгыз гына чиртүе, Зөһрәнең иркә дала җиледәй өзелмичә аккан уйчан-моңсу җыры күңелләрне шундый биләп алды ки, гүя без чынлап та йолдызлардан иңгән ак канатлы фәрештәдән Тукай догасын ишеткәндәй булдык.

«Ходай! Син тыйган эшләр тәмам әкътаг вә әбтәр, дим;
Иям баш сәҗдәгә: «Аллаһы хак! Аллаһы әкбәр!» — дим.

Бу концерттан Зөһрә ханым безгә яңа бер ягы белән ачылды: яраткан җырчыбыз чын мәгънәсендә Тукай җырчысы да икән... Гүя алар бер-берсен тапканнар. Икесе дә бик халыкчан, бик моңлы, бик садәләр... Бигрәк тә Зөһрә ханымның җыйнак-сылу гәүдәсе, чамалы гына хәрәкәтләренең нәфислеге, чишмә агышыдай ягымлы, иркен-көчле тавышы бу охшашлыкны бары тик көчәйтә генә иде. Арттырып әйтү түгел: Тукай үзе ишетсә дә, Зөһрәне әнә шул кыяфәтендә бик яратып тыңлар иде. мотлак, чөнки аның табигатенә һәртөрле кыланчыклык, ясалмалык, талымсызлык бик ят икәнен яхшы беләбез.

Тукай безнең җыр сәнгатендә үзенә аерым бик кадерле урын алып тора. Аның халык көйләренә җырлана торган «Зиләйлүк», «Әллүки», «Туган тел»е татар күңелендә мәңге сакланачак... Дөньяның берәр почмагында өч татар яши икән, алар очрашканда «Туган тел»не бергәләп җырламыйча калмыйлардыр, мөгаен, чөнки «Туган тел» ул бөтен дөньяга сибелгән татар галәмен милләт итеп саклаучы, берләштерүче, яшәтүче гимн-җырга күптән инде әйләнде...

...Өлкән буын композиторларыбызның да Тукай сүзләренә язган көйләре шактый икән (Тукай иҗатыннан файдаланып язылган зур музыкаль әсәрләр турында сүз бармый биредә). Зөһрә ханым үзенең ялгыз концертында әнә шул җырларның күбесен җырлап чыкты... Без гүя Тукайның үзе белән янәшә беткәнче моң-сагышка күмелеп утырдык.

Әмма өстәп шуны да әйтергә кирәк: Тукайның җанын, акылын, нинди шагыйрь икәнлеген тагы да ачыграк, тулырак тоярга һәм аңларга Илдус Әхмәтҗановның Зөһрә җырлары арасында шагыйрьнең шигъри юлларын камил белеп, гаять үтемле итеп, аеруча бер дәрт белән укуы да бик нык ярдәм итте... Нур өстенә нур дигәндәй, Илдус тарафыннан бик оста сайланган шигъри юллар Тукайга багышланган концертның мәгънә тирәнлеген һәм тәэсирен аеруча көчәйтте генә... Ихтимал, шул сихри тәэсир аркасындадыр, миндә сәер генә бер уй да туды: без Тукай исемен тәсбих төймәсен тарткандай өзлексез кабатларга яратабыз, әмма үзебез аңа лаек варислармы соң?.. Тукай югарылыгына күтәрелә алганыбыз бармы?.. Дөньяны күрә белүдә, аңлый белүдә Тукай дәрәҗәсенә җитәрбезме?..

Тукай җиһанга бик биектән караган — ерак офыклар ачылган аның үткен күзләре алдында... Ул үзен Пуш-

кин вә Лермонтов белән тиңләгән, татар халкының хокукларын дәгъвалап, патша хәзрәтләренә дә мөрәҗәгать иткән, халык көткәнне бирә алмаган Думадан да көлә белгән, шундагы карагруһ шовинистларга җавап итеп, «Китмибез» шигырен дә язган. (Бик хикмәтле шигырь, тик без аны бер генә яклы итеп укыйбыз.) Шул ук вакытта Тукай һәртөрле фиркаләрдән, сәяси шаукымнардан өстен торган шагыйрь. Ул әнә большевик Хөсәен Ямашевка да, имам-галим Шиһабетдин Мәрҗанигә дә багышлап үзенең мәдхиясен яза, чөнки ул аларның иң элек нинди чын, «бөтен» кеше икәнлекләрен күрә.

Тукай — ачы хакыйкать җырчысы... Үз милләтенең бөтен ямьле вә ямьсез якларын ачып салучы...

Яхшылыкка эреп китәм — балавыз мин,
Мактап сөйлим изге эшне — бал авыз мин;
Бер яманлык күрсәм, сүгәм, мактый алмыйм? —
Ул тугрыда бик явыз, ай-һай, явыз мин!

Яки:

Мәлганәт, пычырак вә ялган берлә тулган безнең эч;
Бар начарлыктан, бозыклыктан гыйбарәт безнең эш.
Шаккатабыз тышкы зиннәтләргә, киемнәргә карап;
Җан сатабыз әллә нинди вак «тиеннәргә» карап.

Һәм шагыйрь кыска гына гомеренең соңгы сулышына кадәр әнә шул пычрак вә ялганга, начарлык белән бозыклыкка каршы көрәшә дә. Ләкин ул үзен дә гөнаһлардан азат, изге җан дип санамый... Ул да кеше, бары тик кеше, әмма вөҗданын, намусын җуймаган кеше... Инде үләренә санаулы көннәр генә калгач, соңгы мизгелен көткән хәлсез шагыйрь тирән сыкрану белән икрар итәргә мәҗбүр була:

Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,
Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.
Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

Йә, егетләр, инде без, Тукай варислары, үзебез турында нәрсә әйтә алабыз?.. Әлбәттә, без дә тик ятмыйбыз (дибез инде), нидер эшлибез, аһ-зарларыбызны да яшермибез, «өстеннәрне» дә тәнкыйть иткәлибез — димәк, бигайбә!.. Әмма ләкин безнең өстебезгә утырган кер, тузан, пычрак та Тукайларныкы белән чагыштырганда берничә карышка калынрак бит... Мәгәр тоябызмы шуның авырлыгын, газабын, оятын?.. Кайда ул, Тукай шикелле, үзебезгә карата әйтелгән әче хакыйкать сүзе, каты таләп, чын гражданлык кыюлыгы?.. Пакьләнү сүзен минем әле берәүдән дә ишеткәнем юк... Кире-

сенчә, без үзебездән һәм эшебездән бик тә канәгатьбез бугай... Үзара макташу бик көчәйде... Кем турында гына сүз чыкмасын, ул — даһи!.. Хәтта кайберәүләрне исәнимин чагында ук «бөек ул, үлемсез» дип атый башладык... Ә Тукайга тере чагында «бөек син, үлемсез» дип әйтүче булмаган... Без менә бөтен бер гасыр буена аны исебез китеп укыйбыз. Үлемсезлек әнә шулай гына килә ул!..

...Тукта, без бит концертта утырабыз лабаса!.. Гафу итегез инде, минем болай «читкә чыгып» китүемне... Зөһрә әнә «Җидегән чишмә»не җырлый. Йа Хода! — сүзләре, моңы, җыры — яшьләрне тыю читен... Татар күңелендәниләр генә уятмыйдыр ул!..

Кодрәтле нәрсә ул сәнгать! Пакьләнер өчен дә безгә нәкъ менә җылата да, юата да алырлык шифалы чын сәнгать кирәктер, мөгаен... Рәхмәт Зөһрә ханымга «чын безнеңчә матур милли көй»ләре өчен!

*«Татарстан яшьләре», 1997*

## БЕР ХАТИРӘ

1957 елның августында мин Язучылар союзы командировкасы белән озын сәфәргә чыгып киттем. Юлым Алма-Ата, Ташкент, Сәмәрканд, Ашхабадка чаклы иде. Миңа йөкләнгән бурыч — журналыбыз «Совет әдәбияты»н пропагандалау һәм аңа язылуны көчәйтү иде. Булган ул елларда шундый зур эшкә безнең тәвәккәллек тә, мөмкинлек тә! Тик бу язмада мин өстемә йөкләнгән эшне тәфсилләп тормыйм, чөнки максатым башка. Сүзем казах халкының классик язучысы һәм олы галиме Мохтар Ауэзов турында.

...Алма-Атага баргач, мин беренче визитымны гадәт буенча Язучылар союзыннан башладым. Кемгә кердем, кем белән сөйләшеп чыктым — хәзер инде искә төшерә алмыйм. Әмма бер вакыйга һич онытылмаслык булып хәтеремдә калды. Таш йортның икенче катындагы баскычка каршы иркен зур бүлмәсендә бер-ике казах язучысы белән сөйләшеп торам. Шул чакта безгә якын ишектән тагын бер олырак яшьтәге казах килеп чыкты. Мин аны шундук таныдым — портретлары буенча бу Мохтар ага Ауэзов иде. Базык гәүдәле, зур башлы, ак чырайлы... Ул безнең яныбыздан үтеп китешли, туктала биреп, минем яндагы егетләр белән исәнләште, миңа да «бу кем» дигәндәй, бер карап алды. Һәм егетләр шунда ук «Казаннан килгән жазусы» дип, аны минем белән

таныштырдылар... Казаннан килгән татар язучысы аңарда кызыксыну уятты бугай. Кыска гына сөйләшү булды, үзе белгән берничә язучының исәнлеген сорашты, нинди эш белән килүемне сорады һәм, һич көтмәгәндә, миңа үзенең өй телефонын әйтте дә «иртәгә бер вакыт табып миңа чылтыратыгыз» дип китеп тә барды.

Язучылар союзыннан чыккач, туганнарыма кайтышлый мине һаман сөенечле бер гаҗәпләнү уйландырды: Мохтар агайның телефонын әйтеп, өенә чылтыратырга кушуын ничек аңларга?.. Минем язучы икәнемне ул, әлбәттә, беренче тапкыр ишетә торгандыр, чөнки исемем Казаннан читкә чыкканы юк диярлек... Ләкин мәшһүр өлкән язучы татар әдәбиятын, аның элеккеге һәм хәзерге зур язучыларын яхшы белеп, шуларга хөрмәт йөзеннән миңа да игътибарлы булгандыр дип уйладым. Әйтергә кирәк, Мохтар Ауэзовның абруе бик үскән, даны бөтен Советлар Союзына таралган чагы иде. Бик хаклы рәвештә аны казах әдәбиятының классигы һәм олы галиме дип таныйлар иде. (Ул академик иде.) Менә шундый кеше белән мин, үзе кушуы буенча, телефон аша гына булса да, тагын бер сөйләшергә тиешмен.

Икенче көнне мин сәгать уннар тирәсендә аңа чылтыраттым (минем уемча, бу аның өчен уңай вакыт булырга тиеш иде). Трубкада Мохтар аганың ашыкмыйча тыныч кына «кем» дигән тавышы ишетелде. Мин кичәге очрашуыбызны, аның чылтыратырга кушуын исенә төшердем. Аз гына тынып торганнан соң, ул сорады: Сез бүген миңа килә аласызмы?.. Мин шунда ук, теләгән вакытыгызда бара алачакмын, дидем. Ул сәгатен әйтте һәм адресын язып алырга кушты. Шуның белән сүз бетте.

Минем якын туганнарым Зөләйха белән Шәрәфетдин Горький урамында, Галимнәр йортында торалар иде. Алар икесе дә Алма-Атаның югары уку йортларында укыталар. Соңрак Шәрәфетдин Казах университетында математика кафедрасының мөдире дә булды... Алма-Ата — ул бакчалар эчендәге шәһәр, ә минем әле бу шәһәргә беренче килүем генә. Шулай да, туганнар өйрәтеп җибәрүе буенча, мин үземә кирәкле урамны тиз таптым. Кызганыч, исемен оныткanmын, ләкин ул бакча аллеясы шикелле туп-туры сузылган озын бер урам иде. Нәкъ уртасыннан ике яклап утыртылган биек таза агачлар тезелешеп баралар. Мин шул сөзәк кенә үргә таба күтәрелгән аллея-урам буйлап ашыга-ашыга атладым. Менә ул миңа кирәк йорт. Ул якта берничә колонналы ап-ак ялгыз таш йорт... Урта бер җиреннән урамга караган парад-

ный ишек. Мохтар агай бик хаклы рәвештә үзенә аерым шәп йортта тора икән, дип, эчемнән генә уйлап куйдым... Ишегенә килеп, звонок төймәсенә бастым. Миңа ишекне пөхтә киенгән, башына җиңелчә генә яулык бәйләгән урта яшьләрдәге бер мөлаем ханым ачты. Күкрәкчәле алъяпкычына карап, мин аны хадимәдер дип уйладым, сөйләшүеннән дә шулайрак сизелде. Ул миңа:

— Мухтар Омирханыч тышта бакчада әле. Киностудиядән аны төшерергә килгәннәр иде, озакламый бушар. Сез шушында көтеп утырыгыз,— диде.

Ишектән кергәч зур гына бүлмә, хәзергечә холл дисәк тә була. Чиста җыештырылган, стена буена йомшак урындыклар куелган. Мин, рәхмәт әйтеп, шуларның берсенә утырдым. Киностудиядән нинди уңай белән килделәр икән, дип уйлап куйдым. Хәер, хуҗаны озак көтәргә туры килмәде. Мохтар ага каяндыр үзе генә килеп чыкты. Мин тордым. Исәнләшеп күрештек.

— Кинога төшерүчеләр ике сәгать вакытымны алдылар,— диде ул, аз гына зарлангандай. Аннары каршыдагы биек икеле ишекнең берсен ачып, мине бер бүлмәгә ияртеп керде. Бу аның эш бүлмәсе икән. Түрдә зур таза язу өстәле, аңа язу машинкасының да кечкенә өстәле терәп куелган... Мәгәр мин кабинетның эчен махсус кызыксынып карарга, билгеле, кыенсындым. Ләкин аның зур һәм якты булуына игътибар итмичә калмадым... Һәрхәлдә, мондагы бөтен нәрсә бик затлы, бик матур иде кебек... Тагын хәтердә калганы — ишектән сул яктагы келәм җәйгән иркен бер урында казахның, аяк бөкләп утырып, чәй эчә торган кечкенә тәбәнәк өстәле тора иде... Бу инде Мохтар аганың үзенә килгән дус-ише белән чәй эчә-эчә гәпләшеп утыра торган урыны булырга тиеш...

Ләкин без зур язу өстәле янына утырып сөйләштек. Сүзне, билгеле, хуҗа үзе башлады. Минем белән ул татарча дип әйтерлек сөйләште — һәр сүзен мин аңлап бардым. Һәм сүзен дә ул, ни гаҗәп, турыдан-туры татар әдәбияты, татар язучыларын мактаудан башлап китте.

— Тукайлар, Галимҗаннар сезнең генә түгел, безнең дә беренче мөгаллимнәребез,— диде.— Безнең казахта бары татар әдәбиятында тәрбияләнеп үскән язучылар да бар.

Шуларга өстәп Мохтар ага, татарлар революциягә кадәр Русиядәге төрки халыклар арасында иң алдынгы халык иде, дигән бик кыю фикерен дә әйтте... Минемчә, Казаннан килгән билгесез бер язучыга яхшатланып кы-

на әйтелгән сүзләр түгел иде бу. Олы акыл иясенең тарихны бик яхшы белеп әйткән сүзләре иде алар...

...Янә сөйләшү ахырындарак Мохтар ага моңарчы мин ишетмәгән куанычлы яңа бер хәбәрне дә миңа җиткерде. Үзбәк шагыйре Гафур Голәм белән алар икәү күптән түгел Мәскәүдә булып кайтканнар... Икесе дә Ленин премиясе комитетының әгъзалары икән... Менә шул комитет утырышында язучылардан кемнәргә Ленин премиясен бирү мәсьәләсе каралган. Сүз безнең Муса Җәлил турында да барган. Кайбер комитет әгъзалары Муса Җәлил шигырьләренә зур бүләкне бирүгә каршы чыкканнар. Мохтар ага әйтә, без Гафур Голәм белән Мусаның «Моабит дәфтәре» Ленин премиясенә һичшиксез лаек булуын исбат итеп чыктык, ди. Бәхәс кызу булды, әмма без үз сүзебездә нык тордык, күпчелек тә безгә кушылды һәм Муса Җәлилне Ленин премиясенә комитет исеменнән тәкъдим итүгә дә ирештек, ди.

...Мохтар аганың бу ашыкмыйча гына әйткән сүзләрендә мин мактануга охшаш берни дә сизмәдем, ләкин хаклы бер эшне яклаудан туган канәгатьләнү сизелмичә калмады. Инде кузгалырга вакыт иде... Хушлашып китәр алдыннан ул миңа тагын шуны да әйтте:

— Шушы айда минем 60 яшемне бәйрәм итәчәкләр... Вакытыгыз булса, килегез, кунагым булырсыз,— диде.

Мондый көтелмәгән тәкъдим мине, әлбәттә, һәм сөендерде, һәм көендерде. Тыныч калу мөмкин түгел иде.

— Юк шул, Мохтар ага, миңа тиздән китәргә кирәк,— дидем, дулкынлануымны баса алмыйча, һәм, кат-кат рәхмәтемне әйтеп, аның җылы йомшак кулын кыстым.

Мохтар ага мине кабинет ишеге төбеннән озатып калды. Әлеге мөлаем ханым миңа парадный ишеген ачып озатты.

Урамга чыккач та, мин тиз генә тынычлана алмадым. Урам-аллея буйлап бара-бара һаман бер нәрсәне аңларга тырыштым: хуш, олы әдип белән бу очрашу ни өчен әле мине шулкадәр гаҗәпләндерде һәм сөендерде?.. Күрәсең, күптәнге бер хакыйкать: бөек кешеләргә гадилек хас лабаса! Алар бит кайда гына, кем белән генә очрашмасыннар, «бу кеше минем кем икәнлегемне беләме икән?» дигән уй-хәсрәттән азатлар... Мохтар Ауэзов белән бер сәгать чамасы сөйләшеп утыру әнә шул җәһәттән минем өчен дә сабак булды. Ә аңа баруым 1957 елның 18 сентябрендә булган икән — блокнотыма шулай язып куйганмын. Быел исә мәрхүмнең тууына 100 ел тулуны казах халкы бәйрәм итәчәк.

*«Ватаным Татарстан», 1997*

## ШӘХЕС

Башта мактанып аласым килә: мин Бакый абзый Урманчега иң якын кешеләрнең берсе идем. Без сердәшләр идек. Без бик теләп сагынышып очраша идек. Араларыбыз ерак, ул Ленин, ә мин Вахитов районында, еш очрашып та булмый, әмма инде барып чыккан чакларымда без сөйләшеп туймый идек. Ачыктан-ачык, турыдан-туры, күңелдә булганның бөтенесен сосып сөйләшә идек. Һәм нәрсәләр турында гына сүз бармый иде: заман, җиһан, милләт, режим, җитәкчелек, әдәбият һәм сәнгать — берсен дә калдырмый идек. Һәм шуларның барсына да карашларыбыз бер диярлек яки бик якын. Асылда исә ул карашлар заманны һәм дөньяны үзебезчә тирән аңлап тәнкыйтьләүдән гыйбарәт иде. Ни дәрәҗәдә бер-беребезгә ышануыбызның, никадәр якын фикердәш булуыбызның бер дәлиле итеп, Бакый абзыйның миңа язган сүзләрен биредә китермәкче булам, ләкин, зинһар, мине тыйнаксызлыкта гаепләмәсәгез иде. 1982 елда оештырылган зур күргәзмәсенең каталогына менә ниләр язып биргән иде ул:

> *«Газиз дустым, моңдашым, олугъ әдип, намус иясе Әмирхан мирза Яники җәнапларына — тамь самимият белән Габделбакый».*

(Бу сүзләр билгеле гарәп хәрефләре белән язылган, шуңа күрә бер сүзне «тамь» дип күчердем. Дөрес булуына шигем зур.)

Дөрес, Бакый абзый һәркемгә диярлек «дустым» дип дәшәргә ярата иде. Мәгәр бу очракта миңа карата язган сүзләре аңа хас әдәп, нәзакәтлелек билгесе генә түгел, минемчә... Бу — башка. Кешесе дә, мәгънәсе дә башка.

1997 елның февралендә Габделбакый Идрис улы Урманченың тууына 100 ел тулачак. Ә март башында миңа, исән торсам, 88 яшь булачак. Аерма 12 ел. Шулай да без бер заман, бер чор кешеләре идек. Бер үк тоталитар системада яшәп, аның төрле дәверләрен күреп уздырган совет гражданнары идек. Бакый абзый күрү генә түгел, ул системаның нәрсә икәнен үз җилкәсендә дә татып өлгергән иде инде. Мәгълүм булганча, егерменче елларның ахырында ул солтангалиевчелектә гаепләнеп, 5 ел Соловкида да торып кайтты. Елын ачык кына хәтерләмим, Соловкидан котылгач, ул каядыр китеп барышлый Казанда бер генә тәүлеккә тукталган чагында, аның белән миңа очрашырга да туры килгән иде. Очрашу —

шәкерте рәссам Мортаза Абдуллинда булуы. Кунагы янына Мортаза мине дә дәшкән иде. Бакый абзыйны беренче күрүем, мәһабәт-таза, бөтен кыяфәтеннән үзенә бер ягымлылык бөркелеп торган ир уртасы кеше, ләкин сөргеннән кайтканлыгы өс-башыннан ук күренеп тора: аякларында гади солдат итекләре, өстендә таушалган кыска бишмәт (бушлат), башында... ансын хәтерләмим, мәгәр татарда сирәк очрый торган аксыл чәчле икәнлеге исемдә калган... Әзрәк кенә эчтек, ашадык, аны-моны сөйләшкәләп утырдык, ләкин бик тирәнгә кермичә генә... Бакый абзый гел елмаеп кына утырды — без дә аңлый идек моның сәбәбен. (Авызы пешкән кеше салкын суны да өреп каба.) Аннары елмаю аңа бик килешә дә иде. Табигатенең бер сыйфаты — гомере буе ул елмаеп яшәде... Соңыннан Мортазадан ишетеп кенә белдем — Бакый абзыйга Мәскәүдә дә, Казанда да тору тыелган, хәзер аның Урта Азия якларына табан китеп баруы икән.

Чынлап торып танышуыбыз сугыштан соң, Бакый абзый Казанга кайткач башланды. Ничектер бик тиз якынаеп киттек — гүя бер-беребезгә мохтаҗ кешеләрдәй... Болай диюем кайберәүләргә, бәлки, сәер дә тоелыр, чөнки Бакый абзый һәркемгә бик ачык кеше иде, дус-ишләре дә күп иде. Күбесе белән бик ихлас сөйләшеп утырулары да аз булмагандыр... шулай да безнең арадагы дуслык башкачарак иде. Сәбәбе — башта әйткәнемчә, күп мәсьәләләрдә карашыбызның тәңгәл килүе иде. Күрәсең, очрашып танышканчы ук инде безнең рухи халәтебез һәм фикер сөрешебез бертөслерәк булгандыр. Миңа аның «моңдашым» дип язуы да шуңа ишарә түгелме соң?! Һәрхәлдә, Бакый абзыйның шулай диюе җыр-моң ятатуы белән генә бәйләнмәгән ул, минемчә...

Әйтергә кирәк, җыр-моң Бакый абзыйдан чишмә шикелле бәреп тора иде. Күпләр белә моны, күпләрнең аны сокланып, исләре китеп тыңлаганнары бар. Әмма миңа ни сәбәптер аның Коръәнне кычкырып укуы гаять ошый иде. Мәгәр миңа гына микән?.. Бу уңай белән бер вакыйганы искә төшерәсем килә. Хәсән абзый Туфанның 80 яшьлек бәйрәменә Уфадан Сәйфи ага Кудаш белән Нәҗәр Нәҗми дә килгәннәр иде... Юбилей көннәре үтеп киткәч, Нәкый абзый Исәнбәт Уфа кунакларын үзенә чакырып алды. Билгеле, алар янына Хәсән абзый үзе дә, Бакый абзый да, мин дә чакырылган идем. (Җәмәгатьләребез белән бергә.) Әйбәт кенә ашап-эчеп, күңелле генә сөйләшеп утырганнан соң, мин Бакый абзыйдан мөхтәрәм кунакларга Коръән дә укып күрсәтүен үтендем. Нәкый абзый да моңа бик теләп кушылды. Һәм Бакый

абзый артык кыстатып тормыйча, тик аз гына тынып торганнан соң, бик әйбәтләп Коръәнне яттан укый да башлады. Без һәммәбез дә мәрткә киткәндәй өнсез калып, тын да алмыйча, аны тыңладык. Тәэсире искиткеч булды, бигрәк тә Уфа кунакларына, Сәйфи абзыйның күзләренә мөлдерәп яшьләр дә килде. Ул да бит «Галия» шәкерте, Коръәнне менә шулай укыган чаклары да булгандыр, ләкин совет заманында аңа дуслар мәҗлесендә бер генә тапкыр булса да Коръән укыганны ишетергә туры килде микән?! Минемчә, ул чакларда түгел, хәзер дә Уфаның шагыйрьләр мәҗлесендә Коръән укылмый торгандыр... Ә бездә Бакый абзый исән чакта укыла торган иде. Белмим, аның кебек шундый көчле-көр тавыш белән, шундый моңлы-матур мәкам белән һәр сүзен, һәр ноктасын аңлап-тоеп Коръәнне укый алучы бүтән берәр кеше Казанда булды микән?! Аны ишетү — илаһи бер мизгел иде.

Һәркайсының тормыш юлы кабатланмас бер тарих. Ләкин нидер аларны берләштерә дә... Язмышларындагы охшашлык түгелме икән... Дүртесе дә бит рәхимсез тоталитар системаның каты сынаулары аша үттеләр. Ирексездән Дәрдемәнд сүзләре искә төшә: «Биетте ажгырып аны замана»... (Һәркайсын.) Әмма ничек кенә биетмәсен усал замана, аларның берсе дә сыгылса да, сынмады... Күптән инде алар һәртөрле ялганнан айныган, һәрнәрсәгә төпле нык карашлары булган, үз бәяләрен дә бик яхшы белгән, Тукайча әйтсәк, бөтен шәхесләр иде. Тормыштагы кыйблалары да ачык булды: халыкка хезмәт итмәктә!.. Һәм моны алар гомерләре буе баш күтәрмичә эшләп калдырган гаять бай үлемсез мираслары белән исбат та иттеләр... Тик саклый бел дә, кадерен генә бел!..

...Алардан калган рухи байлыкны сакларга тиешле дәүләтебез бар, аның Фәннәр академиясе дә бар бит әле. Игътибарны да, кайгыртуны да шулардан көтәргә туры килә. Ләкин безнең Татарстанда элек-электән үк иҗат кешесенең эшенә игътибар җитәрлек дәрәҗәдә булмады. Җитәкчеләребез аларга да үз вазифаларын үтәүчеләр итеп кенә карадылар, һәм эшләренә дә башлыча конъюнктура таләпләреннән чыгып кына бәя бирделәр. Иҗат ителгәннең сыйфаты һәм тарихи әһәмияте күп очракта исәпкә алынмый да иде.

Әнә бит нindидер билгесез сәбәпләр аркасында Бакый Урманче музеен оештыру мәсьәләсе дә һаман хәл ителә алмыйча сузылып килә. Хәлбуки Бакый абзыйдан калган байлыкны бары махсус музей оештырып кына җыеп һәм саклап булачак. Искә төшерик — кем ул Ба-

кый Урманче татар мәдәнияте өчен?.. Менә аның хакында Нәкый Исәнбәт фикере: «Бездән татар поэзиясе һәм музыкасының нигезләрен салучылар кемнәр?» — дип сорасалар, без Тукай белән Сәйдәшне атыйбыз. Инде татар сынлы сәнгатенең нигезен салучы кем дип сорасалар, без Бакый ага Урманче дибез»... Димәк, өчәүнең берсе... Исәнбәт сүзләренә аеруча игътибар итәргә туры килә, чөнки әдәбиятыбызны һәм сәнгатебезне бик тирәнтен белгән кешенең сүзләре... ...Югыйсә бит Тукайга кадәр дә гасырлар буе татар поэзиясе яшәп килгән (бер үк елларда Дәрдемәнд кебек бөек шагыйрь дә яшәгән). Сәйдәшкә кадәр дә музыка язучылар булган (Солтан Габәшине генә искә төшерү дә җитә), шулай ук Урманчега кадәр дә сурәт ясаучылар булгандыр, мотлак... Әмма Исәнбәт аларның өчесен дә «нигезен салучылар» дип атый... Һәм бу бик дөрес, һәм бик хаклы да. Нәкъ Тукайдан башлана саф татар җанлы шигъриятебез, Сәйдәш белән Урманчедан башланып китә музыка һәм сынлы сәнгатьнең профессиональ сәнгать буларак тәмам формалашуы һәм танылуы...

Алардан соң мәйданга кемнәр генә, нинди генә даһилар күтәрелеп чыкмасын, әмма Тукай, Сәйдәш, Урманче иҗаты — олы елганың чишмә башы шикелле, мәңге тибеп торачак. Шулай гына яшәвен дәвам иттерә һәрбер милли әдәбият, милли сәнгать. Моны яшьләр бик нык исләрендә тотарга тиешләр. Әлбәттә, эзләнү кирәк, яңа табышлар кирәк, иҗат шунсыз була алмый, әмма ләкин табышларның да шул ук тирәндә яткан төп тамырдан үсеп чыгуын да онытмаска кирәк.

Яшь аермасы шактый булуга карамастан, миңа соңгы 20—25 ел дәвамында Бакый абзый белән дә, Нәкый абзый белән дә, Уфадагы Сәйфи ага белән дә бик якыннан аралашырга туры килде... Кунакка йөрешүләр, мәҗлесләрдә бергә утырулар гадәткә кергән иде инде. Аннары мин аларга үзем генә дә һаман баргалый идем. Бусы аеруча тансык иде безнең өчен... Иң ихлас ачык сөйләшүләр дә шул чакта гына була да торган иде.

...Картларга мине нәрсә тартты, нәрсә аеруча якынайтты?.. Күп мәсьәләләрдә уртак фикер, уртак караш булуын әйткән идем инде. Шулар өстенә искә төшерерлек кадерле исемнәрнең булуы да үзара якынлыкны көчәйтә генә иде. Хосусан, Тукайга мөнәсәбәтләре... Алар һәммәсе дә чын мәгънәсендә «тукайчылар» иде. Тукайга гомерлек мәхәббәт саклау гына түгел, аның бөтен иҗатын бик тирән белүчеләр һәм аңлаучылар да иде. (Нәкый абзый, мәсәлән, бөтен Тукайны яттан белә иде.)

...Инде Бакый абзыйга килсәк, ул мәрхүм рәссам һәм һәйкәлтараш (скульптор) буларак, Тукайның үзен, шулай ук әдәби образларын мәңгеләштерүдә күпме гомерен биреп, күпме онтылмаслык сурәтләрен ясап калдырды. Аның бу эшләре күпкырлы гаять бай иҗади мирасының Тукайга гына багышланган, махсус өйрәнүгә лаек олы бер тармагын тәшкил итеп тора.

Ләкин дә бит әле Бакый абзабыз, Тукай үлгәч, аның баш очында тәһлил әйтеп, Коръән укып төн чыккан яшь шәкерт тә, һәм шул ук вакытта бөек шагыйрьне озатуның милли матәмгә әйләнүен үз күзләре белән күреп калучылардан безнең көннәргә кадәр яшәгән бердәнбер кеше дә иде ул... Ә мин шуларны аның үз авызыннан ишеткән кеше — ихтимал, бу да тарихка кереп калыр әле...

Аннары Бакый абзый инкыйлаб елларында Гаяз Исхакый белән дә очрашырга өлгергән. (Кулын үбеп күрештем дип сөйләгән иде.) Исхакыйның татар дөньясында даны аеруча нык күтәрелгән чагы, аңа баш июче яшьләр, әлбәттә, күп булгандыр, мәгәр дошманнары да аз булмаган — бигрәк тә большевикларга иярүчеләрдән. Әмма Гаяз Исхакый барысыннан элек бөек әдип — менә шунсы Бакый абзыйны беренче нәүбәттә әсир иткән булырга тиеш... Мин дә Гаяз Исхакый дигән әдипне ишетеп кенә түгел, бик яшьтән үк укып та беләидем. Бездә аның кайбер әсәрләре бар иде — егерменче елларның башларында ук миңа шуларны укырга да туры килде. (Соңыннан иң хәтәр елларда да мин аларны үземдә саклaдым.) Күрәсез, Гаяз Исхакый мәсьәләсе дә безнең өчен уртак тема иде.

...Үткәннәр турында сүз чыкканда, Бакый абзый Соловкида бергә «утырган» якын танышларын — Татарстанның беренче җитәкчеләреннән Кашшаф Мохтаровны, Микъдат Бурундуковны, Мәхмүх Бөдәйлине, шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләйне, янә шунда ук Солтангалиевнең үзе белән дә очрашып сөйләшүләрен еш кына исенә төшерә торган иде... Сәгыйть Сүнчәләйне инде мин бала чагымнан ук беләм — ул бит җизнәбез Шәриф Сүнчәләйнең бертуган энесе иде.

...Әнә шундый «уртаклыклар» бар иде безнең арада — әлбәттә, якынча. Бакый абзый белгәннәрнең һәммәсен дә мин дә беләидем, дию зур тыйнаксызлык булыр иде, мәгәр күргән-кичергән заманнарыбызның бер үк чорларга туры килүе безгә аңлашырга бик ярдәм итә иде булса кирәк.

...Кайбер нәтиҗәләр ясарга да вакыттыр, ахрысы — шунсыз күңелдәгене әйтеп бетереп булмас кебек...

Картлыкка ияреп ялгызлык килә. Озак яшәгәннәр өчен бу сер түгел, мәгәр төрле кешегә төрлечәрәк килә ул ялгызлык... Минем үземә ничектер капылт килде: берзаман тукталып тирә-ягыма карасам, мин япа-ялгыз калганмын, имеш!.. Үз тиңдәшләремнән берәү дә калмаган — бөтенесе китеп беткәннәр... Хәтта миннән шактый яшьрәк замандашларымның да күбесе юк инде — татар әдәбиятының соңгы 2—3 ел эчендә генә дә бу хәтле күп югалтуларга дучар булуына искитмичә мөмкин түгел... Әйтерсең яңа заман белән бергә ниндидер үләт килде безгә...

Бу гасырның башында туганнардан без икәү генә калдык: Гомәр абзый да мин генә!.. Гомәр абзый үзен ничек тоядыр, мәгәр мин соңгы бер-ике елда нык кына бирештем... Аның белән дә җәмәгать урыннарында гына аратирә очрашабыз. Хикмәт шунда ки, картлык көчәя барган саен, үзара бәйләнешләр дә зәгыйфьләнә бара.

Әйтергә кирәк, әлеге фоторәсемдәге мөхтәрәм абзыйлар озак яшәделәр һәм тигез картайдылар. Һәммәсе дә диярлек туксан яшьләрен җиңел атлап уздылар. Тик араларыннан Хәсән абзый гына иртәрәк китеп барды. (Аның күргән-кичергәннәре белән сиксәнгә җитүенә дә шөкрана кылмыйча мөмкин түгел...) Ә менә Сәйфи ага, рәхмәт төшкере, йөз яшенә дә җитә язды — ел ярым гына калган иде бугай...

Ләкин шулай да аларның күрер күзгә үк иң тазасы, аксавына да карамастан, Бакый абзый иде, әлбәттә... Күрәсең, аңа тазалыгын, җегәрлеген сакларга рәссамлык белән һәйкәлтарашлык эше бик нык ярдәм иткәндер. Әгәр дә көтелмәгән сырхау килеп чыкмаса, бәлки, йөзгә дә җиткән булыр иде. Ул үзе дә моңа гүя бер дә икеләнмичә ышана иде.

Әмма тәкъдиреңә язылганны күрми чара юк. Соңгы тапкыр без шифаханәдә очраштык. 1990 елның апрелендә булса кирәк, мин үпкә авыруы белән шифаханәгә кердем. (Чехов базары янындагы спецклиникага.) Бакый абзый белән Флора ханым да шунда аерым бер палатада яталар иде. Ләкин аларның чыгар вакытлары җиткән иде инде. Бер-ике көн генә алар янына кереп, Бакый абзый белән сөйләшеп утыра алдым. Авыруы турында сүз булмады диярлек — шифаханәдән чыгаралар икән, димәк, хәвефләнергә урын да юк кебек иде...

Мәгәр күпмедер вакыттан соң алар яңадан керәләр — бу юлы инде ерактагы республика шифаханәсенә... Шунда Бакый абзыйга операция ясыйлар... Әмма ни хәлләр итәсең — әҗәлгә килгән авырудан котылу юк, күрәсең! Өендә тагын күпмедер ятканнан соң, Габделбакый Ид-

рис улы Урманче августның алтынчы көнендә фани дөнья белән мәңгегә бәхилләшә. Җеназа укытып озату 9ында булды. Кабере Тукай янында, башы очындарак... Ахирәткәчә алар бергә булачаклар. Бакый абзый да Тукай шикелле үк Аллага инанган һәм сыенган кеше иде. Тукайның вафатын ишеткәч, Фатих Әмирхан укыган догаңы минем дә кабатлыйсым килә: Иннәә лилләәһи үә иннәә иләйһи раажигун!.. Адәм баласы өчен Аллага кайтудан башка чара юк!.. Ышансаң-ышанмасаң да...

Мин чын ихластан әйтә алам: әнә шул исемнәре аталган асыл затлар белән якыннан аралашуымны гомерем өлешенә чыккан сирәк олы бәхеттән саныйм. Кемгә ничектер, әмма минем үземә аларның йогынтысы гыйбрәтле китап укыгандай бары уңай, бары файдалы гына булды. Алар безнең дәвернең бөтен мәкерле сынаулары аша үтеп тә иманнарын җуймаган таза үзәкле, тотрыклы кешеләр булып кала бирделәр. Менә шуны яхшы аңлаган әдип-шагыйрьләр, сәнгать әһелләре һәм галимнәр аларга һәрдаим тартылалар да иде... Бакый абзыйның остаханәсенә, мәсәлән, яшь рәссамнар еш кына килеп йөриләр иде. Ул уздырган мәҗлесләрдә әдипләр, фән әһелләре белән бергә музыкантлар, җырчылар да була торган иде. (Фәридә Кудашева — Казанга килгән саен — Ренат Еникеев, Шамил Монасыйпов аның даими кунаклары иде.) Үзе дә — җырга гашыйк кеше — еш кына аягүрә басып, көр, иркен тавышы белән йә «Уел»ны, йә «Ончы Фәхри»не җырлап җибәрә торган иде.

Шуларны искә төшергәч, бик мөһим бер нәтиҗә үзеннән-үзе туа: әйе, алар кебек күпне белгән, күпне кичергән шәхесләр белән якыннан аралашу ул ничектер милли аңны тирәнәйтә, милли тойгыны көчәйтә... Алай гына да түгел, фикри офыкларны киңәйтә — гүя тар дөньядан иркенрәк дөньяга чыгара...

Моның шулай икәнен, үзем татыган кеше буларак, аеруча яшьләр колагына әйтәсем килә: өлкәннәр тәҗрибәсе файдалана белгәндә зур мәктәп ул... Мәгәр яңа заман яшьләре совет заманыннан калган картларны өнәп, яратып бетермиләр. Тоталитар системаның бөтен әшәкелекләрен шулардан күрмәкчеләр... Билгеле, ул заманнардан калган картлар арасында кемнәр генә юк?! Ләкин бит яшьләр дә бервакытта да бер генә төсле булмадылар. Без аларны күреп уздык. Сыйнфый көрәш юри чамасыз көчәйтелгән чакларда, идеология сагында торып, үтә «уяулык» күрсәтүче яшь «тәнкыйтьчеләр» Такташ бичараның җанын соңгы гомерендә күпме кыйнамадылар... Аның дустын, бер гөнаһсыз әдип Садри Җә-

лəлне дə, махсус «чистарту» оештырып, «Дим буенда» романын язганы өчен генə эт итеп сүктелəр. (Ə роман морзалар тормышыннан, Тургенев стилендə.) Мескен Садри абзый сəхнəдəн төшмичə үк: «Ник кенə яздым мин шуны?!» — дип, өстəлгə капланып җылаган да, имеш!..

...Кеше замана колы иде — гамəлен дə аның замана билгелəде. Җитмеш ел буена ул шулай дəвам итеп килде. Сугыштан соң əдəбиятка килгəн яшьлəрнең барсы да диярлек партиягə кереп беттелəр... Хəзер инде шуларның бик күбесе йə кəттə демократ, йə ата миллəтче!..

Ə менə мин замана колына əверелмəгəн, үзенчə яшəп, үзе телəгəнне иҗат итə алган мөхтəрəм Бакый ага Урманче җəнаплары турында яздым... Чөнки ул кабатланмас чын шəхес иде. Аны оныту мөмкин түгел. Күңел əле дə булса аны юксына. Кайчандыр мəрхүм Такташ та «шаян» бер шигырендə: «Дөнья матур, Лəкин сезнең өчен Ни кызыгы калыр мин үлгəч»,— дип язган иде.

Сизгəн шагыйрь кешелəргə кирəклеген... Əмма ни үкенеч: сирəк, бик сирəк туа алар шикелле кабатланмас шəхеслəр!

*Казан—Ромашкино*
*Август, 1996*
*«Казан утлары», 1997, 1 сан*

## НƏГЫЙМƏ ТАҖДАРОВА

### *Укучы игътибарына*

*Нəгыймə Таҗдарова турындагы бу монография 1945—1946 елларда язылган иде. Нəгыймə апа үзе исəн иде əле, лəкин каты авыру иде инде... Мин аның янына йөреп, хəле җиткəн кадəр сөйлəтеп һəм килгəн саен язганымны аңа укып бардым... Ул үзе турында язганны ишетеп дөньядан китте, мəрхүмə!*

*Əйтергə кирəк, безнең əдəбиятта артист иҗатына махсус багышланган беренче хезмəт ул минем язганым... Лəкин аны китап итеп чыгару бары 1957 елны гына мөмкин булды... Беренче-икенче буын артистларыбыз күптəн инде китеп бетте — сəхнəлəребездə хəзер картаеп барган урта буын да, яңа — яшь буын!.. Шуңа күрə дə мин татар театрының 90 еллыгын билгелəп үткəн көннəрдə бөек артисткабыз Нəгыймə Таҗдарова турында бик күптəн чыккан рисалəне, яшь буын, бəлки, кызыксыныр дигəн өмет белəн, яңадан гəзит битлəрендə бастырып чыгаруны кирəк таптым. Билгеле, бер генə сүзен дə үзгəртмичə — укучы моны исендə тотсын иде.*

...1915 елның 19 январенда «Новый клуб» (хәзерге Тинчурин театры.— *Ред.*) сәхнәсендә «Сәйяр» труппасы «Ямьсез тормыш» дигән яңа спектакль уйнап күрсәтә. Уйнаучылар арасында арык кына гәүдәле, зифа буйлы, ак чырайлы бер яшь ханым да була. Ул Һаҗәр исемле бер хатын булып уйный. Тамашачылар сәхнәдә беренче мәртәбә күренгән бу «артистка»га шактый сәерсенеп карыйлар. «Артистка»ның тавышы бик әкрен ишетелә, бөтен хәрәкәтеннән аның тарсыну, уңайсызлану сизелеп тора: гүя ул үзе дә сизмәстән ялгыш кына халык алдына килеп чыккан да аптырап каушап калган... Тиз генә борылып качар иде дә, тик менә янындагы иптәшләре аңа ирек бирмиләр... Безнең уебызча, шул чакта күпләр «артистка»ның бу беренче чыгышын бик үк ошатып бетермәгәннәрдер. Алар аның турында, ихтимал, «буе-сыны да бар, йөзе дә сөйкемле, тавышы да ягымлы, әмма шулай да артистка була алмас, артык кыюсыз, оялчан» дигән нәтиҗәне ясаганнардыр.

Яшь «артистка» бераз югалып торганнан соң, тагын тамашачылар алдына чыга. Бу юлы ул үзенең ролен шактый шома үтәгән кебек була. Ләкин... әлеге дә баягы кыюлык җитмәү аны тагын суя. Шик юк, нидер бар бу сөйкемле ханымда, тик ни сәбәптәндер ачылып, җәелеп кенә китә алмый ул!

Берничә ел вакыт уза... Яшь «артистка»быз Казан тамашачыларына үзен, ниһаять, танытып өлгергәч кенә, каядыр югала... Менә бервакытны Оренбург, Уфа сәхнәләрендә яңа бер исем калкып чыга. Аның турында сөйлиләр, язалар... Галиябануны кем уйнаган? Ул. «Юлбасарлар»да Амалия кем иде? Ул инде, ул! Ә «Уйнаш»тагы Сәрби, «Мәкер вә мәхәббәт»тәге Луиза?.. Халык арасында шундый сүз йөри: имеш, «Мәкер вә мәхәббәт»нең соңгы картинасында, Фердинанд Луизага эчәргә биргән чакта, залдан берәү «Эчмәгез, агу ул!» дип кычкырып җибәргән, ди. Ләкин тамашачылар сәхнәдә барган уенга шулкадәр йотылганнар, имеш, теге берәүнең кычкыруын гүя бөтенләй ишетмәгәннәр — залдагы тирән тынлык шул килеш сакланып калган, ди. Әнә шулай тамашачыларны биләп алган ул яшь «артистка»!

...Бер ун ел чамасы вакыт үткәч, безнең «артистка»быз яңадан Казанга кайта. Тамашачылар аны таныйлар. Бу әлеге шул «Ямьсез тормыш»та курка-курка гына уйнаган юка гәүдәле, ак чырайлы «артистка» икән. Ләкин нинди зур үзгәреш! Кая ул элекке кыюсызлык, эзе дә калмаган. Бу инде үзенең көченә нык ышанган, тәмам өлгереп җиткән сәхнә остасы. Спектакльдән спектакль-

гә ул тамашачыны үзенә ныграк бәйли бара, һәр уйнаган роле белән үзенең, чыннан да, нинди зур көчкә ия булуын күрсәтә бара.

Шушы кайтуыннан ул, бүтән беркая китмичә, үлгән көненә кадәр, ягъни 1947 елның мартына чаклы, татар сәхнәсенә хезмәт итә. Берсеннән-берсе гүзәл, онытылмас образлар тудырып, ул халыкның тирән мәхәббәтен казана.

Без менә шул зур сәхнә остасы — Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисткасы Нәгыймә Таҗдарова турында кадәрихәл сөйләп бирергә булдык.

## Авыл кызы

Нәгыймә ханым 1888 елны Утараты (хәзерге Татарстан, Арча районы) авылында Әхмәдулла агай семьясында туа. Кайсы айның кайсы числосында? Ул кадәресе билгеле түгел. Баланың тууын теркәгән мулла метрикасында әнә шул елдан башка нәрсә табылмый. Инде елның дүрт фасылын дүрт төрле дөнья нужасына җигелеп үткәргән атаана да кызларының тәгаен туган көнен хәтерләрендә саклап тота алмаганнар. Җитмәсә, Әхмәдулла абзый белән Сәхипҗамал җиңги өчен Нәгыймә сигезенче бала булып тормышларына керә һәм унынчы кашык булып табыннарына утыра. Ул туганда әле Әхмәдулла абзыйның аты да, сыеры да булмый. Шуның аркасында Әхмәдулла абзый үз гаиләсенә тигән 4 имана җирнең бары икесен генә чәчеп, эш итә ала. Гомеренең күбрәк вакытын исә ул, зуррак балаларын ияртеп, алпавыт җиренә йөреп үткәрә яки авылындагы бай агайларда көнлекче булып эшли.

Күрәсез, кечкенә Нәгыймәне «тәрбияләп» үстергән шартлар шактый караңгы чырайлы, каты куллы булалар. Кече яшьтән үк ул нужаның нәрсә икәнен татый һәм бик иртә авыр хезмәткә җигелә. Кызчык чагында күрше-тирәнең бозауларын көтә, үсә төшкәч, әтисенә ияреп, көнлекле эшкә йөри, ә кышларын апалары белән бергә Казан байларына читек кайый.

Авылда кызлар мәктәбе булмаса да, Нәгыймә бер тол абыстайга берничә кыш сабакка йөреп укырга да өйрәнә. Дөрес, шаян була, абыстайдан үзенә чыбык еш төшә. Ләкин бик тырышып укый, әлеп-бидән башлап «Мөхәммәдия»гә кадәр барып җитә. Китап уку белән бик мавыга, абыстайда булган һәм авылда табылган һәртөрле көйсез китапларның, көйле бәет, мөнәҗәтләрнең берсен калдырмый укып бара. «Йосыф» китабын һәм башка шуның төс-

ле дини тарихтан алынып язылган нәрсәләрне хатын-кызларга, карчыкларга кычкырып укый; елый-елый тыңлаган әбиләр аны аркасыннан сөеп мактыйлар. Бәйрәмнәрдә исә абыстай янында шәриктәш кызы белән бергә көйләп мөнәҗәтләр әйтә. Бу вакытларда Нәгыймә көй көйләү белән шундый мавыгып китә, хәтта, үзенең әйтүенә караганда, көрәк тактасына ат койрыгының кылларын куеп, скрипка сыман нәрсә дә ясап маташа.

Абыстай абыстай инде ул. Кыз шәкертләрен укырга өйрәтсә дә, язу язарга өйрәнүдән каттый рәвешле тыя. Ләкин Нәгыймәнең язу язарга бик өйрәнәсе килә, һәм ул аптырап калмый: ирләр мәдрәсәсендәге шәкертләрдән җиткән кызларга хат ташый, шул «хезмәте» өчен кулга эләкмәстәй кечкенә каләм калдыкларын сорап ала һәм үз тырышлыгы белән язарга да өйрәнә. Бу вакытларда инде аның характеры да тулырак билгеләнә: кыю табигатенә хас буларак аңарда хөрлек, бәйсезлеккә омтылу шактый нык сизелә.

Нәгыймә яшьли үк шәһәр күрә. Үсмер кыз чагында ул кышкы айларда Казанга — әнисе белән бертуган апасына килеп тора. Апасы хәлле кешедә кияүдә була һәм берданбер кыз бала үстерә. Нәгыймәне, гадәттә, шул кызга иптәш итәр өчен авылдан китертәләр. Бу килеп торуларның Нәгыймәгә билгеле бер файдасы да тия: ул апасының кызы белән бер-ике кыш шәһәр мәктәбенә укырга йөри. Шәһәр үзе дә аңарда зур кызыксыну тудыра; апаларына ияреп йөрергә чыкканда, ул шәһәрнең бакчаларын, матур урамнарын күрә. Шәһәрне ярата башлый һәм аның күңелендә «шәһәрдә генә торсаң иде» дигән уй туа.

Еллар үтәләр. Нәгыймәнең шулай бозау көтеп, абыстайда укып яшь балалык вакыты, әтиләре белән уракка йөреп, чигү чигеп, Казанга килеп-китеп яшүсмер чагы да үтеп китә. Ниһаять, Нәгыймә үсеп буйга җитә. Дөресен әйтергә кирәк, авыр, михнәтле, кысынкы тормыш шартларында үсүенә карамастан, ул үз заманы өчен авыл кызларының алдынгыларыннан берсе була. Һәртөрле эш кулыннан килү белән бергә, ул әле укый-яза да белә. Шуның өстенә төскә-башка сөйкемле, буйга сылу кыз ыспай, чибәр итеп киенергә дә ярата.

Нәгыймә ханым, кыз вакытларын сагынган чагында, «мин авылның Галиябануы идем» дип әйтә торган иде.

Әгәр халык күңеленә кереп урнашкан Галиябану образының мәхәббәт трагедиясен бер читкә куйсак, аның үз-үзенә биргән бу охшатуында дөреслек юк түгел. Чыннан да, җиткән кыз Нәгыймә үзенең нечкә, сизгер таби-

гате, сылу кыяфәте һәм кешеләр күзенә сөйкемле күренүе белән без белгән Галиябануны хәтерләтсә, бу бер дә гаҗәп булмас иде.

Ләкин Галиябануларның язмышлары бер булмый. Аларның кайберләре көчле мәхәббәт фаҗигасен башларыннан кичерәләр, ә күпләре, мәхәббәт уты белән кабынырга да өлгермичә, ир хатыны, бала анасы булып китәләр. Ул заманда бик җиткән кыздан кайчан, кемгә иргә чыгарга теләвен сорап тормаганнар — ай-ваена карамыйча, тотканнар да биргәннәр. Нәгыймә дә бу кыргый гадәттән котыла алмый. Туганнан туган апасы дүрт баласын калдырып үлеп китә; шуның иренә, ягъни җизнәсе тиешле кешегә, әлеге дүрт баланы тәрбияләп үстерер өчен дип, Нәгыймәне көчләп кияүгә бирәләр.

Хаксызлыкны кече яшьтән үк күтәрә алмаган, һәрвакыт хөрлек, бәйсезлеккә омтылган, күңеле һаман нәрсәдер эзләгән Нәгыймә өчен мондый язмышның никадәр аянычлы хәл булуын әйтеп торасы да юк.

Нәгыймә, үзенең барлык табигате белән бу ясалма, ялган тормышка сыя алмыйча, көчләнеп бер-ике ел яшәгәннән соң, ниһаять, яшь баласын күтәреп, кире әти-әнисе йортына кайта.

Ирдән кайткан Нәгыймә өчен авылда торуның һичбер мәгънәсе калмый, һәм ул 1912 елны, авылны ташлап, кечкенә кызы белән Казанга күчеп килә.

### Нәгыймә — Казанда

Казан Нәгыймәне күптәннән үзенә тарта иде. Аның тынгысыз җаны бары шунда гына үз теләген табар төсле; гүя киләчәк бәхетенең ачкычы шәһәрнең шау-шулы, буталчык тормышы эченә яшерелгән һәм шуны тапса, ул бәхетле дә, ирекле дә булырга тиеш иде.

Инде менә ул шәһәр тормышының бусагасыннан атлап керде. Нәрсә көтә аны алда? Нәгыймә киләчәгенә батыр карый, чөнки аңарда яшьлек дәрте көчле, теләгенә ирешү өчен авырлыклардан курку юк, шуның өстенә нужа аның тирбәлеп үскән бишеге булды, ә эш аның өчен тормыш үзе иде.

Нәгыймә башта бер бай гиләсенә асрау булып керә. Ләкин озак та үтми, асраулык хезмәтенең үзе өчен бер дә кулай булмавын күрә. Бай хатынының капризларына, һәртөрле җәбер-кыерсытуларга чыдавы Нәгыймә өчен бик авыр була. Ахырда ул, артык чыдап тора алмыйча, асраулыктан чыгып китә.

Аннан берникадәр вакыт Яңа бистәдә тегү тегеп, чи-

гү чигеп көн кичерә, ләкин анда да ялгыз, яшь хатын тыныч тормыш таба алмый. Кибетчеләрнең бәйләнүләреннән качып, шәһәрнең югары ягына, руслар арасына күчеп китәргә мәҗбүр була. Биредә ул Гайниҗамал исемле бер ялгыз хатынның йортына квартирага урнаша. Һәм эшләп җыйган акчасына «Зингер» машинасы алып, казнага солдат күлмәк-ыштаннары тегәргә тотына.

Йорт хуҗасы Гайниҗамал элек ятимлектә үсеп, күп еллар буена байларда асраулыкта йөргән бер кыз була. Соңыннан ул ниндидер бер байның никахсыз хатыны булып, шул бай алып биргән махсус квартирада яши. Нәгыймә башта ук Гайниҗамалга ошап куя; көн-төн машина яныннан тормыйча эшләгән яшь хатынны ул кызгана башлый һәм Нәгыймәнең кәсебен үзгәртү, тормышын җиңеләйтү турында сүз кузгаткалый.

Ул Нәгыймәне үз юлына өстерәми, күрәсең, үз тормышы аңа бик татлыдан булмый, шуңа күрә ул Нәгыймәгә, һәртөрле мактауга лаек булган, бик кешелекле бер тәкъдим ясый: ул аңа укырга һәм, башлыча русча укырга куша, «акчасын үзем түләрмен» ди. Нәгыймә үз нәүбәтендә бу тәкъдимгә, рәхмәт әйтеп, берсүзсез риза була, чөнки аның иркенрәк тормышка, яшәвен генә тәэмин итә торган түгел, ә җанын канәгатьләндерердәй хезмәт мәйданына чыгасы килә. Ул инде күңеленнән «мөгаллимә булырмын» дип уйлап та куя. Тиз арада укуның чараларын да күрә башлыйлар. Нәгыймә үзе уку өчен кирәк булган әсбапларны сатып ала, ә Гайниҗамал укытучы әзерләргә керешә.

...Һәм менә һич көтелмәгәндә бер хәл була: Нәгыймә «Зингер» машинасы артыннан торып, сәхнәгә чыга. Ул — «Сәйяр» артисткасы!.. Чыннан да, кайвакыт очраклы гына хәл дә кешенең тормыш юлын үзгәртеп җибәрер өчен җитә кала икән.

Ничек була соң бу?

Әлеге йорт хуҗасы Гайниҗамал апага «Сәйяр»ның бер артисткасы — Мәрфуга ханым Иманская — ара-тирә кием-салым алыр өчен килеп йөри. Шулай, аның бер килүендә хуҗа хатын ничектер уйламастан гына әйтеп куя:

— Сезнең театрга хатыннардан уйнаучы кирәкмиме?

— Нигә, әллә берәр кешең бармы, Гайниҗамал апа? — дип сорый.

— Кирәк булса, менә минем йортымда Нәгыймә исемле бер яшь кенә, укый-яза белгән ялгыз хатын тора,— ди Гайниҗамал.

Иманская кайтып бу хәбәрне «Сәйяр» җитәкчесе Габ-

дулла Кариевка сөйли. Кариев игътибар белән тыңлый, Нәгыймәнең кем булуы, нинди кәсеп белән торуы хакында сораша. Үз кул көче белән торучы бер хатын икәнен белгәч, ул аның белән сөйләшергә була.

Һәм менә көннәрдән бер көнне Нәгыймәгә Кариевтан «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» спектакленә чакырып записка килә. Запискасында Кариев Нәгыймәдән, театрга килгәч, сәхнә артына кереп, үзе белән танышуын үтенә.

Бу чакыруның никадәр көтелмәгән һәм сәер бер хәл булуына карамастан, Нәгыймә театрга барырга була. Йортта торучы квартирантлар Нәгыймәне киендереп, ясандырып, театрга озатып калалар. Баргач, Нәгыймә, партерның беренче рәтендә утырып, спектакль карый, антракт вакытында, сәхнә артына кереп, Кариев белән таныша. Бу кыска танышу вакытында мәсьәләне хәл итәрлек җитди сөйләшү булмый. Бары тик Кариев Нәгыймәгә ни өчен чакырганын әйтә һәм ике көннән соң «Шәрык» клубына килергә куша. Нәгыймә чыгып киткәч, Кариев, янындагы артистларга:

— Бу ханымның күзләре акыллы, әдәпле хатын булырга тиеш,— ди.

Нәгыймә үз нәүбәтендә Кариевның тәкъдименнән бик нык уйда кала. Артистлык эшенә халык начар карый, юньле кешегә бу эш килешми, кардәш-туганнар да ишетсәләр ачуланырлар, дип уйлаудан бигрәк, ул үзенең артистка булырга никадәр ярау-ярамавы турында борчыла. Шуның өстенә укып, мөгаллимә булу мөмкинлеге дә алда тора. Кайсын сайларга? Шулай да ул Кариев чакырган көнне «Шәрык» клубына бара һәм Кариев белән күрешкәч, аңа:

— Мин сездә эшли алмыйм инде, мин мөгаллимә булам,— ди.

Кариев Нәгыймәне бик озак үгетли. Аның сүзләре белән тәэсирләнмичә, аның әйткәннәренә ышанмыйча калырга һич мөмкин булмый. Ниһаять, Нәгыймә ханым «Сәйяр» труппасына артистка булып керергә ризалык бирә. Бу 1914 елның соңгы айларында була.

* * *

Артистка булып киткәнчегә кадәр Нәгыймә ханымның театр белән танышлыгы һәм аңардан алган тәэссораты ничек иде?

Әле үсмер кыз чагында, Казанга килгәләп торган вакытларында ул апаларына ияреп, Панаев бакчасына (хәзерге «Динамо» стадионы) баргалый. Апалары ул бакча-

ларга, анда татарлар булмыйлар, шуңа күрә бит каплап, абынып-сөртенеп йөрисе юк, дип баралар. Нәгыймә бакчаның ачык сәхнәсендә русларның водевильләрен, балетларын күрә, концертларын тыңлый. Русча ул бернәрсә аңламаса да, сәхнәдәге тамашаларны таңга калып карый. Андагы декорация һәм җиһазлар, артист-артисткаларның буй-сыннары, кыланышлары, кием-салымнары гади тормышта һичбер очрамый торган, әкияттәге шикелле искиткеч матур булып күренәләр. Нәгыймә сәхнәдәге бу матурлыкка чын-чынлап соклана. Шәһәргә килеп, үз башына тора башлагач, бигрәк тә Гайниҗамал йортында торган чагында, Нәгыймә Казанның рус драма театрына ара-тирә баргалый. Ул анда 15 тиенгә иң арзанлы билет алып, студент яшьләр белән бергә галеркадан спектакльләр карый. Беренче күргән спектакле «Осенняя скрипка» дигән әсәр була: бу спектакль аңарда шундый көчле тәэсир калдыра ки, бөтен гомере буена Нәгыймә ханым аны хәтерендә саклый.

«Сәйяр» тарафыннан куелган татар спектакльләреннән «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин»гә кадәр ул русчадан тәрҗемә ителгән «Табылдык» белән Мольердан күчерелгән «Саран Хәмит»не күрә. Үз ана телендә күргән бу спектакльләрдән алган тәэссорат тагын да көчлерәк була.

Ләкин ул тәэссоратлар нәрсәгә кайтып кала соң? Нәгыймә тәҗрибәсез карауч‍ы, театрдан хәбәре юк, дөнья белән танышлыгы бик тар, шуңа күрә теге яки бу спектакль сурәтләп күрсәткән тормыш — бөтенләй башка тормыш, башка дөнья булып күренә аңа. Җитмәсә, сәхнәдә сурәтләнгән тормыш вакыйгалары өсте-өстенә тупланганнар, тормыш каршылыклары соң дәрәҗәдә кискенләштерелгәннәр һәм ул вакыйгалардагы шул каршылыкларны тудыручы кешеләр характерлары белән берберсеннән бик нык аерылып торалар, үзләренең эчке кичерешләрен ачыктан-ачык әйтеп бирәләр; сөйсәләр, алар һәркемне сокландырырлык итеп, гаҗәп матур һәм ялкынлы сөяләр; газаплансалар, һәркемне елатырлык итеп, бөтен җан-тәннәре белән газапланалар; ачулансалар, һәркемнең котын алырлык итеп ачулана беләләр. Инде хаксызлыкка каршы нәфрәтләнеп сөйләүләре яки хаклык өчен үзләрен мәгъруур рәвештә корбан итә белүләре белән һәркемне тетрәтә, таңга калдыра алалар.

Нәгыймә өчен бу сәхнә дөньясы сокландыргыч гүзәл, мавыктыргыч кызыклы иде. Бигрәк тә аны хәйран иткән нәрсә — шул дөньяны тудыручы артистлар иде. Аның белүенчә, сәхнәдәге кеше кыю да, батыр да, гадел дә, затлы да һәм матур да булырга тиеш иде. Юк, Нәгыймә

өчен театр эшлексез, юньсез, азган-тузган кешеләр урыны түгел, ул мөкатдәс урын һәм аның бусагасыннан атлап түренә бары тик чын талантлы, йөзе белән дә, йөрәге белән дә матур, сөйкемле кешеләр генә үтәргә тиешләр. Ә менә авылдан килгән ярлы кызы Нәгыймәнең шул мөкатдәс урынга керергә хакы бармы? Аңарда якты рампа алдына чыгып тамашачыларны көлдерә дә, елата алырлык сәләт, кодрәт табылырмы? Нәгыймәнең шиге бары тик шунда гына...

Ләкин шобага салынган, язмыш үзе аны җитәкләп театр ишегеннән кертте. Хәзер ул сәхнәгә чыгарга тиеш.

## Нәгыймә ханым — «Сәйяр» артисткасы

1915 елның 19 январенда, дүшәмбе көн «Новый клуб» сәхнәсендә уйналачак спектакльгә карата чыгарылган афишада «яңа артисткаларыбыздан Нәгыймә ханым Таҗдарова иштирак итәчәк» дип язылган була.

Ләкин ни өчен Таҗдарова? Нәгыймә ханымның үз фамилиясе Әхмәдуллина ич.

Борыннан театр әһле арасында яшәп килгән традиция буенча, артисткалар, гадәттә, үзләренең артык гади булган фамилияләрен затлырак, сирәгрәк очрый торган фамилия белән алыштырырга яратканнар. Шул гадәт буенча, күрәсең, Нәгыймә ханымның да Әхмәдуллина дигән гади фамилиясен әйтергә ансат, ишетер колакка матур булып тоелган бер оригиналь фамилия белән алыштыруны кирәк тапканнар. Яңа фамилияне Нәгыймә ханымга Кариев табып бирә. Ул «ский»ларга беткән фамилияләрне яратып бетерми, шуңа күрә сирәк очрый торган Таҗдарова фамилиясен тәкъдим итә. Һәм Нәгыймә ханым Таҗдарова булып китә.

Аның сәхнәгә бу беренче чыгышын артистка буларак беренче дебюты дип һич тә атап булмый әле. Чөнки бу психологик әзерлексез, ихтыяр тупланмыйча, акыл белән иҗат бурычын төшенмичә, бары тик суфлер биргән сүзләрне әйтеп бару өчен генә булган бер чыгыш иде. Аның артистка өчен әһәмияте ачык сәхнәнең якты рампасы алдына чыгып, залдагы тамашачылар белән беренче тапкыр очрашудан һәм шул чакта үзен ничек итеп тоюдан гына гыйбарәт иде. Кыскасы, бу чыгыш Нәгыймә ханым өчен боз шикелле салкын суга кинәт чумып, чиркануны качыруга охшашлы бер хәл булып кала. Нәгыймә ханым үзе дә бу беренче чыгышы турында: «Мин, сәхнәгә керегез, дигән кушуны ишеткәч, ихтыярсыз, чүгәләп куйдым, кергәч — залны күрмәс, авызымнан чык-

кан сүзләремне ишетмәс булдым. Ярый әле ике тәҗрибәле артист минем ике ягымнан торып, сукырны җитәкләп йөрткән шикелле йөртеп, әйтәсе сүзләремне әйттереп, чыгарып җибәрделәр»,— ди.

Нәгыймә ханымның сәхнәгә беренче чыгышы әнә шулай үтә. Мондый курку, калтырау белән үткән чыгыш аркасында ул «Сәйяр»ны чак ташламыйча кала. Табигый буларак, ул, рольне үти алмадым, дип уйлый, артистка була алуына тәмам ышанычын югалтып куя. Иптәшләренә күренергә ояла һәм спектакльдән соң бер атна театрга бармыйча өендә утыра.

Нәгыймә ханым шулай «югалып» торгач, Кариев үзе аның квартирасына эзләп бара. Ул, әлбәттә, яшь артистканың шул вакыттагы кичерешләрен яхшы аңлый, тәҗрибәле артист буларак аны юата, тынычландырырга тырыша һәм кире театрга чакыра. Ләкин Нәгыймә ханым бу юлы тиз генә бирелергә теләми, бары сүзсез генә башын селкеп тик утыра. Кариев үгетләп-үгетләп тә күндерә алмагач, ниһаять, сабырлыгын җуеп әйтә:

— Әгәр, ханым, мин сезгә ялварган шикелле Аллага ялварган булсам, ул миңа күктән фәрештәләр җибәргән булыр иде,— ди.

Асылда, театрны яраткан һәм анда эшли алуны зур дәрәҗәгә санаган Нәгыймә ханым, Кариев кадәр Кариевтан шундый сүзләр ишеткәч, бик нык уйга төшә, һәм ахырда «Сәйяр»га яңадан кайтырга ризалык бирә.

## Беренче дебют

Шундый зур шик һәм эчке каршылыкларын җиңеп «Сәйяр»га кире кайткач, Нәгыймә ханымны бик җаваплы сынау көтеп ала: «Сәйяр» Фатих Әмирханның «Тигезсезләр»ен куярга хәзерләнә.

Биредә яшь, тәҗрибәсез Нәгыймә ханымның хәлен читенләштергән бер моментны әйтеп үтәргә кирәк: нәкъ шул сезонда «Сәйяр»ның хатын-кыз составы сан ягыннан бик кечкенә була. Труппада профессиональ артисткалар булып бары Гөлсем ханым Болгарская белән Иманская гына эшлиләр. Гөлнар исемле бер ханымның һәвәскәр булып кына катнашып йөрүен исәпкә алмаганда, Нәгыймә ханым Таҗдарова труппага өченче артистка булып килә. Хатын-кызга труппада шундый кытлык булганда, табигый инде, һәр артисткага эш йөкләмәсе ифрат күп төшә.

Башта Нәгыймә ханымга «Тигезсезләр»дән Маһруй дигән икенче дәрәҗәдәге гимназистка ролен бирәләр.

Репетицияләр бара. Ләкин һәрдаим репетицияләргә килеп, карап утырган Фатих Әмирхан Кариевка, Маһруй ролен Нәгыймә ханымнан алып, аңа Рокыя ролен бирергә тәкъдим итә. Кариев автор тәкъдиме белән килешә һәм Нәгыймә ханымга Рокыя ролен бирә.

Гаять җаваплы әсәрнең авторы, иҗат мәсьәләсендә аеруча таләпле Фатих Әмирхан белән артист иҗатын һәркемнән тирәнрәк аңлаган Кариев ни өчен тәҗрибәсез артисткага пьесаның иң әһәмиятле үзәк ролен бирергә булалар? Бу сорауның җавабын табу хәзер читен. Кеше юклыктан гына дигән сәбәп белән килешеп булмый, чөнки «Сәйяр»ның берничә еллар дәвамында уйнап килгән артисткалары бар иде. Алар үзләренең тышкы һәм эчке билгеләре белән Рокыя роленә туры килеп бетмәсәләр дә, уйнау тәҗрибәләре белән бу авыр рольне башкарып чыгуны, һәрхәлдә, тәэмин итә алган булырлар иде. Ләкин шуңа карамастан автор һәм Кариев Рокыя ролен Нәгыймә ханымга бирәләр. Ихтимал, Нәгыймә ханым үзенең тышкы билгеләре — яшь чырайлы, юка гәүдәле, дикциясенең ачык, тавышының саф булуы белән 16 яшьлек Рокыя образына, башкаларга караганда, лаеграк булып күренгәндер. Һичшиксез, бу момент аңа Рокыя ролен биргәндә нык искә алынгандыр, дип уйларга туры килә.

Шулай итеп, Нәгыймә ханым «Тигезсезләр»дә Рокыя ролен башкарырга тиеш була. Кем соң ул Рокыя? Фатих Әмирхан тарафыннан зур мәхәббәт һәм чын осталык белән тудырылган бу туташ татар буржуазиясе җитештергән һәм татар хатын-кызларына үрнәк булырга тиешле булган яңа тип татар кызы — менә кем ул. Тормышта гына түгел, әдәбиятта өр-яңа образ!

Рокыя беренче пәрдәдә әле 16 яшьлек кенә кыз була. Шуңар күрә аның холкында балалык сыйфатлары аеруча нык сизелеп тора; ул җиңел сөякле, үз-үзеннән очынып торган кыз, аның бөтен эше, хәрәкәте бары настроение белән эшләнә, кәефе тиз, кинәт үзгәрә — бер минутта рухланып, кабынып китә һәм, сүнеп, рухы төшеп тә кала. Ул иркә, назлы, балаларча беркатлы, ләкин юк-бар капризлар белән кешенең теңкәсенә туктаусыз тиеп тормый. Шуңа күрә аның үпкәләп һәркемгә «мәхәббәтсез» дип дәшүен дә бары көлеп, чынга алмыйча гына тыңлыйлар.

Шуның белән бергә Рокыя үз-үзенә нык ышанган, үз төшенчәләрендә нык торган оптимист натуралы кыз ул. Һәрнәрсә аңа җиңел бирелә, киләчәге аның ачык, үз максатына ирешүендә шиге юк. Һәркем аны ярата, ул моны

яхшы белә, ләкин үзенең теге яки бу кешегә карата булган чын хисен яшерми, мөнәсәбәтен ачык билгели. Ул үткер, зирәк акыллы, тормышның табышмак булып аны борчый торган яклары юк шикелле, хәер, ул төрле проблемалар белән баш ватучылар җөмләсеннән түгел.

Ике елдан соң Рокыя тәмам җиткән кыз булып өлгерә, автор әйткәнчә, «аның баласымак матурлыгы җиткән кыз матурлыгына әйләнә». Ләкин характеры әүвәлгечә саклана: һаман ул очынып торган кыз, һаман шат күңелле, садә-сөйкемле кыланышлы, үз-үзенә ышанган бәхетле, чибәр туташ... Дөрес, хәзер инде аңарда җиткән кызларга хас сыйфатлар (кирәк чакта назлы гына чытлыклана белү, артыннан ухаживать иткәнне ярату һ.б.) бар, ләкин бу сыйфатлар, күз өстендәге каш шикелле, балалыктан арынып җитмәгән туташны аеруча нәфис, нечкә табигатьле итеп күрсәтәләр. Юкка гына Сөләйман аңа: «Рокыя, сиңа ефәктән эшләнгән канатлар бик килешер иде!» — дип әйтми.

Әнә шундый Рокыяны Нәгыймә ханым ничек итеп тудырырга тиеш иде; ничек итеп, нинди чаралар белән ул бу оригиналь образның гаять үзенчәлекле характерын бөтен бизәк һәм нюанслары белән иҗат итә алырга тиеш иде?

Әгәр Нәгыймә ханымның аң, төшенчә, зәвыгын, ниһаять, шәхси тормышын уйнаячак образның шул яклары белән чагыштырып карасак, бер генә дә туры килеп тиешкән ноктаны күрмәбез, киресенчә, һәрьяктан тирән аерма, капма-каршылык ярылып ята. Ә бит тәҗрибәсез артисткага теге яки бу образны тудырганда үзенең тормыш тәҗрибәсеннән файдаланмыйча, үзенең шәхси кичерешләрен, ихтыярсыз образ кичерешләре итеп күрсәтмичә һич мөмкин түгел. Ә биредә нәрсә? Рокыя бай сәүдәгәр кызы, Нәгыймә ярлы крестьян кызы, Рокыя гимназия бетерә, Нәгыймә берничә кыш абыстайга йөри, Рокыя рояльдә уйный, Нәгыймә машинада солдат күлмәкыштаны тегә; Рокыя сентименталь язучы Сөләйман белән романтик мәхәббәт кичерә, ә Нәгыймә башына нинди «мәхәббәт» төшкәнен күргән идек. Рокыя хезмәтнең нәрсә икәнен дә белмичә, җаны ни теләсә, шуны үтәп, гамьсез, тыныч яшәргә өйрәнгән; Нәгыймәнең башы авыр хезмәттән, тормыш нужасыннан чыкканы юк. Күрәсез, Нәгыймә ханым каршында бөтенләй ят кеше образы басып тора, һәм ул, артистка буларак, шул кешегә әверелергә тиеш. Сүз юк, беренче дебют өчен бу хәзерлексез артистканың мөмкинлекләре күтәрә алмаслык, гаять авыр бер бурыч иде.

Ләкин әнә шундый бер рольне башкарып чыгу өчен Нәгыймә ханым нинди хәзерлек үтә, кем аны ролен дөрес уйнарга өйрәтә? Ул заманда ярым кустарьчылык, ярым һәвәскәрлек белән эшен алып барган труппада, әлбәттә, хәзерге без белгән тәртиптәге хәзерләнү булмаган. Репетицияләр, гадәттә, турыдан-туры мизасценалардан башланып китkәннәр, һәм рольне дөрес тоеп, аның мимикасын, хәрәкәтен, интонациясен табу башлыча һәр артистның үз сизгерлеге һәм тәҗрибәсе белән эшләнә торган булган. Дөрес, Кариев артистлар белән бик нык эшләгән, аларга кирәкле юнәлешне бирә белгән, һәр артистны, ролен мөмкин кадәр дөрес аңлап, тамашачыны ышандырырлык итеп уйнарга өйрәткән. Шул ук «Тигезсезләр»не куяр өчен дә Кариев гаять күп көч сарыф итә. Һичшиксез, Нәгыймә ханым белән дә нык шөгыльләнә. Ләкин Нәгыймә ханымга үз ролен тиешенчә үзләштерү өчен өйрәтү системасы да җитеп бетми һәм бигрәк тә җитәрлек вакыт та булмый. «Тигезсезләр»не бары 15 репетиция белән сәхнәгә чыгаралар.

Ләкин ничек кенә булмасын, «Тигезсезләр» 1915 елның 9 февралендә «Новый клуб» сәхнәсендә уйнала һәм Рокыя ролен Нәгыймә ханым Таҗдарова башкара.

«Тигезсезләр»не уйнаганнан соң, Кариев Нәгыймә ханымга 25 сум акча бирә. Бу — зур уңыш белән үткән спектакльнең бай сборыннан һәр артистка, дәрәҗәсенә карап, тигән өлеш иде. Мондый зур акча Нәгыймә ханымның кулына гомерендә беренче тапкыр керә. Ул «театр уйнап» шулкадәр акча алуына бик гаҗәпләнә һәм чын-чынлап куана.

Гомумән, Нәгыймә ханым бу спектакльдән соң үзендә театрга карата олы бер мәхәббәт уянуын тоя, һәртөрле шикләре таралып китә, ничектер яшәвенең мәгънәсе һәм максаты табылгандай була. Шуңар күрә дә ул үзенә:

— Ниһаять, мин тормышта эзләгәнемне таптым! — дип әйтә ала.

Дөрес, һәрбер эш, бигрәк тә сәнгать эше, җиңеллек белән бирелми; сәнгать остасы булыр өчен күп авырлыкларны баштан кичерергә, бер уңыш артыннан ун уңышсызлыкка очрарга туры килә. Еш кына һәртөрле шик һәм өметсезләнүләрне җиңеп чыгарга кирәк була. Ләкин яраткан эшнең кодрәте шундый инде, ул кешене авырлыкларга да түзәргә мәҗбүр итә, уңышсызлыкларга да бирешмәскә, шикләрне дә баса белергә өйрәтә.

Нәгыймә ханымга да башта җиңел булмый. Ул кыенлык белән акрынлап үсә, үзенең көчен, сәләтен тулысынча ачып күрсәтү өчен шактый вакыт кирәк була. Шуңа

күрә дә яшь артистка театр сәхнәсенә чыгу белән өр-яңа бер талант булып танылу һәм беренче чыгышыннан ук шөһрәт иясе булып китү бәхетенә ирешә алмый. Хәер, андый «бәхеткә» ул кызыкмый да, ул эш сөюче, һәм шөһрәт, бәхетнең хаклы хезмәт нәтиҗәсендә генә килүен ярата. Инде Нәгыймә ханымга теге яки бу пландагы артистка булып формалашу өчен нииндидер үрнәкләрдән өйрәнергә, кем тарафыннандыр дөрес юнәлеш алырга, кемнеңдер оста җитәкчелеге астында бай тәҗрибә мәктәбен үтәргә кирәк иде. Һәм Нәгыймә ханым боларның барысын да «Сәйяр»да таба, аның җитәкчесе Габдулла Кариевтан өйрәнә, тәрбияләнә. Ул үзен «Мин Кариевның шәкерте» дип атый. Бу, асылда, дөрес, чыннан да «Сәйяр» аның өчен мәктәп, Кариев исә оста укытучы була.

Татар театры кыска гына бер вакыт эчендә халыкчан, реалистик театр буларак, шактый зур уңышларга ирешә. Ул инде үз тарихы, үз йөзе, үз традицияләре булган утраклы профессиональ театрга әверелү дәрәҗәсенә якынлашып килә, күп кенә талантлы артистлар җитештерә, рус һәм Аурупа классикларын сәхнәгә куя башлый.

«Сәйяр»ның кыска вакыт эчендә шундый иҗади уңышларга ирешүендә рус театр сәнгатенең аңа турыдан-туры зур йогынты ясавын әйтеп үтәргә кирәк. Бу йогынтыны «Сәйяр» читтән торып кына түгел, ә бәлки, рус театры белән конкрет бәйләнешкә керү нәтиҗәсендә ала. Мәгълүм ки, әле 1913—1914 елларда Казан рус театрының күренекле артисты, кайчандыр МХАТта, Станиславский кул астында эшләгән М.А.Громов, Кариев чакыруы буенча «Сәйяр»га килеп, «Мәкер вә мәхәббәт», «Хөкемдә хаталык» һәм «Яшенле яңгыр» кебек тәрҗемә әсәрләрне сәхнәгә куеша. Ә инде 1917 елны «Сәйяр» үзенең составында штатлы рус режиссеры да тота. Шуның белән бергә Кариев үзенең артистларын Казанда булсын, гастрольдә чакта башка шәһәрләрдә булсын, буш кичләрендә гел рус театрына алып йөртә. Ул артистларына һәркайчан рус сәхнә осталарын үрнәк итеп күрсәтә һәм алардан өйрәнергә куша. Әнә шулай рус театры белән даими бәйләнештә булып, аңардан өйрәнеп «Сәйяр»ны һаман көчәйтә, үстерә барган Кариев үзе дә артистлык иҗатын дөрес һәм тирән аңлаучы, башкаларның артистлык талантын тиз сизә белүче кеше була. Аеруча, Кариев үзенең олы таланты белән кабатланмас образлар тудырып, башкаларга реалистик уенның җанлы үрнәге булып тора.

Менә шул Кариевтан Нәгыймә ханым нәрсәләргә өйрәнә, артистлык иҗатының нинди серләренә төшенеп

кала? Кариев, гадәттә, «артист сәхнәдә үзен уйнамаска тиеш» дип әйтә торган булган. Моның белән ул артисттан һәр конкрет рольне башкарганда, шул рольгә керә белүне таләп иткән. Шуның белән бергә Кариев артист алдына иң беренче шарт итеп тамашачыны ышандыра алуны куйган. Бу артист өчен иң авыр бурыч, чөнки реаль кеше образын тудыру өчен, аның, ягъни образның, бөтен эчке һәм тышкы үзенчәлекләрен табарга, өйрәнергә, үзеңнеке итәргә кирәк. Кыскасы, бу — уйный торган образыңа тәмам әверелү дигән сүз. Ләкин ничек итеп, нинди юллар белән?

Кариев моның да җавабын бирә. Ул: «Артист иң әүвәл үзе үз уенына ышанырга тиеш, шуннан соң гына ул тамашачыны ышандыра ала»,— ди. Икенче төрле әйткәндә, образның һәр сүзен чынга алырга, һәр хәрәкәтенә, һәр кыланышына бары тик шулай гына булырга мөмкин, дип ышанырга кирәк. Кариевча артист үз күңелендә шундый ышану тудырмыйча торып, образга әверелә алмый, ә бу ышану исә образның эчке җанын тоюдан, аның характерын дөрес аңлаудан башланырга тиеш. Шул вакытта гына артист роль эченә керә ала.

Кариев артист иҗатының нидән гыйбарәт булуын әнә шулай аңлаткан һәм үзенең артистларын «уен уйнау» тәртибендә түгел, ә иҗат итү принцибында өйрәтергә тырышкан. Шуңа күрә ул сәхнәдә тормышча гадилек, чын садәлек булуны яраткан, һәртөрле фальшне тиз сизгән, аны сәхнәдән мәрхәмәтсез рәвештә куган.

Ниһаять, Кариев үзенең артистларын тормыштагы төрле типларны — аларның характерларын, кыланышларын, сөйләү манераларын өйрәнергә чакырган. Кариев үзе, замандашларының әйтүенә караганда, шундый өйрәнү белән бик мавыккан. Мәсәлән, аның «Безнең шәһәрнең серләре»ндәге Мөхәммәтҗан Хафиз образын тормыштагы чын Мөхәммәтҗан Хафиздан өйрәнеп тудыруын хәзер дә әле карт артистлар сокланып сөйлиләр.

Нәгыймә ханым «Сәйяр»да өч сезон уйный. Беренче сезонда ул Рокыя роленнән соң, башка вак-төяк рольләрне исәпкә алмаганда, «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин»дәге Салихә, «Бәхетсез егет»тәге Җәмилә, «Шәфкать туташы»ндагы (тәрҗемә әсәр) Юлия рольләрен башкара. Соңгы ике рольне исә шактый уңыш белән башкарып чыга. Шулай да беренче сезон Нәгыймә ханымны артистка буларак артык күтәреп җибәрми, уңышлар чамалы гына була. Җитмәсә, Кариев та сезон уртасында авырып, Кырымга китеп бара. Аның юклыгы да яшь артистканың үсеп китүенә беркадәр тоткарлык ясаган булырга тиеш.

Лəкин сезоннан сезонга Нəгыймə ханымның тəҗрибəсе арта, тəҗрибə белəн бергə артистлык осталыгы да һаман үсə бара. Өч сезон эчендə ул дистəлəрчə рольлəр башкара. «Сəйяр»ның репертуары шактый чуар һəм күп була. Мəсəлəн, бары 1914—1915 елгы сезонда гына ул 25 исемдə спектакль бирə. Шуңар күрə Нəгыймə ханымның өч сезонда уйнаган рольлəре бик күп булалар. Тик артисткаың ничек үсүен характерлый торган һəм игътибарга лаек булган иҗат эше итеп, аның рус классик драматургиясеннəн «Ревизор»да Мария Антоновна, «Гаепсездəн гаеплелəр»дə Каринкина, «Төшемле урын»да Юлия рольлəрен башкаруын күрсəтеп үтəргə кирəк. Аеруча уңыш белəн ул Найденовның «Ванюшин балалары»нда Елена ролен башкарып чыга. Ул чакларда Нəгыймə ханым күбрəк яшьлəр рольлəрендə уйный торган артистка булып танылa. Башта аны инженю драматик амплуадагы артистка дип йөрилəр, лəкин ул аналар һəм карчыклар ролен дə зур уңыш белəн башкара.

Кыскасы, «Сəйяр» аны өч ел эчендə татар сəхнəсенең җитди, күренекле артисткасы итеп танып өлгертə. Без моның шулай икəнен, мəсəлəн, түбəндəге факттан ачык күрəбез: 1917 елның көзенə таба Ырынбурдагы «Ширкəт» труппасы Нəгыймə ханымны үзенə төп рольлəрне башкаручы беренче положениедəге артистка итеп чакыра. Нəгыймə ханым бу чакыруны кабул итə һəм 1917 елның сентябрендə Ырынбурга бара.

## Нəгыймə ханым Ырынбурда

Бу вакыт ике революция арасы иде. Русия халкы бөек тарихи вакыйгалар чорын кичерə. Беренче империалистик сугыштан тəмам йончыган һəм туйган барлык миллəт хезмəтчел халкы февраль буржуаз революциясеннəн көткəнен ала алмый, солых һəм азатлык өчен көрəш көннəн-көн көчəя, Ленин җитəкчелек иткəн Коммунистлар партиясе бу көрəшнең башында тора, хезмəтчел халыкны политик властьны яулап алу өчен соңгы һəм хəлиткеч кораллы көрəшкə — социалистик революциягə алып бара. Инде бу социалистик революциянең тирəн сулышы сизелə, ул менə хəзер кабынып китəргə тора. Бу шартларда халыкның политик һəм җəмəгатьчелек тормышы бик активлашып китə, барлык социаль катлаулар хəрəкəткə килə, массада революцион рух һаман үсə бара.

Менə шундый бер вакытта Нəгыймə ханым Таждарова Ырынбур сəхнəсендə беренче положениедəге артистка булып уйный башлый. Театр эченə заманның тынгы-

сыз рухы керә, ә театр залы исә бөек вакыйгалар күтәреп аякка баскан халык белән тула. Халыкта рухани азыкка сусау бик көчәя һәм труппаның бөтен артистларына зур активлык күрсәтеп, нык җигелеп эшләргә туры килә.

Дөресен әйтергә кирәк, Нәгыймә ханымның Ырынбур сәхнәсендәге чыгышлары гаять зур уңыш белән үтәләр. Ул үзен киң тамашачылар массасына, чыннан да, бай мөмкинчелекле, олы талантлы артистка итеп таныта ала. Күп һәм төрле-төрле була аның башкарган рольләре: оригиналь әсәрләрдән «Яшьләр»дә Зәйнәп, «Хаҗи әфәнде өйләнә»дә Камилә, «Уйнаш»та Сәрби, «Галиябану»да Галиябану, «Тигезсезләр»дә Рокыя (биредә күп мәртәбә уңышлырак уйный), тәрҗемә әсәрләрдән «Урман»-да Аксюша, «Мещаннар»да Полина, «Хөкемдә хаталык»-та Адрияна, «Тайфун»да Елена һ.б. Янә беренче положениедәге артистка буларак, ул дөнья классикларыннан «Мәкер вә мәхәббәт»тә Луиза, «Юлбасарлар»да Амалия рольләрен дә зур уңыш белән башкара.

Нәгыймә ханымның Ырынбур сәхнәсендә ничек уйнавын күз алдына китерер өчен, ул тудырган Галиябану образына тукталып китәргә мөмкин.

«Ширкәт» труппасы «Галиябану»ны башлыча драматик спектакль итеп күрсәтә. Беренче планга әсәрнең фаҗигале вакыйгасын тормышча итеп күрсәтү һәм образларның асыл кичерешләрен дөрес итеп ачу куела. Шуңар күрә спектакль башыннан ахырына кадәр, эзлекле рәвештә, реалистик стильдә алып барыла. Әсәрнең мелодраматизм ягына басым ясау булмый, ә җыр-музыка өлеше драматик уенны көчәйтә, тулыландыра торган бер чара итеп кенә алына. Нәтиҗәдә тамашачының күз алдына сәнгатьчә бик бөтен оештырылган, тере сулышлы тормыш үзе килеп баса.

Нәгыймә ханым Галиябану образын җаны-тәне белән яратып китә. Ниһаять, аңа үзе белгәнне, үзе тойганны уйнап күрсәтергә туры килә. Ләкин ничек һәм нинди итеп тудыра соң ул Галиябануны? Биредә шуны да онытмаска кирәк, Нәгыймә ханымның җырчылык сәләте бик чамалы була, шунлыктан аңа бу җәһәттән зур уңыш көтәргә туры килми. Әмма ул Галиябануны гаять тирән хис иткәнлектән, аның чын образын бик дөрес таба. Бу инде авылча киенгән шәһәр туташы булмый, юк, бу чын мәгънәсендә табигый авыл кызы була. Нәкъ менә авылча әдәпле, тыйнак, оялчан, әчкерсез ул. Йөрәгендәге саф, тирән мәхәббәт тә аның әнә шул оялчанлык аша күркәм, тыйнак булып чагыла. Моның белән бергә Галиябануның мәхәббәте һич көчсезләнми: ачык, ялан-

гач итеп күрсәтүгә караганда, тыеп, яшерә төшеп күрсәтү, киресенчә, ул мәхәббәтне тагын да көчлерәк, тәэсирлерәк итә. Шуңа күрә дә бу мәхәббәттән аеруча бер табигый нәфислек, самими сөйкемлелек сизелеп тора. Әйе, бу чыннан да 18 яшьлек кызның, яңа ачылган чәчәк төсле, беренче саф мәхәббәте була. Ләкин бу авыл кызы мәхәббәте һәм Нәгыймә ханым аны, ул мәхәббәтне, һәртөрле ясалмалыктан, «уйнап» күрсәтүдән сакларга тырыша. Шуңар күрә Галиябану һәр сүз, һәр карашына кадәр тирән художество зәүкы белән эшләнгән сәхнә образы булып туа. Билгеле инде, Нәгыймә ханым Галиябануны уйнаганда һәртөрле кискен хәрәкәтләргә, дорфа карашка, әйткән сүзенә, эшләгән эшенә исәп бирмичә кылануларга юл куймый.

Шуның белән бергә ул Галиябануны күпме генә әдәпле, тыйнак, оялчан итмәсен, ләкин бөтенләй куркып, калтыранып торган ихтыярсыз бер кыз дәрәҗәсенә дә төшерми. Галиябану белән Хәлилнең бер-берсенә булган саф, кайнар мәхәббәтләре никадәр башкаларның каршылыкларына очраса, авыр хәлдә кала барса, шулкадәр көчәя, тирәнәя бара. Бу мәхәббәт аларны ахырда хаклык, гаделлек өчен көрәшүчеләр югарылыгына күтәрә. Һәм менә Галиябану бай малае Исмәгыйльнең мәкер һәм явызлыгын, әтисе Бәдри картның бай малаена сатылуын белгәч, үз мәхәббәтен яклау өчен үзендә көч тә, ихтыяр да таба. Ниһаять, Хәлил үтерелгәч, Галиябану оялчан кыздан кинәт бөтен мәкер-җинаять бауларын өзеп ташларга хәзер торган героиня дәрәҗәсенә күтәрелә һәм тамашачыны тетрәткеч тирән драматизм белән Хәлилгә булган олы мәхәббәтен, Исмәгыйльгә карата утлы нәфрәтен йөрәге төбеннән чыгарып әйтә. Аның Исмәгыйльнең битенә бәреп:

— Аны син үтердең, син бит!..— дип әйткән сүзләре крәстиән кызларын хурларга, курчак итәргә тырышкан бай малайларына карата мәрхәмәтсез гаепләү булып яңгырый һәм Исмәгыйльне мораль яктан тәмам үтерә.

Шулай итеп, Нәгыймә ханым Галиябануның эчке кичерешләрен әсәрдәге вакыйгаларның үзгәрүенә һәм катлауларына бәйләп алып бара, бу кичерешләрне ул шул вакыйгаларның табигый чагылышы итеп күрсәтә, нәтиҗәдә образның характерын һәрьяклап ачуга ирешә. Галиябану Нәгыймә ханым башкаруында, мәхәббәте белән бәхетле чакларында да, олы фаҗигане кичергән минутларында да тормышча табигый, гади авыл кызы булып кала. Һичшиксез, үзе авылның бер Галиябануы шикелле булып үскән артистка, бу образны бөтен йөрәге белән

тоеп, үз башыннан кичергәннәрен тулысынча салып иҗат итә. Ләкин бу Галиябануны очраклы бер тип итеп түгел, ә бәлки, сәнгатьчә җыелма образ итеп тудыра.

Нәгыймә ханым: «Мин Галиябануны уйнаганда үзем еламыйча, тамашачыны елата идем»,— ди. Менә бу сүзләрдән аның ул чакта инде артистлык осталыгының серләренә никадәр төшенеп эш иткәнлеген күреп була. Кариевтан дөрес юнәлеш алып киткән артистка иҗат иткәндә башлыча акыл һәм ихтыяр көче белән эш итүче, тирән эмоция кичерешләрен дөрес таба, тудыра һәм шул ук вакытта аңа хуҗа да була алучы чын оста булып үсә бара.

Шул ук 1917—1918 елның сезонында француз драматургиясеннән «Тайфун» исемле әсәр куела һәм Нәгыймә ханым төп героиня — Елена ролен башкара. Елена — француженка, япон дипломатының сөяркәсе, актриса, үзенең холкы белән бик тиз үзгәреп торучан, үткер характерлы яшь ханым. Менә шул образны Нәгыймә ханым гаять зур уңыш белән башкарып чыга һәм тамашачыларда бик тирән эз калдыра. Ул вакытларда яңа гына театрга якынлашып йөри башлаган Хәлил Әбҗәлилов менә хәзер, 30 еллап вакыт үткәннән соң: «Нәгыймә ханымның «Тайфун»да уйнавын бервакытта да онытачак түгелмен. Ак күлмәкле зифа бер ханым хәзер дә минем күз алдымда басып тора»,— дип сөйли. Әдәпле, оялчан, саф авыл кызы Галиябану һәм ирләрне бармагы тирәсендә әйләндерергә өйрәнгән француженка — актриса — бу икесе ике котыпта торган типларны иҗат итеп бирә алу — Нәгыймә ханымның нинди иҗади көчкә ия булганын бик ачык күрсәтсә кирәк.

Тагын шунысы характерлы. Нәгыймә ханым бервакытта да яхшы, оста уйнауның чиге бар дип белми. Кемнән, нәрсәдән өйрәнергә мөмкин булса, ул шуларның барысыннан да файдаланган. Аеруча сәхнәдәш иптәшләренең әйткән фикерләренә, күрсәтмәләренә колак салырга яраткан. Мәсәлән, соңгы гомеренә кадәр ул «Ширкәт»тә үзе белән бергә эшләгән Сыртланованы зур ихтирам белән исенә төшерә килде: «Лиза апай миңа ничек уйнавымны турыдан-туры әйтеп бирә иде, ә миңа бары шул гына кирәк»,— ди торган иде.

Кем соң ул Сыртланова? Татар театрына зур хезмәт күрсәткән бу бай тәҗрибәле, зур культуралы артистка турында да берничә сүз әйтеп үтәсе килә.

Елизавета Александровна Сыртланова — Бирски шәһәрендә самоварлар белән сәүдә итүче Шляхтин дигән рус купецының кызы була. 1912 елны Бирскига татар

артисты Мохтар Мутин килеп, спектакль куярга тырышып йөри, ләкин спектакльдә уйнар өчен хатын-кыз таба алмыйча йөри. Шәһәрдәге татар кызларыннан берәүнең дә артистка якын килергә, аның белән «театр уйнарга» йөрәге җитми. Ахырда яшьләр тәмам аптырауда калган артистка: «Бездә бер Лиза исемле рус кызы бар, татарча бик оста сөйләшә, шул уйнамасмы икән»,— диләр. Лизаны чакырталар һәм спектакльгә катнашуын үтенәләр. Лиза бик куанып риза була. Ниһаять, спектакль уйнала һәм бу спектакль яшь кыз Лизаның йөрәген театрга тәмам бәйли дә куя. Аңарда чынчыннан артистка булу теләге туа һәм ул әлеге артистка ияреп китеп тә бара... Шулай итеп, яшь кенә кыз Лиза Шляхтина ул заманда охшашлы булмаган гаять кыю бер адым ясый һәм үзенең тормышын, киләчәген татар сәхнәсе белән бәйли.

Ата-аналары кызларының татар артистына ияреп, татарча театр уйнап йөрергә чыгып китүеннән гаҗәп-хәйранга калалар, аның башына нәләт-каргыш яудыралар һәм, билгеле инде, кызлары итеп танудан шунда ук баш тарталар. Ә Елизавета Александровна татар сәхнәсенең хатын-кызларга иң аптыраган чагында килеп, озак еллар дәвамында татар театрына фидакарьләрчә хезмәт итә һәм Сыртланова фамилиясе белән татарның үз кешесе — күренекле карт артисткаларыбызның берсе булып танылa.

## Чыныгу еллары

1919 елның яз башында, Ырынбурны аклар алу куркынычы тугач, «Ширкәт» труппасы тарала. «Ширкәт»нең бер төркем артистлары — Нури Сакаев, Нәгыймә ханым Таждарова, Сыртланова, Сәмитова, Әхәт Хисамов, Нургали Якупов һәм янә берничә кеше — шәһәрне калдырып чыгучы Кызыл Армия белән ияреп китәләр. Аларга махсус вагон бирәләр һәм алар, Туркармия штабының политотделы карамагындагы труппа булып, фронт артыннан калмыйча, Кызыл Армиягә спектакльләр күрсәтеп йөриләр.

Колчак кире чигенә башлый, аклар Идел күперен ваттыралар. Кызыл Армия Уфага керә алмыйча тора. Хәл болай булып киткәч, безнең артистларыбызны Самарага (Куйбышевка) Армиянең көньяк группасы карамагына җибәрәләр. Самарада алар завод-фабрика эшчеләре арасына, Кызыл Армия частьларына барып, 1919 елның көзенә кадәр спектакль уйнап йөриләр.

Кызыл Армия Уфаны алып, Колчакны Урал аша куып киткәч, артистларның бер өлеше Уфага кайта. Алар анда шәһәрдә табылган көчләрне җыеп, бер труппа оештыралар һәм 1919—1920 елның сезонын шунда үткәрәләр. Җәй башында Уфага 5 нче Армиядә эшләп йөргән артистлар да кайталар. Алар арасында Шакир Шамильский да була. Нәгыймә ханым беренче тапкыр татар сәхнәсенең онытылмас бу якты таланты белән шул чакта очраша. Соңыннан алар дуслашалар, озак еллар дәвамында бергә эшлиләр һәм үзләренең акыл көчләре, интуиция тирәнлекләре, сокландыргыч осталыклары белән бер-берсенә шактый охшаган артистлар булып, сәхнәбезне артистлык иҗатының югары художество үрнәкләре белән баеталар.

1920 елның көзендә Нәгыймә ханым белән Нури Сакаевны Ташкентка чакыралар. Алар бу чакыру буенча баралар һәм Урта Азия Реввоенсоветы карамагындагы агитпоездда эшли башлыйлар. 15ләп вагоннан торган бу агитпоездда бөтен культура һәм сәнгать (клуб, музей, китапханә, типография һ.б.) чаралары тупланган була. Менә шул агитпоезд белән алар Урта Азиянең бик күп шәһәрләрен йөреп чыгалар. Поездагы татар артистлары һәр туктаган җирдә концертлар бирәләр һәм «Галиябану», «Хаҗи әфәнде өйләнә», «Көнче ир» кебек репертуарда торган спектакльләрен күрсәтәләр. Гаскәри тамашачыларга бигрәк тә «Галиябану» ошый, Нәгыймә ханым тудырган шундый гади, сөйкемле саф авыл кызы Галиябану кызыл сугышчы татар егетләрен аеруча сокландыра; алар Галиябану белән Хәлилнең бәхетсез мәхәббәтләрен йөрәкләренә бик якын алалар һәм сәхнәдә барган фаҗигане тормыштагы чын бер вакыйга төсле итеп кичерәләр. Кыскасы, спектакль аларны бик тирәнтен дулкынландыра, һәм алар, сәнгатьнең көчен, бәлкем, беренче мәртәбә татыган гади тамашачылар, артистларны, зур рәхмәтләр әйтеп, тантаналы рәвештә озатып калалар.

Агитпоезд, күп шәһәрләрне йөреп үткәннән соң, 1921 елның язында кире Ташкентка кайта.

Нәгыймә ханым Ырынбурдан башланып киткән бу йөрүләреннән зур канәгатьләнү ала. Беренчедән, ул туган халкы алып барган бөек көрәштән читтә торып калмый; үзе иске тормышның бөтен ямьсезлеген һәм нужасын җилкәсендә татыганга күрә, ул бу көрәшнең бөек максатларын аңлый, йөрәгенә якын ала һәм, артистка буларак, үзенең таланты, осталыгы белән шул көрәшкә хезмәт итә. Икенчедән, ул моңарчы театр залларында күренмәгән яңа тамашачы белән очраша. Бу тамашачы

нечкә зәвыклы театраль публика түгел, ләкин чын белән фальшьне бик тиз сизә белүче, бай тормыш тәҗрибәсе булган халык. Менә шушы халык алдында артистлык осталыгын сынап карауның Нәгыймә ханым өчен әһәмияте, әлбәттә, зур иде. Бу яңа тамашачы җитди игътибар белән бик бирелеп сәхнәдәге уенны күзәтә, һәм алар алдында «менә мин ничек уйныйм» дип кыланып маташу уңайсыз, аларны ничек тә ышандыра белергә кирәк иде. Һәм менә артистканың күңелен туктаусыз «алар минем уйнавыма ышаналар микән?» дигән уй борчып тора. Әйе, алар ышаналар, ләкин никадәр гади итеп, тормыш чынлыгына якын торып уйнасаң, шулкадәр ышана төшәләр. Нәгыймә ханым, алар алдында үзен сынау нәтиҗәсендә, халыкка җитә торган сәнгатьнең бары реалистик сәнгать кенә булуына күңелен тәмам беркетә. Әйтергә кирәк, бу моментның артистканың тәмам формалашуы өчен гаять зур әһәмияте була. Революция сәнгатьнең чын, асыл мәгънәсен, ягъни аның турыдан-туры халыкныкы булырга тиешлеген, бары тик халыкка хезмәт итәргә тиеш булуын ача. Бу хәл исә сәнгатькә булган җитди мөнәсәбәтне көчәйтә, аңлы җаваплылыкны үстерә. Ниһаять, бу хәл сәнгатьнең эчтәлеген тирәнәйтүгә, аның чараларын камилләштерүгә, формасын садәләштерүгә алып бара. Менә шушы сәбәпләр нәтиҗәсендә безнең артисткабызның иҗади үсүе һәм камилләшүе тагын да көчәеп, тулыланып китә. Аның артистлык хезмәте яңа мәгънә белән сугарыла, ул чын дәрт, чын илһам белән эшләргә керешә.

1921 елның көзендә исә Татарстанның Мәгариф Халык Комиссариаты Нури Сакаев белән Нәгыймә ханымны Казанга чакырып ала. Шулай итеп, Нәгыймә ханым 4 ел йөргәннән соң, беренче мәртәбә сәхнәгә аяк баскан сөекле Казанына яңадан кайта. Ләкин бик авыр вакытка туры килә ул. Идел буенда мәрхәмәтез ачлык хөкем сөрә. Яшь Совет дәүләте бөтен көчен, бөтен ихтыярын җигеп, шул ачлыкка каршы авыр көрәш алып бара. 1920 елның көзендә оештырылган Татар дәүләт академия театры әйтеп бетергесез зур кыенлыклар белән 1921—1922 елгы сезонны үткәрә. Сезон бетүгә, Нәгыймә ханым белән Сакаев тагын Уфага китәләр һәм анда 1922 елдан 1926 елга кадәр тоташ өч сезонны үткәрәләр. Бу сезоннарда Башкортстан дәүләт труппасына шактый зур көчләр җыела. Анда Нури Сакаев белән Нәгыймә ханым Таҗдаровадан башка, Шакир Шамильский, Маһирә Мирвәлиева, Гыйләҗ Казанский һ.б. булалар. Уфа гаять бай театраль сезоннарны күреп үткәрә.

Нәгыймә ханым: «Уфа дәвере минем артистлык сәләтемнең иң пешеп өлгергән чагы булды»,— ди. Әлбәттә, Нәгыймә ханым Уфадан соң да иҗади үсүендә дәвам итә һәм иң көчле, бай образларын «Уфа дәвере»ннән соң тудыра. Ләкин Нәгыймә ханымның ул сүзләрендә дөреслек юк түгел. Чыннан да, әгәр без Нәгыймә ханымның сәхнәгә чыккан көненнән алып соңгы елларга кадәр башкарган рольләрен тикшереп карасак, «Уфа дәвере» аның иҗатын икегә бүлгән бер сызык булып тора, дип әйтә алыр идек. «Сәйяр»дан башлап Уфага кадәр ул башлыча «яшь кокеткалар» («Ревизор»да Мария Антоновна, «Гаепсездән гаеплелеләр»дә Каринкина) һәм «яшь героиня»лар («Галиябану»да Галиябану, «Мәкер вә мәхәббәт»тә Луиза) дип йөртелә торган рольләрне уйнавы белән таныла. Шик юк, бу төр рольләрне иҗат итүдә ул Уфа сәхнәсендә зур уңышларга ирешә, «яшь героиня» буларак, үзе әйтмешли, тәмам пешеп өлгерә.

Инде 1926 елны кире Казан сәхнәсенә кайткач, Нәгыймә ханымның башкара торган рольләре үзгәрә. Ул безнең сәхнәдә башлыча социаль героинялар һәм олы яшьтәге аналар, карчыклар рольләрендә уйнавы белән таныла.

## Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә

1926 елның апрелендә Уфа труппасы Ырынбурга гастрольгә бара. Җиде ел элек, Ырынбур сәхнәсендә үзенең гүзәл уеннары белән тамашачылар күңелендә тирән эз калдырып киткән Нәгыймә ханымны Ырынбур халкы бик сагынып каршы ала.

Гастрольләрдән соң Нәгыймә ханым белән Нури Сакаев Уфа труппасыннан аерылалар. Соңгы вакытларда аларда, бигрәк тә Нури Сакаевта, Казанга кайту теләге бик көчәя. Икесе дә артистлык хезмәтләренең бишеге булып саналган Казан сәхнәсен сагыналар, яңадан шунда кайтып эшләү дәрте белән яна башлыйлар һәм тәвәккәлләп Ырынбурдан туры Казанга киләләр.

Ләкин шундый зур ашкыну белән килгән бу ике артистның берсе, кызганычка каршы, туган сәхнәсендә бик аз гына вакыт уйнап кала. Беренче сезонда ук, ягъни 1927 елның 28 февралендә, йөрәк параличыннан кинәт Нури Сакаев вафат була. Нәгыймә ханым һич көтмәгәндә үзенең озак еллар буенча кулга-кул тотынып бергә эшләгән, бергә артистлык юлын үткән тормыш дустыннан аерыла. Театрыбыз исә пәрдәсе ачылган көннән диярлек фидакарьләрчә хезмәт итеп килгән, зур талант ия-

се, гаять оригиналь артистын югалта. Казан халкы үзенең сөекле артистын яшь композитор Салих Сәйдәшев тарафыннан артист вафаты уңае белән язылган беренче татар матәм маршының тирән моңнары астында озатып кала. Ул көнне барырга тиешле булган премьера бер атнага кичектерелә.

1921—1922 ачлык елындагы сезонны исәпкә алмаганда, Нәгыймә ханым безнең Казан сәхнәсенә, 10 ел чамасы вакытын читтә үткәреп, яңадан кайта. Бу еллар аның өчен бушка, нәтиҗәсез үтмиләр. «Сәйяр» труппасында беренче тәҗрибәсе итеп Рокыя, Каринкина, Мария Антоновна рольләрен уйнап киткән яшь актриса, инде шактый олыгайган һәм сәхнә остасы буларак тәмам җитешеп өлгергән, бай тәҗрибәле артистка булып тамашачылар алдына баса.

Бу вакыт эчендә татар театры да вакыйгаларга бай юл узган, зур үзгәрешләр кичергән һәм иҗади өлгергән театр булып җитешә. Ул инде 1920 елдан бирле Татарстанның дәүләт театры исемендә яшәп килә. 1926 елның язында татар театрының 20 еллык бәйрәме үткәрелә, Дәүләт театрына — Татар дәүләт академия театры дигән олы, мактаулы һәм җаваплы исем бирелә. Ул театр сәнгате дөньясында билгеле булган көчләрнең күпчелеген үзенә җыя, үз бинасында сәхнә сәнгатенең катлаулы иҗади эшен планлы рәвештә, киң колач белән алып бара.

Ләкин үсү, үзгәрү процессы, гомумән, театр өчен дә, шул җөмләдән Нәгыймә ханымның үзе өчен дә туктап тормый, әлбәттә, ул һаман дәвам итә. Илдә барган экономик, социаль-политик тирән, катлаулы үзгәрешләр, табигый буларак, идеология өлкәсенең бер тармагы — театр сәнгатендә дә чагылмыйча калмый. Бу чагылу театрның җаны булган репертуарында аеруча нык күзгә ташлана. Театр буржуа, мещан зәвыгына яраштырып язылган, массаның игътибарын иҗтимагый көрәш проблемаларыннан ераклаштыра торган һәм художество ягыннан зәгыйфь булган әсәрләрдән арына. Яңа репертуар, советчыл репертуар мещан макулатурасын шактый зур кызулык белән театрдан куып чыгара. Сәхнәгә революцион көрәшнең һәм совет чынбарлыгын чагылдырган әсәрләр менә.

Бу үсешнең конкрет чагылышын 1928—1929 елгы сезонда сәхнәгә куелган «Разлом» (Б.Лавренев) постановкасында күргән идек. «Разлом» Татар дәүләт академия театрының зур иҗат уңышы булып, аның эшчәнлек тарихына кереп кала.

«Разлом»нан соң революция вакыйгаларына һәм граж-

даннар сугышына багышланган Фурмановның «Мятеж», Корнейчукның «Эскадра һәлакәте», Шәриф Камалның совет чынбарлыгын һәм сыйнфый көрәшнең кискен күренешләрен чагылдырган драмалары, Һади Такташның «Камил» кебек әсәрләре безнең сәхнәдә төп урынны алалар. Соңрак Таҗи Гыйззәтнең революциягә чаклы татар авылының сыйнфый каршылыкларын чагылдырган пьесалары («Чаткылар», «Ташкыннар») театр репертуарын баеталар. Менә бу репертуардагы үзгәреш, театр сәнгатенең башка сызыклары буенча да иҗади эзләнүләргә, яңа сыйфатлар табуга алып барырга тиеш иде.

Тирән социаль эчтәлекле революцион көрәшне яки совет чынбарлыгын гәүдәләндергән әсәрләрне куюда режиссер яңа методлар табарга, артист исә ул әсәрләрдәге яңа тип кешеләрне тудыруда яңа иҗат алымнарын кулланырга тиеш иде. Мәсьәлә шунда ки, бу әсәрләр үз стильләрен, ягъни тормыш чынлыгын перспективада, үсүдә сурәтләүче социалистик реализм һәм бөек тарихи вакыйгаларның пафосын күрсәтүче революцион романтизм стилен театрга алып килә. Һәм шушы стиль сәхнә сәнгатенең бөтен тармакларындагы иҗат алымнарын бигрәк тә артист уенының яңа чараларын билгели. Чыннан да, бу әсәрләрдәге революцион идеяләрне раслаучы социаль геройларны артист иске чаралар белән генә тудыра алмый иде. Артист алдына шул образларның идеяләрен үзенеке итү, аларның тормышка һәм кешеләргә булган мөнәсәбәтләрен үз мөнәсәбәте итә алу, аларның теләк, тойгылары белән яши белү, кыскасы, социаль геройны реаль чынлыкта тамашачыны ышандыра алырлык итеп тудыру бурычы бөтен авырлыгы белән килеп баса. Безнең сәхнәдә социаль геройларны тудыруда беренче югары үрнәкне биргән, социаль геройның чыннан да тормышчан җанлы, тулы итеп гәүдәләндергән беренче артист мәрхүм Шакир Шамильский булды дисәк, хата әйткән булмабыз. Аның чын художество осталыгы белән тудырган «Разлом»дагы Гадоны, «Эскадра һәлакәте»ндәге Гайдае, «Томан арты»ндагы Кузнецовы, гомумән, театрыбызның яңа кешеләрне бирүдә зур иҗади уңышы булып саналырга тиеш. Социаль героиняларны башлап зур уңыш белән башкару шәрәфе исә Нәгыймә ханым Таҗдарова өлешенә төшә. Рокыядан, Галиябанудан, Луизадан ул «Разлом»дагы Татьяна, «Эскадра һәлакәте»ндәге Оксана рольләрен башкару дәрәҗәсенә килеп җитә. Бу аның Академия театры сәхнәсендәге яңа үсеше, үзен, сәхнә остасы буларак, яңа яктан күрсәтүе иде. Нәгыймә ханымның социаль героиня образын ни-

чек итеп тудыруын күрү өчен, без аның «Эскадра һәлакәте»ндәге Оксана роленә тукталырга тиешбез. Корнейчукның талантлы әсәрендәге бу Оксана роле, Нәгыймә ханым башкарган шул типтагы рольләрдән иң характерлысы һәм уңышлысы иде.

## Оксана ролендә

«Эскадра һәлакәте» гражданнар сугышының иң фаҗигале һәм, шуның белән бергә, иң героик вакыйгасын — революцион матросларның үз куллары белән Кара диңгез флотын батыруларын күрсәтә. Бу — тарихи факт.

Оксана «Эскадра һәлакәте»ндә бердәнбер хатын-кыз роле. Ул большевиклар партиясенең Кара диңгез флотындагы вәкиле, революцион комитетның җитәкчесе. Бу большевик әнә шул караңгы төндә дулаган диңгезнең үзе кебек дәһшәтле, куркыныч вакыйгаларның үзәгендә тора. Гаять авыр һәм җаваплы эш йөкләнгән аның ябык җилкәләре өстенә. Ул Кара диңгез флотының хәлен дөрес аңларга тиеш, корабльләрдә нинди көчләрнең хәрәкәт итүен ачык күрергә, дус белән дошманны аера белергә тиеш. Иң авыр шартларда да ул ачык акылын, ихтыярын җуймаска, иң буталчык хәлләрдән дә чыгу юлын дөрес табарга тиеш. Шундый авыр җаваплы бурычларны үтәү өчен, аңарда нинди характер, нинди кешелек сыйфатлары булырга тиеш соң?

Нәгыймә ханым өчен Оксана, моңарчы артистлык тәҗрибәсендә һич очрамаган, өр-яңа образ иде. Бу образны кай җиреннән тотып алырга, ничек итеп, нинди материаллардан аны торгыза башларга, ниһаять, нинди җан белән аны тере итәргә? Артистка алдына үтә катлаулы, авыр, ләкин шуның белән бергә, бик шәрәфле иҗат бурычы килеп баса.

Һәрбер иҗат эшендәге шикелле, артист тарафыннан образ тудыру эшендә дә алдан ук уңышны билгели торган бер психологик хәл Нәгыймә ханымга ярдәмгә килә: ул Оксананы ярата. Образга тирән җылылык, мәхәббәт тоеп, Нәгыймә аны тудыру өстендә уйлана башлый. Ләкин тудырачак образыңны ярату бик әһәмиятле һәм кирәкле нәрсә булса да, Оксана шикелле героиняны, тарихи бер вакыйганың үзәгендә торучы тип буларак, чын художество югарылыгына күтәреп, дөрес гәүдәләндерү өчен, аны бөтен акылың, йөрәгең белән аңларга да кирәк иде. Һәм җитди, уйлап эш итүче Нәгыймә ханым Оксананы дөрес аңлый. Аныңча, масса җитәкчесе большевичка Оксана, халыкка читтән килүче түгел, ә революцион

ция кодрәте белән шул халыкның үз эченнән чыккан кеше булырга тиеш. Халык аның үз даирәсе, димәк, ул аларга мөнәсәбәттә рәсми түгел, ә гади, табигый булырга тиеш. Шул ук вакытта бу халыкның үз эченнән чыккан гади хатын масса башында торучы, масса белән җитәкчелек итүче дә: димәк, ул һәркайчан үзенең акылы, ихтыяры белән өстен, көчле бер кеше булып башкалардан аерылып торырга тиеш. Аңарда эчке җыйнаклык, зур җаваплылыкны тоюдан килеп чыккан тимер дисциплина: тышкы хәрәкәтләргә ул саран, һәрвакыт тигез, сабыр тавыш белән генә сөйли, интонациясен урынлы-урынсыз кискен итеп үзгәртми, ялган пафоска яки ясалма төчеләнүләргә һич бирелми. Ләкин момент таләп иткәндә, бу үзен гади генә тоткан хатын, теге яки бу кешегә карата кискен, каты була белә һәм аны үз ихтыярына буйсындыра ала.

Нәгыймә ханым Оксананы әнә шулай аңлый һәм аны большевик-революционерка итеп, шул сурәттә гәүдәләндерә. Ләкин Оксана революционерка булу белән бергә хатын кеше дә. Артистка моны бик яхшы исендә тота һәм Оксананың хатын-кызга гына хас сыйфатларын — пөхтәлеген, әдәплелеген, кешеләрне кайгыртучан йомшак күңелен мөмкин кадәр тулырак чагылдырырга тырыша. Шартлар никадәр авыр, көрәш никадәр кискен, шәхси җаваплылык никадәр зур булмасын, Нәгыймә ханымның Оксанасы үзенең тыйнаклыгы, җитдилеге аша кешеләргә карата булган эчке җылылыгын чын-чынлап күрсәтә ала.

Оксананың барлык төп сыйфатлары Гайдайга булган мөнәсәбәтендә бик тулы чагыла. Гайдай — әсәрдәге иң катлаулы образларның берсе. Ул революциягә бөтен җаны-тәне белән бирелгән, үзе әйтмешли, революция өчен үлемдә дә тормыш таба торган кеше; ул, революцион комитетның актив членнарыннан берсе булган большевик, хезмәт иткән корабын туган анасыннан да битәррәк яратучы матрос. Ләкин аның характерында дуамал стихия көчле, аңа сабыр, айнык акыл җитеп бетми. Шуңар күрә ул буталчык шартларда дөрес юлдан тайпылучан, вакыт-вакыт катлаулы көрәшнең серләренә төшенә алмый. Дус белән дошманны аерып бетә алмыйча йөри.

Гайдай ролен мәрхүм Шакир Шамильский һич онытылмаслык итеп, гаҗәп бер осталык белән башкарган иде. Һәм менә сабыр, тыйнак Оксана — Таҗдарова һәм ут булып янган Гайдай — Шамильский, сәхнәдә соклandыргыч бер контраст булып күз алдына басалар. Ике олы талант шундый бер-берсенә каршы булган кеше ха-

рактерларын бер үк дәрәҗәдәге ышандыру көче белән гәүдәләндерәләр. Ләкин Оксананың Гайдайга мөнәсәбәте нинди? Гайдай революциянең тугрылыклы солдаты, ләкин акыл ихтыярына буйсынып бетмәгән темпераменты еш-еш кына аны ярсытып җибәрә, яраланган арысландай ул, ак-караны белмичә, төзәлмәс хаталар эшләп ташларга хәзер тора. Һәм Оксана Гайдайның менә шул уңай һәм тискәре якларын бик ачык күрә; ул революциягә бөтен йөрәге белән бирелгән Гайдайны, һичшиксез, үз, якын итә, аңа гади дустанә мөнәсәбәт күрсәтеп, уңай йогынты ясарга, аның урынсыз ярсуын басарга, аны хата адымнардан сакларга тырыша. Кирәк урында Оксана аңа карата туган апасыдай булып, тирән кайгыртучанлык күрсәтә; күкрәген ачып салкын диңгез җиленә каршы торган Гайдайга ул, һич ясалмасыз табигый җылылык белән, «бушлатыңның төймәләрен каптыр... менә шулай... салкын тидерерсең» ди. Шул ук вакытта Оксана Гайдайның хаталарын кичерергә хәзер тормый, киресенчә, әгәр Гайдай үзенең ачу һәм ярсуында чиктән узып китсә, уртак эшне зур куркыныч астына куйса, ул аңа карата һич икеләнми каты, килешмәс сызыкка күчә. Шәхси тойгылары белән хисаплашып тормыйча, революция таләп иткән кискен чараны большевистик турылык белән куллана. Гайдай Балтыйк флотыннан килгән вәкилләрне провокациядә гаепләп, аларны атуны таләп иткәч һәм күпчелек ихтыярына буйсынмыйча комитетны ташлап чыгып киткәч, Оксана, эчке дулкынлануын көч белән басып:

— Партиянең тимер дисциплинасын җимергән өчен Гайдайны партиядән чыгарып ташларга! — дигән катгый тәкъдимен кертә.

Ләкин Оксана Гайдайның үзе сизмәстән хата юлга басуын, ялгышуын ачык күрә, шуның өчен дә ул һаман аңа хакыйкатьне аңлатырга, аны тәмам һәлак булудан коткарырга тырыша. Ниһаять, Лениннан корабларны дошман кулына бирмәс өчен батырырга кушып радиограмма килгәч, Оксанада беренче башлап туган теләк — Гайдайны күрү, Гайдайны хәтәр эштән туктату була. Ул Гайдайны, мәкерле, усал провокатор Кобза белән бергә икәүләп, Балтыйк вәкилләрен ябылган урыннарыннан чыгарып атарга җыенган җирләрендә очрата. Оксана: «Туктагыз!» — дип кычкыра, Гайдайга яныннан Кобзаны куарга куша, «Гайдай, син хәзер барысын да белерсең»,— ди... Ахырда, Гайдайны үзенә буйсындырыр өчен револьверын чыгарып, аның күкрәгенә төзи... Шул чакта петлюрачы провокатор Кобза Оксананы атып үтерә.

Гайдайга айныр өчен провокаторның шушы атуы кирәк була. Ул айный, ул Кобзаның үзен дөмектерә, үзенең дуамаллыгы нинди фаҗигале бәхетсезлеккә китереп чыгаруын әйтеп бетергесез тирән, үкенечле әрнү белән кичерә, һәм революциянең аяусыз таләбен, ниһаять, аңлап, җаныннан кадерле корабын, беренче булып, үз кулы белән диңгез төбенә җибәрә.

Менә шундый фаҗигале һәм героик вакыйгалар каһарманы булып гәүдәләнә Оксана... Юка гәүдәле, ак чырайлы ул, өстендә аның солдат гимнастеркасы һәм күн куртка, аякларында гади солдат итекләре, хәрәкәткә саран, тигез күкрәк тавышы белән сөйли, ләкин һәр хәрәкәте, һәр сүзе гади, табигый, үзен зурга санау, кәпрәю юк. Тыйнаклык, хисләренә хуҗа була белү — аның характерында төп сыйфатлар. Ул халыкның үз эченнән чыккан масса җитәкчесе, ул партия тарафыннан тәрбияләнгән тимер дисциплиналы, айнык акыллы, көчле ихтыярлы большевик көрәшче,— революция дошманнарына никадәр килешмәс катылык күрсәтә белсә, аның тугрылыклы солдатларына шулкадәр җылы дуслык, ана шикелле кайгыртучанлык күрсәтә белә. Менә шундый булып Нәгыймә ханым тудырган Оксана тамашачылар күз алдына баса, аларның йөрәкләренә кереп кала.

Оксана образы — талантлы артистканың, һичшиксез, зур иҗат уңышы иде, һәм бу образны тудыру белән, Нәгыймә ханым үзен социаль героиня рольләрен башкара алу көченә ия булган, киң пландагы драматик актриса итеп таныта.

## Ана образы

Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә без Нәгыймә ханымны бик еш кына олы яшьтәге аналар һәм карчыклар рольләрендә дә күрәбез. Гомумән, соңгы елларга таба аның уйнаган рольләре, яшь һәм характер ягыннан үзгәрә баралар. Мондый үзгәреш күп артистларның иҗат гомерләрендә очрый торган табигый хәл. Рус сәхнәсенең даһие Гликерия Федотовна да билгеле бер яшькә җиткәннән соң, карчыклар роленда уйный башлый, ләкин аңа карап, Федотова Федотова булудан туктамый, бөек таланты бөтен көченә саклана.

Нәгыймә ханымның яңа төр рольләргә күчүе бик табигый була, бу күчү аның иҗатына һичбер нинди торгынлык китерми. Киресенчә, бу яңа төр рольләрне башкару, артистканың иҗатында яңа үсеш билгесе булып тора, аның таланты яңа бер яктан ачыла. Нәгыймә ха-

ным үзе: «Тамашачы өчен, бәлкем, яшь рольләрдә күренү яхшыдыр, ләкин чын артист өчен яшь белән карт, бай кием белән сәләмә кием арасында аерма юк, алар барысы да аңа кадерле, аларның барысын да ул тудыра»,— ди. Бик дөрес фикер, һәм Нәгыймә ханым, чын талантлы артистка буларак, безгә бөтен бер галерея аналар һәм карчыклар образларын тудырып күрсәтә. Аның бу образлары төрле социаль катлаудан, төрле милләттән булалар. «Томан арты»нда ул совет чорындагы шәһәр эшчесенең хатыны, инженер анасы, «Профессор Мамлок»та антифашист профессор хатыны, «Ташкыннар»да исә ярлы крәстиән карчыгы һ.б.

Нәгыймә ханым бу образларның социаль һәм семья хәленә хас булган уй-кичерешләрен тирән ачып, характер үзенчәлекләрен дөрес табып гәүдәләндерә. Аның карчыклары бер калыптан төшкән стандарт карчыклар булмыйлар; шуңар күрә ул уйнап күрсәткән һәрбер карчык тамашачы хәтерендә конкрет бер кеше булып урнашып кала.

Һәрбер артистның уңыш белән уйнаган бик күп рольләре арасында аеруча аерылып торганнары, хәтергә ныграк кереп калганнары була. Нәгыймә ханымның әнә шундый роле итеп, Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар»ындагы Гөлнисаны күрсәтергә мөмкин.

«Ташкыннар» пьесасы 1914—1917 еллардагы татар авылын, андагы беренче дөнья сугышы кузгаткан вакыйгаларны чагылдыра. Электән яшәп килгән сыйнфый каршылык, империалистик сугыш нәтиҗәсендә кискенләшә, өскә калкып чыга, ярлы крәстиән эшче сыйныфының союздашы булып, Октябрь революциясенә килә — менә әсәрнең идея сызыгы шул.

Гөлниса — балта остасы Биктимер картның карчыгы, өч җиткән улның, ике җиткән кызның анасы. Янә аның ике килене, бер кияве дә бар. Күрәсез, озын тормыш юлы үткән, киленнәр күрү, кызларын бирү бәхетенә ирешкән, һәртөрле ихтирамга лаек карт ана. Һәм Нәгыймә ханым Гөлниса карчыкны иң әүвәл чын мәгънәсе белән әнә шундый ана итеп бирә. Җиткән улларына, кызларына карата тирән аналык мәхәббәте — менә аның һәр хәрәкәтеннән, һәр сүзеннән сизелеп торган эчке җаны шул. Ләкин Нәгыймә ханымның Гөлнисасы улларына, кызларына булган бу аналык хисләрен күрсәтүдә тыйнак була: ул төчеләнми, урынлы-урынсыз кайгы яки шатлык яшьләрен күрсәтеп тормый, ә бәлки, ана йөрәгенең эчке сылулыгын тыйнак, ягымлы итеп сурәтләргә тырыша.

Аның өч улы да герман сугышына китәләр, җиткән

кызын бай старшина улы алдап хурлый, солдатка булып калган бер килене аза башлый... Йә, ана өчен болардан да авыр, газаплы бәхетсезлекләр булырга мөмкинме? «Ай, бу балалар мине вакытсыз гүргә кертәләр инде»,— ди Гөлниса, тирән кайгыдан йөрәге сыкранган минутларда, әмма шулай да ул искиткеч сабыр, чыдам карчык. Һәм Нәгыймә ханымның Гөлнисаны уйнавында сокландыргыч момент — менә шул безнең аналарыбызга хас булган сабырлык, чыдамлылыкны күрсәтә белүендә иде. Кайгы никадәр тирән, бәхетсезлекләр никадәр зур булмасын, Нәгыймә ханымның Гөлнисасы акыл ихтыярын җуеп, туктаусыз елап торган, эшкә яраксыз авыру карчыкка әверелми, ул кайгы-хәсрәтләрнең барысын да үзенең зәгыйфь җилкәләрендә күтәрә ала, эчке рухи ныклык, киләчәккә өмет аңарда һаман саклана.

Гөлниса — Биктимер картның 35 ел бергә гомер иткән тугрылыклы тормыш дусты. Алар бер-беренә арка таянычы булып яшиләр, кайгы-шатлыкны бергә кичерү генә түгел, тормышны бертөрле аңларга да өйрәнгәннәр. Алар бер-берсенең киңәшенә, бер-берсен юатуга мохтаҗ булып торалар, алар арасында озак еллар буенча сыналып килгән чын, тирән, җылы татулык. Нәгыймә ханым Гөлниса карчыкны әнә шулай бай тормыш тәҗрибәле, аек акыллы, картына карата һәрвакыт тугрылыклы дус, якын киңәшче, кешелекле кайгыртучы итеп гәүдәләндерә.

Бу сыйфатларның барысын да ул, образны тирән, дөрес тоеп, чын сәнгатькә хас гадилек, табигыйлек белән иҗат итә.

## Татар совет сәхнәсенең олы остасы

Нәгыймә ханым Таҗдарова үзенең 30 елдан артык дәвам иткән артистлык гомерендә 270ләп роль башкара. Бу сан аның татар театр сәнгатенә нинди интенсив рәвештә һәм күпме зур йөкләмә белән хезмәт итүен үзеннән-үзе күрсәтеп тора. Билгеле инде, бу кадәр күп рольләрне биредә санап кына чыгарга да мөмкин булмас иде. Шуңар күрә дә без Нәгыймә ханымның иҗатын характерлау өчен, ул башкарган төрле типтагы рольләрдән берничәсен генә алып тикшерү белән чикләндек. Ләкин шулкадәресе дә безгә Нәгыймә ханымның нинди артистка булуы аның иҗат үзенчәлекләрен аңларга мөмкинлек бирә дип уйлыйбыз. Чыннан да, Нәгыймә ханым Таҗдарова нинди стильдәге артистка соң ул?

Ул — реалистик стильдәге драматик актриса. Үткер,

айнык акыллы, тирән интуицияле, индивидуаль сыйфатларга бай булган, чын мәгънәсе белән олы талантлы һәм киң диапазонлы сәхнә остасы. Тышкы билгеләре белән ул уртача буйлы, юка гәүдәле, ак озынча чырайлы, түбән күкрәк тавышы белән сөйли, дикциясе аның бик чиста һәм ачык. Характеры белән исә сабыр холыклы, ихтыяр көченә ия, кешеләргә карата кешелекле һәм гаҗәп тыйнак, намуслы бер кеше иде.

Эчке һәм тышкы артистлык сыйфатлары, характеры белән Нәгыймә ханымны әнә шулай танырга, күз алдына китерергә мөмкин.

Нәгыймә ханым үзенең иҗатында елдан-ел һаман үсә, камилләшә барган артистка ул. Аның шулай икәнен без ул иҗат иткән образларга тикшерү ясаганда күреп үткән идек. Ләкин Нәгыймә ханымның уйнау стиле үзенең үсешендә бер үк юнәлешне саклый, ягъни ул сәхнәгә чыккан көннән алып, реализм юлы белән үсә, тирәнәя бара һәм, ниһаять, реалистик пландагы сәхнә остасы булып формалаша. Юкка гына ул үзен Кариев шәкерте дип атамый. Әйе, Нәгыймә ханым Кариев шәкерте, татар сәхнәсенең танылган олы остасы булу өчен кирәкле оеткыны һәм юнәлешне ул аңардан ала. Ләкин бит Нәгыймә ханым Кариев белән бергә бары өч кенә сезон эшләп кала. Кариев 1920 елны вафат була, Нәгыймә ханым исә аңардан соң театрда чирек гасырдан артык вакыт эшләп, һаман үсә, камилләшә барды.

Бу үсү, камилләшүнең сәбәбен Нәгыймә ханым үзе башлыча туктаусыз эзләнүдән, өйрәнүдән күрә. Ул: «Мин һәрбер артистның уенын җентекләп өйрәнергә яратам. Яхшы уйнаучыдан да, начар уйнаучыдан да үземә кирәкне табарга тырышам»,— ди. Димәк, ул уртак тәҗрибә белән файдаланырга омтылучы артистка була. Билгеле инде, татар сәхнәсенең талантлы зур осталары бу җәһәттән Нәгыймә ханымга күп үрнәкләр бирәләр, һәрдаим уңай йогынтыларын ясап торалар. Бигрәк тә аның совет чорында үсүенә безнең мәктәп күргән профессиональ режиссерларыбыз — Г.Девишев, Г.Исмәгыйлев, Ш.Сарымсаков һ.б. зур йогынты ясыйлар. Безнең тыйнак артисткабыз хәтта бөтен уңышларын шул үрнәк, йогынтылар тәэсире астында булган нәрсә, дип аңлатырга тырыша иде. Без, әлбәттә, аның бу фикере белән килешеп бетә алмыйбыз, чөнки Нәгыймә ханым үзе дә иптәшләренә күп уңай йогынты ясаган, бай үрнәкләр биргән артистка ул.

Һәрхәлдә, өйрәнү, эзләнү Нәгыймә ханым өчен башкаларның иҗатларын күзәтү белән генә чикләнеп кал-

мый. Ул, мәсәлән, реаль, объектив тормышны һәрьяклап белүне үзенә шарт итеп куя. Чөнки ул бай тормыш тәҗрибәсенең теге яки бу иҗат бурычын дөрес хәл итәргә тырышканда ярдәмгә килүен бик яхшы сизеп, аңлап тора.

Янә, ул һәрвакыт үз иҗатын объектив тикшереп, дөрес аңларга, дөрес нәтиҗә чыгарырга һәм, шул рәвешчә, үз тәҗрибәсеннән өйрәнергә тырыша. Аныңча, артист бервакытта да үз уеныннан риза булып бетми, ул һәркайчан «бүген кичәгегә караганда яхшырак уйнар идем» дип уйлый. Шуңар күрә дә ул: «Әллә кайчан уйнаган рольләремне исемә төшереп, тикшереп карарга яратам»,— ди иде.

Менә болардан Нәгыймә ханымның эзләнү-өйрәнүләре никадәр күпьяклы һәм җитди булуы ачык күренсә кирәк. Инде Нәгыймә ханым иҗат методының үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?

Гадәттә, роль алып, шуның өстендә эшләргә керешкәч, аның иҗат процессын характерлый торган түбәндәге тәртип һәм моментларны күрергә була:

1. Иң әүвәл ул үзе катнашасы әсәрнең темасы һәм тулай эчтәлеге белән таныша, аның төп идеясен үзе өчен ачыкландыра. Соңра, әсәрдәге башка персонажларның нинди кешеләр булуы белән кызыксына, аларның кешелек сыйфатларын, характерларын өйрәнә. Шул рәвешчә, ул әсәрнең эчтәлек-идеясеннән, анда катнашучы бөтен персонажларның кем булуларыннан чыгып, үзе уйныйсы рольнең урынын, әһәмиятен билгели.

2. Ул тудырган кеше кем? — Менә бу сорауның ачык җавабын табу өчен, Нәгыймә ханым уйныйсы рольнең социаль йөзен, тормышка һәм кешеләргә булган мөнәсәбәтләрен, характерын, уй-кичерешләрен җентекләп өйрәнә. Бу — образны эзләү-табу процессы, һәм бу процесс артистка өчен һәркайчан әһәмиятле һәм кирәкле бер эш булып санала. Чөнки «рольнең яныннан үтеп кенә китәргә мөмкин, яки аны кулыннан җитәкләп, сәхнәдән йөртеп чыгарырга була, яисә рольнең эченә кереп, ул булып яшисең» ди Нәгыймә ханым.

3. Һәм менә рольнең эченә кереп, ул булып яшәр өчен, Нәгыймә ханым рольдәге ышандырыр моментларны эзләргә керешә; аның һәр эшен, һәр сүзен, һәр хәрәкәтен логик һәм психологик җәһәттән тикшереп чыга. Рольнең нәрсәсе ышандыра, нәрсәсе ышандырмый, аның һәр сүзе, һәр кыланышы психологик кичереш ягыннан акланамы? Шушы сорауларга җавап тапмыйча торып, Нәгыймә ханым тынычлана алмый. Бергә эшләгән иптәшләренең әйтүләренә караганда, Нәгыймә ханым рольнең

әнә шул ышандырыр якларын эзләү, табу өстендә аеруча тирән иҗат газабы кичергән.

4. Рольдәге ышандырыр моментларны эзләп тапканнан һәм җыйганнан соң гына, ул аны образ итеп тудыру эшенә керешә. Инде үзе ышанганны тамашачыны ышандырырлык итеп бирер өчен ул рольнең характерына, эчке кичерешләренә табигый ятышлы, лаек булган тышкы чараларны — хәрәкәт, мимика, интонацияне табарга тырыша. Бу җәһәттән дә ул үзенә гаять зур таләпләр куя, бик четерекле булып, үз эшеннән канәгатьләнә алмыйча йөдәп бетә. Репетиция вакытларында аның: «Юк, бу болай булмый, бу ялган, дөрес түгел»,— дип, үз-үзенә әйткән сүзләрен иптәшләре еш ишетә торган булганнар. Ләкин аның шулай туктаусыз эзләнү белән тапкан хәрәкәте, интонациясе инде рольнең органик, чын, үз сыйфаты булып чыга. Нәгыймә ханым тышкы чараларга гаять саран артистка, ул бары аларның иң кирәк булган кадәресен генә, психологик яктан тәмам акланганын гына куллана. «Сәхнәдә минем бары образ кушканны гына эшләргә хакым бар»,— ди ул. Һәм бу принцип Нәгыймә ханымның девизы. Шуңар күрә аның уенында һичкайчан үлчәүдән чыккан бер генә хәрәкәт яисә ышандырмас бер генә интонация дә булмый.

Әнә шулай итеп, Нәгыймә ханым, ниһаять, образ тудыра. Һәм аның образы коеп куйган тере, реаль кеше булып тамашачы алдына баса. Сәхнәдә Нәгыймә ханым юк, ә ул тудырган образ гына бар. Ул тудырган образлар шулкадәр тормышчан, чын булалар ки, тамашачыны үзләренең уй-кичерешләренә генә түгел, хәтта физик хәлләренә кадәр ышандыралар. Мәсәлән, «Ташкыннар»да Гөлниса карчыкны уйнаганда, аның юка, ябык гәүдәсе авыр хәсрәтләрдән менә хәзер сынар кебек тоела, гүя бөтен картлык сызланулары аның гәүдәсенә таралгандыр төсле сизелә. Аның бу хәлен әйткән сүзләреннән, зарлануларыннан гына түгел (киресенчә, ул һич зарланмый, сыкранмый), бәлки, озын гомерен нужада үткәргән, хәзер исә шундый авыр хәсрәтләр кичергән чын карчык булуыннан күрәсең. Шул ук вакытта әнә шундый физик какшаган тәндә никадәр рухи көч, өмет, җан җылылыгы күреп, аңа чын-чыннан сокланасың, йөрәк авыртуы белән аны кызганасың...

Мондый ышандыру көче белән образ тудыра алу, һичшиксез, зур талантка ия булган артистканың бөтен акыл һәм йөрәк көчен җигеп, туктаусыз газаплы иҗат утында янып эшләү нәтиҗәсендә генә булырга мөмкин иде. Чыннан да, Нәгыймә ханымның иҗатына башлыча нәрсә ха-

рактерлы? Ул бай тормыш тәҗрибәсенә хуҗа, ул тирән интуициясе кеше, ләкин ул үзенең иҗатында иң элек акыл белән эш итүче оста. Иҗат бурычын һәрьяктан уйлап төшенү, образны тудыруда һәрдаим акыл белән эзләнү, интуиция тапкан моментларның да чынлыгына акыл белән ышану, уен вакытында үз өстеннән акыл контролен булдыру — менә аның иҗатын характерлый торган асыл сыйфаты шул иде.

* * *

Нәгыймә ханым: «Театр минем төп йортым»,— ди иде. Ул сәхнә сәнгатен бөтен җаны-тәне белән ярата, ул үзенең аңлы гомерен, барлык көчен, дәртен, ниһаять, сәламәтлеген шул сәнгатькә бирә. Йә, аның менә бу сүзләре артистлык хезмәтенә һәм туган сәхнәсенә булган тирән мәхәббәтен ачык күрсәтмиләрме соң? «Пәрдә төшеп тамашачыдан аерылу, уен бетте дип белү минем өчен һәрвакыт авыр була, хәтта уйнаганнан соң парик белән күлмәкне салу авыр, гүя бер кадерле, җанга якын нәрсәләреңнән аерыласың».

Әйе, Нәгыймә ханымның театрга булган бу мәхәббәте бик аңлаешлы һәм табигый, чөнки ул тормышның төбеннән чыгып зур сәнгатькә килде, шунда ул яшәвенең мәгънәсен тапты.

*«Мәдәни җомга», 1997*

## ТАТАР БАЛАСЫНА УРЫСЧА БЕЛМӘҮ КУРКЫНЫЧЫ ЯНАМЫЙ

Зиннур туган!

...Сез телебез турында сүз кузгаттыгыз... Аның хакында минем уй-теләкләрем бик гади. Аларны мин күптән берничә тапкыр язып та чыктым, төрле сөйләшүләрдә дә әйтә килдем.

Җыеп кына әйткәндә, тел мәсьәләсендә минем карашым менә нидән гыйбарәт: татар халкының кимендә яртысы үз телен (ана телен) югалтты. Сәбәбе билгеле: большевиклар партиясенең вак халыкларны, аеруча безнең татарны, әкренләп урыслаштыру сәясәте иде... Хрущев вакытында ук Татарстан шәһәрләрендә, шулай ук күрше өлкәләрнең авылларында да татар мәктәпләре ябылып бетте диярлек... Казанда, мәсәлән, татар балаларының 93 проценты урыс мәктәпләренә күчте. Утыз ел буена без балаларыбызны ана телендә укытудан мәхрүм булып тордык. Шул вакыт эчендә урыс мәктәпләре аша узган берничә буын үз телен онытты, урыс теле генә төп

тел булып калды. Без аларны хәзер маңкортлар дип сүгәбез... Хәлбуки аларның бер гаебе дә юк, киресенчә, туган телдән аерылулары үзләре өчен дә, безнең өчен дә зур фаҗига ул... Бездән туган балалар ич!..

Менә шул фаҗигадән ничек чыгарга?.. Моның өчен туган телебезгә яңадан кайту кирәктер. Ә кайтыр өчен татар балалары һәммәсе дә (100 проценты белән) бары тик ана телендә укый башларга тиеш... Бөтен дөньяда ул шулай — һәр милләт баласы иң элек үз телендә укырга-язарга өйрәнә... Безгә дә шул максатка ирешер өчен, беренче нәүбәттә башлангыч мәктәпләрне тизрәк ачарга һәм аларның саннарын да күбәйтергә кирәк иде. Бу хакта мин «үзгәртеп кору» башлангач та язып чыккан идем. Ләкин ни сәбәптер баштарак моңа юньләп игътибар итүче дә булмады... Ә соңрак инде «нигә башлангыч мәктәп» кенә?

«Юк, безгә татар гимназияләре, татар университетлары да кирәк»,— дип, бик ялкынланып китүчеләр дә булды... Әмма адәм баласы укуын университеттан башламый, мәктәпнең беренче сыйныфыннан башлый. Сүз бит яшь буынны «маңкорт» булудан саклап калу турында бара!

Шуннан соң 10—15 ел вакыт үтеп китте, ә без туган телебезнең язмышы турында һаман баш ватудан, бәхәсләшүдән узганыбыз юк... Дөрес, ана телен укытуда шактый ук уңышларга ирештек бугай... «Туган телендә белем алучы татар балаларының саны 20 процентган 47 процентка кадәр артты» дип белдерә әнә «Мәгърифәт» гәзитәсе. Әмма татар балаларының һәммәсен дә ана телендә укыту башлауга ирешкәнебез юк шикелле әле... Бигрәк тә Казанның үзендә.

Бу мәсьәләдә мин һаман иске карашымда торам... Мәгәр кайбер яңа тәкъдимнәр дә өстисем килә.

1. Балаларны ана телендә укыта башлау безнең Татарстанда, махсус закон нигезендә, мәҗбүри булырга тиеш. Кабатлап әйтәм, сүз укыта башлау турында гына бара. Ягъни бала үз телендә камил укый-яза белгәнчегә кадәр... Моның өчен дүртьеллык башлангыч мәктәпне тәмамлау җитәчәк. Шуннан соң баланың теләсә нинди телдә укуын дәвам иттерергә хакы булырга тиеш.

2. Татар балаларын урыс мәктәпләренең башлангыч сыйныфларына кабул итми торырга... Иң элек ул татар мәктәбенә барырга тиеш. Аннары урыс телен татар мәктәбендә дә өйрәнәчәкләр. Ләкин беренче класстан ук түгел, яшь балага берме-икеме ел фәкать үз телен генә укыту кирәк.

3. Татар мәктәбе үзенә аерым булырга тиеш... Балаларны чорнаган мохитнең да «татарча» булуы кирәктер, мөгаен... Өч-дүрт урам саен бер башлангыч мәктәп булсын иде... Аңа зур биналар кирәкми, әнә Казанны уратып алган меңнәрчә ике-өч катлы коттеджлар да ярый торгандыр, минемчә... Бу изге эшкә хөкүмәт акча табарга тиеш.

Минем бу тәкъдимнәремдә яңалык юк диярлек. Татарның белемгә юлы ана теленнән башланган. Үзебездәге мәктәп-мәдрәсәләрдән соң, әгәр теләсә, югары белемне чит илләргә барып алган. (Истанбулга, Бәйрутка, Каһирәгә, хәтта Сорбоннага.) Әмма инде туган телен берваКытта да онытмаган. Бу җәһәттән олы шәхесләребезнең белем юлы безгә бик матур үрнәк!..

Соңгы сүзем. Татарның урысча белмичә калу куркынычы юк. Ул аны белергә мәҗбүр, хәтта уку йортларында 10—15 ел буена «зубрить» итмәсә дә... Тормыш үзе бик шәп өйрәтә... Ә үз телебез зур куркыныч кичерә... Аны саклап калу өчен кыю, тәвәккәл чаралар кирәк.

Урысларны татарча укытып азаплану исә бәрәкәтсез бер эш, минемчә... 70 еллык ачы тәҗрибәбез шуны ачык күрсәтә... Ят телне өйрәнү өчен ихтыяҗ туарга тиеш, ләкин урыслар өчен бездә андый ихтияҗның туганы юк... Татар һәм урыс телләре дәүләт теле булып саналгач, без шул ике тел белән әйбәт кенә яшәргә тиешбез... Әмма татар теленең ролен көчәйтү бик кирәк. Мәсәлән, халыкның 70—80 проценты татарлар гыйбарәт районнарда идарә итү эшләре татар телендә барырга тиеш. Бу бик законлы булачак. Шулай ук дәүләт органнары тарафыннан чыгарылачак һәртөрле карар, законнар да башта татар телендә язылып, соңыннан русчага тәрҗемә ителергә тиеш. Телне эшләтә белергә кирәк. Гамәлдә никадәр күбрәк кулланылса, тел шулкадәр камилләшәчәк.

*«Таһир-Зөһрә», 1998*

## ЯЛГЫШЫРГА ХАКЫБЫЗ ЮК

Апрель аенда булса кирәк, Премьер Фәрит Мөхәммәтшин латинга күчүгә багышланган бер киңәшмә уздырды. Мин дә чакырылган идем... Фикер алышуда катнашып, мин сүземне: «Латинга күчү мәсьәләсен сәясәттән аерырга кирәк иде»,— дип башладым. Миннән соң сүз алган Рафаэль Хәкимов: «Юк, латинга күчүне сәясәттән аерып булмый, ул — сәяси мәсьәлә!» — диде. Һәм бик дөрес әйтте. Хәреф алыштыруның үтә сәяси мәсьәлә икән-

леген ишетеп кенә түгел, күреп тә мин бик күптәннән беләидем. Ике тапкыр хәреф алыштыру минем күз алдымда булып узды... Һәм моның нәтиҗәләре дә миңа бик яхшы билгеле иде.

Шуңа күрә дә мин, үткәндәге хаталарны яңадан кабатламас өчен, бу юлы латинга күчүне сәясәттән аерырга кирәк дип әйткән дә идем. Сәясәт бит безне ике тапкыр хәреф алыштырырга мәҗбүр итте. Тарихка бер күз салыйк.

Егерменче елның урталарында азәрбайҗаннар латин алфавитына күчү кирәклеген күтәреп чыктылар. Шул ук вакытта аларга тугандаш һәм якын күрше Төркиядә дә латинга күчү буенча кызу эш башланган иде... (1928 елның көзендә Төркия рәсми рәвештә латинга күчте дә.) Әлбәттә, төрекләрнең латинга күчүләре бездә дә латинчыларның позициясен көчәйтте. Алар латинга күчүнең зарурлыгын фән-техниканы үзләштерү, алдынгы Европа культурасына якынаю һәм төрки халыкларны бер-берсенә якынайту өчен дә кирәк булуы белән аңлатырга тырыштылар... Сүз-бәхәс күп булды ул чакта. Тик бер нәрсә гаҗәпләндерә: большевиклар да төрки халыкларның ният-теләкләрен хуплыйлар кебек иде.

Күпләр мондый сәясәтнең төбендә нинди максат ятканын аңлаудан ерак иде әле. Тик бер кеше — Галимҗан Ибраһимов кына латинга күчүнең нәтиҗәсен алдан күрә белде: латинга күчү — рус алфавитына күчүнең башы, диде ул.

Аның хаклы булуы бик тиз расланды да. Латинга күчүебезгә ун ел да үтмәде, безне бик әйбәт кенә рус алфавитына күчереп тә куйдылар. Большевиклар мәкерлеге менә шул чакта гына аңлашылды да инде: ислам дине белән бергә килеп, мең ел буена кулланышта булган гарәп әлифбасыннан төрки халыкларны аеруы бик читен булачагын алар, әлбәттә, белеп торганнар. Ә латиннан аеру әнә ничек ансат-шома гына узды. Әмма бу хәреф алыштырулар корбаннарсыз гына узмады.

Большевикларның мәкеренә исең китәр. Үзенә күрә югары бер мәктәп ул... Гадәттә, алар зур бер эш башлар алдыннан шуның инициаторын табалар. Әйтик, яңа заем чыгарырга кирәк икән, берәр зур заводның коллективы исеменнән партия һәм хөкүмәткә мөрәҗәгать оештыралар... Шуның шикелле хәреф алыштыру мәсьәләсендә дә инициаторны алдан әзерләделәр: бичара Кырым татарлары латиннан руска күчү кирәклеген күтәреп чыктылар. Моның өчен ул халыкның большевиклардан нинди «мөкяфәт» алганын сез инде яхшы белә-

сез. Андый коточкыч алдануны һәм фаҗигале бәхетсезлеккә юлыгуны Ходай бүтән бер халыкка да күрсәтә күрмәсен!..

Әйе, хәреф алыштыру үтә сәяси мәсьәлә. Әмма аны хәл иткәндә, ни сәбәптер тел язмышы һәр очракта да «онытыла» торган иде. Гел кемгәдер ярау да ияру «алга» чыга иде. Рус хәрефләренә күчкәндә, «бөек урыс халкына» якынаю кирәклеген яшереп тә тормадылар. Нәтиҗәсе күз алдыбызда. Халкыбызның яртысы диярлек ана теленнән аерылып, «урыска» әйләнеп бетте. Күрше-тирә өлкәләрдә, аеруча мишәрләр илендә, татарча укый-яза белүче калмады. Ул тарафлардан яңа Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Һади Такташлар бүтән чыкмаячак инде.

Менә шуларны истә тотып, мин яңадан латинга күчкәндә, сәясәт белән мавыкмаска кирәк дигән дә идем. Күчкән тәкъдирдә бердәнбер теләгебез — телебезнең киләчәген кайгырту, аның сафлыгын, табигый үзенчәлеклеген саклау булырга тиеш дип әйткән идем. Ләкин фикер алышканда тагын төрки телләрне якынайту, унификацияләштерү турында сүз куерта башладылар... (Киләчәктә уртак бер тел булачак дип уйлаучылар да бар бугай.) Кысыр хыял... «Тәрҗеман» гәзите 35 ел буена төрки халыклар арасында төркиләштерелгән уртак бер тел урнаштырырга тырышып карады, әмма барып чыкмады. Һәр халык борыннан килгән үз телендә кала бирде. Булмый, барып чыкмый ул телләрне көчләп якынайту яки берләштерү... Мәсәлән, татар теле белән казах телен якынайтып буламы? — һич мөмкин түгел, минемчә. (Чөнки казах теле тоташы белән диярлек «җ» авазыннан тора: юл дими ул, җол, ди.) Телне югалту мөмкин, икенче телгә күчү яки йотылу мөмкин — моның мисаллары тарихыбызда җитәрлек... Тик яңадан кабатланмасын иде ул югалту, йотылулар... Тел язмышы — милләт язмышы, диләр ич!

Яңа вариант файдасына тагын шундый дәлил дә китерәләр: янәсе, ул компьютерда куллану өчен уңайлырак... Нәрсә дим, бәлки, шулайдыр да. Минем компьютер алдында утырганым юк, аңа нәрсә кирәген бөтенләй белмим дә. Ләкин бер генә халык, бер генә дәүләтнең дә компьютерга яраклаштырыр өчен генә алфавитын алыштырганын ишеткәнем юк әле.

Кыскасы, латинга күчүне аклап, теләсәң ни сөйләргә була, бары тик телебез хакында гына сүз юк... Ә бит ул иң төп сәяси мәсьәлә!

Менә безнең алдыбызда яңадан латинга күчүнең ике варианты ята. Берсе — төрекләр алфавитына таянып эшләнгән вариант, икенчесе — кайчандыр үзебез кулланган яңалиф варианты. Аермалары шактый зур: һәр ике варианттагы 34 хәрефнең сигезе бер-берсенә туры килми. Яңалифтәге телебезгә иң кулай хәрефләр беренче вариантка кертелмәгән, алар урынына төрекләрдәге хәрефләр алынган...

...Мин үзем башта ук яңалифкә кайту ягында идем. Ул телебезнең табигатенә якын, яраклы итеп төзелгән иде. Аны өйрәнү, үзләштерү дә җиңел булган иде — халкыбыз аңа тиз ияләште. Инде тәкъдим ителгән ике вариантны игътибар белән чагыштырып караганнан соң да, башта әйтелгән фикерне кабатларга туры килә: **яңалифкә кайту телебезнең киләчәге өчен дөресрәк булачак**. Билгеле, кирәксә, кайбер төзәтүләр кертеп...

...Беренче вариантны төзүчеләр һәм яклаучылар, сүз дә юк, бик көчле кешеләр, шул ук вакытта хакимияткә дә якын торучылар... Алар белән бәхәскә керергә, бәлки, җөрьәт тә итмәс идем, ләкин алар хәреф алыштыруга сәяси мәгънә бирделәр... Шуңа күрә генә үз сүземне әйтеп каласым килде.

...Без өченче тапкыр алфавит алыштырырга мәҗбүрбез. Әлбәттә, бик җитди сәяси акт бу... Үткәндәге ике мәртәбә алыштыру да телебез язмышына, тел аша халкыбыз язмышына бик тирән, бик авыр йогынты ясады. Күп кенә корбаннар да алды ул... Бу юлы инде без саграк булырга тиеш түгелбезме?! Сәясәтнең бик мөһим икенче бер ягын да онытмаска кирәктер. Һәрбер халык үзенең туган телен саклый яки безнең кебек сакларга тырыша. Фарыз эш... Халыкларның төрле булуы, төрле телләрдә сөйләшүе табигый күренеш... Дөнья шулай яратылган, шулай гына яши дә ул... Тел аермасы, тел мөстәкыйльлеге халыклар арасында эшлекле мөнәсәбәт урнаштырырга, ә милли вә рухи якын халыкларга үзара тугандаш мөнәсәбәт сакларга да комачаулык итми һәм итмәскә дә тиеш.

Ә алфавит сайлау безнең эчке эшебез. Бәхәс чыккан икән, аны ахыр чиктә референдум үткәреп тә хәл итү мөмкин булыр иде. Ул чагында ана телебезгә битараф булмаган һәр кеше «сайлау»га катнаша да алыр иде.

Өченче тапкыр ялгышырга безнең хакыбыз юк — шуны исебездән чыгармыйк!

*«Шәһри Казан», 1998*

## ГӨМБӘГӘ БАРУ

...Сентябрь ахырлары иде бугай — көннәр тын, талгын, җәйгечә җылы гына... Әбиләр чуагы, диләр мондый көннәрне... Менә шундый беркөнне миндә кинәт кенә кая да булса барып йөреп кайту теләге туды. Иртәнге чәйдән соң бераз эшләп тә утырган идем, ләкин вакыт җитәрлек иде әле... Тик кая барырга — билгеле инде, урманга! Көзге урманның үзенә генә хас хозурлыгы була бит, күреп калырга кирәк. Аннары гөмбә вакыты — аны эзләү дә бик күңелле. Акларын тапсаң — хәзинә тапкандай буласың...

Ләкин ялгыз баруның кызыгы аз — кемне чакырырга? Тоттым да Фатихка (Хөснигә) чылтыраттым.

— Фатих, сәлам!.. Көн бик әйбәт, әйдә, якын-тирәдәге берәр урманга барып йөреп кайтыйк әле, булмаса!

— Һе...— дип куйды Фатих.— Кая, парккамы?

— Парк урманмыни... Ераккарак, чын урманга!

— Шулай да кайсы тарафларга?..

— Ну, Биектауга табарак...

Фатих кыска гына көлеп куйды да:

— Тиле! — диде.— Көн үтеп бара ич инде...

— Борчылма! — дидем, сүзен бүлеп.— Вакыт җитәрлек әле. Безне минем кияү машинада илтеп ташлар.

...Шуннан соң телефон трубкасы шактый тынып торды.

— Йә, ник дәшмисең? — дидем ахырда.

— Сагыз булдың син дә... Мәрфуга бикәдән рөхсәт сорадым...

— Соң?..

— Фатихасын бирде. Тик синең белән миңа гына ышанып бетми... Тагын бер тәүфыйклы кеше дә кирәк. Кемне ияртәбез?..

— Кемне, кемне? — дидем, әз генә уйланып.— Хәсән абзый белән сөйләшеп кара. Ул урманда йөрергә ярата бугай...

— Дөрес. Чын тәүфыйк иясе... сөйләшермен. Кайда очрашырбыз?

— Капка төбегезгә чыгып торыгыз, шуннан алып китәрмен, тик, зинһар, озак юанмагыз! — дидем, сүзне бетереп... Гөмбә турында хәзергә әйтеп тормадым. Йә тагын киреләнә башлар — Фатихныкын белмәссең... Ә машина турында әйтүем дөрес. Кодаларның «Москвич»ы бар, безнең ишегалдында ук тора... Фатихка чылтыратканчы ук мин инде кияү белән сөйләшеп куйган идем.

Тиз генә әзерләнә башладым. Урманга бару — нәш-

риятка бару түгел. Шуңа күрә искерәк чалбар белән кирза итегемне, өстемә кыска курткамны кидем. Карчык әзерләгән ризыкны, термос белән чәйне җыйнак кына түгәрәк кәрзингә салып, пәке белән таягымны да онытмыйча, чыгып утырдым. Кияү инде капканы ачып, машинасында көтеп утыра иде... Кузгалдык — киттек. Сәгатемә карадым — бер тулып килә икән шул... Зарар юк, икегә барып җитсәк, караңгы төшкәнче йөрергә 4—5 сәгать вакытыбыз бар әле.

...Маяковский урамына барып та җиттек. Тегеләр капка төбендә күренмиләр бит әле... Хәер, озак көттермәделәр — әнә ике шөһрәт иясе, кулларын кесәләренә тыгып, ашыкмыйча гына чыгып та киләләр... Гулятькә чыккандай, икесе дә костюм өстеннән плащ кигәннәр, галстукларын да такканнар, башларында — берсендә кепка, икенчесендә эшләпә... (Хәсән абзый бервакытта да эшләпә, Фатих исә кепка кимәде.)

Болар машинага кереп утыргач кына, мин борылып үзләренә әйттем:

— Гөмбәгә шулай киенеп баралармыни?..

— Тукта, тукта,— диде Фатих, шунда ук кабаланып,— нинди гөмбә ул тагын?..

— Соң, бу вакытта ерак урманга ни өчен баралар... Нәкъ сезоны бит...

— Юк инде, бигайбә!.. Гөмбәне син үзең җыярсың, ә без күзге урманда бер хозурланып йөрер өчен барабыз...

Ләкин Хәсән абзыйны гөмбә куркытмады. Киресенчә:

— Җыябыз — ник җыймаска! — диде ул җанланып.— Әмирханның кәрзинкәсен тутырырга кирәк ләсә!

— Сабый! — дип куйды Фатих.— Син, Хәсән абзый, Әмирханнан элек үзеңне кайгырт... Урманда бит кырын ятып, бераз капкалап та алырга кирәк булыр... Ә как же!

— Минем термос белән чәем бар.

— Чәй белән кытай, беләсеңме, кулын гына юа... Ә безгә әйбәтләп тамакны юарга кирәк... Давай, берәр кибет алдында туктыйк әле.

— Мәйле!

Дербышки аша узганда, чаттагы гастрономга туктадык. Өчебез дә кердек... Нәрсә алырга?.. Сайлар нәрсә күп түгел. Шүрлектә тезелеп торган шешәләр арасында коньяк та бар икән — Фатихның күзе иң элек шуңа төште.

— Әнә шул биш йолдызлыны алыйм әле мин, каян килеп, кая китмәгән безнеке,— диде ул, үзалдына гына сөйләнгән булып.— Калганын үзегез карарсыз.

Калганын миңа карарга туры килде. Бер генә төрле колбаса ята, төргән сыр, янә балык консервалары бар...

Шуларның һәркайсын кирәк кадәр алырга булдык, ә икмәк миндә җитәрлек иде.

— Консерва нигә, ничек ачабыз аны? — диде Фатих.

— Пәкенең үткере бар миндә,— диде Хәсән абзый.

Фатих кинәт кеткелдәп көләргә тотынды:

— Мөселман пәкесеме?

Мин дә көлдем, Хәсән абзый үзе дә кызара төшеп көлгән булды. Аның пәке турында сөйли торган бер анекдоты бар иде, шуны искә төшердек.

...Инде бүтән бер җирдә дә тукталмыйча туп-туры гына Биектауга элдерттек. Кызу гына бара торгач, тиздән аны да узып киттек. Тагын күпмедер барып, Рөстәм кияү безне Казанка буендагы урман кырыена илтеп төшерде... Машинадан чыккач бер сәгатькә, бер кояшка карадык. Өч тулып килә икән шул инде... Кияүне кайтарып җибәрдек — ул бүтән килмәячәк. Мин юлдашларыма «маршрутны» аңлаттым: урман эченнән без әкренләп кенә килгән якка таба барабыз, Биектау турысына җиткәч, станциягә чыгабыз. Вакыт әле җитәрлек, капкалап алырга да өлгерербез... «Ярый, синеңчә булсын» диделәр юлдашлар. ...Урман эченә тирәнрәк кереп кайтыр якка таба атладык. Артымнан сабыр гына иярүчеләргә мин, кулыгызга таяк алыгыз, куак асларын караштырып барыгыз, гөмбәнең шәбе шунда посып ята, дидем. Тыңладылар әйткәнне тагын. Хәер, беләм, гөмбәчеләр бу урманны аркылысына-буена сөреп чыкканар инде — юк монда гөмбә! Бөтен Казан гөмбәгә ташланды — чәчеп үстергәне дә җитмәячәк. Ләкин барыбер эзлисең, ялгыш кына яшеренеп калганы табылмасмы дип эзлисең! Гөмбә эзләү кешене беткәнче йота торган бер чир ул — хәтта әнә Фатих та таяк тоткан, эзләнеп бара...

Ә урман тын, буш, әкрен генә яфракларын коя... Нигәдер моңсу — боек ул — арыган, өшәнгән җан иясен хәтерләтә... Бик тапталган, бик чүпләнгән — ниләр генә аунап ятмый монда!.. Кадере юк бездә урманның...

...Шулай да каранып йөри торгач, мин каен төбеннән берничә гөмбә табып алдым (подберезник дип атала ул). Хәсән абзый да ашарга ярарлык өч-дүрт гөмбә табып китерде. Ә Фатих дус гөмбәне бөйтенләй танымый икән... Җыеп китергән гөмбәләре барысы да поганка иде.

— Син, иптәш, боларны кулың белән өзеп йөрмә! — дидем мин аңа.

— Аяк белән генә тибеп өзәм мин аларны! — диде ул эре генә.

Гөмбә эзләгәндә вакытның үтүе сизелми дә кала... Күтәрелеп карасак, кояш агач башларына кунган икән инде... Бу аның соңгы юмарт яктыртуы... Тагын әзрәк баргач, без иркен генә түгәрәк бер аланлыкка килеп чыктык...

— Туктыйк шушында,— диде Фатих.— Җитеп торыр морза артыннан ияреп йөрү... аякларга да ял кирәк.

Килештек. Аланлыкның тапталмаган чиста уртасында туктадык... Хәсән абзый көтелмәгәндә бездән сорады:

— Егетләр, мин сезгә учак ягып күрсәтимме?

Фатих шунда ук аның сүзен күтәреп алды.

— Давай, Хәсән абый, давай, күрсәт осталыгыңны!

— Алайса, коры-сары җыеп китерегез... Бераз юанрак ботак та...

...Без коры-сарыны тиз генә җыеп, бер юан ботакны да сөйрәп китердек. Хәсән абзый тезләнеп эшкә дә кереште... Җыйнак кына итеп коры-сарыны аркылы-торкылы салды, озын ботакның юан башы белән бастырып та куйды... Бисмилласын әйтеп, кабызып җибәрүенә, учак дәртле генә янып та китте. Безнең дә кәефләр күтәрелеп китте... Тик Хәсән абзый гына учагына карап, уйланып калган иде. Ихтимал, ул Себердә көтү көткәндә кабызган учакларын исенә төшергәндер... Әйтергә кирәк, төрмәдә һәм сөргендә күргәннәрен ул сөйләргә яратмый иде. Минем үземә аңардан ишетергә туры килмәде.

Ярый, учак күңелле генә яна торсын, ә без аның тирәсенә кырын ятып, үз эшебезгә керешик әле булмаса... Кәрзиннән азык-төлекне чыгарып, җәйгән гәзиткә тездек. Әйбәт кенә табын булды... Шешәне дә ачтык... Фатих белән минем «салуның» тәмен яхшы белгән чагыбыз, ә Хәсән абзый, билгеле, сакланып кына эчә, ләкин үзе әйтмешли, «арыслан тотарлык» кына төшерергә ярата... Үзем китергән сырлы стаканга яртылаш кына салып, мин иң элек аңа суздым.

— Тот әле, Хәсән абзый!

Ул бераз уңайсызланыбрак калды.

— Нигә миннән?..

— Яшькә карап, иң элек сезгә, аннары Фатихка...

— Йә, йә, Хәсән абый, көттермә, безгә үрнәк күрсәт! — диде Фатих та.

— Кем хөрмәтенә соң? — диде Хәсән абзый, стаканны кулына алып.

— Бөек партиябез хөрмәтенә! — диде Фатих, бик җитди итеп, үзе шунда ук кеткелди дә башлады.

Аңа ияреп без дә ирексездән көлеп җибәрдек. Күреп торам, Хәсән абзыйның җитди буласы килә, ләкин көлү-

еннән тыела алмый гына... «Ну, Фатих, телеңә шайтан төкергән!» дип тә куйды, аннары тынычлангач:

— Иң әйбәте — исәнлеккә-саулыкка! — диде дә стаканын күтәрде, төбенә төшмичә генә...

Шулай башланып китте безнең бу бик хозур мәҗлесебез. Монда, дөрләп янган учак яктысында, ашау да, эчү дә, рәхәтләнеп көлү дә җан теләп торган зарури гамәл иде. (Саваплы дисәм дә артык булмас...) Без бит бер Алла бәндәләре, бер-беребезне бик күптәннән беләбез, дөньябыз бер, эшебез бер, димәк, рухи якынлык та бар — өчебез — өч төрле булсак та... Шуңа күрә дә без менә хәзер тормыш ваклыкларыннан тәмам азат булып, чын күңел хөрлеге тоеп, телебезгә ни килсә, шуны сөйләп, көзге тын урманда кырын ятабыз түгелме соң?!

...Бертын әйбәт кенә капкалап алдык. Телләр дә тик тормады... Учагыбызга да коры-сарыны Хәсән абзый һаман өстәп торды... Фатих нәүбәттәгесен әзрәк йоткач, аңардан сорап куйды:

— Хәсән абый, яшермичә генә әйт әле, сине Себер марҗалары бик яратканнар, имеш... Дөресме?

Җавапны Хәсән абзый, әз генә тынып торганнан соң, башкачарак итеп бирде:

— Беләсезме, мәрхәмәтле кешеләрне мин төрмәдә һәм сөргендә күбрәк очраттым.

Ләкин шәрехләп тормады. Хәер, болай да бик аңлашыла. Сүз бит үзе кебек төрмәдә утыручы зыялы кешеләр турында бара. Андыйлар арасында бер-берсенең хәлен аңлаучы мәрхәмәтлеләре дә аз булмагандыр... Ә сөргендә авыл сыерларын көткәндә, гади халык аңа, һичшиксез, җылы карагандыр... Йомшак күңелле марҗалар, бәлки, җәлләп тә... Хәсән абзый бит ул бөтен килеш-килбәте белән бик ягымлы кеше. Әмма аның уекүңеле бары туган якларына тартылган... «Агыла да болыт агыла» сөргендә язылган шигырь... Һәр сүзендә бәгырьләргә төшәрлек тирән сагыш!.. Әмма иң гаҗәбе — шагыйрьнең ачы, фаҗигале язмышыннан туган шигырьләрен кайберәүләр оялмыйча «төрмә лирикасы» дип атадылар. (Шундый гаепне аңа союзның идарә утырышында такканнар иде.) Әгәр шагыйрь шул фаҗигале язмышын йөрәк каны белән язмаса, ул Туфан да булмас иде.

Мин аңа сак кына әйттем:

— Хәсән абзый, «төрмә лирикасы»ннан берәр шигыреңне укып та күрсәтсәң иде.

Ул чал башын игән килеш, янган утка карап күпмедер тынып торды да моңарчы мин ишетмәгән шигырен,

кемнәргәдер мөрәҗәгать иткәндәй, әкрен генә укый башлады. Без шылт та итмичә тыңлап тордык.

Азмыни ишләр? Тик алар
Гамьсез дә җансыз.
Көннәрем ил белән дә бит,
Төннәрем ялгыз.

Кайда сез, безнеерактан
Таный алганнар,—
Без офыкка күмелгәнче
Озатып калганнар?
Кайда сез?

Адашсам язмышта әгәр
Давыллы төндә,
Кемне соң, кемне дәшим мин?
Эндәшим кемгә?

Урлады юлдашны язмыш,
Талады, каһәр!
Сердәшем — китап та дәфтәр
Таңнарга кадәр...

Тырнагын, тутык тырнагын
Иңемнән алды.
Ярасы ләкин озакка
Үзәктә калды.

Кайда сез
Безне юлларда
Таный белгәннәр?
Яраларны бәйләгәннәр,
Сулар биргәннәр
Кайда сез?

Давылга әгәр юлыксам
Болытлы төндә,
Эндәшим фонарь сорап мин
Кемгә соң?
Кемгә?

Бусы инде кайткач язылган шигырь... Без шактый телгә килә алмыйча тордык. Шигырь үзе дә, Хәсән абзыйның укуы да бик тирән үтте безгә... Ахырда Фатих, дулкынлануыннан калкына биреп:

— Гамьсез-җансызлар гына түгел, без дә бар бит әле, черт возьми! — диде.— Без башка, Хәсән абый, үзең дә сизә торгансыңдыр... («Абый» килешкәндәй елмаеп кына башын кагып куйды.)

— Ягез, бер күтәрик әле чын талант, чын шигырь өчен!.. һәм... минем өчен дә! — Әмирхан өчен дә! — дип кыстырды Хәсән абзый...

— Ягез алайса Фатих Әмирхан өчен! — диде Фатих, миңа хәйләкәр генә күз кысып.

Ихластан көлештек тә, чиратлашып күтәрдек соңгысын... Бушаган стаканга мин термостан чәй салып, Хәсән абзыйга бирдем — шигырен сөйләгәч тә ул чәй сораган иде.

...Сүз, әлбәттә, күп булды, кыю фикерләр дә әйтелде, кайбер кадерле кешеләрне дә искә төшердек... Такташ турында сүз чыккач, Хәсән абзый аның нинди чирдән үлүен сөйләде. Без моңарчы тифтан дип йөри идек — шулай хәтердә калган. Юк, тифтан түгел, менингиттән икән... Алар, ике дус шагыйрь, ноябрьнең каты суык бер көнендә, Болак буендагы мунчага барганнар. Такташ, гадәтенчә, яланбаш... Мунчадан чыккач әле алар бер киоск алдына туктап сыра да эчкәннәр... Күрәсең, шул көнне Такташның кибеп җитмәгән юеш башына салкын тигән булган. Икенче көнне үк инде аның хәле бик авырая. Зур докторларны чакыралар. Башта алар тиф дип уйлылар. Ә Һади ут эчендә ята, башын кая куярга белми. Салкын тиюдән менингит башлана, һәм шул яман чир аны алып та китә.

Сүзнең ахырында Хәсән абзый Такташка багышланган шигыреннән бер өзеген исенә төшерде:

Нидер яна аның йөрәгендә,
Нидер кайный аның җанында!
Ничек аны
Ялгыз калдырыйм да
Ташлап китим шундый чагында?!

Әйе, фаҗигале язмышлар күп безнең тарихыбызда... Мәгәр бик иркен сөйләшү белән мавыгып без вакыт чамасын бөтенләй онытып җибәргәнбез. Кайчан кояш баеп, кай арада төн булганын да сизмәгәнбез. Учагыбыз янып беткәч, дөм караңгылык эчендә калдык... Һичнәрсәне күреп тә, шәйләп тә булырлык түгел. Кайсы якка китәргә белмичә аланлык уртасында басып торабыз. Безгә бит Биектауга чыгарга кирәк, шуның станциясенә... Кайда ул Биектау — дөм караңгыда түгел, көпә-көндез дә урманнан туры гына чыгуы читен... Бердәнбер чара — поезд тавышын ишетү... Шул тавышка карап кына кузгалырга мөмкин. Менә берәр поездның Биектауга шаулап килгәнен яки кычкыртканын көтеп торабыз да торабыз... Эшләр шәптән түгел — кайчан кычкырта ул, җен орган поезд?!

— Болай булмый бит, егетләр! — диде Фатих түземсезләнеп.— Беренче әтәчләр кычкырганын көтергәме әллә... Кайсы якта синең ул Биектауың?..

— Сул тарафта булырга тиеш...

— Киттек сул тарафка... Кая да булса барып чыгарбыз.

— Берәр юлны, сукмакны табасы иде,— ди Хәсән абзый,— юл алып чыга кирәк җиргә.

...Без кузгалгач кына, шаулап килгән поезд тавышы да ишетелде. Ерак та түгел кебек... Арча ягыннан килә бугай...

— Әнә ишеттегезме?..

— Ишеттек, ишеттек, давай атлавыңны бел! — ди Фатих, мине ашыктырып.

...Күзләр инде караңгылыкка бераз ияләшкән иде.

Агачларны аерып була... Миңа, ияртеп китерүче буларак, алдан барырга кирәк. Куак-чытырман арасына кермәскә тырышып, сак кына атлыйм. Ә каты юлны яки сукмакны аяк белән капшап эзләргә туры килә. Тик ничек тә юнәлешне югалтмаска кирәк. Төнге урманда мөмкинме бу?.. Шулай да капшанып атлый торгач, аяклар каты җиргә басты... Юлмы бу?.. Юл икән шул, рәхмәт төшкере!.. Инде киттек сул тарафка кыю гына!.. Ә бер егерме минуттан Биектауның үзенә дә килеп чыктык. Урман аңа терәлеп кенә түгел, эченә үк кереп тора. Билгеле, сүз тимер юл буендагы поселок турында бара... Станциянең кайдарак икәнен якты утларыннан чамалап, туры шунда киттек. Вакыт шактый соң булса кирәк — ашыгабыз. Бераздан вокзал бинасына барып кердек. Уртача зурлыктагы буш бүлмә — шуның уртасында ике кеше сөйләшеп тора. Поезд мәсьәләсен белергә кирәк. Касса тәрәзәсенә сугылдык — ябык, ике яктагы ике ишеккә төртелдек — бикле!.. Дежурные кайда утыра соң моның?.. Ләкин Фатих башта теге сөйләшеп торучыларга мөрәҗәгать итте:

— Сез белмисезме, Казанга электричка кайчанрак булыр икән?

Тегеләрнең озын буйлы яшьрәге җавап бирде:

— Казанга бүген поезд юк инде, абый!..

— Нишләп алай, Арчадан килергә тиештер бит әле?

— Китеп беттеләр шул, соңгысын яңарак үзем озаттым.

— Вәт сиңа мә!.. Ишеттегезме, әфәнделәр? — диде Фатих, безгә борылып. Без ни әйтергә белмичә, җилкәләрне генә җыердык. Фатих миңа текәлде:

— Син, гөмбәче, расписание белергә тиеш идең бит!

— Сәгатькә карарга онытканбыз! — дип акланган булдым.

Фатих янә озын егеткә дәште:

— Соң, пассажир поездлары... алар да шушы юлдан үтә торгандыр бит?!

— Үтәләр, ләкин туктамыйлар...
— Берсе дәме?
— Берсе дә!
— Нәләт икән... Ә Арчаныкы кайчан булачак?
— Иртәнге алтыда!
Сәгатьләребезгә карадык — ун тулып киткән...
— Тәмле булсын йокыгыз! — диде Фатих безгә,— сигез сәгать шушында аунарга туры киләчәк. Бер эскәмия дә юк бит, йә, ни дисез?
Хәсән абзый бер дә исе китмичә:
— Идәне чиста, үзе такта, төн үткәреп була монда,— диде.
— Их, Хәсән абый! — диде Фатих ачынып.— Өйрәнгән инде синең газиз башкайларың түшәк-мендәрсез йокларга... Юк, миннән булмый, миңа Мәрфуганың ястыгы кирәк. (Хәсән абзый башын селкә-селкә көлә генә.) Әллә машина юлына чыгып карыйбызмы?.. Кайтмый калсам, Сафура бураннары кубачак бит, беләсезме сез шуны?!
Ә бездән күзен алмыйча карап торган егет ахырда кыюланып сорады:
— Сез кемнәр буласыз соң?!
Фатих аңа сынаулы гына карап алды:
— Чынлап сорыйсыңмы, туган?.. Чынлап сорасаң, рәхим итеп таныштырам: менә бу дәү абыең Хәсән Туфан булыр, ишеткәнең бармы?
Егет, телсез калгандай, авызын гына ачты.
— ...Ә бусы гөмбәче — әдип Әмирхан Еники әфәнде! Ә мин инде шушы ике тилегә ияреп йөрүче...— Фатих Хөсни җәнаплары! — дип өстәдем мин.
Шуннан соң егетебез әллә нишләде. Бер кызарды, бер елмайды, тынычлыгын җуйгандай таптанып та алды... Ахырда катгый рәвештә:
— Алайса, киттек безгә! — диде.
Инде без ни әйтергә белмичә бер-беребезгә караштык. Шик юк, егет чын ихластан чакыра иде. Ләкин без бит аңа җиде ят — ансат кына ияреп китү ярыймы, килешәме соң?!
— Рәхмәт инде, туган! — диде Фатих аңа.— Хатының бардыр ич, төн уртасында өч мужикны ияртеп кайтуыңа ул ни әйтер?
— Бер дә борчылма, Фатих абый! — диде егет ашыгып,— хатын да бер сүз дә әйтмәс, мин белеп чакырам, валлаһи менә!
Фатих янә безгә карады:
— Йә, нишлибез, союз әгъзалары?.. Әллә егетнең ихлас чакыруын кабул итәбезме?

Хәсән абзый бер сүз дә әйтмәде. Мин дә икеләнеп калдым: кешегә мәшәкать ясавы уңайсыз, йокысыз төн үткәрүе дә читен булачак — нишләргә?.. Мәсьәләне Фатих үзе хәл итте:

— Ярый, туган, килештек, әмма бер шарт белән: безнең өчен берәүне дә борчымаска — баш куярга урын булса, безгә шул җиткән.

— Урын җитәрлек, яңа гына апаны Казанга озаттым,— диде егет, мәсьәләгә ачыклык кертеп.

Шулай итеп, без аңа ияреп киттек... Поселок йоклый иде инде. Читтәге тып-тын урамга җитеп, бер агач йортның капка төбендә тукталдык. Урамга караган өч тәрәзәсендә дә ут яна иде әле...

Егет капканың кечесен ачып:

— Әйдәгез, әйдә! — диде, нигә тукталдыгыз дигән шикелле...

Кердек, егет ишегалдына караган тәрәзәгә чиртте, өй ишегенә килдек... Аз гына көттереп ишек ачылды. Озын күлмәк кигән, яланбаш яшь хатын куркып киткәндәй артка чигенеп куйды.

— Әстә! — диде әкрен генә.

— Менә кунак урынына кунаклар сиңа! — диде егет шаулап, куанычлы хәбәр җиткергәндәй.

Яшь хатын чигенә-чигенә ачык ишектән кереп китте... Без дә егет артыннан башларны иеп кенә өйгә уздык... Керү белән хуҗабыз безне телсез калган хатынына берәмләп күрсәтә дә башлады:

— Менә бу дәү абый Хәсән Туфан, бусы Фатих абый Хөсни, бусы...— егет әз генә тотлыгып калды. (Миңа чират җитте исә нигәдер гел шулай була.)

— Әмирхан абый!.. («Еники» дигәнен Фатих өстәде.)

— Әйе, әйе, Әмирхан абый Еники,— дип шаулый бирде егет,— беләсеңме, кемнәр алар?

— Белмәгән кая инде, белмәгән кая! — диде яшь хатын, ниһаять, исенә килеп һәм яктыра башлап.

Шулай итеп без, өч шөһрәт иясе, һич көтелмәгәндә, һич белмәгән кешеләрнең төнге мөхтәрәм кунаклары булдык. Исемнәрен дә бераздан гына сорап белдек: егет — Наил, яшь хатын — Зәйтүнә икән... Билгеле, без һәртөрле сыйдан баш тарттык. (Югыйсә Зәйтүнә тиз генә самоварга да тотынган иде.) Безнең өчен иң кадерле сый — таңга хәтле баш куеп тору, дидек.

— Ник ашыгасыз? — дип сузды яшь ханым,— әйбәтләп йоклагыз... бездә тыныч, бала-чага юк...

— Рәхмәт инде, бик мәшәкатьләдек сезне...

— Берни түгел, берни түгел...

Сизгәнсездер, баштан ук инициатива Фатихка күчте, сөйләшүне дә гел ул алып бара. Мин ничектер югалыбрак калдым. Хәсән абый да сүзсез, тын гына тора — бу тамашаны уйчан гына читтән күзәтә иде.

Хуҗалар безгә «баш куяр» өчен урынны да бик әйбәт әзерләделәр. Хәсән абзыйны түр баштагы сиртмәле йомшак караватка яткыздылар, ә Фатих белән икебезгә кече яктагы киң генә агач караватка урын җәеп бирделәр. Баш астында ике зур мендәр, өстә сырган юрган — рәхәтләнеп йоклыйсы гына!.. Үзләре өй алдындагы чоланга күчтеләр. Татарның борыннан килгән күркәм гадәте инде бу — һәр җире чиста, һәркемгә урын җитәрлек.

Тәмле йокының очкан коштай үтеп киткәнен сизми дә калдык. Хәсән абзый безне төртеп уятты. Фатих сукранып алды:

— Йокы сиңа бер дә кадерле түгелмени?

— Аның кадерен мин белгән кадәр кайсыгыз белә икән,— диде Хәсән абзый.

Урыннарыннан торып яшь хуҗа үзе дә, артыннан хатыны да чыкты... Безнең киенеп беткәнне күреп гаҗәпләнә калдылар: нигә ашыгасыз, чәй эчеп китәрсез, беренче поездга булмаса, икенчесенә өлгерерсез дип кыстый башладылар. Ләкин без җылы урыннары өчен каткат рәхмәтебезне әйтеп, чыгып китәргә ашыктык... Беренче Арча поездына да өлгердек...

...Хуш, кемнәр булды соң ул безне төн уртасында ияртеп кайткан яшь егет һәм йомшак урыннар җәеп биргән яшь кенә хатыны?.. Әлбәттә, алар урта татар мәктәбен бетергән, шуңа күрә безне ишетеп тә, күпмедер укып та белгән чын саф татар яшьләре иде... Һәм аларның үзләре өчен дә тере язучыларны күрү, җитмәсә, өйләрендә кундырып чыгару исләренә төшереп сөйләрлек онытылмас бер вакыйга булгандыр, билгеле... Безнең өчен дә гөмбәгә баруның иң зур куанычы — әнә шундый саф татар җанлы яшьләрне очратуыбыз булды.

* * *

Бу әдәбиләштерелгән истәлек. Ягъни хыялда туган бизәкләр белән баетып, кешеләрне җанлы итәргә тырышып, беркадәр арттырып — күпертеп тә — кыскасы, хикәя язгандай тәфсилләп язу... Истәлекләрне болай язу бик таралган әдәби алым... Бездә дә аның үрнәкләре җитәрлек. Мәсәлән, мәрхүм Мөхәммәт Мәһдинең «Ачы тәҗрибә»се чын мәгънәсендә әдәбиләштерелгән истәлекләрдән гыйбарәт. Мин дә менә беренче тәҗрибә рәвешендә

шулай язып карадым. Әмма төп вакыйгалар — Биектау урманына бару, гөмбә эзләп йөрү, учак ягып сөйләшеп утыру, поездга соңга калу, ниһаять, бер егетнең чакыруы буенча аңарда кунып чыгу — болар барсы да чын, булган вакыйгалар... Калганы — хикәячедән.

* * *

Инде шушы истәлеккә өстәп, бер уңайдан Хәсән абзый Туфан турында әйтәсем килгәнне язып бетерәсем килә. Хикмәт шунда, Туфан ул һәркемне уйландыра торган шәхес. Аңа битараф калу мөмкин түгел — фаҗигале язмышы гүя бездән «Кем соң син?» дип сорый кебек. Шушы сорау аның кешеләргә мөнәсәбәтен билгели дә булса кирәк.

Ни сәбәптер минем күңелгә кайчагында сәер генә уй килә торган иде: даһи шагыйрьләр каты бәгырьле булалар түгелме икән?! Бу шигемне мин бик танылган зур бер шагыйрьгә әйтеп тә карадым. Ул, бик тиз килешеп, «әйе, бөек шагыйрьләрнең андый яклары бар» диде. Ләкин нидән икәнлеген аңлатып тормады.

Шулай да нидән килә ул — каты бәгырьле булу?.. Артык таләпчән булуданмы?.. Үзләрен һәртөрле түбәнлектән, ваклыктан, бозыклыктан өстен санап, башкалардан да бары шуны таләп итүдәнме? (Ләкин кимчелексез кем генә бар икән бу дөньяда?!)

Хәсән абзыйның да кешеләргә таләбе каты иде. Әхлак ягыннан аныңча түбән яки бозык булганны ул күтәрә алмый. Нәфрәтләнә, читләшә, андый кешегә рәхимсез дә була ала иде. Аның шундый икәнен без шагыйрь Мәхмүт Хөсәенгә һәм язучы Хәсән Сарьянга карата булган мөнәсәбәтендә күрдек... Өчесе дә мәрхүмнәр, өчесе дә безнең күңелләрдә һәм әдәбиятыбызда лаеклы урыннарын алган шәхесләр — бәлки, аларның рухларына кагылмаска да кирәктер... Ләкин күптән мине уйландырган вә борчыган бер мәсьәлә булганга күрә, кагылмыйча да кала алмыйм.

...Ике шагыйрь — Хәсән Туфан һәм Мәхмүт Хөсәен... Кайсы яктан гына килеп карасаң да, алар бер-берсеннән бик ерак, бернинди охшашлык юк, мәгәр икесе дә шигърият дигән мөкатдәс эшкә хезмәт итәләр. Әмма ни өчен соң Хәсән абзый Мәхмүт Хөсәенне кеше итеп тә, шагыйрь итеп тә таныргa теләмәде?.. Бу — сер түгел, күпләр моны беләләр иде. Ләкин бит кешене танырга теләмәү, аңардан тәмам бизү өчен бик җитди бер төп сәбәп булырга тиештер, мөгаен... Менә шул төп сәбәп миңа ачылмаган бер табышмак булып калды да хәзергә кадәр...

...Хәсән Сарьянга карата Хәсән абзыйның тискәре карашы нәрсәдән икәнлеген күпләр беләдер. Моңа Сарьянның татар теле турында язган сатирик әсәре сәбәп булды. Ни өчендер Хәсән абзый шул әсәрне телебезне бетерергә юнәлдерелгән бер пасквиль дип кабул итте. Шуңа күрә ул, Сарьян турында бик начар фикергә килеп, аңардан йөз чөерде... Әмма кем генә белми Сарьянның туган телебез өчен Туфан шикелле үк җан атып торганын, телебезне бик тирәнтен белгәнен һәм аның сафлыгы өчен соңгы сулышына кадәр көрәшкәнен... Сатирик әсәре дә телебезне бозучыларга (опошлять итүчеләргә) каршы язылган... Хәсән абзый шуны ничектер ялгыш аңлап, авторына карата тискәре хөкемен чыгара да. Сарьян мәрхүм олы шагыйрьнең нахак хөкемен һәм үзенә булган начар карашын бик авыр кичерде, чынлап рәнҗегән чаклары да булды. Мин моны күреп һәм белеп әйтәм.

Әйе, даһиларның караш-мөнәсәбәте белән бик нык хисаплашырга туры килә. Яхшы карашлары сөендерә, начары — көендерә. Менә мин дә шул турыда уйланырга мәҗбүр идем.

Шагыйрь Хәсән Туфанны мин бик күптән — 1926—1927 еллардан ук беләм. Җыелышларда очрашып таныштык, сүз алышкан чакларыбыз да булды, ләкин якынлашу булмады. Яшь аермасы да шактый, дәрәҗәләр дә бер түгел. Ул инде татар әдәбияты күгендәге биш йолдызның берсе иде... Ә утызынчы елларның башыннан алып миңа инде аның белән очрашырга да, аралашырга да туры килмәде. Шуңа сүз дә Туфанның сөргеннән кайткач башланган еллары турында гына барырга мөмкин.

Ул үзенең 16 ел бушап торган урынына кайтты. Әдәбият дөньясы аны бик куанып каршы алды. Бик тиз ул язучылар арасына керде, элекке замандашларын очрату белән бергә, яңа дуслар да бик тиз табылды. Хәсән абзыйда кешене үзенә тарту куәсе бик көчле иде... Аның тирәсендә инде җыен тәүфыйклы кешеләрдән гыйбарәт аерым бер даирә дә хасил булды. Шул даирә аны үзенең канаты астына да алды. Моңа, ихтимал, аларның бер тирәдәрәк яшәүләре, җәйләрен «Аккош күле»ндә гел бергә булулары да ярдәм иткәндер... Мин үзем ул даирәгә керә алмадым, чөнки өем дә читтә, бакчам да читтә, үзем дә бер читтәрәк... Дөрес, Хәсән абзый белән очрашулар, сөйләшүләр, утырдаш булулар әледән-әле булгалап торды... Мөнәсәбәтебез дә дусларча гына кебек иде... Ләкин шулай да мин үземне Хәсән абзыйга якын кешеләрнең берсе идем дип әйтә алмыйм.

...Миңа калса, дусларча нормаль мөнәсәбәт нигезендә кешегә карата ныклы бер фикер-караш та ятарга тиеш... Үземнекен әйтеп тә тормыйм — бөек шагыйрьгә тирән хөрмәттән гыйбарәт ул!.. Ә менә Хәсән абзыйда минем турыда нинди фикер, әйбәт кенә мөнәсәбәте артында нәрсә — нинди караш ята?.. Мин моны сизәргә, чамаларга тиеш түгелмени?.. Бер уйлаганда, борчылырга сәбәп тә юк кебек... Элек тә, хәзер дә, беркайчан да минем Хәсән абзыйга бертөрле дә зыяным тимәде. Ул җәһәттән җан тыныч... Ә шулай да борчылам. Сүз бит һәр җәһәттән өстен олы шәхеснең фикер-карашы турында бара... Үзе ул бик таләпчән дә... Борчылуымның төп сәбәбе — гайбәттән курку. Мин яшеренеп яшәүчеләрдән түгел идем. Ә гайбәтне аны, гадәттә, үз гөнаһларын оста яшерә белүче көнчеләр тарата. Күләгәң шикелле артыңнан ияреп йөри ул гайбәт дигән мәлгунь!..

Әмма ләкин Хәсән абзый колагына минем хакта нинди генә сүз кермәсен, аның миңа карашы, асылда, начар булмаска тиеш дигән ышану бар иде миндә. Шуның кайбер дәлилләрен искә төшермәкче булам.

Алтмышынчы елның урталарында булса кирәк, Ташкенттан кайткан Шакир Мөхәммәдъяров белән сөйләшеп утырыр өчен Хәсән абзый мине дә үзенә чакырды. Бүтән бер кешене дә... Хикмәт шунда, Шакир Мөхәммәдъяров ул Гаяз Исхакый замандашы, фикердәше, аңа бик якын торган, бергә эшләгән, Гаязның «Ил» гәзитәсендә язышкан кеше... Бөтен кич буена мөхтәрәм карт исемен телгә алырга да куркыныч Исхакый турында безгә сөйләп утырды... Тукайның «Мөхәрриргә» дигән шигыре нәкъ менә Гаязга багышланган булуын да исбатлап аңлатты... Югыйсә ул шигырьнең кем турында икәнлеге Тукай томнарының берсендә дә моңарчы әйтелмичә килде.

Кыскасы, Гаязлар заманыннан калып, читтә кагылыпсугылып яшәргә мәҗбүр булган карт бер зыялы янына Хәсән абзыйның бары мине генә чакыруы — бу, әлбәттә, аның миңа ышану билгесе иде... Мин аны шулай кабул да иттем... («Мирас» журналында бу хакта язганым басылып та чыкты.)

Икенче дәлил. Хәсән абзыйга минем «Туган туфрак» һәм «Әйтелмәгән васыять» дигән хикәяләрем бик ошаган икән... Шулар һәм башка әсәрләрем беренче мәртәбә Тукай бүләгенә тәкъдим ителгәч, Хәсән абзый обком секретаре Табеев янына кереп минем бүләккә лаек язучы булуым турында сөйләшергә дә уйлап караган... Мәгәр ни сәбәптер керә алмаган. Моны миңа белгән кешеләр

әйттеләр... Шулай да анық Тукай комитеты утырышында минем әсәрләрне яклап сөйләве мәгълүм.

...Өченчесе. Җәйге озын көннәрнең бик җылы бер кичендә без өчәү — Хәсән абзый, Гомәр абзый вә мин ниндидер бер мәҗлестән чыгып, әкрен генә өйләребезгә кайтып барабыз. Маяковский чатына җиткәч туктадык. Белмим, әллә кызыклы сүзебез бетмәгән идеме, әллә җәйге төн бик хозур булганга күрәме, нидер җитмәгәндәй, урам чатында таралып китә алмыйча торабыз... Шул чакта мин бу ике абзыйга әйттем: әйдәгез миңа киттек, аулакта сөйләшеп утырырбыз, дидем... Һәм ни гаҗәп, абзыйлар җиңел генә риза да булдылар. Җәяүләп кенә минем шәһәр читендәге бакчалы өемә киттек. Төнлә дус-ишне ияртеп кайту гадәтемне өйдәгеләр беләләр иде инде. Беренче тапкыр гына түгел... Кайтып җитүгә абзыйлар беркемне дә борчымаска куштылар... Җәмәгатем Гөлсем минем ияртеп кайткан кунакларымны бик яхшы белә иде — шунда ук безгә чәй әзерләмәкче булды, ләкин абзыйларым: «Зинһар, мәшәкатьләнә күрмәгез, тиздән без китәбез»,— диделәр.

...Мин аларны үземнең эшләп утыра торган бүлмәмә алып кердем. Бакчага караган тәрәзәне дә ачып җибәрдем... Язу өстәле тирәсенә утырышып, әкрен генә сөйләшүне дәвам иттек... Нәрсә турында, нинди мәсьәләләр тирәсендә, кем нәрсә диде, ни сөйләде — хәзер инде бугазымнан алсагыз да, һичберсен хәтерли алмыйм. Билгеле инде, кирәкмәс сөйләшү булмагандыр, кешеләре бит юкны бушка аударып утыручылардан түгел. Сүзнең төрлесе — әһәмиятлесе дә, кызыклысы да булгандыр — мавыгып китеп, күпме вакыт узганын да сизмәдек... Кыска төн үтеп тә бара икән... Агарып кына таң да ата башлады. Шул чакта гына без өзелмәс-бетмәс сүздән туктадык. Әңгәмәдәшләрем китәргә ашыктылар. Мин аларны озата чыгып артларыннан карап калдым. Мөхтәрәм абзыйлар әле беркем дә күренмәгән буш урам буйлап, икәү генә үзләренә таба атладылар...

...Менә шундый сәер генә бер маҗара!.. Ничек моны аңларга?.. Ул абзыйлар төн уртасында теләсә кемгә барып утыра торган кешеләр түгел бит инде... Әле быел гына, Гомәр абзый белән очрашкач, шул вакыйганы искә төшердек. Онытмаган икән туксан биш яшьлек картым: әз генә елмая биреп, «ийе, бар иде шул безнең дә дуамал егет чаклар» дип куйды...

Соңгысы... Минем дә «түгәрәк даталарым» булып узды — шау-шусыз гына... Җитмеш тугызынчы елның мартында Актерлар йортында миңа 70 яшь тулу көнен бәйрәм иттек. Бәйрәм кичәсенә Хәсән абзый үзе килә

алмады — күрәсең, авырып торган чагы булгандыр. Ләкин шигъри котлавын Нәҗибә ханым аша җибәргән иде... Кичәне алып баручы Гөлсем ханым Исәнгулова аны залда утыручыларга укып та күрсәтте. Соңыннан минем үземә бирде. Машинкада басылган, яшел кара белән шагыйрьнең кулы куелган ике строфалы гына шигырь ул... Матбугатта чыкканы юк — үземдә саклана. Беренче тапкыр шуны биредә күчереп язарга җөрьәт итәм.

Башына: *Кадерлебез Әмирхан!* дип куелган.

Тик без генә түгел, энем,
Безнең белән бергә бүген
Котлый сине, Әмирхан:
— Ялалардан коткарылган
Һәм халыкка кайтарылган
Ибраһимов Галимҗан
Котлый сине, Әмирхан!
— Хәлләр ничек, Хәсән абый?
Сездәниләр бар? — дисең.
— Төннәр буе йокы бирми,
Тынгы бирми һич тә миңа
Синең «Туган туфрагың»да
Сурәтләнгән Санияң!
Сәлам белән: Х.Туфан. 16.03.1979

Бу котлау мине борчыган мәсьәләгә ачыклык кертә бугай. Башта бит мин Хәсән абзыйның кайберәүләргә карата каты бәгырьле булуын да әйткән идем. Менә шуның сәбәбен беләсем килә иде: нидән икән бу?.. Кайдан килгән аңа бу бөтен иҗатына һәм табигатенә ят сыйфат?.. Ә сәбәбен шагыйрь үзе үк әйтеп бирә түгелме соң?!

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте.
Кайсыгызның кулы җылы? —
Бәйлисе бар йөрәкне...

Ә йөрәктә тирән яра... Ялгыш кына кагылуны да күтәрә алмый ул. Җылы кулга бик мохтаҗ булып кайткан шагыйрь... Мәгәр моны киң мәгънәдә аңларга кирәктер, минемчә. Сүз яралы йөрәкне бәйләү турында гына түгел, тапталган иманны тергезү турында да барырга мөмкин бит... Шушы күзлектән караганда, ихтимал, минем кайбер хикәяләремнән дә тапкандыр Хәсән абзый үзенә кирәкле җылыны... Һәрхәлдә, аның туган көнемә онытмыйча шигъри котлау җибәрүе миңа зур сөенеч һәм тынычлану китерде... Гүя без сөйләшмичә генә аңлаштык. Болай аңлашуны — хисләр очрашуы дип атаган иде мәрхүм Сибгат Хәким.

*Май, 1997*
*«Казан утлары», 1997, 10 сан*

# ЧЕНӘКӘЙ КЕМ УЛ?

Төхфәт Ченәкәй — әдәбияттан сызылган шагыйрь. Аның хакында сез беркайдан, бернинди мәгълүмат тапмассыз. «Совет Татарстаны язучылары» дигән белешмә китабында юк ул... «Татар поэзиясе антологиясе»нең беренче басмасына да (1956), икенче басмасына да (1992) аның бер генә шигыре дә кертелмәгән. Гүя Ченәкәй дигән шагыйрь безнең әдәбиятта бөтенләй булмаган да... Әмма андый шагыйрь бар иде, исеме дә күпләргә билгеле иде. Без, өлкән буын язучылары, аны күреп тә, укып та белә идек. Мин үзем аның белән якыннан аралашкан кеше. Шулай да әйткәннәремне раслар өчен яңа гына чыга башлаган «Татар энциклопедик сүзлеге»н ачып карарга тәкъдим итәм: 230 нчы битендә «Ченәкәй Төхфәт (Гыйззәтуллин Төхфәтулла. 1893—1959) — шагыйрь» — дигән бик кыска гына сүзләрне укырсыз... Хәзергә бу Ченәкәй турында бердәнбер мәгълүмат — рәхмәт сүзлек төзүчеләргә — каяндыр табып кертүләре өчен...

Әмма Ченәкәйнең шагыйрь һәм кеше буларак озак еллар тәмам онытылып торуының сәбәпләре нәрсәдә?.. Ул бит революциягә кадәр үк, 1913—1914 еллардан башлап, «Шура»да, «Кармак»та, «Вакыт»та Сәмави һәм Һомаюн имзалары белән басылып килгән шагыйрь. Революциядән соң да яңа гәзитә-журналларда аның шигырьләре басылып чыккалый торды, күбрәк Ченәкәй имзасы белән... Асылда, ул Ырынбур шагыйре, күп китаплары шунда чыга, Казанда исә бик аз — 28 нче елны, Галимҗан Нигъмәтинең кереш сүзе белән «Карагайлы каен урманда» исемле юка гына бер җыентыгы чыгып калды. (Шагыйрь үзе язып биргән ул китап миндә саклана.) Дөресен генә әйткәндә, Ченәкәйнең совет шагыйре буларак дәрәҗәсе түбән иде. Кайчандыр Сәмави чагында (сәмави — күктән иңгән мәгънәсендә) дини-милли рухта язган кешенең хәзер тиз генә, бик тырышуына да карамастан, чын совет шагыйренә әйләнүенә безнең сәяси уяу әдәбият әһелләребез, билгеле, ышанмыйлар иде. Алай гына да түгел, ул бичараны һаман каккалый да суккалый тордылар, «чистка» (чистарту) аша да үткәрделәр[1], җитмәсә, «җидегәнчелек»тә гаепләп утыртып та чыгардылар.

Хәлбуки Ченәкәйне бик күпләр беләләр иде, күп кенә язучы иптәшләр аңа барып йөриләр иде — бүлмәсе-

---

[1] Күрдем мин ул «чистартуларны» — кешене төрлечә гаепләп, тагы да ныграк пычрату гына иде.— *Ә.Е.*

нең ишеге һәркемгә ачык иде... Ченәкәй ул, ничек дим, шактый талымсыз, теләсә кемгә ярый ала торган, йомшак мөгамәләле, үпкә-рәнҗүләрен дә яшерә белгән, йомышы төшкәннәргә ярдәмчел, эчми-тартмый торган ялгызак бер кеше иде.

Әмма язмыш аны әдәбиятыбызның фаҗигале рәвештә һәлак булган ике бөек шагыйрь белән кайчандыр дусларча якын итеп бәйли дә. Берсе аның — Шәехзадә Бабич, икенчесе — Муса Җәлил... Һәм алар белән якынлык соңыннан Ченәкәйнең үз язмышында да тирән эз калдыра.

Ченәкәй белән Бабич Ырынбурда очрашалар, һәм бик тиз дуслашып та китәләр. Дуслык нык булган булса кирәк. Миңа Бабичның Ченәкәйгә шигырь белән язган озын хатын да күрергә туры килгән иде. (Хат Ташкенттагы Сәхи Рәхмәти карт кулында саклана иде.) Әмма ике шагыйрь арасындагы дуслыкның тирәнлеге Бабич һәлак булганнан соң аеруча тулы булып ачыла. Шагыйрьнең күп җирләрдә чәчелеп калган әдәби мирасын Ченәкәй борынгы дәрвиш шикелле авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә йөри-йөри җыя. Шул рәвешчә ул Бабичка биргән вәгъдәсен үти. (Зәки Вәлиди хәрәкәтенә кушылган шагыйрь, үзе белән төрле хәл булу ихтималын алдан сизгәндәй, Ченәкәйнең вәгъдәсен алгандыр, күрәсең.)

1922 елны Казанда беренче мәртәбә чыккан Бабичның «Шигырьләр мәҗмугасы», асылда, Ченәкәй җыеп тапшырган әсәрләрдән төзелә. Галимҗан Ибраһимов җыентыкка язган зур күләмле кереш мәкаләсендә Ченәкәйнең изге эшен тәкъдирләп, аңа махсус тукталып уза.

Инде Муса Җәлилгә килсәк, монда эшләр башкача. Муса да фаҗигале корбан, ләкин Бабичныкыннан аермалы буларак, аның үлеме — исемен күкләргә күтәрде... Шул ук вакытта Мусаның күптәнге «шагыйрь дусты» Ченәкәйне әдәбияттан бөтенләй сызып ташлауга да китерде... Ни өчен?.. Кайберәүләр фикеренчә, бөек даны бөтен җиһанга таралган Муса Җәлил исемен яманаты чыккан нindидер Ченәкәй белән янәшә куярга ярамый, янәсе!..

Әйе, шулай, берсе гаять югары, икенчесе бик түбән, ләкин аларның тигез чаклары да бар иде — әйтик, егерменче елларның ахыры, утызынчы елларның башында. Икесе дә танылган шагыйрь, тик берсе инде зениттан узган, икенчесе якынлашып кына бара. Билгеле, шигърият мәйданын тотучылар түгел — мәйдан тотучылар Такташ, Туфаннар... Ләкин шулай да Мусаның зур бер өстенлеге бар: ул коммунист, төрле вакытта комсомол, пар-

тия органнарына сайланган, гәзитә вә журнал редакторы булып эшләгән кеше... Шушы ноктадан караганда, Ченәкәйне Муса белән янәшә куеп булмый билгеле... Әмма нәрсә бәйли, нәрсә якынайта соң бу бер-берсеннән шактый ерак кешеләрне?.. Яшь аралары да зур гына... Моны аңлар өчен аларның үткәненә борылып карарга кирәк.

Мәгълүм ки, алар икесе дә Ырынбур ягыннан — шунда туып, шунда үскәннәр. Очрашулары да Ырынбурда... 1914—1917 елларда 8 яшьлек Муса — «Хөсәения» шәкерте. Ә Төхфәт абыйсы шул мәдрәсәнең яшь хәлфәсе — тел-әдәбият укытучысы... Муса шигырь язу белән мавыга... Хәтеремдә, Ченәкәйнең Муса алдында көлебрәк әйткән сүзләре: бәләкәй Мусаны үземә алып кайтып, урындыкка бастырып, шигырьләрен яттан укыта идем...

Димәк, буйга кечкенә шәкертнең шигырьләрен иң беренче булып тыңлаган һәм шигырь язу турында аңа ниндидер киңәшләрен дә биргән кеше — Төхфәт Ченәкәй!.. Беренче хәлфәсе... Ә беренче хәлфәне кеше, соңыннан нинди генә биеклеккә күтәрелмәсен, бервакытта да онытмый... Муса өчен дә ул шулай — аралары өзелмәгән, дуслыклары дәвам иткән...

Ләкин дөнья үзгәрмичә тормый — бигрәк тә ул буталчык елларда... Капыл гына Октябрь инкыйлабы булып куя... Гражданнар сугышы башлана... Ченәкәй — Муса мөнәсәбәтләре өзелә, юллары да аерыла... Шагыйрь шәкертне революция дулкыннары үзенә суырып ала... Җиһанны тетрәткән вакыйгалар вакытында кеше йә бик тиз күтәрелә, йә кинәт түбән тәгәри. Яшь кенә Мусаның да инкыйлаб аркасында гаҗәп тиз күтәрелә башлавын күрәбез. Ул инде туган авылына кайтып комсомол ячейкасы да оештыра, кулына корал алып, «кулак бандаларын» тар-мар итүдә катнаша... Болар барсы да әлеге белешмә китабында язылган — әгәр дөрес булса. (Бу китапта ялган җитәрлек.)

Ә менә Төхфәт Ченәкәй турында бер мәгълүмат та юк. Гомумән, аның тәрҗемәи хәлен белмибез — бары туган һәм үлгән еллары гына мәгълүм...

...Ченәкәй егерменче елларның урталарында Уфадан Казанга күчеп килә. Менә шул вакыттан алып Муса — Ченәкәй бәйләнешенең икенче чоры башлана. Бу якын бәйләнеш бер дүрт-биш ел дәвам итте булса кирәк...

Һәм соңыннан Ченәкәйнең 40—50 ел буена онытылып торуына да сәбәпче була ул... якын бәйләнеш!..

...Ярый әле Муса Җәлилнең бик күптән үз кулы белән язган «Булачак иптәшемә хатлар» дигән истәлекләре былтыр гына «Мәдәни җомга»да басылып чыкты...

Әйтергә кирәк, бу тәүбә-истигъфар юкка гына язылмаган. Муса үзе турында төрле сүз-гайбәтләр булачагын һәм ул гайбәтләрнең иртәме-соңмы «булачак иптәшенә» (ягъни хатынына) килеп җитәчәген гүя алдан ук белгән... Шуңа күрә егет чагындагы «мәхәббәт маҗараларын», шуның белән бәйләнгән авыр кичерешләрен һәм тирән уйларын хатлар итеп язып куюны кирәк тә тапкан... Беренче хатында ул Ченәкәйне дә телгә ала:

«Минем Ченәкәй дигән бер шагыйрь дустым бар. Син минем белән тора башлагач, аның турында күп ишетерсең әле (ассызык минеке.— *Ә.Е.*). Ул минем гомеремдә һәм яхшы, һәм начар күп роль уйнаган кеше»,— дип яза Муса, күрәзәләрчә бөтенесен алдан күреп.

Шуны да истә тотыйк: Муса бу хатларын Әминә исемле кызны очратканчы һәм аңа өйләнгәнче язган... Әминә ханым аларны озак еллар үзендә саклаган, аннары тел-әдәбият институтына тапшырган... Ниһаять, хатлар 1997 елда гына мәрхүм Нил Юзиевның кереш сүзе белән «Мәдәни җомга»да басыла башлый. Бу инде үзенә күрә Ченәкәйне «реабилитировать итү» дигән сүз. Чөнки Муса үзе Ченәкәй дигән бер шагыйрь белән якын бәйләнештә булуын ачып бирә... Инде бу бәйләнешнең нидән гыйбарәт икәнен, «шагыйрь дустының» аның гомерендә «һәм яхшы, һәм начар роль» уйнаганын аңлар өчен әнә шул истәлек-хатларны бик игътибар белән укып чыгарга кирәк... Муса язганны шәрехләп торуның кирәге юк, ләкин шулай да минем кайбер аңлатмалар гына өстисем килә.

Хатлардан күренгәнчә, Муса 1929 ел башында, ягъни каникуллар вакытында, Ченәкәй чакыруы буенча Казанга кайта. (1925 елны Мәскәүгә киткәннән соң беренче кайтуы.) Ченәкәй ул вакытта хәзерге Киров урамындагы элеккеге «Сарай» номерының бер бүлмәсендә тора иде... Шушы кайтуыннан башлап, Муса һәр елны, кайчан гына кайтмасын, бары Ченәкәйдә туктала, аның янында тора торган булды. Мин үзем дә Муса белән Ченәкәйдә очрашып таныштым.

Бу вакытларда Ченәкәй утыз бишләр чамасындагы ялгыз буйдак, ә Муса егерме бишкә якынлашып барган чын егет иде. Билгеле, ике ялгызакның кайбер теләкләре туры да килгәндер, әйтик, хатын-кыз мәсьәләсендә... Әмма һәркайсының үз башы, үз акылы — икесе дә мәсьәләне үзләренчә хәл итүчеләр... Хатлардан күренә ки, рольләре дә ике төрле: Ченәкәй Мусаны кызлар белән таныштыра, аңа теге яки бу кызны димли, чөнки аның Мусаны өйләндерәсе килә... Ә Муса Ченәкәйнең актив-

лыгын бик үк өнәп бетермәсә дә, аңа ияреп, кызлар белән танышып йөри... Әйтергә кирәк, Ченәкәй таныштырган кызларның берсе дә тыйнаксыз кыз түгел иде. Мин аларның икесен — Мөбинә Габитова (соңыннан Таһирова) белән Мәрьям Гобәйдуллинаны яхшы ук беләдә идем. Уфаның сәүдәгәр кызлары, мөселманча гаилә тәрбиясе алган бик инсафлы туташлар (аеруча Мәрьяме). Икесе дә бик сылу, чибәрләр, мәгәр Мөбинә туташ үзенә башка чибәрлеге белән аерылып тора иде.

Мусаның истәлек-хатлары да менә шул Мөбинәгә булган тирән, онытылмас мәхәббәте турында. Ләкин бу мәхәббәт тарихын моннан күп кенә еллар элек миңа Мөбинә ханым үзе дә сөйләгән иде. Ул аны язган да булган, Казанга да китергән, ялгышмасам, заманында «Казан утлары»на биреп тә караган, ләкин аның язганнары дөньяга чыкмады. Сәбәбе ачык булса кирәк... Инде менә Муса кулы белән язылган хатлар, ниһаять, килеп чыкты. Мәхәббәт тарихын тасвирлаудан Мөбинә ханым язмасы белән Муса хатлары арасында шактый гына аерма булырга тиеш, минемчә. Аларны чагыштырып карау кызыклы булыр иде. Ләкин бармы икән ул язма, кайда, кемдә саклана икән?.. Гомумән, бер шөбһә минем җанымны борчып тора: Мөбинә ханым үзе исән-саумы икән, Муса хатларын укый алды микән?.. Рафаэль Мостафинга мин Мәскәүгә чылтыратып, шуны белергә кирәк дигән идем. Күпмедер вакыттан соң Рафаэль миңа «Мәскәүгә Мөбинә ханымга чылтыратып караган идем, телефонны алучы, җавап бирүче булмады»,— диде... Йә Хода, Муса хатлары аның дөньядан киткәнен көтте микәнни?!

Ә менә вакыйгаларның икенче героинясы Мәрьям Гобәйдуллина минем әйтүем буенча, Муса хатларын укып чыгарга өлгерде... Хәтта миңа чылтыратып, Мусаның аңа карата язганнары бик үк дөрес булмавын да әйтте. Мәрьям ханым — туксан яшен тутырып, 1998 елга кергәч кенә бу фани дөньядан китеп барды.

Авыр туфрагы җиңел булсын!..

Шактый тыгыз башланган Муса — Ченәкәй бәйләнеше, минем белүемчә, озакка сузылмады — күп булса, дүрт-биш ел дәвам иткәндер... Муса Казанга елдан-ел сирәгрәк кайта башлады, ә Ченәкәй 1934 елны микән, Казанны ташлап, Үзбәкстанга китеп барды... Бу ике дус шагыйрьнең бөтенләйгә аерылышулары иде.

Ченәкәй Мусаны өйләндерә алмаса да, үзе ул ялгыз буйдак булып калмый... Музыка техникумын бетергән бер кыз белән бергә китеп, бераз вакыт Ташкентта торып, шуннан Әндиҗанга барып урнашалар. Икесе дә укы-

тучы булып, гаилә корып, балалар үстереп (5 балалары була), шунда тыныч кына гомер сөрәләр.

...Шул китүеннән Ченәкәй, күп кенә еллар узса да, Казанга бер тапкыр да кайтмый... Дөрес... 1958 елны ул Уфага кайта, озак кына тора, Казанга да килмәкче була. Ләкин авырый башлап, туры өенә кайтып китә... Күрәсең, әҗәленә тигән сырхау булгандыр инде, 1959 елның кайсыдыр аенда ул дөньядан да китә... Бик күп татарларныкы шикелле үк аның да кабере чит-ят туфракта. Мәрхүмнең исән чагында кадере булмады, үлгәч каберен дә белмибез...

Шулай да безнең Язучылар союзы Ченәкәй шигырьләрен җыеп чыгарырга бер талпынып карады. Моны Союзның ул чактагы рәисе Ибраһим Гази кузгатты. Ченәкәй турында йөргән сүзләрне ул, әлбәттә, белә иде, ләкин үзенчә уйлаучы тәвәккәл кеше буларак, көннәрдән бер көнне мине чакырып алды да әйтте:

— Син Ченәкәйне яхшы беләсең шикелле... Менә шуның әйберләрен җыеп чыгарырга кирәк. Исемен белүчеләр күп, ә нинди шагыйрь икәнен белмибез... Үзе дә дөньяда юк, ләкин гаиләсе каядыр Үзбәкстанда бугай... Мин сиңа командировка бирәм, җыен да бар, эзләп тап, архивы белән таныш... Ни өчен килгәнеңне әйт, китабын чыгарабыз, диген...

— Ләкин Ченәкәйне чыгарып булырмы соң, аның исемен бит Муса белән бәйләргә ярамый...— дип әйтә башлаган идем, Ибраһим мине кырт кисте:

— Менә шуның өчен дә чыгарырга кирәк... Югыйсә монда Мусаны күптән белүчеләр бик күбәеп китте, ә Ченәкәйнең исемен дә атарга ярамый, имеш!.. В конце концов, ике шагыйрь арасында казыну безнең эшебез түгел, безгә Ченәкәйнең нинди шагыйрь икәнен белү кирәк.

Ибраһимның шул нәсыйхәтен тыңлаганнан соң, Союздан командировка алып, 1969 елның көзендә мин озын сәфәргә чыгып киттем. Башта Ташкентта тукталып, шуннан Әндиҗанга юл тоттым. Кулымдагы адрес буенча Ченәкәйнең гаиләсен дә тиз эзләп таптым. Мине әйбәт кабул иттеләр. Килүемнең максатын әйткәч, урта яшьләрдәге сөйкемле генә ханым Ченәкәйнең зур ашъяулыкка төрелгән кәгазьләрен алдыма китереп куйды... Тәртипсез буталып беткән шул кәгазьләрне мин озак кына утырып, бергәләп карап чыктым. Әмма игътибарга лаеклы бер генә кәгазь дә таба алмадым. Соңга калганмын — миңа хәтле инде кемнәрдер килеп, Муса турында материал эзләп, табылганын алып, калганнарын бутап бетереп киткәннәр.

...Калган кәгазьләр арасыннан шулай да бердәнбер кыйммәтле нәрсә табылды — ул Шакир Мөхәммәдъяровның Ченәкәйгә язган озын хаты иде. Менә шуны миңа алырга рөхсәт иттеләр. Соңыннан мин аны «Мирас» журналында бастырып та чыгардым.

...Ченәкәйнең тол калган җәмәгате белән шактый гына сөйләшеп тә утырдык. (Кызганыч, исемен язып куймагач, хәзер инде онытканмын.) Билгеле, мин аңардан ни өчен Ченәкәйнең үз китаплары юк, дип сорадым. Ханым, Ченәкәй Ташкентка китешли бер кечкенә сандык тулы китапларын, кульязмаларын Ырынбурдан ерак түгел авылда торучы якын туганына калдырып китте, диде... Бирегә килгәч, сирәк язган, китап чыгару мөмкин булмаган... Укытучы булып тыныч кына яшәгәннәр, Ченәкәй бик гаилә җанлы булган, балаларын бик яраткан... Исемнәрен дә гел үзе куйган. Мин ул исемнәрне язып та алганмын: Көндез, Алмагөл, Ялкын, Тату, Аяза (Аяз түгел). Бу балалар әтиләре турында ни беләләр икән дигән уй шул чакта җанны борчып күңелгә килмичә калмаган иде.

Әмма минем бу сәфәрем бөтенләй үк уңышсыз булмады. Ташкентка кайткач, мин бик кирәкле кешене — Ченәкәйнең якын кардәше Һибатулла абзый Таналинны очраттым (Ташкентка килгән чагы булган). Аннары шул ук Ташкентта бик күптән яшәүче Сәхи Рәхмәти карт та исән иде әле... Менә шулар ярдәме белән мин Ченәкәйнең шигырьләрен җыеп алдым. Һибатулла абзый иленә кайткач та, миңа гәзит-журналларда басылган шигырьләрен күчереп, үзендә сакланган аерым китапларын да җибәрде. Шулай итеп, Ченәкәйнең шактый күп нәрсәсе минем кулыма керде.

...Менә шулардан мин, берничә ай утырып, бик җентекләп-чүпләп, Ченәкәйнең тулы гына бер җыентыгын әзерләп нәшриятка тапшырдым. Җыентык безнең Союз тәкъдиме белән дөньяга чыгарга тиеш иде, әмма ни үкенеч, ул арада Ибраһим Гази үзе дә кинәт кенә үлеп китте. Җыентык, әлбәттә, чыкмады. Табу!.. Ишетүемә караганда, Ченәкәй җыентыгын чыгаруга Шәйхи Маннур бик нык каршы торган, имеш!.. Булыр да, бик принципиальный кеше. Ихтимал, ул Ченәкәйне шагыйрь дип танымый да торган булгандыр... Күпме йөрү, күпме мәшәкать шулай итеп юкка чыкты.

Хәзерге вакытта миндә өч кенә китабы саклана, аннары нәшриятка тапшырылган шигырьләрнең копиялары, бирелми калганнары, бигрәк тә Һибатулла абзый кулы белән төзелгән барлык шигырьләрнең исемлеге иске бер папкада сакланып ята... Шул кулда калганнардан

бик азын гына сайлап, журнал соравы буенча «Казан утлары»на бирергә булдым... Ченәкәйнең кем икәнлеген искә төшерер өчен генә...

Ченәкәй Октябрь инкыйлабы аркасында урталай сынган шагыйрь... Шагыйрь булып калыр өчен ул большевиклар заманына яраклашырга тырышып та күп язды. Аның кебек урталай сынып яраклашырга тырышучылар аз булмады. Мәсәлән, Сәгыйть Рәми, Сәгыйть Сүнчәләйләр хәтта партиягә дә керделәр, әмма шигырь язудан туктадылар... Соңыннан Рәмиев үлеп котылды, Сүнчәләйне аттылар...

Галимҗан Нигъмәти Ченәкәйнең «Карагайлы каен урманда» дигән китабына язган кереш сүзендә башта ук: «Ченәкәй революциягә килергә тырышып та килә алмаган шагыйрь»,— дип әйтә, һәм ул моны үзенчә исбатлый да... Менә шул күзлектән караганда, Ченәкәй иҗаты игътибарга лаеклы һәм өйрәнер өчен кызыклы.

Инде Муса белән Ченәкәйгә килсәк, монда һәммәсе бик ачык. Муса легендага әйләндерелгән шагыйрь. Аның белән бүтән бер генә шагыйрьне дә янәшә куеп булмый — хәтта бөекләрен дә... Безнең әдәбият Муса алдында бурычлы булып калмады. Аның хакында пьесалар, поэма-шигырьләр, роман, опера, кино, махсус китаплар, бихисап мәкаләләр язылды. Әмма моның өчен Ченәкәй исемен сызып ташлауның һич тә кирәге юк иде... Ченәкәй дә шагыйрь лабаса!.. Аның да әдәбиятта кечкенә генә булса да үз урыны бар, һәм шул урынына кайтырга хакы да бардыр ахыр чиктә!..

*Гыйнвар, 1998*
*«Казан утлары», 1998, 4 сан*

## САНАУЛЫ КӨННӘР

*Эссе*

Бу язманы шигырь белән башлыйсым килде. Бисмилла шикелле кыска гына булырга тиеш ул. Мин аны Дәрдемәндтән эзләдем — иң кыска, иң тирәнне аңардан гына табарга була... Һәркайсы үзенә бер фәлсәфи җәүһәргә тиң шигырьләре арасыннан, ниһаять, менә монысын күчереп алдым:

Җәй үтте...
Кар-яңгырлы көз урнашты,
Күк тугайның баурына боз урнашты.
Гөл кипте,
Сабагында кинә калды.
Былбыл!
Сиңа бер бөртек инә калды.

Шигырь унҗиденче елның кара көзендә, октябрь инкыйлабыннан соң язылган булырга тиеш. Большевиклар золымы белән килешә алмыйча язган тагын шуның ише берничә шигыре Дәрдемәнд үзе исән чакта дөньяга чыга алмаган. Исмәгыйль Рәминең искәрмәсенә караганда, ул шигырьләр 1923 елны гына Уфа журналы «Яңа юл»да беренче мәртәбә басылганнар.

Әнә шул кыска гына шигырь белән мин бүгенге үз хәлем арасында ниндидер аваздашлык барын сизгәндәй булдым. Минем дә сиксән сигезенче җәем үтеп китте... Минем өчен дә «кар-яңгырлы көз урнашты»... Әмма шигырьнең бөтен эчке мәгънәсе бу тышкы охшашлыкта гына түгел, ә «Гөл кипте, сабагында кинә калды» дигән сүзләрендә... Нәрсә ул «кинә»? Минем белүемчә, кинә сүзе кешенең телдән әйтә алмаган эчендәге авыр кичерешләрен яки ачу-нәфрәтен аңлата... Ялгышмыйм дип, «Татарча-урысча сүзлек»не ачып карадым: «Кинә тоту — таить злобу» диелгән анда... Әгәр шулай икән, бүгенге хәлләрдән (режимнан) тирән канәгатьсезлек, ачу-нәфрәт кемдә генә юк ул хәзер?! Әнә кайда икән ул Дәрдмәнднең моннан сиксән ел элек әйткән сүзләре белән безнең бүгенге хәлебез арасындагы уртаклык! Шигырьдәге шушы бер генә сүзнең тирән мәгънәсенә сокланмыйча мөмкин түгел. Ә «кинә»гә өстәлгән «Былбыл! Сиңа бер бөртек инә калды» дигән соңгы сүзләре ялгызлыкка дучар шагыйрьнең бөтен ачы язмышын ачып бирә түгелме соң?!

Әйе, кайчандыр сүзнең кодрәте бар иде, аңа ышана да идек — күп вакытта дөресне ялганнан аерып та тормыйча... Хәзер исә ышану бетте, сүзнең кирәге дә калмады. Чөнки сүз белән генә дөньяны үзгәртеп булмаячагын аңламаган кеше дә калмады бугай... Сүз белән гамәл берберсеннән шулкадәр ераклаштылар ки, кеше бәйләнчек сукыр чебеннән качкан шикелле, кибәккә әйләнгән буш сүзне дә үзеннән куа торган булды.

Әмма сүзсез яшәү мөмкин дә түгел. Ходай безгә тел белән акылны да сүз әйтер өчен биргән бит инде. Аннары кәгазьгә төшерелгән сүз югалмый, саклана да бит әле... Ихтимал, шуңа күрәдер, инде минем дә язасым килә. Язу — минем өчен бердәнбер шөгыль — бүтән эшем юк минем. Ә берни эшләмичә торып та булмый бит — тәндә җан барында...

Дөрес, язу минем өчен бервакытта да җиңел булмады. Бер җөмләне кайчагында унар тапкыр язып карарга туры килә. Укырга җиңел булсын дип азапланганмын, күрәсең. Хәзер инде бигрәк тә — дәрт белән дәрман ара-

сы көннән-көн ераклаша бара... Әмма ләкин тәртә арасына бер кереп алгач, карт алашадай, бөкрәеп булса да тартырга туры киләчәк. Вакыт һәм көч җиткән кадәр... Башлаган эш — беткән эш, диләр иде кайчандыр агайлар. Бетәрме-юкмы, тик бер Ходайның үзенә тапшырдык!.. Ахырына җитәр өчен санаулы көннәрнең күпме кирәклеген бары ул гына белә.

...Каләм кулда, хуш, нәрсәдән башларга? Утырам, уйланам... Беренче җөмләнең дә әһәмияте бик зур — ул укучыны тотып алырга һәм ычкындырмаска тиеш. Хәтерлисездер «Әйтелмәгән васыять»не, ул «...Кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә...» дип башланган иде. Әллә нинди сагышлы-сәер генә шушы җөмлә укучы күңелен үзенә җәлеп итмичә калмагандыр, мөгаен. Ләкин бу юлы мин хикәя язарга утырмадым — ниндиерәк сүзләр белән башлыйм икән дип азапланмаска да була. Әмма укучыга теләгем баштан ук ачык булырга тиеш. Теләгем исә минем бик гади — күңелемә ни килсә, шуны язып бару гына... Мәгәр алар күптөрле булыр: вакыйгалар, эпизодлар, мәзәкләр, уйланулар, искә төшерүләр — кыскасы, кырык тартмачының әйберләре шикеллерәк... Ничек, ни рәвештә күңелдә тусалар, шул тәртиптә язылып та барылыр. Һәммәсен дә түгел, үзем кирәк дип тапканнарын гына. (Югыйсә күңелгә ниләр генә килми!) Мисал өчен, искә төшкән менә мондый бер мәзәк.

...Моннан шактый еллар элек, бик әйбәт шагыйребез Зөлфәт «Казан утлары»нда басылган шигырьләренең берсен миңа багышлаган иде. Мин бик сөендем: шагыйрь игътибарына лаек булу зур мәртәбә ич ул! Аеруча, минем өчен...

Күпмедер вакыттан соң Зөлфәт шигырьләре аерым китап булып та чыкты. Анда мине сөендергән әлеге шигырь дә бар иде. Ләкин ни өчендер миңа багышланган булуы әйтелмәгән иде... Гаҗәпләндем, әзрәк кәефсезләндем дә, нәшриятта сыздылар микәнни дип тә уйладым. Ул чакларда нәшриятның ни кылса да ирке бар иде. Тик шулай да бер очрашканда Зөлфәтнең үзеннән моның сәбәбен сорадым. Ул, балаларча ваемсызлык белән генә:

— Китапны чыгарганда Мөдәррис Әгъләм сезнең исемне сызарга кушты,— диде.

Көтелмәгән бу җаваптан мин башта аптырап калдым, аннары эчемнән генә уйлап куйдым: ничек инде Зөлфәт җан дусты Мөдәрриснең сүзен тыңламасын, ди?! Мөдәррис гаҗәп тә акыллы бит ул, бик еракка карый белә...

Зөлфәткә нәрсә дип әйткәнемне хәтерләмим, ләкин

бернинди үпкә-мазар белдермәдем. Шагыйрьләрнең кәефе тиз үзгәрүчән, ашыгып сөенергә ярамый — менә шул бу «мәзәк»нең минем өчен нәтиҗәсе...

Үткәннәрне искә төшерүләр булгалар әле, ә хәзер сүзне быел күргәннәрдән башлыйсым килә. Онытылмас борын, барысы да истә чагында... Быел миңа 88 яшь. Күңелемдә миңа тынгылык бирмәгән уй-теләгем бар: читтә яшәгән якын туганнарым белән мин ничек тә очрашырга тиешмен!.. Бәлки, соңгы тапкыр... Ә быел уйлаганны алдагы елга һич тә калдырырга ярамый. Картлыкның таләбе шундый — исән чагымда эшләп калырга кирәк. Моның өчен миңа Уфага һәм Алма-Атыга барырга кирәк булачак. Минем якын туганнарыма, безнең төмәннәрчә әйтсәк, миңа тудыклар, ягъни атам-анам ягыннан бертуган балалары янына... (Үземнең бертуганым юк, бердәнбер энем күптән вафат, аның вакытсыз үлеме — минем гомерлек, төзәлмәс йөрәк ярам.)

...Тудыкларымның күбесе Уфада яшәде. Ләкин алар елдан-ел кими баралар. Анам ягыннан булганнары үлеп беттеләр, тик бер Факиһә исемле сеңелем генә калды. Атам ягыннан булганнарының байтагы исәннәр. Шуларның берсе, яшь ягыннан миңа иң якыны, Зөләйха Алма-Атыда тора. Мин менә башта Уфага кайтып, исәннәре белән күрешергә, үлгәннәренең каберләрен зиярәт кылырга тиешмен. Аннары инде ничек тә Алма-Атыга барып, Зөләйханы күрергә. Бару-кайтуны — якын калага җәен, ерагына көзен эшләргә исәбем.

Инде уйлаганны гамәлгә ашыру гына кала. Кечкенә мәсьәлә. Китәр көнең якынлашкач, барып, йә поездга, йә самолетка билет кына аласы... Кайчандыр шулай эшли дә идек. Әмма хәзер юлга чыгу минем өчен иң авыр, иң башкатыргыч мәсьәләгә әйләнде. Чи төен... Әйтик, былтыр әле Уфага очар өчен 450 мең сум түләргә кирәк иде. Кайтуы белән 900 мең — моңа инде минем айлык пенсиям дә җитми. Быелгысын әле белгән дә юк. Алма-Аты юлын да мин былтыр ук белешеп карадым. Казаннан самолет юк, Мәскәү аша очарга кирәк икән. Билет бәясе 850 мең сум, ә бару-кайту исә 1 миллион да 700 мең! Әллә-лә!.. Мәскәүгә чаклы да барасы бит әле. Ә без юлга Нәҗия апагыз белән икәү чыкмакчы идек... Кыскасы, Алма-Атыда бер атна кунак булу кимендә 5 миллионга барып басачак. Моңа инде икебезнең 5 айлык пенсия дә җитмәячәк... Юл йөрү хәзер язучы өчен түгел, ул мөмкинлектән безне мәхрүм иттеләр.

...Шушы урында чагыштыру өчен генә әзрәк үткәнгә кайтасым килә. Соңгы елларга кадәр мин Уфага еш

кайтып йөрдем. Реформа башланганчы, минем пенсиям 120 сум, ә авиабилет 11 сум иде — хет ай саен оч! Уфада туганнардан башка дус-ишләр дә күп, алар белән аралашу ансат булсын өчен, гадәттә, кунакханәгә төшә идем. (Телефоны бар, аста гына рестораны да.) Шуларның һәммәсенә дә 120 сум пенсиям җитә торган иде.

Гомумән, реформага чаклы юл йөрүләр проблема түгел — һәркемнең хәленнән килерлек иде. Шуңа күрә елына ике тапкыр без, язучылар, җәмәгатьләребез белән иҗат йортларына — кышын Малеевкага, җәен-көзен Ялтага, Пицундага яки Дубылтыга бара торган идек. Бар иде заманалар!.. Мин, мәсәлән, соңга табарак, башкалага барсам, «Москва» кунакханәсенә генә туктала башладым. Ватан сугышы ветераны булгач, отказ юк — аерым номер бирәләр иде. Тәүлеге 4 сум 60 тиен... Сагынып сөйләргә генә калды.

Сәясәткә һич тә кагыласы килми килүен. Сәясәт — Русиянең бәхетсезлеге, оятсыз кәсепкә әйләнгән пычрак эш... Әмма сасы искә ияләшкәндәй, без аңа ияләштек инде. Көн дә шуны сулыйбыз...

Мин байлыкның нәрсә икәнен белмим. Күргәнем юк. Шулай да реформа алдыннан минем икътисади хәлем шактый әйбәтләнгән иде. 1991 елның декабрендә саклык кассасында 60 мең акчам яткан. 60 меңгә 6 «Жигули» машинасы алып була иде ул чакта. Кайдан бу хәтле акча? Биш ел эчендә минем алты китабым чыккан — шуның берсе — 3 томлыгым. (Алты китапның өчесе берәм-берәм Уфада, Мәскәүдә, Ташкентта дөнья күрде.) Менә шуларның гонорары кыска гына вакыт эчендә минем саклык кассасына керде. Электән үк әз-әзләп җыелып килгәне дә бар иде...

Шулай итеп, без дә совет заманында ук инде шактый мая туплаган кеше булганбыз икән. Хәзерге кайбер түрәләр шикелле, шәп кенә машина да, чибәр генә йорт та алырга хәлемнән килгән икән... Әмма ни кызганыч, боларның берсе дә миңа насыйп булмады. 1992 елның беренче гыйнварыннан господин Гайдар башлап җибәргән реформа халыкның саклык кассаларында яткан акчаларын, сорап та тормыйча, тотты да йотты. Ә без бер көн эчендә хәерчелеккә төшүебезне сизми дә калдык.

...Кызык хәл. Зур акчаның нәрсә икәнен аңлап җиткермәгәнгә күрәмедер, мин баштарак көтелмәгән югалтуны ничектер җиңел кичердем... Үлем-бетеменә җыйганын югалткан бичара карчыклар хәлендә түгел бит әле мин, дип үземне юаткан булдым. Иллә мәгәр вакытлар узып, реформаның нәрсә икәнен җитәрлек күргәч, мин-

дә маңгай тирем белән тапканны тартып алучыларга карата ачу-нәфрәт көннән-көн көчәя генә барды. Һәрбер «мерседес» хуҗасында, агачлар ышыгында ташпулат салдыручыда мин үземне талаучыны күрәм хәзер...

Без инде социализмга кул селтәп («төкереп» диясем килми), яңа бер режимга, йомшартып әйткәндә, базар мөнәсәбәтләренә кердек. Ә чын дөресе — кыргый капитализмга күчтек. Моның әйбәт якларын да күрдек. Кытлык бетте, дефицит бетте, таңнан торып сөткә яки аракыга чират торулар да бетте. Җаның теләгән бөтен нәрсә дә бар — алырга хәлеңнән килсә... Дөрес, һәр яхшының бер яман ягы да була. Мәгәр бу режимның яхшы ягыннан яман ягы йөз тапкыр күбрәк булса кирәк. Аларны санап торасым килми, әйтик, балаларның ачтан үлүләрен яки 13—14 яшьлек кызларның фахишәлеккә төшүләрен — боларны һәм болардан да әшәкерәк, фаҗигалерәк хәлләрне кемнәр генә белми?..

Моның сәбәпләре дә яшерен сер түгел: ул — господин Чубайс үткәргән приватизациянең турыдан-туры нәтиҗәләре. Әле күптән түгел генә Б.Березовский бер интервьюсында ачыктан-ачык әйтте: приватизация гадел була алмый ул, диде. Белеп әйтә банкир — үзе шул эштә актив катнашып, котырып баеп киткән кешеләрнең берсе... Приватизация ул элекке партия номенклатурасы белән яңа чиновникларның ил байлыгын үзара бүлешүләре иде. Моны күреп торган халык аны шунда ук «прихватизация» дип атады да... Хәзерге монополист-капиталистларның һәммәсе диярлек кичәге коммунистлар ич!

Кайчандыр Сталин үткәргән коллективизация белән Ельцин башлаган реформа арасында зур охшашлык бар кебек. Һәр икесе дә нәкъ большевикларча булды — берәүдән дә сорап тормыйча, тиз генә үзләре теләгәнне эшләделәр. Ахырын уйлап тору да булмады. Нәтиҗәдә берсе, авыл хуҗалыгын аяктан егып, илгә ачлык китерде, икенчесе, Русия икътисадын җимереп, халыкның күпчелеген тирән бөлгенлеккә төшерде.

Миңа калса, Сталин белән Ельцин характерлары ягыннан да бер-берсенә бик якын торалар. Мәгәр акыл ягыннан түгел.

Русиянең янә бер бәхетсезлеге — гаять зур булуында. Халкы да бик чуар — йөз төрле. Шуңа күрә аның белән идарә итү, закон урнаштыру, тотрыклы тәртип саклау беркайда да тиешле дәрәҗәдә була алмады. Урыннардагы комсыз түрәләр һәм ришвәтче чиновниклар ни теләсәләр, шуны эшләделәр, теләсә кемгә берәүдән дә курыкмыйча сатылдылар. Бик зур Русиянең төрле җир-

ләрендә Ходай бирмеш табигый байлыклар бихисап күп булганга күрә, аны талап, урлап бетерү дә бик җиңел булды. Байлык өчен җинаять кылу бөтен илне каплап алды... Русия бик зур булганга күрә, халкы бервакытта да оеша, берләшә алмады. Бары тоталитар система гына Русияне авызлыклап тора алды. Югыйсә ул күптән, бәлки, таралып та беткән булыр иде.

Без менә XX гасырны тәмамлыйбыз. Борылып карасак, ни күрәбез: Русиянең XX гасыр дәвамында кичергән бөтен бәла-казалары, фаҗигале бәхетсезлекләре, түккән каннары өч большевик — Ленин, Сталин, Ельцин исеме белән бәйләнгән. Аларның өчесенә дә власть кирәк булды. Ә власть өчен нишләсәң дә ярый — алдау, көчләү — явызлыктан тыя торган бернинди мораль кагыйдә юк. Большевикларның канына сеңгән бу гадәтләр аларның балаларына да күчәчәк әле.

...Язучының котылгысыз бер «чире» — уйланулардан котыла алмау. Монда язганнарым шул уйлануларның йөздән бере... Дөреслеген һич тә дәгъва итмим, акыллы башлар бик күбәйде, чын дөресен алар эзләсен. Ә мине башка эшләрем көтә.

## Юл башы

Башта әйткәнемчә, миңа быел Уфа белән Алма-Атыга барып кайту кирәк иде. Алдагы 1998 елга калдырсам, бара алуым бик икеле — мин тагын бер елга картаям. Ләкин быел да уйлаганны гамәлгә ашыруның башны катырган авыр яклары бар. Иң элек — акча мәсьәләсе. Бу хакта мин әйттем инде... Нишләргә? Берәү дә миңа бурычлы түгел — бары дәүләт кенә бурычлы... Ләкин тартып алганны кире кайтармый дәүләт. Иң читене кемгә дә булса сорап мөрәҗәгать итү. Дөнья бозылды, кеше кырысланды, әгәр мөрәҗәгать итсәң, аның «синнән миңа ни файда» дип уйлавы бар. Әмма шул ук вакытта кеше кешедән башка тора да алмый. Авыр заманнарда кеше аеруча кешегә таянучан. Борыннан ук килгән, нык сыналган ул гадәт. Тик кешене бик яхшы белергә кирәк — бик авыр табышмак бу.

Быел минем Уфага да, Алма-Атыга да бара алуым нәкъ менә мине яхшы белгән кешеләр аркасында булды. Шулар миңа ярдәм кулларын суздылар. Бу җәһәттән 1997 ел минем өчен бик бәрәкәтле булып чыкты. Февраль аенда ук Азат әфәнде Зыятдинов безне Түбән Камага Бакый Урманченың 100 еллыгына чакырды. Килеп алу, өч көн буе әйбәт кунак итү, Бакый абзыйның 100 еллыгын бик

тулы, бик күркәм итеп билгеләү, ахырдан безне шәп автобуста Казанга кайтару — һәммәсе дә Азат әфәнде тырышлыгы белән оештырылган иде. Түбән Кама — татар җанлы гаҗәеп бер кала ул безнең җөмһүриятебездә. Милли мәдәниятебезгә иң зур игътибарны, иң чын хөрмәтне аеруча шушы яңа яшь шәһәрдә күрәбез. Электән үк шундый иде. Казан һәм Уфаның күп кенә әдип, шагыйрьләре, сәнгать әһелләре, махсус чакыру буенча бирегә килеп, аның халкы белән очрашып, «Җидегән чишмә» дигән һәвәскәр ансамбльнең чын үзебезчә матур-моңлы концертын тыңлап, бик әйбәт кунак булып киттеләр. Моның эше күркәм эшләрне оештыра белүче, Азат әфәнде Зыятдинов кебек милләтнең тәрәккый-пәрвәр кешеләре анда, күрәсең, аз түгел.

...Бакый Урманченың тууына 100 ел тулу уңае белән бу калада аның исеме бер гимназиягә бирелгән, урам аталган, һәйкәле эшләтелгән һәм урыны да билгеләнгән. Бу инде шәһәр хакимиятенең дә милли рухи тәрбиягә никадәр зур игътибар бирүен күрсәтеп торган, күпләргә үрнәк булырлык эшләре диясем килә, һич арттырмыйча гына.

Күрәсең, Татарстан шәһәрләре һәм районнарының матди мөмкинлекләре шактый ук арткан. Күп нәрсәләрне алар хәзер үз исәпләренә, үзләре теләгәнчә эшләтә алалар. Совет заманындагы шикелле, кечкенә бер эшкә дә Казан рөхсәтен көтеп ятмыйлар.

Ә бит рөхсәтсез берни эшли алмаган чаклары бар иде. Бу уңайдан бер аяныч вакыйганы искә төшерәсем килә... Илленче елларның башында булса кирәк — шулайрак хәтердә калган — ямьле җәйгә кергәч, Татарстан язучыларының нәүбәттәге съезды булып узды. Тугандаш республикалардан кунаклар да килгән иде. Алар арасында ерак Төрекмәнстаннан килгән мөхтәрәм олы язучы Берды Кербабаев та бар иде. Съезд эшен бетергәч, без кунакларыбызны Арча сабан туена алып бардык. Ул чакта район башкарма комитеты рәисе язучыларга яхшы таныш Абдуллин дигән кеше иде. Аның безне чын хуҗаларча каршы алып, саф татарча кунак итүенә бик ышанган идек. Ләкин танышыбызның ялга киткән чагы икән — каршы алучыларыбыз башкарак кешеләр булып чыкты. (Моны соңрак белергә туры килде.) Киң болындагы сабан туе бик җанлы-матур узды, кунакларыбызга да бик ошады. Ярыш-уеннар бетүгә, безне кунак итәр өчен, җәяүләтеп кенә Арча тавына алып менеп киттеләр.

Сугыштан соңгы Арча бик хөрти иде әле. Яңа биналар юк, ашханәсе дә электән калган тимер ишекле таш

бер кибеттә иде. Безне шунда кертеп, озын такта өстәл әйләнәсенә утырттылар. Тәрәзәләрендә пәрдә дигән нәрсә юк, сабан туеннан кайтучылар язучыларның ашау-эчүләрен карап торыр өчен шул тәрәзәләргә капландылар... Өстәлдә аракы тулы берничә графин, сырлы стаканнар, әмма бер төрле дә закуска-мазар юк. Татар гадәтенчә, шунда ук алюмин тәлинкәләрдә кайнар шулпа китерделәр. Сырлы стаканны күтәреп, кунаклар хөрмәтенә сүз әйтеп, беразын «каплагач», кайнар шулпаны өрә-өрә, шуның белән тамакны юып җибәрдек. Хәерчелек инде, нишләмәк кирәк, аның каравы тостлар бик шәп, ихлас, купшы сүзләр җитәрлек. Ә сугыш арты хәерчелеге бер Арчада гынамыни — бөтен Советлар Союзында, так что, гаепләштән булмасын, хөрмәтле кунаклар. Эчтән генә үзебезне шулай юаткан булабыз.

Шулпадан соң икенче блюдә килде. Тәлинкәдә макарон өстенә салынган кушуч кадәр чучка ите... Күзләребезгә ышанмыйча торабыз. Моның оятын тост белән генә капларлык түгел, җир ярылса — җир ярыгына кертерлек... Кунакларның берсе дә җәелеп яткан чучка итенә кагылмады, ә Берды агай, ачыктан-ачык җирәнеп, тәлинкәсен этеп кенә җибәрде. Ярый әле, татарның гармуны бар, шуны кычкыртып уйнап җибәргәч кенә авыр - читен хәлдән әзрәк чыккандай булдык. Әмма бу хурлык өчен кемдер җавап тотарга тиеш иде. Яшьрәкләр җырлап-биегән арада, безнең өлкәннәребез район җитәкчеләренең кайберләрен мыштым гына кухня ягына алып чыгып, аларга бик каты әйткәннәр: бөтен Татарстанны оятка калдырдыгыз бит, неужели бер сарык суярга да хәлегездән килмәде?

— Ник килмәсен — килер иде,— дигәннәр җитәкчеләр.— Ләкин сарык түгел, тавык суярга да хакыбыз юк. Терлек сую катгый рәвештә тыелды.

— Кем тарафыннан?

— Соң инде приказ Мәскәүнең үзеннән үк, обком да рөхсәт итә алмый...

— Ә чучкага рөхсәт бармы?

— Анысын мондагы бер дуңгыз асраучы агайдан гына алдык,— диде хуҗаларның берсе.

...Кичердек без шундый ач-ялангач чакларны. Хәтеремдә — Башкортстанның Яңавыл тирәсендәге авылларыннан ач кешеләрнең, ике вагон арасындагы буферга атланып, Сарапулга икмәккә барулары... Ә татар авылларында дуңгыз асрау гадәти бер эшкә әйләнде. Белмим, хәзер ничектер. Бәлки, мәчет салдырган авылларда дуңгызны бетереп, яңадан сарыкка күчкәннәрдер.

Ул заманнар бик еракта калды, яңасы башланганга да ун елдан артык вакыт узып китте. Үзгәрешләр шаккатырлык!.. Хәзер инде югарыда утыручылардан курку да, баш иеп буйсыну да, рөхсәт итүләрен көтеп яту да бетте диярлек. Кешедән генә көтеп була үзеңә кирәкне. Дәүләттән берни сорап, өмет итеп булмаган чакта, кемдер сиңа үзе теләп яхшылык эшли яки ярдәм кулын суза...

...Инде нәүбәттә Уфага бару. Бусы алдан ук уйланылган иде. Гадәттә, мин туган якларга тәмам җәйгә кергәч кайтырга ятам. Июньнең икенче яртысында яки июль башларында — көннәрнең иң озын, яктылык белән җылылыкның иң мул чагы. Янә минем өчен бик мөһим бер вакыйганы истә тоту кирәк иде. Июнь ахырында, Уфада Башкортстан татарларының беренче съезды булырга тиеш. Минем шул съезд көннәрендә анда буласым килә. Моны аңлатып торуның кирәге юктыр дип беләм. Әлбәттә, ул съездга Казаннан да кемнәрнедер чакырачаклар. Мин үзем чакыру көтмим. Татарстан исеменнән баручылар электән килгән гадәт буенча рәсми кешеләр булыр дип уйлыйм. Һәм тиздән барысы да ачыкланды: съезд 28 июньдә булачак икән, Татарстаннан 3 кеше барачак. Болар — Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ренат Харис, Президентның дәүләт киңәшчесе Рафаэль Хәкимов һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетыннан Римзил Вәлиев. Өчесе дә күптәнге якын, үз кешеләр. Менә шулар арасына сыеп булмасмы икән? Машинада барачаклары билгеле... Башта тәвәккәлләп Римзилгә шалтыраттым. Ул минем теләкне хуплады, ләкин Ренат Харис белән сөйләшергә кушты. Ул делегация җитәкчесе икән. Аңа шалтыраттым. Теләгемне әйткәч, Ренат, бер дә икеләнеп тормыйча, ярар, Әмирхан абый, бергә барырбыз, 27сендә бик иртә кузгалабыз, әзер булып тор, диде. Мәсьәлә әнә шулай ансат кына хәл ителде. Китәр көн дә килеп җиткән иде инде. Кичтән тәмам әзерләнеп, мин бик иртән йорт алдына чыгып бастым. Без барыбыз да бер тирәдә торабыз: Рафаэль — минем белән бер йортта, Ренат — каршыда, Римзил да каядыр якында гына... Күрми калу куркынычы юк. Сөйләшкәнчә, 27сендә, сәгать 8ләрдәме икән, без ике машинада кузгалып та киттек. Беренче машинада мин, Рафаэль, аның хатыны Мәүлидә ханым; икенче машинада Ренат үзе, Римзил һәм шагыйрь Госман Садә... Шулай итеп, алты кеше барабыз — өч рәсми вәкил, өч кунак. Шуларның өчесе — Башкортстанның үзеннән чыккан татарлар, иншалла, кабул итәрләр.

Безне ияртеп, алдан «мигалка»сын уйната-уйната, милиция машинасы чаба. Бик кызу барабыз — алдагы машиналар безгә юл биреп, бер читкә тайпылып калалар. Минем болай баруым беренче мәртәбә. Әзрәк кенә үсеп киткәндәй булдым.

Актанышны узгач, Башкортстанга керер алдыннан, Ренат Мәгъсумович беренче машинага, безнең янга күчеп утырды. Хәзер инде ул үзенең төп вазифасын үти башларга тиеш. Читләр алдында аңа Ренат дип кенә дәшү зур тәкәллефсезлек булачак.

Татарстанга чиктәш беренче район — Илеш. Менә шуның мәркәзенә җитәрәк, юл өстендә безне район хакимияте җитәкчеләре ипи-тоз, җыр-музыка белән каршыладылар. Машинадан иң элек Ренат Мәгъсумович чыкты, аның артыннан калганнарыбыз... Якты чырайлы хуҗалар белән чын ихластан куанып-елмаешып күрештек, чибәр кызларның чигүле сөлге белән тотып торган ак күмәчләрен чеметеп каптык, тустаганга салып биргән тансык кымызны күтәреп эчтек. Бәрәкәтле Башкортстан туфрагында бу беренче сый-хөрмәт. Ләкин башы гына икән әле. Әнә шулай зурлап каршы алганнан соң, хуҗалар, үз машиналарына утырып, безне, район үзәгенә кереп тормыйча гына, юл буендагы кечерәк бер урманга алып бардылар. Ашамлык-эчемлекләр белән тулы бай табын урманның аулак бер аланында безне көтеп тора икән ләбаса! Беренче ялкынлы тостлар шушында әйтелде, беренче рюмкаларны да шушында күтәрдек. Шау чәчәкле ямьле аланчыкта бер сәгать чамасы күңелле генә сөйләшеп, тыйнак кына сыйланып утырганнан соң, без кузгалдык. Соңламыйча, бик әйбәт кенә Уфаның үзенә барып җитәсе бар.

Әнә шулай матур башланды безгә тугандаш, ә минем туган туфрагым Башкортстанга безнең бу визитыбыз, һәм шулай бик матур дәвам да итте ул. Ачык йөз, якты чырай, байларча сый-хөрмәт һәр җирдә безне каршылады... Картлыкның бер өстенлеге дип әйтимме — барган җирләребездә егетләр мине иpләп кенә гел алгы сафка чыгара торган булдылар. Шулай итеп, мин, үзем дә сизмәстән, икенче урындагы кешегә әйләндем (ләкин статус буенча түгел). Әмма моның җаваплылыгы да зур икән. Сүзне бик чамалап сөйләргә кирәк — бигрәк тә хискә бирелеп китәргә ярамый. Рафаэль Хәкимовтан үрнәк аласы бар.

...Хәер, безнең барып җиткәнебез юк бит әле. Юллар шәп, машиналар оча гына... Илештән соң Чакмагыш, Дүртөйле, Кушнаренко җирләрен дә узып, ниһаять, Уфага якынлаштык. Әнә ул каршыбыздагы биек тау башын-

да... Егет чакта җырлый торган идек: Уфа таулары биек, йөри арыслан-киек; су сипмәгән гөлләр кебек йөрибез янып-көеп. (Җырның ертыгы юк.)

...Сәгать 5ләр тирәсе иде бугай. Агыйделнең икенче яңа күперенә җитәргә шактый җир каларак безне юл буенда берничә машина каршы алды. Туктап, сәлам биреп күрешүгә безгә әйттеләр: «Сезне Президент көтә!» — диделәр. Алай икән... Шунда ук машиналарга утырдык та Уфага ашыктык... Кара «Волга»лар, алдан да, арттан да юл ярып баручы «мигалка»лар белән каланы аркылы кисеп, Агыйделнең иң биек ярларыннан гүя бөтен Башкортстанга карап торган Президент сараена килеп тә туктадык. Бу зур, мәһабәт, ак-матур бина Брежнев заманында салынды бугай... Монда күпмедер вакыт Мидхәт Шакиров белән Таһир Ахунҗанов утырдылар. Шул чакта мин Таһир Исмәгыйлевич янында берничә тапкыр булган идем. Ул бит идеология секретаре иде, әмма идеология аңардан бер дә аңкып тормый иде. Сүзгә бик җор, уенкөлке ярата, шәп гармунчы, оста каләм иясе — гәзит теле белән әйткәндә, күпкырлы шәхес... Сөйләшеп утырулардан кәеф кенә күтәрелә иде. Миңа, читтән кайткан фиркасыз кунакка, шул җиткән дә иде.

...Президент Мортаза Гобәйдуллович Рәхимов безне үзенең зур кабинетында аягүрә каршы алды. Зур, таза кеше, чын башкорт икәнлеге йөзеннән үк күренеп тора. Кабинетта тагын кемнәрдер бар. Башта, билгеле, түбәнчелек белән Президент кулын кыстык, аннары башкалары белән күрешеп чыктык. Әз генә ыгы-зыгыдан соң утырыштык — Президент үз урынына, без стена буендагы озын өстәл тирәсенә. Өстәлдә чибәр вазаларда затлы чәчәкләр. Күләгә төсле тавыш-тынсыз гына йөргән официант кызлар, кымыз шешәләрен ачып, нечкә стаканнарга салып чыктылар. Иң беренче сый — башкортның милли эчемлеге кымыз, аның да Президент өстәленә куяр өчен махсус әзерләнгәне. Уртлап карагач та мин моны сиздем — кымыз миңа бик күптәннән таныш, әзрәк аера беләм ничегрәк икәнен... Ә бераздан коньяк килде, җиңел закускалар куелды.

Әнә шуларны авыз итә-итә барган сөйләшү дә якын кешеләр арасындагы шикелле бик гади һәм табигый иде. Ренат белән Рафаэльнең Мортаза Гобәйдулловичны күрүләре беренче тапкыр гына түгел, билгеле. (Татарстандагы зур бәйрәмнәргә аның килмичә калганы юк.) Моннан өч-дүрт ел элек Мортаза агай мине дә бер кабул иткән иде. Ул чакта ул Башкортстан Югары Советының Рәисе иде. Сөйләшүебез бик әйбәт, эчтәлекле булган иде.

Оныткандыр инде дип уйласам, юк, онытмаган икән — исенә төшерде.

...Ишетүем бик зәгыйфьләнде, кулымны колагыма куеп тыңлыйм, ләкин барыбер күп кенә сүзләрне ишетми калам... Аннары минем игътибарымны каршыда гына утырган урта яшьләрдәге таза, чибәр генә бер кеше җәлеп итте. Сүзгә катнашмый, эчемлеккә дә кагылмый, тик ни өчендер һаман миңа карый кебек. Кем ул? Бары соңыннан гына белдем: татарлар съездына Мәскәүдән махсус чакырылган ике бертуган Акчуриннарның берсе — Ельцинга операция ясаган, исеме бөтен дөньяга таралган хирург Ринат Сөләйманович икән ләбаса!.. Бәлки, минем хакта абыйсыннан әзрәк ишеткәндер — абыйсы генерал-полковник Рәсим Сөләйманович белән мине Мәскәүдә таныштырганнар иде. Переделкинода ял иткән чагымда ул, Фуат Маннанов белән бергә килеп, миндә озак кына утырып та киткәннәр иде. Ләкин Президент кабинетында мин генералны күрмәдем. Ә съездда алар икесе дә булдылар...

Башкортстан татарларының беренче съезды 28 июльдә, сәгать 10да ачылырга тиеш иде. Без алданрак барып җиттек. Съездның урыны — Башкортстан Дәүләт җыелышы-корылтае өчен махсус салынган яңа бинада. Без килеп җиткәндә, аның тирәсендә машиналар һәм кешеләр шактый ук иде. Очраган таныш-белешләр белән исәнләштек-күрештек.

...Башкортстан автономиясе игълан ителгәннән соң, 78 ел узгач, монда яшәүче татарларның беренче мәртәбә җыелышып сөйләшүләре, әлбәттә, зур тарихи вакыйга. Хәлбуки Уфа үзе татарның милли азатлык хәрәкәтендә күренекле урын тоткан кала. Аеруча 1917—1918 елларда монда татар хәрәкәте бик көчәя, Милләт Мәҗлесе үзенең атналарга сузылган утырышларын шушында үткәрә, беренче татар хөкүмәте дә шушында төзелә, ниһаять, «Идел-Урал штаты» дигән мәмләкәт төзү идеясе дә шушы Уфада туа. Әмма ул вакыйгалар тарих битләрендә генә язылып калды.

Башкорт һәм татар икегә аерылып, ике автономия барлыкка килгәч, Уфаның да статусы гына түгел, ике тугандаш халыкның тормышында тоткан урыны да бик нык үзгәрде. Ләкин чынбарлыкта исә Башкортстан җирләрендә миллионнан артык татар яши (сан ягыннан икенче урында). Үзенең теле, дине, гореф-гадәтләре белән бик күптәннән шушы уртак иленә бөтен көчен-куәтен биреп яши.

Минем татар, башкорт мөнәсәбәтләрендә казынасым

килми. Трибуналардан «ике тугандаш халык» дип сөйләргә яратсак та, мөнәсәбәтләрнең ямьсезләнеп киткән бик киеренке чаклары да булгалады. Моннан берничә ел элек минем үземә дә ул мөнәсәбәтләр турында «Тигезлек аша татулыкка» дигән мәкалә белән матбугатта чыгарга туры килде. (Казанда һәм Уфада да басылды ул.) Әмма без үткәнне искә төшерү белән түгел, киләчәкне кайгырта белеп яшәргә тиешбез.

...Яңа заманга кердек. Бу заманның һәрбер халык өчен дә никадәр ышанычсыз, куркыныч булуын әйтеп тору кирәкме икән?! Башкорт белән татар алдына да ул милләт буларак саклану һәм яшәү мәсьәләсен бөтен үткенлеге белән китереп куйды. Мондый шартларда аларның бер-берсенә арка таянычы булмыйча хәлләре юк. («Арка таянычы» бик борыннан яшәп килгән тәгъбир. Гүя ул ике батырның, аркалары белән бер-берсенә терәлеп, үзләрен урап алган дошманнарына каршы сугышуларын хәтерләтә.)

Аннары һәр ике халыкның төп максаты чын демократик һәм югары цивилизацияле җәмгыять төзү булса, моңа ирешү дә бары үзара татулык вә тигезлек аркасында гына мөмкин булачак. Шушы күзлектән караганда, татарларның бүген ачылачак беренче съезды аеруча әһәмияткә ия, минемчә. Башкортстан Президенты һәм хөкүмәте бу съездны оештырып бик дөрес эшләгәннәр диясем килә. Тик аның нәтиҗәләре ике халык өчен дә өметле һәм игелекле була күрсен иде.

...Минем урыным да президиумда — алдан ук язып та куелган. Уң ягымда — Наҗар Нәҗми, аның белән янәшә утыру минем өчен бик әйбәт булды.

Зал халык белән шыгрым тулы. Стена буенда, ишек төпләрендә басып торучылар да шактый иде. Көтә халык — зур тарихи бер вакыйганы көткәндәй, җитди, сабыр гына көтә.

Съезд, гадәттәгечә, аз гына соңга калып башланды. Аны оештыру комитетының рәисе Миңнерәис әфәнде Ишмуратов ачты. (Исеме дә туры килгән бит!) Һәм ахырына кадәр бик оста алып та барды. Минем өчен яңа кеше. Башкортстан парламентындагы бер палатаның да рәисе икән ул. Күренеп тора, җитәкчелек итә белүче.

...Беренче сүз, әлбәттә, мөхтәрәм Президентка... Мортаза Гобәйдуллович үзенең эчтәлекле чыгышында татар халкына карата җылы сүзләр әйтте, аның республика тормышында тоткан урынын югары бәяләде, гомумән, күпмилләтле Башкортстанда үзара дуслык һәм татулыкның тотрыклы булуын искәртте.

Татарстан вәкилләре исеменнән котлау сүзен, билгеле, Ренат Харис әйтте. Рәсми дәрәҗәсе буенча һәр җирдә беренче сүз аңа — Ренат Мәгъсумович бу шәрәфле вазифаны оста башкарырга күптән инде күнеккән һәм, шагыйрь булгач, сүзен үзенчәрәк итеп әйтә дә белә. Зал аны игътибар белән тыңлады. Аңардан соң төп доклад өчен сүз Башкортстан Премьер-министры Рим Сәгыйтович Бакиевка бирелде. Фамилиясе таныш, ләкин беренче күрүем. Аны чын татар, диделәр. Димәк, иң югары өч җитәкченең берсе татар милләтеннән икән. Бу инде зур игътибарга лаек — бик әһәмиятле факт.

Чыгып сөйләүчеләр күп булды. Кызганыч, ишетүем бик зәгыйфьләнде, бик ачык сөйләүчеләрне генә ишетә алам. Күбрәк залның ничек тыңлавын, ничек кабул итүен күзәтеп утырдым. Яки күршемдәге Наҗардан «Нәрсә әйтте?» дип, аны борчыйм. (Минем кулымны колагыма куеп, тыңлап утыруымны төшереп алып, «Өмет» газитенең беренче битендә фотомны да басып чыгардылар.) Ике кешенең чыгышын яхшы ук тыңладым шикелле. Берсе — Рәиф Әмиров чыгышы: татарларга ниләр кирәген ул бик конкрет сөйләп төште... Башкортстан Фәннәр академиясе президенты Роберт Нигъмәтуллинның чыгышы тыңлаучыларга аеруча нык тәэсир итте. Бик ялкынланып, бик кыю сөйләде ул. Әлбәттә, урысча. Әмма аның «Татардан башка башкорт юк, башкорттан башка татар юк!» дигән сүзләре бөтен залны бик җанландырды.

Шушы урында минем чигенеш ясыйсым килә.

Хикмәт шунда ки, Роберт Нигъмәтуллин — миңа шактый ук якын кардәш тиешле кеше. Аның әтисе Искәндәр абзый белән мин, төмәнчә әйтсәк, тумачалар, ягъни өченче буын бертуганнар. Ә минем атам белән Искәндәр абзыйның әнисе ике бертуганнар — безнеңчә, тудыклар (двоюродныйлар). Ә атамның атасы белән Искәндәр абзыйның әбисе бертуганнар... Әнә шулай дәвам итеп килә безнең туганлык. Тик монда бер ачыклык кертергә кирәк: Искәндәр абзыйның төп фамилиясе (димәк, Робертның да) — Терегулов. Атасы — Нигъмәтулла Терегулов, безгә җизни тиешле... Искәндәр абзый фамилиясен атасы исеменә уку елларында күчергән булса кирәк. Ул бит үзе дә фән докторы, танылган галим, Бауман исемендәге югары техник училище профессоры иде. Уллары Роберт белән Булат та фән докторлары. Бертуган агасы Гыйниятулла абзый Терегулов (Уфа халкына бик мәгълүм кеше) һәм аның улы Рал да медицина өлкәсендә зур урын тоткан галимнәр. Гомумән, бу Саттый карт нәсе-

леннән чыккан укымышлы кешеләр күп иде. (Аларның бабаларын шулай дип йөртәләр иде; тулы исеме Гапсаттар.) Мичурин шәкерте профессор Хәсән Еникеев та шул нәселдән.

Искәндәр абзый улы Роберт Нигъмәтуллин исә дөнья күләмендә танылган зур галим, академик — менә шуны Президент Мортаза Рәхимовның Уфага чакыртып алып, Башкортстан Фәннәр академиясе президенты итеп сайлатуын бик урынлы булган дип әйтәсем килә. Боларны язуым Роберт белән мактаныр өчен түгел, ә безнең татардан кемнәр чыкканын күрсәтер өчен генә... Аз түгел алар. Тик күрә белергә дә тарта белергә генә кирәк.

Төп чыгышлар зур тәнәфескә кадәр бетте диярлек. Тәнәфестән соң төрле карарлар, мөрәҗәгатьләр кабул итәлергә һәм сайлаулар үткәрелергә тиеш иде.

Төшке ашны шул ук бинаның бер бүлмәсендә Президент белән бер табында ашадык. Билгеле, бу табын күп кеше өчен түгел — читтән килгән кунаклар һәм съездны алып баручылар өчен генә. Казан кунакларыннан башка, монда Мәскәүдән бертуган Акчуриннар һәм шагыйрьләрдән Мостай Кәрим бар иде. Ашау-эчү бер дә тартынусыз, җиңелчә генә сөйләшү белән үтте. Мондый табында минем әле беренче мәртәбә диярлек булуым.

Аштан соң Президент безне якында гына салынып яткан бер биек бинаны күрсәтергә алып барды. Моны, дөрес ишеткән булсам, Башкортстанның милли үзәк банкы өчен төзиләр икән. Эченә кердек. Бөтен эче әллә саф алтыннан, әллә алтынга манчылган — күз камашырлык. Иң югары төзелеш таләпләренә җавап бирерлек итеп эшләнә икән бу бик зиннәтле шәп бина. Әйтергә кирәк, соңгы бер-ике ел эчендә генә дә Уфада күп кенә чибәр йортлар салынган. Малай чактан ук таныш каланың бик кызу үсүе һәм үзгәрүе күптән үк башланган иде, иске йөзе бөтенләй калмады диярлек (өч-дүрт урамын исәпләмәгәндә). Хәзер инде аның йөзен тагын да заманчарак, матур итеп үзгәртергә тотынганнар булса кирәк. Суверен республиканың мөмкинлекләре җитәрлек, күрәсең...

Олы тәнәфестән соң инде сөйләүчеләр күп булмады, вакыт күбрәк карарлар, мөрәҗәгатьләр кабул итүгә, төрле сайлауларга китте. Карар-мөрәҗәгатьләр алдан язылып, сайлау исемлекләре дә алдан төзелеп, делегатларга таратылганга күрә, бу эшләр һәммәсе дә бәхәссез, шома гына узды диярлек. Залдан татар теле дә дәүләт теле булсын дигән тәкъдим әйтелгән иде, утырышны алып баручы Ишмуратов моны да ничектер ансат кына карар-

га кертеп җибәрде. Әллә әһәмият бирмәделәр, әллә сизми калдылар... Аннары программа буенча кичке сәгать 7дә Опера һәм балет театрында зур концерт та булырга тиеш. Шуңа күрә утырышны озакка сузмаска тырыштылар. Тавыш бирүләр дә төгәлләнгәч, беренче татар съезды әшен тәмамлады. Халык кузгалды, «Туган тел»не җырлап тору булмады. Кешеләр көне буе утырып ялыккандыр, мөгаен,— сүзсез генә таралдылар. Тик соңыннан гына кайбер сүзләрне ишеткәләргә туры килде — җае чыкса, бәлки, язармын да әле...

Мин дә бик арыган идем. «Президент-отель»гә кайтып, бераз ял итәсем килде. Кара «Волга» мине шунда илтеп куйды.

Суыткычтан бер банкы сыраны алып эчтем дә, чишенеп, аркылы ятарлык киң караватка сузылдым... Дүнгән карт башым шунда ук йокы чоңгылына да чумды... Һәм, билгеле инде, бик тансык концерттан колак та кактым. Иң кызганычы, бик яраткан башкорт җырын ишетмичә калдым.

...Сәгать 10нар тирәсендә микән, кемдер ишекне какты. Торып ачтым — бер яшь егет миңа түбәнгә төшәргә кушты. Төшсәм, әлеге аулак бүлмәдә төрле нигъмәт тулы бай табын. Бу инде безнең хөрмәткә оештырылган кечкенә бер банкет икән. Кеше дә күп түгел — башлыча съездны җитәкләп алып баручылар җыелган. Мәҗлеснең төп хуҗасы — Президентның уң кулы Мансур Әнвәрович Әюпов. (Уфада «әфәнде» дип әйтү гамәлгә кермәгән әле.)

Сый — мул, күңелләр — хуш, сүзләр — җылы, уенкөлке аралаш ихлас теләкләр дә әйткәләп һәм капкалап матур гына утырдык... Казан кунаклары иртәгә юлга чыгарга тиеш. Шуңа күрә мәҗлесне бик озакка сузмадылар. Сәгать 12ләр тулып узгач, безгә инде кузгалырга рөхсәт иттеләр. Хуҗаларга кат-кат рәхмәтләр әйтеп, кат-кат кул бирешеп, ниһаять, бүлмәләргә таралыштык.

...Кичтән шактый гына йоклап алганга күрә, озак кына күз йома алмыйча, төнге тынлыкка колак салып яттым. Башка әллә нинди сәер генә уйлар килә. Үземдә нindидер бер үзгәреш тоям кебек... Мин бит бүгенге тормыштан канәгатьсез кеше, хәзерге режимны бер дә яратмыйм. Ә менә монда шул канәгатьсезлек бетте кебек. Ике-өч көн кадерле кунак булып йөри торгач, режимның бөтен караңгы, әшәке яклары онытыла да башлаган, имеш... Әнә нишләтә икән ул «югары»га якынаю. Хәер, бу якынаю вакытлы гына. Үзеңнең көндәлек гади

пенсионер тормышыңа кайткач, бөтен нәрсә яңадан иске чын кыяфәтендә күренә башлар, шәт!..

Аннары уйлана торгач, төрле очрашуларда, ашау-эчү вакытында әйтелгән сүзләрне искә төшергәләдем. Сүзгә катнашуның үзенә күрә язылмаган кагыйдәсе бар. Иң элек төрле дәрәҗәдәге мәртәбәле кешеләр җыелган җирдә үз урыныңны яхшы белү кирәк. Мәртәбәсе югары булганнардан узып, сүз башларга ярамый да... Инде чиратыңны белеп, котлыйсың яки тост әйтәсең икән, сүзең мәгънәле, тапкыр һәм кыска булырга тиеш. Моның тәҗрибәле үз осталары була. Ләкин миндә андый тәҗрибә юк диярлек. Шуңа күрә еш кына үзем кирәк дип тапканны әйтергә тырышам. Билгеле, ул мәгънәсез буш сүз булмаска тиеш. Бу ике көндә ярамаган, килешмәгән сүз әйтмәдем бугай. Ләкин артыгын ычкындырдым шикелле, хәерсез!.. Минем яшьтәге кешегә ул һич тә килешми, һәм соңыннан бик нык үкенергә дә туры килә...

Җитеп торыр, ахрысы, бу вакытсыз уйланып яту — әнә, беленә башлаган таң яктысыннан зур тәрәзә әкрен генә агара да инде. Һич югы, ике-өч сәгать булса да йоклап алырга кирәк. Бисмилла әйтеп, күзне йомдым. Килә күр матур төшләрең белән, татлы йокы!..

Бүген 29 июнь, татарлар съезды һәм съезд белән бәйләнгән тамаша тәмам. Казан кунакларына кайтып китәргә вакыт. Ләкин башта Аургазы районындагы Солтанморат авылына барып, Галимҗан Ибраһимовның яңа музеен күрергә тиешбез. Бу алдан ук уйланылган теләк иде. Шуннан соң кире Уфага кайтып, Илеш юлы белән Казанга китәргә кирәк булачак. Моны белгәч тә, миндә янә бер теләк туды: Солтанмораттан Дәүләкәнгә узарга... Аралары ерак түгел, күп булса, 40-50 километр булыр. Ә Дәүләкәннән Бүздәк аша Туймазы юлына да, Илеш юлына да чыгып була. Уфа аша урап йөргәнче, мин әйткән маршрут туррактыр да әле...

Минем теләгем, бер уңайдан Дәүләкәнемне күреп киту булса, икенчедән, аны Казан егетләренә дә күрсәтәсем бик килә иде... Мине үстергән, дөньяга чыгарган, ниһаять, язучы иткән бу кечкенә шәһәрчекне Казан язучыларыннан, Илдар Юзеевтан башка, берәүнең дә күргәне юк ләбаса! Татарстан туфрагында туганнарның авылларын бик яхшы беләләр, барып та йөриләр... Минем «яшел бишегем»не дә Ренат Харис, Рафаэль Хәкимов, Госман Садәләр күреп китсәләр ни була, ни югалталар?.. Бу ихлас теләгемне кичтән үк егетләргә әйтеп караган идем. Ләкин ни өчендер тиз генә килешеп, кабул итүче булмады. Китәсе көнне дә ялварып диярлек өнди башла-

дым. Рәхмәт башкорт дусларга, алар мине тизрәк аңладылар: «Борчылма, Әмирхан агай, Дәүләкәнгә дә җитәбез»,— диделәр. Чынлап та, без, иртәнге чәйдән соң юлга чыгып, Аургазы аша Солтанморатка барып җиткәндә, анда Дәүләкән хакимияте башлыгы Марат Латыйпов безне инде көтеп тә тора иде. (Мондый өлгерлек, мөгаен, Уфадан Мансур Әюповның боерыгы нәтиҗәсендә булгандыр.)

...Иртәнге чәйдән соң, без өч машинада Солтанморатка чыгып киттек. Беренче машинада — безне алып баручы Дәүләт җыелышы депутаты, фәлсәфә фәннәре докторы, профессор Алим Әхәтович Әхмәдиев; тагын ике машинада без — Казан кунаклары... Билгеле, безне алдан да, арттан да «мигалка»лы милиция машиналары озата барды. (Боларны язып торуым — безнең имиджны күрсәтер өчен. Ә нәрсә ул «имидж» — ачык кына белмим дә.)

Аургазыда тукталып тормыйча гына Солтанморатка уздык. Олы юлдан аерылып авылга керә торган юл башында безне сылу кызлар ипи-тоз белән, егетләр исә гармун уйнап каршы алды. Үз машиналарында килгән район җитәкчеләре дә, билгеле, шушында иде.

1987 елны Галимҗан Ибраһимовның 100 еллыгын бәйрәм иткәндә, без, Казан язучылары, Солтанморатка килеп, әдипнең күптән түгел ачылган музеенда булып киткән идек инде. Ләкин ак бүрәнәдән салынган җыйнак йорт кайсыдыр елны янып юкка чыккан. Йорт кызганыч, йорттан да бигрәк, эчендәге берәмләп җыелган нәрсәләре аеруча кызганыч. Репрессия корбаннарының әйберләрен табу гаять читен. Аларның бик күбесе органнар тарафыннан юк ителгән яки югалып беткән. Галимҗанның да Кырымнан кайткан архивы шундый язмышка дучар булды.

Инде менә янган йорттан бераз читтәрәк, музей өчен кызыл кирпечтән яңача стильдә бик матур бина салып куйганнар. Без менә шул чибәр бинаның шактый иркен эчен, андагы экспонатларны ашыкмыйча гына карап, танышып чыктык. Музейны караучы ханымның тырышлыгы нәтиҗәсендә күп нәрсә җыелган, ләкин бушлык нык сизелә иде әле. Мәсәлән, мин үзем Г.Ибраһимовның шушы музей өчен җибәргән «Нәхү» исемле китабын һәм әдипнең Газим Касимовка үз кулы белән язган хатын монда күрмәдем. Ахрысы, аларны миннән алып киткән Уфа галиме тапшырырга өлгермәгәндер...

...Солтанморатта эш беткәч, без Дәүләкәнгә ашыктык. (Мин инде тукталган бер җирдә сыйланып чыгуларны

язып тормыйм — укучының саруын кайнатасым килми.) 40—50 километр араны тиз уздык. Кайчандыр «Тазлар Дәүләкәне» дип йөртелгән, аерылыбрак торган кечкенә генә авыл янындагы яңа күпердән Дим елгасы аша чыктык. Ләкин «Тазлар» авылы юк инде, ул күптән зур Дәүләкәнгә кушылган. Озын урам буйлап бара-бара, без, ниһаять, шәһәр үзәгенә җитеп, бер бик шәп яңа йорт янында туктадык. Элек безнең заманда бу урында ак таштан түгәрәкләп салынган биек кенә «Водокачка» дигән корылма тора иде. Шуннан кайчандыр аны сүтеп, монда Дим буйларына «карап торган» ресторан салганнар иде. Хәзер ул да юк. Алар урынында ак кирпечтән төзелгән менә шушы чибәр-шәп яңа йорт тора. Бу — Әхияр Хәкимов йорты... Әхияр — Дәүләкән районындагы бер авылда (исемен оныттым) туган кеше, бик билгеле язучы, гомеренең күп өлешен Мәскәүдә «Лит. газета»да эшләп уздырды, аның редколлегия әгъзасы да булды. Хәзер инде пенсиядә. Менә туган иленең җитәкчеләре Әхияр Хәкимовның башкорт әдәбиятына күрсәткән хезмәтләре өчен шушы йортны махсус салдырып аңа бүләк иткәннәр... Үзара сөйләшүләрдән ишетеп калдым: йорт бер миллиард сумга төшкән, имеш! Миллиард — акчамыни ул Башкортстан өчен...

Йорт хуҗасы Әхияр безне урамга чыгып каршы алды. Рәшәткә койма белән генә әйләндереп алынган шактый иркен ихатасына кердек, өеннән башлап Дим читенә кадәр үк төшкән, бик тәртипле утыртылган яшь бакчасын карадык. Аннары өенә уздык. Шәһәрчә бөтен шартын җиткереп эшләнгән өй ничә бүлмәледер, әйтә алмыйм, мәгәр югарыда зур гына мансардасы да бар икәнен күрдек.

Әхияргә әйтәм:

— Син инде Дәүләкәннең үз кешесе булгансың, гомереңне шушында гына уздыра торгансыңдыр?

— Әйе, җәен шушында, ә кышын — Мәскәүдә,— диде ул.

Шул арада ике ханым зал якта ашыгып табын да әзерли башладылар. Әхияр шешәләрен дә чыгарды. Ләкин мин аның эшен бүлдем:

— Әхияр, без монда узышлый гына тукталдык, юлыбыз «Аслы күл»гә. Әгәр теләсәң, әйдә, сыйларыңны ал да безнең белән «Аслы»га киттек!

Ул үзе дә, ханымнар да бу тәкъдим белән бик тиз килештеләр. Әмма минем Дәүләкәндә тукталуымның төп сәбәбе — үзем үскән йортны Казан егетләренә күрсәтү иде бит. Андый йорт та бар бит әле монда... Хуҗаларны

һәм кунакларны шуны барып карарга чакырдым, моннан ерак та түгел, дидем. Сүзсез генә килештеләр. Машиналарга утырмыйча гына киттек. Безнең йорт төп урамда, мәчетне узып бераз баргач, сул якта.

...Менә ул агачлар ышыгындарак торган, өч тәрәзәсе урамга караган, асты — таш подвал, өсте — бүрәнәдән, гади генә йорт... (Тик хәзер аның өстен ак штукатурка белән сылаганнар.) Моннан чыгып китүебезгә 65 ел узса да, йорт мине таныйдыр кебек. Чөнки кайткан саен мин аның каршысына килмичә калмыйм.

Йортны урамнан аерыбрак торган рәшәткә буена тезелештек. Ни диеп әйтергә ияреп килүчеләргә? Мин шушында үстем, егет булдым дияргәме? Ләкин моның ни әһәмияте бар? Экскурсовод шикелле тыныч кына булырга тырыштым мин: «Безнең бу йортта,— дип сүз башладым,— заманында безгә туган тиешле Шәриф һәм Сәгыйть Сүнчәләйләр була торган иде. Алар янына Көрмәнкәйдә кымыз эчеп яткан Мәҗит агай Гафури да килгәли иде... Ә бер җәйне Уфа артистлары Нури Сакаев, Нәгыймә Таҗдарова, Маһирә Мирвәлиева, Шакир Шамильскийлар кымызга барышлый бездә бер атна торып киткәннәр иде... Әйе, бу бичара йорт...». Ләкин кинәт күңел тула башлаганын сиздем дә сүземне бетермичә тизрәк бер читкә борылып киттем. Ярый, сорау-фәлән бирүче булмады — хәлемне аңладылар булса кирәк. Бу килүем, бәлки, соңгысыдыр инде... Ә йорт торыр әле, торыр... Нигезе таза... Менә аны хакимият башлыгы Латыйпов та күрде. Мин бит әле Дәүләкәннең тарихын да яздым («Соңгы китап»та) — ул аны да белергә тиеш. Шунда ул үзенең туган авылы Корыятмасны да күрер... Араларыбыз никадәр ерак булмасын, без бит бер үк һаваны сулап, бер үк суларны эчкән кешеләр.

...Үзара сөйләшмичә генә машиналарыбыз янына киттек, утырыштык, һәм Латыйпов машинасы артыннан ияреп, «Аслы күл»гә юл тоттык. Мондый кыска арада Дәүләкәннең үзен дә, Дим буйларын да күреп булмады. Егетләрем артык кызыксынмадылар да шикелле — вакытлары бик кадерле. Мәгәр «Аслы күл»не күрмичә китү һич тә ярамый. Көне нинди дә, әйләнәдәге табигать нинди — буй җиткән гыйффәтле кызлардай... Сихри гүзәллектән качарга ярыймы соң?! Рәсми калыптан чыгарга да, чишенеп ташлап, «Аслы күл»нең көмеш суына чумарга!.. Сез бит әле шагыйрьләр дә... Мин менә, 90га җитеп килсәм дә, «Аслыкаем»да чумып-йөзеп чыгачакмын, Аллаһы бирсә!..

Без Бүздәк юлы белән барабыз. Күл бу зур юлдан

бераз читтәрәк. Күпмедер баргач, күлнең үзенә асфальт юл аерыла. Ләкин күлгә килеп җитәрәк, алдан баручы машина асфальттан чыгып, арба юлы белән китте. Хикмәт шунда, «Аслы күл»нең Дәүләкәнгә караган ягы бөтен буена диярлек таулыклар. Тау өстендә тау... Алдагы машина үлән баскан тар, текә юлдан шул тауларга «пошкырып-пошкырып» үрмәли. Без аның артыннан... Юлның шундый хәтәр урыннары бар ки, машина чана шикелле чалулап китәр кебек... Ниһаять, Латыйпов машинасы борыла-борыла үрмәли торгач, тауның иң биек бер ноктасына җитеп туктады. Шөкер, барыбыз да исән-сау менеп җиттек. Бу — тигез-иркен генә бер тау түбәсе иде. Машиналардан чыктык, һәм алдыбызда бөтен иңебуе белән җәелеп яткан «Аслы күл» кинәт кенә ачылды. Йа Хода, менә кайда ул әкиятләргә кергән «Аслы күл»!.. Миңа аның бөтен әйләнәсе таныш — бу биек ноктадан карап торуым да беренче тапкыр гына түгел. Ләкин барыбер мин аңа беренче мәртәбә күргәндәй карыйм — гүя сихерле, гүя үзенә тарта ул мине!..

Әмма бик дөрес эшләде Латыйпов туган Казан кунакларына биек түбәдән бу тылсымлы тамашаны күрсәтеп... Бәлки, исләренә төшерерләр — шушы бит инде Мәҗит Гафуриның «Зыятүләк белән Сусылу» әкиятендәге тирән күл... Шушы әкият буенча Нәкый Исәнбәт либреттосына Нәҗип Җиһанов тарафыннан «Түләк» операсы язылды — шунда бит инде бу күлнең су асты патшалыгы күрсәтелде... Хәзер әнә чын «Аслы күл» үзе түбәндә, серләрен яшергәндәй, тыныч кына ялтырап ята. Бер генә күрсәң дә гомерлеккә истә калачак!..

...Инде төшәргә вакыт. Биектән түбәнгә төшү — менүгә караганда да куркынычрак. Юл бик текә, Алла сакласын, мәтәлеп китүең дә бар... Ләкин машиналар таза кулларда — безне исән-имин күл читенә төшереп җиткерделәр. Сулга борылдык. Моннан ерак та түгел күл буеның, әйтерсең истирахәт өчен генә яратылган бер җире бар. Амфитеатр шикелле өч ягы куе агачлык белән капланган таулар, ә күлгә караган ягы ачык — әйләнә-тирәсе шау чәчәкле зур гына иркен бер аланлык... Гаҗәеп урын. Монда бит яңа байларны әллә кайлардан тарта торган кәеф-сафа йорты ачып җибәрергә дә мөмкин булыр иде. Ләкин, шөкер әле, базар мөнәсәбәтләре «Аслы күл»гә килеп җитмәгән. Сусылу күлен пычратырга әле өлгермәгәннәр...

Машиналардан төшеп, тирә-юньне сокланып бер күзәткәч, иң беренче эшебез, әлбәттә, күлдә коену булды. Яры биек түгел, ирләр, хатын-кызлар өчен утыртып ку-

елган аерым куышы да бар — кыскасы, әфәнделәр һәм ханымнар шул куышларда эчке киемнәрен алыштырып, күлгә йөгереп төшеп чума да башладылар. Әйткәнемчә, мин дә алар артыннан, соңга калыбрак булса да, бисмилланы әйтеп, үз аягым белән суга кердем. Суның читендә аяк әзрәк ләмгә бата икән, тик берничә адым эчкә кергәч кенә такыр комлыкка басасың. Ә без егет чакларда такыр комлык суның читеннән үк башлана иде. Таш табакка салган су кебек чиста иде бу күл ул чакларда. Аягым такыр комлыкка тигәч тә, берничә тапкыр чумып алдым, аннары колач салып, әзрәк йөзгән дә булдым. Бераздан, инде җиткәндер, дип (чаманы онытырга ярамый), судан чыга да башладым. Ярга менәргә миңа кемдер ярдәм итте. Әмма «Аслы күл»нең салкынча суы тәнгә генә түгел, җанга да җиңеллек китерде. Хәтта картлыгымны оныткандай булдым.

Бу чыр-чулы, рәхәт коенулардан соң, безне агачлар ышыгына әзерләнгән табынга чакырдылар. Озын өстәл әйләнәсенә утырыштык. Алдыбызда ниләр генә юк, аппетитның да «авызы» ачылган чагы... Башта кымыз бик килеште, аның артыннан башкасы да шома гына үтә башлады — закускага җылкы казылыгы (колбаса түгел), яшелчә, җиләк-җимеш... Шулар янына килгән ашларны санап тору кирәкме икән?! Монда белеп торуның иң кирәге: бу бит безнең аерылышыр алдыннан соңгы мәртәбә бер табында утыруыбыз, башкорт дуслар белән бергә соңгы сыйлануыбыз. Шуңа күрә артык төчеләнмичә гади генә әйтелгән хушлашу һәм рәхмәт сүзләре дә чын ихластан иде. Тик мин генә, күбрәк төшерү аркасындамы, хатирәләргә бирелеп китеп, моннан 70 еллар элек без — Дәүләкән яшьләренең, атларга төялеп, шушы «Аслы күл»гә ял көннәрендә күңел ачар өчен килүебезне сөйли башладым. Нәп заманы, мәгәр комсомолның бик көчәеп барган чагы — шуның бик тәкъва, бик таләпчән башлап йөрүчеләре, безне оештырып, алып киләләр иде. Кымыздан башка, эчү дә, тәмәке тарту да юк, катгыян тыелган!.. Хәтта берәр егет белән кыз икәү читкәрәк китеп йөрсәләр, аларны түгәрәк уртасына бастырып, нигә сез коллективтан аерыласыз, дип тиргиләр иде. Бөтенебез дә бары тик бергә йөрергә, бергә уйнарга, бергә коенырга тиешбез. Комсомол таләбе әнә шундый иде. Ләкин кызларыбыз малайлар белән бер урында су керергә теләмиләр, шактый читкә китеп, кайчандыр Сусылу чәчен тарап утырган зур таш артына яшеренеп, үзләре генә коеналар иде. Минем бу әкиятемне сабыр гына тыңладылар тагын... Әйдә, сөйләсен, картның бердәнбер юа-

ныгы — үткәннәрне искә төшерү, дигәннәрдер инде эчләреннән генә. Әллә юаныч, әллә сагыш, әллә аяныч — тик мин сөйләгәннәрнең берсе дә инде кайтмый да, кабатланмый да...

Ә мәҗлес бик күңелле генә бара. Сүз белән генә мавыкмыйча, җырга-музыкага да күчтеләр. Безне сыйлаучы кызлар һәм кунак егетләр кара-каршы биеп тә алдылар. Ләкин шулай да Казан кунаклары — бигрәк тә Ренат Харис — китәргә ашыгалар иде. Көн төштән авышты, алда озын юл, бүген кайтып җитәргә кирәк. Кысташып тору булмады — кунаклар соңгы рәхмәтләрен әйтеп, китәргә җыендылар. Монда тукталу аларга, һичшиксез, ошаган булырга тиеш — әнә Римзил Вәлиев тә машинага утырыр алдыннан: «Мин бу «Аслы күл»гә, Зиләне алып, тагын бер киләм әле»,— диде. (Зилә ханым — аның хатыны.) Кунакларыбыз өч машинада күл буйлап кузгалып киттеләр — без кул болгап озатып калдык...

...Мин әлегә монда калдым — Уфага кайтырга кирәк, анда үз эшләрем бар. Бераз юанганнан соң, без дә кузгалырга булдык. Без дигәнем, мин дә, кунакларны озата килгән Башкортстан халык депутаты, профессор Алим Әхәтович... Дәүләкән кешеләре, Әхияр үзенең ханымнары белән биредә калдылар (кунаклардан соң сыйлану дәвам итә әле ул), ә без кара «Волга»да Дәүләкән юлы белән Уфа тарафларына элдердек...

Бүген 1 июль. Минем статусым үзгәрде. Кичәдән үк инде мин Башкортстан кунагы түгел. Үз эшләрем белән килүче гади бер кеше генә. Шулай булгач, миңа да бу «Президент-отель» дигән махсус кунаклар йортыннан каядыр күчәргә кирәктер инде. Хуҗалар үзләре дә моны онытмаганнар икән. Мансур Әюпов үзе миңа шалтыратып әйтте: «Әмирхан агай, бүген Сезне «Агыйдел»гә аерым номерга күчерерләр, шунда теләгән кадәр торыгыз, бернәрсә турында да борчылмагыз»,— диде. Һәм, озак та үтмәде, бер чибәр ханым мине машина белән «Агыйдел»гә илтеп тә куйды. Бер кешелек кенә номер, бөтен нәрсәсе эчендә, телефоны да бар — тагы ни кирәк?! Кунакханәнең шәһәр үзәгендә булуы да минем өчен бик уңай — теләгән җиремә бара алам, теләгән кеше миңа килә ала. Хәзер моның ише кунакханәләрдә номерлар гаять кыйммәт, диләр, ләкин миңа ул хакта «борчылмаска» куштылар. Борчылмасам да, күпме тора икән, дип уйлап куйдым, ләкин сорарга курыктым.

Ә бер-ике көннән Мансур Әнвәрович үзе дә, алдан хәбәр итеп, Уфаның бик атаклы табиб-хирургы, профессор Наил Гайнәтович Гатауллин белән икәү бергә, кичкә та-

бан миңа килделәр. Яшәп яткан җирем белән танышкач, мине түбәнгә алып төштеләр. Ресторанның аулак бер урынында әйбәт кенә сыйланып, күңелле генә сөйләшеп утырдык. Миңа мондый илтифатның сәбәбе — карт язучы булуым өстенә, өчебезнең дә бер үк районнан чыккан кешеләр булуыбыздыр да дип уйлыйм. Мансур Әнвәрович үзе Дәүләкәнгә якын гына Исмәгыйль авылыннан; Наил Гайнәтович исә Чуенчы дигән зур мишәр авылыннан. Мин бу авылны «Соңгы китабым»да телгә алган идем бугай. Чуенчы — ул Башкортстанга шактый зур кешеләрне биргән авыл — Наил Гатауллин шуларның берсе һәм иң зурысы булса кирәк. Әйе, без якташлар, шуның өстенә без фикер ияләре дә... Заман турында, теге яки бу мәсьәләләр хакында фикер алышу безнең өчен үзе бер җан таләбе дияр идем. Дәрәҗә һәм эшләребез бик төрле булуга карамастан, без уртак тел табып, бик ачык, бик иркен сөйләшеп утырдык. Һәм бик мәмнүн булып аерылыштык та.

Шулай да, «Агыйдел»гә күчеп тора башлагач, мин үземнең шактый ук хәлсезләнүемне сиздем. Ике-өч көн машинадан төшмичә озын юллар узуның нәтиҗәсе булса кирәк. Инде менә йөрәк хәлләнсен, куәт тә кайта төшсен өчен күбрәк яткалап торырга туры килә. Ләкин бер көнне дә әрәм итәргә ярамый. Туганнарны күрәсем, кайбер дус-ишләр белән очрашасым бар — Уфага кире борылып кайтуым да шуның өчен генә иде... Кайчан, ничек китү мәсьәләсен дә хәл итәргә кирәк. Кемдер исәбенә монда озак яту да килешми — кунак белән балыкның гомере өч көн, диләр. Кыскасы, мин бер көнемне дә бушка уздырмадым. Телефон бик нык ярдәм итте. Башта туганнарым белән очраштым — мине килеп алдылар. Анам ягыннан бик якын ике туганым Әминә белән Раилә үткән көз һәм аннан элекке көзне вафат булганнар иде. Әлбәттә, мин аларның каберендә булырга тиеш идем. Әминәнең улы Ринат туганым машинасында ерактагы зиратка бардык, каберләре янында булдык, чәчәкләр салдык. Эчемнән генә белгән догамны укыдым: Иннә лиллаһи вә иннә илаһи рәҗигун — Алладан килдек, Аллабызга кайтабыз. Безнең яшәвебез әнә шуңардан гыйбарәт. Киткән чакта сәер бер уй күңелне биләп алды: кабердәгеләр безнең килгәнне гүя белделәр һәм рәхмәтләрен әйтеп калдылар кебек. Бәлки, ул чынлап та шулайдыр... Безнең өчен дә бит алар һаман тере булып сакланалар. Ләкин без җир астында түгел, җир өстендә һаман йөрибез әле... Анам ягыннан бала чактан ук гомер юлын бергә узган якын туганым бары бер Факиһә генә калды.

Атам ягыннан булганнары да әкренләп китә тора, шулай да күбесе, шөкер, исәннәр әле.

Дус-ишләр белән очрашулар да көн саен диярлек булгалап торды. Кайберләре мине үзләренә чакырып алдылар, ә кайберләре үзләре минем номерга килделәр. Билгеле инде, бу очрашулар, гадәттәгечә, чамалы гына сыйлану белән бергә, бик ихлас, бик тансык сөйләшүләр белән үтә торган иде. Мине кызыксындырган бер мәсьәлә — ул да булса Башкортстан татарларының яңа гына булып узган беренче съездына аларның карашы. Әмма карашлар бик төрле икән. Гаҗәп тә түгел, татар үзе дә бик чуар халык бит. Шул ук Башкортстанда әллә ничә төрле: типтәр, мишәр, түбән, казан татары, башкорт булып йөрүче татарлар... Шуңадыр инде берәүләр ул съездга бөтенләй игътибар да итмәгәннәр, икенчеләр, игътибар итсәләр дә, аңардан татарлар өчен бер үзгәреш тә көтмиләр, өченчеләр съездның булуын бик хуплыйлар һәм уңай нәтиҗә дә бирер дип өметләнәләр. Тик съездда булган бер дус кына, бәя-фәлән бирeп тормыйча, «Чебешне көз көне саныйлар» дигән хикмәтле мәкальне генә кабатлады. Мин төрле караштагы дусларның кемнәр икәнен әйтеп тормыйм, тик бик кыска гына үз сүземне әйтергә телим: миңа калса, Башкортстан татарларының беренче съезды уңай бәяләнергә тиеш, чөнки ул һәр ике халыкка да бик кирәк иде. Чын дуслык, татулык һәм тигезлек хакына! Әгәр киләчәкне уйлый белсәк.

Минем китү мәсьәләсе дә ансат кына хәл ителде. Уфадан 7 июльдә тарихи Болгарга һәм Казанга махсус пароход китәчәк икән. Менә шул сәяхәтне оештыручы Марат әфәнде Шәрипов мине дә бик теләп үзләре белән бергә алып китәргә булды. Әйтергә кирәк, Уфа татарларының махсус пароход алып, изге Болгар җиренә барулары беренче тапкыр гына түгел. Аларның бу сәяхәтләре күркәм бер традициягә әйләнде дияргә була. Баручылары да бик мөхтәрәм кешеләр: укытучылар, табиблар, галимнәр, мәдәният хезмәткәрләре, пенсионерлар һәм укучы яшьләр...

Билгеле, мин Марат әфәнденең тәкъдимен бик куанып кабул иттем. Бу кайтуның минем өчен үзенә күрә бер хикмәте дә бар: 1925 елны, 16 яшемдә мин ак пароходның 4 нче класс сәндерәсендә, Агыйдел—Кама буйлап, беренче мәртәбә Казанга килгән идем... Инде менә 72 ел узгач, 88 яшемдә мин ак пароходның 1 нче класс каютасында тагын шул ук елгалар буйлап кайтачакмын. Беренче һәм соңгы мәртәбә (бәлки) бер үк юлны кабатлавым. Самолетлар, машиналар юк чакларда Уфа—Казан

арасын су буйлап күп узарга туры килә иде. Иң күңелле, иң рәхәт юл иде бу. Әмма озак яши торгач, Агыйдел—Кама буйлары минем күз алдымда диярлек бик нык үзгәрде. (Бигрәк тә Каманы буып куйганнан соң.) Су бик күбәйде, ә чын табигый матурлык каядыр читендә, ераклашты. Агыйделнең «Сандугач бугазы» дигән бик тар, гаҗәеп гүзәл, берничә чакрымга сузылган җире бар иде. Шуннан үткәндә, яр буендагы тирәкләрдә сандугачларның «чут-чут» сайраулары каюталарга ишетелә торган иде. Мин көнозын шул җирдән үтүебезне көтеп каранып бардым. Ахырда юлдашларымнан сорашып карадым. Агыйделнең «Сандугач бугазы» дигән җирен күреп тә, ишетеп тә белүче булмады. Юк ул, киткән — мөгаен, су төбенә.

Камадагы ком утрауларның читләрендә нечкә-озын аякларында басып торган торналарны да күреп уза торган идек. Торналар да, башларын кырын салыбрак, безгә карап калалар иде. Инде алар да күптән юкка чыктылар. Торналар кайтып төшәрлек су буйлары калды микән безнең Татарстанда? Кешеләр хәтта судан ераклашты, Казан—Уфа арасында пассажир пароходлары йөрү күптән туктатылды. Үзебезнең су буендагы шәһәрләргә ракета-метеорлар йөрү дә бетерелде. Пристаньнарның күбесе ябылып бетте — Кама—Агыйдел буйлары ничектер бушап, җансызланып калды. Безнеке шикелле ялгыз пароход кына читләре күренмәгән су уртасыннан ашыгып бара да бара. Тугайсыз-болынсыз су буйларының элеккеге матурлыгы да, хозурлыгы да юк шул инде...

Фазыл Туйкинның мондый шигъри юллары гына, сагышлы-моңсу җыр шикелле, хәтерләрдә сакланып калды:

Идел буйларында киң болында,
Җылкыларым утлый чабында;
Оҗмахларың торсын бер ягында
Шул болында йөргән чагымда...

Әмма Тукай исемен йөрткән пароходның үзендә озын юлыбызны бик күңелле, бик матур уздырдык. Җыр күп, музыка күп, төрлечә күңел ачулар, очрашу-сөйләшүләр һаман кабатланып кына торды. Бу җәһәттән безнең бик дәртле, бик эшлекле егетләребез — Марат Шәрипов белән Рәүф Идрисов — бик зур осталык һәм уңганлык күрсәтә белделәр.

Пароходта төрле яшьтәге могтәбәр кешеләрнең булуын әйткән идем инде. Тик шуларның берсен генә атыйсым килә, чөнки каюталарыбызның ишекләре кара-каршы гына иде, аннары юл буе гел бер өстәлдә тукланып

бардык. Бу — Фәридә ханым Кудашева, күптәнге танышым һәм бик хөрмәт иткән кешем.

...Унынчы июльнең иртәсендә, ниһаять, Болгарга килеп җиттек. Изге Болгар туфрагында булу — бу сәфәрнең төп максаты иде. Пароходтан төшмичә калган берәү дә булмагандыр. Борылмалы баскычтан төркем-төркем югары күтәрелдек. Көн бик әйбәт иде. Яшел чирәмле иркен мәйданындагы Бөек Болгардан калган сирәк корылмаларны яки шуларның кайбер калдыкларын халык ашыкмыйча гына карап йөри, таныша... Кайберәүләр утырып дога да кылалар. Болгарга килү татар кешесе өчен коры бер кызыксыну гына түгел, минемчә. Монда күргән-ишеткәннәрдән кем икәнеңне аңлау, рухи куәт алу һәм иман яңарту да була, дияр идем. Татарларның еракеераклардан бу изге җиргә килүләре дә иң элек шуның өчен булса кирәк.

...Эсседә йөреп әлсери башлагач, без ике карт — мин дә Равил әфәнде Үтәбәй — пароходка алданрак төшеп киттек. Кайткач, аның карчыгы Маһинур апа, безгә чәй кайнатып, палубага чыгарды. Утырып чәй эчкән чакта, Равил әфәнде, тынычлыгын җуеп, урыныннан тора да китә, тора да китә. Сәбәбе: каршыбызда гына Болгар хәрабәләре уртасында зур чиркәү басып тора. Борынгы ислам җиренә килүчеләргә иң элек ерактан ук шул чиркәү күренә. «Ник шуны тоталар, ник сүтеп кенә ташламыйлар шул ләгънәтне?» — дип өтәләнә Үтәбәй абыз... Чыннан да, татарның кабер ташлары өстенә салынган чиркәү күпләрнең җанын сыкрата торгандыр. Дөрес, чиркәүне хәзер музейга әйләндергәннәр, аның эчендә Болгар тарихы, тик шулай да очындагы тәресен кисеп төшерү, мотлак, кирәктер...

Төш вакытындарак әллә кайдан гына ялгыз болыт килеп чыкты да кинәт кенә эре яңгырын тыпырдатып коеп китте. Болгарда йөрүчеләр йөгерә-йөгерә пароходка кайттылар. Ә кичкә табан инде без бу тарихи урыннан тарихи Казаныбызга кузгалып киттек. Озын, онытылмас сәфәребезнең соңгы кыска өлеше...

Баксаң, Казанга без таң вакытында ук килеп җиткәнбез икән, тик, пристаньга кермичә, су уртасында озак кына туктап торганбыз. Иртәнге аштан соң, сәгать 9ларда гына пароходтан төштек. Казан инде һәрбер татар кешесен үзенә тартып торган кала. Халык ярга чыгу белән төрле якка тарала да башлады: туганнарына, дус-ишләренә, магазиннарга... Ә беренче килүчеләр, автобусларга утырып, шәһәр белән танышырга киттеләр...

Мин инде үз өемә кайткан кеше буларак, кайбер якын

дусларны — Фәридә ханымны, Марат һәм Рәүф туганнарны хатын, бала-чагалары белән үземә төшке ашка чакырдым. Килделәр, күңелле генә ашап-эчеп утырдык. Фәридә ханым кыстамыйча гына җырлап та безне бик сөендерде. Билгеле, вакыт үткәне сизелми дә калды — сәгать алтыда инде алар кире Уфага кузгалырга тиешләр.

Боларны язуым мактаныр өчен түгел — безнең гаять кырыс заманда бергә йөрү-аралашу бик тансык булганга күрә генә. Минем инде истәлекләр белән генә яши торган чагым. Укучым моны, шәт, аңлар һәм гаеп итмәс дип ышанам.

### Бирим дисә колына...

...Мине Алма-Атыда якын туганым Зөләйха көтә. Баруны быелдан да калдырмаска кирәк... Икебез дә картлыкның чигенә җитеп киләбез.

Әмма баруның хәл итәсе шактый авыр мәсьәләләре бар. Казакъстан хәзер чит мәмләкәт, акчасы да башка, юлы да ерак... Рәсми чакыру, виза кебек нәрсәләр кирәкмәсә дә, бару-кайту кимендә ике-өч миллионга төшәчәк. Пенсионер кесәсе күтәрә алырлык түгел... (Совет заманында айлык пенсия Алма-Атыга барып кайтырга җитә торган иде.) Зөләйха да мәсьәләнең шушы якларын уйлап булса кирәк, бер хатында миңа: «Быел көз казакълар Мохтар Ауэзовның 100 еллыгын бәйрәм итәләр, син шул бәйрәмгә кунак булып килергә тырыш»,— дип, кызыклы гына киңәшен язды... Аның бу киңәше мине чынлап та кызыксындырды.

...Мохтар Ауэзов — казакъларның бик зур кешесе — классик язучылары, академик галимнәре. Совет заманында, бигрәк тә сугыштан соң, һәрбер милли әдәбиятта берләнбер кеше иң беренче урынга куелды. (Безнең татарда гына берәү дә «иң беренче» була алмады. Югыйсә лаеклы талантлар бар иде.) Казакъларда иң беренче урынны биләүче Мохтар Ауэзов иде. Әйтергә кирәк, бик хаклы рәвештә. Чөнки эше-иҗаты шуңа лаек иде. Аеруча Абай турындагы романнары чыкканнан соң, аның абруе бөтен Союз күләмендә бик нык күтәрелде... Һәм менә миңа да шул зат иясе белән Алма-Атыда 1957 елны танышырга, чакыруы буенча өендә булырга, сөйләшеп утырырга туры килгән иде. Ул елны аның 60 еллыгын бәйрәм итәргә җыеналар иде. Мохтар ага сөйләшү ахырында миңа: «Вакытыгыз булса, көтегез, кунагым булырсыз»,— дип тә әйткән иде. Ихлас әйткәндер дип уйлыйм, ләкин мин аның өчен бик яңа кеше, юбилейга чакыруын берсүзсез

кабул итү минем тарафтан тыйнаксызлык булыр иде. Аннары сәяхәтем дә моннан Ташкентка бару иде. Тиздән китәсемне әйтеп, чын күңелдән рәхмәтемне белдереп, саубуллашып, мин Мохтар агадан чыгып киттем... Һәм чыгып китү белән, урам буйлап сузылган бакчаның бер эскәмиясенә утырып, бу тарихи очрашуны блокнотыма бик кыска гына язып та куйдым.

...Ул вакыйгадан соң инде 40 ел үтеп тә киткән. Быел, сентябрь ахырында, әнә 100 еллыгын бәйрәм итәчәкләр. Бу юлы мәрхүмнең бәйрәмендә булу миңа бик тә ярар иде (Мохтар Ауэзов 60 еллыгын үткәргәннән соң, 4 кенә ел яшәп калды). Бездә Мохтар аганы исән чагында күрүчеләрдән Гомәр Бәширов та мин генәдер, мөгаен. (Гомәр абзый аның белән күп очрашкан булырга тиеш — чакыру да иң элек аңа килергә тиеш. Тик бара алуы бик икеле.) Ә мин инде Алма-Атыга барырга күптән җыенып йөрим. Баруым да казакъларның әнә шул зур бәйрәмнәренә туры килә ләбаса! Ул тантанага күп илләрдән зур кунаклар чакырылачак, әлбәттә. Мин үзем андый чакыру көтмим, билгеле. Әмма бездән дә кемнәрнедер чакырырлар, мотлак. Казакъларның татарларга мөнәсәбәтләре начар түгел. Казакъ язучылары белән очрашу-аралашулар элек булгалап тора иде. (Кызганыч ки, мине белүчеләр калмады диярлек.) Хәзер дә аралашулар дәвам итә бугай... Ике президент арасында мөнәсәбәт тә яхшы булса кирәк. Һәрхәлдә, «олы туй»га чакыру килмичә калмас дип уйлыйм. Тик кая, кемгә, ничә кешегә?..

Шуны беләсем килде. Зур түрәләрне борчырга яратмыйм, ишекләренең кайсы якка ачылганын да белмим. Ә безнең бит әле үзебезнең «берлек» дигән нәрсәбез дә бар.

Берлек җитәкчесе Ринат Мөхәммәдиевкә шалтыратырга булдым. Ул — читтәге һәртөрле тантаналарга да безнең исемнән даими йөреп торучы...

— Казакълардан Ауэзовның 100 еллыгына чакыру килмәдеме?— дип сорадым.

— Килде,— диде Ринат Сафиевич.

— Кемнәргә?

— Минем исемгә...

— Сиңа гына?

— Әйе, миңа гына.

Мәсьәлә бик тиз ачыкланды бит әле — сусын басылмагандай, сүз дә җитмичә калды.

— Казаннан тагын баручылар бардыр бит?

— Анысын мин белмим,— диде Ринат.

Рәиснең кыска гына җавапларыннан сөйләшүнең кирәксезлеген аңладым. Гомумән, Ринат әфәнде соңгы вакытларда минем белән сүзен әнә шулай кыска тота башлады. Беренче генә сынавым түгел. Күрәсең, кирәгем беткәндер дип уйларга мәҗбүрмен.

Шушы сөйләшүдән соң, мин Алма-Атыга кемнәр баруы белән кызыксынуымны кырт кистем. Кеше үз табигатенә ят эш белән шөгыльләнмәскә тиеш. Ә менә Мохтар агай турында кыска гына истәлекне язачакмын. Бусы — минем эш.

...Алма-Атыга бару минем өчен хәл ителгән мәсьәлә. Бик борчыган чыгым мәсьәләсе дә көтмәгәндә генә хәл ителде. Мин бит әле сугыш ветераны. Закон буенча түләүсез барырга да хакым бар. Моның өчен безгә транспортның бөтен төрләре күрсәтелгән махсус талоннар да бирелгән иде. Элеккерәк елларда Советлар Союзының теләсә кайсы почмагына елына бер тапкыр бушлай барып кайтып була иде. Тик ни гаҗәп, мин шул хокукымны онытып җибәргәнмен. Ерак юлларга күптән чыгып йөрмәгәнгә күрәдер инде... (Аннары дөньясы да әллә нишләп бетте бит — мулла кушкан исемеңне дә онытырсың.)

Ярый әле үзем кебек бер ветеран, очрашып сөйләшкәндә, талоннар мәсьәләсен искә төшерде. Срогы чыккан иске талоннар урынына быел яңаларын бирәләр икән. Райсобеска барып алырга кирәк, диде. Үзе ул яңа талоннар белән Ташкент якларыннан бушка йөреп тә кайткан икән инде. Минем ише дөньяны төзәтмәкче булып, башын чүп-чар белән тутырган язучы әфәндегә «права»сын онытмаган карт ветеранның киңәше бик тә ярап куйды.

...Тиз арада иске талоннарны һәм документларымны алып, мин дә Райсобеска ашыктым. Ветераннарны кабул итүче мөлаем гына бер кыз кәгазьләремне карап чыкты да яңа талоннарны берсүзсез биреп тә җибәрде. Бүлмәдән чыккач, шунда ук яңа талоннарны тикшереп карадым: алар арасында «Бесплатно, воздушный транспорт» дигәне дә бар иде. Булды болай булгач! Очабыз гына, боерган булса!..

Мин инде самолет хәлләрен белешкән дә идем. Быел Казаннан Алма-Атыга туры самолет бар икән. (Моңарчы булганы юк иде.) Атнага бер тапкыр, җомга көннәрендә оча. Алдагы җомгалар 19ы вә 26 сентябрьгә туры килә. Шушы ике число арасында Ауэзов көннәре дә башлана бугай. Мин 19ында очарга булдым.

...Мохтар агай турында хатирәмне язган идем — ул

китәсе көнне генә «Ватаным Татарстан»да басылып та чыкты. Гәзитне өемә китереп тә бирделәр.

Инде соңгы эш — барып билет аласы гына калды. 17сендә паспортым белән яңа талоннарны алып, иске аэропортка киттем. Шундагы кассаларның берсенә тукталып, Алма-Атыга билет сорадым һәм паспорт белән талоннарны бирдем. Ике кат тәрәзәле кассада утыручы ханым талоннарымны ашыкмыйча гына карады да сез боларны дежурный администраторга күрсәтегез әле, диде. Ни өчен? Шулай кирәк, имеш. Администратор тәрәзәсенә киттем. Бу тәрәзәдә утыручы ханым татар икән. Үз кешебез, гадәттә, ышаныч уята. Мин аңа талоннарымны суздым. Алма-Атыга билет алмакчы идем, кассир ни өчендер сезгә күрсәтергә кушты, дидем. Ханым талоннарны алып карады да: «Сез бераз көтеп торыгыз»,— дип, каядыр чыгып китте. Көтелмәгән бу тоткарлык кәефемне боза башлады. Әйбәт кенә башланган эш берәр нәрсәгә сөртенмичә калмый. Бездә генә мондый «тәртип»... «Согласовать» итәргә киттеме соң?! Ниһаять, ханым килеп керде бүлмәсенә. Миңа карамыйча гына тирән итеп сулап куйды, аннары иплэп кенә әйтте:

— Абый, сезнең талоннарыгыз Россия өчен генә, СНГ илләренә ярамый шул...

— Ник ярамый, элекке талоннар ярый иде бит,— дидем мин, бик гаҗәпләнеп.

— Былтыр ярый иде, ә быел юк инде, яңа талоннар кирәк.

— Яңалары кулыгызда ич!

Кычкырыбрак әйттем бугай, ханым ничектер кызара төшкәндәй булды.

— Абый, аңлагыз, болары Россия шәһәрләре өчен генә, читтәге шәһәрләргә ярамый.

— Нишләргә соң миңа?

— СНГ өчен аерым талоннар бирергә тиешләр. Сезгә ни өчен бирмәгәннәрдер... Түләп алырга туры киләчәк, абый! — диде ханым һәм талоннарымны миңа сузды.

Мин сүзсез калдым. Бер мәлгә уйлау сәләтемне югалткандай булдым. Талоннарны тоткан килеш тәрәзә яныннан китә алмыйча торам.

Ханымда азрак кызгану уянды булса кирәк, кешеләрчә генә миңа киңәш бирде:

— Сез тагын барып карагыз әле, бәлки, бирергә оныткандыр...

Мин исемә килдем: әйе, бик дөрес, барырга кирәк, минем башка чарам юк. Рәхмәтемне әйттем дә, кинәт кубып, автобус тукталышына ашыктым. Шунда ук су-

лышым кысылды, ләкин адымны әкренәйтеп тормадым, үтәр әле дидем. Беренче тапкыр гына түгел. Озак та тормыйча автобуска утырып китеп тә бардым. Йөрәк тә тынычланды. Хәлемә керә белә ул минем йөрәк!..

Менә мин яңадан собеста, әлеге мөлаем кыз янында. Ни өчен килүемне сабыр гына аңлаттым.

— СНГ талоннары бездә хәзергә юк шул әле,— диде кыз.

— Ни өчен юк соң ул?

— Ул талоннарга аерым түләргә кирәк, ә безнең министерствоның түләп алырга акчасы юк.

— Элек бит бөтен җиргә бер талон ярый иде.

— Ә хәзер аердылар. Быелдан Россиянеке үзенә, СНГныкы үзенә.

— Кайчан булыр соң ул каһәр суккан СНГныкы?

— Министерствоның түләп алырга акчасы булгач.

Сөйләшүе авыр иде. Һәм дәвам итүнең мәгънәсе дә юк иде. Менә шулай, бер исерекнең Советлар Союзын таратып җибәрүе, ә Русиянең хәерчелек сазлыгына кереп батуы тагын безгә, карт солдатларга китереп сукты... Һәм без, фашизмны тар-мар итүчеләр, властьны кулларына эләктергән президентлар алдында көчсез, бөтенләй көчсез. Үзебезне яклап берни дә эшли алмыйбыз шул инде.

...Кузгалырга кирәк иде. Иң ахырдан гына мин кыздан иске талоннарны биреп торуын сорадым. Шулар белән тагын классларга барып карамакчы булдым. (Искеләрнең берсен дә былтыр файдаланырга туры килмәгән иде.)

Яңадан әлеге ханымның тәрәзәсенә бардым... Талоннарымның яңасын да, искесен дә алып, ханым каядыр киткән булды. Бераздан килеп, йомшак кына әйтте:

— Юк шул, абый, булмый. Искеләрнең срогы чыккан, яңалары — ярамый.

Әлбәттә, әлсерәп килеп йөрүнең һич тә кирәге юк иде. Шуны белә торып, өстерәлеп килгән булдым. Тавык акылы да калмаган башта. Стресс галәмәте бу.

Аякларым мине туры гына өйгә алып кайттылар. Уйлый алуым да әкренләп кайтты кебек. Моның ише каты алданулар аз булмады безнең гомердә. Стресс та беренче генә түгел — йөз дә беренчедер кимендә. Алдану минем теләгемне аз гына да какшатмады, киресенчә, ныгытты гына. Китәм, ике миллионны туда и обратны түлим дә китәм, боерган булса. «Демократ»ларның талавына да, борчагა ияләшкән эт кебек, ияләштек инде.

Бәйрәмгә безнең җитәкчеләрдән, Ринаттан башка, та-

гын кемдер бара торгандыр мотлак. Абай юбилеена Президент үзе шул ук Ринатны ияртеп барган иде. Бу юлы да хакимияттән кемдер барырга тиеш — Ауэзов бәйрәме казакълар өчен Абайныкыннан бер дә ким түгелдер, минемчә. Әгәр хуҗалардан берәрсе барса, ул инде аерым махсус самолетта оча торгандыр. Яшерәсем килми, мәсьәләнең шушы ягы мине кызыксындыра иде.

...Өйгә кайткач та, мин Зиннур Мансуровка шалтыраттым. Безнең үзара мөнәсәбәт күптән бик әйбәт, дусларча. «Мәдәни җомга»ның мөхәррире буларак, ул күп нәрсәдән хәбәрдар, билгеле. Аннары җәй көне үк әле аның белән Мохтар Ауэзов еллыгына бару турында сөйләшү дә булган иде. «Икәү бергә барырбыз, Әмирхан абый!» — дип әйткән иде ул шул чакта. Шаяртып кына түгел, ничектер ышанып әйткән иде. Шалтыраткач, шуны да искә төшереп, мин аңардан сорадым:

— Зиннур, казакълардан сиңа чакыру килмәдеме?

— Юк, Әмирхан абый.

— Ауэзов юбилеена язучылардан Ринат бара, ә хакимияттән кем бара икән, белмисеңме?

— Ринат әйтмәдемени?

— Белмим, диде.

Аз гына тынып торганнан соң Зиннур:

— Алайса, син, Әмирхан абый, мәдәният министры Марсель Мәзһәровичка шалтыратып кара әле. Ул бара бугай, үзе белән бер төркем артистлар да алып бара дип ишеткән идем.

Ләкин мин икеләнеп калдым. Бер-беребезне бик күптән белсәк тә, мөхтәрәм министр Таишев белән якыннан аралашканыбыз юк. Минем шалтыратуым аны бик гаҗәпләндермәс микән? Моңарчы бит минем аңа бер тапкыр да мөрәҗәгать иткәнем булмады. Әмма ярты юлда тукталып каласым килмәде — тәвәккәлләп, шалтыратырга булдым.

...Күп очракта министрлар үз урыннарында булмый торганнар иде. Ләкин Марсель Мәзһәрович үзендә иде — шунда ук телефонны алды. Мин кем икәнемне әйттем, исәнләштек. Гаҗәпләнүен сизмәдем, шулай да сүземне кыска тотарга тырыштым:

— Марсель Мәзһәрович, ишетүемә караганда, Сез Мохтар Ауэзовның 100 еллыгына барырга җыенасыз икән, үзегез белән концерт группасы да алып барасыз бугай...

— Юк, мин үзем генә барам,— диде ул тиз генә.

— Алайса, гафу итегез!

— Эш нәрсәдә соң, Әмирхан абый?

Минем өчен иң читен сорау иде бу. Һәм җавап бир-

мичә калуы да мөмкин түгел иде. Мин бит министр белән сөйләшәм — ни өчен шалтыратуымны ул белергә тиештер ләбаса!.. Кыенсынып, ык-мык итебрәк булса да, Ауэзов тантанасына үземнең дә барасы килүемне аңлатырга тырыштым.

— Аңладым,— диде министр, гадәтенчә тиз генә, һәм шунда ук сорап та куйды.— Казаннан Алма-Атыга билет күпме тора?

— Баруы кайтуы ике миллион,— дидем, ни өчен соравын абайлап та бетермичә.

— Хәзер бухгалтериягә әйтәм, бүген үк сезгә ике миллионны илтерләр.

Бу ни бу — мин тәмам аптырадым да калдым.

— Туктагыз әле, Марсель әфәнде! — дидем кабаланып, аннары: «Мин бит, ни бит...» — дип, нидер әйтергә азаплана башлагач, министр сүземне бүлеп:

— Борчылмагыз, Әмирхан абый! — диде ашыккандай.— Квартирагыз ничәнче әле сезнең?

— Сигезенче...

— Көтегез! — диде дә трубкасын да куйды. Минем көчкә генә рәхмәт диюемне дә ишетмәде бугай. Эше бик тыгыз булса кирәк. Ә квартирамны соравының сәбәбе — без бит бер үк йортта торабыз.

Инде тагы да шаккатырганы — 30–40 минут үттеме микән, тулы гына бер ханым, машинада килеп, минем өстәлемә ике миллионны чыгарып та салды. Миңа бары әзер кәгазьгә кул гына куярга туры килде. Менә ниләр булып куя безнең бу әкәмәт заманда!..

Әйтәсе дә түгел, мәдәният министрының һич көтмәгәндә мондый изгелек эшләве миндә бик күп каршылыклы уйлар тудырды. Шул уйларга җавап табып, ничектер тынычланасы килә иде. Иң элек мин безнең хакимияттәге тәртип-низамнарны бөтенләй белмим икән. Үзе үтенеп сорамаган кешегә министрның акча бирергә хакы бардыр дигән уй ник бер башыма кереп чыксын ки!.. Акчасы булса, хакы да бар икән бит! Әмма ни өчен миңа карата мондый юмартлык? Мәдәният министрлыгы белән минем бер төрле дә бәйләнешем юк бит. Ләкин шуңа карамастан министрыбыз карт язучыга әнә ничек ярдәм кулын сузды...

Ә минем бик кешелекле бу ярдәмне кабул итәргә хакым бар идеме соң?! Җанны иң борчыганы шушы сорау. Җитмәсә, карчыгым Нәҗия дә бу акчаны алмаска кирәк иде дип тора. Әмма, күрдегез ич, мин бит мөхтәрәм министрга акча сорап мөрәҗәгать итмәдем. Әгәр Социаль тәэминат минситрлыгы мине түләүсез барудан мәхрүм

итмәсә, мәдәният министрына шалтыратуның һич тә кирәге булмас иде. Бер үк хөкүмәтнең ике министрлыгы мине шушы хәлгә куйды: берсе закон буенча тиешлесен бирмәде, икенчесе сорамасам да, тотты да бирде. Йә, минем ни гаебем бар?!

...Озын сүзнең кыскасы, шул ике пачка акча белән кассага бардым да Алма-Атыга очар өчен билет алып кайттым. Ерак сәфәрдән исән-сау кайтып, шактый вакыт узгач, миңа ике миллионны рәсмиләштерү өчен кечкенә генә хисап бирергә туры килде. Шул чакта министрлыкның бухгалтериясенә, сездән алган акчаны йә өлешчә, йә тулысынча кайтарырга мин әзер, дип гариза да яздым. Министрның үзенә дә бу хакта әйттем. Миңа тагын борчылмаска куштылар. Рәхмәт инде үзләренә. Ихлас күңелдән...

## Жебек Жолы

Бу — Алма-Атыдагы Зөләйхалар торган урам исеме. Элек ул М.Горький исемендә иде. Казакъстан бәйсез дәүләткә әйләнгәч, Горькийны ташлап, казакъча исем биргәннәр. Зөләйханың хатлары миңа әнә шул Жебек Жолыдан килә башлады. Ләкин бу сәер исемнең мәгънәсенә төшенә алмыйча йөдәдем: кем ул яки нәрсә ул — Жебек Жолы? Казакъның сөйләшендә яки язуында шул «ж» авазының бик күп булуы аерым сүзләрне аңлауны шактый ук читенләштерә. Уртак сүзләрне генә тиз аңлап була: без дә, мәсәлән, үзебездә «язучы», ә аларда инде «жазушы», Алма-Ата да хәзер саф казакъча Алматы дип йөртелә.

Казан—Алма-Аты арасы ерак, вакыт аермасы да 3 сәгать бугай. Казаннан көн уртасында күтәрелгән идек, өч сәгать ярым әйбәт кенә очып, Алма-Атыга барып төшкәндә, кич иде инде. Вакыт күпме булгандыр — белмим, еракка очканда аның исәбен югалтасың.

Аэропортта мине Зөләйханың улы Риель каршы алды. Менә бик әйбәт, югыйсә мин, Зөләйха аңа хәбәр итәргә өлгердеме икән, дип борчылыбрак килгән идем. (Алар аерым яшиләр.) Яктырып, куанып күрештек. Шунда ук кулымнан әйберләремне алды, хәл-әхвәлебезне кыска гына сораша-сораша, мәйданга чыктык. Самолеттан төшүчеләрне көтеп торучы машиналар монда күп иде. Шуларның берсе белән Риель тиз генә сөйләште дә утырып китеп тә бардык. Кичә генә әле мин Алма-Атыга китә алмыйм, ахрысы, дип ут йоткан идем, бүген инде менә ике яклап та төз, биек топольләр тезелеп киткән тигез

юл буйлап аңа таба җилдерәм генә — кызык та соң безнең заманның кеше белән шаяруы!..

...Барышлый гына булса да сезне туганым Риель белән әзрәк таныштырыйм әле. Ул университет тәмамлаган, фән кандидаты. Күп еллар үзе дә югары уку йортларында укытты, хәзер исә пенсиядә. Атасы кебек эре сөякле, озын буйлы таза кеше. Җитмеш яшенә җитеп килә инде. Ә мин бит аның 4–5 яшьлек чагын да беләм. Һай, бу гомерләр!.. Бала картка әйләнә, әмма мин аны карт итеп күрмим әле. Атасы — Шәрәфетдин, анасы — Зөләйха, үзе менә... Риель. Нинди исем, кайдан тапканнар — шуны сорашып белә алганым юк. Без — татарлар балаларыбызга чит-ят исемнәр кушуда барлык халыкларны да уздырдык бугай... Бу шаукымнан шәһәр халкы гына түгел, иң караңгы авыллардагы агай-апалар да читтә калмадылар. Аңламыйча-белмичә нинди генә исемнәр кушып бетермәделәр.

...Шәһәргә килеп керүебезне монда ачык кына күреп булмый диярлек. Борылмыйча-нитмичә барабыз да барабыз. Тирә-ягыма каранам — озын урам таныш кебек.

— Риель, бу сезнең урам түгелме соң?

— Безнең урам.

— Элек Горький исемендә иде бит...

— Ә хәзер — Жебек Жолы!

— Нәрсә соң ул Жебек Жолы?

— Ефәк Юлы!

Һай, Аллам! Күпме уйланып та белә алмаганмын шуны, миңрәү баш! Казакълардан оят... Димәк, кайчандыр Кытайдан ефәк ташучы кәрван шушы җирләрдән узган икән ләбаса! Үзәк урамнарның берсенә борынгы тарихи исемне кушып, казакълар бик дөрес эшләгәннәр.

Инде менә Жебек Жолы урамындагы 60 нчы йортка килеп тә җиттек. Машинадан төштек. Сугыштан соң ук галимнәр өчен махсус салынган йортның өченче катына күтәреләбез. Ишекне ачып кергәч, коридор үтәсе бар...

Зөләйха мине зур гына залда аягүрә каршы алды. Ике бик якын туганның очрашуын тасвирлау өчен сүз табуы бик читен... Кирәк микән сүз мондый чакта... Кем кичермәгән мондый мизгелне... Кочаклашып күрештек. Аннары утырыштык. Сүзсез генә, әллә еларга, әллә елмаерга җыенгандай, бер-беребезгә карап тордык, әмма күз яшьләребезне тыя алдык. Бары тик шуннан соң гына, исебезгә килеп, хәрәкәтләнә башладык. Зөләйха шикелле үк якын туганым Бибинурның улы Бари да монда икән. Бер читтә сүзсез генә басып тора. Бари ул гаять тыйнак егет, күрешергә дә кыймыйча тик кенә

тора бирә. Әнисе Бибинур белән сирәк очрашабыз — яшәве монда түгел, Талдыкурган өлкәсендә, бөтен гомерен шунда укытучы булып уздырды.

...Зал уртасында озынча түгәрәк, зур таза өстәл. Зөләйха, көчкә генә йөрсә дә, без кайтуга мул итеп табынын әзерләп куйган. Аның кулы аш-суга бик юмарт — өстәл төрле сыйлар белән туп-тулы. Бер карау белән исемә төште: ире Шәрәфетдин мәрхүм үзе дә сыйланырга, кешене дә сыйларга бик ярата иде. Аның белән бу өстәл янында бик тәмләп ашап-эчеп утырган чакларыбыз булды безнең. Хәзер инде аның урынында Риель. Утырышкач, коньякны да ул ачты. Мин генә түгел, Зөләйха да бу шәрабтан әзрәк авыз итте. Шулай ашап-эчкәләп, ниләр турында озак кына сөйләшеп утыруыбызны хәзергә калдырып торам — атна буена барган сөйләшүләребезнең кирәк кадәресен генә соңыннан аерым язарга туры киләчәк. Бүген исә чәй эчә-эчә сөйләшүдән кайчан туктаганбыздыр — әйтә дә алмыйм. Аерым бүлмәдә әзерләнгән урынга мин кереп яткач та, Зөләйха бераз янымда утырды. Ике ел буена борчылып көткән очрашуның бик тансык беренче киче бит бу... Кайда инде монда йокы кайгысы. Ә шулай да арып килгән морзага вакыттыр инде. Ахырда миңа хәерле йокы теләделәр.

...Мин уянганда, хуҗаларым күптән торганнар, иртәнге чәйне дә өлгерткәннәр. Алар вакыты белән сәгать ун, имеш! Ә бездә җиде генә бит әле. Җайлашырга кирәктер инде, ләкин мин сәгатемне күчереп тормадым — бер атна өчен генә.

Иртәнге чәйне кайнар пәрәмәч белән ашыкмыйча гына эчкәннән соң, без Риель белән базарга чыгып керергә булдык. Тик башта ук әйтеп китәсем килә: Зөләйха сыңар аякта гына йөрсә дә (бер аягына баса алмый ул), һәр көнне иртәнге чәйгә дә таба ашы өлгертте, төшке ашны да төрлечә итеп үзе пешерде. Риель официант шикелле ташып кына торды.

Алма-Атының иң зур үзәк базары аларга якын гына. Базар капкасына җиткәнче үк урам буйлап тезелеп киткән сәүдә «нокталары» башлана. Ниләр генә юк монда... Ләкин безгә азык-төлек кирәк — анысы базар эчендә. Әйтергә кирәк, Шәрык базарлары гаять бай һәм шаушулы булуы белән аерылып тора. Миңа Ташкент, Сәмәрканд, Маргилан базарлары яхшы таныш. Совет заманында да аларда азык-төлек тулып ята торган иде. Алма-Аты базары да шундыйларның берсе — җаның теләгән бөтен нәрсә бар монда...

Мәгълүм ки, бәйсез Казакъстанның үз акчасы — тәңгә

(дөрес язсам). Урыс акчасы монда йөрми. Шуңа күрә мин базарга керер алдыннан яңа акча белән ике йөз рубльне көчләп диярлек Риельгә тоттырдым. Ул шунда ук алыштыру пунктларының берсендә рубльне тәнгәгә әйләндерде. Бу эш бирелә яхшы куелган.

Базарга кергәч, иң элек ит павильонына юнәлдек. Мәйдан кадәр павильон эчендә һәр малның үз рәте — сарыкныкы, сыерныкы, җылкыныкы... Шушы соңгысы мине аеруча кызыксындырды. Җылкының итен генә түгел, тутырган казылыгын да  саталар икән. Казакъның казылыгын авыз иткәнем бар — телеңне йотарлык! Дөрес, безнең үзебездә дә, башкортта да казылык була торган иде, әмма берсе дә казакъныкына җитми, минемчә... Әзер казылыклар киртәләрдә асылынып тора. Әгәр әзерен алырга теләмәсәң, рәхим ит, шунда ук яңасын үз алдыңда тутырып бирәләр: итен, маен, башка кирәкләрен дә үзең сайлыйсың. Һәммәсе алдыңда ята. Мин инде кайтып киткәндә берәр «бөят»не* тутыртып алырга кирәк булыр дип эчемнән генә уйлап та куйдым.

...Безгә хәзер итләрнең төрлесен алырга кирәк иде. Рәтләр буе йөреп, сыер, сарык, җылкы итләрен алдык. Бәяләр, тәнгәне рубльгә әйләндерсәң, бездәге белән бер чама шикелле... Монда эшне бетергәч, җиләк-җимеш, яшелчәләр рәтенә күчтек. Җаның ни тели, һәммәсе бар кебек. Ләкин мине ике нәрсә гаҗәпләндерде: Алма-Атының куш йодрык хәтле, хуш исле, мәшһүр апорт алмалары юк, күренми иде. Нигә юк, дип, Риельдан сорыйм. Ник булмасын, әнә алар, ди Риель, бер төрле гадәти вак алмаларны күрсәтеп. Апорт андый булмый иде бит, дим. Хәзер шундыйлар гына, ди юлдашым. Мәшһүр алманың тамырын корыттылар микәнни, дип уйлап куйдым эчемнән генә. Ләкин күптән ишеткәнем исемә төште: даны дөньяга таралган Америка бае Рокфеллер, махсус самолет җибәреп, бездән үзенә гел генә Чарджоу кавынын, апорт алмасын, башкорт балын кайтарта икән. Бәлки, мәшһүр алма да читкә китеп бетә торгандыр. Зөләйха әйтә, бездә хәзер эчә торган суны да чит ил фирмаларына саталар, ди. Су өчен акчаны да шуларга түлибез, ди...

Икенче бик гаҗәпләндергәне — шушы үзәк зур базарда карбыз-кавынның бөтенләй булмавы. Бездә бит тулып ята, ә монда юк кына бит. Эзли-эзли базарның читенә барып чыктык. Шунда гына берәүнең кул арбасына салып китергән сабый башы хәтле генә карбызларын күр-

---

* *Бөят* — камытның эчке ягындагы йомшак әйләнәсе. Русча — подхомутник.— *Ә.Е.*

дек. Хикмәт нәрсәдә икән соң? Мал куып йөргән казакъ үзе кавын-карбыз үстерергә өйрәнмәгән, күрәсең, ә күршесе Үзбәкстан бу нигъмәтләрне казакъ юлдашына бирмичә, бөтенесен Русиягә җибәреп ята, ахрысы, дип уйларга туры килә. Сентябрь ахырында, Җәнүбтәге кала базарында кавын-карбызның бөтенләй булмавы, икътисади сәясәтнең монда да әллә нинди гайре табигый булуын күрсәтә түгелме соң? Хәер, кечкенә бер мисалдан бик зур нәтиҗә ясамыйча торыйк әле.

Ярый, җиткән, бик кирәкләре белән сумкаларыбызны тутырдык — инде өйгә таба атларга вакыт...

Бүген — шимбә, иртәгә — якшәмбе, монда да ял көннәре. Мохтар агайның 100 еллыгы турында белешеп йөрисе юк — димәк, минем өчен дә буш көн.

...Сөйләшүебез көнозын диярлек дәвам итә. Зөләйха аш-су әзерләгәндә генә өзелеп тора да тагын ялганып китә. Күбрәк ул сөйли, мин тыңлыйм гына. Атналар буена диярлек шулай барды.

Ике карт туганның, очрашкач, сүзләре үткәннәрне күбрәк искә төшерүдән башлана. Бу бик табигый... Ә Зөләйха өчен җан таләбе дә дияр идем. Картлыкка ияреп ялгызлык килә. Өеннән беркая чыга алмыйча яткан Зөләйха бу ялгызлыкны аеруча нык татый, билгеле. Шуңадыр инде ул бөтен күргән-кичергәннәрен миңа сөйли дә сөйли. Әмма бу сагынып сөйләү түгел, бу — сыкранып, әрнеп сөйләү иде...

Хикмәт шунда ки, 1930 елның октябрендә аның атасы Нигъмәтулла дәдәкәйне Уфага алып китеп, төрмәдә күпмедер ябып тотканнан соң, судсыз-нисез, «тройка» карары белән генә чыгарып аталар. Әлбәттә, һичбер гаепсезгә... Билгеле булганча, колхозлаштыру вакытында атылган, сөрелгәннәрнең һәммәсен дә соңыннан акладылар. Әмма кешене башта нахакка үтереп, аннары акланган булуы гына авыр газап-нужага дучар ителгән хатыны һәм балаларының йөрәгендәге тирән яраны төзәтә аламыни?! Юк, мөмкин түгел вәхши явызлыкны кичерүе!.. Зөләйха да менә миңа атасының башына кемнәр җиткәнен, шулар аркасында күпме түбәнлек-кимсетүләр күрергә туры килгәнен гүя мәңге сүрелмәс нәфрәт, сызлану белән сөйли. Беренче генә ишетүем түгел...

Укучы, бәлки, хәтерли торгандыр, мин Нигъмәтулла дәдәкәй фаҗигасе турында «Соңгы китап» дигән әсәремдә язган да идем. Мәдинә җиңгәчәйдән һәм Зөләйхадан ишеткәннәргә таянып һәм, әлбәттә, цензура сыйдырган кадәресен... Ул китапның ничек басылуы турында

мин түбәндәрәк тукталырмын әле. Шуңа күрә хәзер Зөләйха сөйләгәннәрдән моңарчы ишетмәгән берничә эпизодны язу белән генә чикләнмәкче булам. Заманы өчен бик характерлы алар.

Атасы һәлак булган чагында Зөләйха Уфада, институтка керү өчен хәзерлек курсларында укып йөргән. Атасының Уфа төрмәсендә ятуын да ишетмәгән ул. Курсларда укучы өч кыз бер карчыкта фатирда торганнар. Ә курсларның комсомол секретаре чибәр-сылу Зөләйха артыннан бик каты чирттерә дә башлый. Егет баш түбәсеннән үк гашыйк, янәсе. Әмма озак та үтми, атасының «халык дошманы» булуы турындагы хәбәр курсларга килеп җиктәч тә, кызга мөнәсәбәт шунда ук бик кискен рәвештә үзгәрә. Иң элек Зөләйханы бер көн дә тотмыйча курслардан куып чыгаралар... Бик яхшы укып баруына карамастан. Хәзер инде аңа да «халык дошманы кызы» дигән мөһерне сугалар. Ә берничә көннән бергә торучы шәриктәш кызлары аңа кыенсынып кына: «Зөләйха, нишлибез, безгә бит синең белән бергә торырга кушмыйлар»,— дип әйтергә мәҗбүр булалар. Ни өчен сорап торырга, кызларга Зөләйханың үпкәсе дә юк, ләкин кая гына барырга? Яманатың үзеңнән алда йөри ләбаса!.. Хәер, иң куркыныч вакытта да мәрхәмәтле кешеләр табыла: шул ук йортта торучы бер яһүд гаиләсе Зөләйханы үзенә кертә.

Әмма иң гыйбрәтлесе башка: Зөләйха артыннан янып-көеп йөргән әлеге комсомол секретаре, стена гәзитенә «Сәяси сукырлык» дигән мәкалә язып, «халык дошманы» кызына белмичә гашыйк булуы өчен тәүбә итә... «Бәхетсез малай!»— ди Зөләйха ул егет турында. Аның да мәхәббәте — репрессия корбаны, башы исән калса да...

Зөләйха сөйләгәндә зарларына көтелмәгән берәр мәзәк тә кыстырырга ярата. Ул туган авылыбыз Каргалы кешеләрен бик яхшы белә — менә хәзер дә шуларның берсен исенә төшерде. Сүз Ибәтулла дигән кеше турында. Мин дә аны күреп беләм. Атам замандашы, чибәр кеше иде.

...Ибәтулла абзыйның кушаматы — Кердеш... Кайдан бу? Өйләнгәч, ул яшь кәләшен үзенә килен итеп төшермәгән, ә үзе аның өенә кияү булып кергән. Менә шуннан инде аңа Кердеш кушаматын такканнар да. Кушаматсыз кеше безнең авылда кешегә дә саналмаган. Нигъмәтулла дәдәкәйнең кушаматы Татыра иде. Шәп кушамат, минемчә.

Кердеш Ибәтулла абзый — морза, аксөяк, эшләп ва-

тылырга бер дә яратмаган. Җәйнең эссе, озын көннәрендә капка төбенә чыгып, тып-тын авылга колак салып утыра торган булган. Берәр яктан сарык кычкырган тавыш ишетелмиме? Әгәр ишетелсә, «Әһә, бүген фәләннәрдә сарык суялар!» дип, бик дөрес нәтиҗә ясый икән. Чөнки суелачак сарыкны хуҗа көтүдән алып кала, абзарына ябып куя. Бичара сарык, билгеле инде, кычкырмыйча торалмый. Ибәтулла абзый аның кайчанрак суелачагын да бик дөрес чамалап, ашыкмыйча гына сарык тавышы тынган йортка бара. Хуҗа инде сарыгын чалган, лапасында тунап ята... «Һай, бәрәкалла, нинди симез мәхлук, ризыкка язган икән»,— ди Кердеш Ибәтулла, кулларын угалап һәм хуҗа янына чүгәләп... Мал суйган вакытка туры килгән кешене буш җибәрү юк — йола шундый. Хуҗа үткен пычагы белән сарыкның йомшаграк җиреннән бер шулпалыкны кисеп алып, Кердешкә тоттыра... Шулай икәүләп, чүгәләгән килеш кенә битләрен дә сыпырып куялар.

— Атакай мал суйганда, Ибәтулла абзыйның «туры килмәгән» чагы булмагандыр,— ди Зөләйха.

...Сүз арасында кайбер якын кардәшләрне дә искә төшердек. Мәсәлән, Гайса морза Еникеевны. Тарихта мәгълүм бу зат иясенең әбиебез ягыннан безгә кардәш икәне миңа күптән билгеле иде, ләкин ничек, ни рәвештә — ачык кына белми идем. Зөләйха әйтә, безнең әбекәйнең инәсе белән Гайса абзыйның инәсе бертуганнар, ди... Димәк, этиләребез белән Гайса ике бертуган балалары — бу инде бик якын кардәшлек. Гайса морза безнең әбекәйгә «Балтүткәй» дип дәшә торган булган.

Ә менә безгә шулай ук якын кардәш тиешле Әбделкәрим абыйның хатыны Хәят җиңкәй (олы яшьтәге җиңгәчәйгә шулай дигәннәр), әйе, Хәят җиңкәй Нигъмәтулла дәдәкәйгә «Сылу морза!» дип дәшкән икән. Төмән халкы — татлы телле... Әмма кирәк чакта бик әче телле дә... «Анаңны ач этләр таласын» ди ул ачуын китергән кешегә. (Бусы телчеләр колагына.)

...Сөйләшүдән тынып торган арада, Зөләйха, уйга калып, әкрен генә җырлап та ала. Безнең сөйләшүебез элек-электән үк җырсыз узмый торган иде. Кайда гына очрашсак та... Зөләйха яшь чагында бик матур җырлый иде. Күбрәк атасыннан отып калган борынгы Каргалы көйләрен. Хәзер инде әкрен җырлый, әмма барыбер бәгырьләргә үтеп керә — бик тансык, бик кадерле миңа атайлардан калган моңнар...

Риель, шунда ук пианино янына утырып, әнисенә уй-

ный башлый. Һич бозмыйча, ашыкмыйча, йомшак, моңлы гына итеп уйный ул. Мин гаҗәпләнеп тә, сөенеп тә аның киң аркасына карыйм: димәк, бар бу пенсионер «бала»да татар җаны! Хатыны марҗа, уллары да урыс, ә үзе менә саф татарча сөйләшә, саф «татарча» уйный да. Ата-бабадан килгән кан үзенекен итә шул — тота, җибәрми...

Мин килгән көннән алып киткәнчегә кадәр Риель һәр көнне әнисендә кунды. Телдән әйтелмәгән туганлык хисен гел тоеп тордык. Ул безне бик, бик якынайтты.

...Аларның хәзерге матди хәлләре турында кыскача гына әйтмичә уза алмыйм. Зөләйха да, улы Риель дә пенсия акчасына яшиләр. Күпме аласыз дип сорамадым, әлбәттә. Әмма гомерен югары мәктәптә укытып уздырган Зөләйханың да, гыйльми тикшеренү институтында эшләгән фән кандидаты Риельнең дә пенсияләре бик чамалы булса кирәк. Алдау-талауга корылган режим кайда да бер. Русиядәге шикелле үк, Казакъстанда да белем-фән иярен хәерчелектә тоталар. Тормышлары елдан-ел авырая бара. Совет заманындагы белән чагыштыру мөмкин дә түгел. Мин моны Зөләйханың хатларыннан да беләә идем. Әмма яшиләр. Ач-ялангач түгелләр. Риель эш тә тапкалый, аннары казакъларга диссертация язарга да булыша дип ишеткән идем. Гомумән, яшьләр аның фикере белән бик хисаплашалар икән. Тик әнисе аның сәламәтлеге өчен борчыла — исән генә була күрсен инде...

Инде кечкенә генә бер чигенү... «Соңгы китап» башта «Казан утлары»нда 1981 елны басыла башлады. Цензура күзәтүе көчле булуга карамастан, әсәр ахырына кадәр үзем язганча, кыскартусыз-үзгәртүсез басылып барды. Ә менә 1987 елны китап булып чыкканда инде, кыскарту да булды, бераз үзгәртү дә кертелде. Китапның редакторы Яхъя Халит иде. Мин аның булуын үзем теләдем. Бик тәҗрибәле, әдәбиятның нәрсә икәнен бик яхшы белә, телне нечкә тоя — моңарчы да күп әйберләрем аның аша узды. Кыскартуга килгәндә, Яхъя моның кирәклеген китапны нәшрият планында күрсәтелгән күләменә сыйдыру өчен дип аңлатты. Һәм әсәрнең төрле җирен ул үз кулы белән кыскартты да. Шул чакта кайбер төзәтүләр дә кертелде. Алар күп түгел, ләкин шактый әһәмиятле... Мәсәлән, журналда Нигъмәтулла дәдәкәйнең Уфа төрмәсендә атылуы әйтелгән иде, китапта инде «атылу» «югалу»га әйләнде. Янәсе, төрмәдәге кеше атылмый, ә каядыр югала?! Аннары журналда Мәдинә җиңгәчәйнең төрмә капкасы төбендә көнозын карлы

яңгыр астында күшегеп-туңып беткәнче торып та, алып килгән ризыкларын иренә тапшыра алмыйча кайтып китүе язылган иде. Менә шул эпизодны да Яхъя дус, минем ризалыгымнан башка, тоткан да сызган.

...Хәзер гаҗәпләнеп уйлыйм: нәрсә бу — тәҗрибәле редакторның артык сак кылануымы, әллә явызлыкны үзе теләп йомшартырга тырышуымы? Әмма мин беләм, Яхъя Халит андый булмаска тиеш иде.

«Соңгы китап» кайчан да булса яңадан чыга калса, ул, әлбәттә, журналда басылганча чыгарга тиеш.

Билгеле, нәшрият практикасында китапны кыскарту-үзгәртүләр гадәти эш иде ул чакларда — моны үзе кичермәгән язучы, мөгаен, юктыр да. Без инде йомшартуга, шомартуга, кирәксә, чын дөресен яшерүгә дә күнегеп беткән идек. Менә шуның бик ямьсез бер үрнәге турында мин әйтмичә кала алмыйм. Сүз — «Совет Татарстаны язучылары» дигән белешмә китап хакында. 1986 елда чыккан шактый калын шул китапны сез юри генә актарып карагыз: язучыларга бирелгән биографик белешмәдә Сталин заманындагы репрессия корбаннары турында бер авыз сүз юк. Гүя аларны утыртмаганнар да, атмаганнар да. Тик иң соңгы җөмләдә «фәлән елны вафат булды» дип кенә әйтелгән. Әйтерсең җылы түшәкләрендә җан биргәннәр.

Бер генә өзек китерәсем килә. Китапта Хәсән Туфан турында болай дип язылган: «1940—1956 елларда аңа кабат Себердә булырга, ул якларның тормышы белән ныклап танышырга һәм хәтер хәзинәсен яңа тәэсирләр, истәлекләр белән тулыландырырга туры килә...»

Башта атылырга хөкем ителгән, соңра күп еллар төрмәләрдә утырган. Себергә сөрелгәч, урыс авылының көтүен көткән шагыйрьне иҗат командировкасыннан кайткандай итеп күрсәтүгә гаҗәп-хәйран калмыйча мөмкин түгел. Бу хәтле дә фарисейларча ялганлап маташу кемгә, ни өчен кирәк булды икән?! Китапны төзүчеләрнең берсе — Рәис Даутов, ләкин мин аның репрессия корбаннары турындагы ялганнар белән килешүенә ышанмыйм. Чын хакыйкатьне яшерү каяндыр югарыдан чыккан булырга тиеш.

Кыскасы, белешмә хезмәтен үтәүче ул китапны барлык ялганнардан чистартып, яңа басмасын чыгарырга вакыт — күптән вакыт. Яшь буыннар алдындагы җаваплылык бездән шуны таләп итә.

...Бүген дүшәмбе — эш көне. Миңа да дөньяга чыгарга вакыт. Ләкин ияртеп йөртүче кирәк. Риельнең үз

эшләре белән йөрисе бар, шуңа күрә Зөләйха күптәнге якын бер танышына шалтыратты.

Озакламый килеп тә җитте. Кечерәк кенә буйлы, җитез хәрәкәтле, өсте-башы да бик пөхтә, олы яшьтәге, ләкин чын яшен чамалавы читен бер кеше иде ул. Таныштык: Газиз Баһаутдинов. Баксаң, ул инде сиксәннән дә узган икән. Әмма терелегенә, җиңеллегенә карап, җитмештән артык бирмәссең. Сөйләшүләрдән тагын шулкадәресе дә мәгълүм булды: сугыш алдыннан ул Казан университетын бетереп кайткан математик икән. Озак еллар безнең Шәрәф белән Казакъ университетында укыткан фән кандидаты. Хәзер дә әле укыту эшен ташламаган, шуның өстенә һәртөрле җәмәгать эшләрендә бик актив катнашып йөри икән. Әмма минем өчен тагы бер уңай ягы — ул Акъмуллада туып-үскән татар, имеш! Казакъның үзен дә, телен дә, гореф-гадәтләрен дә бик шәп белә — аны казакълашкан татар дип әйтергә дә була. Ләкин татарлыгын да бик нык саклаган. Элек ике халыкка да бер үк дәрәҗәдә якын кешеләрне качыр дип атау да бар иде. Газиз әфәнде мине гафу итсен — ул моны үзе дә белә торгандыр.

Чәй эчкән арада мин аңа кайбер теләкләремне аңлаттым. Ул мине кирәк җиргә алып барырга, кирәк кешеләр белән очраштырырга берсүзсез риза булды.

...Зөләйхалар янында гына шәһәрнең зур парк-бакчасы... Урамга чыккач, Газиз әфәнде мине шул парк аша җәяү генә алып китте. Сентябрьнең икенче яртысы булса да, бакча ямь-яшел, агачларда бер генә сары яфрак та күренми. Һава да бездәге җәй башындагы шикелле — күлмәкчән йөрерлек. Җип-җиңел Газиз әфәнде кызу атлый, мин аның артыннан көчкә өлгерәм. Барасы җиребез — Казакъстан Фәннәр академиясе.

Алматы миңа азмы-күпме таныш шәһәр. Беренче килүем генә түгел. Дәүләт органнары, төрле оешмалар урнашкан үзәк урамнарында бик иркен йөри идем. Әмма хәзер ул тирәләр шактый үзгәргән, зур-зур яңа биналар арткан, үзем генә йөрсәм, кирәк җирне тиз генә таба да алмас идем.

Фәннәр академиясе урнашкан биналар да яңа салынган, шактый мәйданны биләгән аерым бер комплекс булса кирәк. Без менә шуның Мохтар Ауэзов исемендәге әдәбият институтына барып кердек. Газиз әфәнде башта директор кабинетына сугылып карады, ләкин аның каядыр чыккан чагы икән... Шуннан ул мине күршедәге бер бүлмәгә алып керде. Бүлмә түрендә утыручы яшь кенә казакъ егете безне ачык каршы алды. Газиз әфән-

дене барысы да яхшы беләләр, күрәсең. Казакъча айвайлап исәнлек-саулык сорашканнан соң, юлдашым минем кем булуымны, кайдан килүемне егеткә бик әйбәт кенә сөйләп бирде. Аннары инде мин дә казакъ язучылары белән күптән таныш булуымны, Мохтар ага белән дә очрашуымны үзебезчә кыска гына сөйләп, аның хакында хатирәм басылган гәзитне өстәленә куйдым. Егет шактый яктырды, хуплап нидер әйтте дә, өстәл тартмасыннан чыгарып, үз кулы белән язып, икебезгә дә «шакыру» билетлары бирде. Мохтар Ауэзовның 100 еллыгына багышланган тантана 25 сентябрьдә башланып, өч көн дәвам итәчәк икән. Безнең билетларыбыз шуның беренче көненә иде. Ачып карагач, исем китте: билетта «Әмирхан Еники мырзага» дип язылган иде. Кызганыч, соңыннан Газиз әфәндедән сорап, мин шуның серен белә алмадым. (Бәлки, «мырза» аларда «әфәнде» урынына йөри торгандыр.)

...Без рәхмәтебезне әйтеп кузгалдык. Егетебез озата чыкты. Чыгу белән безгә министрларча өр-яңадан бик шәп киенгән, төскә дә бик чибәр яшь казакъ очрады. Әйтергә кирәк, монда очраган казакъларның һәммәсе дә бер чамадагы яшьләр иде. (Хәер, казакъның яшен чамалавы да читен.) Егетебез безнең кемнәр икәнебезне очраган казакъка түбәнчелек белән әйтеп бирде. Ул шушы институтның директоры булып чыкты. Кул биреп күрешкәч, безне кабинетына чакырды. Артыннан ияреп кердек. Иркен кабинет, затлы җиһаз, һәртөрле техника... Директор морза зур, таза өстәле артына утырып, яртылаш кына елмаеп, вәкарьлеген саклаган хәлдә, ашыкмыйча гына безнең белән сөйләште. Бу инде читтән килгән кунакка, дәрәҗәсенә карап, кирәк кадәр игътибар күрсәтү иде. Без дә дәрәҗәбезне төшермичә, сүзне озакка сузмыйча биш минут чамасы утырдык та кузгалырга булдык. Хуҗа да урыныннан торды. Бу кереп чыгуны «визит вежливости» дип әйтергә дә ярый торгандыр. Һәрхәлдә, мин канәгать. Казакъ бәйсез-өстен, без һаман әле тышауда — шулай да татарга игътибар бар, кирәк кадәренчә... Урамга чыккач, мин Газиз әфәндене үзебезгә чакырдым. Ул риза булды. Троллейбуска утырып киттек. Безгә якын тукталышка җитеп төшкәч, бер азык-төлек кибетенә дә кереп чыктык. Ни өчен икәнен әйтеп тормыйм. Кайтып керсәк, Зөләйханың озынча түгәрәк өстәлендә һәммә нәрсә әзер иде. Бу юлы дөньядан артык зарланмыйча, капкалап-ашап, күңелле генә сөйләшеп утырдык.

## Алма чәчәк ата

Элек-электән үк «Алма-Ата»ны әнә шулай аңлый торган идек. Хәзер каланың исемен казакъча Алматы diләр. Ләкин алма белән бәйләнгән мәгънәсе үзгәрмәгәндер, шәт — һәрхәлдә, үзгәртәсе килми бер дә.

Алматы миңа бик ошый. Чыннан да, бакча эчендәге кала — һәр урамы озын бер аллея... Биек таулар итәгендә утыра ул — үзе дә шактый биектә. Шуңадыр инде, аңа төрле хәтәр-хәвеф тә яный икән. Көчле җир тетрәү яки тауларда кинәт ишелеп төшкән кар-суларның басып китү куркынычы бар. Әмма бу соңгысыннан каланы бик нык саклау чараларын күрәләр.

Алматы урыслар салган бик яшь кала. (150 ел чамасы гына әле аңа.) Исеме дә башта Верный булган. Шуңа күрә монда Урта Азиянең борынгы шәһәрләренә хас кәкре-бөкре бик тар урамнар да, биек диварлар эчендәге балчык йортлар да, шәрык стилендәге тарихи биналар да юк. Шулай да ул географик яктан Урта Азия каласы. Алматы озак еллар Казакъстанның башкаласы булып торды. Әлбәттә, бик нык үскән һәм үзгәргән дә булырга тиеш. Инде менә Нурсолтан Назарбаев пайтәхетен моннан Акмуллага күчерде. Алматы бик зур Казакъстанның иң читендәге кала, ә Президентның, аны урта бер җиргә күчереп, шуннан ил белән идарә итәсе килә. Дөрес эшли торгандыр, мотлак, ләкин Алматы халкы югары идарәнең, хөкүмәт органнарының күчеп китүеннән бер дә канәгать түгел шикелле — шулайрак ишеттем. Башкаланың абруе да башка, яшәве дә уңайрактыр билгеле... Әмма Алматы барыбер казакъларның рухи вә мәдәни үзәге булып калыр дип уйлыйм мин үзем.

Якындагы паркка кереп утырырга яратам. Парк уртасындарак гаҗәеп матур, бай итеп салынган бик мәһабәт чиркәү басып тора. Рус империясенең куәтен һәм өстенлеген күрсәтү өчен төзелгәндер инде ул. Аңа тиң торырлык бүтән бина юк Алматыда. Чиркәү әйләнәсендә иркен генә мәйдан, эскәмияләр куелган. Эскәмияләрдә чиркәүгә карап утыручыларның күбесе олы яшьтәге кешеләр. Мин дә чиркәүгә сокланып карап утырам. Чын матурлыкка сокланмыйча мөмкин түгел. Бөек сәнгать үрнәге бу чиркәү — мин аны шулай кабул да итәм.

Парк аллеясе буйлап төркем-төркем казакъ яшьләре уза. Үзләре чибәр, өс-башлары чибәр — яшьлек җиле кагылып китә алардан. Киләчәкләре дә чибәр булыр дип уй-

лыйсы килә. Мондый сәер уй шулар шикелле көлешеп узган яшьләрне күргән чакта гына туа хәзер. Ә бүгенге көнебез турында бөтенләй уйлыйсы килми. Уйлану да, сөйләү дә тәмам туйдырып бетерде. Әйтик, Казакъстанның бүгенге хәле нинди — язучы буларак мин кызыксынырга тиеш идем шикелле. Ләкин теләк тә юк, иренәм дә...

Чыннан да, без белмәгән нәрсә бар монда?.. Кая барсаң да бер үк кояш — димәк, дөньясы да бер үк. Монда да халык, Русиядәге шикелле үк, килешмәс ике төркемгә аерылган: кечкенә бер төркеме түрәләр дә байлар, иң зур икенче төркеме — чиге-ахыры күренмәгән бөлгенлектә яшәүчеләр. Араларында тирән упкын.

Хәер, бер аерма бар шикелле. Мәгълүм булганча, мондагы республикалар башына бәйсезлек, Советлар Союзы көтмәгәндә генә таралып китү аркасында, кинәт ишелеп төште. Шуңа күрә Мәскәү раслап куйган беренче партия секретарьлары ансат кына Президент булдылар. Алар туган-тумачалардан гыйбарәт номенклатураны да яннарында сакладылар. Инде күпмедер вакыт узып, бәйсез идарә итүнең нихәтле шәп нәрсә икәнен белеп алгач, президентларның һәммәсе дә ханга әйләнде. Хәзер бөтенесендә дә ханлык хөкем сөрә. Әнә көлке сүз остасы Михаил Задорнов: «Казакъстан — демократический феодализм»,— ди. Әлбәттә, шулай, ханнар үзләре дә ике куллап демократия яклы, тик менә халыклары гына аның нинди җимеш икәнен белмиләр.

Ханлык итүнең тагын бер галәмәте — көндәш булырдай кешеләрдән котылу. Ул аларны йә алыштыра, йә куа. Ишетүемчә, Нурсолтан Назарбаев та бу мәсьәләдә бик каты тора, имеш.

...Казакъ шагыйре Олжас Сулейменовны кем генә белми икән — даны дөньяга таралган, Президентка көндәш булырлык көчле шәхес. Назарбаев тота да аны Италиягә үзенең илчесе итеп җибәрә. Һәм бик акыллы эшли: шагыйрь өчен Италия кебек күңеленә хуш килгән бүтән илнең булуы мөмкинме соң? Мондый мәртәбәле урын татар шагыйренең төшенә дә кермәячәк.

Җитәр, ахрысы, чиркәүгә карап, көенеп утыру — кузгалырга вакыт... Кайтышлый бик бай бер киемнәр магазинына кердем. Ләкин монда долларга гына саталар икән. Күрәсең, әйберне долларга алучылар да күптер. «Известия»дә укыган идем: имештер, Казакъстанның 90 процент байлыгы чит илләр кулына күчкән. Хода белсен, бездә ниләр генә язмыйлар. Ә шәп яшәр өчен тәңгәгә караганда долларның күбрәк булуы, һичшиксез,

кирәктер. Долларга кешеләр генә түгел, дәүләтләр дә сатыла хәзер...

Атнакич, 25ендә, Газиз әфәнде безгә бик иртә килеп җитте. Ул мине Мохтар Ауэзовның юбилей сессиясенә алып барачак. Иртәнге чәйне тиз генә эчтек тә чыгып киттек. Чыгып китәр алдыннан гына Зөләйха өс-башымны күздән бер кичерде. Өстемдә спай гына соры костюм, шуңа килешле күлмәк белән галстук, башымда кара бәрхет кәләпүш. Бусы инде минем кайсы илләрдән килгән кунак икәнемне күрсәтер өчен... «Ярый, бик әйбәт, хәерле юл»,— диде Зөләйха, кыяфәтемнән канәгать булып.

...Сессия сәгать 10да башланырга тиеш иде — соңга калмыйча барып җиттек. Фәннәр академиясенең зур конференц-залы халык белән тулы иде инде. Без дә шунда уздык. Урыныбыз алгы рәтләрнең берсендә — президиумнан да ерак түгел. Кунакларга хезмәт күрсәтүче казакъ егете миңа колак аппараты да бирде. Кыскасы, әйбәт урнаштык.

Нәкъ вакытында президиумга махсус чакырылган кешеләр чыгып утырдылар. Юбилей сессиясен кыскача кереш сүз белән мәдәният министры һәм Фәннәр академиясенең президенты В.Школьник дигән кеше ачты. Ике зур вазифаны казакъларда бер кешенең башкаруы минем өчен яңалык иде. Газиз әфәндедән әкрен генә сорадым: кем ул Школьник? «Мәскәүдән махсус чакырылган бер яһүд»,— диде Газиз әфәнде. Бу хәбәр мине бик гаҗәпләндерде: неужели Назарбаев фән белән мәдәниятне җитәкли алырлык кешене казакълардан тапмады икән?! Сере нәрсәдә моның? Әллә Школьник дигән яһүд дөнья күләмендә танылган зур галимме, әллә инде эшне бик оста оештыра белүчеме, шуның өчен генә бик җаваплы дәүләт эшенә чакырылганмы ул? Әллә булмаса, мәдәният белән фән өлкәсендә казакъларны үзара сугыштырмас өчен Назарбаев читтән башка милләт кешесен чакырып куюны кирәк тапканмы? Булыр да... Югыйсә, казакътан куелса, кемнәр генә академик булып бетмәс иде. Бездәге шикелле... Президент Назарбаевның котлавын укыганнан соң, сүз төп чыгыш ясаучыга бирелде. Аны казакъ академигы Кошанов «Мохтар Ауэзов һәм хәзерге дәвер» дигән темага сөйләде. Әлбәттә, саф казакъча... Аңардан соң докладчыларга чират җитте. Алар күп түгел иде — өч кенә кеше. Программада шулардан икенче докладчы — Чыңгыз Айтматов... Темасы да бик кызыклы: «Мохтар Ауэзов һәм бөтендөнья сәнгать куль-

турасы» (урысча: «М.О.Ауэзов и мировая художественная культура»). Билгеле инде, мин бик кызыксынып аның чыгышын көттем.

Ләкин һич көтелмәгән бер хәл булды. Беренче докладчы академик З.Әхмәтов сөйләп бетерүгә, Чыңгыз Айтматов урыныннан тора башлады. Мәгәр нәкъ шул чакта рәислек итүче Школьник нишләптер сүзне өченче докладчы — казакъ галименә бирде. Трибунага якын гына утырган галим шунда ук торып та басты. Ә Чыңгыз, кәгазьләрен тотып баскан килеш, бер мәлгә аптырап калды. Аннары өстәл янындагы урынына кире килмичә арткы рәттәге буш урынга барып утырды. Ләкин анда да озак тормады, президиумнан бөтенләй чыгып та китте. Мин бу тамашаны карап утырдым. Школьник әфәнде ялгыштымы, әллә сүзне кыргыздан элек казакъка бирүне кирәк таптымы — әмма ничек кенә булмасын, Чыңгыз Айтматов мондый сансызлыкны күтәрә алучылардан түгел, әлбәттә. Тәнәфескә хәтле аның мин көткән доклады булмады, һәм ул үзе дә бүтән бер җирдә күренмәде.

Докладлардан соң чыгышлар башланды. Франция, Төркия, Пакистан, Венгрия галимнәрен тыңладык. (Чыгышлар урысчага микрофон аша тәрҗемә ителә барды.) Шулай ук Санкт-Петербург, Мәскәүнең зур галимнәрен дә ишеттек. Бу чыгышларның һәммәсен дә диярлек Мохтар Ауэзовның дөнья әдәбиятында тоткан урыны турында сүз барды. (Әчемнән генә казакъ әдәбиятының абруе һәм дәрәҗәсе башкарак икән шул, дип уйлап утырдым.)

Әмма барлык чыгышлардан да иң көчле тәэсир иткәне Мохтар агайның үз улы М.Ауэзовныкы дияр идем. Ул урысча гаҗәеп чиста вә оста сөйләде. Эчтәлеге һәм фикер тирәнлеге белән дә күп чыгышлардан өстен иде. Иң көчле кул чабулар да аңа булды...

Мәгълүм ки, Мохтар аганың хатыны урыс милләтеннән иде. Ләкин Газиз әфәнде миңа егетнең анасы казакътан дип әйтте. Димәк, язучының беренче хатыны үз милләтеннән булган... Хәер, бу кадәресен тикшерү безнең эш түгел. Тик шуны гына әйтәсем килә: казакъта көчле кешеләр күп — моны күрмичә мөмкин түгел.

Нәкъ сәгать бердә юбилей сессиясе тәмамланды. Кунакларны төшке ашка алып киттеләр. Сәгать өчтә фәнни конференция башланырга тиеш. Анда Казаннан чакырылган безнең галим Хатыйп Миңнегулов та катнашачак. Ләкин без очраша алмадык.

Газиз әфәнде мине үзенә алып кайтты. Квартиры ерак та түгел — бик матур аулак урында. Газиз әфәнденең хатыны безне әзер аш белән каршы алды. Ханым иреннән күпкә яшь булса кирәк... Аш янында сүздән сүз чыгып, мин аның Башкорстаннан, Стәрлебаш авылыннан икәнен белдем. Тукаевлар нәселеннән икән. Бу мине бик кызыксындырды. Чөнки Стәрлебаш авылы да, андагы Тукаевлар да бик атаклы — даннары еракка таралган. Татарның иң борынгы мәшһүр мәдрәсәсен Тукаевлар XVIII гасырда ук шушы авылда ачканнар. Шуңа күрә Стәрлебаш белән Тукаевларны бер-берсеннән аерып та булмый. Бу нәсел буыннан буынга тәрәккыйпәрвәр дин әһелләре булып килгәннәр. Аларның берсе Шакир Тукаев патша заманында 2 нче һәм 3 нче Дәүләт Думасының депутаты да булып сайлана.

Әмма большевиклар инкыйлабыннан соң авылның гайрәтле-мокыт «кызыл авызлар»ы 150 ел яшәгән мәдрәсәне дә ябалар, Стәрлебашка дан китергән Тукаевларны да туздыралар. Газиз әфәнденең җәмәгате әнә шул туздырылган Тукаевлардан берсенең читтә туып үскән кызы булса кирәк. Аларның очрашып танышулары да Акмуллада булган шикелле... Төпченеп сорашу уңайсыз иде. Шулай да мин тыйнак кына сөйләшүче бу мөлаем ханымның исемен, фамилиясен һәм адрес белән телефоннарын да аерым кәгазьгә язып алдым. Исәбем — кайткач боларны Зәки Зәйнуллинга бирү иде. Ул бит үзе Стәрлебаштан — Тукаевлар тарихы белән кызыксынуын да белә идем. Мәгәр, үкенечкә каршы, язып алган кәгаземне кайткач күпме эзләсәм дә, таба алмадым. Белмим, әллә онытып калдырганмын, әллә югалтканмын.

Соңыннан Зөләйха миңа язды: ханымның тулы исеме Кодрәтталаян, ләкин аны Кодрәт ханым дип йөртәләр икән. Әти-әниләре бу хикмәтле исемне бик белеп кушканнар — сөрелеп, читтә туган бала, яшәр өчен, әлбәттә, кодрәтле булырга тиеш. Тукаевлар нәселенең дәвамы бит ул!..

Сәгать өчтә башланачак фәнни конференциягә мин бармаска булдым. Иртәгә бик иртә китәсе көнем. Зөләйха янына кайту кирәк. Соңгы көннең бер сәгатен дә әрәм итәргә ярамый. Мин инде үземә кирәк кадәресен ишеттем.

Газиз әфәндегә, безнең якка кайта торган берәр транспортка утыртып кына җибәр, дип әйтсәм дә, ул үзе мине, һич иренмичә, Зөләйханың өенә хәтле илтеп, ишеген ачтырып, тапшырып китте. Гаҗәеп игътибарлы, ярдәмчел кеше иде шул бу сиксәннән узган татар кардәше-

без. Җиңел гәүдәсенә, өлгер аякларына Ходай тазалык бирсен!..

Соңгы кичебезне, килгән көнемдәге шикелле, тагын бергә җыелып уздырдык. Бибинурның улы Бари туганым да килгән иде. Менә бер атна үтеп тә китте. Шушы бер атна өчен без ике ел хатлар языштык, һаман уйландык-хыялландык, төрле кыенлыклар да кичердек — кыска, бик кыска безнең көтеп алган көннәребез... Таң алдыннан күргән төш кебек кенә.

...Кичке аш, кичке чәйне озакка сузып, ничектер тыныч кына утырдык. Сөйләшү дә әкрен барды. Сүзләр әйтелеп беткәнгә күрә түгел, ә күбрәк эчебездән генә уйланып утырганга күрәдер — шулайрак була да ул аерылышыр алдыннан. Беләбез, бу инде соңгы очрашуыбыз (чөнки запас гомеребез бик кыска), әмма шулай да, соңгы сүзебез итеп, яңадан күрешергә насыйп булсын, дибез. Җан чыкмыйча өмет өзелми. Яшәүнең бердәнбер мәгънәсе дә, бәлки, шулдыр...

Ятар вакыт җиткәнен белсәк тә, һаман кузгала алмыйча озак утырдык. Ахырда мин, торып, әйберләремне юл сумкасына сала башладым. Шул чакта Зөләйха бүләкләрен китерде: кызларыңа булыр дип, миңа кечкенә генә энҗеле калфак бирде. Борынгы бик затлы әйбер. Сорур тутакайдан калган булса кирәк. Аның туташ чагында нәкъ шушындый калфакны баш түбәсенә генә куеп, әти-әнисе белән төшкән фоторәсеме миндә саклана. Зөләйха тагын Наҗия ханымга дип мәрҗәннән төзелгән муенса, ә якын туганыбыз Зәйнәпкә дип бик матур ефәк яулык та бирде. Бу бүләкләр барысы да Зөләйханың үз хәзинәсеннән. Аның төсе булып бездән дә балаларыбызга калыр, иншалла.

...Иртә тордык. Иртәнге чәйне эчтек. Мин киендем. Утырып дога кылдык. Торып, Зөләйха белән соңгы тапкыр сүзсез генә кочаклаштык. Риель әйберләремне алды. Ишектән чыгып баскычтан төшкәндә генә, күзләремне сөрттем.

Урамга чыккач, Риель бер машинаны туктатты — шуңа утырып, «ефәк юлы» белән аэропортка киттек.

Безгә регистрация башланганны көтеп бераз утырырга туры килде. Риельгә киоскыдан, булса, «Известия» гәзитен алып килергә куштым. Юлда карап барыр өчен. Ул берничә гәзит китереп бирде.

Менә регистрация дә башланды. Чират торып аны да уздык. Самолетка чыгара торган бүлмәнең ишеге төбендә Риель белән дә, ниһаять, аерылыштык. Ни хикмәт-

тер, бу килүемдә ул миңа аеруча якын булып китте. Хәтта күңелемдә кызгану хисе дә туды. Ул да әкренләп картая лабаса! Инсафлы кешеләр өчен иң кабахәт бер заманда!..

Бер генә салонлы иске самолетка утырдык, бик кызу чаптырып барып, һавага да күтәрелдек. Түбәндә Алма чәчәк ата торган шәһәр калды. Анда бүген дә казакъның зур бәйрәме дәвам итә, ә мин борынгы Казаныма — картлык ялгызлыгыма кайтып барам...

* * *

Шөкер, әнә шулай төгәлләнде минем алдан уйланган сәяхәтләрем. Якын туганнар белән очрашып калуымнан мин, фарыз гамәлне үтәгәндәй, канәгать идем.

Тик менә үзем дә көтмәгән, мәгәр минем өчен бик мавыктыргыч, бик кызыклы тагын бер сәяхәтнең булмыйча калуы гына канәгатьләнүемне шактый ук бозды. Эш шунда ки, язучыларның Пен-клуб дигән оешмасы мине 1997 елның августында, дөньякүләм мәшһүр шул үзәкнең Шотландиядә булачак нәүбәттәге конгрессына кунак итеп җибәрмәкче иде. Бу хакта берничә ай алдан ук матбугатта да, радиодан да хәбәр иттеләр. Совет заманында миңа, бик теләсәм дә, чит илләргә чыгып йөрү мөмкин булмады. Шуңа күрә Пен-клубның үземнән сорап та тормыйча, өлкән яшьтәге язучыга хөрмәт йөзеннән булса кирәк, Аурупаның бик борынгы демократик иленә кунак итеп җибәрергә теләве мине башта бик сөендергән дә иде. Баруым да ялгызым гына түгел, бездән конгресска сайланачак вәкилләр белән бергә булырга тиеш иде...

Әмма күпмедер вакыттан соң, вәкилләрне сайлаган чакта, минем кунак булып баруым кинәт кенә өзелде. Безнең Президентыбыз (Пен-клуб җитәкчесе шулай итеп атала) Туфан Миңнуллин гадәтенчә тәкәллефсез генә туптуры әйтте:

— Шотландиягә барыр өчен акча сайланган вәкилләргә генә биреләчәк, кунак булып баручыга акча юк, теләсә, кунак үз исәбенә барырга тиеш,— диде.

Мин шунда ук барудан баш тарттым. Болай йөзгә бәреп әйтүе мине бик нык кимсетү иде, һәм Туфан үзе дә моны белергә тиеш иде.

Соңрак, уйлана торгач, акча юклыгы бер сылтау гынадыр, төп сәбәп — минем картлыгымдыр, дигән фикергә килдем. Димәк, мин инде кемнәрдер өчен артык бер

йөк кенә. Әгәр шулай икән, мине, миннән дә бигрәк, җәмәгатьчелекне алдау нигә кирәк булды? Җитмәгәнмени моңарчы күргән-кичергән алдау-ялганнар?!

Инде миңа бу ямьсез вакыйгадан үзем өчен дә нәтиҗә ясарга кирәк иде. Пен-клуб оешкан көннән башлап, мин аның эшенә актив катнашып йөрдем, әмма үзем белән башкалар арасындагы зур аерманы чамалый белмәгәнмен. Һәм бу аерма яшь ягыннан гына түгелдер дип уйлыйм... Кыскасы, алар башка, мин башка. Шуңа күрә Пен-клуб ишеген каты япмыйча, тыныч кына чыгып китү кирәк иде миңа. Шулай итмәсәм, мин кешелек абруемны саклый алмаган булыр идем.

Нокта куйдык, әмма соңгысы түгел...

*«Мәдәни җомга», 1998*

## ТАҢ АТА ДА КИЧ БУЛА

*Эссе*

Таң ата да кич була... Санаулы көннәр өзлексез үтеп кенә тора. Горькийның кайсыдыр пьесасындагы («Дачники»да бугай) зәһәр телле бер персонаж әйтә: көн үткән саен, кеше үзенең каберенә бер адымга якынлаша, ди. Бик аяусыз хакыйкать! Әмма Ходай Тәгалә адәм баласына шул котылгысыз хакыйкатьне җиңеләйтү сәләтен биргән. Кеше кайчан үләсен алдан белеп тормый. Һәм ул турыда уйларга да яратмый. Аның максаты яшәү — ничек тә озаграк яшәү... Шуңа күрә дә ул әҗәл көтеп ятмый — көне-төне тирләп-пешеп дөнья куа. Пәйгамбәребез әйткән ич: «Иртәгә үләсеңне белгәндәй гыйбадәт кыл, мәңге яшәрдәй булып хәрәкәт ит!» — дигән. Кеше бу бик акыллы киңәшнең беренче өлешен еш кына онытса да, икенче өлешен бервакытта да исеннән чыгармый. Хәрәкәт итү аның өчен закон, һәм шул закон белән яши дә ул!..

Әмма ләкин туксанга җитеп килүченең хәле башкачарак. Ул инде гомеренең ахырына җитүен сизеп тора. Шулай да әҗәл көтеп ятмый, һәр якты көн өчен шөкрана кылып, нидер эшләргә дә тырыша.

...Мин менә «Санаулы көннәр»емне әкрен генә язып ятам. Редакция аны «эссе» дип атады. Мин каршы килмәдем, тик салкын гына булмасын, дидем. Эчтәлеге нидән гыйбарәт буласын башта ук язган идем — кабатлап торасым килми. Әмма бер сүземне әйтүне кирәк

табам. Бу «эссе»не кемнәргәдер ошасын, макталсын дип язмыйм — ул кайгыдан мин хәзер тәмам азат. Бердәнбер теләгем — үзем кирәк дип тапканны язып өлгерү — көчем һәм вакытым җиткән кадәр. Соңгы ноктасы аның, бәлки, куелмыйча да калыр...

Хәзер кайбер кыска гына язмаларыма күчәм.

## Кичеккән тәүбә

Бүген, 17 июльдә, Санкт-Петербургта Николай патшаның һәм гаиләсенең сөякләрен җирләүне телевидениедән күрсәттеләр. 150 миллион урыс халкының шул җирләү тамашасын тын да алмыйча йотылып караган чагында йөрәкләре, мөгаен, бертөсле генә типкәндер. Һәм бу 150 миллион йөрәк моннан 80 ел элек патшаның үзен, хатынын гына түгел, буй җитеп килгән кызларын, 13 яшьлек авыру улын да, Ипатов йортының подвалына алып төшеп, стена буенча бастырып аткан большевик палачларына мәңге бетмәс нәләт вә нәфрәт белән тулы булгандыр... Бөек халыкны, ниһаять, берләштергән бер мизгел иде бу патша гаиләсенең җеназасы.

...Күптәнме әле коммунистлар партиясенең танылган бер лидеры, патша гаиләсе үтерелгән шәһәрдә обком секретаре булып торган, хәзер исә «демократик» Русия Президенты Ельцинның, җирләү көнне генә Петербургка килеп, күмү мәрасимендә катнашуы, патша сөякләре яткан табут алдында чал башын иеп, большевиклар җинаяте өчен тәүбә итүе һәм ярлыкау соравы әлеге 150 миллион халыкны аңа табыну дәрәҗәсенә китереп җиткергәндер... Әгәр икенче көнне (җирләү җомга көнне булды) Русиядә сайлаулар үткәрелсә, урыс халкы аны, бөтен гаепләрен кичереп, өченче тапкыр да, һичшиксез, Президент итеп сайлаган булыр иде.

Әмма бу аның өчен бер генә көнлек өметле мизгел иде... Әгәр дә сайлаулар бер генә көн соңрак үтсә, господин Ельцин бу юлы инде президентлыктан мотлак колак каккан булыр иде. Урыс халкының патшаны җирләгәндә һәммәсе бергә кичергән уртак изге хисләре шул арада төтен шикелле таралып та бетәр иде. Нинди илдә, нинди шартларда яшәвен аңлаудан гаҗиз халык, Николайдан да юньсезрәк «патшалык» итүчедән тәмам туеп, үзе дә белмәгән әллә кемнәргә тавышын биргән дә булыр иде. Кайда инде монда урыс милләтенең бердәмлегә, бөтенлеге вә бөеклеге — күптән инде ул аларны югалтып бетерде... (Ә, гомумән, булды микән аның шундый

чаклары?!) Бер гасыр дәвамында гына да бу халык инде ничә тапкыр алданды.

Русиядә президентлар күп хәзер... Аларга да патша сөякләрен җирләү вакыйгасыннан гыйбрәт алырга ярый торгандыр, минемчә. Ельцин әнә бер мизгелдә генә булса да халыкның җаны ни көткәнен ишетә белде. Димәк, халкыңа бәхетсезлекләр китермәс өчен, иң элек аның җанын ишетә белү кирәк...

...Таң ата да кич була. Санаулы көннәр кире кайтмый... Сулар үргә акса да... Ашыгырга кирәк. Хәзер инде гомернең калган өлешен еллап түгел, айлап санарга туры килә. Әйтик, яңа елны каршы алганда, моның ахырына җитеп булырмы икән, дип уйлыйсың. Артыгына күз җитми...

Инде менә 1998 елның көзенә дә килеп кердек. Сентябрьне исәпләмәгәндә, ахырына барып җитәргә өч ай вакыт калды. Әмма шуның икесе — ноябрь белән декабрь — минем иң яратмаган айларым. Мин шомланам, бу айларда минем һич тә үләсем килми. Салкын, шыксыз, көннәр кыска. Озатучылар өчен дә нинди ямьсез, ипсез вакыт... Декабрь аенда минем анам белән атам гүр иясе булдылар — шомлануым да, ихтимал, шуннан килә торгандыр...

Әгәр исән-имин бу елның да ахырына барып җитә алсам, ниһаять, 90 яшемә җитәргә дә ике генә ай вакыт кала. Ходаның рәхмәте белән, бәлки, ансына да барып җитәрмен. Туксан яшь — күпне кичергән озын гомернең бик мөһим бер ноктасы ул. Аның хакында ирексездән күп уйланырга да туры килә. Мәгәр уйларымны эчемдә генә саклыйм — иртәрәк әле, вакыты җитмәгән... Әмма әйтер сүзем булачак...

Хәзер исә «санаулы көннәр»не башка нәрсәләргә багышлау кирәгерәк. Нәүбәтен көтеп яткан нәрсәләр күп — менә шуларны ничек тә язып өлгерәсе иде.

## Зар

Мин яшем белән бер-берсенә һич охшамаган ике буын арасына туры килдем: иске буын әле китеп бетмәгән, ә яңасы туып, күтәрелеп кенә килә иде... Искеләре дигәнем гасыр башында мәйданга чыгып, милли мәдәниятебездә күренекле урын тоткан олы шәхесләр — Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов, Җамал Вәлиди, Гали Рәхим, Садри Җәләл һ.б. Яңалары исә революциядән соң күтәрелеп, большевиклар хакимлек итә

башлаган елларда формалашкан яшь буын — Шамил Усманов, Мәхмүт Максуд, Гомәр Толымбайский, Кави Нәҗми, Гомәр Гали, Һади Такташ, Гадел Кутуй, Муса Җәлил һәм башкалар, һәм башкалар... Искеләрен «попутчик»лар дип атыйлар иде, яңалары инде — «пролетарский»лар (соңрак «советский»га әйләнделәр).

1925 елны Казанга килгәч, «попутчик»ларның күбесен читтән генә булса да мин күреп калдым. Ә яңалары белән инде күпмедер вакыт бер заман кешесе булып яшәдем дә. Барысы белән дә таныш идем.

Әмма сез беләсез инде, бу бер-берсеннән ерак ике буынны Сталин «атабыз», мыегын сыпыра-сыпыра гына, берbegin бер артлы юкка чыгарды. Башта «искеләр»не кырып бетерде, аннары итеген ялаучы «яңалар»ның да күпчелеген аттырды, тик бик сирәге генә котылып кала алды...

Әнә шул иске зыялылардан ничектер исән калган, миннән яше белән дә, эше белән дә бик ерак торган, исеме бик мәгълүм бер кеше белән миңа һич уйламаганда очрашып танышырга, өендә булырга, таңга кадәр зарын да тыңлап утырырга туры килде. Бу — Камил абзый Мотыйгый...

Кем соң ул? Яңа чыга башлаган безнең татар энциклопедиясендә аның хакында кыскача гына болай диелгән: Мотыйгый (Төхфәтуллин) Камил Мотыйгулла улы (1883—1941) җырчы, нәшир, журналист.

Шуннан башка безнең матбугатта аның хакында махсус язылган материалны минем күргәнем юк. Әмма заманында аны күреп яки ишетеп белмәгән кеше булдымы икән?! Чөнки аның исеме турыдан-туры һәм бик тыгыз рәвештә Тукай белән бәйләнгән. Яхшы һәм яманаты да Тукай аркасында дөньяга таралды... Җыеп кына әйткәндә, Камил Мотыйгый 1905—1906 елларда Уральскида үз тырышлыгы белән, үз акчасына «Фикер» гәзитен һәм «Әлгасрелҗәдит» журналын чыгара башлап, Габдулла Тукайга әдәбият дөньясына мәйдан ачкан кеше. Тукай шул гәзит белән журналда көне-төне эшләп һәм язып, үзен бик кыска вакытта җитди, өметле шагыйрь итеп бөтен тирә-якка танытып та өлгерә. Шул чакта бит инде Мотыйгый белән Тукай, кулга-кул тотышып, фотога да төшәләр... Әмма алар арасындагы бу дуслык һәм бердәмлек шул ук гәзит белән журнал аркасында, ниһаять, тәмам бозыла да... Нидән, ничек бозылганын сез мәрхүм Ибраһим Нуруллинның «Габдулла Тукай» исемле китабыннан укып белә аласыз — анда һәммәсе дә бик тулы язылган.

...Мин дә Камил абзыйны күреп белә идем. Аның хакында телдә йөргән төрле сүзләрне дә ишеткәнем бар. Имеш, ул шактый үзенчәлекле сәер бер кеше булган: барган бер җирендә мәчетләрдә Коръән дә укыган, кичләрен концертлар да биреп йөргән, көченә таянып, циркларда да көрәшеп караган, хәтта кайсыдыр елны мөселманнарның мөфтие булып сайланырга да үзен тәкъдим иткән... Билгеле, болар һәммәсе дә аның революциягә кадәрге гамәлләре. Ләкин күпмесе дөрестер — әйтүе читен. Тик шулай да моңа шул ук Тукайдан җавап табып була. 1910 елны «Ялт-Йолт»та аның «Сибгатуллин» исемле шигыре басылып чыга. Сибгатуллин исеме астында Төхфәтуллинның күзаллануы бәхәссез — бөтен эчтәлегеннән күренеп тора. Бу — үтергеч шигырь. Камил абзыйның рухын рәнҗетмәс өчен соңгы юлларын гына күчерәм.

Кайда барса, шунда «милләт» дип йөри,
«Мин — мөхәррир һәм дә бик шәп!» — дип йөри.
Инде дә, милләт, тәрәккый итмәсәң:
Ресторанларга кереп акрып йөри!

Миңа да аның җырлаганын ишетергә туры килде. Егерменче елларның ахыры иде шикелле, Академия театрында Камил Мотыйгыйның бердәнбер концерты булды. Исеме күпләргә таныш булса да, нинди җырчы икәнлеген ишетеп кенә белгән яңа заман тамашачылары (бигрәк тә яшьләр) белән зал тулы иде. Сәхнәгә бик төз-озын буйлы мәһабәт кеше чыгып басты. Өстендә кара фрак, катыргы ак яка, зур кара бант... Шушы кыяфәте белән үк инде ул «эшче-крестьян» тамашачысына ят кеше булып тоелды булса кирәк... Тавышы бик көчле иде. «Абау алла, Гайшәм»не ул нәкъ урыс артистлары кебек калынкөр тавыш белән бик сузып җырлады. Бусы да татар колагына сәер ишетелгәндер — тавышы бар, моңы юк, дигәндер... (Ул елларда безнең җырчылар, хәзергеләр шикелле, җыр ахырын муен тамырлары бүртеп чыкканчы сузмый торганнар иде.) Ләкин Камил абзыйның концерты ничек кенә үтмәсен, бу инде иң соңгысы булгандыр, башка беркемгә дә аны яңадан ишетергә туры килмәгәндер...

Шул вакыйгадан соң, күпмедер вакытлар үткәч, мин Камил Мотыйгыйны Казан урамнарында сирәк кенә очрата башладым. Әмма бу инде башка кеше иде. Шактый олыгайган, буе-сыны да бөкрәя төшкән, өстендә таушалган пәлтә, култык астында иске генә портфель — кешеләрне күрәсе килмәгәндәй, аяк астына карап кына ат-

лаучы, гүя бирәүгә дә билгесез булган бер абзый иде. Миңа аның болай нык үзгәрүе беркадәр аңлашыла да иде. Мотыйгый белән Тукайның Уральскида чакта берберсенә никадәр якын булуларын әйткән идек инде. Ә менә 30 елдан соң Мотыйгыйның шул ук Тукай өчен Казанда иң сүгелгән, иң каһәрләнгән чагы иде. Безнең һич уйламаганда очрашып танышуыбыз да нәкъ шушы вакытка туры килде. Вакыйга болай булды.

...Җәйге эссе көннәрнең берсендә мин Куйбышев урамындагы Ленин бакчасына каршы сыраханәгә сусауны басар өчен барып кердем. Бер кружка сыра алып, читтәге буш өстәлләрнең берсе янына уздым. Озак та үтми, сыраханәгә озын гына буйлы бер абзый кереп, сыра салдырып, кружкасы белән минем каршыдагы буш урынга килеп утырды. Бу — Камил абзый Мотыйгый иде. Олыгайган, суырылган, ияк очындагы кечкенә кара сакалы да шактый агарган... Үзе тирләгән, авыр сулый, сырасын да аз-азлап кына эчә. Мин дә ашыкмыйча гына уртлап куям.

Бертын шулай сүзсез генә сырабызны эчкәләгәннән соң, ничек сөйләшеп киткәнбездер — әйтә алмыйм. Ихтимал, мин үзем аңа башлап дәшкәнмендер — күптән күреп белгәнгә күрә... Һәм без ансат кына сөйләшеп тә киттек. Камил абзый үзе дә сүзгә сусагандай бик тиз ачылды. Без әле сыраны да тагын берәр кружка кабатладык. Билгеле инде, нәрсә турында сөйләшүебез күптән онытылган, искә төшерүе дә мөмкин түгел. Әмма очраклы гына бу сөйләшү Камил абзыйга җитми калды, күрәсең, сыраханәдән чыккач, ул миңа тотты да:

— Әйдәле, туган, миңа кереп бераз утырыйк, мин әнә якында гына торам,— диде.

Абзыйның һич көтелмәгән тәкъдиме мине, әлбәттә, бик гаҗәпләндерде. Минем кем икәнемне дә юньләп белми ич ул!.. Хәер, сыра эчкәндә мин үзем хакында, бәлки, кайбер нәрсә әйткәнмендер дә, бәлки, әдәбиятка кагылышлы сүз дә булып алгандыр. Тик шулай да сыраханәдә беренче генә тапкыр очраган кешене тот та үзеңә чакыр, имеш?! Ни өчен, нинди хаҗәт — яшьләребез дә туры килми ләбаса! Баштарак ни уйларга, ни әйтергә белмәдем... Әмма олы яшьтәге мөхтәрәм бер кешенең сүзен мин тыңламыйча булдыра алмадым.

...Торган җире, чыннан да, якында гына икән. Шул ук Ленин бакчасына каршы, Дзержинский урамы яклап. Хәзерге Опера һәм балет театрын узгач та, чаттагы ике катлы таш йортта. Үзенә күрә бу тарихи йорт: егер-

менче елларның ахырына кадәр анда урыс гәзитенең редакциясе иде; репрессия еллары башланганчы ул йортта Фатих Сәйфи-Казанлы, Сәләх Атнагулов, тагын шулар кебек кайбер мәгълүм кешеләр дә торды...

Менә шул йортның икенче катындагы иркен генә бер бүлмәсенә барып кердек. Каршыдагы ике тәрәзә нәкъ «Бакыр бабай» бакчасына карый, сул як стена буенда киң генә агач карават, урын җыелмаган, тузылып ята, уң якта озын гына бер өстәл, берничә урындык, урта бер җирдә иске генә бәрхет кресло — шулайрак хәтеремдә. Камил абзый миңа шул креслога утырырга кушты. Бүлмәдә бүтән бер кеше дә юк иде. Караңгы төшеп ярты төн җиткәнче утырсам да, монда кемнең дә булса башка берәүнең барлыгын сизмәдем. Күрәсең, Камил абзый ялгызы гына яши бу нигәдер ямансу-тын бүлмәдә...

...Менә күпме еллардан соң мин шул бүлмәдә берберсеннән бик ерак ике кешенең сөйләшүен искә төшерергә тиешмен. Мөмкинме бу?.. Тик шуны гына әйтә алам: сүзне башлаучы да, бертуктамый сөйләүче дә Камил абзый үзе, ә мин бары тыңлаучы гына. Әле өстәл янына утырып, әле бүлмә буйлап йөри-йөри, ашыгып, гүя әйтеп бетерәсе килеп сөйли дә сөйли. Күренеп тора, ул тыңлаучыга сусаган, тыңлаучы юктан интеккән — шуңа күрә Чехов хикәясендә извозчик үз хәсрәтен атына сөйләгән шикелле, миңа, беренче очраган ят кешегә, ачыктан-ачык эчен бушата.

Ә сүз нәрсә хакында барды соң? Күпмедер вакыт узгач, мин моны калын дәфтәремә кыскача гына язып та куйганмын. Менә шуңа таянып, инде әйтә дә алам: Камил абзый Мотыйгыйның бөтен ачынып сөйләгәне — Тукайдан зарлану иде, зарлану гына түгел, аңа чынлап рәнҗүе дә иде. Тыела алмыйча, кабатлый-кабатлый сөйләде, һәм ахырдан гына Тукайга каршы язган шигырен дә укыды...

Мин исә олы яшьтәге бу кешенең шулкадәр ачынып, онтылып сөйләвен ни әйтергә дә белмичә, хәйран калып, бары тыңлап кына утырдым. Шигыре миңа әллә ни тәэсир итмәде, әмма сөйләве, сөйләве тиз генә онытылачак түгел иде. Кеше бит Тукайдан зарлана, Тукайга рәнҗи — кемнең моны ишеткәне бар әле?!

Дөресен генә әйткәндә, минем үз хәлем дә бик четерекле иде. Әлбәттә, кеше буларак мин Камил абзыйны кызганырга тиеш идем. Әмма ни гаҗәп, бик табигый уяна башлаган кызгануны нидер тыя, нидер буып тора.

Тукайның исеме безнең өчен изге бит... Кыска гына гомеренең һәр көнен диярлек беләбез. Ниләр күргән, ниләр кичергән — барысы да хәтеребездә. Шуның өстенә рухи дөньябызда бердәнбер сакланып калган терәгебез, юанычыбыз да бары шул Тукай гына лабаса!.. Ничек инде аңардан зарланып, аңа рәнҗеп була? — Моны бит күңел һич тә кабул итәргә теләми...

Ә Камил Мотыйгый кем безнең өчен, нәрсә генә беләбез аның хакында?! Уральскидагы мәшһүр Мотыйгулла ахун-хәзрәтнең улы, Тукай күргәннәрнең йөздән берен дә күрмичә үскән бәхетле чибәр егет булган... Тукайдан зарланырга аның ни хакы бар? Дөрес, ул, Мисырда укып кайткач, Уральскида үз акчасына Ырынбур-Уфалардан да элегрәк татарча гәзит-журнал чыгара башлаган, ә Тукай бик теләп үзенең беренче шигырьләрен шуларда бастырган. Йә шуннан соң?! Мотыйгый — хуҗа, Тукай исә аңа ялланып эшләүче түгелмени?

...Онытмыйк, бу очрашуыбыз утызынчы елларда иде. Классик әдипләрдән өч кенә кешенең — Г.Тукай, Г.Камал, Г.Коләхмәтовның гына исемнәре әдәбиятта яши иде. Башкалар юк, гүя булмаган да... Тукайны аз гына кыерсыткан кешене дә изүче, талаучы дип атау бик җиңел иде ул елларда. Җитмәсә, Тукай үзе дә Мотыйгый турында әнә: «Кайда бай күрсә, шуңа сатылып йөри»,— дип язып калдырган.

Бәс, шулай булгач, Камил Мотыйгыйның хәлен аңлау, зары белән килешү мөмкин идеме — кешегә ышану тәмам беткән бер заманда?! Ә мин ышанырга тиеш — аңа шул кирәк лабаса!..

...Камил абзый сөйләде, сөйләде дә, ниһаять, тынды. Бөтенләйгә тынды. Вакыт бик соң иде инде... Мин урынымнан кузгалдым. Камил абзыйга нәрсә әйткәнемне хәтерләмим, һәрхәлдә, берәр юату сүзе чыккандыр дип уйлыйм. Бәгырь таш түгел, кеше хәсрәтен тоя белә... Тик аның үзендә нәрсә соң — җан газабын бушатып җиңеләюме, әллә үкенүме?! Саубуллашып чыгып киткәндә, ул минем арттан ишеген сүзсез генә бикләп калды...

Биш ел мин Казанда булмадым. Шуның өч ел ярымы фронтта узды. Инде сугыш бетеп, исән калган язучылар һәммәсе дә кайтып, әдәбият тирәсендә аралашып йөри башлагач, мин кемнәндер Камил Мотыйгыйның асылынып үлүен ишеттем. Фәүкылгадә аяныч хәбәр булса да, ышана калдым, чөнки аның нинди хәлдә булуын онытканым юк иде. Әмма фаҗиганең кайчан, ничек булганын минем моңарчы ишеткәнем юк иде. Ләкин Камил

Мотыйгыйның үзенә кул салуы рас икән — моны миңа Лерон Хәмидуллин әйтте.

...Әйе, кешенең үз-үзенә кул салуы — зур фаҗига. Һәм бик зур батырлык та дияр идем мин... Тик үлү датасының ике төрле булуы миндә беркадәр шик уята: «Тукай турындагы истәлекләр» китабында Мотыйгыйның үлгән елы 1940 диелгән, ә күптән түгел чыккан Энциклопедик сүзлектә 1941 ел күрсәтелгән... Кайсы дөрес? Һәрхәлдә, 40 нчы ел дигәне дөрес булырга тиеш, чөнки кешеләрне эзәрлекләү, каһәрләү һаман дәвам итә иде әле ул елны...

Тукай вафатыннан соң, утыз ел чамасы вакыт узгач, әнә шул рәхимсез каһәрләү Камил Мотыйгыйның башына җитте дә булса кирәк. Аның миңа гаять ачынып сөйләгән зары котылгысыз фаҗигагә таба баруның башы булмады микән?! Мин хәзер шулай уйлыйм, ә ул чагында бу дәү абзыйның ачы зары ни дәрәҗәдә хаклы дигән уй мине күбрәк биләгән булса кирәк.

Тик сугыштан соңгы елларда гына Тукай белән Мотыйгый арасында ни булганын ачык белү өчен мөмкинлек туды. Ибраһим Нуруллинның «Тукай» китабында бу хакта шактый тулы язылган. Аннары Тукай замандашларының истәлекләре дә күп нәрсә өстәде. Ләкин шулай да төп чыганак ул — башта Мотыйгыйның милләт файдасына кылган эшен бик хуплап, аның үзен һәртөрле ялалардан аклап, инде аралары бозылгач, аны бик әшәке хурлап язган Тукайның үз шигырьләре... Менә шул шигырьләрнең бары соңгыларына гына таянып, безнең совет әдәбиятчылары теге елларда тере Мотыйгыйны хөкем иттеләр дә инде. Бигрәк тә Мотыйгыйның 1914 елда язган үз истәлеге аны гаепләр өчен җитә кала: матбагасында эшләүчеләрне эш ташларга котырткан өчен ул Тукайны хезмәтеннән чыгара. Һәм өстәп тагын шуны да яза: «Бу эш (ягъни хезмәттән чыгару.— Ә.Е.), минемчә, бик урынлы булып күренде исә дә, Габдулла әфәндегә бик каты тәэсир әйләмеш иде. Ул шуның өчен үлгәнче миңа ачуланып һәм кәефе китеп йөрде...».

Сизмәгән, бичара, шулай дип язуы белән берзаман Тукайның «сыйнфый дошман»ына әйләнәчәген һәм нинди зур бәхетсезлеккә дучар булачагын.

Мәгълүм ки, 1905 елның инкыйлаб җиле (җене дип тә әйтергә була) япь-яшь Тукайга да кагылмыйча калмый. Шуның аркасында ул берара шактый суллашып та китә. Матбага эшчеләрен эш ташларга котыртуы да шул чакның бер шаукымы булса кирәк. Хәер, эш ташларга

өндәүнең кирәге дә калмый — нәширлек хокукын югалткан һәм бөлгенлеккә төшкән Мотыйгый тиз арада матбагасын да, гәзит-журналын да икенче бер байга сатарга мәҗбүр була. Тукай бу хәлләрне, әлбәттә, белеп торган. Ләкин аңа Мотыйгый хәленә керүдән бигрәк, эш ташларга өндәү мөһимрәк булган, күрәсең...

Кайбер тарихчыларның Тукайны бик кызыл итәргә тырышулары да башлыча әнә шул Уральски вакыйгалары белән бәйләнгән. Әмма Уральскидан татар халкының бик тиз танылачак һәм яратып укылачак, чын мәгънәсендә хөр фикерле милли шагыйре күтәрелеп чыга... Һәм турыдан-туры Камил Мотыйгулла улы Төхфәтуллин аркасында. Бер идеал, бер изге теләк аларны берләштерә. Күрәсез ич, аларның кулга-кул тотынышып төшкән фоторәсемен. Моңа күз йому һич тә мөмкин түгел!

...Әлбәттә, Тукай соңрак булса да мәйданга, һичшиксез, чыгачак иде, әмма ләкин бер-ике ел алданрак чыгуы өчен аның Уральскида яшәве һәм Камил Мотыйгый белән очрашуы кирәк булган. Бик кыска гомерле шагыйрь өчен моның әһәмияте гаять зур дияр идем мин.

Бу язганнарым Мотыйгый белән Тукайны тиңләү түгел, әлбәттә. Тукай — халкыбызның тарихында, аңында, йөрәгендә мәңге җуелмас урын алган бөек шәхес. Ләкин бөек булу һәркемгә дә миһербанлы булу дигән сүз түгел әле. Бөекләргә — килешмәү, кичермәү бик хас, Тукайда ул аеруча көчле булган. (Ни дәрәҗәдә урынлы һәм хаклы — анысы икенче мәсьәлә.) Әмма хакыйкатьтән дә качып булмый: бөек шагыйрь Тукай артында аның иң беренче нәшире Камил Мотыйгый шәүләсе тоныкына басып тора... Йә, аларны бер-берсенә каршы куеп буламы?! Тарих хөкеме гадел булырга тиеш!..

1998 ел, 1 август. Роберт Миңнуллинның юбилей мәҗлесендә миңа котлау сүзе әйтергә туры килде.

— Мин — XX гасыр кешесе, син, Роберт, XXI гасырда да яшәячәксең — мин сиңа кул болгап калырмын...

Әмма сиңа ике теләгем бар. XX гасырда безнең әдәбиятта Гаяз, Тукай, Дәрдемәнд, Әмирхан, шулай ук Бабич, Такташ, Туфан, Муса кебек бөек әдип, шагыйрьләрнең һәм алардан кала башка бик күпләрнең яшәп, иҗат итеп китүләрен онытма! Алар XXI гасырда да татар халкына кирәк булачаклар.

Икенче теләгем: син бер үк вакытта шагыйрь дә, дәүләт эшлеклесе — депутат та... Шагыйрьлегең гомерлек, депутатлыгың вакытлы, дип язган да идем мин, сине Тукай бүләгенә тәкъдим иткәндә... Ләкин миңа калса,

синең акылың һәрвакытта алдан йөри. Дәүләт эшлеклесе өчен бу бик кирәкле сыйфаттыр, мөгаен. Бәлки, син киләчәктә дә шигърият белән дәүләт эшен бергә килештереп алып бара белерсең. Тарихта моның мисаллары бар — Бөек Гётене искә төшерү дә җитә. Кыскасы, синдәге шагыйрьлек белән дәүләт эшчәнлеге халкыбызга тагы да күбрәк файда китерер дип ышанасы килә. Әмма шагыйрь үзенең дәүләт эшчәнлеге өчен дә җаваплы — шуны да исеңдә тотсаң иде. Шагыйрьгә без күбрәк ышанабыз.

...Таң ата да кич була. Пенсия килгәнне көтеп... Ә санаулы көннәрне әзрәк кенә булса да төрләндерәсе килә. Ходайның рәхмәте белән тагын менә якты җәйне күрүгә ирештек. Сагыш тулы карт күңел дә, читлектән иркенгә омтылган кош шикелле, каядыр барасы-йөрисе килеп җилкенә...

Ихлас теләк кабул булмыйча калмый икән. Иң элек Нәҗия апагыз күптән күрешә алмаган бик якын туганнарын күрер өчен ерактагы Бишкекка тәвәккәлләп барып кайтты. Бик куанып каршы алганнар. Өч атна буе кунак иткәннәр — әгәр мин «кайт инде» дип ялвармасам, апагызның кузгалырга исәбе дә булмаган. (Икәүләп бармавыбыз өчен үкенеп тә куйдык.)

...Аннары июнь ахырында Уфа татарлары елдагыча махсус пароход белән изге Болгар җирен зиярәт кылырга һәм тарихи Казанны күреп китәргә килделәр... Былтыгы сәяхәтләрен алар минем 90 еллыгым якынлашуга багышлаганнар. Шул сәбәпле безне дә үзләре белән Уфага алып киттеләр. Өч тәүлек Чулман—Агыйдел буйлап, беренче класслы каютада булуы гаять рәхәт вә күңелле булды. Пароходтагы юлдашлар арасында җанга якын күптәнге танышлар — Фәридә Кудашева, Фәния Чанышева, Нәҗар Нәҗми кебек дуслар да бар иде. Шулай ук якын туганым Факиһәнең дә булуы мине бик куандырган иде. Инде сәяхәт җитәкчесе Марат Шәрипов һәм радио тапшыруларын оештыручы Рәүф Идрисовның һәм бер үк исемдәге бик уңган, бик мөлаем Венера ханымнарның безгә күрсәткән игътибар вә хөрмәтләрен әйтеп торасы да юк. Гомумән, бу сәяхәтнең күркәм ягы да пароходта баручыларның үзләрен бер гаилә кебек тотуларында иде. Очрашу-сөйләшүләргә, һәртөрле күңел ачуларга һәммәсе дә бик теләп катнашалар. Безнең өчен иң тансыгы да әнә шул үзара бик табигый якынлык иде.

...Чаллыга барып җитүебезгә, безне Түбән Камадан үз машинасында килгән Азат әфәнде Зыятдинов каршы

алды. Көтелмәгән куанычлы очрашу булды бу. Хатыны Сания ханым белән пароходка кереп, үз якыннары белән шаулап күрешкәч, алар шунда ук безнең өчен салонда мул табын да әзерләттеләр. Өстәлгә үзләре китергән затлы эчемлек белән төрле күчтәнәчләрен дә тезеп куйдылар...

Өч сәгатькә сузылган бик күңелле бу мәҗлес ничектер сизелмичә дә калды. Иң гаҗәбе — Азатның үзе язган шигырьләрен аягүрә бик шәп итеп укуы булды. Һәм гаҗәпләндерүе дә, шәп укуыннан бигрәк, шигырьләренең бик көчле һәм тирән мәгънәле булуында иде. Хәтта шигъриятә мәйдан тоткан Наҗар Нәҗми дә, танылган шагыйрәбез Фәния Чанышева да аны исләре китеп тыңладылар бугай... Ә минем өчен инде техник фәннәр докторы, нәрсәнеңдер генераль директоры Азат әфәнде Зыятдиновның чын шагыйрь дә икәнен белү «Америка ачу» белән бер булды диярлек.

Тагын өстәп шуны да әйтәсем килә: мин үзем, асылда, пессимист кеше. Хәзерге тормышның бер генә дә якты ягы юктыр кебек... Тик менә Азат шикелле үз-үзенә нык ышанган, тәвәккәл, рухи таза, максаты ачык кешеләр ара-тирә очраганда тормышның якты яклары да бар бугай дигән ышану туа. Ышану пессимистларга аеруча кирәктер инде...

Уфага дүшәмбе көн иртәнге сәгатьләрдә килеп җиттек. Безне якын туганым Ринат үз машинасы белән каршы алды. Иң элек Уфадан Казанга самолет кайчан буласын белү кирәк иде. Белештек — бүген үк кичке якта оча икән — шуңардан калмаска да булдык. (Икенче самолет атна ахырында гына булачак иде.) Дөрес, Уфа дуслар безгә ашыкмаска куштылар. Кунак итүне дәвам да итмәкчеләр иде, ләкин без инде өч көн буе бик шәп кунак булдык, җитеп торыр, дидек. Аларга рәхмәттән башка сүзебез юк.

...Уфага өч тәүлек килгән идек, өебезгә ике сәгатьтә кайтып җиттек. Менә ни өчен Казан—Уфа арасында йөрүче пароходларны күптән бетерделәр. Кешегә хозурлык түгел, тизлек кирәк. Тизлек ул хәзер кешенең яшәү чарасы...

Минем әле тагын бер сәяхәтем булды. Мәскәүдәге дуслар һаман дәшәләр иде, үземнең дә «яңа» Мәскәүне күрәсем килә иде. Август ахырында үзебезнең мактаулы «Татарстан» поезды белән киттем дә бардым.

Фуат дустым Маннапов мине каршы алды. Бер атна мин аның кунагы булдым. Килгән көнне үк минем белән күрешергә Әкъдәс Борһановны, Әдеһәм Тенишевне,

Миргазыян Юнысны чакырган иде. Болар миңа иң якын кешеләр. Бик күңелле сөйләшеп утырдык. Мин үзем белән безнең радиодан тапшырылган «Курай» исемле әйберемнең язмасын алып барган идем. Шуны уйнаттык. Кунаклар мөкиббән китеп тыңладылар. Айрат Арслановның укуы да, башкорт кураеның моңы да аларга гаять ошады. Татарлар яшәгән җирләргә таратырга кирәк бу язманы, диделәр.

Бер уңайдан әйтеп китим: Фуат дус күптән инде мине академик Рәшид Сюняев белән таныштырмакчы иде. Ләкин күп вакытын чит илләргә йөреп уздырган академик белән очрашу моңарчы мөмкин булмады. Бу килүемдә, ниһаять, очраштык. Соңгы кичемдә, Фуат чакыруы буенча, Рәшид әфәнде җәмәгате һәм туташ кызы белән бергә килделәр. Әкъдәс дус та килгән иде. Шактый озакка сузылган бик кызыклы һәм мәгънәле сөйләшеп утыру булды: «мактаулы» заманыбыз турында, илдәге вакыйгалар турында һәм, билгеле инде, баш катыргыч татар мәсьәләсе турында да...

Рәшид әфәнде унике илнең академигы икән — үзе шулай диде (фәнни эшчәнлеге космос белән бәйләнгән). Минем өчен зур яңалык... Югыйсә бит без телевизор караганда бары Мансур Хәсәновның ике ягына тезелешеп утырган борынгы тарихчылар белән әдәбиятчыларны гына күрәбез. Читтәгеләр турында ишеткәнебез дә юк. Казан үзен генә белә... Инде дөньякүләм танылган галимнең кузгатылган мәсьәләләре турында фикерен ишетү аеруча әһәмиятле иде. Чит илләрне яхшы белгән кеше буларак, аның китергән мисаллары да кызыклы иде. Һәм иң мөһиме, өстәл әйләнәсендә барган сөйләшүдә фикерләр уртаклыгы шактый ук икән... Мәҗлес ахырында Рәшид әфәнде минем Фуатта сакланган ике китабымны да сорап алып китте.

Гаҗәп хәл, озак яши торгач, минем өчен утырдаш булырдай рухи якын фикердәшләр читтә генә калдылар. Казандагы миңа якыннар китеп беттеләр. Картаеп килүче яшьрәк буын белән аралаша алганым юк — андый ихтыяҗның кирәклеге дә бик үк сизелми. Кешеләр хәзер бер-берсеннән ераграк торуны артыграк күрәләр...

Күптән түгел берәү миңа бик акыллы киңәш бирде. Ул миннән күпкә яшь, әмма югары даирәләрдә яхшы ук танылган кеше. Мин аңа бик ышана идем. Очрашканда зарымны яки гозеремне дә сөйли торган идем. Көннәрдән бер көнне, бер җыелыштан соң, ул мине үз машина-

сында өемә китерде. Кайтып җиткәч, мин машинадан төшмичә аңа кайбер гозеремне сөйли башладым. Ул сабыр гына тыңлады да ахырда сүземне бүлеп әйтте:

— Ташла, Әмирхан абый! Шушы шәп йортыңда әйбәт кенә тор, юкка кыбырсынма, аракыны да әзрәк эч! — диде.

Минем яшьтәге кеше өчен бик тә дөрес киңәш иде бу. (Алар үзләре бу «шәп» йортка күчүдән баш тартканнар икән.)

...Мәскәүдә инде мин ялгызым гына йөри алмыйм. Элек тә аз белә идем бу каланы, хәзер исә урамга чыксам, кайсы якка табан барырга кирәген дә чамалый алмыйм. Ә «яңа» Мәскәүне күрәсе килә. Фуат иртәдән кичкә кадәр эштә. Шуңа күрә Миргазыян мине ике көн Мәскәү белән таныштырып йөртте. Беренче көнне Татарстан вәкиллеге безгә ике генә сәгатькә машина җибәргән иде, шуның белән башта «Поклонная гора»га бардык. Тау белән танышып кайткач, машина китте, без үз аякларыбызга күчтек. Дөрес, миңа олы калада җәяү йөрүе җиңел түгел, әмма дәрт, теләк дигән нәрсә йөртә минем кебекне дә...

Без Пушкин музеенда булдык. Заллары буйлап бөек рәссамнарның үлемсез картиналарын карап уздык. Шушы дөнья бәясе җитмәс байлыкны җыеп калдырган Иван Цветаевның кызы, бөек шагыйрә Марина Цветаеваны совет хөкүмәтенең җәбер-золымы ахыр чиктә безнең Алабугада асылынып үләргә мәҗбүр итте. Мәскәү язучыларының гына түгел, Татарстан язучыларының да хурлыклы бер сәхифәсе дияр идем ул фаҗигане...

Без Манеж мәйданындагы җир асты сәүдәсен дә тиз генә карап чыктык. Бусы безнең кебек долларсызлар өчен бик ят дөнья иде.

Тротуардагы китап рәтләрен дә карап уздык. Миргазыян бит ул интеллектуаль — аның белән йөргәндә күп нәрсәне белеп каласың...

Икенче көнне дә Миргазыян мине иске-яңа Мәскәү белән күпмедер таныштырып йөрде. Ләкин Мәскәү тиз туйдыра торган кала. Элек әйбәт заманда килеп, «Мәскәү» кунакханәсенә урнашып булган чакларда да минем тизрәк кайтып китәсем килә башлый иде. Хәзер инде ул миңа бөтенләй ят кала. Миргазыян да шуны сизгәндәй, мине озак әлсерәтеп йөртмичә, үзенең кайсыдыр тарафтагы ерак торагына алып китте... Кайтып җиткәч, ул тәбәнәк өстәлгә җыйнак кына табын әзерләде, хуҗабикә авырып тора икән, шуңа карамастан Рәисә ханым

минем белән көрешергә торып чыкты... Аннары без, ике акыл иясе, кара-каршы утырып, җиңелчә генә сыйлана-сыйлана, бик ихлас, бик ачык сөйләшүебезне дәвам иттек. Бөтен мәсьәләдә дә карашларыбыз туры килә дип әйтмәс идем. Әмма шуңа карамастан без бер-беребезне бик яхшы аңлыйбыз. Фикри бәйсезлек һәм аңлаша белү кешеләрне чынлап якын итә дә, минемчә.

...Тагын беркөнне без Әкъдәс Борһанов белән Мәскәү буйлап йөрдек. Бу йөрүнең соңыннан минем өчен гаять мөһим нәтиҗәсе дә булды.

Эш шунда ки, тарихыбызда Таһир Ильяс дигән шактый мәгълүм кешебез бар. Гарәп телен камил белүче, гарәп-татар сүзлеген чыгара башлаучы, «Мөхәммәдия» хәлфәсе һәм «Хөсәения»нең баш мөдәррисе, соңыннан Мәрҗани мәчетенең имамы... Аерым әйтү кирәктер, Таһир Ильяс Мәрҗани хәзрәтләренә кияү тиешле, минем карчык Наҗия апагызның әтисе. Билгеле ки, үзе галим, үзе имам кеше Сталин репрессиясеннән читтә калмый, 30 нчы елның башында ук кулга алына, 5 елга хөкем ителеп, Беломорканалга җибәрелә һәм шундагы ачлы-туклы авыр эштә ватылып, имгәнеп, ахыр чиктә һәлак тә була.

Репрессия корбаннарын аклау күптән инде дәвам итә. Таһир Ильяска кагылганмы аклау — менә шуны безнең бик беләсебез килә иде. Наҗия апагыз шул хакта Казандагы органнарга кат-кат язып карады. Казан үз нәүбәтендә Мәскәүгә мөрәҗәгать итеп карый — әмма алардан «Таһир Ильясов эше бер җирдә дә табылмады» дигән җавап кына килә. Акланганмы-юкмы — һаман билгесез булып кала бирә.

Мәскәүгә баргач та мин хәрәкәт итеп карамакчы булдым. Президент администрациясе карамагында бугай, репрессия корбаннары эше белән шөгыльләнүче кеше бар, ул — академик Александр Яковлев... Исәбем — мөмкин булса, шуңа керү иде. Ул инде аклау мәсьәләсен үзе генә дә хәл итә алыр дип уйлый идем. Теләгемне Әкъдәс дуска да әйттем. Ул академик Яковлев белән таныш та икән — белешергә вәгъдә итте... Һәм тиз арада миңа шалтыратып, Яковлев чит илдә икән, кайчан кайтасын ачык кына белмиләр дә, диде. Шунда ук ул, син, Әмирхан абый, хәзерге ФСБ (элеккеге КГБ шулай атала) директоры исеменә гариза язып калдыр, анда бу эшнең очына чыгарлар, дип киңәш тә бирде.

Башка чарам калмагач, мин Әкъдәс киңәше белән әлеге шул ФСБ дигән органның директорына, гозеремне аң-

латып, кыскача гына гариза яздым. Һәм Әкъдәс белән очрашкач, ул мине ФСБның кабул итү йортына алып китте. Кузнецкий мосттагы шул йортка барып кергәч, анда утыручы өлкән бер офицер безгә, әнә ящик, алып килгән материалыгызны шунда салыгыз, диде. Мин икеләнә калдым, берәр зуррак начальник кулына үзем тапшырырмын дип килгән идем. Инде нишләргә?.. Ләкин Әкъдәс мине тынычландырды: бу йортта тәртип шундый, борчылма, бикле ящиктан алырлар, укырлар, җавап та бирмичә калмаслар, диде. Шуннан соң мин гаризамны, төрле белешмә кәгазьләрен салып ябыштырган конвертны ишек төбендәге торган зур ящикка, эчемнән генә бисмилла әйтеп, төшереп җибәрдем...

Инде бу изге эшне үтәп чыкканнан соң, без озак йөрмичә, Әкъдәснең әллә кайсы тарафтагы өенә кайтып киттек. (Кабатлап әйтәм, чөнки мин бу бинихая зур калада Җир шарының дүрт ягын юньләп чамалый да алмыйм.) Кайтып, янәшә утырып әйбәт кенә сыйландык. Мәскәү табыны башкарак, сыйның күбесе импортный. Миңа тансык... Әкъдәс безгә килсә, аңа татар ашлары тансык. Без бик иркенләп, бик күп сөйләшәбез. Ул зур галим, мин язучы гына, ә шулай да сүзләребез бик килешә.

...Хәзерге дәүләт органнарына ышану күптән бетте. Мин калдырган гариза да комга киткән су кебек югалыр, бернинди дә нәтиҗә бирмәс дип уйлаган идек. Әмма Ходаның хикмәте, ике ай чамасы вакыт үткәч, һич көтмәгәндә, шул ФСБ дигән хәтәр җирдән безгә җавап килеп тә төште: Таһир Әхмәтҗан улы Ильясов Русия Генераль прокуратурасы тарафыннан 1989 елның 3 мартында реабилитацияләнгән икән. Шулай итеп, Мәскәүгә баруым әрәмгә китмәде — күптән беләсе килгәнне, ниһаять, белдек. Моны куанычлы хәбәр дип әйтергә ничектер тел бармый — башта үтереп, соңыннан аклауны җан кабул итә аламыни?! Әмма җанны гел борчып торган бер мәсьәләнең ачыклануы ниндидер тынычлану китерде дип әйтергә, бәлки, ярый да торгандыр.

Мәскәү өчен бер атна бик кыска вакыт. Ләкин безнең заман өчен анысы да күп. Кеше монда яшәр өчен, урыс әйтмешли, зырлап бөтерелергә тиеш. Менә минем дә бөтерелә торгач, китәр көнем килеп җитте.

Бу көн — 27 август иде бугай. Без академик Әдеһәм Тенишев белән «Татарстан» поездында, бер үк вагонның бер үк купесында кайтырга тиешбез (билетларны ул үзе алдан ук шулай алып куйган иде). Августның соңгы көне Татарстан мөстәкыйльлеге игълан ителгән көн — зур

бәйрәм көне. Әдеһәм әфәнде менә шул бәйрәмгә чакырылган. Бу тантанага генерал Рәсим Акчурин да барырга тиеш икән, ләкин бездән бер көн соңрак китмәкче. Шулай да ул Фуат белән мине үзенең бик шәп иномаркасында Казан вокзалына илтеп куйды. Без әле поезд кузгалганчы купеда бераз сөйләшеп утырдык — фотога да төшерделәр. Мактану булса булыр, әмма минем өчен затлы кешеләр белән аралашу — бу заманда үзе бер зур юаныч...

«Татарстан» поездын бик мактыйлар. Яхшы икәнен мин дә беләм, ләкин күптән утырганым юк иде. Хәзер монда, самолеттагы шикелле, кичке чәйгә тәмле ризыклар да бирәләр икән. Менә без дә Әдеһәм әфәнде белән, кара-каршы утырып, шул ризыклар белән тәмләп чәй эчәбез. Сөйләшкән сүзләребезгә дә гүя тәм керә. Ә поезд безне нык селкетмичә генә алга чаба... Казанга бару татар кешесендә милли горурлык хисе уятмыйча калмыйдыр. Һәрхәлдә, шулай уйлыйсы килә... Казаныбыз берничә ел эчендә шактый төзекләнде, чистарды, матурланды. Килүчеләр дә күбәйде. Калабызга шул килүчеләр күзе белән карарга тырышам. Ирексездән ике бөек шагыйрьнең аның хакында әйткәннәре хәтергә килә: берсе — «Нурлы Казан» дип язган иде, икенчесе «Фахиш шәһәр» дип атады... Беренче шагыйребез пар атта килгәндә, каланың нечкә манараларын еракта күреп, шатлыгыннан «Нурлы Казан» дип оран салса, икенче шагыйребез Казанга килеп күпмедер торгач, аны «Фахиш шәһәр» дип, нәфрәтләнү белдерергә мәҗбүр була. Бусы инде нәп вакытында. Һәм, әйтергә кирәк, ул чактагы Казан белән хәзерге Казан арасында эчке бер охшашлык та бар кебек.

Әмма нинди генә булмасын, Казан саф үзебезнеке — ятим калган манарасы белән бәгырьләребездә саклана ул!..

Мин Мәскәүдә йөргәндә, бик әйбәт яңа кризис башланган иде. Баштарак мин моңа артык әһәмият бирмәдем — кайчан соң безнең кризистан чыкканыбыз бар, дип уйладым.

...Казанга кайткач, мине бу яңасы чынлап уйландыра башлады. Бәйрәм көннәре минем иң тыныч көннәрем. Берәү дә килми, чакырмый, борчымый... Татарстанның ярты-йорты мөстәкыйльлегенә караганда, миндә, ичмасам, тулы мөстәкыйльлек. Президентыбыз Минтимер әфәнде Шәймиев бәйрәм уңае белән мөхтәрәм кунакларын һәм яраннарын ияртеп, алдан җырлап-биеп баручыларга

кәефләнеп, Болак буен карап узганда, мин, түшәмгә карап, кризис турында уйланып яттым. Чыннан да, яңасы искесенә караганда күп мәртәбә әшәкерәк икән. Нәкъ 1992 ел башында шикелле, бусы да безне бер тәүлек эчендә тагын хәерчелек төбенә ыргытты. Барлы-юклы акчабыз берьюлы өч тапкырга кимеде. Ә бәяләр... Бәяләр көне-сәгате белән, шаян тиен шикелле, югары үрмәләде...

Хуш, инде нишләргә? Тагын яңа хөкүмәтнең кризистан чыгу чараларын тыңлап, ач утырыргамы? Һәм, гомумән, кризистан чыгып булачакмы соң? Берсе артыннан икенчесе килеп кенә тора лабаса!..

Шушы уңай белән бер япон язучысының дөнья шаулаткан романы хәтеремә килде. Күптән укыганга күрә, романның исеме онытылган, әмма төп вакыйгасы истә. Ул менә нидән гыйбарәт: бер хатын комлыктагы шактый тирән чокырга, ялгыш таепмы, төшкән була. Ләкин күпме генә азапланса да, чокырдан кире чыга алмый. Үрмәләп менгән саен, чокырның комы ишелә дә ишелә, ком белән бергә хатын да түбән шуып төшә дә төшә...

Ахырда хатын, ишелә торган комны җиңә алмыйча, шул чокыр төбендә бөтенләйгә торып та кала. Аның янына әле бер ир дә төшә. Шунда алар бергә тора да башлыйлар... Роман аларның чокыр төбендә ничек яшәүләрен тасвирлый. Бердән, мистик, икенчедән, фантастик бу әсәргә ышанмаска да була. Әмма ком чокырына бер эләксәң, кире чыга алмыйсың икән... Менә безнең кризислар да ком чокыры түгелме соң? Чыгып кына булмый лабаса!..

Әйтәләр, кризис кемнәргәдер бик файдалы, дип. Димәк, аны юри дә ясап була икән. Исегезгә төшерегез, бичара Кириенко кризистан чыгу чараларын игълан иткәч кенә, Ельцин, борынын сеңгергәндәй, аны алды да ташлады. Шунда ук ата бүре Черномырдин хакимияткә яңадан кайтыр өчен өтәләнеп йөри дә башлады... Чөнки аңа «Газпром» байлыкларын саклау кирәк иде.

...Авыр болытларны җил тарата, ә авыр уйларны нәрсә тарата ала? Ихтимал, хәтердә сакланган күптәнге берәр кызыкны искә төшерү ярдәм итә торгандыр. Менә минем дә башны әзрәк җилләтер өчен әллә кайчангы бер кызыкны искә төшерәсем килеп китте.

...Сугыштан соң бөлгенлек тә көчле, Сталин да яши иде әле. Шулай да без, фронттан исән-сау кайткан язучылар, җиңелчә бер хөрлек тоеп, үзара еш кына очрашырга, чамалы гына сыйланып, җитди сүз арасына кызык-мәзәк тә кыстырып, кәефләнеп утырырга ярата идек.

Көлү-көлдерүсез бер генә очрашу да узмый торган иде. Моның Әхмәт Фәйзи, Салих Баттал кебек үз осталары да бар иде. (Хәзер инде мин көлүне оныттым диярлек...)

Мәрхүм Әхмәт Фәйзи белән без күптәнге якын танышлар идек, аңа бик ияләшкән дә идем, серләребез дә килешә иде. Мәскәүдә торса да, ул Казанга бик еш килә, озак кына торып та китә иде.

Бер килүендә ул, тансыклаган ризыгын исенә төшергәндәй, миңа әйтте:

— Беләсеңме, Әмирхан, минем мичтә пешкән шулпалы бәлешне агач кашык белән ашыйсым килә,— диде.

Аның бу бик табигый теләген аңлавы читен түгел иде. Мәскәүдә бит миче дә юк, агач кашыклары да юк, ә хатыны Елизавета ханым татарның шулпалы бәлешен, бәлки, ишеткәне дә юктыр. Ә бездә барысы да бар: зур мич тә, тирән таба да, кизделе ашъяулык белән агач кашыклар да... Гөлсем ханым шулпалы бәлешне бик әйбәт пешерә дә белә. Шулай булгач, мин Әхмәт Фәйзине сагынган тансык ашы белән сыйларга булдым...

Очрашкач, үзенә: «Иртәгә син теләгән шулпалы бәлеш булыр, миңа килерсең»,— дидем. Ул бүлмәсе буйлап йөри-йөри тамагын кыргалады, башын селеккәләп, кулларын да угалады, хәтта әле: «Ну егет тә син, малай!» — дип тә куйды. Мин әле аңа, бәлешне ашау тәмлерәк булсын дисәң, үзең теләгән берәр дусны да алып кил, дидем.

...Икенче көнне Әхмәт Фәйзи, Салих Батталны ияртеп, төшке аш вакытына килеп тә җитте.

— Мәрхәбә! — дип каршы алдым үзләрен.

Безнең пружиннары төртеп торган бер иске турецкий диваныбыз бар иде. Кунак чакырганда, урталай бөкләп, аңа чиста палас яба идек. Мин кунакларымны шул «затлы» диванга утырттым. Өстәлгә кизделе ашъяулык җәелгән, тәлинкәләр белән агач кашыклар куелган иде.

Менә бераздан яңа гына мичтән чыккан, өстенә тастымал капланган, кабарып торган шулпалы бәлешне Гөлсем апагыз, тирән табаны ике ягыннан калын чүпрәк белән тотып, көчкә өстәлгә китереп куйды. Мин таба өстеннән тастымалны алып, башта үткен пычак белән бәлешнең капкачын ачтым, аннары кырыен әйләндереп кисеп чыктым һәм туракладым. Бәлешне үз камыры белән ашыйлар... Бәлешнең эченнән хуш исләр күтәрелгәч, шагыйрьләрнең борыннары да киерелде, йөзләренә илһам галәмәтләре дә чыкты.

Яшь сарык итеннән, яңа бәрәңгедән пешерелгән бә-

леш эчен зур кашык белән тәлинкәләренә өеп салдым, икешәр кисәк кырыен да куйдым.

— Ягез, агайлар, бисмиллагызны әйтеп җитешегез! — дидем.

Ләкин алар «ташланырга» ашыкмадылар, түзделәр. Үзләре алып килгән «шифалы су»ны берәр рюмка күтәргәч кенә, бәлешне бик әйбәтләп «ура» башладылар. Әлбәттә, тансык ризыкны мактый-мактый, Гөлсем ханымга рәхмәтләрен әйтә-әйтә ашадылар. Тәлинкәләргә тагын мул гына өстәп салганнан соң, бәлешнең калган яртысын мин кухняга чыгардым. Пешерүче белән кызларыма...

Билгеле инде, авыз үз эшен үтәгәндә, телебез дә тик тормады. Бәлеш янында сөйләшү аеруча тәмле, кызыклы иде.

Әхмәт тә, Салих та сүзгә гаять җор, тапкырлар, бер-берсен уздырып, ниләр генә уйлап тапмыйлар... Рифмалап әйтергә дә бик осталар. Батталның: «Килеп керде бер бабай — Берды Кербабай»,— дип әйткәне кебек. (Сүз Төрекмәнстанның халык язучысы турында бара.) Кызганыч ки, алардан җиңел генә чәчрәгән сүз чаткыларын тотып, терки белмәгәнбез. Шулай да Әхмәт Фәйзинең чәй көткәндә әйткән бер шигъри мәзәге әле дә булса хәтердә.

Былтырмы-быелмы Фәйзи санаторийда булган. Ул елларда санаторийга килгән кешене башта ваннага кертәләр, шуннан соң гына палатага урнаштыралар иде. Менә Әхмәтне дә Анна исемле чибәр генә бер сестра иң элек ваннага алып керә. Һәм шул чакта Әхмәт күңелендә ирексездән дүрт кенә юллык «шигырь» дә туа. Шуны ул безгә чәй көткәндә әкрен генә кабатлады:

Барып кердем Аннага,
Алып керде ваннага.
Торып була ваннасыз,
Чыдап булмый Аннасыз...

— Кыһым, кыһым,— ди Фәйзи, төкеренгәндәй итеп, ә без Баттал белән эч катканчы көләбез генә.

Моннан 50 ел элек ишеткәнне бүген искә төшергән өчен тәүфыйклы укучылар мине, шәт, кичерерләр дип ышанам. Безнең дә бит сөлектәй ир чакларыбыз бар иде, беләсегез килсә!

...Әхмәт Фәйзинең Казанга тагын бер килүендә мин янә шундый ук «шулпалы бәлеш» оештырдым. Бу юлы Әхмәт үзе белән Сибгат Хәкимне алып килде. Мәрхәбә! Күңелгә хуш кунаклар...

Сибгат та бик мәртәбәле кеше. Аңардан да бик хикмәтле сүзләр чыга иде. Әйтәчәк сүзен көтеп ала торган идек.

...Алдыбызда киҗеле ашъяулык, агач кашык, шулпалы бәлеш. Утырганнар фиркасез Әхмәт, коммунист Сибгат, морза Әмирхан — юк, без мотлак бер имандагы чын татарлар...

...Таң ата да кич була... Тагын күпме кабатланыр икән. Сизәм, көннәр беләп бергә көч-хәл дә әкренләп китә тора. Соңгы ноктага тизрәк барып җитәсе килә. Сүзне кыскарак тотарга кирәктер, ахрысы...

...Минем Ельцин чоры беткәнен күрәсем килә иде. Мәгәр аның үзенә әҗәл теләмәдем бервакытта да. Җаһар Дудаевны алдап үтертсә дә... 1996 елның ноябрендә хирург Ринат Акчурин, Президент йөрәгенә бик җаваплы операция ясап, үлемнән алып калгач, мин «Сихәтләнү» дигән мәкалә бастырып, аның исән-сау озак яшәвен дә теләгән идем. Хикмәт шунда, 1917 елдан соң ил белән идарә иткән большевик җитәкчеләренең барысы да эшләгән эшләренең ахырын күрмичә үлеп киттеләр. Лениннан алып Брежневка хәтле... Һич югы, господин Ельцин Русияне нинди һәлакәт чигенә китереп җиткергәнен күрсен иде, дигән теләгем бар иде. Билгеле, ул эшләгән хаталары һәм җинаятьләре өчен үкенә торган кеше түгелдер, әмма җиде ел буена алданып һәм таланып яшәргә мәҗбүр булган халыкның ачу-нәфрәтен ишетергә тиештер ахыр чиктә...

...Инде аның хакимлек итү вакыты да күп калмады, авырудан да башы чыкмый, идарә итү дә башкалар кулына күчте диярлек. Ләкин шуңа карамастан Думадагы коммунистлар, авыруын сылтау итеп, аны хәзер үк Кремльдән кумакчы булалар. Бу кадәресе, миңа калса, инсансызлык... Хәер, хакимият өчен сугышканда нинди инсанлык булсын ди?! Борис патша да нәзакәтлеләрдән түгел — Думаның үзен пыр туздырып кумагае. Яңа президент сайлаганчы әлләниләр булып бетәр әле — исән-саулар күрерләр.

Большевикларның гамәлләренә торып-торып ис-акыллар китә. Кайчан гына әле алар хосусый милекнең иң явыз дошманнары иде, күпме хосусый милекчеләрне (мәсәлән, кулакларны) кырып бетерделәр. Инде базар мөнәсәбәтләренә күчкәч, иң беренче, иң комсыз хосусый милекче — байлык җыючы да шулар булдылар. Шулар аркасында без икенче тапкыр инде тирән бөлгенлеккә кереп баттык. Халыкның 90 проценты хәзер Ельцин-

ның хакимияттән китүен таләп итә. Ихтимал, алдагы сайлауларда власть сул коммунистлар кулына күчәр, ә уң коммунистлар (хәзерге демократлар) оппозиция булып оешырлар. Менә берзаман шулар үзләренең демонстрацияләренә Ельцин портретын күтәреп чыгарлар. Байракларына базар кирәк, тауар кирәк, хосусый милек кирәк, дип язарлар.

...Сиксән ел инде большевиклар безне сарык көтүедәй бер урыннан икенче урынга куып йөртәләр. Гомер буе шуларга буйсынырга мәҗбүр булып, ялган, ясалма тормышта яшәргә туры килде.

Әйе, большевизм куркыныч, бик куркыныч! Аңа ышану мөмкин түгел. Кешегә үз ихтыяры белән, үзе теләгәнчә, әмма берәүнең дә хакына тимичә яшәр өчен буыннар алмашынуы кирәк булачак.

Сәясәткә һич тә кагылмас идем, ләкин ул үзе миңа кагыла — көндез дә, кич тә, өнемдә дә, төшемдә дә... Тәмам каныкты, явыл! (Бу — дьяволның мишәрчә варианты.)

Коммунистлар яңадан хакимияткә килә калсалар, безнең мөстәкыйльлек белән нәрсә булачак? Хокуксыз автономиягә кире кайтумы, әллә зур бер губернаның кечкенә өязе булып калумы? Үтә сәяси мәсьәлә ич бу... Һәм аны Татарстан файдасына хәл итәр өчен бик көчле сәясәтчеләр дә кирәк булачак.

Шундый сәясәтчеләрдән бүгенгесе көндә иң ышанычлы төп терәк — Минтимер Шәймиев. Кайберәүләрнең ачуларын китерсәм дә, мин моны турыдан-туры әйтәм. Дөрес, Шәймиев тә коммунист-демократ, әмма ул инде Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгытуда, аның иминлеген саклауда һәм аны җиһанга танытуда бик күп тырышлык, бик зур осталык та күрсәтте. Шуның белән ул үзенә дә, халкына да онытылмаслык дан-шөһрәт тә китерде. Моңарчы күпләргә билгесез хәтәр исемле халыкны дөнья мәйданына чыгару бик мөһим вакыйга дияр идем мин.

...Дөрес, Шәймиевнең милли сәясәтен каты тәнкыйтьләүчеләр дә булды. Хәтта аны президентлыктан төшерүне таләп итүгә хәтле дә барып җиттеләр. Әле дә тынганнары юк шикелле. Сәбәп нәрсәдә соң? Радикал милләтчеләр фикеренчә, ул, Шәймиев, янәсе, Татарстанга тулы мөстәкыйльлек алып бирә белмәде. Мәскәүгә күп ташламалар ясады, Республикабызны аның сателлиты итеп калдырды.

Белмим, бу бик җитди гаепләрнең күпмесе хаклыдыр — тарих кайчан да булса үзенең гадел хөкемен чы-

гарыр. Әмма ләкин бик гыйбрәтле бер фактка без күз йома алмыйбыз. Минтимер Шәймиев ирешкән уңышлар башкаларга да үрнәк булды. «Татарстан моделе» дигән нәрсә юктан гына тумады ул...

Ләкин бу әйткәннәребез медальнең бер генә ягы. Аның әле икенче ягы да бар. Анысы — Татарстанның әчке хәле. Тышкы мактаулы ягын телевизордан күреп белсәк, әчке хәлен үз җилкәбездә татып беләбез. Бер сүз белән генә әйткәндә, алама безнең әчке хәлебез... Бездә генә түгел, бөтен Русия күләмендә бик алама. Җиде ел инде без шушы алама режимда яшибез. Бу режим социализмны ташлап, капитализмга күчеп маташу аркасында туды. Һәм иң аянычы — ул күпчелек халык өчен беренчесенә караганда әшәкерәк булып чыкты. Аның тәгаен генә үз исеме дә юк — ул инде социалистик режим да түгел, чын, табигый, законлы капиталистик режим дип тә атап булмый. Шуңа күрә аны кеше исеме белән атап йөртәләр: Ельцин режимы, Лукашенко режимы, бездә инде мөхтәрәм Шәймиев режимы.

Мин бу режимның илгә күпме бәла-каза китергәнен, халыкны чиге күренмәгән газап-нужага дучар иткәнен язып тормыйм... Бишектәге бала гына аларны белми торгандыр. Ул да, бичара, сизеп ята торгандыр әле...

Ләкин бер объектив дөреслекне әйтмичә китү ярамас. Бездәге режим мөстәкыйльлекнең баштагы елларында күп өлкәләргә караганда җиңелрәк иде, халкыбыз да, гомумән, тук вә тыныч кына яши иде. Мәгәр елдан-ел без шушы өстенлекне югалта бардык. Арттагылар, безне узып, алга чыга башладылар. Инде бу соңгы күтелмәгән кризиска да без бик тирән кереп баттык. Акчасызлык безне хәзер кычкыртып буа. Ни генә эшләргә уйласак та, акчасызлыкка килеп терәләбез. Хәтта китап чыгару туктатылды бит... Без, татарлар, Русия империясендә иң күп китап чыгарган халык әнә нинди хурлыкка төштек... Безнең җитәкчеләр, күрәсең, республиканың икътисади хәлен дөрес чамалый белмәгәннәр. Республикабыз табигый байлыкларга чагыштырмача ярлы — нефть белән икмәктән башка байлыгыбыз юк. Бердәнбер нефтьтән килгән акчаны да урынлы-урынсыз исраф иттек. Ул акчаның да күпмесе казнага, күпмесе кесәләргә кергәнен бер Ходай үзе генә белә торгандыр. Һәрхәлдә, Казанны әйләндереп алган меңнәрчә яңа йортларның бик күбесе хәрам акчага салынган булуларында шик юктыр...

Шулар өстенә безнең үзебезгә генә хас җитди пробле-

маларыбыз бар: иң элек Татарстанның мөстәкыйльлеген саклау... Икенчедән, татар халкының милли мәнфәгатьләрен яклау. Бер-берсе белән бик тыгыз бәйләнгән проблемалар. Әмма бүгенге шартларда аларны хәл итәр өчен башта икътисади һәм иҗтимагый тирән кризистан чыгу кирәк. Бөлгенлектә яшәүче халыкта милләт кайгысы булмаячак. Тамак хакына кеше коллыкка да риза... Димәк, халыкның яшәү шартларын җиңеләйтү беренче нәүбәттә торган иң төп максат булырга тиеш.

Кызганыч ки, безнең Татарстан халык җөмһүрияте була алмады. Ул, асылда, чиновниклар дәүләте булып калды. Хакимият, закон, байлык чиновниклар кулында — ни эшләсәләр дә аларга ярый, беркем алдында җавап тоту юк. Сүз, билгеле, хакимияттәге эре түрәләр турында бара. Алар үзләренә аерым бер таифә (каста) булып оештылар, халыктан тәмам аерылдылар, бөтен гамәлләрен яшереп, посып яшиләр. Халык үзе дә төрле груһларга бүленеп бетте. Бер-берсеннән ераклашты. Яңадан ике дошман сыйныф — азчылык байлар белән күпчелек ярлылар сыйныфы туды дияргә дә була. Коммунистларның көчәеп, хакимияткә омтылулары да шуның аркасында.

Менә бу бик хәвефле, гайре табигый хәлдән чыгу кем өстенә төшә? Билгеле инде, беренче нәүбәттә Президент өстенә! Ул татар халкының танылган лидеры. Халык та әле аңа ышана, аңардан көтә.

...Минтимер Шәрипович дәүләт белән идарә итүдә күп тәҗрибә туплаган кеше. Акыллы, ягымлы җитәкче. Халык белән дә күп аралаша, кирәксә, йомшак кына юата да белә. Ә халыкны ишетү, аңлау аның үзенә дә бик кирәк. Тик кызганыч ки, Президент белән халык арасында бик тыгыз номенклатура сафлары тезелеп тора. (Алар арасында элек коммунист булмаган бер генә кешене дә күрмәссең.)

...Кеше гадәт колы, дигән Достоевский. Номенклатураның төп сыйфаты да «хуҗа»га ялагайлану, ярау. Дөресен яшерү, булмаганны бар дип күрсәтү... Боларның барысы да партия диктатурасы заманыннан сеңеп калган гадәтләр. Идарә итү эшләрендә ул гадәтләрнең никадәр тере булуын без һаман да тоеп яшибез.

Без хәзер бөтен Русия күләмендә аеруча көчәеп киткән кискен көрәш чорын кичерәбез. Билгеле, ул рәхимсез, канлы көрәш безне дә читләтеп узмаячак. Гаять катлаулы бу вазгыять Президентыбыздан бик ачык, принципиаль позициядә нык торуын таләп итә. Үткәнгә кире кайтумы, әллә алга баруны дәвам итүме? Әгәр чын

демократ икән — ә без аның бары чын демократ булуын телибез — ул алга баруны сайларга тиеш. Бу очракта инде ул оппозициягә юл ачарга, милли хәрәкәтне дә кысмаска тиеш булачак.

Тулы мөстәкыйльлеккә юлыбыз озын булачак. Бу юлны үтәр өчен ике нәрсә таләп ителә: беренчедән, Идел-Урал арасында бик борыннан яшәп килүче, язмышлары бертөсле халыклар, милләт буларак сакланып калу өчен, үзара якынаерга һәм ничектер берләшергә тиеш булачаклар... Икенчедән, һәр республика үзенең эчке хәлен бик нык кайгыртырга тиеш. Туклык-иминлек, социаль гаделлек, законлылык, тәртип-низам — менә нәрсәләр зарур аларга... Шулар булса гына авыр сынауларны сынмыйча үтеп булачак.

Әлбәттә, моның кебек олы максатка ирешү өчен Илбаш тирәсендәге номенклатура гына җитмәячәк. Халыкның уянуы, бердәм хәрәкәт итүе кирәктер... Халык бит ак белән караны аера белә. Айнык акыллы, рухи таза көчләр дә җитәрлек. Президент беренче нәүбәттә әнә шуларга таянырга тиештер дә мотлак!..

...Биредә язганнарым кемгә дә булса акыл бирү түгел. Бу минем ялгыз башыма борчылып уйлануларым — укучы аны шулай гына кабул да итәргә тиеш.

*«Мәдәни җомга», 1998*

## ТАТУЛЫКНЫ ГАДЕЛЛЕК БЕЛӘН ТИГЕЗЛЕК КЕНӘ САКЛЫЙ АЛА

*— Әмирхан ага, Сез татарның иң өлкән әдипләреннән берсе, тугыз дистәне очладыгыз. Шуңа күрә дә әңгәмәбезне Сезне юбилей белән котлаудан, «Әссәламегаләйкем, остаз!» дип, хәл-әхвәл сорашудан башлыйк әле. Ни хәлләрдә яшәп ятасыз, сәламәтлегегез, көн күрмешләрегез ничек?*

— Мин күптәнге пенсионер, сугыш ветераны, пенсиям моңарчы көн итәргә җитеп килде... Сәламәтлегем дә, Аллага шөкер, ару гына иде, мәгәр узган көздән еш кына авырый башладым. Хәлсезлек көчәйде, 90 яшь үзенекен итә, күрәсең.

*— 90 еллык бәйрәмегез уңаеннан халыктан һәм хөкүмәттән нинди кадер-хөрмәт көтәсез?*

— Хөкүмәттән берни дә көтмим, ә халыкның минем язганнарны кызыксынып укуын телим. Шунсына да бик канәгать булыр идем — заманына күрә!

*— XX гасыр татар әдәбиятында Әмирхан Еники иҗаты турында нәрсә әйтер идегез?*

— Бу сорауга җавап бирү минем өчен шактый читен эш... Язучы бит бервакытта да үзенә һәм иҗатына объектив дөрес бәя бирә алмый. Бу — әдәбиятчылар эше... Менә 90 яшькә җитү уңае белән миңа багышланган язмалар чыкмыйча калмас — әнә шулардан инде белеп булыр фәкыйрегезнең нинди язучы икәнен дә.

*— Татарлар — 250 миллионлы төрки халыклар гаиләсенең бер әгъзасы. Соңгы вакытларда төрек матбугатында төрки халыклар суперэтносының формалашып килүе сизелә, дип язалар. Әле XIX гасырда ук мәшһүр галим һәм фикер иясе Исмәгыйль Гаспралы төрки халыкларны берләштерүне иң бөек максат итеп куйган иде. Аның «Телдә, фикердә, эштә берлек!» дигән шигарен хәтерлисездер. Сез бу шигарь белән килешәсезме, ул бүген дә актуальме? Сезнеңчә, татар халкы киләчәктә нинди юл белән барырга тиеш? Аерыммы, әллә берләшепме? Һәм кем белән, нинди өлкәләрдә берләшеп?*

— Бу үтә җитди, бик зур мәсьәлә! Мәгълүм ки, унҗиденче елга кадәр Рәсәйдәге төркиләр зур бер империянең колониаль халыклары булып санала иде. Колониаль халык буларак, шул империя законнарына буйсынып яшәргә дә мәҗбүрләр иде. Диннәре бер булганга күрә, аларны бер исем белән — «мусульмане» (яки мәсхәрәләп — басурманы) дип кенә йөртәләр дә иде. Мәсәлән, казахны кыргыздан аерып тору юк иде.

Әнә шул мөселман — төркиләр ул заманда, бик табигый рәвештә, бер-берсенә якынрак та һәм ышанычлы таяныч та иделәр... Чөнки язмышлары бер, диннәре бер, язулары бер, телләре бер тамырдан, уртак сүзләре дә күп — кыскасы, бер-берсен җиңел аңлыйлар, төрки телләрдә чыккан китапларны да укый алалар иде.

Шуңа күрә дә Исмәгыйль бәк Гаспринскийның (гафу итегез, мин аның исем-фамилиясен элек бездә аталып йөргәнчә әйтәм), әйе, әнә шул төрки халыкларны бербөтен милләт итеп берләштерү идеясе ул заман өчен, ихтимал, бик мавыктыргыч булып күренгәндер дә... «Телдә, фикердә, эштә берлек!» дигән өндәве дә бик урынлы кебек иде... Әмма бөек мәгърифәтченең ул өндәүләре гамәлгә аша алмыйча калды. Моның өчен вакыт та кыска булды, шартлары да өлгереп җитмәде, аннары төркиләрнең милли-мәдәни җәһәттән тәрәккый итүләрендә аерма да бик зур иде... Мәсәлән, татар халкы кыска гына вакыт эчендә бик үсеп-күтәрелеп китте, ә башка халык-

ларда ул үсү-күтәрелү шактый әкрен барды. Бер генә мисал китерәсем килә: 1913 елда үзбәк телендә 37 китап, казахча — 40 китап чыккан булса, татарлар 340 исемдә китап чыгарганнар. («Мы и планета» дигән китаптан.) ...Гаспринский өндәвенең нигезендә телләрне берләштерү идеясе ята иде. Телләрне берләштереп, бөтен бер милләт булу... Әмма бу теләккә ирешүнең мөмкин түгеллеген тормыш үзе бик ачык күрсәтте... Үзара бик аралашып, җиңел аңлашып яшәгән төркиләрнең һәркайсы үз телен саклады, үз телендә кала бирде... Төрле телләрдән уртак бер тел ясау барып чыкмады — бер тамырдан булуларына да карамастан...

Унҗиденче елдан соң инде төрки халыкларны «мусульмане» (басурманы) дип кенә йөртү бетерелде. Һәр халык үз исеме белән яши башлады — кайберләре үзләренең борынгы иске исемнәрен дә кайтардылар.

Большевиклар партиясенең милли сәясәте диннәре бер, телләре дә бер диярлек халыкларны берләштерү түгел, бер-берсеннән аеру иде. Һәркайсына җирле автономия бирде. Бу автономияләр шул ук партия кул астында, ул күрсәткән юл белән яшәргә һәм милләт буларак «тәрәккый» итәргә тиешләр иде... Төрки халыкларның үзара берләшүе турында сүз дә булуы мөмкин түгел иде. Элек-электән үк дәвам итеп килгән Төркия белән якын бәйләнеш тә тәмам өзелде. Төркияне искә төшерү генә дә үзе бер зур гаептән санала иде. Пантюркизм дигән нахак гаеп белән күпме кеше һәлак тә булды. Әнә шундый хәвефле шартларда рухи кол булып, бер 60—70 ел яшәргә туры килде.

Инде менә колларча буйсынып яшәгән төрки республикалар, Советлар Союзы таралып китү аркасында, кинәт кенә бәйсезлеккә ирештеләр. Хәзер аларның бөтен кайгысы — шул бәйсезлекне ныгыту, үзләрен дөнья күләмендә мөстәкыйль дәүләт итеп таныту һәм лаеклы урыннарын алу... Моның өчен һәркайсы үзен һәр җәһәттән үсә барган көчле милләт итеп танытырга тиеш булачак... Шуңа күрә аларда хәзерге көндә төркиләр үзара якынаерга, ничектер берләшергә тиеш дигән теләкнең туганы юк әле... һәркайсы үзе белән мәшгуль: үзбәкнең саф үзбәк, казахның саф казах, төркмәннең саф төркмән булып кына каласы килә... Аларда бит «ханнар» хакимлек итә, ә ханнар бүтәннәр белән кушылуны бер дә яратмыйлар.

Рәсәй эчендә торып калган төркиләрдә дә шул ук тенденция. Алыгыз татар-башкорт мөнәсәбәтләрен генә... Ничәмә гасырлар буе бер үк җирләрдә аралашып яшә-

гән бу бер-берсенә бик якын ике халыкның кушылуы турында сүз дә булуы мөмкин түгел, алар арасында тирән упкын хәзер. Моның төп сәбәбе — хокукый тигезсезлек. Бик аяныч, әлбәттә...

Бездәге чынбарлык хәзергә әле әнә шундый. Сез куйган сораудагы «Телдә, фикердә, эштә берлек!» дигән теләкнең максаты мавыктыргыч, әмма аларның һәркайсына ирешү өчен кирәкле шартлар өлгергән булырга тиештер инде... Әйтик, эштә һәм фикердә тора-бара нindидер бердәмлеккә ирешү бәйсез, мөстәкыйль төрки дәүләтләр өчен мөмкин булыр, иншаллаһ!

*— Исмәгыйль Гаспралы үзенең мәгълүм шигырен әйткән вакытта мөселман-төрки дөньясында язу һәм өлешчә тел берлеге булган, дидегез. Хәзер исә, мәгълүм сәбәпләр аркасында, төрки халыкларның үзара аңлашуы хәйран бер авыр эшкә әверелде. Сезнеңчә, телләребезне якынлаштыру чаралары бармы? Сез төркиләрнең гомуми язмасын булдыру турында нинди фикердә?*

— Инде тел мәсьәләсенә килгәндә, мин үзем төркиләр өчен нindидер уртак бер тел ясарга тырышуны кирәкле эш дип санамыйм. Күргәнебезчә, төрле телләрдән бер тел ясау мөмкин дә түгел... Әнә Аурупа илләре акчаларын берләштерәләр, ләкин телләрен һәм язуларын берләштерү турында уйламыйлар да... Немец немец, француз француз булып кала бирә... Ходай Тәгалә бит үзе шулай яраткан, халыкларны мең төрле итеп... Мең төрле булып яши дә белергә кирәк. Һәр милләтнең саф үзенчә булып калуы белән дөнья кызыклы да.

*— Әңгәмәбезнең икенче өлешенә күчеп, фани дөньяга әйләнеп кайтыйк әле. Әмирхан Еникиның нинди үкенечләре бар?*

— Мондый сорауны түрәләргә бирү урынлырак булыр иде. Шулай да әйтим: кешенең гамәле заман таләбе һәм тормыш шартлары белән бик нык бәйләнгән. Шул сәбәпле үз гомерендә үкенечле эше булмаган бер генә кеше дә юктыр дип беләм... Ләкин берәү дә үкенечле эшләрен фаш итәргә ашкынып тормый... Әмма безнең бөтен гамәлебезне Хак Тәгалә белеп тора — без бары Аның алдында, көне килеп җиткәч, җавап тотарга тиеш булачакбыз. Шулай түгелме?..

*— Татар барда — хәтәр бар, дигән гыйбарә яшәп килә. Дөрес, аны хәзер икенче мәгънәгә күчереп әйтергә омтылулар бар. Әмма, ничек кенә булмасын, бу гыйбарәне телдән төшереп калдырып булмый. Сез бу хакта ни уйлыйсыз?*

— «Татар барда — хәтәр бар» дигән гыйбарәне татар үзе чыгармагандыр, мөгаен. Башкаларны куркытыр өчен дошманнары чыгарган булса кирәк. Нәҗар Нәҗми бер шигырен «Хәтәр барда — татар бар» дип атаган иде. Менә бусы дөреслеккә күбрәк туры килә, минемчә...

— *Хәзер телебезгә байлар һәм ярлылар дигән төшенчәләр килеп керде. Кая карама — гаделсезлек. Сез җәмгыятьтәге гаделлеккә һәм тигезлеккә ышанасызмы?*

— Гаделлек белән тигезлек яшәүнең беренче шарты... Халыклар арасындагы татулыкны да бары гаделлек белән тигезлек кенә саклый ала.

— Сезгә исәнлек-саулык, җан тынычлыгы телибез. Безне илтифат итеп сорауларыбызга җавап биргәнегез өчен Аллаһның рәхмәте яусын!

*«Заман», 1999*

## ИГЕЗӘКЛӘР

Борис Немцов күптән түгел «АиФ» гәзитәсендә басылган кыска бер интервьюсында: «Россия — жестокая страна»,— дип әйткән иде. Татарчага әйләндерсәк, «Русия — мәрхәмәтсез ил» дип атарга да була. Ләкин минем «мәрхәмәтсез» дигән сүзгә «бәхетсез» дигән сүзне дә өстисем килә. Чөнки Русиянең бәхетсезлеге аның мәрхәмәтсезлеге белән нык бәйләнгән. Алар, сиам игезәкләре шикелле, бер-берсенә ябышканнар, аеру мөмкин түгел. Ерак тарихка кермичә, Русиянең соңгы ун елын гына алсак та, ул тоташ мәрхәмәтсезлек белән бәхетсезлектән гыйбарәт...

...Менә алты ел инде Русия Чечня белән тартыша. Заманында Берия Кавказ мөселманнарын гомер иткән җирләреннән төрле якка сөргән иде. Хәзер инде әнә бик кыю хөкүмәт җитәкчесе террорчыларның ике башлыгын тотар яки үтерер өчен дип, Чечняга меңләгән гаскәр кертте, иң яңа, иң хәтәр — усал коралларын ходка җибәрде... Әлбәттә, Басаев та ялгыз түгел, аның да үзе кебек меңләгән башкисәр террорчылары бар. Урыс генераллары башлыча шуларны эзәрлекләү, бетерү өчен бик каты эшкә керештеләр... Ләкин бит Ичкериянең хөкүмәте бар, президенты бар, ни өчен шулар белән сөйләшүдән, аңлашудан эшне башламаска?! Масхадов бит кайчаннан бирле Ельцин белән очрашып сөйләшүне зарыгып көтә...

Мин әйткәннәр террорчыларны аклау дип аңлашыла күрмәсен иде! Юк, мин җаным-тәнем белән террорга кар-

шы кеше. Бу хакта инде Чечня мәхшәренә чаклы ук язган да идем. Хәзер сүзем «мәрхәмәтсезлек» белән «бәхетсезлек» турында бара. Бер генә мисал: Дудаев вакытында Чечняда 1 миллион 200 мең кеше яшәгән, хәзер исә 350 мең кешесе калган («АиФ» гәзитәсеннән). Ягъни 70% кешесе юкка чыккан... Йә, бу бөтен бер халыкны таратып, туздырып, күпмесендер кырып бетерү түгелмени?! Шушы берничә айлык сугыш барышында гына да күпме авыл, күпме йортлар җимерелде... 300 меңләп кешесе тирә-якка китеп, качып котылырга мәҗбүр булды...

...Максат нәрсәдә соң, Чечня халкын мөмкин кадәр күбрәк бетерүдәме?.. Әмма бу Чечня халкына гына килгән фаҗига түгел, мәрхәмәтсезлек аркасында Русия халкы да елдан-ел һаман кими бара бит...

...Дошманлык ул һәрвакытта ике яклы. Иң аяусыз сугыш — дин өчен сугыш. Ачы хакыйкатьне Чечня террорчылары турында да ачык әйтергә кирәк... Аларның да ниндидер бик яман фанатик мәрхәмәтсезлеге күпме кешегә гомерлек бәхетсезлек китерде.

Әгәр ки илебездәге вәхши террорчылыкны тамырыннан корыта алмасак, ә алдагы сайлауларда Ельцинның үзенә охшаган кеше президент булып калса, безнең башлар «мәрхәмәтсезлек» белән «бәхетсезлек»тән тиз генә чыга алмаячак.

*«Татарстан яшьләре», 1999*

## ЮБИЛЕЙ САБАКЛАРЫ

Вакыт үз эшендә. Әзрәк тынып торыйк әле, дип әйтә белми — минем һәр мизгелемне «үтте-бетте» дип сызып кына бара...

Шушы 1999 елның март башында миңа 90 яшь тулды. Бу яшькә җитүемне мин күптән көтә башладым. Мәгәр җитә алуыма ышанычым аз иде. Кече яшьтән үк чирләш булдым. 16—17 яшемдә үпкәләремдә туберкулез башланды — ә ул бу яшьтәгеләр өчен иң хәтәр авыру... Әмма болардан бигрәк тормыш үзе мине бик иртә типкәләргә тотынды. Бик күп авырлыклар, кыерсытулар, кимсетүләр кичерергә туры килде. Бер сүз белән генә әйткәндә, хәзерге заманның бик модныйга әйләнгән зәхмәте — стрессны җитәрлек татыдым. Хәтта картайгач та, аңардан котыла алганым юк... Әмма шуларга карамастан, мин әкренләп 90 яшемә якынлаштым. Бер-

ничә генә ай, берничә генә атна үткәреп җибәрәсе калды. Тик шулай да җан тыныч түгел, килеп җиттем дигәндә генә китеп баруың да бик мөмкин бит... Картлыкның һәр көне исәптә. Әмма, мең шөкер, мин, ниһаять, 90 яшемә килеп җиттем. Күрәсең, нәселдән килгән тамыр тазалыгы моңа ярдәм иткәндер инде.

...Хуш, инде мин бу фәүкылгадә вакыйга уңае белән нәрсә эшләргә тиеш? Мин бит гап-гади генә бер кеше түгел — танылган язучы, «халык язучысы» дигән олы исемем дә бар, Тукай бүләге иясе, 90 яшьлек аксакал!.. Гадәттә, мондый кешенең «туган датасы»н игътибарсыз калдырмый торганнар иде. Ничек кенә булса да «юбәләен» үткәрәләр. Шундый көннең миңа да килеп җитүе мөмкин бит...

Бу хакта мин бик иртә уйлана башладым. Кирәкме ул туган көнне тантаналы бәйрәм итүләр? Минем өчен бу бик принципиаль мәсьәлә иде. Кеше һәм язучы буларак заманга карашым һәм мөнәсәбәтем белән бәйләнгән иде бу.

Әйтергә кирәк, Горбачевның «үзгәртеп коруы» җимерелгәннән соң, бигрәк тә Ельцин режимы урнашкач, миндә бик тирән рухи торгынлык башланды. Бөтен гомерем большевиклар чорында совет системасы белән килешә алмыйча узганнан соң, ниһаять, яңа демократик чорга керәбез дип, шуңа бик нык ышанып һәм куанып яши башлагач кына, көтмәгәндә тагын бик каты алдануны кичерүе минем яшьтәге кеше өчен гаять авыр булды, әлбәттә. Инде яңадан ниндидер яктылык күрүне өмет итү өчен вакытым да узган иде...

Тиздән туачак 1999 ел бигрәк тә авыр, алама, афәтле булыр кебек... 1998 елның 17 августында Кириенко дигән өлгер-шома бер егет Русияне тагы да тирәнрәк кризиска кертеп батырды. Кризисның бик әшәкесе булды бу. Хәер, Ельцин властька килгән көннән башлап, илнең кризистан чыккан чагы да булмады. Президент, пирчәткәсен алыштырган шикелле, хөкүмәт җитәкчеләрен алыштыра торды, мәгәр аларның берсе дә илгә җиңеллек китерә алмады. Экономика җимерелде, хәерчелек көчәйде, үзләре газ, нефть исәбенә котырып баеды, миллион-миллиард долларларын чит ил банкларына күчерә тордылар (гәзитләр бу хакта яшермичә язалар). Әмма болар өчен җавап тотучы юк. Чөнки алдау белән талау (ягъни коррупция) хакимиятнең иң югары даирәләренә үтеп керде. Чынлыкта власть белән байлык яңа номенклатура һәм банкирлардан гыйбарәт булган бик көчле һәм

кечкенә бер таифә (каста) кулына кереп бетте. Бу таифә властьны һич беркемгә дә бирмәячәк, әлбәттә... Хәтерлисездер, 1996 елны 13 банкир Ельцинны икенче тапкыр президент итеп калдырды. Сайлаулар нәтиҗәсен бездә тавыш түгел, акча хәл итә. Хәерчелектән тәмам миңгерәүләнгән халык теләсә кемгә сатылырга әзер... Шул ук Ельцинның өченче тапкыр да утырып калуы бик мөмкин — хәзер инде аның «династия»сен саклау турында сүз бара.

Киләчәге билгесез әнә шундый бер режимда яшәп ятабыз. Дөнья кызыксыз. Канәгатьсезлектән башка берни дә юк. Шулай булгач, нәрсә хакына «юбәләйләр» үткәреп тору?! Күңелем төшенке, теләк юк, сәламәтлегем дә бик чамалы. Үткән елның октябрь ахырында мин бик хәвефле кризис кичердем. Йөрәгем гүя тибүдән туктый башлады... Шушы кризистан соң мин бик хәлсезләндем, һәм бу хәлсезлектән минем хәзергә кадәр чыга алганым юк әле... Билгеле, мондый хәлдә юбилей кебек тантананы күтәрә алуым бик мөхәл (икеле) иде.

...Аннары хәзерге юбилейларның ничек итеп, кем исәбенә оештырылуын да мин бөтенләй белмим. Бу хакта миңа беркемнең дә бер сүз әйткәне юк. Кайберәүләрнең театр залларында туган көннәрен бик тантаналы итеп үткәрүләрен күреп торам. Әмма аның матди чыгымнары миңа билгесез. Әйтәләр, туган авыл-районнарыннан зур ярдәм килә, дип... Ә минем туган-үскән җирем читтә, еракта, икенче бер «бәйсез» җөмһүрияттә... Татар язучысының «юбәләй» кайгысыннан азат алар.

Башта ук миндә инде җан тартмаган эштән тыелу хәерлерәк булыр дигән уй туган иде. Бигрәк тә вакыты күптән узган бер картка... Без малай чакта вакытсыз типтереп йөрүче кеше турында, «ни думбра, ни кубыз — ник котыра бу дуңгыз?» дип әйтә торганнар иде... Минем хакта болай ук әйтмәсләр әйтүен, әмма урысларның «Пир во время чумы» дигән сүзләре әфәндегезнең «юбәләенә» бик тә туры килүе мөмкин иде.

Кыскасы, мин 90 яшемне бәйрәм итүдән баш тартырга булдым. Минем өчен бу принципиаль ныклы карар иде. Күңелдә күптән туган карарымны кайбер якын дусларыма да әйттем. Берәүләре минем белән килешкән шикелле дә булдылар. Сөйләшкән чакта дәшми калган үтә сизгер бер дустым мин әйткәннәргә тамчы да ышанмаган икән... Ул моны шул ук көнне сөйләшүдә катнашкан икенче бер дустыбызга туп-туры әйткән дә: «Юк, Әмирхан абый туган көнен, һичшиксез, бәйрәм итәчәк!» —

дигән... Ул үзе үк шулай дип әйткәнен миңа язды да... (Аныңча, мин үз сүземдә тормый торган, тиз килешүчән, принципсыз бер кеше, имеш! Тел төбеннән шулайрак аңлашылды әйтергә теләгәне.) Һәм ул хаклы булып чыкты. Ахыр чиктә миңа, «ныклы» карарымны бозып, туган көнемне бәйрәм итү белән килешергә туры килде. Аклану өчен түгел, аңлату өчен генә мин инде килешүнең сәбәбен язарга мәҗбүрмен. Чөнки замана үзе миннән шуны таләп итә.

Элекке елларда берәр язучының «түгәрәк датасы» якынлашса, башта аның үзе белән сөйләшеп, туган көнен кайчан, ничек үткәрү мәсьәләсе хәл ителә иде. Аннары махсус комиссия төзелеп, бөтен оештыру эшләре шуңа тапшырыла иде. Һәм бу эшләр кимендә берничә ай алдан башлана торган иде.

Хәзер исә Язучылар берлегенең «юбәләй» эшләрен нәрсәдән, ничек башлавын мин ачык кына белмим... Дөрес, ул ике зарури вазифасын бик төгәл үтәп бара: юбилярны котлый, үлгәнне җирли. Икесе дә бик фарыз эш. Элек-электән үк ул шулай эшләнә иде. Билгеле, кешесенә карап төрлечәрәк эшләнә...

...Инде минә фәкыйрегезнең дә «түгәрәк датасы» якынлаша. 1998 ел да үтеп бара — күп тә калмады. Иске гадәт буенча мин Язучылар берлегеннән сүз көтәм. Ни уйлыйлар, нишләмәкче булалар?.. Күптән инде сүз арасында гына Ринат Сафиевич бер: «Менә Әмирхан абыйның да туган көнен әйбәтләп үткәрәсе бар»,— дип әйтеп куйган иде. Шул чакта мин аңа: «Бу хакта безгә аерым сөйләшү кирәк булыр»,— дип әйткән идем. Ләкин шактый күп вакыт үтсә дә, «аерым сөйләшү» безнең арада булмады. Минем инде карарым әзер иде, тик аны җиткерү өчен җитди бер сөйләшү кирәк иде — мин һаман шуны көтәм. Ә вакыт уза. Көтә торгач 1998 ел да үтеп китте, яңа елның ике атнага сузылган бәйрәмнәрен дә уздырып җибәрдек. Халык язучысы, аксакалга 90 яшенә җитәргә бер ай чамасы гына вакыт калып бара, әмма һичбер тарафтан, беркемнән дә бу хакта бер сүз ишетелгәне юк... Миңа калса, Язучылар берлеге, һичьюгы: «Безнең карт нишли икән, нәрсә уйлап ята икән?» — дип, гадәти бер кызыксыну күрсәтергә тиеш иде кебек, әмма анысы да юк ләбаса!..

Әлбәттә, мондый хәл мине бик гаҗәпләндерә башлады. Әллә, мин әйтәм, союз җиткәчеләре минем карарны ничектер белеп, үзләре үк «юбәләйләр» ясап маташудан ваз кичтеләр микән?! Әгәр шулай булса, бу бит ике як-

ның да хәлен бик җиңеләйтәчәк. Сөйләшү-аңлашуларның кирәге дә булмаячак. Ринат мәшәкатьтән азат, мин — борчылудан... Ләкин ашыга төшкәнмен икән. Җитди сөйләшүләр алдарак икән әле. Иң элек миңа көтелмәгәнрәк хәбәрләр ишетелә башлады: татар мәктәпләрендә минем иҗатка багышланган дәресләр үткәрелә икән. Аннары университетның татар филологиясе әдәбият факультеты фәнни конференция дә үткәрмәкче икән. Болар бит минем туган көнемә багышланып эшләнә торгандыр, мотлак... Димәк, мин тик яткан арада, ниндидер хәрәкәт башланган икән инде. Әмма бу хәрәкәт кайдан, кемнән чыга соң? Шуны ачыклар өчен мин Язучылар берлегенә үзем шалтыратырга булдым. Ринат Сафиевич үзе юк иде, Әхмәт Гадел белән сөйләшергә туры килде. Җылы гына исәнләшкәннән соң, мин аңардан гүя болай гына сорадым:

— Йә,ниләр бар сезнең тирәләрдә, ни эшләр бетерәсез?

— Менә сезнең туган көнне матур гына итеп үткәрергә җыенабыз, Әмирхан абый! — диде Әхмәт, көр тавыш белән мине шатландырырга ашыккандай.— Тиздән чакыру билетлары бастырмакчы булам...

— Алай...й! — дип суздым мин ирексездән.— Бик зур эшкә тотынгансыз икән... Мәгәр кем рөхсәте белән?

— Бәй, бәй...— дип куйды Әхмәт, көләсе килгәндәй.— Кемнән, нинди рөхсәт ди ул, язмаганны?!

— Мәсәлән, миннән... Мин бит әле тере кеше... Башта аның үзеннән сорыйлар — туган көнен бәйрәм итәргә телиме ул, әллә юкмы?

Әхмәт беразга тынып калды — миннән бер дә көтмәгәнен ишетте бугай... Аннары ашыкмый гына әйтте:

— Әмирхан абый, сез бит инде туган көнегез килеп җитәчәген, аны зурлап бәйрәм итәчәкләрен алдан ук белеп торгансыздыр, шәт?!

— Юк,— дидем мин кискен генә,— бәйрәм итү турында моңарчы беркем белән бернинди сөйләшү булганы юк. Бары менә бүген беренче мәртәбә сездән ишетәм... Һәм шуңа күрә сезгә ачыктан-ачык әйтеп тә куям: минем туган көнемне рәсми рәвештә бәйрәм итүгә мин каршы, миңа кирәкми ул!..

— Ни өчен? — диде Әхмәт, нигәдер бик әкрен генә. Аның никадәр гаҗәпләнеп калуы телефон аша сүзсез дә килеп җитә иде кебек...

Миңа хәзер баш тартуның сәбәбен артык тирәнгә кермичә, кыска гына итеп аңлату кирәк иде. Кешенең башына кинәт кенә суккан шикелле булмаска тиеш.

— Әхмәт туган, син мине дөрес аңларга тырыш. Көзге кризистан соң мин шактый хәлсезләндем, еш авырыйм, йөрәгем борчый, бу хәлемдә зур бәйрәмнең авыр йөген күтәрә алуыма ышанмыйм... Аннары елы да нинди авыр, хәвефле, халык бөлгенлектән интегә... Шуңадыр инде кәеф начар, теләк юк. Шуңа күрә кабатлап әйтәм, мин зур, тантаналы бәйрәм итүне кирәк тапмыйм... Бу әйткәннәремне Ринатка җиткерерсең. Хәзергә хуш!..

Шулай дидем дә трубканы куйдым. Ләкин Әхмәтнең бик ашыгып: «Әмирхан абый, ярамый бит болай, сез кырт кисмәгез әле!» — дигән сүзләрен ишетеп калырга өлгердем.

Әмма Ринат Сафиевич минем белән сөйләшүне нигәдер һаман сузды. Бәлки, эше күпкә күрәдер... Ике-өч көн узгач кына, мин, ниһаять, аның телефоннан әйткән сүзләрен ишеттем. Гадәттә, миңа карата хөрмәт саклап, җылы гына сөйләшә торган рәисебезнең сүзләре бу юлы бик катгый һәм кыска булды.

— Әмирхан абый,— диде ул, һәр сүзен үлчәп кискәндәй,— туган көнегезне бәйрәм итү ул сезнең теләктән дә, минем теләктән дә тормый... Эш башланган, бәйрәм итү булачак — бу югарыда хәл ителгән мәсьәлә... Ә сез тыныч кына шуңа әзер булып торыгыз!..

Шулай диде дә трубкасын «элеп» тә куйды. Мин бер сүз әйтергә дә өлгермичә калдым. Безнең болай беркайчан да сөйләшкәнебез юк иде әле... Әхмәт Гаделдән ишеткәннәре аның кәефен бик нык бозгандыр, күрәсең. Авырткан башка тимер тарак!.. Әмма гаеп миндәме соң?! Миннән сорамыйча гына «эш башлау»ны ничек аңларга? Акылым җитми... Хикмәт нәрсәдә соң?!

Тагын берничә көннән соң Министрлар Кабинетыннан вице-премьер Илгиз Кәлимуллович Хәйруллин үзе миңа шалтыратты. Без бер-беребезне күптәннән беләбез. Йомышым төшкәндә мин еш кына аңа мөрәҗәгать итәм. Аңа ничектер сүзем үтә — йомышымны үтәмичә калганы юк диярлек — аның белән сөйләшүе дә җиңел, эше тыгыз булса да, сүзне бүлмичә тыңлый ала.

Менә бүген дә ул ашыкмыйча, сабыр гына сүзен башлады. Хәлемне сорашканнан соң миңа бик иплəп кенә болай диде:

— Әмирхан абый, без сезне вакытсыз борчырга теләмәгән идек. Соңга калып хәбәр итүебез бары шуның аркасында. Сез инде безне кичерә күрегез!.. Ә мәсьәлә болай тора: Сезнең туган көнне бәйрәм итү — ул хакими-

ят карары белән үктәреләә, аның бөтен чыгымнарын да хакимият үзе күтәрә... Бу Язучылар союзы эше генә түгел. Халык язучысының 90 еллыгын бәйрәм итү Татарстан җитәкчеләре өчен дә бик мөһим. Зур вакыйга ул. Президентыбыз үзе Сезне котларга килмәкче... аннары җәмәгатьчелек Сезнең бәйрәмне күрергә тели бит. Әгәр булмый калса, халыкка аңлатып та булмаячак. Бик зур җаваплылык Сезнең өскә төшәчәк!.. Баш тартудан элек тагын бер уйлагыз әле, Әмирхан абый, мәсьәләнең һәрьягын...

— Мин инде күптән ул хакта уйлаган идем.

— Ләкин сез бит эшнең кем тарафыннан, ничек башланганын белмисез...

— Әйе, миңа әйтүче булмады, менә хәзер генә күп нәрсәне сездән ишеттем... Ләкин мин нәрсә эшләргә тиеш?

— Иң яхшысы, Әмирхан абый, башлаган эшне дәвам иттерү... Оештыру эшләрен без Язучылар союзы белән Мәдәният министрлыгына тапшырдык. Сезгә бер мәшәкате дә булмаячак... Юбилей көнен тыныч кына көтегез. Без аны 5 мартта үткәрмәкче булып торабыз. Бу җомга көн булачак — ял көннәренә каршы... Болар барысы да Сезнең өчен эшләнә... Әгәр клиникага кереп, бераз дәваланып чыгарга телисез икән, без иртәгәдән үк Сезне урнаштыра алабыз. Әле бер ай чамасы вакыт бар...

— Рәхмәт, Илгиз Кәлимуллович,— дидем мин чын ихластан,— ләкин кереп ятуның кирәге булмас, мин бит әле, шөкер, аяк өстендәге кеше.

— Менә бик әйбәт... Шулай сәламәт, тыныч кына көтегез!..

Озын сүз әнә шулай тәмамланды. Нәтиҗәдә ситуация кинәт үзгәрде. Минем бәйрәм итмим дигән карарым ничектер бик кечерәеп, гүя шунда ук әһәмиятен югалтты. Алга, беренче урынга этика мәсьәләсе (әхлакый кагыйдә) килеп басты.

...Туган көнне бәйрәм итү безгә дә күптән кергән бер йола. Инде менә миңа да ул «көнем» килеп җитте. Безнең хөкүмәтебез минем туган көнне бәйрәм итүне кирәк тапкан. (Хөкүмәтнең мондый эшкә катнашуын моңарчы ишеткәнем дә юк иде.) Йә, мин нишләргә тиеш?.. Әйткән сүземдә торам дип, аның теләгән кире кагаргамы? Нинди сылтау, нинди йөз белән? Аннары Татарстан Президенты үзе мине котларга килмәкче икән... Мин аның котлавын да кабул итмәскә тиешме? Минтимер Шәрипович Шәймиев мөстәкыйль Татарстанның халык тарафын-

нан сайлап куелган иң югары дәүләт җитәкчесе — аны шул сыйфатында тану һәм хөрмәт итү һәркемнең гражданлык бурычы. Минем өчен дә ул иң беренче нәүбәттә олы ихтирамга лаек Президент!.. Татарстаныбызның бүгенгесе һәм киләчәге өчен җавап бирүче... Шуннан кала башкасы... Хәер, башкасы миннән таләп тә ителми. Бөтен уй-карашларым үземдә кала. Алар сер түгел, кат-кат язылган, үзгәртүнең кирәге дә юк.

...Шулай ук мине әйткән сүздә тора белмәүдә, килешүчәнлектә гаепләү дә урынсыз дияр идем. Болай ансат кына хөкем итүләр кешенең үткәнен яхшы белмәүдән килә торгандыр инде... Юк, дускай, минем курыкмаган, бирешмәгән, килешмәгән чакларым да булды.

Халыкны минем бәйрәмне күрергә теләве дә гаҗәп түгел. Язганнарымны халык яратып укый — күптәннән мин моны тоеп, белеп киләм. Бу минем бердәнбер юанычым. Димәк, миңа да иң кирәге — укучыларым...

Менә шуларның һәммәсен дә уйлаганнан соң, мин ничек итеп, нинди йөз белән туган көнемне бәйрәм итүдән баш тарта алам?! Минем бу «отказ»ны әдәби җәмәгатьчелек карт язучыга һич тә килешми торган бер түбәнлек яки тәкәбберлек дип кабул итмәсме?.. Юк, түбәнлек белән тәкәбберлек миңа бөтенләй ят нәрсә. Минем абруем башка — мин шуны сакларга тиеш. Иң яхшысы — килешү... Ахыр чиктә бары аңлашу-килешү юлы белән генә нидер эшләп була. Кешеләргә яшәр өчен шул кирәк булган... Без дә тәвәккәлләдек!.. Тик ул көнне исән-сау күрергә бер Ходаем үзе насыйп итсен иде!

...Илгиз әфәнде Хәйруллин миңа «бәйрәм» көнен тыныч кына көтәргә кушты. Ләкин тынычлык миннән качты. Башкача булуы мөмкин дә түгел иде. Килеп җитәчәк бәйрәмнең ничек, ни рәвештә үтәчәге турында борчылып уйлану мине тәмам йотты диярлек. «Юбәләй» дигән тамашаны бездә хәзер бик тантаналы итәргә тырышалар. Тик менә миңа, 90 яшьлек бабайга, килешер микән артык купшы тантана?! Башны чөя биреп, җиңел адымнар белән сәхнәгә чыгып, горур гына елмаеп һәм бөгелә төшеп, тамашачыларны сәламли алырлык чакларым үтте бит инде. Минем өчен хәзер үземне күрсәтүдән бигрәк, азмы-күпме иҗади эшемне күрсәтү әһәмиятлерәктер...

Әмма бармы соң юбилейда күрсәтерлек эшләрем?.. Мине көне-төне борчыганы — нәкъ әнә шул мәсьәлә. Минем бит сәхнәдә уйнап күрсәтерлек бер генә әйберем дә юк. Шулай ук җырлар өчен язылган бер генә шигъри

юлым да юк... (Гомәр абзыйдан, әнә, мәңге онытылмас «Җидегән чишмә» калды, ичмасам!) Минем бөтен язганым бары укыр өчен генә. Сәхнәдә бары шуларны гына укып булачак. Ләкин тамашачы китаптан карап укыганны яратмый, диләр белгән кешеләр... Нишләргә тиеш соң мин?!

Шуның ише ямьсез уйларга бирелеп утырган көннәрнең берсендә янымдагы телефон хәлемне аңлагандай телгә килде. Трубканы алсам, Ринат Сафиевич тавышы:

— Әмирхан абый,— диде ул миңа.— Сезнең кичәнең сценариесын Камал театры артисты һәм режиссеры Айдар Хафизов язачак. Сез аның белән очрашып сөйләшегез, теләкләрегезне аңа әйтегез... (Хәтта телефонын да бирде.)

Минем өчен бу бик кирәкле хәбәр иде. Әлбәттә, кичәнең программасы була — кемдер аны алдан төзи дә... Театр кешесе бу эшкә тартылгач, минем башымны өзлексез авырттырган «мәсьәләләр» ансатрак хәл ителергә тиеш иде. Хафизовны якыннан белмәсәм дә, мин аңа ничектер алдан ук ышандым. Ул бит «Камал»дан!.. Чыннан да, беренче очрашуда ук ул минем ышануымны аклады диярлек. Минем күп әйберләремне ишетеп кенә түгел, укып та белә икән. Бу инде укыр өчен нәрсәләр сайлауны да шактый җиңеләйтте.

Уку мәсьәләсенә килгәндә, мин кайбер таләбемне әйтүне кирәк таптым: иң элек әсәрнең табигый агышын тотып, шуны ахырына кадәр сакларга; бернинди «күчәйтү», «үзгәртү» «өстәүләр» булмаска тиеш. Әдәби әсәр — сүз сәнгате... Тик сүзнең сихри көчен тыңлаучыга җиткерә белергә генә кирәк.

Минем әсәрләрне укучы артистлар күп... Әмма мине дөрес аңлап, нечкә тоеп укучыларым дип мин беренче нәүбәттә Шәүкәт Биктимеровны, Ирек Баһмановны, Айрат Арслановны атар идем. Ләкин кичәдә бүтәннәр укыды. Аларны да яратып тыңладылар. (Театрның Төркиягә киткән чагы.)

Хафизов мин әйткәннәр белән килеште бугай: «Борчылмагыз, Әмирхан абый, барысы сез әйткәнчә булыр»,— дип, мине тынычландырырга ашыкты. Әмма бик җитди бер мәсьәләдә без тиз генә килешә алмадык.

...Сценарий буенча, пәрдә ачылгач, бер чибәр туташ белән бер сылу егет мине ике ягымнан култыклап, сәхнәгә алып менәргә һәм махсус әзерләнгән урынга утыртырга тиешләр иде. Мин моңа бик каршы идем. Минем урыным сәхнәдә түгел, залда, тамашачылар арасында бу-

лырга тиеш... Башта ук уйлап куйган теләгем бу — шуны мин сценарийны төзүчегә дә әйттем. Бераз бәхәсләшергә дә туры килде, ләкин теләгемне үзгәртмәдем... Әлбәттә, миңа сәхнәгә менәргә туры киләчәк: берсе аның Президент котлавын тыңлаган чакта, икенчесе — соңгы сүземне әйтер алдыннан... Ахырда шулай килештек тә. Кичәдә мин тамашачы булып утырдым.

Юбилей кичәсенең ничек узганын язып тормыйм — күпләрнең хәтерендәдер әле ул... Зал, гадәттәгечә, шыгрым тулы иде. Килгән халык та гадәттәге тамашачылар. Тик шулай да олырак яшьтәге зыялыларның, фән һәм сәнгать әһелләренең гадәттәгедән күбрәк булуы сизелә. Нидер көткәндәй тын гына утыралар... Гомумән, бу кичә башта ук моңарчы булып үткәннәрдән нәрсәсе беләндер аерыла кебек иде — әгәр ялгышмасам...

Кичәне Ринат Мөхәммәдиев башлады. Аның инде бик күпләрнең юбилей кичәләрен ачып, беренче котлау сүзләрен әйткәнен кем генә белми... Бу эшнең чын остасы ул. Әмма аның осталыгына гаҗәпләнмичә дә булмый: бервакыттада ул күп әйтелеп таушалган бер үк сүзләрне кабатламый, һәр юбилярга бик туры килә торган үз сүзләрен таба белә.

Кыска гына кереш белән кичәне ачканнан соң, Ринат Сафиевич беренче сүзне Президентка бирде.

Минтимер Шәрипович Шәймиев сәхнәгә бер яктан күтәрелде. Мине таза бер егет култыклап икенче яктан менгезде... Бераз читтәрәк һәм арттарак торып, мин Президент котлавын тыңладым. Әмма аның бу чыгышы күпшы сүзләрдән генә торган гадәти котлау гына булып калмады. Күпләр өчен, шул җөмләдән минем үзем өчен дә һич көтелмәгән чыгыш булды ул... Иң элек Минтимер Шәрипович минем ниндиерәк язучы булуымны ишетеп кенә түгел, укып та белә икән. Иҗатыма шактый тирән кереп, аерым әсәрләремә махсус тукталып, ул бик мәгънәле һәм кызыклы фикерләр әйтте. Президент кешенең язучы иҗатына шулай киң тукталып, үзенчә бәя биреп, кыю фикерләр әйтүен, асылда, беренче мәртәбә ишетүебез. Аның чыгышы гүя кичәнең һавасын үзгәртеп җибәрде. Кичәдә утыручы һәркем шул чыгыш йогынтысына ирексездән бирелгән кебек иде.

Президент котлавыннан соң, мин яңадан залга төшеп утырдым... Кичәнең дәвамы Хафизов төзеп калдырган программа буенча бара бирде... Ул үзе Төркиягә китеп барган иде, кичәне хатыны Фәридә ханым матур гына алып барды.

...Инде программаның үзенә килгәндә, ул һәрбер юбилярныкы шикелле үк бер төслерәк иде — җыр, музыка, бию, нәфис сүз... Тамашачы да шуңа күнеккән инде. Әмма бүгенге программада, башкалардан аермалы буларак, минем үз әйберләрем шактый урын алып торды. Саф проза... Җыр-музыка арасына кертеп укылган шул прозаны тамашачы ничек кабул итәчәк? Дөрес, сайлап алынган әйберләремнең яратып укылуын мин беләм белүен, ләкин аларның сәхнәдә укылуын беренче мәртәбә генә ишетүем. Миңа җиңел түгел, нервыларым уйнаклый — нигәдер уң аягымның тезе әкрен генә сикергәли — мин шуны баса алмыйча азапланып утырам...

Әмма ни гаҗәп, тамашачылар һәр укылган әйберемне бик дикъкать белән, бик бирелеп, тәэсирләнеп диярлек тыңладылар. Хәтта минем үземә дә тәэсир итмичә калмады. Билгеле инде, әсәр үзе генә түгел, укучының осталыгы да тыңлаучыны, һичшиксез, әсир итте... «Матурлык» хикәясен Әзһәр Шакиров укыды. «Кем җырлады»-ны миңа аз таныш Фәнис Җиһанша дигән артист бик табигый һәм бик тәэсирле итеп укып чыкты. Кайберәүләр минем кебек, бәлки, яшьләрен дә тыя алмагандыр... Инде иң ахырдан «Курай»ны укыган Айрат Арсланга карата мактау сүзләре әйтүнең кирәге дә юк, ул аңа мохтаҗ түгел. «Курай»ны ул курай моңына кушып укыды. Сүз белән моңның кушылуы тыңлаучыны, ихтимал, сихерли дә төшкәндер...

...Кыскасы, кичәдә укылган хикәя һәм өзекләр өчен миңа кызарырга туры килмәде — «имтихан» уңышлы узды. Әгәр укый белүчесе табылса, гади генә хикәяне дә, Фатих мәрхүм әйтмешли, «мамыгын-йонын коймыйча» тыңлаучыга җиткереп була икән.

...Әлбәттә, «юбиляр әкиятләре»ннән башка, кичәдә катнашучы Фәридә Кудашева, Зилә Сөнгатуллина, Римма Ибраһимова, Рафаэль Ильясов, Айдар Фәйзрахманов кебек халыкның яраткан җырчылары бәйрәм концертының абруен күтәрделәр диясем килә. Уфа кунагы Марат Шәриповның җырлавы да кичәбезне бик күтәрде.

Котлаулар күп булды. Арада Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимовның да котлавы бар иде — аны башта ук укыдылар... Чәчәкләрнең һәр төрлесе бик күп иде. Шулар өстенә тагын төрле бүләкләр дә... Һәр котлаучы чәчәген, бүләген минем өчен махсус куелган өстәлгә илтеп салды. Ә мин шул тамашаны залдан карап утырдым... Һәм һич уйламаганда миндә бер үкенү хисе кузгалды: юбилярга болай читтән карап утыру килешәме

соң?! Мин бит һәр котлаучыга рәхмәт сүземне әйтеп, аның кулын кысарга тиеш идем. Шуны мин эшли алмадым. Бик үкенечле томаналык. Әмма мин аны ничектер төзәтергә дә тиешмен...

...Ниһаять, минем үземә дә сәхнәгә менәр вакыт җитте. Читтән килгән кунаклар, кичәдә барлык катнашучылар сәхнәне тутырып мине көтәләр иде. Микрофон алдына бастым, бераз тынып тордым... Әйтәсе сүземне мин алдан язып килгән идем. Әмма ләкин сүзне мөмкин кадәр кыска тотуның кирәклеген сизеп торам. Ярый әле мин аны бераз кыскартып өлгергән идем... Хәзер менә халыкка әйткән шул соңгы сүземне кабатлау урынсыз булмас дип уйлыйм. (Тарих өчен булса да.)

*Мөхтәрәм замандашлар, туганнар!*

*Туксан яшенә сирәк кеше килеп җитә. Без менә шул сирәкләрнең берсе булабыз... Дөресен генә әйткәндә, мин үзем 90га җитүемә һич тә ышанмый идем. Чөнки заманасы шундый иде... Әмма гаҗәп хәл — 89га кергәч, 90га да барып җитәсем килә башлады. Үткән елым гел шул хакта уйлану белән узды диярлек: барып җитәмме-юкмы?! Туган көнемә өч көн кала мин кинәт кенә авырып киттем, температурам 38,6га җитте... Әллә гомеремнең башы белән ахыры бер көнгә туры киләме, дип тә уйларга мәҗбүр булдым. Гүя тәкъдирем мине юри шулай котырта кебек иде... Мондый хәл минем гомеремдә булгалады. Мин бит бер җирдә туып, икенче җирдә үстем... Аннары безнең гәзитләр минем туган көнем турында да ике төрле яздылар. Кайберләре 16 февральдә үк мине туган көнем белән котладылар, икенчеләре исә — 2 мартта язып чыктылар... (Бу иске белән яңа стильне бутау аркасында килеп чыккан ялгышлык иде.) Шулай итеп, мин әле ике тапкыр туганмын да икән! Бусы ярый, моңа мин каршы түгел, тик ике тапкыр үләргә генә Ходай язмасын иде...*

*Кыскасы, мин өметләнә торгач, 90 яшемә килеп җиттем. Инде менә сезнең алдыгызда басып торам... Әмма дөресен әйтик, минем 90га җитүем бик авыр елга туры килде. Тирән кризиста утырабыз, халык бөлгенлектән интегә... Шуны уйлап, мин инде туган көнне рәсми рәвештә бәйрәм итүдән баш та тарткан идем. Ләкин миңа, халык көтә, халыкка кирәк бит, диделәр... Бу — көчле дәлил иде. Мәсьәлә шунда ки, халык язучының үзенә дә бик кирәк лабаса!.. Заманыбызның нинди булуына карамастан, без менә бүген, ниһаять, очраштык... Минем тормышымда бу көн, бәлки, иң соңгы, иң зур бер*

*вакыйга булып калыр... Бүгенге бәйрәмем, миңа калса, күркәм узды. Мин бик канәгать!..*

*Һәм шушы залга җыелып, миңа кадер-хөрмәт күрсәтүчеләрнең һәммәсенә дә 90 яшьлек башымны түбән иеп, тирән рәхмәтемне белдерәм... Рәхмәт сезгә татар әдәбиятына күрсәткән хөрмәтегез өчен!..*

*«Гомерем кояшы баюга табан әкрен генә төшеп бара» дип башлаган идем кечкенә бер китабымны... Соңгы сүзем дә шул хакта: «Бер үк мизгелдә кемнеңдер гомер кояшы бата, кемнекедер яңа гына чыгып килә... Яшәешнең мәңгелек әйләнеше бу... Без әзер, без тыныч... Кояшлары яңа гына чыкканнарга бездән хәер-фатиха!.. Хушыгыз!..*

Мәгәр безнең эшләр соңгы сүзне әйтү белән генә бетмәде әле... Театрның түбәндәге бер бүлмәсендә мул гына табын әзерләнгән иде. Халык таралышкан чакта, безне шул бүлмәгә чакырдылар. Егерме-егерме биш кеше сыярлык өстәл тирәсендә читтән килгән кунаклар һәм кайбер мөхтәрәм каләмдәш дуслар утырышкан иде. Минтимер Шәрипович белән мин, билгеле, түрдә янәшә утырдык. Әйбәт эчемлекләрдән авыз иткәләп һәм тансык сыйларны капкалап, дусларның чын ихластан юбилярны котлап әйткән сүзләрен тыңладык... Бу инде үзенә күрә банкет сыманрак мәҗлес иде. Әмма монда чын банкетта булырга тиешле кешеләрнең бик күбесе юк иде. Банкетның чыны, зурысы соңыннан, һичшиксез, булыр әле дигән ышану миндә бик көчле иде. Бөтен гомерләрен әдәбиятка багышлаган замандашлар белән иркенләп бер утыру минем өчен фарыз гамәл иде. (Андый банкетларны оештыручылар булды.) Ләкин ни кызганыч, зурысын оештыру миңа насыйп булмады.

Икенче көнне, 6 мартта мин читтән килгән кунакларны үземә чакырган идем. Алар барысы да шул ук көнне китәргә дә тиешләр иде. Һәркайсының Казанда үз эше дә булганга күрә, төрлесе-төрле вакыттарак килделәр. Башта кадерле авылдашларым, аннары Уфадан Фәридә ханым Кудашева, Наҗар Нәҗми, Марат Шәрипов, Рәүф Идрисов Венера ханым белән; Мәскәүдән исә академик Әдһәм Тенишев, профессор Әкъдәс Борһанов, дустым Фоат Маннапов түремдә кунак булдылар. Алар янына кайбер якын танышларымны да чакырган идем.

Сыем җитәрлек иде. Мәҗлес уен-көлке белән бик күңелле узды. Минем туган көнне Мәскәү белән Уфада үткәрү турында да сүз булды. Наҗар Нәҗми безне туган районы Дүртөйленең «Агыйдел» санаториена чакырды.

Болар өчен рәхмәттән башка сүзебез юк. Теләкләребез бик ихлас, тик якты җәйләрне исән-сау гына күрү насыйп булсын иде...

Ә иртәгесен инде мин йокыдан авырып уяндым. Сизәм, юбилей мине күпмедер аяктан екты.

1999 елның авыр, афәтле булачагын мин ничектер алдан ук сизеп тордым. Хәер, миннән башка да сизүчеләр аз булмагандыр, чөнки яхшыга табан бернинди үзгәреш юк, ә халыкта исә канәгатьсезлек көннән-көн көчәя генә... Бу өметсез елның сәяси, иҗтимагый сәбәпләрен мин язып тормыйм — алар болай да һәркемгә билгеле. Минем бары юбилеем артыннан ук бер-бер артлы килеп торган афәтләр турында гына язып үтәсем килә.

...Юбилеемнан соң бер атна да үтмәгәндер, безгә иң якын, иң кадерле кешебез — олы кызымның ире, киявебез Сәгыйт Тюминев 11 нче мартта вафат булды... Ул гүя минем бәйрәмне бозмас өчен генә җан бирүен шулай берничә көнгә кичектереп торган... Ул миңа чын ихластан «әти» дип дәшә иде.

Сәгыйт мәрхүмнең кем икәнен аңлар өчен, аның үтә гыйбрәтле язмышына күз салырга кирәк. Үзе исән чакта мин моны эшли алмадым. Икебез өчен дә бу бик четерекле мәсьәлә иде — аның үз «тарих»ын сөйләргә ни сәбәптер теләге юк кебек, ә минем, кеше ярасына кагылып, төпченергә әрсезлегем җитми иде. Хәзер исә мин белгәнемне язарга бурычлымын. (Белгәнем дә бик тулы түгел.)

...Сәгыйт Ырынбурның бер сәүдәгәр гаиләсендә туган була... Утызынчы елларның башында ул сәүдәгәрне хатыны белән бергә Инза тирәсендәге бер лагерьга алып китәләр. Ләкин лагерьда аларны озак тотмаганнар. Нишләткәннәр аларны? Сәгыйт әнисенең бертуган абыйсы Рәхим кода язмаларында кыскача гына шундый юллар бар: «Сеңелем белән киявебез икесе дә бер вакытта һәлак булганнар...» Чын дөресен яшереп язылган бу сүзләрне бары бер генә төрле аңларга була: Сәгыйтнең әтисен дә, әнисен дә лагерьда бер үк көнне атканнар... Монда бернинди шик булуы мөмкин түгел, чөнки бу «сыйнфый дошман»ны күпләп кыру еллары иде. Юк кына бер сылтау белән дә кулакны яки сәүдәгәрне юк итү органнарның көндәлек эше иде. («Колхозлаштыру» шулай гына барды да бит.)

Әмма үтерелгән ата-анадан дүрт бала ятим кала. Менә шул балаларны ике якның да якын туганнары үзара бүлешеп алалар. Һәркайсы үзенә тигән балага үз исе-

мен, үз фамилиясен бирә, үз баласы итеп тәрбияләп үстерә. Шул рәвешчә, бертуган дүрт бала дүрт кешенең фамилиясе белән гомерләре буе яшиләр.

...Сәгыйт әти-энисеннән 2-3 яшендә аерылып кала. Аны әнисенең бертуган сеңлесе һәм җизнәсе тәрбиягә алалар. Ул шуларның гүя улы булып, җизнәсенең исем-фамилиясен йөртә: Сәгыйт Алиевич Тюминев. (Җизнәсенең исеме, ихтимал, Гали булгандыр.) Үлгән көненә кадәр шушы исем-фамилия белән яшәде, мәрхүм. Үз әтисенең чын исем-фамилиясен ул бервакытта да белмәде.

Эш шунда ки, тәрбиягә алучылар Сәгыйттән дә, һәм башкаларыннан да, чын әти-әниләренең фаҗигале язмышын катгый рәвештә яшерәләр. Моның ике төрле сәбәбе булырга мөмкин: яки бу балалар яңа гаиләдә үзләрен ятим итеп тоймасын өчен, яки инде ул балаларның совет органнары тарафыннан атылган «дошман» токымы икәнлекләрен яшерер өчен — менә бусы, минемчә, дөресрәктер дә... Үз язмышымнан беләм, ул елларда кем баласы булуыңның әһәмияте гаять зур иде.

Әйе, әйтәсем килә, өелешеп ятим калган балаларны ятимнәр йортына тапшырмыйча, үзара бүлешеп алып, аларга үз исемнәрен биреп, төрле хәйләләр белән булса да саклап калган, үстереп кеше иткән бу фактны татарлар арасында сирәк очрый торган гыйбрәтле вакыйга һәм зур бер изгелек дип атар идем...

Менә безнең киявебез Сәгыйт тә җизнәсе биргән фамилия белән урта мәктәпне бетерә. Аннары хәрби училищены тәмамлый. Шуннан соң аны Семипалат өлкәсендәге атом бомбалары шартлата торган полигонга җибәрәләр. Шунда хезмәт иткәндә ул көчле радиация ала. Күпмедер вакыт әле Байконурда да хезмәт итә. Бусы да зәхмәтле бер урын... Ахырда бик хәтәр авыруы билгеле булгач, аны тиз генә запаска озаталар. Әмма бер генә документта да аның авыруы күрсәтелми — радиация яшерен авыру, аны күрсәтү тыелган була. Ә пенсия алу өчен ул бик кирәк — Сәгыйт мескен армиядә радиация алуын исбат итәр өчен кемнәргә генә язмый, кайларга гына бармый... Ахыр чиктә Куйбышевтагы хәрби госпиталь врачлары аның авыруы турында чын дөресен язып бирәләр. Шуннан соң гына ул инвалид пенсиясе ала башлый...

Башта, врачларның әйтүенә караганда, аның бер генә ел гомере калган була... Ләкин шул төзәлмәс чир белән ул 34 ел газап чигә. Ел саен 1-2 ай хастаханәдә ятып чыга. Шул чагында аңа көн саен диярлек яңа кан

өстәп торалар. Дөресен генә әйткәндә, аның бөтен гомере үлем көтеп, ләкин ничек кенә булса да яшәргә тырышып узды.

Сәгыйт мәрхүм бик тыйнак, бик тырыш, бик инсафлы кеше иде. Җир эшен, бакча эшен бик ярата иде. Хәле җиңеләйгән чакларда ул көннәрен гел бакчада казынып уздыра иде. Үзе үстергән җиләк-җимеш, алмачияләрне безгә дә күп ташыды.

...Озын чирнең ахыры — үлем, диләр. Минем юбилей үтеп, атна да узмый, ул, ниһаять, бу фани дөньядан китеп тә бара.

Җизнәсенең исем-фамилиясен йөрткән Сәгыйт тә, асылда, большевиклар системасының корбаны... Башта бу система аның әти-әнисен үтерә, аннары үзенә хезмәт иткән яшь егетне гомере буе төзәлмәс газаплы чиргә дучар итә. Моның ише имансыз, миһербансыз системага без әчебездән генә бәддога укып, кулыбызның сырты белән битебезне сыпырырга тиешбез...

Афәт ул ялгыз йөрми. Еш кына берсе артыннан икенчесе килә... Кешенең үлемен афәт дип атау, бәлки, дөрес тә түгелдер, чөнки әҗәл иртәме-соңмы һәркемгә килә, аңардан котылу юк. Ләкин инде сиңа якын яки күптән белгән кешеләр бер-бер артлы китә башласалар, моны афәт димичә дә булмый. Ни гаҗәптер, менә минем бәйрәм артыннан да шундыйрак хәл кабатланды...

...Сәгыйт кияүне озатканнан соң, озак та үтми безнең арадан шагыйрь Мөхәммәт Садри китеп барды. Без бер заман кешеләре идек, бик күптәнге танышлар... Ул, мәрхүм, бик дус җанлы кеше иде. Дошманы булдымы икән аның? Ничектер дөньяның ямен татып яши белде ул шагыйрь-балыкчы.

Мөхәммәт Садри артыннан, шулай ук кыска бер арада Гомәр абзый Бәшировны югалттык. 98 яшенә җитүгә карамастан, аның үлеме бөтен татар халкы өчен зур югалту иде. Гомәр абый кебек кешеләр дөньяга бик сирәк килә... Онытылмый торган шәхесләрнең иң затлысы иде ул.

...Миндә бик кадерле бер истәлек саклана. Гомәр абзый 98 яшен тутырган көннәрдә, без Түбән Камадан килгән Азат Зыятдинов белән икәү аның хәлен белергә барган идек. (Азат махсус шуның өчен килгән иде.) Гомәр абзый безне бик куанып каршы алды. Без гаҗәпләнә калдык: йөзгә җитеп килгән әдип нәкъ искечә — сөйләшүе дә бик әйбәт, гәүдәсе дә гадәттәгечә төп-төз, аяк атлаулары да нык — әлхасил, бернинди картлык зәгыйфьлеге сизелми иде аңарда...

Лилия ханым әзерләгән чәйгә утырдык. Гомәр абзый кушуы буенча өстәлгә бик әйбәт кызыл вино да куелды... Сөйләшү, билгеле, бик күңелле узды. Бу бик тансык сөйләшү иде. Сүзгә мавыгып, тәмле кызыл винону да өчәүләп эчеп бетерә яздык... Фотога төшәргә булдык — алар Азат әфәндедә саклана торгандыр.

...Кыскасы, без бу очрашудан бик канәгать булып, Гомәр абзыйның җегәрлегенә бик сокланып һәм исәнсау әле озак яшәвенә нык ышанып кайттык.

Әмма Гомәр абзый яшендәге кешеләрнең һәр көне исәптә... Һич көтмәгәндә өзелеп куюы бик мөмкин. Гомәр абзый белән дә шулайрак булды, күрәсең...

...Инде Гомәр абзый артыннан, күпмедер вакыт узгач та, безнең арадан шагыйрь Рәшит Гәрәй китеп барды. (Ни сәбәптер аларның дөньядан китү аралары бер чама иде — гүя Хак Тәгаләгә шулай кирәк булган...)

Рәшит Гәрәйнең бөтен шигърияте авыл турында иде. Тумыштан ук ул авыл шагыйре иде. Бөтен мәхәббәте, сагышы, гаме, борчылуы, яну-көюләре авыл белән бәйләнгән, авылга багышланган иде. Һәм шуларның һәммәсен дә ул үзе белән каберенә дә алып китте — нигәдер шулай уйлыйсы килә.

Тагын шул ук бер чама вакыт арасында драматург Шәриф Хөсәенов үлеп китә. Мин моны гәзитәдән укып белдем... Аның үлеме минем өчен һич көтелмәгән бик үкенечле югалту булды. (Ул бит әле бик тәҗрибәле врач та иде.)

Шәриф Хөсәен бик үткен фикерле чын талант иде. Дөрес, безнең аралар шактый ерак булды, аның миңа мөнәсәбәтен дә мин ачык кына белмәдем, әмма минем өчен ул сугыштан соңгы драматурглар арасында иң көчлесе иде... Аның «Зөбәйдә — адәм баласы» һәм «Әни килде» драмалары иң беренче нәүбәттә Тукай бүләгенә лаек әсәрләр иде. Бу карашымны мин бервакытта да беркемнән дә яшермәдем... Бүләк алганнарның бик күбесе күптән инде онытылып бетте, ә Шәрифнең әнә шул әсәрләре чын мәгънәсендә үлемсез. Әсәрнең язмышын бүләк хәл итми, вакыт хәл итә. Ни өчен Тукайны онытмыйбыз, чөнки ул безгә бүген дә кирәк.

...Шәриф проза әсәрләре дә язды. «Мәхәббәт сагышы» дигән повестен басылмас борын ни сәбәптер миңа укырга биргән иде. Бу инде тәмам өлгергән әсәр иде. Ихтимал, Шәриф мине сынар өчен генә биргән булгандыр. Ул кешеләрне бик нык аера белә иде — чын дуслары да күп түгел иде шикелле...

Бик кызганыч ки, шундый берәүгә дә охшамаган, үзенә башка чын талант китте безнең арабыздан...

Югалтуларның бер ахыры булырга тиештер инде. Монда язылган кадәресе дә гаҗәпләргә калдырырлык. Тик шулай да үзем генә белгән бер югалту турында әйтмичә китә алмыйм.

...Минем «Кем җырлады?» дигән хикәям бар — күпләр аны беләләр. Шул хикәядә җырлаучы кыз белән мин фронтта кыска гына арада танышкан идем. Исеме аның — Таһирә иде. Саф татарча матур гына җырлый да иде. Хәтерлисездер, көзге караңгы төндә ябылып бетмәгән теплушка ишегенә сөялеп, әкрен генә җырлаучы да шушы Таһирә иде. Ул ничектер үзеннән-үзе минем күз алдыма килде. Һәм хикәягә дә мин аны үзенең чын исеме белән Таһирә дип яздым... Шулай итеп, мин белгән татар кызы хикәя героена әйләнде...

Соңыннан Казанда очрашкач, ул үз исемен хикәядә күреп, бик сөенгәнен миңа әйткән иде. Ул бит үзе дә укытучы иде. Әдәбиятны аңлавы да башка. Сөенү белән бергә, бәлки әле горурлык та кичергәндер.

Инде менә хикәя битләрендә яшь, сылу кыз булып сакланачак Таһирә дә яши торгач, сиксәннән узып, күптән түгел бу фани дөнья белән хушлашты. Авыр туфрагы җиңел булсын! Аның яшьлеге минем дә яшьлегем иде...

...Биш ай эчендә алты кешене конвейерга салып җибәргәндәй бер-бер артлы ахирәткә озату һәм шул хакта бик аптырап, авыр уйларга бирелү минем өчен котылгысыз табигый хәл иде. Үзеннән-үзе иң элек килә торган уй — чиратта тагын кем соң?! Вакыты җиткәннәрдән мин берүзем калдым... Димәк, чират минеке... Шуның өстенә хәлем дә җиңелдән түгел. Соңгы айларда кабатланып торган авырулардан мин бик хәлсезләнеп калдым. Элекке нормаль хәлемә кайта алганым юк. Күрәсең, бу афәтле ел минем өчен дә соңгысы булуы бик мөмкин...

Әмма үлемнең никадәр әшәке нәрсә икәнен белсәм дә, үземдә бернинди курку-каушау кебек борчылу сизмим. Гаҗәп, мин бик тыныч... Моның сәбәбе — тәкъдиремне бер Аллага тапшыруда түгел микән?! Алдан юрап, гүя Аллаһы Тәгаләнең ачуын китерәсем килми... Тик аңардан бер генә үтенечем бар: җан бирүләрем җиңел генә узсын иде... Атамның инәсе әбекәй мәрхүм намаз арты саен: «Йа Хода, кыска сырхау, ансат үлем бир!» —

дип дога кыла иде. Аның шушы догасы минем күңелемә бала чактан ук кереп калды... Әмма 70 ел буена без Алланы инкарь итеп, динне бөтенләй ташлап, чын дәһриләр булып яшәдек. Хәзер исә тиз генә тәүбәгә килеп, яңадан Аңа сыенмакчы булабыз. Ләкин безнең бу ашыгып «тәүбә»гә килүебезне Аллаһы Тәгалә кабул итәр микән соң?!

Ә юбилей һаман дәвам итә. Бөтен март буена сузылды диярлек. Хәлем әйбәттән булмаса да, төрле очрашуларга күп йөрергә туры килде. Үземә килүчеләр дә аз булмады. Бу юлы Казан минем туган көнемне бик югары күтәрде. Моның төп сәбәбе — Минтимер Шәриповичның минем хакта әйткән мактау сүзләре булса кирәк... Югарыдан чыккан сүзнең әһәмияте хәзер дә бик зур икән әле. Күзгә ташланмыйча тыныч кына яшәгән фәкыйрегез турында матбугат битләрендә язулар да күп булды, фотога төшерү, интервью алулар да аз булмады. Хәтта Санкт-Петербург художнигы рәсемемне, Казан скульпторы бюстымны да ясады. Элек Казан художниклары миңа сәлам дә бирмиләр иде...

...Айга якын сузылган юбилей шаукымы ничектер кинәт кенә сүрелде. Югарыда һәм Язучылар берлегендә: «Бабай үзенә тиешлесен алды, җитеп торыр»,— диделәр бугай. Карчыгым белән икебезгә шул ук Илгиз әфәнде Хәйруллин ярдәме белән «Казан» санаториесенә 11 көнлек путевка да бирделәр. Ял итеп алу миңа бик кирәк иде — хәлсезлегем бәйрәм мәшәкатьләре белән шактый ук көчәйгән дә иде.

Һәрхәлдә, Казан үз эшен эшләде. Туган көнемне бик югары итеп уздырды. Мин бик канәгать — рәхмәттән башка сүзем юк. ...Әмма бик җитди ике мәсьәлә мине гел борчып тора. Шулар турында уйланудан мин һич котыла алмыйм. Болар — Мәскәү белән Уфага бару мәсьәләсе. Минем туган көнемне билгеләп үтү аларда да булырга тиеш, янәсе... Юбилейга килгән Мәскәү кунаклары шул чакта ук миңа бик өзеп әйттеләр: «Киләсең, каршы алабыз, бәйрәмеңне бик шәп итеп үткәрәбез, сиңа бер мәшәкате дә булмаячак»,— диделәр... Ә мин, үз хәлемне онытып, таза ир чагымдагы шикелле, ансат кына риза булдым: нигә бармаска, нигә мөхтәрәм кунак булып, мактаулар ишетеп, бер сыйланып кайтмаска?! Гомер ике килми ләбаса!.. Без хәтта бару вакытын да билгеләдек: июньнең беренче яртысында мине каршы алырга тиешләр...

Мәгәр акыл дигән нәрсә кешедә соңрак уяна. Кем

чакыруы буенча мин Мәскәүгә барырга тиеш — үзеннән-үзе туган иң беренче сорау менә шушы. Чакырып китүче 3-4 кеше минем иң якын дусларым. Алар минем Мәскәүгә баруымны чын ихластан телиләр. Әмма алар чакыруы гына җитәме? Мәскәүдә бит бик көчле татар җәмәгатьчелеге бар. Аларның бик абруйлы, танылган зур лидерлары бар — мәсәлән, генерал-полковник Рәсим Акчурин... Мине чакыруда алар читтә калырга тиеш түгелдер дип уйлыйм. Сүз бит карт язучының 90 яшен билгеләп үтү турында бара. Аңа беркадәр рәсми төс бирү кирәктер, мөгаен. Димәк, мине чакыру да алар эше булырга тиеш — әйтик, берәр җәмәгать оешмасы исеменнән... Ләкин бармы аларда андый теләк?

Менә шушы мәсьәләгә беркадәр ачыклык кертү өчен, Мәскәүдәге дустым Әкъдәм Борһановка шалтыратып, аңа кайбер теләкләремне әйттем: мине чакыру рәсми рәвештә булырга тиеш. Шулай ук каршылау, озату, берничә көнгә кунакханәгә урнаштыруны да алар кайгыртырга тиешләр.

Шактый вакыт узуга карамастан, минем бу мөрәҗәгатемә җавап булмады... Мәсьәлә ачыкланды шикелле, тик нәтиҗә генә ясарга кирәктер, ахрысы... Чынлап уйлаганда, минем Мәскәүгә баруым кем өчен, нәрсә өчен кирәк ул? Кешеләрне хәзер бөтенләй башка уй, башка мәшәкатьләр басып китте. Адәм баласына яшәргә кирәк бит! Татар әдәбиятын укымый, татар язучыларын белми, телен оныта, дип минем һич тә зарланасым килми. Күп чәйнәлгән чүбек. Без инде күптән бербөтен, оешкан милләт түгел. Һәркем үзенең утырып калган җирендә, заманга яраклашып яшәргә тырыша. Мәсәлән, Мәскәү татарларына, аеруча Сергач мишәрләренә, елына бер тапкыр Сабан туе булса, ике тапкыр гаетне бәйрәм итсә, аңа бу имансыз заманда хак мөселман булып йөрер өчен шул җиткән...

...Яңадан Әкъдәскә шалтыратып, бара алмавымны әйткәч, ул минем белән бик тиз килеште. Мәскәү хәлләрен бик яхшы белә ул — ә минем өстән әйтерсең тау төште.

...Икенчесе — Уфага бару мәсьәләсе. Бу хакта сүз инде былтыр ук башланган иде. Башкортстан — минем туып-үскән җирем. Бәс, шулай булгач, минем 90 яшемне Уфага кайтып үткәрүне дә күпләр зарури бер эш дип саныйлар. Бу хакта дус-ишләр ниндидер хәрәкәт тә башлаганнар иде. Мәгәр минем үзем өчен Уфага кайту шактый каты бер чикләвек дияр идем. Бу яшемдә юл мәшәкатьләрен күтәрү җиңел булмасын белү өстенә, мине ан-

дагы татар-башкорт арасының киеренке булуы да бик борчый иде. Кагыласым килми иде минем ул мәсьәләгә, әмма ирексездән кагылуым да мөмкин. Җанны кыерсыткан мәсьәлә... Ләкин халыкның әйткән сүзе бар: кунак булсаң, тыйнак бул, дигәннәр.

Минем Уфада булуым бер-ике көн генә дәвам итәргә тиеш. Тагын бер-ике көн — туган-үскән җирләрне карап узу... Шуннан инде туп-туры Казанга! Минем янымда карчыгым йә кызым булырга тиеш. Мин инде ялгыз йөри алмыйм.

Менә шуларның һәммәсен дә уйлагач, мин Уфадагы иптәшләргә үз таләбемне әйтүне кирәк таптым: иң элек чакыру рәсми булырга тиеш. Моны бары Башкортстан Язучылар союзы исеменнән эшләргә кирәк... 40—50 ел буена мин шушы Союзны белдем. Барлык замандашларым да — башкорты һәм татары — шушы Союзның әгъзалары иде. Аларның бик күбесе юк инде, әмма минем хәтеремдә барышулар гына. Аларның якты истәлегенә мин тугрылыклы булып калырга тиеш. Моны татар да, башкорт та аңлар дип ышанам...

Тагын бер теләгем: Президент аппараты минем бәйрәмнән читтә калмасын иде. Мортаза Гобәйдуллович Рәхимов үзе дә мине белә. Аның игътибарын җәлеп итү үземә кирәктән түгел — мин инде яшен яшәгән, ашын ашаган карт әдип. Бу — татар әдәбиятына булган ихтирамын күрсәтү өчен. Татар әдәбиятының башкорт әдәбиятына йогынтысы һәм хезмәте аз булмады диясем килә.

...Инде туган елым да узып бара, ләкин Уфадан бертөрле дә хәбәр алганым юк. Сәбәбен дә ачык кына белмим. Дөньяның эше бетәрлек түгел. Ә эшләр куера гына бара. Сайлаулар якынлаша. Бу инде, үзегез дә беләсез, бөтен җитәкчеләрне һәм алар тирәсендәге чиновникларны баш-аягы белән йота торган эш... Башкасы турында уйларга вакыт та юк. Туган көннәрне дә хәзергә онытып торырга туры килә.

Бу минем фараз кылуым гына. Чөнки бөтен Русиядә бер үк ситуация: сайлаулар белән шашкан чагы...

Уфага минем бертөрле дә дәгъвам юк. Андагы хәлләрне белмәсәм дә аңлыйм кебек. Туган көнне билгеләп үтү булмый кала икән, мин моңа бик тыныч караячакмын... Уфада мин күп булдым, туган-үскән җирләрне дә җитәрлек күрдем — яңадан махсус йөреп чыгуны кирәк тапмыйм. Кайта алмавым бары минем файдага булачак. Болай диюем берәүне дә гаҗәпләндермәсен — хәлем минем шундыйрак... Әмма туган туфрак кеше күңелендә

соңгы сулышына хәтле саклана — тик ул аны вакыты җиткәч калдырып кына китә.

...Шулай да Башкортстан дигән олы Ватанның бер почмагында булу язган икән әле... Хәтерлисездер, минем бәйрәмгә килгән Нажар Нәҗми безне туган районына чакырып киткән иде. Үз исеменнән генә түгел, Дүртөйле хакимияте исеменнән дә: җәйнең матур бер вакытында апа белән килегез, бик әйбәт санаториебыз бар, шунда ял итәрсез, бу безнең сезгә бүләгебез булыр, дигән иде. Соңыннан язган хатларында да ул һаман шул чакыруын кабатлады. Шагыйрьнең безгә үз авылы Миңештене дә (сәер исем), һичшиксез, күрсәтәсе килә иде. Авылында шагыйрьгә яңа йорт салынып ятуын да без инде белә идек.

Июнь ахырында Нажар үзе, хакимият кешесе белән бергә, безгә шалтыратып әйтте: фәлән числога килеп җитегез, яңа килүчеләрне кабул итү шул чакта булачак, диде. Бу инде июнь ахыры — июль башлары иде. Нәкъ шул көннәрдә Уфа татарларының ел да Болгарга сәфәр кыла торган пароходлары килеп җитте. Килүчеләр арасында безгә бик якын кешеләр бар иде, алар белән дә очрашмыйча булмый... Әмма олы шагыйрьнең чын ихластан чакыруын да онытырга ярамый — оныту гафу итмәслек сансызлык булыр иде. Ләкин без икесенә дә өлгердек: уфалылар белән дә очраштык һәм, ике көн соңга калып булса да, Дүртөйлегә дә китеп бардык. (Аз гына соңга калуыбызны мин шалтыратып әйткән идем инде.)

...2 июльдә, көн ахырына табарак, безне Нажар үзе һәм хакимият башлыгы Равил Шәрифҗанович каршы алдылар. Равил әфәнде кабинетында әзрәк хәл-әхвәл сорашып, азрак кына кымыз да эчкәләп алганнан соң, безне хаким ярдәмчесе һәм Нажар «Агыйдел» санаториесенә илтеп куйдылар. Болай тәфсилләп язуымның сәбәбе — безне ял итәргә килүче дип кенә түгел, чын кунак сыйфатында кабул иттеләр. Безгә дигән ике бүлмәне алдан әзерләп, саклап торганнар. Хәтта безне китерә килгән кызым белән кияүгә дә кунып китәр өчен аерым бүлмә бирделәр... Әнә шулай урнаштык без...

Санаторий үзе бик матур итеп салынган, бик пөхтә, бик иркен яңа бина. Казан тирәсендә моның кебек матур санаторийны минем әле күргәнем юк. Ул Агыйделнең биек, текә яры өстендә берничә йөз метр читтәрәк тора. Өч ягы урман, бер ягы яшел кырларга чыга... Бик тыныч, бик аулак урын — һавасы сулап туймаслык.

Нажар безне бер дә онытмый. Әледән-әле килгәләп, хәлебезне һаман белеп тора. Ул бит татар әдәбиятының бик күптәнге дусты. Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәр замандашы — шулар иде аның иң якыннары да.

Безнең танышлык та бик күптәннән килә. Мәгәр ике арадагы якынлык аеруча соңгы елларда көчәйде. Сәбәбе ачык булса кирәк: без элекке дус-ишләрне югалтып бетердек... Уфада — ул, Казанда мин ялгыз. Без хәзер бер-беребезгә мохтаҗ замандашлар һәм фикердәшләр... Әмма шулай да без бер-беребезне белеп бетермәгәнбез икән әле. Чынлап белү өчен Дүртөйле кирәк булды. Мине, мәсәлән, Нәҗминең кунакчыллыгы гаҗәпләндерде. Кунакчыл булыр өчен бер дуслык кына җитми, моның өчен күңел байлыгы белән юмарт кул да кирәктер инде. Болар кешегә тумыштан бирелә. Беренче тапкыр мин Нәҗмидә шуларны күрдем. Аның аркасында көн дә кымыз эчтем. Авылдан китереп тордылар. Кымыз минем өчен иң тансык сый иде.

...Ике көн соңрак Түбән Камадан Азат Зыятдинов үз машинасында безнең арттан Дүртөйлегә килеп җитте. Азатны да мин гаҗәеп кешеләрнең берсе дияр идем. Уйлап карагыз: килүенең максаты — миңа ияреп, минем туып-үскән җирләрне күреп кайту икән... Моның өчен нинди тәвәккәллек кирәк?! Ә миндә туган җирләрне күрү теләге юк. Кадерле ялым кызганыч, хәлем дә шәптән түгел... Шуннан соң Азат әфәндегез хәләл җефете Сания ханымны янына утыртты да тере «классик» чыккан шәһәрне күрер өчен, 200 километрдагы Дәүләкәнгә китеп тә барды. Шул кечкенә шәһәрнең урамнарында йөреп, кешеләрдән сорашып, мин үскән йортны эзләгән... Аңа күрсәткәннәр, ләкин ялгыш — без торган йортны белүче юк диярлек... Икенче көнне Азат дустым «Аслы күл» буйларын да әйләнеп, матурлыгына сокланып, көмештәй суында коенып, өченче көн дигәндә кайтып керде. Бик шат, бик канәгать — шушы сәяхәт өчен вакытын да, бензинен дә кызганып тормады. Тик миңа, «классик» булума карамастан, мондый гадәттән тыш игътибарны күтәрүе җиңел түгел иде. Оят булыр шикелле...

...Гомумән, без «Агыйдел»дә бик әйбәт кешеләр белән очраштык һәм таныштык. Уфадан килгән академик Марат Әхсәнович һәм аның бик сылу бичәсе Айсылу ханым белән без бер вакытта ял иттек. Алар Казанда чакта ук инде без якын танышлар идек. Монда очрашу ике як өчен дә бик куанычлы булды дияр идем.

Аннары Уфа шәһәре башлыгының урынбасары Мидхәт Әхмәтханович белән танышу да бик матур тәэсир калдырды. Зур урын биләүче булса да, ул бик тыйнак, бик әдәпле кеше иде. Бер өстәлдә утырып ашадык. Түрәлеген бер вакытта да сиздермәде, безгә дә бик игътибарлы булды. Үзе Баймак ягыннан чыккан чын башкорт икән...

Шулай ук санаторийның баш табибы Фәһимә ханым да безгә ачык йөз күрсәтеп, хәлебезне гел белешеп торды... Әнә шулай безне кайгыртучы башкалар турында да язып китсәм, тиз генә очына чыга алмам дип куркам.

Бу очрашуларның минем өчен кызык ягы шунда ки, Дүртөйледә мин татар белән башкорт арасында бер төрле дә аерма сизмәдем диярлек. Бәлки, монда татар күбрәк булганга күрәдер... Ләкин хикмәт анда гына түгел шикелле. Бигрәк тә тел мәсьәләсендә. Әгәр дөрес сизгән булсам, монда ниндидер бер гибрид тел әкрен генә көчәя бара кебек... Ике телнең якынлыгы күптән билгеле. Татар һәм башкортта уртак сүзләр (ягъни бер үк сүзләр) 90 проценттан да ким түгел. Соңыннан башкорт үзе керткән яки татар әдәбиятыннан күчкән сүзләр калган 10 процентка кереп бетә торгандыр. Әмма төп аерма сүзләрнең әйтелешендә иде: безнеңчә — сәнәк, башкортча — һәнәк; без «бармый», «килми» дибез, башкортлар «бармай», «килмәй» диләр...

Менә шушы фонетик аерма әкренләп югала кебек. Колак салам — татар сүзе — чын татарча, мәгәр әйтелеше башкортча... Бигрәк тә сүзнең ахырын — фигыльне (глаголны) башкортчага әйләндерәләр.

Ике республиканың иҗтимагый тормышында да аерма шактый ук сизелә. Башкортстанда совет заманы дип әйтерлек... Мондый аерма телдә дә чагылмыйча калмый, әлбәттә. Уфа татарларында, мәсәлән, әфәнде, ханым, туташ дигән сүзләр юк. (Белгәннәре дә кулланмыйлар.) Совет елларындагы шикелле, кешеләр бер-берсенә «фәлән фәләнович» дип кенә дәшәләр. (Шулай ук хатын-кызлар да.) Бер хатынга китап биргәндә мин «ханым» дип яза башлаган идем, алай язмагыз, бездә мондый сүзне белмиләр, диде ул. Аңа «фәлән фәләновага» дип язу кадерлерәк иде...

Аннары телләрнең ераклашуында тагын бер җитди сәбәп, ул да булса, безнең соңгы елларда гарәп сүзләрен телебезгә кирәксә-кирәкмәсә дә күпләп кертүебез дияр идем. Аларны чүпләп утырырга вакыт кызганыч, шуңа

күрә бер генә мисал белән чикләнәм. Әйтик, «промышленность» дигән сүз урынына без «сәнәгать» дигән сүзне кullана башладык. Бу — 20 нче елларның башында ук безнең телдән төшеп калган сүз. Әйтелеше ягыннан аңа бик якын, ләкин мәгънәсе бик ерак «сәнгать» сүзе бар бит — бу сүз телебездә кала, әмма «сәнәгать» дигәнен кире кага.

Тукай шуны сизгәндәй, «сәнәгать» урынына башка сүз таба. 1909 елда балалар өчен язган шигырен ул «Кярханә» дип атый. Нәрсә соң ул «кярханә»? 1911 елны Уфада чыккан бик әйбәт гарәп-татар лөгате ул сүзгә менә нинди мәгънә бирә: «Кярханә — төрле нәрсәләр эшләнә торган урын, завод, фабрика...» Димәк, без «кярханә» сүзен файдалана алабыз. Әмма иң яхшысы — завод-фабрикалар сүзен куллану... Телебезгә күптән кергән, халыкка бик аңлашыла, мәгънә ягыннан аерма юк диярлек. Халыкка кергән сүз генә яши ала.

Татар, башкорт арасында чыккан тел җәнҗалын мин беркадәр ишетеп белә идем... Әлбәттә, бу гаять җитди, нечкә мәсьәлә. Ахырда шушы мәсьәлә татар-башкорт арасын бозды да инде. Монда гаеп, минемчә, «атта да, тәртәдә дә бар...» Татар түрә булырга ярата, ә башкорт татарны шуның өчен яратмый. Монда ике төрле язмыш, ике төрле психологиянең роле зур булса кирәк. Ләкин минем бу мәсьәләдә бик тирәнгә кереп акыл сатасым килми иде. Бары тел турында үз фикеремне әйтү белән генә чикләнәсем килә.

Миңа калса, Башкортстанда бер генә тел — башкорт теле генә дәүләт теле булырга тиеш иде. Урыс теле исә бөтен Русия өчен дәүләт теле. Аны Башкортстанда икенче тапкыр дәүләт теле итүнең бер дә кирәге юк иде. (Башкортстан — Русия субъекты.) Урыс теленә өстенлек бирү — татар телен түбәнәйтү, кимсетү булып чыкты. Асылда исә, башкорт белән татар телен дәүләт теле итү дөресрәк булган булыр иде. Ләкин моңа башкорт, әлбәттә, риза булмас иде. Шул сәбәпле аның үз телен генә дәүләт теле итүе белән татар да тизрәк килешә алган булыр иде...

Инде урыс белән татар теленә килсәк, аларның статуслары бер булырга тиеш. Хокуклары, дәрәҗәләре, мөмкинлекләренең тигез, тиң булуы зарур... Милли татулык, иминлек өчен моның әһәмияте бик зур дияр идем.

Менә шушы ноктадан караганда, татарны башкортча сөйләшергә өйрәтеп маташуның да һич тә хаҗәте

юк, минемчә. Телләребез бер дип әйтерлек. Казан татарын мишәрчә сөйләшергә өйрәтү шикелле кирәкмәгән бер эштер... Ул әнә ике халык арасын бозуга гына китерде.

Хәлбуки Башкортстанның киләчәге башкорт һәм татар халкының татулыгы белән бик нык бәйләнгән. Алар бер-берсенә бик кирәк халык. Шушы уңай белән Айсылу ханымнар мәҗлесендә булып узган бик кызыклы бер сөйләшүне искә төшерәсе килә.

...Менә каршымда гына Наҗар утыра. Совет заманында ук татар телен яклап иң кыю шигырь язган башкорт шагыйре. Татар шагыйрьләреннән андый шигырьне яза алучы булмады ул чакта. Без әйтергә кыймаганны башкорт әйтте.

Менә мин — татар язучысы... Башкорт корткасы Акъәби язмышы турында башкорт үзе язмаганны мин яздым. «Әйтелмәгән васыять»не хәзер кем генә белми. Чын мәгънәсендә классик әсәр... Ике әдәбиятның уртак хәзинәсе — бер заманда да онытылачак һәм югалачак түгел. Мәгәр гаҗәбе шунда ки, башкортлар шушы үлемсез әсәрне 20 ел буена башкортчага күчерми тордылар. Кемнеңдер рөхсәте булмагандыр, күрәсең.

...Менә өстәл башында мәҗлес хуҗасы Марат Әхсәнович — ул күбрәк кунакларын сыйлау белән мәшгуль. Әмма Урал эченнән чыккан шушы башкорт егетенең дә фән биеклегенә юлы Казаннан башлана. Ул килгән елларда Казанда Хәмит Мөштәри дигән зур галим бар иде. Марат шуның шәкерте, шуның кул астында үсте, күтәрелде, чын галим булып танылды. Инглиз телен бик яхшы белә, чит илләргә барып, шул телдә лекцияләр укып йөри. Кыскасы, Марат Әхсәнович фәнни дәрәҗәләрнең һәммәсенә дә Казанда иреште. Уфага киткәндә ул инде академик иде. Хәзер Башкортстан Фәннәр академиясенең вице-президенты...

Бу сөйләгәннәрне минем шәрехләп торасым килми. Гыйбрәтле тирән мәгънәсен чукрак кеше дә аңларлык. Бик борыннан килгән рухи якынлык бу... Инде хәзер бер ише башкорт «егетләре» шушы якынлыкны бозарга, татардан читләшергә, милли мәнфәгатьләрен чикләргә тырышалар. Моны ничек дип атарга? Геноцидның ямьсез бер күренеше түгелме бу?! Әмма бу бит Башкортстан зарарына... Башкорт халкының, әйтик, 100дән 99ы моның ише «милли сәясәт»кә каршы булачак. Иманым камил!

...Ихтимал, Айсылу ханымның җырлавы да минем

хыялларны артык канатландырып җибәргәндер. Айсылу гаҗәеп матур җырлый икән. Башкортның озын, татарның моңлы көйләрен җырлап, ул мәҗлесебезне биһуш итте. Ә миңа җитә калды... Үземне белә башлаганнан алып мин шул җырлар белән сихерләнгән кеше. Минем дөньяга чыккан иң беренче әйберем дә «Озын көй тыңлаганда» дип аталган иде.

Озак та үтми, көннәрдән бер көнне Уфадан безнең белән күрешер өчен бер машинада Рәүф Идрисов, хатыны Венера ханым белән, Фәридә ханым Кудашева, минем якын туганым Факиһә апагыз Дүртөйлегә килеп җиттеләр. Күчтәнәчләре белән. Карбызның яңа чыккан чагы иде — Фәридә ханым күчтәнәч итеп, безгә самавыр зурлык карбыз китерде... 200 чакырымнан безне күрер өчен иренмичә килүләре, сүз дә юк, безнең күңелебезне бик күтәрде... Моны бер дуслык кына дип әйтүе дә читен, кешенең кешегә мәрхәмәте, игелеге дип әйтәсе килә. Чын дуслык-туганлык та әнә шуннан башлана.

...Күчтәнәчләр белән чәйләр эчеп, бик матур сөйләшүләр булды. Аннары машиналарына төялеп, кире Уфага кайтып киттеләр. Безгә якты бер истәлек калдырып... Рәхмәт, хәерле юл сезгә!..

...Менә таралышыр көннәр дә килеп җитте. Маратлар бездән бер көн алдан киттеләр. Киткән чакларында якын туганнарча: «Әмирхан абый, берәр нәрсә кирәк булса, йомышың төшсә, безгә хәбәр итегез, кулыбыздан килгәнне эшләрбез»,— диделәр. Фәннәр академиясенә йомышым төшүе бик икеле, әмма яхшы сүз — җан азыгы, диләр ич. Сирәк кешеләрдән генә моны ишетергә була.

Иртәгә китәбез дигән көнне Наҗар Нәҗми безне үз авылына яңа йортын күрсәтергә чакырды. Моңарчы Уфадан җәмәгате Флорида ханым килә алмыйча торды — кичегүнең сәбәбе шуның аркасында иде бугай. Без, бичәләребез белән дүрт кеше, хакимият машинасында 40 километрдагы Миңеште авылына сәгать 3ләрдә барып җиткәнбездер. Авыл очындагы ак кирпечтән салынган чардаклы бер чибәр йорт каршына җитеп туктадык. Безнең инде бу йорт турында хәбәребез бар иде. Хакимият тарафыннан шагыйрь Наҗар Нәҗмигә махсус салынган, зурлыгы һәм матурлыгы белән авылда бердәнбер йорт иде ул...

Без, сәлам биреп кергәч, иң элек йортның үзе белән таныша башладык. Ни дисең — гаҗәпләнү, соклану, бәл-

ки, әзрәк көнләшү дә булгандыр. Йортның түбәнге катында зур гына зал, иркен йокы бүлмәсе, тагын бер аулак бүлмә (килгән-киткәннәр өчен), кухня, ванна бүлмәсе — кыскасы, каланың түрәләр генә тора торган шәп квартирасында ни булса, шуларның һәммәсе дә биредә бар. Ә югарыда, чардак дигәне дә (бәлки, аны мансарда дип атау дөресрәк булыр) шагыйрьнең Агыйдел буйларына караган зур тәрәзәле эш бүлмәсе.

Күпмегә төшкәндер инде бу йорт. Җитмәсә, аның күп җиһазларын да Дүртөйле хакимияте үзе алып куйган. Яңа йорт белән танышып чыккач, олы шагыйрьгә нинди зур игътибар һәм хөрмәт дип әйтәсе килгән иде. Ләкин бу сүзләрне бер шагыйрьгә түгел, 99 шагыйрьгә дә әйтергә ярый торгандыр. Алар да игътибар белән хөрмәткә лаек. Тик һәммәсенә дә яңа йортлар салдырып тормаслар. Бик сирәкләр өчен генә эшләнә ул. Шулай да минем беренче күрүем генә түгел. Мин үскән Дәүләкәндә нәкъ шушындый йортны Әхияр Хәкимовка да салып биргәннәр. Аның туган авылы Дәүләкән районына керә. Яңа йорт салып бирү өчен шул җиткән. Хәтта аның башкорт булуы да шарт түгел... Менә шигырьләрен саф башкортча язучы, башкортча бик оста сөйли дә белүче чын татарның «аксөяге» булган шагыйрьгә туган авылында йорт салып яталар. Бәлки, аныкы менә бу йорттан шәбрәк тә, зуррак та булыр әле. Ул бик таләпчән кеше...

Дөресен генә әйткәндә, мин Башкортстан хөкүмәтенең язучыларга йортлар салдыруда бу кадәр юмартлык күрсәтүен аңлый алганым юк. Максат нәрсәдә? Башкаларны шаккатырыр өченме?.. Әйтик, Наҗар Нәҗмигә килгәндә, берәүнең дә моңа исе китми. Наҗарның нинди шагыйрь икәнен барыбыз да бик яхшы белә.

Әмма мине монда күргәннәр белән үзебездәге хәлләрне чагыштырып карау бик нык борчый. Аерма тирән чокырдай зур шул. Ишетүемә караганда, Уфада фатирсыз язучы юк икән. Күптән ике төрле пенсия алалар: берсе — хөкүмәттән, икенчесе — Президент Рәхимовтан. Хәтта Ельциннан өченче пенсияне алучы да бар. (Исеме һәркемгә мәгълүм.) Иҗат йортларына юлламаны да Мәскәүдән шактый зур ташлама белән алалар.

Боларның берсе дә бездә юк. 260 язучы ничек яши, нәрсә ашый, нәрсә кия — моны берәү дә белми. Татарстан хөкүмәте акыл иясе язучыларга, тулаем алганда, бик игътибарсыз. Әлбәттә, аның эше күп, ул әнә шәһәребезне матурлый. Бик кирәкле эш, әмма кешенең рухи дөньясын матурлаучыларны да онытмаска кирәк иде.

Әле реформа башланган чакларда ук Ринат Мөхәммәдиев безгә: «Президент өстәлендә олы яшьтәге хөрмәтле язучыларның исемлеге ята. Аларга ай саен акчалата ярдәм күрсәтеләчәк. Бу хактагы Указга бүген булмаса, иртәгә кул куелачак»,— дигән иде. Ринат шул сүзләрне 3 ел буена кабатлады-кабатлады да ахырда ташлады. Ә исемлектәгеләр кул куйганны көттеләр-көттеләр дә берәмберәм Яңа Бистәгә китеп тә беттеләр. Бер мин генә торып калдым шикелле... Инде «яңа хөрмәт ияләре» өлгереп җитәчәк. Аларны ни көтә — Хода белсен!

Мин татар белән башкорт арасындагы бу тикле аерманы аңлаудан гаҗизмен: әллә безнең Татарстан Башкортстанга караганда күп тапкыр ярлырак; әллә инде безнең мөхтәрәм Президентыбыз артык саран кешеме?!

...Флорида ханымның табыны бик мул иде. Кайсын эчәргә, кайсыннан башлап ашарга да белмәссең. Ләкин миңа иң ошаганы кымыз иде... Мәҗлес, әлбәттә, бик күңелле узды. Сүзләр сөйләшеп бетерерлек түгел иде. Шулай да юлга кичтән әзерләнәсебез булгач, без иртә кузгалдык... Ә икенче көнне инде Наҗар күчтәнәчләре һәм зур бутил кымызы белән безне озатырга иртүк килеп тә җитте. Сәгать 8ләрдәме икән, без ике машинада юлга да чыктык. Безне Казанга хәтле Дүртөйле машинасы илтәчәк. (Бу да бит алар өчен өстәмә мәшәкать.) Азатлар Чаллыга хәтле безне озата барачаклар... Санаторийда кеше аз калган иде инде. Безне баш табиб Фәһимә ханым, Наҗар, шәфкать туташлары чәчәкләр биреп бик җылы озатып калдылар...

...Кеше кирәк!.. Яхшымы-начармы, яшәр өчен кеше кирәк. Дөньясы шулай корылган. Әйтик, берәүләргә дошман кирәк — дошманы булса, ул үзенең кем икәнлеген күрсәтә алачак. Ходай мине бу сыйфаттан мәхрүм иткән. Мин үземә дошман эзләмәдем. Кимсетүчеләрдән үч ала белмәдем, кеше өстеннән әләк белән обкомнарга барып йөрмәдем... Миңа фикердәш кирәк иде. Бу — җан таләбе... Фикердәш белән серләшеп кенә түгел, бәхәсләшеп тә була, әмма дуслык кала.

Мин үземә фикердәшләр таптым. Бәхетемдер инде, алар һәммәсе дә бик ышанычлы, затлы кешеләр иде. Хәзер инде мин ялгыз бер карт... Көлү бетте, күз яшьләре кипте — замана әнә шулай безне корытты...

Мин инде авыру кеше, вакытым да, бәлки, җитә торгандыр. Ләкин гаҗәеп бер хәл: мине хөрмәт итүче яхшы кешеләр бар чагында, мин дә озаграк яшәрмен төс-

ле. Фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килсен иде.

...Юбилейдан алган иң беренче сабагым — кешеләрне тану булды...

P.S. Бу язманы мин 6 сентябрьдә, ниһаять, «Мәдәни җомга»га тапшырдым. Редакциядән килеп алдылар. Шул ук көнне бераз соңрак Роберт Миңнуллин миңа шалтыратып әйтте: «Әмирхан абый, бүген 6 сентябрь иртәсендә, операциядән соң, Нажар Нәҗми вафат булган»,— диде.

Һуштан яздырырлык бу хәбәрнең тәэсирен мин язып тора алмыйм. Тик бер генә нәрсәне беләм: Нажарның үлеме минем үз авыруымны гүя бермә-бер көчәйтте. Яшәүнең гүя мәгънәсе калмады...

*Сентябрь, 1999*
*«Мәдәни җомга», 1999*

## ЭЧТӘЛЕК

Касыймга сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Мәгънәле яшәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Бер сорауга бер җавап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Чынбарлык һәм туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Халыкның күзен ача белү дә кирәк . . . . . . . . . . . . 34
Тәвәккәллек телим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Татар мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Сарьян . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Кем җаваплы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Ялганны яклау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Президент Минтимер Шәймиевкә язучы Әмирхан Еникидән ачык хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
«Биектән карап торасым килә» . . . . . . . . . . . . . . 121
Кем хаклы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Фронт дәфтәреннән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Кояш баер алдыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Сихәтләнү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 260
Хаинлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 264
Без дә бардык Төркиягә! . . . . . . . . . . . . . . . . . 266
Сөртенү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 280
...Тагын бер елның соңгы көннәре . . . . . . . . . . . . 282
Дөнья безне танысын! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 285
Күңел йолдызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 290
Бер хатирә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 293
Шәхес . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 297
Нәгыймә Таҗдарова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 304
Татар баласына урысча белмәү куркынычы янамый . . . . . . 338
Ялгышырга хакыбыз юк . . . . . . . . . . . . . . . . . . 340
Гөмбәгә бару . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 344
Ченәкәй кем ул? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 360
Санаулы көннәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 367
Таң ата да кич була . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 420
Татулыкны гаделлек белән тигезлек кенә саклый ала . . . . . 444
Игезәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 448
Юбилей сабаклары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 449

Литературно-художественное издание

*Амирхан Еники*
*(Еникеев Амирхан Нигметзянович)*

ТОМ 5

**ПУБЛИЦИСТИЧЕСКИЕ ЗАМЕТКИ**
**СТАТЬИ**

(на татарском языке)

Нәшрият мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *В.В.Фомин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, М.Ш.Хәйруллина, Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 25.12.2003. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 25,20+ф.0,21+вкл.1,68.
Шартлы буяу-оттиск 27,20. Нәшер-хисап табагы 27,15+ф.0,36+вкл.1,60.
Тиражы 5000. Заказ Я-868.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.